КАЮМ
НАСЫЙРИ

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ДҮРТ ТОМДА

**3**

том

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)+82
Н 26

Төзүчесе, гарәп графикасындагы аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы
***Хуҗиәхмәт Мәхмутов***

**Насыйри Каюм**
Н 26 Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том.— Казан: Татар.кит. нәшр., 2005.— 384 б.

Энциклопедист-галим, әдип һәм мәгърифәтче Каюм Насыйри «Сайланма әсәрләре»нең бу томына, нигездә, ул җыйган халык иҗаты әсәрләре, аның фольклористикага, төбәк тарихына, татар этнографиясенә караган гыйльми хезмәтләре тупланды. Китапта шулай ук госманлы теленнән иҗади эшкәртелгән «Гөлрох һәм Камәрҗан әкиятләре», төрле фәннәргә караган хезмәтләреннән өзекләр, авторның шәхси хатлары урнаштырылды.

ISBN 5-298-04085-3 © Татарстан китап нәшрияты, 2005

## КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ

Әдип-мәгърифәтче һәм энциклопедист-галим Каюм Насыйри үзенең хезмәтләре белән татар фольклористикасы тарихында да тирән эз калдырды. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге, Х.Ярми билгеләп үткәнчә, нигездә өч төп юнәлештә барды. Беренчедән, ул, татар фольклорын турыдан-туры халыкның үз авызыннан язып алып, тупланган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирде. Икенчедән, үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, аның дөньяга карашы белән башка халыкларны таныштыру максатында, К.Насыйри татар халык иҗаты әсәрләренең иң характерлы үрнәкләрен рус телендә бастырып чыгаруга күп көч куйды. Өченчедән, мәгърифәтче-галим Көнчыгыш фольклорын җентекләп өйрәнде һәм аның күп кенә үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итеп бастырды[1].

Әлбәттә, беренче юнәлеш дигәнне, ягъни фольклорны җыю һәм бастыруны, киңрәк һәм тирәнрәк мәгънәдә аңларга кирәк. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм матбугатка чыгару процессында К.Насыйри аларны, билгеле бер системага салып, жанрларга аерды, бу жанрларга — билгеләмәләр, ә аерым әсәрләргә искәрмәләр, аңлатмалар бирде. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: К.Насыйриның фольклористик эшчәнлеге бөтенләй буш урында башланмады. Аның элгәрләре һәм замандашлары М.Иванов, Г.Балинт, Г.Ваһапов, С.Кукляшев, М.Салихов, Г.Фәезханов, Т.Яхин һәм башкалар тарафыннан да кызыклы һәм үз заманы өчен бай гына фольклор җыентыклары дөньяга чыгарылды. Ләкин, болар белән чагыштырганда, К.Насыйри хезмәтләре, бер яктан, материалның күләме һәм сыйфаты, фольклорның барлык жанрларын да диярлек үз эчләренә алулары

[1] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты.— Казан, 1967.— 30—31 б.

белән аерылып тордылар. К.Насыйриның Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә татар фольклоры әсәрләрен тапшыруы уңае белән күренекле ориенталист Н.Ф.Катанов болай дип язды: «Бу көнгә кадәр Казан татарларының халык иҗаты һәйкәлләрен җыйнаучылардан берәүнең дә бу хәтле күп мәкальләр һәм җырлар тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тапшырган материаллар, бөтен гомерен үз халкы арасында үткәреп, аны төрле яклап өйрәнүе сәбәпле, аның үз халкының тормышы һәм теле белән яхшы таныш икәнлеген бик ачык күрсәтә»[1].

Икенче яктан, фольклорны җыю һәм бастыру, аны лингвистик, тарихи-этнографик хезмәтләрдә, хрестоматияләрдә, уку китапларында файдаланудан тыш (боларны аның элгәрләре дә эшләде), К.Насыйри халык иҗатын махсус фән буларак өйрәнә башлауга нигез салды. «Каюм Насыйри,— дип язды Х.Бәдигый,— Казан татарларының үз араларыннан чыккан һәм үзен чолгап алган надан муллалар, ишаннар, суфилар дин исеменнән халык җырларын, бәетләрен, такмакларын, көйләрен тыеп торганда, ул, аларның әһәмиятен аңлап, *аларны өйрәнүне аерым бер гыйлем санап* (курсив безнеке.— *Х.М.*), шул бабда ишеткән, күргән материалларының берсен дә югалтмыйча дикъкатьләп өйрәнә һәм җыя баручы үз галимебездер»[2].

К.Насыйрига бирелгән бу бәяләрнең никадәр хаклы икәнлекләрен күрү өчен, хәзер аның фольклорга караган хезмәтләрен янә бер кат барлап, кыскача гына булса да күздән кичереп чыгыйк. Дөрес, К.Насыйри үзе җыйган материалларны махсус фольклор җыентыклары итеп чыгара алмады, ләкин ул аларга үзенең аеруча әһәмиятле хезмәтләрендә махсус бүлекләр багышлау мөмкинлеген тапты.

— 1880 елда басылып чыккан «Кырык бакча» китабының кырыгынчы бакчасы (бүлеге) түбәндәге фольклор әсәрләрен эченә ала: 296 мәкаль, 116 кыска җыр, «Сәламнамә», «Мәдех чәй», «Уңмаган килен» һәм «Әбъят» исемле бәетләр, «Зиһен сынашмак» исеме астында бирелгән өч табышмак-мәсьәлә («Ике көтүче», «Кәҗә, бүре, кәбестә», «Өч сәүдәгәр»).

---

[1] Н а с ы р о в К. Образцы народной литературы казанских татар // Известия Общества археологии, истории, этнографии (ОАИЭ).— 1895—1896.— Т.13.— Вып. 5.— С.375.

[2] Б ә д и г ы й Х. К.Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлындагы хезмәтләре // Каюм Насыйри мәҗмугасы.— Казан, 1922.— 104–112 б.

— 1884 елда дөнья күргән «Фәвакиһел җөләса» китабының соңгы бүлеге тулысынча диярлек халык иҗаты әсәрләренә багышланган*. Дөрес, аларның шактый өлеше «Кырык бакча»дагы материалларны кабатлый, ләкин яңа әсәрләр дә өстәлгән. Аеруча мөһиме: һәр жанрга автор кыскача билгеләмә бирә һәм бик күп әсәрләрне фәнни комментарийлар белән бастыра. Аларга без әле соңрак тукталырбыз. Бу китапка кергән фольклор әсәрләре: 27 табышмак (болары «Кырык бакча»да юк иде), 117 кыска җыр, «Әбъят мәхбүбләргә сәламнамә», «Әбъят чәй бәянында», «Әбъят уңмаган килен бәянында» исемле 3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтем.

— Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре. Нигездә, өстә телгә алынган ике китаптагы материалларны кабатлаучы 28 табышмак, 244 мәкаль һәм әйтем, 116 кыска җыр һәм «Гыйшык хәлләре» дигән бәет, дөресрәге, кыска җырларга тартым шигъри куплетлар (алар «Кырык бакча»да «Әбъят» исеме белән бирелгән иде). Бу материаллар, татар телендә һәм русчага тәрҗемә ителеп, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләр»енең 1896 елгы 13 нче томында басылдылар.

— Шушы ук «Хәбәрләр»нең 1900 елгы 16 нчы томында К.Насыйри П.А.Поляков белән берлектә «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» дигән тагын бер зур хезмәт бастыра. Анда халкыбызның 11 әкияте («Салам Торхан», «Ахмак угыл», «Үги кыз», «Гөлнәзек», «Байдек», «Өч угыл», «Акыллы угыл», «Төлке», «Мәче берлән Аю», «Аю берлән Төлке», «Сандугач берлән Бытбылдык») татар һәм рус телләрендә дөнья күрде. Хезмәтнең П.А.Поляков тарафыннан язылган теоретик өлеше дә бар.

Каюм Насыйри үзе җыйнаган фольклор материалларының шактый өлешен «Календарь»ларында бастырып килде:

— 1871 елга «Календарь»да «Халык арасында тәҗрибә буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында» дигән баш астында, күк җисемнәренең, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышларына карап, һава торышының нинди була-

---

* Әлеге әсәрләр совет чоры җыентыкларында аерым кыскартулар белән басылып килде. Бу бигрәк тә дәлил, үрнәк, чагыштыру өчен китерелгән Коръән аятьләренә, хәдисләргә, гарәп мәкальләренә кагыла. Ошбу томда алар оригиналдагыча бирелә.— *Х.М.*

чагын билгеләүче 81 сынамыш китерелгән. Шулар ук 1879 ел өчен «Календарь»да кабат басылганнар.

— 1876 елга «Календарь»да «Халык телендәге сүзләр» исеме белән һәр айның билгеле бер көнендә һава хәленең нинди булуына карап, киләчәктә һава торышы һәм ашлык-яшелчә уңышы нинди булачагын билгеләүче сынамышлар. Барысы — 65 берәмлек.

— 1881 елга «Календарь»да «Казан шәһәре хакында риваятьләр» урнаштырылган (алар эченә «Шигали бәете» һәм «Казан алынганы хакында» дигән 2 бәет кергән). Болардан тыш шушы ук «Календарь»да «Казанның кадимге ихатасы», «Әмәт тавы», «Хан мәсҗете», «Кабан күле», «Казан бәетендә мәзкүр Үлмәс вә Әбелхалык», «Арча кыры» хакында риваятьләр дә басылган.

— 1883 елга «Календарь»да «Алып адәмнәр» хакындагы легенда бирелгән.

Каюм Насыйри халык иҗаты әсәрләрен үзенең грамматика китапларында, сүзлекләрендә, тарих һәм этнографиягә караган хезмәтләрендә дә бастыра килде.

— Татар теленең «Ләһҗәи татари» исемле ике томлык аңлатмалы сүзлегендә 150 дән артык мәкаль һәм әйтем, шулай ук байтак җыр, такмак, табышмак текстлары очрый. Болар аерым сүзләрнең мәгънәләрен ачучы контекстлар сыйфатында китереләләр.

— «Әнмүзәҗ» грамматикасының «Тәгъризат» бүлекчәсендә 68 әйтем һәм фразеологизм китерелә һәм аларның аңлатмалары бирелә.

— «Хисаплык» дәреслегендә «Йөз каз», «Бүре, кәҗә, кәбестә» шикелле 7 табышмак-мәсьәлә урнаштырылган.

— «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дигән хезмәтендә күп кенә йолалар, ышанулар, им-том текстлары очрый[1].

Югарыда санап үтелгән хезмәтләр К.Насыйриның үзе исән чагында ук дөнья күрделәр. Болардан тыш галимнең кулъязма

---

[1] Насыров К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского русского географического общества по отделению этнографии.— СПб., 1880.— Т.6.— С.247–270.

мирасында да фольклор әсәрләре байтак сакланган. 1926 елда «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» дигән җыентык чыга. Шунда галимнең «Аксак Каратун, Пугачев һәм Ишбулат мулла хакында риваятьләр», «Археология материаллары» кебек хезмәтләре беренче кат басылдылар. Соңгысында автор элеккеге Зөя өязе авыллары хакында күпсанлы риваятьләр китерә. К.Насыйриның Казан дәүләт университеты китапханәсендә «780-Т», «814-Т» шифрлары белән сакланучы кулъязмаларында шактый санда җырлар, мәкаль, әйтем, сынамышлар, «Төлке берлән Әтәч», «Әләкче» дигән әкиятләр, Шүрәле һәм Былтыр турында легенда һ.б.лар теркәлеп калган. Бу әсәрләрнең күбесе К.Насыйриның 150 еллыгы уңае белән чыгарылган икетомлык «Сайланма әсәрләр»енә кертелде.

Н.Ф.Катанов хәбәр иткәнчә, К.Насыйриның фольклор җыйналмасында «Рус-француз сугышы» бәетенең дә бер кулъязма варианты булган. Аның ахырына К.Насыйри кулы белән «1855 елның 12 февралендә тәмамланды» дигән сүзләр дә язылган. Бу бәет Н.Ф.Катановның «Исторические песни казанских татар» исемле хезмәтендә «Николай бәете» исеме белән басылып чыга[2].

Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре турындагы хезмәтендә К.Насыйри күп кенә тылсымлы әкиятләрнең сюжетларын, образларын (дию пәрие, убырлы карчык, юха кыз, кырык потлы күсәкне кулында кечкенә таяк белән уйнаган шикелле генә итеп әйләндерүче ун яшьлек батыр һ.б.) киң файдалана. Күрәсең, бу фактларны ул йә хәтердән китергәндер, йә аның җыйналмасында тылсымлы әкиятләр текстлары да булып, алар югалганнардыр.

Шул рәвешчә, без К.Насыйри тарафыннан татар халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастыру юлында гаять зур эш башкарылган булуын күрәбез. Әлбәттә, бу эшчәнлекнең нигезендә фольклорга зур мәхәббәт һәм аның әһәмиятен тирәнтен аңлау ята. Үзенең элгәрләреннән һәм кайбер замандашларыннан аермалы буларак, К.Насыйри фольклор әсәрләренә башка фәннәрне өйрәнү өчен өстәмә, ярдәмче материал итеп кенә

---

[2] Катанов Н.Ф. Исторические песни казанских татар // Известия Общества археологии, истории, этнографии (ОАИЭ).— 1899.— Т.15.— Вып.3.— С.297.

карамады, бәлки фольклорның мөстәкыйль идея-эстетик кыймmәте һәм зур тәрбияви роле булуына игътибар бирде. Моны шундый мисалдан да ачык күреп була: «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» китабының исеме «Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше» дигән мәгънәне аңлата. Аның өчен күпчелек материалларны ул Көнчыгыш классик әдәбиятыннан сайлап ала. Һәм шул җимешләр белән рәттән, алар белән тигез күреп, китабына татар фольклоры әсәрләрен дә күпләп урнаштыра. Бу әсәрләргә бирелгән күпсанлы искәрмә һәм аңлатмаларында аларның сәнгатьчә гүзәллеген һәм камиллеген каткат күрсәтеп уза. Менә бер генә мисал:

Ары барма, җаный, кайт бире,
Барча эшләр Ходай тәкъдире,—

дигән җыр юлларыннан соң, К.Насыйри тирән соклану белән болай язып куя: «Моннан артык бәлягатьле шигырь ниндәен шигырь кирәк!»

К.Насыйриның халык иҗатына мөнәсәбәте, барыннан да элек, аның мәгърифәтчелек карашлары белән тыгыз бәйләнгән иде. Кешенең олылыгын байлык һәм нәсел-нәсәп белән түгел, ә «акыл белән», «әдәп белән» билгеләүче, аң-белемне, рухи сафлыкны бар нәрсәдән өстән куючы бу гуманист фольклор әсәрләренә кешеләрне мораль һәм эстетик тәрбияләүдә куәтле һәм тәэсирле чара итеп карады. Аның мәкальләргә аеруча зур мәхәббәт баглавы һич очраклы хәл түгел. Аларда галим халыкның бай тормыш тәҗрибәсе, тирән акылы һәм югары әхлакый сыйфатлары гәүдәләнүен бик ачык күрде. Аны мәкальләрнең җыйнаклыгы, тапкырлыгы, образлылыгы сокландыра. Мәсәлән, бер мәкальгә аңлатма биреп, ул аны эчтәлеге ягыннан «үзе бер китаплык сүздер» дип бәяләп үтә. Бу уңай белән А.М.Горькийның да «мәкальләр... һәрвакыт кыска булалар, ә алардагы тирән акыллылык... бик күп китапларга җитәрлек була» дигән сүзләрен хәтергә төшереп үтү урынлы булыр.

«Фәвакиһел җөләса» китабында мәкаль текстлары алдыннан кечкенә генә кереш сүз дә әйтелеп уза. «Мәгълүм ула ки, һәр телнең үзенең махсус әмсал, вә мәкальләре, вә көллияләре буладыр. Халкына күрә гакыл ияләре вә хәкимнәре дәхи бардыр. Әүвәлге раузада гарәп мәкальләре язылмыш иде. Инде бу ахыргы раузада үз телемездә булган әмсалларны илхак кыйла-

мыз»,— дип яза автор. Алга таба татар мәкальләреннән соң ул еш кына аларның гарәпчә аналогларын китереп бара. Шушы рәвешчә, гарәп һәм татар мәкальләрен тиң күреп, янәшә куеп тикшерү аша гүя К.Насыйри үз халкының фольклорына тагын бер мәртәбә югары бәя биреп уза. Реакцион татар руханилары мөселман Көнчыгышы алдында баш бөгеп тә, татар халык иҗатына түбәнсетеп, кимсетеп караган бер шартларда моның әһәмияте нинди зур булуын аңлау читен түгел.

К.Насыйри җыйнап бастырган мәкальләрдә акыл, белем, тырышлык, уңганлык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар мактала һәм, киресенчә, наданлык, ахмаклык, саранлык, ялкаулык, көнчелек ише начар сыйфатлар каты гаепләнә. К.Насыйри шушындый ук функцияне әкиятләргә дә йөкли. Ихтимал, шуңа күрәдер аның хезмәтләрендә көнкүреш әкиятләренә һәм хайваннар турындагы әкиятләргә күбрәк урын бирелә. Дөрес, «Үги кыз», «Өч угыл», «Гөлнәзек» кебек әкиятләрдә убырлы карчык, дию, су иясе кебек мифик затлар да катнаша, ләкин алар белән көрәштә әкият геройлары көч һәм тылсым ярдәмендә түгел, ә тапкырлык, намуслылык, тугрылык, изгелек кебек күркәм сыйфатлар аша җиңүгә ирешәләр.

Мәкальләрнең һәм әкиятләрнең мондый функциональ якынлыгы тагын шунда да ачык күренә: К.Насыйри еш кына мәкальләрне әкиятләргә йомгак ясау, мораль чыгару өчен файдалана. Мәсәлән, «Байдек» әкиятендә герой кеше әйберенә кул суза, ләкин урлаган малның рәхәтен, файдасын күрә алмый. «Шуның өчен дә әйткәннәр, ырыкныкы — шырыкка, дип. Һәм дөрес: ырыкныкы шырыкка китте»,— К.Насыйри әкиятне әнә шулай тәмамлый.

Халык лирикасының эстетик асылын К.Насыйри аларда кеше күңеленең иң саф һәм нечкә хисләре гәүдәләндерелүдә күрде. Аның хезмәтләрендә иң зур күпчелекне мәхәббәт җырлары алып тора. «Кырык бакча» һәм «Фәвакиһел җөләса» китапларында алар «Моңаеп әйткән җырлар», «Мактап әйткән җырлар», «Кавышырга мөштак булып әйткән җырлар», «Сагынып әйткән җырлар», «Үпкәләп әйткән җырлар», «Һиҗран вә фирак җырлары» кебек тематик төркемнәргә бүленеп биреләләр. Инде җырларның темаларыннан ук аларда кеше күңеленең катлаулы кичерешләре, аның хисләренең сафлыгы, матурлыгы турында сүз барганлыгын аңлап була. Мондый эчтәлектәге җырларны

пропагандалап, Насыйри-гуманист гүя кешенең шәхси бәхеткә омтылуын яклап чыга, аның интим хисләрен, шатлык-сөенечләрен, кайгы-сагышларын аңлый белергә чакыра.

Ул замандагы күп кенә тикшеренүчеләр җырларга барыннан да элек тарихи-этнографик чыганак итеп карасалар, халык поэзиясенең бу әсәрләре Насыйрины эмоциональ һәм художество көче белән җәлеп итәләр. Җырларга мөнәсәбәттә мондый аерымлык хәтта Насыйри белән Катанов арасында да күзгә ташлана. «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре»нә язган кереш сүзендә Н.Ф.Катанов, җырларга хас җитешсезлекне күрсәткәндәй, болай дип билгеләп үтә: «Насыйров әфәнде җыентыгындагы җырлар арасыннан без йола җырларын да, үзләрендә борынгы ышанулар эзләрен саклаучы җырларны да таба алмыйбыз»[1].

Шул рәвешчә, матбугат өчен җырлар сайлаганда, К.Насыйри аларның эстетик ягына, сәнгатьчә нәфислегенә зур игътибар бирә. Кешенең эчке һәм тышкы матурлыгын тасвирлау, аның рухи дөньясын ачу өчен, бу җырларда табигать дөньясыннан бик оста сайлап алынган янәшәлекләр, тапкыр һәм төгәл чагыштырулар, метафоралар, эпитетлар һ.б. сурәтләү чаралары киң файдаланылган. Мәсәлән:

Аяз булса — айга көч,
Болыт булса — көнгә көч;
Кая барсаң, бер кояш,
Күбәләктәй газиз җанга көч.

Көмеш йөзек койдырдым
Ялан көмеш акчадин;
Эзләдем сине, таптым, җаный,
Гөлчәчәкләр аткан бакчадин.

«Бу шигырьдә,— дип яза К.Насыйри, соңгы мисалны аңлатып, — бераз тәүрия бардыр ки, гөлчәчәкләр аткан бакчадин димәктән морад пакь-дзаман, ата-анасы вә нәсел-нәсәбе изге булучы кавем эченнән таптым, димәктер».

Эстетик тәрбия чарасы булудан тыш, К.Насыйри фольклор әсәрләренең танып-белү роленә дә зур әһәмият бирде. Мәгърифәтче-галим буларак ул үз халкының тарихы, аның горef-

---

[1] К а т а н о в Н.Ф. Курс. хезм.— 376 б.

гадәтләре белән аеруча тирәнтен кызыксынды. Озак еллар дәвамында халык арасында йөреп, ул, Казан шәһәре, үзе туган Зөя өязе авыллары тарихына, Пугачев восстаниесенә һ.б. вакыйгаларга караган риваять һәм легендаларны җыеп һәм шуларга нигезләнеп, тарихи-этнографик хезмәтләр язды.

Халык иҗаты материалларын галим туган телебезнең лексик һәм стилистик байлыгын өйрәнү һәм үзләштерү, халыкчан әдәби телгә нигез салу өчен дә ышанычлы чыганак итеп санады. «Әбүгалисина кыйссасы», «Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан», «Кырык вәзир кыйссасы» кебек иҗади тәрҗемә итеп эшләгән әдәби әсәрләрендә ул халкыбызның мәкаль һәм әйтемнәрен бик оста файдаланды. Мәсәлән, чит телләрдәге образлы гыйбарәләрне ул еш кына аларның татар телендәге эквивалентлары ярдәмендә аңлатып барды. Әйтик, «Әбүгалисина кыйссасы»нда мондый җөмләне очратабыз: «Бу сәнгатьләрне без аларга сатар идек, инде безгә дә саттылар: мән карраге-коррига, ягъни какма кеше капкасын, кагарлар үз капкаңны, димешләр». Тәрҗемә әсәрләрдә К.Насыйри еш кына геройларның сөйләменә үзлегеннән дә халык мәкальләрен һәм әйтемнәрен кертеп җибәрә һәм аларны «картлар әйтмешли», «дигәндәй» кебек сүзләр белән «ныгытып» бара: «йөргән таш шомара, яткан таш бәсәрә, дигән картлар», «җил исми, яфрак селкенми дигәндәй», «дөя дә бүләк төймә дә бүләк дигәндәй», «башыңа төшсә, ата казга да сәлам бирерсең дигәндәй», «хатыннар әйтә торган сүз: кашыклы су белән йотарсың» һ.б.

Әдәби әсәр тукымасына мәкальләрне болай күп катнаштыруның Насыйри өчен шулай ук принципиаль әһәмияте бар иде. Бер яктан, ул, теге яки бу фикерне дәлилләү өчен, халык акылына, халык тәҗрибәсенә таянды. Икенче яктан, халыкка аңлаешлы әдәби тел тудыру программасы белән чыккан әдип буларак, халык афоризмнарының теле, стиле һәм сурәтләү чаралары әдәби тел нормаларына тулысынча җавап биргәнлегенә дә игътибарны юнәлтте.

Фольклор әсәрләрен гыйльми-иҗади эшчәнлегендә киң файдалану белән беррәттән, К.Насыйри аларның үзләрен фәнни яктан тикшерү буенча да (һәм, алда әйткәнебезчә, беренчеләрдән булып) байтак эш башкарды. Иң элек шуны күрсәтергә кирәк: татар халык иҗатын жанрлар ягыннан классификацияләү проблемасы, нигездә, Насыйри тарафыннан хәл ителде.

Аның хезмәтләрендә, дастаннардан кала, барлык жанрлар да (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, ышанулар, сынамышлар, җырлар, бәетләр, әкиятләр, риваятьләр һәм легендалар) очрый. Билгеле, бу жанрларның күбесе башка авторларның китапларында да күренә килде. Әмма Насыйри инде һәр жанрга кыскача булса да билгеләмә биреп чыкты, аларның идея-тематик һәм художество үзенчәлекләренә караган күп кенә күзәтүләр ясады. Мәсәлән, «Фәвакиһел җөләса» китабында ул татар халык җырларының һәрвакыт ике юлдан торуын, төп фикернең, эчтәлекнең күбрәк соңгы юлда белдерелүен, бер үк җырның ун-унбиш төрле көйгә җырланып йөрүен күрсәтә. Монда сүз безнең кыска җырларыбыз, ягъни дүртьюллыклар (элек алар ике юл итеп язылып йөргәннәр) турында бара, һәм Насыйри биргән характеристика бүген дә үз көчендә кала.

К.Насыйриның бәетләр хакында да кызыклы гына күзәтүләре бар. Ул үзе бастырган бәетләрнең нинди шигъри үлчәмдә иҗат ителүләрен һәм кайсы көйгә башкарылуларын күрсәтә. Н.Ф.Катановның әйтүенә караганда, К.Насыйри аңа «Рус-француз сугышы» бәетенең хор белән башкарылуы турында хәбәр иткән. «Насыйров әфәнденең сүзләре буенча,— дип яза Катанов,— бәетләр чыгару белән гадәттә яшьләр, мәдрәсә шәкертләре, ә кайчакта мөселманча укыган өлкән кешеләр дә шөгыльләнәләр. Халык җырлары исә грамотасыз гавам тарафыннан чыгарылалар һәм башлыча бәйрәмнәрдә (аулак өйләрдә һәм түгәрәк уеннарында) җырланалар»[1].

Соңрак тикшеренүчеләр тарафыннан бәетләрнең язма рәвештә генә түгел, бәлки телдән дә чыгарылулары һәм таралулары ачыкланды. Хәлбуки бер төркем бәетләргә карата Насыйри фикерләре һаман да дөрес булып кала. Ул бу жанрның төп үзенчәлекләреннән берсен — аның язма әдәбият белән якын торуын бик дөрес билгеләп үтә.

Халык иҗаты әсәрләренең идея эчтәлеген һәм сәнгатьчә эшләнешен ачыклау максатында К.Насыйри аларга күпсанлы фәнни искәрмәләр, аңлатмалар биреп бара. Аерым мәкальләр һәм җырларга бирелгән шундый искәрмәләр белән без алдарак танышып үткән идек инде. «Фәвакиһел җөләса» кита-

[1] Катанов Н.Ф. Курс. хезм.— 228–273 б.

бында автор һәр мәкальнең нинди күчерелмә мәгънә аңлатуын һәм нинди ситуациядә файдаланылуын күрсәтеп бара, еш кына аның синонимнарын һәм антонимнарын китерә. Билгеле булганча, кайбер мәкальләрнең килеп чыгышы тормыштагы кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар яки башка төр фольклор әсәрләре (әкият, мәзәк һ.б.) белән бәйләнгән. К.Насыйри бу күренешкә беренчеләрдән булып игътибар итте. Мәсәлән: «Сүз бозау имезер. Бер хикәяткә ишарәттер. Күп сүзгә кереп китеп, эшеңне онытма, димәктер». Яки: «Иртәге өчен ишәк кайгырыр. Дәҗҗал ишәге хакында чыккан зарбе мәсәлдер, хикәяте мәгълүмдер» һ.б.

К.Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре» исемле зур мәкаләсе татар фольклорын өйрәнү тарихында беренче махсус фәнни хезмәт итеп саналырга хаклы. Дөрес, бу автор тарафыннан этнографик планда уйланылган, әмма тулысынча фольклор материалларына нигезләнеп язылган. Аның беренче бүлеге асылда татар мифологиясенең һәм тылсымлы әкиятләрнең сюжетларын һәм персонажларын классификацияләүдән гыйбарәт. Шунысы игътибарга лаек, автор, хезмәтнең темасы таләп иткәнчә, мифик затларга характеристика бирү белән генә чикләнми, ә әкиятләрдәге кеше образларын да тәфсилле итеп тасвирлый. Хезмәтнең икенче һәм өченче бүлекләрендә халкыбызның күпсанлы ышанулары, йолалары, им-томнары җентекләп анализлана.

К.Насыйриның бу хезмәте беренче башлап рус телендә дөнья күрде. Сүз башында автор үзенең төп максатын түбәндәгечә билгеләп үтә: «Татарның тормышын ачыкландыруда рус кешеләренә үземнең көчем һәм мәгълүматым җиткән кадәр ярдәм итәргә теләп, күп еллар бу тормышны тикшерү һәм күзәтү өстендә эшләвемнең нәтиҗәләрен алар белән уртаклашуны үземнең изге бурычым дип саныйм[1]». Әйтергә кирәк, хезмәт, чыннан да, рус фәне дөньясында зур кызыксыну белән каршы алынды һәм югары бәяләнде. Аңа кереш сүзендә XIX йөзнең танылган тарихчысы һәм тюркологы профессор В.В.Григорьев, мәсәлән, болай дип язды: «Казан татары Каюм Насыйров үзенең бу мәкаләсе белән Казан татарларының ислам

[1] Н а с ы р о в К. Поверья и обряды казанских татар...— С.44

кабул иткәннәре аркасында хәзергә кадәр аз сакланып калган борынгы мәҗүси гореф-гадәтләрне тикшерүдә беренче тәҗрибә ясый... Фән ноктасыннан бу — шиксез, бик кызыклы, яхшы ук гыйльми хәзинә бирергә вәгъдә итә торган эш. Бу хакта Каюм Насыйров кебек тикшерүче мөселман татарлары арасында гына түгел, бәлки бөтен ислам дөньясында да чыкканы юк, дисәк, ялгышмаган булырбыз».

Кыскача йомгак ясап әйткәндә, К.Насыйри татар фольклористикасы өлкәсендә гаять күп эш башкарды. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастыру этабыннан аларны фәнни нигезләрдә өйрәнүгә күчү, ягъни татар фольклористикасының мөстәкыйль фән буларак формалаша башлавы нәкъ менә аның эшчәнлеге белән бәйләнгән иде.

*Хуҗиәхмәт Мәхмүтов,*
филология фәннәре докторы

# ХАЛЫК ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕ

## ТАБЫШМАКЛАР

Моннан соң үз халкымызда бәгъзе мөгаммә[1] вә лөгазьләрне[2] бәян кыйлаек ки, телемездә җомак вә табышмак тәгъбир кыйлыныр, ләкин мәзкүр[3] җомак вә табышмак дигәнемез күбрәк лөгазь кабиленнәндер[4] вә гяһан[5] мөсәҗҗәгъ кыйлып[6] әйтеләдер. Мәсәлән:

Әнә бара үзе,
Күренмидер эзе,
Ходайның кодрәте,
Адәмнең дәүләте.

*Су өстендәге көймә*
*ирад кыйлыныр*[7].

Ары да килер карача,
Бире дә килер карача,
Тал төбендә тоnык су,
Тондырып эчәр карача.

*Бу лөгазьдән борча*
*дигән кечкенә хайван*
*ирад кыйлыныр.*

Бер тычканга ике койрык.

*Чабата ирад кыйлыныр.*

Аю акыра, йоны коела.

*Тегермән дигән сүздер.*

Ямавы бар, җөе юк.

*Ала тире ирад кыйлыныр.*

---

[1] Мөгаммә — табышмак, шарада.
[2] Лөгазь — табышмак, аңлавы, белүе читен булган мәсьәлә, сер.
[3] Мәзкүр — югарыда әйтелгән.
[4] Кабил — төр, төркем.
[5] Гяһан — кайчакта.
[6] Мөсәҗҗәгъ кыйлып — рифмалаштырып.
[7] Ирад кыйлыныр — күздә тотып сөйләнер.

Туз чиләктә торымтай уйный.

*Күз ирад кыйлыныр.*

(Торымтай асыл лөгатьтә тырымтайдыр, тәхриф кыйлып[1], торымтай, диерләр, бер нәүгъ шикяри коштыр[2].)

Торса — төядәй, ятса — куяндай.

*Чыбылдыкка әйтелер.*

Ялт-ялт итәр, ялмап йотар.

*Уттыр.*

Акылы юк, җаны бар.

*Сәгатьләмә.*

Югары менәр һи-һи,
Түбән төшәр һи-һи,
Уртасында — былбыл кош.

*Бу лөгазьдән бишектәге*
*бала ирад кыйлыныр.*

Ун ат җиктем, сабан сөрдем,
Шикәр сачтем, тоз бетте[3].

*Кашынмак.*

Мич тулы пәрәмәч,
Уртасында — бер калач.

*Күктәге йолдызлар*
*арасында — ай.*

Атасы ат җиккәнче, углы Петербургка барып җитә.

*Морҗадан чыккан төтен.*
*Мич яхшылап яна башлаганчы,*
*төтене чыгып җитә, димәктер.*

Ишектән керер иңкәеп,
Түргә менәр туңкаеп.

*Суык.*

Ары лап-лап,
Бире лап-лап,
Сөңге саплап,
Киез каплап.

*Коймак пешермәк мораддыр.*

---

[1] Тәхриф кыйлып — сүзнең хәрефләрен үзгәртеп.
[2] Бер нәүгъ шикяри коштыр — бер төр ау кошыдыр.
[3] Бетте — бу урында: үсте.

Борыны бортас,
Карыны картас,
Атка менмәс,
Җәяү йөрмәс,
Тик тормас.

*Комган.*

Башы — тарак,
Койрыгы — урак,
Аны белмәгән — дурак.

*Этәч.*

Чи-чи итәр, читәнгә кунар,
Алтын кашлы, алама башлы,
Аны белгән йөз яшьле.

*Бал корты.*

Өй башында дранча,
Дранча саен бер акча.

*Ботак тактада.*

Аттан биек,
Эттән тәбәнәк.

*Ияр.*

Алпавытның бакчасы,
Бакчасында мунчасы,
Мунчасына су китерә
Киле к... марҗасы.

*Бу логазьдән морад бал кортының умартага бал ташымагыдыр.*

Әпә симез, мае юк,
Тиресе калын, йоны юк.

*Шалкан.*

Бохарадан килгән бер пел,
Уртасында тасма тел.
Җанлыдан җансыз туар,
Ул ни булыр, аны бел.

*Бу логазьдән йомырка ирад кыйлыныр.*

Ул нидер кем: канга биңзәр[1], каны юк,
Җөмлә буен кан алыптыр, җаны юк.

---

[1] Биңзәр — охшар.

Хәляле юк, җефете юк,
Угланнарының саны юк.

*Бу лөгазьдән җиләк мораддыр.*

Ул нидер кем: башы аерук, төге бар,
Башы үзрә ак тимердән бүрке бар.
Аллаһы Тәгаләдән фәрман килсә,
Җан алырга ирке бар.

*Ук.*

Ул нидер кем: йөздер аның бармагы,
Сигез аяк өстендәдер тормагы.
Биш башы бар, биш тәне бар, дүрт җаны,
Ни гаҗәптер, биш барып дүрт кайтмагы.

*Җеназага күтәрелгән мәет ирад кыйлыныр.*

Ул нидер кем: икедер инсанда,
Өчтән артык булмады хайванда.
Синдә бар һәм миндә бар, галәмдә юк,
Җөмләдә[1] бардыр дисәм, адәмдә юк.
Кемсәдә булмас, вәли[2] һәр шәйдә[3] бар,
Булыр аның илә галәм вәкар[4].
Унбиш улмышдыр аның мәнзилләре[5],
Беринә кадир[6] түгел бармак бере.
Бер, ике, өчтән зиядә[7] булмады,
Дүртне бер җирдә кемсә күрмәде.
Шамга[8] барган өчне күрде,
Мисырга барган һичберине күрмәде.

*Ошбу лөгазьдән морад хәреф өстендә вә хәреф астында булган нокталар[9]. Гаҗәп яхшы лөгазьдер.*

Дүрт татар,
Дүртесе дә бер тишеккә атар.

*Сыер саву.*

Әнә бара, эзе юк.

*Көймә.*

---

[1] Җөмләдә — һәммә нәрсәдә.
[2] Вәли — ләкин.
[3] Шәйдә — нәрсәдә.
[4] Вәкар — горур.
[5] Мәнзилләре — куела торган урыннары.
[6] Кадир — көче җитә.
[7] Зиядә — артык.
[8] Шам — Дамаск (Димәшкъ) шәһәре.
[9] Нокталар — сүз гарәп әлифбасындагы хәрефләр турында бара.

Утыз кеше арыш суга,
Сөләйман көлтә әйләндерә.

*Ашамак.*

Утыз тештән чыккан утыз адәмгә җәелә.

*Мәкаль.*

Өй түбәсендә аю бии.

*Төтен.*

Өй аркылы аркан аттым.

*Салават күпере.*

Тарлавына[1] тары сачтем,
Татлысына кинәндем.

*Мунча.*

Агы — китән[2],
Яшеле — суган,
Утырыр — солтан,
Кычкырыр — шайтан.

*Саескан.*

Бүз күлмәк кигән,
Башы тактага тигән.

*Мич.*

Җиз сарайда җизни аты кешни.

*Кыңгырау.*

Ай күрде, кояш алды.

*Чык яки кырау.*

Ике башлы кара кияр,
Кулың сузсаң, сиңа тияр.

*Сөлек.*

Ак ашый, кара төкерә.

*Шәм.*

Яр буенда ярты алачык.

*Колак.*

Кечкенә генә таш пулат,
Ачыгы да, тишеге дә юк.

*Йомырка.*

---

[1] Тарлау — иген чәчә торган җир.
[2] Китән — ак киндер тукыма.

Җир астында җиз бүкән.

*Бәрәңге.*

Кечкенә генә бичура,
Билен буып утыра.

*Себерке яки күәс чиләге.*

— Озын агай, кая барасың?
— Кара борын, син ни беләсең?

*Төтен вә корым.*

Бардым кунак чакырырга,
Киткән кунак чакырырга,
Килер иде килмәсә.

*Чакырырга теләгән кешесе*
*үзе кунак чакырырга киткән.*
*Аның кунагы килмәсә,*
*үзе моңа килер иде.*

* * *

Бер җиде яшәр бала атасыннан сорады:

— Әткәй, син ничә яшьтә? — диде.

Атасы әйтте:

— Әй күземнең нуры углым, үзеңнең яшең янына егерме тугызны кушсаң, мин ничә яшьтә икәнен белерсең, — диде.

Атасы ничә яшьтә булырга кирәк?

*36 яшьтә.*

Бер балага анасы 75 тиенгә итек сатып алып бирде. Углы итекне киде дә китте. Бөтен көн былчырак сөреп йөрде. Иртәгесен нишләсен — итекне аягына кияр хәле юк. Итек аякка керми, каткан. Бала анасыннан тагын «яңа итек алып бир» дип сорый башлады.

Ул баланың бер тутасы бар иде, моны ишетте дә энесенә әйтте:

— Синең хәтереңдә бармы, абый безгә бервакытны бер сүз әйткән иде. Сүзе шул иде: елда 365 көн, дигән иде. Син исәпләп исәбенә чык әле, әгәр дә әни сиңа көн дә син сораган саен яңа итек алып бирсә, ничаклы акча кирәк булыр? — диде.

*273 сум 25 тиен.*

Ике кеше кырдан сарыкларын куып кайтып килгәндә бер елга янында очраштылар да сөйләшә башладылар. Боларның берсе — карт, берсе яшь егет иде. Бу карт кеше шул яшь егетнең сарыкларына карап әйтте:

— Беләмсең, чибәр егет, минем уема ни-нәрсә төште?

Ул егет әйтте:

— Белмим, ни-нәрсә төште соң? — диде.

Карт әйтте:

— Менә мин сиңа ни әйтим: әгәр син миңа бер сарыгыңны бирсәң, минем сарыкларым синеке чаклы ике була,— диде.

Егет башын кашып азрак уйлап торды да әйтте:

— Юк, бабай, болай гаделсезлек булыр. Кая кирәк, син бир миңа бер сарыгыңны, икебезнеке дә бәрабәр булыр, арабызда көнчелек калмас,— диде.

Белергә кирәк: боларның ничәшәр сарыгы бар иде?

*Картның — җиде, егетнең биш сарыгы бар.*

Кышларга киткән казлардан бер төркем каз очып килгәндә, ул казларга каршы бер каз очрап, аларга әйтте:

— Әссәламегаләйкем, йөз каз! — диде.

Ул төркем казларның берсе җавап биреп әйтте:

— Юк, без йөз каз түгел. Без булыр идек йөз каз шул чагында, әгәр дә безнең чаклы тагы да бер булса, тагы да безнең яртымыз чаклы казлар булса, тагы да безнең чирегемез чаклы булса, аның өстенә син бер каз килеп кушылсаң, йөз каз булырмыз! — диде.

Инде ул төркем казлар эчендә ничә каз бар иде, белергә кирәк.

*36 каз.*

Өч сәүдәгәр бик күп мал белән бик ерак шәһәргә ярминкәгә барырга сәфәргә чыктылар, үзләре белән бергә өч хезмәтчеләре бар иде. Аларның хезмәтчеләре, юлга чыккач, байларын таламакчы булып, үз араларында сүз куештылар. Ләкин өч бай өч хезмәтче һәмишә бергә булсалар (ягъни байлар һәм хезмәтчеләр саны тигез булганда.— *Х.М.*), таларга мөмкин түгел, яки ике бай бер хезмәтче бергә булганда талар хәл юк. Әмма ул хезмәтчеләр талар шул вакытта: әгәр бер бай ике хезмәтче белән бергә ялгыз калсалар... Аннан соң бара торгач, байлары бу хезмәтчеләренең бозык ниятләрен белделәр дә бик саклана башладылар. Алар барып җиттеләр бер иделгә[1]. Кирәк булды иделне көймә белән кичәргә. Бары бер кечкенә көймә бар, ике кешедән артык утырыр хәл юк. Инде ни эшләргә? Иделдән дә кичәргә кирәк, хезмәтчеләргә дә талатмаска кирәк. Әмма перевозчик юк, үзләре ишеп чыкмак кирәк. Инде идел аркылы ничек кичкәннәр болар? Икәү утырып чыккач, берсеберсе кире кайтмак кирәк була икенчеләрен алырга.

*Башта теге якка 2 хезмәтче чыгып китә, аннан берсе кире кайта да өченче хезмәтчене дә алып китә, ә үзе бу якка әйләнеп кайта.*

[1] И д е л — елга мәгънәсендә.

*Шуннан соң монда 3 бай, 1 хезмәтче, ә аргы якта 2 хезмәтче була. 2 бай бергә теге яктагы 2 хезмәтче янына чыгалар да 1 бай, 1 хезмәтче кире кайталар: бу якта 2 бай, 2 хезмәтче була. Аннан 2 бай елганы кичеп, теге якта 3 бай, 1 хезмәтче була. Ул хезмәтче берәм-берәм бу ярда калган 2 хезмәтчене күчерә.*

Бер кеше бер җиргә барырга сәфәргә чыкты: үзе белән бер бүресе бар, бер кәҗәсе бар, янә бер кәбестәсе бар. Бара торгач, бер идел аркылы чыгарга кирәк булды. Бер кечкенә генә көймә бар иде. Бүрене, кәҗәне, кәбестәне һәммәсен берьюлы төяп чыгар хәл юк. Бары шул өч нәрсәне берәм-берәм чыгармак кирәк. Болай итеп чыгару бик читен булды, инде ни эшләргә кирәк?

Әгәр әүвәл бүрене икенче якка чыгарып куйса, кәҗә белән кәбестә бу якта калып, кәҗә кәбестәне ашый. Әгәр кәбестәне элгәре чыгарып куйса, бүре белән кәҗә бергә калып, кәҗәне бүре ашый. Әгәр кәҗәне элгәре чыгарып куйса, икенчесен чыгарганда, кәҗә катына бүрене яки кәбестәне чыгарып куймак кирәк була. Әгәр кәбестәне кәҗә янына чыгарып куйса, кәбестәне кәҗә ашый, әгәр бүрене чыгарып куйса, бүре кәҗәне ашый. Ул кеше ничек итеп кичкән идел аркылы бүреләр, кәҗәләр, кәбестәләр белән?

*Теге якка башта кәҗәне чыгара. Бу ярда бүре белән кәбестә кала. Аннары бүрене алып чыга да кәҗәне кире үзе белән ала. Бүре теге ярда үзе генә кала. Шуннан соң кәҗәне бу якта калдырып, бүре янына кәбестәне чыгарып куя. Ахырдан кәҗәне алырга чыга.*

## МӘКАЛЬЛӘР ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР

Мәгълүм ула ки, һәр телнең үзенә махсус әмсал, вә мәкальләре, вә көллияләре буладыр. Халкына күрә гакыл ияләре вә хәкимнәре дәхи бардыр. Әүвәлге раузада[1] гарәп мәкальләре язылмыш иде. Инде бу ахыргы раузада үз телемездә булган әмсалларны илхак[2] кыйламыз ки, ошбулардыр:

**Алла ташламаса, бүре ашамас,** диярләр. Аллаһы Тәгаләгә илтиҗа[3] вә тәвәккәл, вә һәр эштә Аллаһы Тәгаләгә сыгынмага тәнбиһтер[4].

**Аптыраган үрдәк арты белән чумар.** Вә дәһи:

---

[1] Раузада — гөлбакчада; бу урында: китапның бер бүлеге.
[2] Илхак — өстәмә.
[3] Илтиҗа — сыену.
[4] Тәнбиһтер — кисәтү, искәртү, зиһененә салудыр.

**Аптыраган сөлек юкә агачы тешләр.** Гаять гаҗизлектән вә ни эшләргә белмәгәнлектән заһирән[1] файдасы күренмәгән эшкә тотынганда зарбе мәсәл[2] китерелер.

**Эт өрер, бүре йөрер.** Вә дәһи:

**Эт өрер, караван йөрер.** Халык сүзенә вә халык тәгънәсенә[3] каралмас, диячәк урында әйтелер.

**Этнең — эткә, кошның — кошка.**

**Эт — эткә, эт — койрыкка.**

**Эт симерсә, иясен кабар.** Мәнфәгате өмид ителгән кешедән зарар күргәндә зарбе мәсәлдер.

**Этнең күзе нәҗескә төшәр.** Үзенә кирәк нәрсәгә кешенең күзе тиз төшә, диячәк урында вә нәдрәт[4] дәни[5] кемсәнәнең дәни нәрсәгә күзе төшә, диячәк урында әйтелер.

**Эт этлек итәр.** Кешенең җибилли[6] булган мәзмүм[7] холкы калмас, дигән мәгънәдәдер ки, этнең шәэне[8] өрмәк икән, яткан җирдән өрсә дә өреп кала, димәктер.

**Эт күзе төтен белмәс.** Тамгыкяр[9] вә билә дәгъвәт[10] кеше ишегендә йөргәннәр хакында.

**Эт корсагына сары май килешми.** Яхшы нәрсәнең кадерен белмәгәннәргә тәнбиһан әйтелер.

**Этне сөяк белән атсаң — шыңшымас.** Берәүгә изгелек кыйлып, җәфасына да тәхәммел кыйлыр[11], диячәк урында.

**Этнең койрыгын кем киссә, шул яхшы.** Берәүдән җәфа күреп тә, янә аңа мәел кыйлган[12] кеше хакында.

**Эт авызыннан белен алалмассың.** Бер нәрсә кулыңнан китеп бер ләим[13] кулына керсә, кайтарып алу мөмкин түгел, димәктер.

**Аңламый сөйләшкән авырмый үләр.** «Лисанәнә — әсәдүкә, вәләү әрсәлтәһү — йактү лүкә»нең[14] мөфады[15].

**Атаның-ананың — балада, баланыкы — далада.** Ва-

---

[1] Заһирән — ачык.
[2] Зарбе мәсәл — күп очракта мисал итеп.
[3] Тәгънә — сүгү, ачулану.
[4] Нәдрәт — бу урында: кайчакта, сирәк кенә.
[5] Дәни — түбән зәвыклы, түбән.
[6] Җибилли — табигый.
[7] Мәзмүм — начар, бозык.
[8] Шәэне — холкы.
[9] Тамгыкяр — ач күзле, хирыс, комагай.
[10] Билә дәгъвәт — чакырусыз.
[11] Тәхәммел кыйлыр — чыдамлык күрсәтер.
[12] Мәел кыйлган — күңел куйган.
[13] Ләим — саран.
[14] «Телең — арыслан, әгәр җибәрсәң, үзеңне үтерер».
[15] Мөфады — мәгънәсе.

кыйган, ата-ана көн-төн балам дип фикердә-сагышта, хәер хаһлыкта[1] булып, ата-анасына гак вә гасый[2] балалар хакында.

**Атасы болан атмаганның углы колан атмас.** Күбрәк һөнәрсез атадан һөнәрсез бала туа, димәктер.

**Әстерханда сыер бер акча, килә-килә мең акча.** Мәшәкатенә нәзарән[3] мәнфәгате аз нәрсә хакында зарбе мәсәлдер.

**Ач кешенең ачуы яман.**

**Ачка казан астырма, туңганга ут яктырма.** Мигъярсыз[4] исраф кыйлмага тәнбиһтер. Эшнең мигъярын белмәгәнгә эш кушма, димәктер.

**Арба уалса — утын, үгез үлсә — ит.** Хәреҗ[5] вә хәраҗатта[6] хәбәре юк, димәк.

**Азыклы ат армас.** Пөхтә вә хәстәрле булмакка тәнбиһ.

**Ышанган тауда киек юк.** Бер җирдән өмид итеп мәэюс булган хәлдә зарбе мәсәл кыйлыныр.

**Ашап туймаганны ялап туймассың.** Барына канәгать кыйлмасаң, күбенә дә канәгать кыйлмассың, диячәк урында.

**Ашаганнан үлмәссең, күп яхшылык та күрмәссең.** Аз ашамага тәнбиһ мәкамында[7] әйтелер.

**Ашаган табагына төкергән.** Көфране нигъмәт кыйлганнарга[8] тәнбиһ вә тәшәккерсезләргә[9] тәгъриз[10].

**Ашамыйм дигән алтмыш коймак ашаган.** Урынсыз тәкәллефләнгән кунакка тәнбиһтер.

**Ашыккан җитмәс, боерган җитәр.** Гаҗәлә[11] кяр[12] кыйлмас, «әл-әмур мәрһунәтә би әукатиһа»[13]га ишарәттер.

**Ашыксаң, ашка төшәрсең.** Ягъни нәдамәт чигәрсең[14].

**Ашыккан кыз кияүгә барса да мантымас.**

**Асыл сөяк зур булмас.**

**Ат — кешнәшеп, адәм сөйләшеп таныша.**

**Ат аунаган җирдә төк кала.** «Фил хәрәкәти бәрәкәт»[15]нең мөфадыдыр.

---

[1] Хәер хаһлыкта — яхшы теләктә.
[2] Гак вә гасый — ата-анасын рәнҗеткән, гөнаһлы.
[3] Нәзарән — караганда.
[4] Мигъярсыз — үлчәмсез, чамасыз.
[5] Хәреҗ — чыгым, расход.
[6] Хәраҗат — чыгымнар.
[7] Мәкамында — бередә: урынында, очракта.
[8] Көфране нигъмәт кыйлганнарга — аш (яхшылык) кадерен белмәүчеләргә.
[9] Тәшәккерсезләргә — яхшылыкка рәхмәт әйтмәүчеләргә.
[10] Тәгъриз — протест, ризасызлык.
[11] Гаҗәлә — ашыгычлык.
[12] Кяр — эш, шөгыль.
[13] «Эшләрне вакытында эшләргә кирәк» мәгънәсендә.
[14] Нәдамәт чигәрсең — үкенерсең.
[15] «Хәрәкәттә — бәрәкәт».

**Атка ышанма, иделгә таянма.**

**Иргә ышанма, иделгә таянма.** Ат тирәсендә сакланып йөрмәгә вә, хатын булса, ире тирәсендә сакланып йөрмәгә тәнбиһ.

**Асылынсаң, агачның биегенә асылын**. Күбрәк мәнфәгать өмид ителгән җирне кара, димәктер.

**Анадан ала да туа, кола да туа.** Туган туганга охшамый, диячәк урында китерелер.

**Бәла башы бер акча.**

**Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри.**

**Акчаның күзе юк.** Акча син теләмәгән җиргә дә китеп бара, димәктер.

**Акчаны акча таба.** Әт-тайру бит тайри йосаду[1].

**Акча бакыр, санарга такыр.** Акча юклыктан киная.

**Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс*.** Табигатендә кабилият җибиллисе булмаса, синең нәсыйхәтең әсәр итмәс, димәктер.

**Аның мәчесе дә куян тота.** Икъбале[2] алга барган кеше хакында ирад кыйлыныр.

**Үтмәс балта сөяк чабарга ярый.** Ягъни яхшыны-яманны дошман күрмә, бервакыт эшеңә ярар, димәктер.

**Учагыңда борчагың.**

**Өч таган таймас.** Җәмгыятьтә кувәт бар, димәк.

**Урман киексез булмас.**

**Өрә белмәгән эт өенә кунак китерер.** Җайсыз сөйләшеп үзенә зарар сөйләгән кемсәнә хакында.

**Уртак малны эт җимәс.** Мөштәрәк[3] нәрсәнең кадере юк, шәрикләр бер-беренә ышанып карамаенча, нәрсә тәләф булмактан[4] гыйбрәттер.

**Өендә өйрә пешермәгән кеше өендә ботка пешерер.** Мәгърифәте булмаса да, беләмен дәгъвасы кыйлганнар хакында.

**Узган болытны тотып булмый.** Эш үткәч, үкенмәктә файда юк, димәк.

**Узган эштән төш яхшы.** «Мази морд»[5] яки «әлмази ля йөзкәрү», ягъни үткән эш зикер кыйлынмас[6].

**Үзеңнеке үзәктә, кешенеке кештәктә.**

---

* Бу мәкальне К.Насыйри соңрак тагын бер мәртәбә китерә һәм аның «мән ләм йү зә биһи әл-әбәваи ля йүзә биһи әз-заман» дигән гарәпчә төрдәшен бирә. «Кем ата-анасы тарафыннан азапланмаган — ул заман тарафыннан азапланмас» дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Ягъни монда мәкальгә башка мәгънә салына.

[1] «Кош — кош белән аулана» мәгънәсендә.

[2] Икъбале — бәхете, уңышы.

[3] Мөштәрәк — уртак.

[4] Тәләф булмактан — әрәм-шәрәм итүдән.

[5] «Үткән — үлгән» мәгънәсендә.

[6] Зикер кыйлынмас — искә алынмас.

**Авызы пешкән өреп эчәр.** «Ля йалдигу әл-муэминү мин җүхрин мәррәтайни»нең мөфады. Ягъни мөэмин кемсәнә бер тишектән ике мәртәбә алданмас.

**Үзе егылган еламас.** Үзенең ихтыяры белән бер кемсәнәгә бер кәдәр[1] вә мәшәкать вакыйг булганда ирад кыйлыныр.

**Үзе белмәй, кешедән сорамай.** Надан, моганид[2] хакында әйтелер.

**Утка кергән кич кунган.** Тиз үк барып килә торган йомышта озак торган кеше хакында әйтелер.

**Үксез бозау асраган — авызы-борыны май булган, үксез бала асраган — авызы-борыны кан булган.**

**Гарлеләр торып торганчы, гарсезләр ашап туйган.** «Әлхайау йамнагу әр-ризык»[3] дигән хәдискә ишарәттер.

**Ул теле белән кош тота.** Вә дәхи:

**Аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә.** Дәүләте алга барган кемсәнә хакында ирад кыйлыныр.

**Кемә дәүләт кошы кунса, очар һәр яна[4] канатсыз,**

**Кемнең бәхте кутаһ[5] булса, аның дәсте[6] дераз[7] булмас.**

**Авыл — авыз, урман — колак, кыр — күз.**

**Үлгән сыер сөтле.** Үлгән кешене мәдех кыйлганда, тәгъризан[8] ирад кыйлыныр.

**Уйнашка ышанып, ирсез калган.** Берәүдән бернәрсә өмид итүдән мәэюс булганда зарбе мәсәл китерелер.

**Авырткан башка тимер тарак.** Вә дәхи:

**Кутыр өстенә чуан.** Вә дәхи:

**Чөй өстенә тукмак.** Бер зәхмәт вә мәшәкатьтән котылып җитмәстән, икенче мәшәкатькә грифтар булганда зарбе мәсәл кыйлыныр.

**Өйсәң — күп, өләшсәң — аз.**

**Уеннан уймак булыр.** Ягъни мәзах[9] чынга китеп, мохасамә[10] булмак ихтимал, ләкин икенчесе яхшы хосуста да истигъмаль кыйлыныр[11].

**Уңмаганны кума.**

---

[1] Кәдәр — кайгы-хәсрәт.
[2] Моганид — кире, үзсүзле.
[3] «Оят ризыксыз калдыра» мәгънәсендә.
[4] Яна — якка.
[5] Кутаһ — кыска.
[6] Дәсте — кулы.
[7] Дераз — озын.
[8] Тәгъризан — ризасызлык белдереп, каршы әйтеп.
[9] Мәзах— мәзәк, көлке.
[10] Мохасамә — низаг, тарткалаш.
[11] Истигъмаль кыйлыныр — кулланылыр.

**Ит — иткә, шурпа — биткә.** «Әл-ләхму йәтбүтү әл-ләхмә»[1] мәгънәсе.

**Ит күрмәгәнгә үпкә тансык.**

**Әйткән сүз кире кайтмый.**

**Авызыннан чыкканны эт җимәс.** Яман телле вә кабахәт телле кемсәнә хакында ирад кыйлыныр.

**Эчем егълый, тышым көлә.** Вә дәхи:

**Эчем калтырый, тышым ялтырый**. Вә дәхи:

**Эчем бөкмә бөгә, тышым җәймә җәя.** Күңелем хәсрәтләнәдер.

**Ир сынамак — бурыч.**

**Ир — баш, хатын — муен.**

**Ир бала тап, иркенләп ят.**

**Ирсез хатын — йөгәнсез ат.**

**Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас.** Эшнең ибтидасында[2] хәер булмаса, интиһасында[3] хәер булмас, диячәк урында әйтелер. Моның мокабиле[4]:

**Алгы көпчәк кайдан тәгәрәсә, арты шуннан тәгәридер, димәк.**

**Иртәге өчен ишәк кайгырыр.** Дәҗҗал ишәге хакында чыккан зарбе мәсәлдер, хикәяте мәгълүмдер.

**Исереккә ярык арасы бар да акча.**

**Иске байның бөлгәне — яңа байның көлгәне.**

**Иске яңаны асрый.**

**Искегә тисәң, исерерсең.**

**Икмәк югы ямандыр — каты-коты кимертер, хатын югы ямандыр — карт мәткәне кочтырыр.**

**Ике көймә койрыгын тотып булмый.** Бер хиндә[5] ике җирдән файда өмиде бар икән, икесенең мәган[6] хосулы[7] мөмкин булмаган урында ирад кыйлыныр.

**Ике бозауга кибәк аера белмәс.** Һичнәрсә кулыннан килмәс, димәктер.

**Илчегә үлем юк.** «Вә ма гал-р-рәсүли иллял-бәлач[8]».

**Әйләнеч булса да, юл яхшы, аксак булса да, кыз яхшы.**

**Ышанмаганга карганма.**

**Аю да баласына «аппагым» диер, керпе дә баласына «йомшагым» диер.** Моның морадифы:

---

[1] «Ит итне үстерер» мәгънәсендә.

[2] Ибтидасында — башында.

[3] Интиһасында — ахырында.

[4] Мокабиле — кара-каршысы.

[5] Хиндә — вакытта.

[6] Мәган — бергә.

[7] Хосулы — кулга керүе.

[8] «Рәсүлгә (пәйгамбәргә) бары тик Алла сүзен җиткерергә генә тиешле» — Коръән, 5 сүрә, 19 аять; 24 сүрә, 54 аять.

**Этнең — эткә, кошның — кошка.** Һәркемнең баласы үзенә кадерле, димәктер.

**Өеңдәге хәлне күршеңнән сора.** Өең эчендә ни булганын халык сизеп тора, димәктер.

**Бу заманда бияләй эчендә бармак кыймылдатканыңны беләләр,** диерләр.

**Бака сисә, күлгә файда**. «Куллү дахил йанфагу»[1] диясе урында әйтелер.

**Бакча иясенә түтәл юк.**

**Балта-корыч — байдан, үлем — Ходайдан.**

**Балык бирсәң, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир.** «Иннәма әл-ихсан иллә бил-итмам»[2] димәк.

**Бал балчык ашатыр.**

**Бал, «бал» дисәң, бер кими, бармак тисә, икенче кими.** Бал кадерле вә газиз нәрсә икәнлектән гыйбрәттер.

**«Бал», димәк белән авыз татлы булмый.**

**Бардан тия, балдан тама.**

**Бал татлы дип, бармак йотып булмый.**

**Бала туса, заманасына охшар.**

**Байның эше — ялчының тамагы.**

**Бирмәсә дә — бай яхшы, капмасаң да — май яхшы.**

**Байлык ни дидермәс, ачлык ни җидермәс[3].**

**Бер курыккан эт өч көн өрер.** Бер мәшәкатькә грифтар булып котылганнан соң, һаман аны зикер кыйлган кеше хакында ирад кыйлыныр.

**Бер тарыдан ботка булмый.**

**Бер атка ике камыт киертмиләр.** Берәүгә бер хиндә ике хезмәт вакыйг булганда ирад кыйлырлар.

**Бер пычрак сыер бөтен көтүне буйый.** Шәех Сәгъдинең һәм моңар муафикъ бер бәете бар: «Шөнидәстәм ки гав дәр олфзар бийаланд һәме гаван-е деһра»[4]. Ягъни: бер кешенең кәсафәте ничә кешегә сираять кыйлса[5] , зарбе мәсәл китерелер.

**Бер ат аркасында мең ат су эчкән.** Бер кеше өчен хәзерләнгән зыяфәткә[6] ничә адәм наил булган[7] хосуста ирад кыйлыныр.

**Бер төкергән төкерекне кире йотып булмый.** Әйткән сүз кире кайтмый, дигән кабилдәндер.

---

[1] «Һәр кергән нәрсә файдалы» мәгънәсендә.

[2] «Ахырга кадәр җиткерелгән яхшылык кына яхшылык» мәгънәсендә.

[3] Җидермәс — ашатмас.

[4] «Ишеттем мин болында бер [пычрак] сыер авылның барлык сыерларын пычратты».

[5] Сираять кыйлса — йокса, тисә.

[6] Зыяфәткә — сый-хөрмәткә.

[7] Наил булган — ирешкән.

**Бер ир хатын алса, алтмыш хатын егълар.**

**Юк бул, ярлы бул, кулыңда акчаң булсын.** Фәкыйрь кыяфәттә булсаң да, кулыңда акчаң булсын, барлы-юклы акчаң белән байларча булаем, дип тәкәллефләнмә, димәктер.

**Бүләкнең дөясе дә, төймәсе дә бер.**

**Булмас йортка — бөкре хатын.** Ни бәхетсезлек булса, бәхетсез кешегә килә, димәктер.

**Бирсәң — алырсың, иксәң — урырсың.** Гыйлемеңә күрә мөҗазат[1] булыр, димәктер.

**Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз.**

**Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган.**

**Бәла башы бер акча.**

**Белмим бер сүз, беләмен ике сүз.** Ягъни белмим, дидең хәляс[2], беләмен, дисәң, исбат кыйлмак кирәк, җавапка йөрмәк кирәк.

**Белмәгәннең беләге авыртмый.** Дәхи шул мәгънәдә.

**Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.**

**Бии белмәгәнгә көй килешми.** Үзенең белмәгәнен икърар кыйлмый, белмәгәнлеген гайре нәрсәгә иснад кыйлган[3] кемсәнә хакында ирад кыйлыныр.

**Татар теленнән табар.**

**Ташлаган чабатаны яңадан кимиләр.** Аерып җибәргән хатынны яңадан алмак табигатькә мәнфур[4] нәрсәдер, димәк урында әйтелер.

**Кискән икмәк яңадан ябышмас.** Кәзалик[5].

**Тамак тәмугка төшерер.**

**Тамак — гүр, өс — нур.** Ашаган күренми, кигән күренә. Ягъни: һай, пылау ашагансың, дип, сине хөрмәтләмәсләр, өстең-башың яхшы булса, хөрмәт итәрләр, димәктер.

**Каралты түбә белән, адәм кием белән.**

**Тауга карап тау булма.**

**Тавыкны йомырка үгрәтми.**

**Тычкан, тишегенә сыймаса, койрыгына тубал тагар.** Һәрбер илтимас кыйлган[6] кешенең гозерен илтизам кыйлып[7] әда кыйла[8] алмаган кешегә тәгъризан әйтелер.

**Тычканга үлем, мәчегә көлке.**

**Тел белән әйтмичә, бармак белән төртеп булмый.**

---

[1] Мөҗазат — 1) җәза; 2) бүләк.
[2] Хәляс — котылу, азат булу.
[3] Иснад кыйлган — сылтаган.
[4] Мәнфур — җирәнгеч
[5] Кәзалик — шулай ук, шул ук.
[6] Илтимас кыйлган — үтенгән, сораган.
[7] Илтизам кыйлып — үз өстенә йөкләп.
[8] Әда кыйла алмаган — үти алмаган.

**Түзгән түл җыяр.** Мән сабыр зафәра[1].

**Түшәгеңә күрә аягың сузарсың.** Хәлеңә күрә хәраҗатыңны[2] сарыф кыйлырсың.

**Тишек колак ни ишетмәс.** Һәрбер ишеткән сүзне сөйләмәскә тәнбиһтер.

**Тиле түрен бирмәс.**

**Тимер тапкан тилмермәс.**

**Тимерне кызуында сук.** Һәр эшне вакытында әда кыйл, форсат ганимәттер[3].

**Тугры телем таш ярыр.** «Әл-нәҗат фис-садык»[4] мәкамендә.

**Төнлегеннән җил өрми, ишегеннән кеше керми.** Хәсис[5] вә ләимләр хакында ирад кыйлыныр.

**Җабага тайны хурлама, язга чыкса, ат булыр.**

**Чәй чынаягы өч булыр, өчтән ары хуҗага көч булыр.**

**Җете кызыл тиз уңа.** Вә дәхи:

**Кызарып чыккан кояшны болыт каплый.** Әүвәл башта мәдехле вә мактаулы булып та, соңыннан хилафы заһир булган хосуста зарбе мәсәл кыйлыныр.

**Җырның ертыгы юк.** Ягъни бәгъзе шигырьләрдә мөнәсәбәтсез тәшбиһләр[6], вакыйгка мотабикъ булмаган[7] мәгънәләр китереләдер ки, ник алай, ник болай, дип игътираз кыйлынмас[8], димәктер. Мәсәлән:

«Кашларың нечкә бик әйләнгән Казанда бөккән дугадай» дип бәгъзе шигырьдә мәзкүрдер. Мәхбүбләрнең кашын дугага тәшбиһ мөнәсәбәтсезрәк күренәдер. Вә дәһи бәгъзе шигырьдә:

Челтәрле чана куңгырлы,
Тәртәләре яшел тубылгы,—

дип мәзкүрдер ки, тубылгы агачы кызыл буладыр, ник яшел дип китерелгән, дип мөнакашә кыйлынмас[9], димәктер.

**Җабага тайның бете ачы, ярлы кешенең теле ачы.**

**Чынлап егълагач, сукыр күздән яшь чыга.** Мохтаҗлык таптыра, димәктер.

---

[1] «Сабыр кеше теләгенә ирешер» мәгънәсендә.
[2] Хәраҗатыңны — чыгымнарыңны.
[3] Ганимәттер — уңыштыр, бәхеттер.
[4] «Котылу — дөреслектә» мәгънәсендә.
[5] Хәсис — әшәке, саран.
[6] Тәшбиһ — охшату, чагыштыру.
[7] Вакыйгка мотабикъ булмаган — чынга охшамаган.
[8] Игътизар кыйлынмас — каршы киленмәс, дәлил соралмас.
[9] Мөнакашә кыйлынмас — сүз көрәштерелмәс.

**Юкә өзсәң, каеш түләрсең.** Ягъни кеше нәрсәсен тәләф кыйлсаң[1], яхшыракны биреп разый кыйлырсың, димәктер.

**Үрдәк алсаң, каз бирерсең.** Мөҗазәт вә мөкяфатендә «би тәхйатин фә хәййү әхсәни-м-минһа»га[2] ишарәттер.

**Җүләрнең бүрке җүләр булмый, үзе җүләр була.**

**Җүләр егылып үләр.**

**Җүләргә көн дә бәйрәм.**

**Җүләр юкә суяр, гакыллы тәкә суяр.**

**Җүләрне сачеп үстермиләр.**

**Җүләр хатынын мактар, гакыллы атын мактар.** Вә дәхи:

**Чын җүләр үзен мактар, урта җүләр хатынын мактар.**

**Җүн җүнең җетерер.** Ягъни арзанлы нәрсә акчаңны бетерер, димәктән гыйбарәттер, чөнки монда «җүн» ләфзы[3] акча мәгънәсендәдер вә моның морадифендә:

**Ярлы кешенең акчасын яман товар бетерер.**

**Җитез үзен җетерер, акрын эшен бетерер.** Гаҗәлә вә ашыкмактан тәхзир[4] мәкамында.

**Җимешнең асылын эт ашый.** Бер ата баласы газиз вә гүзәл кыз наәһел кешегә бирелсә, тәәссефан[5] зикер кыйлыныр.

**Хатынга ышанма, бозга таянма.**

**Хатын алмак ни кирәк, көн дә батман ит кирәк.** «Ән-никаху фәрхун — шәһер, гам — дәһер»[6].

**Хатын уңса — казна, уңмаса — каза.**

**Дошманның көлгәненә ышанма.**

**Дуңгызны кондыз итәр хәл юк.** Табигъ җибиллисендә[7] яманлык булган адәмне ислях кыйлырмын димә.

**Диңгез баштан болганыр.** Гадавәт вә мохасамә[8] олуглардан зоһур итәр[9], димәктер.

**Димче диңгез кичерер.** «Әл-истишара гайн әл-һидая»-ның[10] морадифыдыр.

**Растлык күзне төртә.** Әл-хакку мөррә[11] мәгънәсендә.

**Заманасына күрә дуңгызны да «җизнәй» диярсең.**

---

[1] Тәләф кыйлсаң — әрәм-шәрәм итсәң, бозсаң.

[2] «Сезгә сәлам биргәндә, яхшырак итеп кайтарыгыз яисә шулай ук сәламләгез» — Коръән, 4нче сүрә — Ниса, 86нчы аять.

[3] Ләфыз — сүз.

[4] Тәхзир — кисәтү.

[5] Тәәссефан — кайгырып, кызганып.

[6] «Никяхның шатлыгы — бер айлык, гаме — гасырлык» мәгънәсендә.

[7] Табигъ җибиллисендә — тумыштан булган холкында.

[8] Мохасамә — низаглашу.

[9] Зоһур итәр — килеп чыгар.

[10] «Киңәш — бәхет ачкычы» мәгънәсендә.

[11] «Хаклык — ачы» мәгънәсендә.

Вакытына күрә дәни кемсәнәләрне дә тәгъзыйм итәрсең[1], диячәк урында әйтелер.

**Сөяксез тел ни әйтмәс.** Хифыз лисанга тәнбиһ мәкамында әйтелер.

**Сөймәснеке сыймас.** Ягъни берәүнең үзен сөймәсәң, аның холкы-фигыле вә гадәте дә мәхбүб түгелдер, ягъни «куллү ма йафгал мәхбүб мәхбүб»нең[2] гакесе[3].

**Симез күркәм, бай чичән.**

**Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер.** «Әл-хаин хаиф»ның[4] морадифыдыр.

**Саплайагы[5] белән бирә, сабы белән төртә.** Изгелеген миннәт иткән[6] кемсәнә хакында әйтелер.

**Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.** Эшнең ибтидасында бәһасен сөйләшмәсәң, низагка мөәдди булыр[7], димәктер.

**Саран ирдә мал торыр.**

**Хисапламый сөйләшсәң, авырмый үләрсең.** «Лисанәкә — әсәдүкә, вәләү әрсәләтәһү — йактүлүкә»[8].

**Су чокыр җиргә җыелыр.** Ни файда булса, байга файда була, димәктер.

**Сукыр тавыкка бар да богдай.** Тәмйиз[9] вә мәгърифәтсез кемсәнә хакында.

**Суфи суган сөймәс, күрсә — кабыгын да куймас.** Ля йөбали[10] булган мөтәсаувифә[11] вә ак кәләпүшләр хакында тәүбихан[12] ирад кыйлыныр.

**Шаталак ак күтәрер, астыртын бот күтәрер.**

**Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый.** Олуглар ашаганда-эчкәндә, кечеләр сабыр итмәккә тәнбиһтер.

**Сыйлаганда су эч.** Ма хазәрә[13] нигъмәте белән берәү хөрмәт итсә, тәшәккерә кабул итмәккә тәнбиһтер.

**Сыйларга сыең булмаса, сыйпарга телең булсын.** Кунакка лаек нигъмәтең булмаса, яхшы сүзең белән хошнуд кыйл[14], димәктер.

---

[1] Тәгъзыйм итәрсең — олыларсың, хөрмәтләрсең.
[2] «Сөйгәнең эшләгән һәр эш сөекле» мәгънәсендә.
[3] Гакесе — капма-каршысы.
[4] «Хыянәтче үзеннән-үзе курка» мәгънәсендә.
[5] Саплайагы — су чүмече.
[6] Миннәт иткән — яхшылыкны искә төшереп сөйләгән, битәрләгән.
[7] Мөәдди булыр — сәбәпче булыр.
[8] «Телең — арыслан, әгәр җибәрсәң, үзеңне үтерер» мәгънәсендә.
[9] Тәмйиз — аера белмәүче.
[10] Ля йөбали — игътибарсыз, пәрвайсыз.
[11] Мөтәсаувифә — суфилык итүче.
[12] Тәүбихан — шелтәләп.
[13] Ма хазәрә — хәзинәдә булган.
[14] Хошнуд кыйл — разый ит, канәгатьләндер.

**Тырманың сирәге яхшы.** Мәҗлестә күп кеше тыгызланып утырганчы, халык азрак булганы яхшы, диячәк урында әйтелер.

**Таз хәйләкәр булыр.**

**Гаепсез бер Алла.** Гаепсез кеше булмас, димәктер.

**Фәлән җирдә казан бар, барсаң — бакрач та табылмас.** Бер җирдән өмид итеп мәэюс булган хәлдә тәәссефан ирад кыйлыныр.

**Капмасаң да, май яхшы, бирмәсә дә, бай яхшы.**

**Каргадан карга туа. Атасына күрә баласы, димәк.**

**Кара сакалың кайда барсаң да калмас.** Бу бер озын хикәяткә ишарәттер. Икъбаленңме[1], идбаренңме[2] — үзең белән бергә йөрер, димәктер.

**Кара эт бәласе ак эткә.** Бер яманның кәсафәте яхшы кешегә сираять кыйла[3], дигәндә зарбе мәсәл кыйлыныр.

**Карама беләккә, кара йөрәккә.** Кешенең сурәт заһирисенә вә кыяфәтенә игътибар итмә, мәгърифәтенә кара, димәк.

**Кара халык — кара сарык.** «Әл-гавам кәл-һәвам»[4] диячәк урында.

**Капчык эчендә без ятмый.** Яманлык бер фаш булмаенча булмый.

**Какма кеше капкасын, кагарлар үз капкаңны.** Кеше гаебен күрмә, үз гаебеңне күрерләр. «Мән карраге — коррига»[5].

**Кайткан малда бәрәкәт бар.** Базарга мал алып барып сатылмый кайтса яки әманәт кайтса, тәфәәлән[6] әйтелә торган сүздер.

**Кол ашаганын мактар.**

**Карга күзен карга чыгармас.** Җенес[7] җенесне ригая кыйлыр[8], түрә түрәне яклар, димәк.

**Курыкканга куш ишетелер.**

**Елан чаккан киндерәдән куркыр.**

**Коры борчак бүрәнәгә ябышмый.** Пакь-даман[9] вә гаепсез кешегә төһмәт[10] вә гаеп исбат кыйлынмас, димәктер.

**Кунак кунакны сөймәс, өй иясе берсен дә сөймәс.**

**Кунак — өй иясенең ишәге.** Кунак өй иясенә табигъ

---

[1] Икъбалең — бәхетең.
[2] Идбарең — бәхетсезлегең.
[3] Сираять кыйла — йога, күчә.
[4] «Гади халык — зарарлы бөҗәкләр кебек» мәгънәсендә.
[5] «Кем сугә — шул сугелә» мәгънәсендә.
[6] Тәфәәлән — яхшыга юрап.
[7] Җенес — бу урында: төр, иш.
[8] Ригая кыйлыр — кайгыртыр, олылар.
[9] Пакь-даман — намуслы.
[10] Төһмәт — яла.

вә мотавәгать булмакка[1] тәнбиһтер. «Җәллис мин кәйсү йөҗәллис»[2] дигәнгә ишарәттер.

**Кулыңдагын нык тот, күршең белән тату тор.** Алышбиреш ясап, күрше хакын заегъ итмә.

**Күп йөргән азар, күп сөйләшкән язар.** «Мән кәсүрә кәламүһ кәсүрә зүнүбүһ»[3].

**Дөньяны җил бозар, адәмне сүз бозар.**

**Сүз бозау имезер.** Бер хикәяткә ишарәттер, күп сүзгә кереп китеп, эшеңне онытма, димәктер.

**Күпне өмид итеп, аздан коры калган.**

**Күп яшәгән ни белгән, күпне күргән ул белер.** Тәҗрибәгә тәргыйб[4] мәкамында әйтелер.

**Кесәле — өйдә, сүке[5] — тышта.**

**Күп ашасаң — аз ашарсың, аз ашасаң — күп ашарсың.** Канәгатькә тәнбиһтер.

**Күз — дәрья.**

**Күрше тавыгы күрекле.**

**Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә.**

**Күрми күргән көндез чыра яндырыр.** Яки: көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр. Фәкыйрьлектән дәүләткә ирешкән кеше хәраҗәтен мигъярсыз сарыф кыйлганда әйтелер.

**Күңелсезгә күлмәк киертмиләр.** Кешене көчләп яманлыкка өндәмиләр, диячәк урында әйтелер.

**Гәүһәр җирдә ятмас.**

**Көнен күрсен, көлдә аунасын.**

**Көяз туңмас, калтырар.**

**Күңел ни теләми, язык җибәрми.** Нәфес белән гакылның мөҗадәләсенә[6] ишарәттер.

**Кибән астында тычкан үлми**. Ире бик дәү булып, хатыны бик кечкенә булып, гаҗәп, бу хатын бу иргә ничек чыдый, дигәндә зарбел-мәсәл китерелер.

**Киңәшле туй таркалмас.** Мөшаварәгә тәргыйб[7] мәкамында әйтелер.

**Килен белгән бер нәкыш.** Һаман бер эштә гадәтләнгән, һаман эштә, димәк.

**Мал — бавыр ите.** «Әл-мал шәкыйк әр-рух»[8] диерләр гарәпчә.

---

[1] Табигъ вә мотавәгать булмакка — буйсынырга, баш иярге.
[2] «Кайда утыртсалар, шунда утыр» мәгънәсендә.
[3] «Кем күп сөйләсә, гөнаһысы артыр» мәгънәсендә.
[4] Тәргыйб — өндәү.
[5] Сук — киндер орлыгыннан ясалган сөт сыман сыекча.
[6] Мөҗадәләсенә — сүз көрәшенә, бәхәсләшүенә.
[7] Мөшаварәгә тәргыйб — киңәшләшергә өндәү.
[8] «Мал — рухның бер туганы» мәгънәсендә.

**Май чүлмәге тышыннан билгеле.**

**Мә аягың, бир табагым.** Нигъмәтенә мокабил галәл фур[1] артыграк мөкяфәт өмид иткәннәр хакында ирад кыйлыныр.

**Мәлсез чәчәк яралмас.** «Әл-омур мәрһунәта би аукатиһа»[2] көллиясенә морадиф сүздер.

**Мулла барда телең тый, оста барда кулың тый.** Галимнәрдән вә муллалардан алда узып сөйләшмәктән мәныйг вә нәһи[3] мәкамында әйтелер.

**Мир — мур.**

**Мир төкерсә, күл булыр.** Җәмәгать вә күплектә кувәт бар. Янә моның морадифы:

**Күп авыз бер булса, бер авыз юк булыр.**

**Һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре.** Һәркем үзенең табигате икътизасынча[4] үз файдасына гамәл кыйлыр, димәктер.

**Гакыл айнымас, алтын черемәс**. Бу мәсәл гакыл табигый хакында булмак дәркярдер ки, артмак вә кимемәкне кабил түгелдер, димәк.

**Май сасымас, кыз картаймас.** Озак кияүгә китми яткан кызны никяхка тәргыйб мәкамында әйтелер.

**Ярлы кеше акчасы торна булып кычкыра.** Чөнки фәкыйрь кеше акчага мәләкәләнмәгәнлек сәбәпле, хирыслыгы һәм юктыр ки, кулына төшкән акчаны тизрәк сарыф кыйлмага мәеле барлыктан, гүя акчасы «мин китәмен» дип кычкырып тора, димәктер.

**Һөнәрле кол үлмәс.** «Әс синагат фил кәфи әман мин әлфәкъри фикърә»сенә[5] ишарәттер.

**Язганны күрерсең, сачкәнне урырсың.** Тәкъдиргә иман китермәгә тәргыйб мәкамында әйтелер.

**Яман булсаң — асарлар, юаш булсаң — басарлар.** Тәвәссыт вә гадәләткә[6] тәргыйб вә шөҗагатьнең[7] тарафәендин[8] тәхдир[9] мәкамында әйтелер ки, гамәлияне[10] мөштәмил[11] үзе бер китаплык сүздер, фән күргән кешегә хәфи[12] булмаса кирәк, шаять, фәһем итәр.

---

[1] Мокабил галәл фур — кара-каршы.
[2] «Эш вакытында эшләнергә тиеш» мәгънәсендә.
[3] Мәныйг вә нәһи — тыю.
[4] Икътизасынча — теләвенчә, соравынча.
[5] «Кулдагы һөнәр — фәкыйрьлектә терәк» мәгънәсендә.
[6] Тәвәссыт вә гадәләткә — уртача һәм гадел булуга.
[7] Шөҗагатьнең — батыр, гайрәтле булуның.
[8] Тарафәендин — һәр ике чигеннән.
[9] Тәхдир — качыру, тыю.
[10] Гамәлия — эш, әмәл.
[11] Мөштәмил — үз эченә алу.
[12] Хәфи — яшерен, билгесез.

**Яхшыга көн юк, яманга үлем юк.** Галибән[1] изге адәмнәрнең вафатына тәәссефан зикер кыйлыныр.

**Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы.** Яман сүзнең әсәре кувәтле булмак җәһәтендин хифыз лисанга тәргыйб мәкамында.

**Яхшы хатын арыш онын кәбаб итәр, яман хатын богдай онын харап итәр.**

**Егъламаган балага имчәк бирмиләр**. Хаҗәтең әда кылынмак өмид ителгән җирдә сөальдән мәныйгләнмә, диячәк урында зарбе мәсәл кыйлыныр.

**Егылганны түбәлә.**

**Егет — егетнең көзгесе.**

**Яманнан җәя буе.**

**Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз.** Гыйлем вә мәгърифәт, вә һөнәргә тәргыйб мәкамында әйтелер.

**Йөргән таш шомарыр, тик яткан таш мүкләнер**. Җиһан гизгән вә сәфәр кыйлган тәҗрибә вә мәгърифәт хасыйл итәр, димәктер.

**Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.**

**Юктан бар булган, Тәңре белән тиң булган.** Фәкыйрь хәлдән дәүләткә ирешкән кешенең гаять тәкәббер булмагыннан гыйбрәттер ки, зәм[2] мәкамында әйтелер. Әл-гыйазе билләһи[3] түгелдер ки, башка сыйфатта тиң булсын. «Һүә-л-җәбберу-мөтәкәббир»[4] — Аллаһы Тәгаләгә махсус сыйфаттыр.

**Бардан юк булган, үлем белән тиң булган.** Байлыктан фәкыйрь хәлгә төшкән кеше, вакыйган, үлем белән бәрабәрдер.

**Сәнәктән көрәк булган.** Дәни вә хәсис кемсәнә бер дәрәҗәгә ирешсә, аны зәм мәкамында китерелер.

**Йокы ястык теләми.** «Иза җааән-науму лә йотлабу әл-фираш»[5].

**Юл газабы — гүр газабы.** «Әс-сәфәр кыйтгат минәс-сәкар»[6].

**Ни чәчсәң, аны урырсың.** Изге гамәлгә дә, явыз гамәлгә дә мөҗазәт булыр.

**Хатыннарның саче озын, гакылы кыска.**

**Чыгасы канны тире тыймас, чыгасы малны ир тыймас.**

**Хат көтмәгән көнең — таң атмаган төнең.**

**Гакыллы уйлап торганчы, тинтәк эшен бетерер.**

---

[1] Галибән — күбрәк.
[2] Зәм — шелтә, әр.
[3] Әл-гыйазе билләһи — Аллам сакласын.
[4] «Ул бөек кодрәт иясе һәм бөекләнгән» мәгънәсендә.
[5] «Йокы килсә, ястык сорап тормас» мәгънәсендә.
[6] «Сәфәр — җәһәннәмнең бер кисәге» мәгънәсендә.

**Алтмышныкы бетә, алтыныкы кала.**

**Күп тә бетә, аз да җитә.**

**Кырык өйдән кырпулык.**

**Балта чапканчы түмгәк ял итә.**

**Киткән кыздан пумала курка.**

**Әйткән — юлда, биргән — кулда.** «Ән-накд хайр мин ән-нәсия»[1] дигән көллиягә ишарәттер. Вә дәхи:

**Таңдагы тавыктан бүгенге йомырка артык.**

**Һавадагы торна.**

**Күтәрә белмәгән күп күтәрер.** Кодрәтеннән килмәгән эшләрне илтизам кыйлганнар хакында зарбе мәсәлдер.

**Берәү акча җыя, берәү капчык тегә.** Берәүнең дәүләте берәүгә күчсә, мәсәл китерелер.

**Арты кычыткан Әстерханга барыр.** Берәү үзеннән-үзе бәла вә мәшәкатькә грифтар булса ирад кыйлыныр.

**Каршы агачка каты чөй.** «Можәзәт-бил-мисал»[2].

**Өй салмакның нисе бар, мүкләсе дә чутласы.** Эшне сәһел[3] хисаплаганнарга рәгъмән[4] әйтелер.

**Куган да Алла, качкан да Алла, ди.** Залим булса да, мазлум булса да, Аллага илтиҗа кыйлыр, димәк.

**Ялгызлык бер Алланың үзенә ярашыр.** Тәәһһелгә тәргыйб[5] мәкамында китерелер.

**Кул кулны белә.** Нәрсәне кемнән алдың, үзенә тапшырмакка тәнбиһтер.

**Барның эше фәрман белән, юкның эше дәрман белән.**

**Эт симез, ашарга ярамый.**

**Кыңгыр эш кырык елдан соң беленә.** Хыянәт фаш булмый калмас, димәктер.

**Киләсе көннең билгесе юк, үткән көннең кайгысы юк.**

**Ачы булсаң — тоздай бул, татлы булсаң — балдай бул.** Яки икенче:

**Тоздай ачы булма, балдай татлы булма.** Ифрат тәфрыйттән[6] тәхзирдер.

**Ике дәрвиш бер паласка сыяр, ике падиша җир йөзенә сыймас.**

**Ике ат башы бер казанга сыймый.**

**Яхшылыкка яхшылык — һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык — ир кешенең эшедер.**

**Чалкайганга чалкай башың күккә җиткәнче, иңкәй-**

---

[1] «Кулда булган байлык — көтәчәктән хәерле» мәгънәсендә.
[2] «Бүләккә — шундый ук бүләк» мәгънәсендә.
[3] Сәһел — җиңел, ансат.
[4] Рәгъмән — каршы.
[5] Тәәһһелгә тәргыйб — өйләнү, кияүгә чыгу, гаиләле булуга өндәү.
[6] Тәфрыйт — чиктән тыш булу.

**гәнгә иңкәй, башың җиргә тигәнче.** Ягъни тәкәбберг тәкәббер садака, димәктер.

**Таш белән атканга аш белән ат.**

**Юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын.** «Әррәфыйк сөммә әт-тарик»[1].

**Үзеңнән түбәнгә карап шөкер ит, үзеңнән югарыга карап фикер ит.**

**Туганда кара туганны сабынлап юсаң да агармас.**

**Бүгенге эшне иртәгә калдырган кешенең эше һич бетмәс.**

**Бер хатынның хәйләсе кырык ир хәйләсеннән артыктыр.**

**Итегең тар булса, дөнья киңлегеннән ни файда, хатының яман булса, йортның тынычлыгыннан ни файда?**

**Атың яман булса — сатып котылырсың, агай-энең яман булса — качып котылырсың, хатының яман булса, ничек котылырсың?**

**Күп картның эчендә бер бала дана[2] булыр. Күп баланың эчендә бер карт бала булыр.**

**Яман җирдә ятсаң, яман төш күрерсең, яхшы җирдә ятсаң, яхшы төш күрерсең.**

**Иелгән башны кылыч кисмәс**.

**Абруеңны ачты.** Ягъни гаебеңне изһар кыйлды[3]

**Авызына бал да җау[4].** Яхшы хәбәр китергән кешегә әйтелер.

**Авызына сумала чапкан.** Ягъни хак эштә сөкүт кыйлган[5] кешегә әйтелер.

**Азамат ирнең баласы өстенә яу килсә дә моңаймас.**

**Ай-вай, эшләгән кеше нидән бай.**

**Ай кебек калкыды, кояш кебек балкыды.**

**Алдырыр көн яздырыр.** Ягъни гафил булып бер нәрсәңне угырлатсаң, язарсың, ягъни саташырсың вә гакылдан чыгарсың. Чөнки нәрсәсен җуйган кеше әүвәл дәфга[6] дивана сыйфат буладыр.

**Аллага бетсәң[7], бер тиен акчам юк.**

**Алмазны алмаз белән кисәләр.**

**Анадан кыйшык туганны тезгә салсаң да тураймас.**

---

[1] «Башта — юлдаш, аннан — сәфәр» мәгънәсендә.
[2] Дана — галим.
[3] Изһар кыйлу — ачып салу, күрсәтү.
[4] Җау (йау) — май.
[5] Сөкүт кыйлу — дәшми тору, тын тору.
[6] Әүвәл дәфга — беренче тапкыр, башта.
[7] Бетсәң — ышансаң.

**Аннан кул селкедем.** Ягъни аннан өмид өздем.

**Аның күле тирән.** Ягъни бай.

**Аның мәчесе дә куян тота.** Ягъни эше һаман алга бара, димәк.

**Аркамны бет ашый, эшләгәнемне эт ашый.**

**Артында патшаны да сүгәләр.**

**Асыл сөяк асылмас.**

**Ата угылны белми, ана кызны белми.** Ыгы-зыгы.

**Ач дөньяда икмәк юк санар.**

**Ачулансаң, борының тешлә**. Нитәкки борын тешләмәк мөмкин түгел, кәзалик ачуың белән һичнәрсә кыйла алмыйсың, димәк.

**Ашын ашаган, яшен яшәгән.** Гомере ниһаятенә[1] иреште, гомеренең ләззәтен күрде. Инде үлсә дә кайгы юк, диясе урында әйтелер.

**Аяз булса — суытыр,**
**Болыт булса — җылытыр.**

**Аяк сузды.** Ягъни вафат булды.

**Аяк тыккач, тояк та тыгасы.** Ягъни бер җирдән файда күреп, янә аннан артыграк файдага касд кыйлмак.

**Аяк урынына тояк.** Ягъни ат сатып, тай алган кебек.

**Байга ни сөйләсә дә килешә.**

**Балтасы суга төшкән.** Ягъни хафа.

**Бар да бер авызда.** Ягъни һәммәсе дә бер иттифакта[2].

**Бары-югы бәрабәр.** Ягъни булса ни, булмаса ни.

**Барына канәгать кыйл, югына сабыр ит.**

**Баш күзеннән ни файда, күңел күзе күрмәсә.**

**Бер колагымнан керер, бер колагымнан чыгар.**

**Берсе арыкта, берсе тарыкта.** Ягъни бер-береннән ерак торалар.

**Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына.**

**Битең сыптыр.** Ягъни өмид өз.

**Богдаен ал, саламына ут төрт.**

**Бозау арты белән киртәгә менгәндә.** Ягъни тәгъликы мөхаль мөхаль[3], димәк.

**Борыны төште.** Ягъни киберенә[4] тиде, тәкәбберлектән кайтты, димәк.

**Бохарага барса, аның аягын җиргә тидермәсләр иде.** Ягъни асарлар иде.

**Булыр-булмаска ышанма, кулыңдагыдан аерылма.**

---

[1] Н и һ а я т е н ә — соң чигенә.

[2] И т т и ф а к т а — бер сүздә, бер киңәштә булу.

[3] «Аңлатып булмаганны аңлатып булмый» мәгънәсендә. Үтәлү шарты һич мөмкин булмаган эш.

[4] К и б е р — үзен зур күрүчәнлек, тәкәбберлек.

**Буш куллы.** Ягъни фәкыйрь.
**Бүрәнә үтә бүре куа.**
**Бүре сырхавы.** Ягъни ачлык.
**Бүрек калыбы.** Ягъни бүрекчеләр.
**Дин угрысы.** Ягъни мораи[1] кемсәнәдер.
**Дөнья иманы.** Ягъни акча.
**Дөнья күргән.** Ягъни әһле тәҗариб.
**Дуга белән печән чаба.** Ягъни «ма нәхнү фиһа»не[2] фәһемләми гайре җәһәттән сөйләшә.
**Җамы фиргавен.** Ягъни фиргавен стаканы — шәраб савыты, гаять зур булучылыгыннан гыйбарәттер. Нитәкки берзаман зур чынаякны Тәтеш пудаукасы диерләр иде.
**Җәймә түгел җәяргә.**
**Ука түгел чукларга.**
**Җәяүлегә янчык авыр.**
**Җил ягына салам кыстырмак.** Ягъни хиффәтрәк[3] табигатьле кешене мәдехләмәк вә аның морадында вә максатынча булмак.
**Җил җак,** яки: **җил куар.** Ягъни ахмак.
**Җиргә керергә җитте.** Ягъни гаять оялды.
**Җүләр әйтер «җиңдем» дип, акыллы әйтер «юл куйдым» дип.**
**Ике азан әйтмиләр.** Ягъни бер вакыт өчен ике азан әйтмиләр; бер сүзне урынсыз ике мәртәбә тәкрар кыйлмыйлар.
**Ир канаты ат булыр,**
**Кыз канаты хат булыр.**
**Ир хурламак постырыр,**
**Аш хурламак костырыр.**
**Иркә кайда — җүләр анда.**
**Исәпсез май җыяр.**
**Иш — ише, куш кушы белән.**
**Калган хәтер — чыккан җан.**
**Капка ачыла башлады.** Ягъни йокы килә.
**Кар башын кар ашый.**
**Кара сакал.** Ягъни фәкыйрьлек вә ихтыяҗ.
**Кара төлке***, яки **газиз[4]-ел-вөҗүд[5].** Ягъни берәү бик сирәк күренсә, «кара төлке булдың» диләр.

---

* К.Насыйри «Ләһҗәи татари» сүзлегендә (1 т., 144 б.) «Кара төлке — төлкенең иң кыйммәтле нәүгыдер (төредер)» дип аңлата.
[1] Мораи — күз буяучы, риялык итүче.
[2] «Эчендә нәрсә барлыгын, ягъни асылын белмичә» мәгънәсендә.
[3] Хиффәтрәк — җиңел акыллылык.
[4] Газиз — кыйммәтле, сирәк була торган.
[5] Вөҗүд — барлык, бар булу.

**Кара чебен.** Каенсар, ягъни мәкъбәрәлек[1].

**Карга, тутый кош йөрешен йөреп, үз йөрешен оныткан.**

**Кәкре каенга терәтте.** Ягъни алдады.

**Кем арбасына утырса, аның җырын җырлый**.

**Кеше «ак» дисә, ул «кара» диер.** Тискәре.

**Кешегә казыган чокырга үзең төшәрсең.**

**Коры кашык авыз ерта.**

**Колагына чүбек тыккан.** Хак сүзне тыңламый, диячәк урында әйтелер, вә хак сүзне кабул итмәгән кемсәнә.

**Көймәсе комга утырды.**

**Куян белән уйнама — чарчарсың,**
**Ут белән уйнама — көярсең.**

**Куян йөрәк.** Ягъни җөбен[2].

**Күздән төште**. Ягъни игътибардан чыкты.

**Күккә баксам — күк ерак,**
**Җиргә баксам — җир каты.** Ягъни һич вәҗһедән[3] өмидем юк, һичкем мөшфикым[4] юк.

**Күңел кошы.** Ягъни гакыл.

**Күп борчак атасың,** диерләр. Ягъни күп ялганлыйсың мәгънәсендәдер.

**Кызыл кар яуганда.** Ягъни һичкайчан.

**Кыяк тешләде.** Ягъни качты.

**Мин «күк» дисәм, ул «җир» ди.**

**Наданга тик тору җавап.**

**Орды бүрене койрыкка.** Һичбер нәрсә кыйла алмады, димәктән кинаядер.

**Өстенә кояш чыгармый.** Ягъни бик иртә тора.

**Печән юлы белән бара.** Ягъни морадны фәһемләми[5] сөйләшә.

**Пешкән кеше**. Ягъни дөнья күргән кеше. Җиһан диде, кар азмуды[6].

**Саран кеше акчадан туймас.**

**Сәфәргә чыксаң, әүвәл юлдаш тап.**

**Сезнең илдә көн дә бәйрәм, көн дә туй,**
**Безнең илдә көн дә сагыш, көн дә уй.**

**Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.**

**Сөяксез бәрәңге була.**

**Суда көймә эзе беленми.**

---

[1] Мәкъбәрәлек — каберлек.
[2] Җөбен — куркак.
[3] Вәҗһедән — яктан.
[4] Мөшфикым — шәфкать итүчем, аяучым.
[5] Фәһемләми — аңламый, төшенми.
[6] «Дөньяны күргән, эшне өйрәнгән» мәгънәсендә.

**Сукыр дәүләт.** Ягъни дәүләткә әһел[1] булмаган кешенең дәүләте.

**Суык куллы**. Ягъни угры.

**Тавык йөрәк.** Ягъни җөбен, куркак.

**Тавык мие эчкән.** Ягъни габи[2], фәһемсез.

**Татар барда хәтәр бар.**

**Татар татлысын алдан ашар.**

**Татарның акылы соңыннан килә.**

**Тау тауга кавышмас, адәм адәмгә кавышыр.**

**Таш күңел.** Яки: **таш йөрәк**. Ягъни рәхимсез вә шәфкатьсез.

**Таягы керсә, аягын да кертмәкче була.** Ягъни берәү бер җирдән бер мәртәбә ихсан[3] күрсә, һаман шуны көтәдер.

**Тәртәсе кыска.** Ягъни ачуланучан, сабырсыз.

**Тешең кыс.** Ягъни сөкүт кыл.

**Тик йөрмәсәң, тук булырсың.**

**Тимер борчак.** Саран кеше хакында.

**Тимерчедән күмер артмас.**

**Тимерченең балтасы китек.**

**Тиресенә сыймый.** Гаять тәкәбберлектән гыйбарәт.

**Төтенсез авыл**, яки **каенсар.** Ягъни мәкабир[4].

**Уен да уен, юкә үбеш тә уен[5].**

**Укымыйча мулла булган, чукымыйча карга булган.**

**Унҗиде суккач*, ашлык чәчмиләр.**

**Урман киексез булмас.**

**Утынны чапкан яксын,**
**Баланы тапкан баксын.**

**Үзеңне зур тотма, кешене күр тотма.**

**Үлән арасыннан ут йөртмәк.** Кинәле вә яшерен эш кылмак.

**Үлгән артыннан үлеп булмый.**

**Үлгән таракан.** Ягъни гафил, җамид[6], фәһемсез.

**Үрәледә — бер кич, боткалыда — ике кич.** Ягъни көн-төн кеше өстендә йөри.

**Халык авызы — капка.** Ягъни халык теләсә, сөйләр, туктатыр хәл юк.

**Халык авызына керде.**

**Халык җилкәсен кимерүче.** Ягъни залим.

**Һавадагы торна.** Ягъни кулга кермәгән нәрсә.

**Һавасы[7] төште.**

---

* Унҗиде суккач — көн озынлыгы 17 сәгатькә җиткәч.

[1] Әһел — биредә: лаеклы.

[2] Габи — аңгыра, зиһенсез.

[3] Ихсан — ярдәм, яхшылык.

[4] Мәкабир — каберлекләр.

[5] Юкә үбеш — бер уенның исемедер. — *К.Н.*

[6] Җамид — туң, каткан.

[7] Һавасы — һавалануы, борын чөюе, тәкәбберлеге.

**Чикмән калыбы,** яки **коры сурәт**. Ягъни һөнәрсез.
**Чиләгенә күрә капкачы.**
**Чуен кисәге.** Ягъни кара кеше, димәк.
**Чыкмаган җанда өмид бар.**
**Чыпчыгы очкан.** Ягъни бәкярәте[1] киткән.
**Ырыкныкы — ырыкка, шырыкныкы — шырыкка.** Ягъни, мал хәрәмнән килгән булса, хәрәмгә, хәлялдән килгән булса, хәлялгә, димәктән кинаядер.
**Элгәре килгән урын өчен.**
**Элеп алды, селкеп салды.** Ягъни гаять сүгү белән сүкте.
**Эчле-тышлы йөри.** Ягъни ихлас күңелдән түгел.
**Ялгыз яуга боерсын.**
**Ярлы кеше яманыр да куаныр.**
**Ярык барабан.** Мәгънәсез күп сөйләүче ирад кыйлыныр.
**Яхшыдан яман туган.**

## СЫНАМЫШЛАР ҺӘМ ЫШАНУЛАР

### Гыйнвар

6сында[2] тулы ай —
Язгы ташу суга бай.

6сында көн җылы —
Кырда икмәк бик куе.

6сында ябалак кар —
Кырда иген бик уңар.

10ында бәс тотса,
Җәй яңгырлы килә.

24 ендә булса аяз —
Бик нәфис килер яз.

### Февраль

Әүвәл киче аяз —
Бик соң килер яз.

2 сендә иртә белән кар —
Ашлык иртә чәчкәне уңар.

Кич белән кар яуса,
Гаҗәп түгел соң чәчкәне уңса.

[1] Бәкярәте — гыйффәтлелеге.
[2] Көннәр иске стиль буенча күздә тотыла.

## Март

Марттагы кар —
Бакча җимешенә бик ярар.

Март берендә аязлык —
Җәй көн кыярга туклык.

Март берендә кайдан җил булса,
бөтен җәй шуннан җил булыр.

25ендә яңгыр булса, арыш игене уңар.

Март берендә аяз —
Аяз булыр бөтен яз.

17сендә көннәр елтырый —
Таудан сулар чылтырый.

## Апрель

5ендә Хозыр Ильяс камчы селти,
ягъни кар көн-төн китә.

## Май

Майда курмың уртак булсын.

Май ае салкын булса, игенгә туклык.

6сында булса чык —
Ул ел кыярга тук.

9ында бака кычкыра башлый. Солы тишелә башлый. Бәрәңге утыртырга вакыт.

Никола[1] көн җил булса, бөтен җәй җил.

Никола җитми җәй булмый,
Никола җитми кыш булмый.

11ендә юеш булса,
Бөтен җәй юеш.

19ында кыяр утырт.

13ендә озын борын чыга.

29ында арыш башак ташлый.

[1] Никола (яки Микула) — искечә 9 май һәм 6 декабрь.

## Июнь

Зендә булса төшлектән җил —
Сабан ашлыгына килә ел.

4ендә җитен чәч.

8ендә яшенләсә әгәр яшен,
Җыя алмассың печәнең яшел.

27сендә яңгырлы —
Җиде атна яңгырлы.

Булса аяз Питрау[1] көн,
Булыр яшел печәнең.
Яңгырлы булуы —
Кырда печән черүе.
Ягъни: Питрау көн яңгырлы булса,
чапкан печәннәр черер.

## Июль

Берендә үлән арасыннан ут йөгерә башлый, һәм тимерчедә ураклар күренә башлый.

4ендә солы ярты үсә.

Инҗил[2] көн өйләдән элгәре җәй,
өйләдән соң — көз.

Арыш соң өлгерсә, Симән[3] көненә чаклы чәч.
25ендә кырау булса, кыш суык килә.

## Август

Икенче Ыспаста арыш чәчү башлана[4].

Җитсә икенче Ыспас,
Бияләй ал кулыңа запас.

Өченче Ыспас —
Кыяр тозла кышка запас.

15енә чаклы сука бетер.
Бер чүмәлә артык китер.

---

[1] Питрау — искечә 29 июнь.
[2] Инҗил (яки Илҗин) — Илья көне, искечә 20 июль.
[3] Симән көне — Симен Столпник көне, искечә сентябрь башы.
[4] Беренче Ыспас — искечә 1 август, икенче Ыспас — 6 август, өченче Ыспас — 12 август.

## Сентябрь

Имән әкәләсе күп булган елны кыш җылы килә, һәм алдагы җәй — туклык.

Җәй кунак — Симән көне озата.

Көз, ягъни сентябрь, аяз — кыш салкын.

Булса 11е сентябрь,
Җәйдән инде бит сыптыр.

14ендә чикмән төшә, тун менә.

15ендә каз оча кышларга,
Шалкан кис базга ташларга.

28ендә каз очса, Покраудa[1] кар ята.

## Октябрь

Октябрь ни арба, ни чана.

Агач яфрак соң койса, ел авыр килә.

Яфрак җиргә капланып төшсә, иген булырга галәмәт.

Әүвәлге карны күрсәтсә, кырык көннән кар ятыр.

Покрау җылысы алып кал, ягъни Покраудa йорт тирәңне кара.

Покрау көн җил кояш чыгышыннан кышка суык китерә, ягъни кыш суык килер.

Октябрь япмаса, Раштуа[2] һәм япмас, ягъни октябрьдә кар яумаса, Раштуага чаклы яумас.

## Ноябрь

Ноябрь кар өрә —
Галәмгә ашлык китерә.

Яңгыр өстенә кар булса, печән бик уңар.

Төнлә былчырак өстенә кар булса, җиргә нык ятыр.

---

[1] Покрау — Покров көне, иске стиль белән октябрь башы, ягъни 1 октябрь.
[2] Раштуа — Рождество, 25 декабрь.

Күҗмә күпер суга, Никола кадак кага.

9ында бәс булса — суыкка, томан булса — җылыга.

11ендә йомшата, азрак-азрак боз вата.

Октябрь — кара бия, ноябрь — ала бия, ягъни октябрь — кара җир, ноябрь — ала кар.

### Декабрь

Иделдә күрүн* күп булса — иген уңарга.

Кар стенага сылап яуса, җәй начар килә.

Стена арасы ачык калса — фәраванчылык.

Никола җитми, кыш булмый,
Никола җитми, җәй булмый.

25ендә агачларны бәс тотса,
Алдагы җәй иген уңар.

Җидедә җиткезә,
Сигездә сикертә,
Тугызда туктата,
Унда уйната,
Унбердә — күк табан,
Уникедә — б... табан**.

* * *

Кояш кызарып чыкса яки кызарып баеса, җил булыр.

Кояш баеганда томан яки болыт булса, иртәгә яңгыр булыр.

---

* Күрүн — бу сүзне К.Насыйри «Ләһҗәи татари» сүзлегендә (2 кис., 62 б.) «Иделдәге боз» дип аңлата.

** Бу сынамышны Н.Исәнбәт түбәндәгечә аңлата: *җидедә җиткерә* — искечә җиденче декабрьдә көннең кыскалыгын җиде сәгатькә, ягъни соң чигенә җиткерә, шуннан да ары кыскармый; *сигездә сикертә* — көн озынлыгы сигез сәгатькә җиткәндә, искечә гыйнвар сигезләрендә, кышның ызгары — крещение суыклары кешене сикертә; *тугызда туктата* — көн озынлыгы тугыз сәгатькә җиткәндә, искечә гыйнвар егерме тугызында, салкыннарын туктата; *унда уйната* — көн озынлыгы ун сәгатькә җиткәндә, искечә февраль унында, кояш үзенең нурларын уйната башлый; *унбердә — күк табан* — көн озынлыгы унбер сәгатькә җиткәндә, искечә февраль егермесендә, чана юлы нык, кышкыдай күк булып тора; *уникедә* — б... табан — көн озынлыгы унике сәгатькә җиткәндә, искечә март бишендә, чана юлы карая (ат тизәге калкып чыга). **Кара**: Татар халык мәкальләре.— Казан, 1959.— 436–437 б.).

Кояш баеганда кызыл булып күренсә, җил булыр.

Кояш тирәсендә алка кебек күренсә, яңгырлы булыр.

Кыш көне кояш тирәсендә алка кебек булса яки кояш колаклы булса, бик суык булыр.

Ай караңгы булып торса, һава юеш булыр, җепшек булыр; әгәр ачык булып ялтырап торса, һава коры булыр.

Ай колаклы булса, суык булыр — кыш көнендә; әмма җәй көне колаклы булса, яңгыр булыр.

Ай тирәсендә алка кебек булса, җил булыр.

Ай тирәсендә кызыллык алка кебек булып тиз бетеп китсә, аяз булыр.

Ай тирәсендәге алка караңгы төсле булса, суык булыр.

Яңа туган айның баш-башы бик очлы булып, бик бөгелеп торса, аяз булыр — җәйдә. Кыш булса, суык булыр. Баш-башы җәелеп торса, яңгырлы һава, юеш, пычрак булыр.

Яңа айның югары башы җәелебрәк, түбән башы урак кебек бөгелебрәк торса, кыш көне айның унбишенә кадәр салкын булыр. Җәй көне булса, җил булыр унбишенә кадәр. Әгәр югары башы бөгелеп, түбән башы җәелеп торса, унбишенә чаклы салкын һәм җил булыр, унбишеннән соң юеш, былчырак булыр.

Айның дүртенче көнендә һава ничек булса, бөтен ай шулай булыр.

Ай тулы вакытта саф һәм якты, ялтырап торса, һава яхшы булыр.

Җәй көне йолдызлар бик чекрәеп ялтырап торса, һава коры һәм эссе булыр. Әмма кыш көне шулай булса, көннәр суык булыр.

Йолдыз тирәсендә кара алка булса, яңгыр булыр.

Кич аяз булып та, йолдызлар аз күренсә, яңгыр булыр.

Йолдыз атылса, җил булыр.

Ерактагы нәрсә аермачык күренерлек булып, һава бик саф булса, аязлык булыр.

Һава болытлырак булып, кызгылт булып торса, өермә белән яңгыр булыр.

Җил кояш артыннан килсә, көн аяз булыр. Ягъни җил кояш чыгышы тарафыннан килсә, һава байтак көннәргә чаклы төзәлеп торыр.

Әгәр җәй көне төшлек тарафыннан кыйбладан җил килсә, һава яхшы булыр. Кыш көне булса — көн җепшек булыр.

Җил кояш баешы тарафыннан килсә, һаман яңгыр китерер.

Җил төн ягыннан килгәндә, һава суык булыр. Кирәк кыш, кирәк җәй.

Салават күперенең яшеле бик ачык яшел күренсә, көн яңгырлы булырга галәмәт. Әгәр кызылы бик ачык кызыл күренсә, җилле булырга галәмәт.

Салават күпере бик югары булса — аяз, бик түбән булса — яңгырлы.

Кич салават күпере күренсә — аяз булыр, иртә белән күренсә — яңгырлы булыр.

Яңгыр тамчысы су өстендә эре булып күбекләнеп торса, янә яңгыр булыр.

Иртәнге яңгырдан соң һава һәркайчан аязып китә. Ягъни иртәнге яңгыр күтәрелә, диләр.

Иртә белән чык яхшы төшсә, аяз булыр. Чыксыз кич күп вакыт иртәгесен яңгыр була.

Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт.

Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.

Ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы булыр, юеш булыр.

Көзнең ахырларында түгәрәк-түгәрәк вак кына боз яуса, кыш суык булыр.

Һавада бөтен көн кара куе болыт агылса, һава озак яңгырлы булып торыр.

Һава яңгырлы һәм юеш вакытта күктә аксыл төсле болытлар йөрсә, аязлыкка галәмәт.

Яңгыр болытлары һавада өзлексез һаман агылып торса, һаман көн яңгырлы булыр. Әгәр шундаен чагында болытлар өзек-өзек булып, җил төн ягыннан исә башласа, аяз булыр.

Әгәр болытлар һавада куе булып, тау-тау өелеп торган кебек күренсә, яңгырлы булыр.

Күк күкрәп, коңгырт сыман көл төсле болыт оеш-оеш булып күтәрелсә, боз явар.

Аяз буласы булса, томан, тамчы-тамчы юеш булыр.
Яңгыр буласы булса, томан күтәрелә.

Томан җиргә төшсә, аяз булыр;

Хайваннар да һаваның табигатен азрак сизәләр. Юеш, яңгыр, былчырак буласы булса, хайваннар тик тормый.

Үгез төш ягына таба борынын сузып торса, һәмишә ялангаласа, яңгыр булыр.

Көн, һава яхшы буласы булса, сарыклар сикерешеп чабар, хәтерләре ачык булыр.

Яңгыр буласы булса, дуңгызлар чыркылдаша.

Көн яңгырлы, юеш, былчырак буласы булса, эт аз ашый, күп йоклый.

Эт үлән ашаса, бик озак яңгыр булыр.

Мәче табанын яласа — аяз булыр, койрыгын яласа — көн бозылыр.

Мәче битен бик озак юса, озак яңгыр булыр; бик бөгәрләнеп ятса — суык булыр; стенаны тырнаса — һава бозылыр.

Күселәр, тычканнар бик чабышып йөрсә, көн яңгырлы, юеш, былчырак булыр.

Көз көне тычкан-күсе күп булса, кыш җылы килер.

Тычканнар, күселәр ояны тирән казыса — кыш суык.

Җитенгә тычкан ояласа, кыш көне кар күп булыр.

Суык буласы булса, төлке эт кебек өрер.

Кыш аяз буласы булса, кошлар, үзен-үзе чукып, борыны белән койрыгын кашыр.

Кечкенә кошлар һавага биек күтәрелсә, аяз булыр.

Каргалар, чәүкәләр бер җиргә җыелышып кычкырышалар, аяз буласы булса.

Һава начар буласы булса, күгәрченнәр бик гөрләшә.

Өй тирәсендә карлыгач очып йөрсә, һава начар булыр.

Яңгыр буласы булса, карлыгач бик түбәнтен очар.

Карлыгач кышларга иртә китсә, кыш суык һәм озак булыр.

Һава яхшы чак торналар кычкырышса, һава бозылыр.

Әгәр торна кышларга тиз китсә, кыш суык һәм озак булыр.

Яңгыр буласы булса, көн бозыласы булса, казлар-үрдәкләр су өстендә җәяү йөгерер.

Каз югарыдан очса, яз көне су күп булыр.

Яңгыр алдыннан күркәләр җирдә аунар, кагыныр.

Тавык бер аяк белән басып торса, өй түбәсенә очып менсә, суык булыр.

Әгәр тәкәрлек һәм бытбылдык биек җиргә оя ясаса, җәй яңгырлы булыр.

Вакытсыз этәч кычкырыр явым буласына. Кыш көне вакытсыз кычкырса, җепшек булыр.

Бака су эчендә кычкырса — аяз, су читенә чыгып кычкырса — болытлы-яңгырлы булыр.

Сөлек төптә ятса, аяз булыр. Әгәр судан корыга чыгарга үрмәләсә, тәүлеккәчә яңгыр булыр.

Яңгыр алдыннан балыклар су өстенә сикерер.

Озак яңгыр буласы булса, суалчаннар җир өстенә чыгар.

Һәвам[1] — шөпшә, төклетура биек очып йөрсә, аяз булыр.

Әгәр шул кортлар октябрьдә күренсә, кыш суык булыр.

Явым буласы булса, тоз даим булып юешләнеп торыр. Кыш көне җепшек булса, тоз юеш булыр.

---

[1] Һәвам — бөҗәкләр.

Купшангы (ат тараканы) юлда йөрсә, аяз булыр.

Төш вакытында яңгыр буласы булса, иртә белән купшангы очып йөрер.

Черки-чебеннәр киле төйгән кебек уйнаса, аяз, һава яхшы булыр.

Яңгыр буласы булса, кырмыска оясына таба йөгерешер.

Әгәр кырмыска биек түмгәк ясаса, кыш суык килер.

Болытлы көнне кояш баюына галәмәт кара чыпчык чыкырдаша, өй эчендә почмакларга караңгы төшә.

Уң колак кычытса, җылы була, сул колак кычытса, суык була.

Чыра пырылдап янса, буран була.

Кеше авырайса, явым була.

Пожар чыккач, утка кара сыер сөте илтеп сипкәч, пожар басыла. Яшен сугып янса.

Балага күз тисә, ишек бауларын, ишек тоткасын чайкап, баланың битенә күрә сыпыралар.

Курыккан кешегә куркулык коялар.

Мәче битен юса, кунак килә.

Чоланга кереп әтәч кычкырса, кунак килә.

Ак таракан төшеп түргә таба барса, кунак килә.

Тун итәге катыланса, сыйлата.

Ут сызгырса, ерактан хәбәр килә.

Самовар озак кайнаса, кунак көтә.

Ирен кычытса, көлчә көтә.

Яңа өйгә мылтык аттыргач, пәри кача.

Яңа өйгә аю керткәч, пәри кача.

# Мәхбүбләрне мәдех бәянында

Мәгълүм була ки, лөгатемезнең[1] шигырьләре* һәркайчан ике мисраглы[2] булып, күбрәк шигырьләрдә соңгы мисраг мәксудны ифадә кыйладыр[3]. Вә дәхи телемезнең хәвасыннандыр[4] ки, бер шигырьне ун-унбиш төрле итеп тәрәннем кыйлмак[5] мөмкин. Бу хасыять башка телләрдә ишетелмидер. Вә дәхи шигырьләремез фирак[6] вә һиҗран[7], вә мәдех, вә иштиякъ[8], васләт[9] вә үпкә бәянында тәрәннем кыйлынадыр. Мәсәлән, мәхбүбләрнең[10] вөҗүден[11], йөзен, бармакларын, гакылын, буен, авызын, кашын, норкын, вәҗнәсен[12] мәдех бәянында ошбу шигырьләр:

Укый торган намазлыгым
Чүпләмәгән[13] җире калмаган;
Күргән саен карыймын,
Һич килмәгән җирең калмаган.

Тәрәзәм төбе асылташ,
Алтын белән, җаный, аралаш;
Бармагың камыш, йөзең кояш,
Гакылларың камил, үзең яшь.

Ак иделләрне кичәр идем,
Иделнең буе саз гына;
Йөзеңне гөлгә тиңләр идем,
Гөлнең гомерләре аз гына.

---

* Шигырь дип К. Насыйри җырларны атый.
[1] Л ө г а т е м е з н е ң — телебезнең.
[2] М и с р а г — шигырь юлы. К. Насыйри җыр строфасын ике юлда бирә.
[3] И ф а д ә  к ы й л а д ы р — аңлатадыр.
[4] Х ә в а с ы н н а н д ы р — үзенчәлегеннәндер.
[5] Т ә р ә н н е м  к ы й л м а к — көйләнү.
[6] Ф и р а к — аерылу.
[7] Һ и җ р а н — сөйгәненнән аерылу.
[8] И ш т и я к ъ — күрәсе килү, сагыну.
[9] В а с л ә т — кушылу, кавышу.
[10] М ә х б ү б — сөйгән кеше.
[11] В ө җ ү д е н — гәүдәсен.
[12] В ә җ н ә — яңак, бит алмасы.
[13] Ч ү п л ә ү — чүпләм сугу, чүпләп сугу — киндер сукканда, бизәкләү өчен билгеле санда җепләрне санап-чүпләп алалар, һәм чүпләп алган җепләр астына чыра сыман юка такта-чыбык тыгып күтәреп торалар, һәм соса белән аркау җебе үткәрәләр. Шулай сугу ысулы чүпләү дип йөртелә.

Түгәрәк куак утлавык,
Аслары такыр үтмәгә;
Буйларың зифа, йөзең күркәм,
Авызларың татлы үпмәгә.

Басмас идем баскычыңа,
Баскычларың бадъян агачы;
Сөймәс идем син матурны,
Гакылларың дөнья бәһасе.

Карлыгандин кара кашларың,
Бөрлегәндин кызыл йөзләрең;
Шикәрдин ширин, балдин татлы
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең.

Кашларың нечкә бик әйләнгән
Казанда бөккән дугадай;
Йөзең күркәм, буең зифа,
Банкаларда үскән кынадай.

(Бу мәзкүр шигырьдә мәхбүбләрнең кашын дугага тәшбиһ[1] мөнәсәбәтсезрәк күренсә дә, җырның ертыгы юк, дигән көллияне[2] игътибарга алсак, мәгъфудыр[3].)

Җәйли печән чапмадым,
Бөрлегән өзеп капмадым;
Күп йөрдем, күп эзләдем,
Синдин матур ярны тапмадым.

Су буйларында багана,
Башларын дулкын кага ла;
Син җаныемның бит уртасы —
Оҗмахларда пешкән багалма.

Көмеш каләм ясадым,
Кешегә түгел, үземә;
Һавадин очкан фәрештә тик
Күренәсең минем күземә.

Биек тауның башында
Ике ат йөри тышаулы;

---

[1] Т ә ш б и һ — охшату, чагыштыру.
[2] К ө л л и я н е — мәкальне.
[3] М ә г ъ ф у д ы р — гафу ителәдер, акланадыр.

Өяздә түгел, юк Казанда
Син җаныйга охшаулы.

Бакча ишеген ачып куй,
Кояш төшсен, җаный, түтәлгә;
Күзем төшсә, күңлем төшми
Син җаныйдан гайре бүтәнгә.

## Һиҗран вә фирак шигырьләре

Җырласаң, егет, ачы җырла,
Йокыдагы кызлар уйгансын;
Дәртле бардыр, дәртсез бардыр,
Дәртлеләрнең күңеле юансын.

Һавадин очкан аккошның
Аякларын күргән бар микән;
Бу дөньяларның эчендә
Миндин дә моңлы бар микән?

Җилфер-җилфер йөргәндә,
Җил ачадыр минем куйнымны;
Җабыгып-җетеп йөргәндә,
Җыр ачадыр минем күңлемне.

Һавада йолдыз ничәдер,
Ничә генә баксаң күчәдер;
Ничә айлар, ничә еллар
Гомерләрем заегъ кичәдер[1].

Аргы якка чыгар идем,
Бирге якта салым юк;
Шул җаныемның гыйшыкындин
Коры гәүдәм йөри, саным юк.

Алтын ияр, штоф мендәр
Акбүз атның сагрында[2];
Шул җаныйның әйткән сүзе
Телләремдә түгел, бәгъремдә.

---

[1] Заегъ кичәдер — әрәм, файдасыз үтәдер.
[2] Сагрында — савырында, сыртында.

Алтын саплы көмеш пәке,
Яшел беләүләргә сызаем;
Ходайдин сине сораем,
Син булмасаң, әҗәл теләем.

(Бу шигырьдә көмеш пәке, яшел беләү, димеш, әмма шигыремездә әүвәлге мисрагның мәзмуны[1] вакыйгка мотабикъ булмак[2] шарт түгелдер.)

Көмеш йөзек койдырдым
Ап-ак кына сәдәфтин;
Бу җырларымны мин җырлыймын
Йөрәкләрем янган сәбәптин.

(Бу шигырьдә дәхи фәһем ителмәсен[3] ки, сәдәфтин көмеш йөзек булмый, дип. Бу шигырьдә мәхзүфләр[4] бардыр. Мәзмуны биләдер: көмеш йөзек койдырдым, кашын сәдәфтин койдырдым.)

Каләнфер белән бадъян
Кай җирләрдә чәчәк ата икән?
Кара кашым, карлыгачым
Кай җирләрдә ялгыз ята икән?

Аргы якта ак җитен,
Бирге якта күк җитен;
Каләнфер сипкән түшәктә
Ялгыз ятулары бик читен.

Ак өйләрнең эчендә
Очып кына йөри күбәләк;
Шул җаныем исемә төшкәч,
Хәлләремне җыям чүгәләп.

Җаныем җефәк җерлидер,
Тегәр җептин бераз нечкәрәк;
Җанкаем мине көтә микән
Икендедин бераз кичкәрәк.

Сатып алдым сары алма,
Йөрәгем башы талганга;
Бу җырлар миңа тәсбих түгел,
Мин җырлыймын йөрәк янганга.

---

[1] Мәзмуны — әйтергә теләгәне, эчтәлеге.
[2] Вакыйгка мотабикъ булмак — чынбарлыкка туры килмәк.
[3] Фәһем ителмәсен — аңланмасын, уйланмасын.
[4] Мәхзүфләр — төшерелгән сүзләр.

(Бу шигырьдән фәһемләнәдер ки, шагыйрь үзе дә шигырьнең мәмдух[1] нәрсә түгел икәненә мокыйрдыр[2].)

Чардакта шәмнәр янадыр,
Майлары эреп тамадыр;
Синең гыйшкың сәбәбендин
Йөрәгемдә утлар янадыр.

## Иштиякъ, васләт

Көмеш йөзек бармакта,
Кашлары аның балдакта;
Шул җаный белән күрешеп
Сөйләшербез микән аулакта?

Алса иде җаный, алса иде,
Агызмаган баллар булса иде;
Хәлял малың биреп алгач,
Кул тимәгән ярлар булса иде.

Бөгәчә[3] айның дүрте бар,
Туасы айның күрке бар;
Ярны ярга, каләм кашка
Кавыштырса, Хакның ирке бар.

Алсана, җаный, алсана,
Ал бишекләргә алып салсана;
Ал бишектә йокым килми,
Бер куеныңа алып ятсана.

Тәрәзә төбем үрмә гөл,
Су сипмичә, җаный, үрмидер;
Синнән гайре ярларны
Күңелләрем кабул күрмидер.

Әйләнә кояш, һай, әйләнә,
Талларга ефәк бәйләнә;
Әйтәсе сүзем күп иде,
Үзеңне күргәч, телем бәйләнә.

---

[1] Мәмдух — мактауга яраклы.
[2] Мокыйрдыр — танучыдыр, икърар итүчедер.
[3] Бөгәчә — бүген, бүген кич.

Асламчылар килсәче,
Ал штуфлар сатам, дисәче;
Һавадан фәрештә иңсәче,
Инде кавышасыз, дисәче.

Ак иделләрнең буенда
Үсә микән богдай бәгъдәсе?
Син җаный белән кавышырга
Җитә микән Хакның вәгъдәсе?

Бакчада кемнәр йөридер,
Ике кулларына гөл учлап?
Шул җаный белән бер кавышсам,
Йоклар идем йокым тынычлап.

Көмеш йөзек койдырдым
Ялан көмеш акчадин;
Эзләдем сине, таптым, җаный,
Гөлчәчәкләр аткан бакчадин.

(Бу шигырьдә бераз тәүрия[1] бардыр ки, гөлчәчәкләр аткан бакчадин димәктән морад пакь-заман[2], атасы, анасы вә нәсел-нәсәбе изге булучы кавем эченнән таптым, димәктер.)

Йөгереп чыктым урамга,
Тәгәрәп килә пар алма;
Пар алмадай пар китереп
Кавыштырыр микән бер Алла.

Тәрәзәләрдин кемнәр карый,
Өсләренә кигән гел сары;
Уйнап-көлеп күземә карый,
Минем күңелләремә шул ярый.

Тәрәзәләрдин ук аттым
Җем-җем иткән сары чәчәккә;
Былбыл булып очар идем
Син җаныем җәйгән түшәккә.

Кара урманны кич уздым
Кара сусар эзендин;
Карасам, күзем алалмаймын
Тулган ай тик нурлы йөзеңдин.

---

[1] Тәүрия — киная.
[2] Пакь-заман — намуслы, гыйффәтле.

Биек тауның артындин
Болыт килә, күрәмсең;
Килсәнә, җаный, бер үпсәнә,
Бер үпкәннән егылып үлмәссең.

Кояш чыгар әйләнеп,
Алма агачларына бәйләнеп;
Исән булып, сау торсак,
Шаять, кавышырмыз әйләнеп.

Изү бавым ал ефәк,
Алып-чалып булмайдыр;
Җөмлә буеңа җофар сипкән,
Күргәч, аерылып булмайдыр.

Энҗеле яка — шау ука,
Җиргә төшсә, җаный, югала;
Йөрсәң йөр күз алдымда,
Сине күргәч, күңелем юана.

Аклы ситсы күлмәгең
Кисәнә зифа буеңа;
Зифа буең хәлял итеп
Керсәнә минем куенyма.

Ак өйләргә керерсең,
Акрын басып йөрерсең;
Куенима кайчан син керерсең,
Сары май булып эрерсең?

Ак иделләрнең буенда
Ак күгәрчен йөри җәяүләп;
Син җаныйны алыр булсам,
Өч ел йөрер идем кияүләп.

Җәйләргә чыккач, без уйнармыз
Болынга төшеп ил белән;
Бигрәк зәвык эшләр икән
Кич йоклавы нечкә бил белән.

Сусадым, җаный, сулар кайда,
Дәрья суы эчеп ни файда?
Сусаган чакта бер үпсәң,
Көйгән йөрәкләргә шул файда.

Сандугач кайда сайрыйдыр, —
Тал башларында ояда;
Сандугач кебек сайрашып
Кавышырмыз микән дөньяда?

Алма аша, җаный, алма аша,
Алма ашасам, тешем камаша;
Син ташламасаң, мин ташламам,
Газраил җаным алмаса.

## Интизар хәбәр вә сагынмалык

Сандугачыңа җим сипмисең,
Сайрамый торсын, дисеңме;
Сагынган чакта юк сәламең,
Саргаеп үлсен, дисеңме.

Сикереп төштем бакчага,
Нәзек чыбык алмага;
Нәзек чыбык — тал чыбык,
Күтә микән җаный талчыгып?

(Бу мәнфур әт-табгы[1] бер шигырьдер ки, асылда ике шигырьнең берәр мисрагыннан мөрәккәб булмак дәркярдыр[2]. Нөсхәмездә булганга күрә яздык тагын.)

Тәрәзәм төбе сандугач,
Уянып китәм сайрагач;
Җырлау түгел егъларсың,
Исләреңә төшеп сагынгач.

(Шагыйрь җанәбеннән бу бер игътизардыр[3].)

Кара урман артында
Карлыгач булыр кагынган;
Очкылык тотса, тот исеңдә —
Мин булырмын сине сагынган.

Бакчада гөлләр алмалы,
Алмалы түгел, чалмалы;
Синдин гайре юк сөйгәнем,
Инан телләремә, валлаһи.

---

[1] Мәнфур әт-табгы — табигый түгел, гадәттәгечә булмаган.
[2] Мөрәккәб булмак дәркярдыр — кушылган булуы ачыктыр.
[3] Игътизардыр — аклану, гафу үтенүдер.

Бакчада былбыл сайрыйдыр
Вәгъдә гөлләр талында;
Иртә исемдә, кич төшемдә,
Син, җаныем, минем ядымда[1].

Ак иделнең буенда
Селәүсен чыгар уенга;
Селәүсен кебек нечкә бил
Кайчан керер икән куенга?

Синең сачең сүтелмәс,
Ука белән үрсәң дә;
Үзеңне күргән кебек булам,
Элеп куйган күлмәгең күрсәм дә.

Түгәрәк күлгә мәрҗән салдым,
Алсана, җаный, болгатып;
Күз алдымда тотар идем,
Юк хәйләләр белән юатып.

Казандин Мәскәү күренә микән,
Биек баскычларга баскачтын?
Безнең җаный сагына микән,
Кич түшәкләренә яткачтын?

Каләнфер белән бадъян
Кай җирләрдә сачәк ата икән?
Сандугач кебек сайраеп,
Кай җирләрдә ялгыз ята икән?

Утырдым усак төбенә,
Коеладыр яшел яфрак;
Иртәсе — кояш, киче — ай,
Кайда йөри икән ялтырап?

Сары ат җиктем яратып,
Капкаларга таба каратып;
Җанкай безне көтә микән,
Бер күрер өчен җан атып?

Асыл кошлар сайрыйдыр,
Кызыл гөлләр чәчәк атканда;
Син җаныйдан сәлам көтәм,
Таң ярылып шәфәкъ батканда.

---

[1] Ядымда — исемдә, хәтеремдә.

# Һиҗран вә җәүр[1], мәгъшуктан[2] шикаять вә үпкә

Кашларың кара каләмдер,
Бу шигырьләрем сиңа сәламдер;
Бу сәламемне алмасаң,
Сөешүләребез безнең әрәмдер.

Тәрәзә төбе сигез гөл,
Сигезе дә анын тигез гөл;
Мине ташлап ятны сөйсәң,
Хаста бирсен сиңа Ходай сигез ел.

Безнең урман буенда
Үсә микән ак зәрдә?
Мине ташлап ятны сөйсәң,
Дәгъвачы мин яүме мәхшәрдә[3].

Биек тауның башында
Самовар кайный күмерсез;
Мине ташлап ятны сөйсәң,
Сөйгән ярың булсын гомерсез.

Һавада болыт агыладыр,
Таудин тауга кагыладыр;
Дөньяда матур бер син түгел,
Кайгыларын күргәч табыладыр.

Салкын сарай алдында
Тилпенеп тора бер күркә;
Чәч бөртекләрең сары ука,
Саргайтасың мине һич юкка.

(Бу шигырь филҗөмлә зәмне[4] һәм мөшгыйрьдер[5], чөнки сары төс мәхбүбләр хакында мәмдүх нәрсә түгелдер.)

---

[1] Җәүр — рәнҗетү, җәфалау.
[2] Мәгъшуктан — сөйгән кешесеннән.
[3] Яүме мәхшәрдә — мәхшәр көнендә.
[4] Зәмне — әрне, шелтәне.
[5] Мөшгыйрьдер — белдерәдер, сиздерәдер.

Алыр идем, сатар идем
Бохараның кызыл басмасын;
Миннән гайре ярлар күреп,
Хуш мөбарәк күңелең азмасын.

Ике җирән, пар көрән,
Ник җибәрдең, җаный, су буйлап?
Сөясе булсаң, сөй тизерәк,
Ник йөрисең инде күп уйлап?

Күлмәгең синең полотна,
Былчыракта киеп аны чылатма;
Сөясе булсаң, сөй тизерәк,
Яшь бала кебек мине юатма.

Биек сарай алдына
Элеп куйдым, җаный, колакчын;
Мине ташлап ятны сөйсәң,
Җаның җәһәннәмгә олаксын.

Челтәрле чана күн япкан,
Эчләренә кереп кем яткан?
Кичә күңелең салкын иде,
Бүген күңелеңне кем тапкан?

Челтәрле чана кунгырлы,
Тәртәләре яшел тубылгы;
Төнә үткән кичләрдә
Кем муеннарына салдың кулыңны?

Түгәрәк күлдә дүрт үрдәк,
Аксаклары ничек йөзә икән?
Якында торып, күзе күреп,
Җаннары ничек түзә икән?

Бакча ишеген ачып куй,
Кояш төшсен, җаный, ак бүзгә;
Җаный, күңелең каты икән,
Таш йомшар иде бу сүзгә.

# Фирак вә өмид васлән

Без элгәре бик дус идек,
Инде булдык, җаный, әлфирак;
Бу фирактан дәһи кавышмасак,
Үлгәнемез безнең яхшырак.

Туп-туп итеп баскан туры [атның]
Тубыклары яшел тут икән;
Төшмәсен гыйшкың матур ярга,
Гомергә сүнмәс ут икән.

Гөл бакчасына керер идем,
Гөл чәчәкләренә буялам;
Син җаныем исемә төшкәч,
Йокыларымдин егълап уянам.

Бакчада гөлләр бетәрме,
Арасындин былбыл үтәрме;
Үзең белән сөйләшмәгәч,
Хатка язып сүзләр бетәрме?!

Ике җирән ат киләдер
Таш урамнарны селкетеп;
Ташлар булсаң, ник үптең,
Минем йөрәгемне җилкетеп?!

Урам буе ташлык юл,
Дагалы булсын атларың;
Йөрәгем башын өзеп ала
Кичә генә килгән хатларың.

Биек тауның башында
Самовар кайный җил белән;
Гыйшык тотып кавышмаган
Бер без генә түгел, ил белән.

Тәрәзәм төбе гөл-сачәк,
Гөл-сачәккә килми бер сачәк;
Минем сөюләрем артык килер,
Мизаннарга салып үлчәсәк.

Тәрәзәм төбе гөлҗимеш,
Ашыйсым килми туксынып;
Өйләргә керәм, тышка чыгам,
Син җанкаемны юксынып.

Тәрәзәң төбе якты икән
Утырып мәрҗән тезәргә;
Анадин зифа тугансың,
Минем бәгырьләремне өзәргә.

Кара урманның артында
Җир җиләге җыйдым яулыкка;
Син җаныйга гыйшык тотып,
Һич туя алмыймын саулыкка.

Каенлыкның какысын
Җыеп ашар идем татлысын;
Валлаһи, җаный, бик сөямен,
Кил, ташлама, Алла хакы өчен.

Биек тауның башына
Менеп кенә булмый — тамырлык;
Ходайдан вәгъдә җиткәнче
Үзе бирсен сабырлык.

Безнең урам аркылы
Агадыр суның салкыны;
Эчем-тышым ут яна,
Тышка гына чыкмый ялкыны.

Күк күгәрчен гөрлидер
Ике сулык аркылы;
Үземез — урам аркылы,
Гыйшыкларымыз — утның ялкыны.

Һавадин очкан аккошның
Авызлары тулы балавыз;
Таң ата, җаный, тор тизрәк,
Сөйләшә алмый калабыз.

(Бу шигырьнең мәзмуны билә булмак кирәк ки, гашыйк гүя үзенең хыялы белән сөйләшәдер.)

Һавадин оча ике кош:
Берсе баулы, берсе буш;
Төшемдә күреп, күңелем хуш,
Уянып китсәм, куеным буш.

Ике идел, бер диңгез,
Агулары аның бертигез;
Күрсәгез, сәлам әйтегез,
Сагышындин саргайган, диегез.

Аккош очар су күреп,
Былбыл очар гөл күреп;
Еракта түгел, бик якында,
Сагынганда булмый бер күреп.

Һавада, җаный, күк томан,
Мин бу илләрдә күп тормам;
Сүзең булса, әйт шушында,
Син сагынган чакта мин булмам.

Акрын атма, биек атма,
Аткан угың югалтма;
Син ташламасаң, мин ташламам,
Миндин күңелләрең суытма.

Ачтым кибет тактасын,
Тапмадым мимеч басмасын;
Сине миңа, мине сиңа
Дошманнар кайчан мактасын.

Алтын тупса, күн ишек,
Көмеш сиртмә, гөл бишек;
Хаста ятып саргаймадым,
Саргайтты мине бу гыйшык.

Алдым атның аласын,
Өч әйләндем Казан каласын;
Сөясе булсаң, сөй тизрәк,
Тиз сөймәсәң, миндин каласың.

Алтын-көмеш — байларда,
Йомры тояк — тайларда;
Сагынмам, дисең, саргаерсың
Җир җиләге пешкән айларда.

Тегермән алды тирән күл,
Бидәрле яулык юдым мин;
Бидәрле кашым, җанкисәгем,
Җан көйдерер өчен тудың син.

Беләзегең, җаный, ике пар,
Берсе иңле, берсе тар;
Валлаһи, җаный, бел хакыйкать,
Бер күрергә булам интизар.

Җәйгә чыккач, чык болынга,
Балан дигән җимеш ашама;

Булыр-булмас ярга ышанып,
Булып беткән ярны ташлама.

Быел койган коймамны
Язгы җилләр какшатты;
Җандин артык сөя идем,
Дошман йөзе кара ташлатты.

Ары барма, җаный, кайт бире,
Барча эшләр Ходай тәкъдире.

(Моннан артык бәлягатьле[1] шигырь ниндәен шигырь кирәк.)

Исәпләп уйлап торамын
Бу башымны алып китәргә;
Бер җырлыймын, бер уйлыймын,
Һич белмимен ни хәл итәргә.

Аяз булса — айга көч,
Болыт булса — көнгә көч;
Кайда барсаң — бер кояш,
Күбәләктәй газиз җанга көч.

Асыл күлмәк асылмас,
Сандыкка салмый басылмас;
Калган хәтер, чыккан җан,
Сатып алсаң табылмас.

Казан дигән шәһәрдә
Ахшамсыз капка ябылмас;
Үткән гомер, калган хәтер
Сатып алсаң табылмас.

Петербур каласы — таш кала.
Барча калаларга баш кала;
Егет өчен егет кеше
Баш китәрлек эшне башкара.

Сандугач сайрар тәхетендә
Төн уртасы сәхәр вакытында;
Булма ярсыз, булма малсыз
Үсеп буйга җиткән вакытында.

Алмалар салдым дәрьяга,
Шәгъләләре[2] төште дөньяга;
Мин туганчы таш тусачы,
Зикер әйтер иде Аллага.

---

[1] Бәлягатьле — матур, тулы, төзек.
[2] Шәгъләләре — шәүләләре.

Туп иткән туры атның
Тустагандай тоягы;
Утта янмас, суга батмас
Сәүдәгәр егет сөяге.

Әйдәгез, барыйк уенга,
Тау буйларындагы болынга;
Уен булса, уйный торсын,
Шаять, керер безнең куенга.

Кара урманның күкесе,
Тәңкә чуар булыр күбесе;
Һич сөешә белмидер
Бу чактагы кызлар күбесе.

Ишек алдым — алмагач,
Ник кисмәскә, алма булмагач;
Дөнья малы белән нишләрсең,
Җанкисәгең җанда булмагач?

Ян тәрәзәм төбендә
Язу яза Җәбраил;
Син җаный белән кавышмасак,
Җаным алсын Газраил.

Юл буйлары, җаный, бөрлегән,
Бөрлегән саен бер үлән;
Син җаныем исемә төшкәч,
Бер тереләм, бер үләм.

Сандык-сандык сары алма,
Сайласам, чыкмый бөтене;
Эчем-тышым ут яна,
Тышкары чыкмый төтене.

Өй түремдә урындык,
Зәңгәр генә баулы чыбылдык;
Кара кашым, карлыгачым,
Кавышмый калсак, ни кылдык?

Атым чак, җаный, атым чак,
Ат өсләрендә ыңгырчак;
Күп җырладык, күп яздык,
Инде җитте куяр чак.

Каш кара лай, һай, маңгайда,
Без чыгарбыз, җаный, мәйданга.
Без чыккан чакта сез булмагач,
Безнең чыгулардин ни файда.

Ике былбыл тиң сайраса,
Моңлы булыр тавышы.
Ике гашыйк җөда булса[1],
Бер-берендә булыр сагышы.

Чите яшел, уртасы ал,
Һаваларда булыр салават;
Сәфәрләргә китәсең икән,
Кайтарсын сине Хода сәламәт.

Кайсы юлдан син китәрсең,
Тозак корыйм юлыңа.
Әгәр озак торыр булсаң,
Талигать бирим кулыңа.

Китәр булсаң озатаем,
Юл азыгың төзәтәем;
Кайсы юлдан китәрсең,
Артыңнан мин күз атаем.

Чылдыр-чылдыр су тавышы,
Гүя язгы кар суы;
Аһ, нишләем, басыласы юк
Йөрәгемнең ярсуы.

Яна йөрәк, яна йөрәк,
Яна йөрәк, янадыр;
Янмыймы соң бу йөрәгем,
Яшьлек үтеп барадыр.

Белер ирсәң иртә берлә,
Ары бар да бире күч;
Иртә торма, соңга калма,
Нәкыд[2] була сәгать өч.

[1] Җөда булса — аерылуга дучар булса.
[2] Нәкыд — нәкъ.

## БӘЕТЛӘР

### Казан бәете

Тарих җите йөздә[1]
Килде Тимер Болгарга,
Габдулла ханның кулыннан
Болгар шәһәрен алдыя.

Ул бөлекнең[2] соңында
Казан суы буенда
Ике углы кәлүбән[3]
Казан шәһәрен салдыя.

Ике йөз алтмыш ике ел
Казан мөселман кулында,
Ахры бары соңында
Урыс халкы алдыя.

Газилары[4] күп иде,
Меллалары чук иде,
Галимнәре күп иде,
Заманы Ядегәр ирдия.

Бу җиһан мөнәүвәр[5] иде,
Җәүр-җәфа юк иде,
Мөрид-мөршид күп иде,
Заманы хуп ирдия.

Галимнәре дус иде,
Мөршидләре хас иде,
Барча дошман пәст[6] иде,
Заманы Ядегәр ирдия.

Ядегәр ханның бер кызы
Калды тугыз ячендә,
Хәләф[7] ишлү эчендә
Күп гакыллы ирдия.

---

[1] Һиҗри белән. Милади ел исәбенчә XIV йөзгә туры килә.
[2] Бөлек — бөлү, һәлак булу.
[3] Кәлүбән — килү белән, килеп.
[4] Гази — сугышчы, батыр.
[5] Мөнәүвәр — нурлы, якты.
[6] Пәст — түбән, хурлыклы.
[7] Хәләф — алмашка килүче, яңа буын.

Тугыз йөз илле җитедә
Ядегәр китте дөньядин,
Атасының урынына
Хан булырсың тидия.

Сән мөәннәс[1] дәгелмесең,
Ханга лаек дәгелмесең,
Ничә ирләр барында
Хан булмасмын тидия.

Ошбу сүздән гыйбрәт алды,
Бу дөньяны юкка санды,
Атасының соңында
Үз җанын үзе алдыя.

Нәселендә бер ир бар ирде,
Исеме аның Шагали,
Шифаларга яр ирде,
Тоткын булмыш ирдия.

Күп халаик бардылар,
Күп мал биреп алдылар,
Ошбу шәһәре Казанга
Хан кылдылар ирдия.

Шәһәре Казан эчендә
Шагали һәм хан булды,
Дөнья дигән сарайга
Җәүр-җәфа тулдыя.

Үз-үзене белмәс,
Күзе һәм малга туймас,
Урыслардин мал алып,
Дарыга су койдыя.

Урыс халкы ишәйде,
Шагалигә кушылды,
Шагалидән Иван урыс
Казан шәһәрен алдыя.

Иван урыс зур булды,
Мөселманнар хур булды,
Ничә вәли[2], ничә газиз
Шәһадәтләр[3] табдыя.

[1] Мөәннәс — хатын-кыз женесе.
[2] Вәли — бу урында: изге.
[3] Шәһадәт — сугышта шәһит булу.

Урыслар хәбәрдар иде,
Мөселманнар бихәбәр иде,
Шәһәре Казан янында
Орыш-тукыш булдыя.

Ул орыштин булмады,
Казан шәһәрен алмады,
Ошбу Зөя тагында[1]
Урыс кала салдыя.

Мөселманнар күрделәр,
Сорап-эзләп белделәр:
«Ошбу безнең җиремез,
Кандин[2] килдең?» — тидия.

«Кандин, урыс, килепсең,
Монда мәкам кыйлыпсың[3],
Кемнән рөхсәт алыпсың?» —
Тиеп җиһад[4] кылдыя.

Бар иде бер мәрде[5] Хода,
Исеме иде аның Чура.
Күп урысны кырмага
Ходай мәдәд[6] бирдия.

Бар ирде бер ир — Үлмәс,
Исеме аның кемсә белмәс,
Шәһәре Казанга килгәнче
Кемсә күрмәс ирдия.

Үлмәс белән Әбелгаликъ,
Ярый бирде җәббар халикъ[7],
Мөэминнәрнең үчене
Барып алыр ирдия.

Диделәр аңа: «Йә Чура,
Ирерсең мәрди Хода,
Алланың хөкеменә нидер чара,
Иван урысны син тура».

---

[1] Таг — тау.
[2] Кандин — кайдан.
[3] Мәкам кыйлу — урнашу.
[4] Җиһад — изге сугыш.
[5] Мәрд — ир, егет.
[6] Мәдәд — ярдәм, булышлык.
[7] Җәббар халикъ — кодрәтле яратучы (Алла).

Килеп житте Чура батыр,
Урыс ханы чатырда ятыр.
Чатыр эченә керүбән
Башын кисеп алдыя.

Ултырып ирде ашына,
Ашы житте башына.
Ашы алдыннан киткәнче,
Башы төште ашына.

Гакылы юктыр башында,
Күп халкы бар кашында.
Ник боермады бер башына:
«Строг торың[1] кашымда».

Кисте аның башыны,
Агызды һәм каныны,
Ул дошманның жаныны
Жәһәннәмгә бирдия.

Тугыз йөз илле тугызда
Сычкан елы иде анда,
Гакрәбнең икенче көнендә*
Иван урыс алдыя.

## Рус-француз сугышы бәете

Французның илләре,
Түгәрәк икән күлләре;
Жиң эченә мылтык алып,
Үзе керә элгәре.

Кушымта:
Ай-ай, голубес, молодес,
Руби зна-та руби знай[2].

---

* Казан алыну датасы өч төрле календарь аша күрсәтелә: һижри белән 959 (милади белән 1552) ел, 12 еллык хайван календарендагы Сычкан (Тычкан) елы һәм зодиак буенча Гакрәб ае (22 октябрь — 22 ноябрь аралыгы — яңа стиль буенча).

[1] Строг торың — строго торыгыз, нык саклагыз.

[2] Ай-ай, голубчик, молодец,
Руби знай да руби знай.

Французның атлары
Бар да ефәк тышаулы;
Николайның казаклары
Әфисәргә охшаулы.

Кушымта.

Французның күперен
Тимер белән бетергән;
Французның йөз кешесен
Унике солдат үтергән.

Кушымта.

Французның атлары
Төзәм җирдә дулыйдыр;
Николайның казаклары
Французны турыйдыр.

Кушымта.

Мендем тауның башына,
Исемем яздым кашыма;
Бу француз азган икән
Үзенең газиз башына.

Кушымта.

Французның капкасы,
Тимер икән тактасы;
Бу дөньяда беткән икән
Французның нәфкасы[1].

Кушымта.

Тирән күлнең эчендә
Озын икән камышы;
Унике король арасында
Французның тавышы.

Кушымта.

Николайның казагына
Унике король баш ора;
Николайның казаклары
Бары берлә сугыша.

Кушымта.

---

[1] Нәфкасы — ризыгы.

# Җыен бәете

Ошбу җыен дигәнебез буладыр матур җәй көне,
Һөнәр иясе булганнар бик хуплап көтә моны.
Атамыздан, бабамыздан кала килгән ошбу дип,
Сарыф итә җыен өчен, юкларын бар итеп.
Өч ай алдан хәзерләп куядыр кирәкләре,
Гәр бәнагяһ[1] бармый калса, янадыр йөрәкләре...

Килә чәршәмбе көн алырга сала кешесе,
Күп вакыт өлгермәгән буладыр кала кешесе.
Җитешкәч тә утырып чыгып китә,
Бара азрак та чәй эчәр җиргә җитә.
Чәй эчәр җиргә җиткәч, сайлый урынның яхшысын,
Юлда чәй эчкән булып бетерә күчтәнәчнең яртысын.
Юлда күрсәң син аны, белерсең, гүя купец;
Барлык алган нәрсәсе һәм акчасы — бары бурыч...

Имди ошбу рәвештә авылга кайтып җитә,
Өсте-башы яхшы булса, авыл кешесенең исе китә...

Өч-дүрт көне үткәч, кайта җыеннан әйләнеп,
Хисап итеп карасалар, бурычка беткән бәйләнеп.
Бәгъзесеннән чәен алган, бәгъзесеннән шикәрен,
Бәгъзесеннән күмәч алган, бәгъзесеннән икмәген.

# Чәй бәете

(Гаять кагыйдәле тасниф ителмеш[2] бәетләрдер, вәзене бәхре һәзәҗдан дүрт мәртәбә мофагыйләндер, «Мөхәммәдия көе» дип мәгъруфдыр[3].)

Җиһан ичрә ул Алланың
Ләзиз нигъмәтләре чуктыр[4];
Вәләкин бу безем җирдә
Бу чәй дик һичбере юктыр.

---

[1] Гәр бәнагяһ — әгәр көтелмәгәндә.
[2] Тасниф ителмеш — язып чыгарылган.
[3] Мәгъруфдыр — билгеледер.
[4] Ләзиз нигъмәтләре чуктыр — тәмле ризыклары күптер.

Бу чәй кеби дәва юктыр,
Гаҗәп хасияте чуктыр;
Әгәр ачлар эчәр булса,
Белерсең: барчасы туктыр.

Ки җәй фасылында бер ирне
Һава сукса хәрарәттән[1];
Эчәр булса бу чәйдин ул,
Котылыр ул мәзараттән[2].

Шита яуминдә[3] дәхи
Бөруд теләнсә[4] бер инсан;
Самовар ла чәй эчерсә,
Бөрудәте китәр шул ан[5].

## Хасияте чәй

Хәвасыннан[6] дәхи аның
Йокыны мөндәфигъ әйләр[7]
Белер моны мөҗәррибләр[8],
Хакыйкать чәй эчәр байлар.

Самовардыр дәхи матлуб[9],
Калебләрдә ирер мәхбүб[10].
Самовар ла чәй эчсәләр,
Эчәнләрә ирер мәргуб[11].

Самовар сауты[12] дилкәштер[13],
Мисале сайраян коштыр;
Килеп утырса сөфрәгә[14],
Кунакның күңеле бик хуштыр.

---

[1] Хәрарәттән — эсселектән.
[2] Мәзарәттән — зарардан, зыяннан.
[3] Шита яуминдә — кыш көнендә.
[4] Бөруд теләнсә — салкын тидерсә.
[5] Ан — вакыт, заман.
[6] Хәвасыннан — үзенчәлекле хасиятләреннән.
[7] Мөндәфигъ әйләр — китәрер, ачар.
[8] Мөҗәррибләр — тәҗрибә итүчеләр, эшләп караучылар.
[9] Матлуб — теләнгән, соралган нәрсә.
[10] Калебләрдә ирер мәхбүб — күңелгә якын, сөекле.
[11] Мәргуб — әйбәт сыйфатлы.
[12] Сауты — тавышы, авазы.
[13] Дилкәш — күңелне тартучы.
[14] Сөфрәгә — аш өстәленә.

Нә дикле нигъмәтең чуктыр,
Самовар лә чәең юктыр.
Кунак чәһрәсе[1] ачылмас,
Һәмишә күңеле сыныктыр.

Әгәр чәеңне китерсәң,
Ачылыр багдагы[2] гөл тик.
Ләтыйф сүзләрен сүзләп
Утырыр мисале былбыл тик.

Илаһи, син аермагыл
Бу чәйдән без зәгыйфь колны;
Эчәргә чәй бетәр булса,
Алырга бирәсең полны[3].

## Чәйнең шартлары

Бу чәйнең шартлары бардыр,
Бәҗай килтерәсең[4] аный;
Бәян итәм сиңа бер-бер,
Колак салгыл моңа, җаный.

Аның шартларының бере
Самовардыр ирер мәзкүр;
Янә янында бер мәхбүб,
Утыра ул әүля[5] мәнзур[6].

Шараиттән[7] дәхи аның
Мосаффа[8] һәм әүля балың;
Ки чын касәгә салубән
Көмеш кашык илә алың.

Ушал балыңны измәгел
Чынаяк эчрә син суда;
Әгәр изсәң аны суда,
Чәеңне кыласың худа.

---

[1] Чәһрәсе — йөзе.
[2] Багдагы — бакчадагы.
[3] Полны — акчаны.
[4] Бәҗай килтерәсең — җиренә җиткерәсең.
[5] Әүля — артыграк, яхшырак.
[6] Мәнзур — каралган, игътибарга алынган.
[7] Шараиттән — шартларыннан.
[8] Мосаффа — саф, таза.

Суы булсын анының яхшы,
Шималә[1] каршы аккан су;
Гаҗәпләнмә бу сүзләргә,
Әтыйббадин бу гөфтегү[2].

Дәхи лимун салыр булсаң,
Аның кадере, бәс, әгъладыр;
Лимун илә чәй эчелсә,
Эчәнләрә күп әүлядер.

Бу шартлар берлә эчсәләр,
Әүля мәсрур[3], әүля хушхәл.
Каму гамләр[4] китәр андин,
Ки шадан әйләеп филхәл[5].

Моны идән кеше имла[6]
Ирур үз урнында мелла;
Гөнаһларин гафу итеп
Бирә максудины Алла.

## Уңмаган килен

(Бу бәет һәм яхшы кагыйдәле тасниф кыйлынган бәеттер, вәзене мофагыйлен фәгулендер, «Бәдәвам» көе шикелледер.)

Уңмаган булса килен,
Пешерә белмидер белен.
Тартып өзәргә телен,
Сүзгә шәблү тидия.

Ятадыр мисле бүре,
Торып ясамый шүре.
Ачуланмыйдыр ире
Яткан өчен тидия.

Иртә мичкә якмыйдыр,
Менеп морҗа ачмыйдыр.
Каен атадин качмыйдыр,
Оятсыздыр тидия.

---

[1] Ш и м а л ь — төньяк.
[2] Ә т ы й б б а д и н  б у  г ө ф т е г ү — бу табиблардан чыккан сүз.
[3] М ә с р у р — шатлыклы.
[4] К а м у  г а м л ә р — күп кайгылар.
[5] К и  ш а д а н  ә й л ә е п  ф и л х ә л — шунда ук шат итеп.
[6] И м л а — әйтеп яздыру.

Иртә сыер саумыйдыр,
Сачен тарап үрмидер,
Бер киләп җеп җерлидер
Биш-алты көн тидия.

Ятадыр мисле туар,
Торса пешерә чумар.
Бәрсә, колагың тонар,
Каты була тидия.

Болар ике килендәш,
Тормас микән, бар, эндәш,
Ята мисле карендәш,
Кузгалмасмы тидия.

Ялкау килен шушыдыр,
Эштән тизрәк бушыйдыр,
Мисле дөя күшидер
Ашаганда тидия.

Җитмәсә, аш сайлыйдыр,
Коймакны күп майлыйдыр,
Бер оекны бәйлидер
Ун-унбиш көн тидия.

Рәхәт булсын аңарга
Каймак өсте яларга,
Хәзер тора танарга
«Ашаган юк» тидия.

Кырга чыкса, юк урак,
Куя белмидер зурат,
Ятадыр мисле сурат,
Ах-ах итеп тидия.

Мунча якса, бар утын,
Чыгармыйдыр һич төтен,
Күтәреп ята ботын
Кичә-көндез тидия.

Бәет булды тәмамы,
Яшь килённең яманы,
Мисле атның чаманы
Эшләгәндә тидия.

# Сәламнамә[1]

Сәламе Аллаһ йөрәгем парасига,
Тәнем рухы, күземнең карасига.

Сәлам, әй кувәти рухы рәваным[2],
Сәлам, әй дилбәри җан вә җиһаным.

Сәлам, и миһербани дилнәвазым[3],
Сәлам, и бостани сәрвиназым.

Сәлам, и ләләи руй[4], гөлгыйзарым[5],
Сәлам, и кувәти җан вә бәһарым[6].

Бәңа сәнсез бу эчкәннәр кызыл кан,
Бәңа сәнсез ачыйг ирер сөчек[7] җан.

Бәңа сәнсез газаб ирер бу рәхәт,
Бәңа сәнсез йөрәкдә мең җәрәхәт.

Бәңа сәнсез харам ирер бу сохбәт
Бәңа сәнсез бу сохбәтләр чу михнәт.

Бәңа сәнсез мосыйбәттер[8] мәгыйшәт[9],
Бәңа сәнсез мәгыйшәтләр мәшәкъкать.

Сәнең гыйшкың билә, ахры, үләрмен,
Фиракың утыйнда эксәр[10] көярмен.

Кыйлыбдыр такатем так иштиякың,
Ки өртәр хаста җанымны фиракың.

[1] Сәламнамә — сәлам хаты (Г.Кандалый әсәре).
[2] Кувәти рух рәваным — рухыма көч бирүчем.
[3] Дилнәваз — күңелгә ошаган, күңелне хушландырган.
[4] Руй — йөз.
[5] Гөлгыйзар — гөл яңаклы.
[6] Бәһар — яз.
[7] Сөчек — татлы.
[8] Мосыйбәт — кайгылы, хәсрәтле.
[9] Мәгыйшәт — тормыш, тереклек.
[10] Әксәр — күбрәк.

Эчәрмен ширбәти һиҗран һәмишә,
Фиракында күзем гирйан[1] һәмишә.

Сәнең ядың белән гөлзар ачылыр,
Сәне күрмәй йөрәктә кан сачылыр.

Мән, и бидил[2] сине кандин күрермен,
Фиракың утыйда бисйар[3] көярмен.

Сәламе Аллаһ йөрәгем парасига,
Тәнем рухы, күземнең карасига.

## Гыйшык сүзләре

Колак салгыл, җанаша,
Сөйләем бер тамаша;
Гыйшык төшеп бу баша,
Ордым башымны таша.

Гаҗәп күңлем саташа,
Кыз дәрдилә маташа;
Үтүбән хәддин аша,
Сокланып кара каша.

Гаҗәп күңлем шуклана,
Кызлар күрсә соклана;
Мелла күрсә сыйблана,
Нидән икән, баксана.

Нидән икән, баксана,
Нәфсем үземә атлана;
Кызлар күрсә шатлана,
Күрдем, диеп мактана.

---

[1] Г и р й а н — елаучы, күз яше түгүче.
[2] Б и д и л — шәфкатьсез, каты бәгырьле.
[3] Б и с й а р — бик, күп.

Кызларның дәрте керә,
Күрер булса сикерә;
Кычкыра да җикерә,
Гүя тартып китерә.

Ишет сүзем, бай дусы,
Быел үткән җәйгесе
Булдым Мысыр байгышы,
Бар да кызлар кайгысы.

И җаныем, сагындым,
Хәсрәт туны ябындым;
Кайда барсам абындым,
Өтәч кебек кагындым.

И җаныем, ник көлдең,
Сөядер диеп белдем;
Кайда барсам төртелдем,
Тавык кебек өтелдем.

Аччы йөзең, күрәем,
И җаныем, түгәрәк;
Кушсаң, җаный, йөрермен,
Хезмәтеңдә түгәрәп.

Булмас безләрдә низаг,
Сезгә булса да иза;
Ятмак куйнында сәза[1],
Үлсәм куйнында риза.

Мин сөямен үзеңне,
Кашың белән күзеңне;
Бал-шикәр кук сүзеңне,
Әле дә үзем түземле.

Авызың, җаный, уймак,
Юктыр күреп туймак;
Һич кулымдин куймайдин,
Ятыр идем бер уйнап.

[1] Сәза — килешле, яраклы.

Күреп төрле уеныңны,
Кочар идем муеныңны;
Тикшерер идем куеныңны,
Шуңар күңлем бик моңлы.

Колагыңда алкадыр,
Сүзем дәхи артадыр;
Йөзең ай тик балкадыр,
Ике садрың[1] калкадыр.

Алтын йөзек-балдагы,
Кызлар мине алдады;
Һич куйнына салмады,
Ышанычым калмады.

Алтын балдак бармакта,
Кызлар ятыр чарлакта;
Мөмкин булса бармакка,
Элэктерер идем кармакка.

Гаҗәп хикмәт бу чакта,
Күңелем теләр очмакка;
Кызлар ятыр почмакта,
Кызыгамын кочмакка.

Кыз бала, и кыз бала,
Кызны күңлем кызгана;
Йөрәгемдә ут яна,
Көлле[2] төшем сызлана.

Кыз бала, и кыз бала,
Кил, кашымда торсана;
Багда утырсана,
Куеныңа тутырсана.

Иртә торып карасам,
Кычкырадыр бер карга;
Бер матур кыз алыр идем
Кочаклашып йокларга.

---

[1] Садрың — түшең, күкрәгең.
[2] Көлле — һәммә, бөтен.

Калпак алып бирер идем
Башыңа һәм кияргә;
[Бер] матур кыз алыр идем,
Алга алып сөяргә.

Иннек-кершән бирер идем
Битләренә ягарга;
Бер матур кыз алыр идем,
Мөмкин булса табарга.

Сөрмә дәхи бирер идем,
Тартыр булса күзенә;
Бер матур кыз алыр идем,
Килер булса үземә.

Сакалымны тарыймын,
Хәсрәтеңдә сарымын;
Ялтын-йолтын карыймын,
Кыз-кыз, ди-ди, арыймын.

Арт тәңкәсе шалтырый,
Түшләре һәм ялтырый;
Минем йөрәк калтырый,
Аның саен ул йөри.

Күп сөйлисең юләр, дип
Башламагыз сүгәргә.
Бер матур кыз алыр идем
Авызыннан үбәргә.

Имән агач төбендә
Тозак кордым төлкегә;
Йөрдем-йөрдем ләкмәде,
Инде калдым көлкегә.

Бу бәетне яза-яза,
Минем ачу кабарды,
Хәсрәт илә укый-укый,
Мәхәббәтем яңарды.

# ӘКИЯТЛӘР

## Үги кыз

Янә борын заманда бер кешенең ике кызы, бер углы бар иде. Берсе үги кыз иде. Аны бер дә яратмыйлар иде. Беркөн киңәш иттеләр, ул үги кызны урманга илтеп адаштырмакчы булдылар. Бу үги кызга агасы әйтте:

— Әйдә минем белән урманга, син җиләк җыярсың, мин утын кисәрмен дә кич белән кайтырбыз,— диде.

Бу үги кыз җомгагын алды, чиләк алды да агасы белән урманга киттеләр. Урманга барып җиттеләр. Урман эченә байтак эчкәре кергәч, бер җиргә туктадылар. Агасы атын тугарып ашарга җибәрде. Үги кызга әйтте: «Бар, син җиләк җый, минем балта тавышым ишетелмәс булгач кайтырсың»,— дип, балтасын алып, утын кисә башлады. Үги кыз, чиләкне алып, җиләк җыярга китте.

Аннан соң агасы бер зур агачка утын тукмагы асып куйды да, атын җигеп, өенә кайтып китте. Үги кыз җиләк җыя калды. Бу үги кыз беравык җиләк җыя да тыңлап тора. Ул арада агачка асып куйган тукмак җил белән селкенеп, тук-тук агачка бәрелеп, үги кызга балта тавышы кебек ишетелә. Кыз: «Агай әле утын кисә икән»,— дип, җиләкне җыя да җыя. Җыя торгач, чиләк тулды. Ул арада кич булды. Җил дә басылды. «Инде агай утын кисеп бетергән икән»,— дип килеп караса, агасы юк. «Инде нишләргә?» — дип, бу үги кыз егълый-егълый урман буйлап китте. Ахыр, бара торгач, урман читенә, кырга барып чыкты. Анда бер юл очрады. Юлга чыгып, юл буенча егълый-егълый бара, мескенчек. Шунда наз тарта: «Тәгәри китте җомгагым, күрмәдегезме, агайлар?» — дип. Бу сүзне әйтә дә егълый, әйтә дә егълый. Бара торгач, бер ат көтүенә барып җитте. Көтүче катына барды да әйтә:

— Тәгәри китте җомгагым, күрмәдеңме, көтүче? — ди.

Көтүче әйтте:

— Күрдем. Менә бер көн көтү көтешсәң, сиңа бер ат бирермен,— ди. Бу кыз: «Ярар»,— дип, бер көн көтү көтеп, аннан бер ат алып, шуңа атланып китте. Үзе ат өстендә һаман егълыйегълый бара. Байтак җир баргач, сыер көтүенә җитте. Сыер көтүчесенә бер көн көтү көтеп, бер сыер алды. Сарык көтүенә җитте. Шул рәвешчә аннан бер сарык алды. Кәҗә көтүенә җитте. Янә аннан бер кәҗә алды. Шулай итеп, бара торгач, кич булды, күз бәйләнде. «Инде нишләрмен?» дип, ат өстендә баягы сүзне кат-кат әйтеп егълый. Ерактан бер кечкенә ут шәүләсе күреп: «Монда авыл бар икән»,— дип сөенеп, атын юыртыбрак китте. Авылның читендә генә бер кечкенә өй бар иде. Анда

барып керде. Керсә, өйдә бер карчык утыра. Ул убыр карчык, имеш. Шунда баягы назны тартып әйтә:

— Тәгәри китте җомгагым, күрмәдеңме, әбекәй?

Убыр карчык әйтте:

— Күрдем, кызым. Син кайдан киләсең? — диде.

Бу кыз үзенең башыннан үткән эшләрне барысын әйтеп бирде. Аннан соң убыр карчык әйтте:

— Кызым, син ерактан килгән икәнсең. Инде минем кызым булырсың,— диде.

Иртәгесен торгач, убыр карчык бу кызны мунча ягарга җибәрде. Кыз мунча ягып булдырды да карчык катына килде. Әйтте:

— Әби, инде мунча булды, әйдә барыйк мунчага,— диде.

Убыр карчык, ярар, кызым, дип, өйдән чыктылар. Карчык әйтте:

— Кызым, мин болай баралмам, син минем кулымнан тот, артыма тип. Шулай итеп мине мунчага алып бар,— диде.

Кыз әйтте:

— Юк, әби, алай ярамас. Син карчык кеше, рәнҗерсең,— дип, карчыкны, күтәреп, мунчага алып барды.

Мунчага баргач, убыр карчык әйтте:

— Кызым, мине чәчемнән тотып ләүкәгә сөйрәп мендер,— диде.

Кыз әйтте:

— Юк, әби, алай ярамас. Син рәнҗерсең,— дип күтәреп мендерде.

Карчык әйтте:

— Кызым, син мине чап. Себеркенең очыннан тот, сабы белән мине сук,— диде.

Кыз әйтте:

— Әби, алай ярамас,— дип, карчыкның аркасын йомшак кына чапты. Аннан соң мунчадан карчыкны күтәреп кайтты да йомшак урынга яткырды.

Убыр карчык әйтте:

— Кызым, башым бик кычыта, азрак башымны тара сана,— диде.

Бу кыз, тарак алып, карчыкның башын тарарга дип ачса, карчыкның чәч бөртеге саен алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, асыл ташлар туп-тулы. Башын тарап бетергәч, карчык әйтте:

— Инде, кызым, бер биеп кара, синең биегәнеңне күрәсем килә,— диде.

Бу кыз биеде, һичнәрсә юк. Аннан соң карчык әйтте:

— Кызым, бар, мунчага барып карачы, мин колаша белән мунчага салат күтәргән идем. Кипмәде микән? — диде.

Кыз мунчага барса, колаша белән алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, кыйбатлы ташлар. Кыз янә мунчадан йөгереп кайтты.

Карчык әйтте:

— Кипкәнме, кызым? — диде.
Кыз әйтте:
— Кипкән, әби,— диде.
Карчык әйтте:
— Яхшы, кызым, тагын бер биеп карачы әле,— диде.
Кыз биеде. Һичнәрсә юк. Аннан соң бу убыр карчык, кызның тугрылыгын белеп, кызга әйтте:
— Инде, кызым, өеңә кайтасың килсә, бар, кайт, — диде.
Кыз әйтте:
— Әби, мин юл белмим ләбаса, бик кайтыр идем кана,— диде.
Карчык әйтте:
— Бар, кызым, юл белмәсәң, мин сиңа юл күрсәтермен. Менә бу яшел сандыкны алып кит, сиңа булсын. Өеңә кайтып җитмәенчә ачып карама,— диде.
Аннан соң кыз сандыкны алды да атына атланды, сыерын җитәкләп, сарык-кәҗәләрен ияртеп, юлга чыгып китте. Көн китте, төн китте, бара торгач, байтак җир китте. Авылына да якынлашты. Агасының этләре бар иде. Шул вакыт этләр: «Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң!» — дип өрештеләр. Бу кызның агалары-җиңгәләре: «Бу эткә ни булган? Бу эт котырган»,— дип, этне таяк белән кыйнасалар да, эт аның саен: «Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң!» — ди. Ул арада бу үги кыз да өенә кайтып җитте. Өенә кайткач, сандыкны ачып караса, ни күрсен: сандык эче туп-тулы алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, кыйбатлы ташлар!
Кыз шуннан баеп китте. Моны күргәч, агалары-җиңгәләре бик көнчелек кыйлдылар, үзләренең кызын шулай җибәрмәкче булдылар. Бу кыз һәм җомгагын алып агасы белән урманга китте. Урманга барып җиткәч, агасы атын тугарып җибәрде ашарга, үзе китте утын кисәргә. Бу кыз китте чиләк алып җиләк җыярга. Ул арада агасы баягы рәвешчә бер агачка утын тукмагы асып куйды да атын җигеп өенә кайтып китте. Бу кыз, тукмак тавышы ишетелмәс булгач, агасы катына дип килсә, җилләр исә, һичкем юк. Агасы кайтып киткән, имеш.
Аннан соң бу кыз урман буенча китте. «Тәгәри китте җомгагым, күрмәдегезме, агайлар?» — дип әйтә-әйтә бара торгач, бер көтүгә барып җитте. Көтүчегә әйтте:
— Тәгәри китте җомгагым, күрмәдеңме, көтүче?
Көтүче әйтте:
— Күрдем, миңа бер көн көтү көтсәң, бер ат бирермен,— диде.
— Миңа ат кирәкмәс,— дип, кыз аннан китте.
Сыер көтүенә җитте. Сарык көтүенә җитте. Кәҗә көтүенә җитте. Бара торгач, баягы үги кыз кебек, убыр карчыкның өенә барып җитте. «Тәгәри китте җомгагым, күрмәдеңме, әбекәй?» — дип, карчыкның өенә керде.

Карчык әйтте:

— Күрдем. Инде бар, кызым, мунча як, — дип, кызны мунча ягарга җибәрде. Аннан соң убыр карчык әйтте: — Инде, кызым, мунчага барыйк. Син минем кулымнан тот, артыма тип. Шулай итеп мине мунчага алып бар,— диде.

— Ярар, әби,— дип, бу кыз, карчык әйткән рәвешчә, кулыннан тотып, артына тибә-тибә карчыкны мунчага алып барды.

Карчык әйтте:

— Кызым, минем аркамны чапса. Себеркенең очыннан тот, сабы белән минем аркама сук,— диде.

Бу кыз себерке сабы белән карчыкның аркасын дөп-дөп итеп ора да ора. Карчык ни әйтсә, ул әйткәнчә кыйла бирә.

Аннан соң карчык әйтте:

— Кызым, минем башымны тара сана азрак,— диде.

Кыз карчыкның башын ачып карады: чәч бөртеге саен алтын да көмеш, кыйбатлы ташлар. Бу кыз карчык башыннан алып-алып алтын-көмешне кесәсенә дә сала, куенына да сала. Тирә-ягын бөтенләй тутырды.

Карчык әйтте:

— Кызым, инде биеп кара, биегәнеңне күрәсем килә,— диде.

Кыз бии башлады. Кыз биегән саен, алтын-көмеш коела.

Карчык кызны мунчага җибәрде: «Карачы, кызым, мунчага салат күтәргән идем, кипмәде микән?» — диде. Кыз мунчага барды, күрде: баягы кебек колаша белән алтын-көмеш туптулы. Кыз тагы да кесәсенә, куенына тутырды: «Түти шулай итеп баеган икән»,— дип уйлады. Карчык кызны янә биергә кушты. Кыз бии башлагач, баягыча, алтын-көмеш янә шалдырап коела башлады.

Аннан соң карчык, бу кызны сынап бетергәч: «Бар, кызым, кайтып кит. Әнә фәләнчә юлдан кит,— дип юл күрсәтеп,— менә, кызым, бу кара сандыкны алып кит», — дип, бер кара сандык биреп җибәрде. «Өеңә кайтып җитмәенчә ачып карама»,— дип кисәтте.

Кыз, сөенеп, сандыкны күтәреп тәпи-тәпи китте. Байтак җир китеп үзенең авылына якынлашкач, баягыча агасының этләре өрә башлады. «Баерга киткән түтекәй үлеп кайта түгелме, ләңләң!» — дип, эт өрә. «Безнең бу эт тилергән, котырган»,— дип, таяк белән эткә аннан да, моннан да ыргыттылар. Эт аларга карамый, аның саен: «Баерга киткән түтекәй үлеп кайта түгелме?» — дип, ләң-ләң итеп өрә. Этне тагы: «Баерга киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң, дип әйт»,— дип кыйнадылар.

Ул арада кыз да өенә кайтып җитте. Кайтып кергәч, кара сандыкны ачып җибәрде. Сандыкны ачуы белән, сандык эченнән бер кара елан сикереп чыкты да, кызның муенына чорналып, кызны буып үтерде.

Менә көнчелек кешене нишләтми.

# Гөлнәзек

Борын заманда Гөлнәзек дигән бик ярлы кеше бар иде. Шайтаннан да ярлы иде. Баласы-чагасы бик күп иде. Бу Гөлнәзек үзе эшлексез, бик ялкау кеше иде. Ярлылыкка чыдый алмаенча, өеннән чыгып качты. Бер тал чыбыгыннан бөгеп җәя ясады, чырадан юнып ук ясады да китте бер урманга.

Барып җитте. Анда бер дию пәрие очрады. Гөлнәзек, аны күреп бик куркып, дер-дер калтырый башлады. Инде моннан ничек котылырмын дип торганда, дию пәрие килеп җитте дә әйтте:

— Син ни кеше, монда ни эшләп йөрисең? — диде.

Гөлнәзек әйтте:

— Мин — аучы, ау ауларга чыктым,— диде.

Дию әйтте:

— Кулыңда ни-нәрсә? — диде.

Гөлнәзек әйтте:

— Ук белән җәям,— диде.— Диюләрне атып үтерергә чыктым,— диде.

Моны ишеткәч, дию курыкты, куркуыннан печән кибәне кебек булып кабарып, ыңгыраша башлады. Гөлнәзеккә әйтте: «Әйдә, дус, миңа, кунак бул, сине сыйлап җибәрим»,— диде. Моны ишеткәч, Гөлнәзек бигрәк тә нык курыкты. Дию белән барырга да курка, калырга да курка. Алай да диюгә ияреп китте. Диюнең өенә барып җиттеләр. Ул арада кич булды. Бу дию Гөлнәзекне ашатты-эчертте, бик сыйлады. Гөлнәзеккә урын җәеп бирделәр. Гөлнәзек ятты. Бер дә күзенә йокы кермәде. Алай да: «Ни булыр икән?» — дип, йоклаган булып ятты. Ул арада дию хатынына әйтте:

— И хатын, башымызга бер бәла очрады. Моннан ничек котылмак кирәк? — диде.

Хатыны әйтте:

— Бу кеше йоклагач, өстенә таш кертеп салыйк. Таш басып үтерер дә, таң аткач, чыгарып ташларбыз,— диде.

Гөлнәзек йоклаган булып бу сүзләрне тыңлап ятты. Аннан соң төнлә торып, дию хатыны белән таш алырга тышка чыгып китте. Ул арада Гөлнәзек урыныннан торып, үз урынына утын агачлары куйды да өстенә тун япты. Имеш, кеше ята. Үзе мич арасына качты. Ташны күтәреп керделәр дә китереп салдылар. Тун астындагы утын агачлары шатырдап уалды. Янә беравык торгач, ул ташны чыгарып ташладылар. Алар чыгып киткәч, бу Гөлнәзек тун астына кереп янә ятты. Болар өйгә кергәч, Гөлнәзек йокыдан уянган кебек булып киерелде-сузылды да:

— Ай-һай, дию дус, өең бик тынычсыз икән. Түшәмнән өстемә әллә бет, әллә таракан төште. Ят кеше булсагыз, өегезне кая

куяр идем, үзегезне кая куяр идем. Әле дә дуслык хакы бар,— диде.

Моны ишетеп, дию тагы бигрәк шүрләде. Бу Гөлнәзектән аерылып калырга да курыкты. Әйтте: «Әйдә, Гөлнәзек дус, мин сине өеңә чаклы озатып куйыйм»,— диде. Гөлнәзек: «Ярар»,— дип, бергә чыгып киттеләр. Гөлнәзекнең өенә барып җиткәндә, ул әйтте: «Дию дус, син монда торып тор. Мин өйгә кереп әйтим, хатыным азрак өйне җыештырсын»,— дип өенә керде. Дию ишек төбендә калды. Гөлнәзек хатынына әйтте: «Бер кунак алып килдем. Мин синнән сорармын, кунакка ашарга китер, дип. Син миңа, өч тапкыр әйткәнче, җавап бирмә, тик тор. Мин өч тапкыр әйткәч, син әйт: кунак алдына китерергә бер нәрсәмез дә юк лабаса, диген. Мин, кичәге диюнең башын, өченче көнге диюнең түшен китер, дип әйтермен»,— дип, хатынын өйрәтеп куйды да диюне өйгә алып керде. Диюне утыртты. Хатынына әйтте:

— Кая, кунакка ни бар ашарга? — диде.

Өч тапкыр әйткәнче хатыны тик торды. Өч әйткәч, хатыны әйтте:

— Кунакка түгел, үзебезгә юк ашарга, ничә көннән бирле балабыз-чагабыз белән ач торабыз,— диде.

Гөлнәзек әйтте:

— Ник булмаска, бар лабаса. Кичәге диюнең башын, өченче көнге диюнең түшен китер,— диде.

Дию пәрие моны ишеткәч, өй почмагын күтәреп, чыгып качты. Барганда диюгә бер төлке очрады. Дию, сулуы кабып, мышкылдап бара иде. Төлке әйтте:

— Нихәл, дию дус, кая бардың? — диде.

Дию әйтте:

— Тукта, тукта, сөйләштермә, харап була яздым,— диде.

Төлке әйтте:

— Ник, бу ни булды сиңа? — диде.

Дию: «Менә шулай-шулай эш булды»,— дип, төлкегә сөйләгәннән соң, төлке әйтте:

— И дию дус, син аннан юкка куркасың. Ул Гөлнәзек бик юаш кеше. Аның кулыннан бер нәрсә дә килми. Мин кичә аның ун тавыгын ашап киттем. Әйдә, барып, тагы да тавыкларын ашыйк,— дип, Гөлнәзек өенә таба кире кайтып китте.

Гөлнәзек моны ишетеп торды да төлкегә кычкырды:

— Әйдә, әйдә, төлке дус, кил тизрәк. Хәер, ялганчы икәнсең. Ике дию китермәкче булып, кичә ун тавыгымны ашап киткән идең. Әле бер генә дию китерәсең, имеш. Китер, китер тизрәк. Бүгенгә берсе дә җитеп торыр. Берсен тагы да иртәгә китерерсең,— диде.

Дию, моны ишеткәч, әйтте төлкегә: «И төлке дус, ышанга-

ным син идең, син мине сатарга алып барасың, имеш»,— дип, төлкенең койрыгыннан тотты да күтәреп җиргә бәрде. Төлке бичараның сөяк-санагы көл булды, җаны чыкты. Дию качып китте. Гөлнәзек чыгып, төлкене тунап, тиресен базарга чыгарып сатты да икмәк алды, ач тамагын туйдырды.

## Байдек

Куптән түгел Түбән Шырданда Байдек дигән кеше бар иде. Беркөн байтак кешеләр белән юлга чыктылар. Бара торгач, бер иделгә җиттеләр. Иптәшләре белән бер байның богдай төягән көймәсен ерак калага илтмәкче булып, богдай төягән көймә белән киттеләр. Бара торгач, Байдеккә авыру тиеп, су якасына чыгарып ташладылар. Байдек мескен егълый-егълый ятканда, Байдекнең катына ике карак килде. «Син монда нишләп ятасың?» — дип, Байдекне бик куркыттылар. «Әйдә, безгә юлдаш бул»,— дип, көчләп алып киттеләр.

Бара торгач, кич булды. Бер авылга җиттеләр. Бер байның келәтен басмакчы булып, келәт түбәсен ачтылар. Байдекне, аркан белән бәйләп, келәткә төшереп җибәрделәр. Байдек келәттә ни нәрсә тапса, барысын биреп бетерде. Бетергәч, үзен бәйләп, иптәшләренә: «Тартыгыз»,— дип кычкырды. Иптәшләре тартып чыгарганда, Байдек икәнен белгәч, арканны кисеп җибәрделәр дә үзләре киттеләр.

Байдек келәттә калды. Байдек мескен, нишләргә белмәенчә аптырап торганда, бер кисмәктә борчак оны бар икән, аны тапты. Борчак онын төкерек белән төкерә-төкерә юешләп, ике йомарлак ясады да, ишек яңагына сөялеп, саклап торды. Көн яктыргач, бер хатын келәткә килеп ишекне ачканда, ике йомарлак онны хатынның ике күзенә атып, үзе келәттән чыгып качты. Хатын күзен тотып егълый калды.

Байдек бара торгач, бер авылга барып җитте. Бер өйгә керде, сәлам бирде. Өйдә бары бер авыру хатын бар иде. Ул хатын Байдеккә: «Яхшы киләсең, туганым, синең карның ачкандыр, менә аша»,— дип, Байдек алдына ак битле пәрәмәч китерде. Байдек ашап туйганнан соң, хатын әйтте: «Мин бала табарга кысталып ятамын. Күрше авылда минем анам бар. Шул анамны алып килсәнә, туганым», — дип җибәрде.

Байдек шул авылга барды. «Әйдә, әби, кызың чакыра сине»,— дип, хатынның анасын алып чыкты. Җәяү килә-килә карчык арыды. Байдек аны күтәреп бара башлады. Байдек тә бара торгач арыды. «Әби, инде азрак ял итим»,— дип, карчыкны бер түмгәк өстенә утырткан иде, коега тап килеп, әби коега төште-китте. «Инде теге хатынга ни әйтергә кирәк»,— дип, Байдек юл буен-

ча исәп итеп кайтты. Кайтып җиткәч, әйтте хатынга: «Юк, ул әби килмәде. Мин сине танымыйммын, дип, миңа ышанмады. Бар, чынлыкка кызымның бер нәрсәсен алып кил, дип, мине кайтарып җибәрде»,— диде. Алай дигәч, бу хатын алтын-көмеш тәңкәдән ясаган хәситәсен бирде. Менә минем хәситәмне илтеп күрсәтсәң, килер»,— дип, Байдекне яңадан җибәрде. Байдек, хәситәне алып, үз юлына китте. Хатын әле булса көтеп тора.

Аннан соң Байдек байтак җир киткәч, кич булды. Бер авылга җитте. Төнлә бер өйдә ут күреп, коймага менеп атланды. Ишегалдында каравылчылары бар иде. «Карак килде!» — дип, Байдекне ботыннан тартып төшерделәр. Байдекне кыйнадылар-кыйнадылар да, бер мичкәгә салып, мичкәнең авызын какадаклап, биек тау башыннан тәгәрәтеп җибәрделәр. Байдек мескен мичкә эчендә тәгәрәп бара-бара мие түнеп, бераз җан тарткач, кесәсеннән пәкесен чыгарып, мичкәне пәке белән уя-уя, кул сыярлык тишек ясады. Аннан соң тыңлап караса — аюлар, бүреләр мичкә тирәсендә иснәнеп йөриләр икән. Мичкә тирәсендә әйләнеп йөри торгач, бер бүренең койрыгы мичкә эченә керде. Байдек бүренең койрыгын кулы белән чорнап тотты да «их!» дип кычкырды. Бүре шул куркудан мичкәне койрыгы белән сөйрәп чабып китте. Чабып бара торгач, бер түмгәккә эләгеп, мичкә таркалып китте. Бүренең дә койрыгы шарт итеп өзелде. Бүре качты, ә Байдек котылды.

Байдек, күзен ачып караса, үзен бер урман эчендә күрде. Төн, караңгы. Әле таң атканы юк. Байдек, бүре тавышларын ишетеп: «Болар мине монда бетерерләр»,— дип куркып, бер зур имән башына менде. «Монда таң атканчы утырыйм»,— дип торганда, имәннең эче куыш икән, төште дә китте. Куышның төбенә җитте. Аягына йомшак тиде. Кабалап караса — имән төбе туп-тулы бал. Балны туйганчы ашады.

Таң атты. Көн булды. «Инде моннан ничек чыгармын?» — дип исәп итеп торганда, югары таба башын күтәреп караса, имән эченә арты белән төшеп килгән бер аюны күрде. Төшеп җитәрәк Байдек, аюның арт ботын бик нык тотып, әче тавыш белән кычкырды. Шул куркудан аю, имән эченнән үрмәләп, имән башына менеп җитте. Байдек тә аю ботына ябышып имән түбәсенә чыкты. Аю имән түбәсеннән үз буен үзе атты да үлде. Байдек имән түбәсендә калды. Әкренләп имән түбәсеннән төште. Аюны тунады да тиресен күтәреп китте. Бара торгач, бер юлга чыкты. Күрде: юлда байтак кешеләр килә. «Сез кайсы якка?» — дип сорашканнан соң, аларга аю тиресен биреп, үзе авылга чаклы утырып кайтты. Яз көне киткән иде, көз көне, кар ява башлагач, кайтты.

Бу Байдек, дус-ише белән күрешкәннән соң: «Инде бер бәйрәм ясыймчы»,— дип, ашлар хәзерләде. Баягы хатынның

хәситәсеннән әллә ничаклы алтын-көмеш чыкты. Янә икенче авылда Байдекнең анасы бар иде. Аны алырга китте. Ул көн яңа гына кар яуган иде. Утын чанасы җигеп китте. Аның анасы бик карчык кеше иде. Анасына бик зур тун киертеп, чанасына утыртты. Ул тунның итәкләре чананың як-ягыннан печән кебек сөйрәлеп кайтты. Беләсез, утын чанасы шулай була. Бу Байдек барган авылда ул көнне печән җуелган икән. Менә Байдекнең артыннан ук тентү белән басып килделәр. «Менә печән чанасы монда кергән»,— дип, Байдекне тоттылар. Байдек, баягы алтын тәңкәләрне биреп, котылып калды. «Ах, бу тун! Миңа зыян китерде»,— дип, ул тунны утка атты. Ул тире тун булса кирәк, утта янып, дуңгыз борыны кебек булып бөреште дә, Байдек аны читән башына чыгарып элде. Янә бер авылда ул көн дуңгыз җуелган икән. Тентү килеп, читән башыннан дуңгыз борыны кебек нәрсә тапты. «Менә бу дуңгыздыр»,— дип, Байдекне тотып бәйләделәр. Байдек, янә баягы хәситәдән сүтеп алган алтын тәңкәләрне барысын биреп, мең бәла белән көчкә котылып калды.

Байдек мескен, юклыкка чыдый алмаенча, баягы хатынның хәситәсен урлап кайткан иде, барысын әрәм-шәрәм итеп бетерде. Шуның өчен әйткәннәр: «Ырыкныкы — шырыкка»,— дип. Һәм дөрес: ырыкныкы шырыкка китте.

## Өч угыл

Янә борын заманда бер кешенең өч углы бар иде. Үзе бик бай түгел иде. Бай булмаса да, тереклеге чибәр иде. Һичнәрсәгә аптырамады. Бер тегермән ташы бар иде, бер барабаны бар иде, тагы чабата калыбы белән шөшлесе бар иде. Үзенә үлем сырхавы тигәч, балаларын чакырып әйтте: «Инде мин үләмен. Мин үлгәч, яхшы торыгыз. Менә сезгә шул җитәр»,— дип, бер углына тегермән ташы бирде, икенче углына барабан бирде, өченче углына чабата калыбы белән шөшле бирде. «Менә шулар белән тамакларыгызны туйдырырсыз, ач булмассыз»,— дип әйтеп үлде.

Аталары үлгәч, өчесе өч якка чыгып киттеләр. Бер угыл китте тегермән ташын алып. Авылдан авылга өй борынча йөреп ярма тартып, кул көче белән казганып, үз тамагын үзе туйдырды, ачлык күрмәде.

Икенче угыл китте барабан алып урманга. Бер урманга барып, бер зур имән башына менде дә барабанын суга башлады. Җыелды аюлар. Ул аюларны тотып, кайсысын сатты, азрак акча ясап, ат алды. Кайсысын үзе алды. Аю җитәкләп, авылдан авылга йөреп, аю биетте.

Бу угыл да барабан аркасында яхшы тереклек кылды, юклыкны күрмәде.

Өченче угыл тагы шөшле-калып күтәреп урманга китте. Урманга барып, бер күл янында шөшлесе белән юкә төшерде дә чабата киндерәсе ишә башлады. Киндерә ишеп торганда, күлдән бер Су иясе чыкты:

— Агай, нишлисең? — диде.

Бу кеше әйтте:

— Аркан ишәмен,— диде.

Су иясе әйтте:

— Ул аркан нигә? — диде.

Бу кеше әйтте:

— Менә бу күлне күккә асмакчы буламын. Күктә су юк. Бер дә яңгыр яумый,— диде.

Су иясе әйтте:

— Агай, тукта, торып тор. Мин бабайга әйтим,— дип, күлгә төшеп китте. Күл төбендә бик карт Су иясе бар иде. Аңар барып әйтте: «Бабай, харап! Бер кеше күлне күккә асам, дип, аркан ишә»,— диде. Бабай әйтте: «Адәмдер ул. Бар, углым, күлне бирмә. Менә бу чукмарны алып чык. Аның белән үлчәш. Кайсыңыз бу чукмарны күтәреп, күл тирәли биш кат әйләнсә, күл аңар булыр»,— диде.

Су иясе чукмарны күтәреп чыкты да әйтте:

— Агай, менә бу чукмарны кайсыбыз биш кат күтәреп әйләнсә, күл аңар булыр,— диде.

Бу кеше әйтте:

— Ярар. Әүвәл үзең әйлән,— диде.

Су иясе чукмарны күтәреп көчкә әйләнде дә чукмарны бу кешенең кулына бирде. Бу кеше, чукмарны җиргә утыртып, үзе югары таба карап тора. «Һай, ни эшлисең?» — диде Су иясе. Бу кеше әйтте: «Менә чукмарны болыт астына тыгып җибәрергә итәмен»,— диде. Су иясе: «И агай, тия күрмә, үзебезгә дә бер генә чукмар»,— дип, бабасы катына төшеп китте.

Бабасы әйтте:

— Нихәл, углым? — диде.

Углы әйтте:

— Ул кеше чукмарны болыт астына тыгып җибәрә язды,— диде.

Бабасы әйтте:

— Алайса бар, менә бу айгырны кайсыгыз күтәреп әйләнсә, күл аңар булыр,— диде.

Су иясе айгырны алып чыкты да әйтте:

— Агай, менә бу айгырны кайсыбыз биш кат күтәреп әйләнсә, күл аңар булыр,— диде.

Бу кеше әйтте:

— Ярар. Әүвәл үзең күтәреп әйлән,— диде.

Бу Су иясе биш кат әйләнде дә айгырны бу кешегә бирде. Бу кеше айгырга сикереп атланды да күз ачып йомганчы биш кат әйләнеп тә чыкты. Су иясе тагы курыкты. Тизрәк бабасы катына китте. Бабасына әйтте: «Ул кеше бик көчле икән, бабай,— диде.— Айгырны бот арасына кыстырып кына күз ачып йомганчы әйләнде,— диде.— Күл китмәсә ярар иде безнең»,— диде. Бабасы әйтте: «Бар, углым, көрәш аның белән,— диде.— Кайсыңыз җиңсә, күл аңар булыр»,— диде.

Су иясе бу кеше катына чыкты да әйтте:

— Агай, әйдә көрәшик. Кайсыбыз җиңәр? — диде.

Бу кеше әйтте:

— Мин әле бушамыймын. Әнә теге куак артында бер бик карт агарып беткән бабам бардыр. Аның белән көрәш,— диде.— Әле ул йоклагандыр. Син бар да колак төбенә сук. Югыйсә ул уянмас,— диде.

Анда бер ак аю бар иде. Бу Су иясе, аю катына барып, аның колак төбенә сукты. Аю сикереп торды да, Су иясен күтәреп, гөп иттереп җиргә салды. Үзе качып китте. Бу Су иясе байтак сулусыз булып ятты. Аннан, торып, янә бабасы катына китте. «Бабай, харап,— диде.— Безнең күл китә, күлсез калабыз»,— диде. Бабасы әйтте: «Ник?» — диде. Бу әйтте: «Юк, бабай, син белмисең әле,— диде.— Аның бер карт бабасы бар икән. Аның белән көрәштем. Күтәреп салды үземне, ничаклы сулусыз булып яттым, үлә яздым,— диде.— Күлсез калсак, ни булыр,— диде.— Инде ул аркан ишеп бетерә, күлне күккә аса», — диде. Бабасы әйтте: «Инде, углым, болай ярамый. Аның белән килешергә кирәк. Бар, әйтеп кара, акча алмас микән?»— диде.

Аннан соң Су иясе егълап чыкты да бу кеше катына килеп әйтте:

— Агай, ни алсаң да ал, күлгә тия күрмә. Акча бирербез, күпме алырсың? — диде.

Бу кеше әйтте: «Ярар»,— диде. Башындагы эшләпәсен күрсәтте: «Менә бу эшләпә белән бер эшләпә акча бирсәңез, җитәр»,— диде.

Су иясе бабасы катына кереп әйтте: «Шулай-шулай әйтә»,— дип. Бабасы: «Күп сорамый икән, чыгарып бир, китсен»,— диде.

Аннан соң бер эшләпә тутырып, бу кешегә чыгарып бирде. Бу кеше эшләпәсен җиргә куйды да акчаны эшләпәгә салды. Ярты эшләпә булды. «Бар, тагы китер, әле тулмады»,— дип, Су иясен тагы бабасы катына җибәрде. Китте. Ул киткәч, бу кеше, эшләпәсенең астына чокыр казып, эшләпәнең төбенә тишек ясады. Ул тишектән акчалар чокырга төшеп китте. Эшләпәдә бик аз калды. Янә чыгарып салды. Тулмады. Шулай итә-итә эшләпәне тутырды. Эшләпә астындагы чокыр һәм тул-

ды. Бу кеше әйтте Су иясенә: «Инде син бу эшләпәне минем өемә илтеп бир,— диде.— Миңа җире дә кирәк, җире белән казып ал да күтәреп илт»,— диде.

Су иясе, «ярар» дип, эшләпәне казып алды да баш түбәсенә күтәрде. Бу кеше дә шөшлесен, калыбын алып, бергә киттеләр. Бара торгач, бер багана очрады.

Су иясе әйтте:

— Агай, бу ни-нәрсә? — диде.

Бу кеше әйтте:

— Бая син күрәшкән бабайның таягы,— диде.

Аннан киттеләр. Бер себерке[1] очрады. «Агай, бу ни-нәрсә?» — диде. Бу кеше әйтте: «Бабайның сакал тарый торган тарагы»,— диде. Янә аннан киттеләр. Бер сука очрады. Су иясе әйтте: «Агай, бу ни-нәрсә?» — диде. Бу кеше әйтте: «Бабайның теш арчый торган шырпысы»,— диде.

Яхшы. Бу кешенең өенә барып җиттеләр. Өйгә керделәр. Бу кеше хатынына әйтте: «Кая, хатын, кунакка ашарга китер»,— диде. Хатын өйдән чыгып китте дә, бер сәнәк алып кереп, иренә бирде. Аннан соң бу кеше сәнәк белән Су иясенең бугазына төртте. «Менә сиңа җәпле теш, аша, аша!» — дип, Су иясен аптыратып бетерде. Су иясе кычкыра башлады: «Инде җитәр, бик туйдым, бик туйдым!» — дип. «Бар инде, туйсаң, озатып җибәрим»,— дип, бу кеше чыкты да этләренә «өс, өс!» дип кычкырды. Этләре «һау-һау» дип килеп ябышты. Кайсы итәгеннән тарта, кайсы битенә сикерә. Су иясе көчкә котылып китте.

Кайтып бабасына әйтте: «Йә бабай, күрдем бер төрле әкәмәт»,— дип, барысын сөйләде. Тагы да әйтте бабасына: «Йә бабай, шунысы бигрәк әкәмәт булды: бардым ул кешенең өенә. Миңа әллә ниндәен җәпле теш дигән аш ашатты. Ашатып-сыйлап үтерә язды. «Туйдым!» — дип кычкыргач кына туктады. «Аша, аша!» — дип, ирексезләп ашатты. Аннан соң мине озатып җибәрде. «Озатыгыз!» — дип, балаларына да кушты. «Һау-һау! Сау бул, сау бул!» дип, улсы да килеп тарта, бусы да килеп тарта, көчкә котылып кайттым»,— диде.

Бабасы әйтте: «Ярар, улым, ни булса да булды, үзебез тынычлап калдык»,— диде. Бу кеше тагын шуннан баеп калды.

## Гакыллы бала

Янә борын заманда бер хатын бар иде. Бер углы, бер кызы бар иде. Беркөн кызы үзе генә ялгыз өйдә егълап утырадыр иде, анасы килеп керде.

---

[1] Себерке — биредә: җир тырмасы.

— Ник егълыйсың, кызым? — диде.

Кызы әйтте:

— И әни, мин кияүгә барсам, миннән бала туса, ул бала үлсә, мин егъламай кем егъласын? — диде.

Анасы да егълый башлады. Ул арада углы килеп керде:

— Ник егълыйсыз? — диде.

Анасы әйтте:

— Менә сеңлең, мин кияүгә барсам, миннән бала туса, ул үлсә, мин егъламай, кем егъласын, диде. Шуның өчен егълыйбыз,— диде.

Углы: «Җүләрсез икән»,— диде дә чыгып китте.

Аннан соң анасы сыер саварга чыкты. Анасы сыер сауганда, сыер һава бозды. «И оятлы булдым, сыер ояты минем оят»,— дип барды да базга төшеп утырды. Анасы артыннан кызы анасын эзләп китте. Базга барды да «әни!» дип кычкырды.

Анасы:

— Ни, кызым? — диде.

Кызы әйтте:

— Анда нишлисең? — диде.

Анасы әйтте:

— Харап булдым, кызым, сыер һава бозды. Сыер ояты минем оят,— диде.

Кызы:

— И әни, синең оят минем оят. Харап булдык,— диде дә анасы катына төшеп утырды.

«Йә, безнең әниләр кайда икән?» — дип, углы китте эзләргә. Барып тапты. Анасы берлән сеңлесе базда утыралар.

— Әни, анда нишлисез? — диде.

Анасы баздан кычкырды:

— И углым, дәшә күрмә, харап булдык. Сыер һава бозды. Сыер ояты минем оят. Минем оятым кызым ояты,— диде.

Аннан углы:

— Әни, сау булыгыз. Сездән җүләрне тапсам — кайтырмын, тапмасам — кайтмамын,— дип, биленә балта кыстырды да чыгып китте. Бара-бара байтак җир китте. Бер төшкә барып җитте. Күрде: тәрәзәсез өйгә тубал белән тыштан якты ташыйлар. Тубалны кояшка чыгарып куялар да, өстән каплап, өйгә алып керәләр. Юк, өйгә якты керми. Аптырадылар. Ул гакыллы бала, биленнән балтасын алып, аларга тәрәзә ясап бирде. «Инде шөкер Ходайга, җүләрне таптым. Безнең әниләрдән дә җүләр бар икән дөньяда» дип кайтып килгәндә, янә бер җиргә очрады. Бер лапас башында бер кешене күрде. Ыштансыз. Биленә чаклы күлмәген күтәреп, лапас башыннан сикереп төшәргә тора. Янә күрде: түбән ике кеше ыштанны ике балагыннан тотып торалар. Гакыллы бала байтак карап торды «бо-

лар нишли икән?» дип. Алар лапас башындагы кешегә ыштан киертергә газапланалар икән. Сикереп төшә кана, юк, ыштан балагына аяклары туры килми. Тегеләрнең кулыннан ыштан ычкына китә.

Аннан соң бу гакыллы бала аларга барып әйтте:

— Агай, нишлисез? — диде.

— Менә бу кешегә ыштан киертмәкче идек,— диделәр.

Аннан соң гакыллы бала ул кешене бер бүкән өстенә утыртты да, әүвәл бер балагын киертте, аннан соң икенче балагын. «Менә ыштанны шулай кимәк кирәк»,— диде.

Аннан соң бу гакыллы бала, бусы баягылардан да җүләррәк икән, дип сөенеп, артына аягы тигәнче йөгереп кайтты. Капкадан ук кычкырып керде: «Әни, чыгыгыз! Сездән җүләрне таптым!» — диде. Анасы белән сеңлесен баздан берәм-берәм тартып чыгарды.

## Җүләр угыл

Борын заманда бер хатын бар иде. Аның бер углы бар иде. Бик җүләр иде. Беркөн моны анасы базарга җибәрде. Бу җүләр, базарга барып, кашык алды, өстәл алды һәм тоз алды. Бу нәрсәләрне алып, базардан кайтырга чыккач, юлда бер күгәрчен очрады. Су эчәргә төшкән иде. Бу җүләр узып барганда, күгәрчен, моннан куркып, су эчүдән туктады. Бу җүләр үзенең күңеленнән әйтте: «Бу күгәрчен суның тозы юкка күрә эчми торгандыр»,— дип. Тозны арбасыннан алып суга салды.

Хуш, аннан китеп бераз баргач, кашыклары шалтырый башлады. «Мине болар үтерергә киңәш итәләр бугай»,— дип, кашыкларын юлга ташлап калдырды. Ул арада аты арыды. Аты арыгач, өстәлне һәм: «Үзеңнең дә дүрт аягың бар, үзең кайтырсың әле»,— дип, юлга ташлап калдырды. Моннан соң үзе өйгә кайтып килде.

Анасы сорады:

— Нәрсәләрең кайда? — дип.

Җүләр әйтте:

— Менә хәзер үзләре бар да кайтып килерләр,— диде.

Аннан соң анасы: «И углым, син йорт тотмассың»,— дип, өйгә кереп китте. Ул көнне кич булды. Кич булгач яттылар, йокладылар. Таң аткач, анасы моны йокыдан уятты: «Ник ятасың, тор, бар, кешеләр катына бар, кеше очраса, сәлам бир, акча исәпләүчегә очрасаң, акча исәпләш»,— диде.

Җүләр өеннән чыгып китте. Юлда этләргә очрады. Бу җүләр аларны күргәч: «Әссәламегаләйкем!» — дип, этләр алды-

на утырып, бармакларын санарга тотынды. Этләр моны таладылар, күлмәкләрен ертып бетерделәр. Бу җүләр анасына егълап керде. Анасы әйтте: «Кемнәр тиде сиңа?» — диде. Анасын алып чыгып, этләрне күрсәтте. «Менә шушылар тиде миңа»,— диде. Анасы этләр икәнен белде: «Углым, болар катына барма, син боларны кыйна»,— диде.

Бу җүләр, шул сәгать бер чукмар ясап, этләрне кыйнамага урамга чыкты. Бер ак сакаллы карт намазга барырга чыккан иде. Намазга барган чакта бу карт янына барды. «Ә-ә, очрадыңмы!» — дип, ак сакаллы картны чукмар белән бәреп үтерде дә өенә кереп китте. Өенә кергәч, анасына мактанды: «Мин баягы этләрнең берсен ипләдем»,— диде. Анасы әйтте: «Ул кай төштә?» — диде. Җүләр әйтте: «Әвен базына салдым»,— диде.

Анасы белән әвен базына бардылар. Төшеп карадылар. Ак сакаллы икәнен күреп, анасы бик кайгырды. Сарайларында бер ак кәҗәләре бар иде. Анасы, углына белгертмәенчә шул ак кәҗәне үтереп, әвен базына ташлады. Теге картны шул әвен базына җиргә күмде.

Аннан соң шул җүләр кулына коймак алып, багана башына менеп ашый башлады. Ул арада теге картның җәмәгате, балалары ул картны эзләмәгә чыктылар. Бу җүләр, аларны күргәч: «Кая барасыз?» — диде. Алар әйттеләр: «Безнең этине күрмәдеңме?» — диделәр. Җүләр әйтте: «Мин сезнең атагызны үтердем»,— диде. Алар әйттеләр: «Кая куйдың?» — диделәр.

«Әйдәңез, күрсәтим»,— дип, аларны әвен базына алып барды. Бара-бара әвен базына җиттеләр. «Менә атагыз шушында»,— диде. Ул җүләргә әйттеләр: «Бар, төшеп алып чык»,— диделәр.

Җүләр әвен базына төшеп китте. Төшкәч үк кулы әүвәл кәҗәнең мөгезенә тиде. Әвен эченнән кычкырды:

— Мөгезе бар идеме атагызның? — диде.

Җүләрдән бу сүзне ишеткәч: «Әйдә, җүләр артыннан йөргән без дә җүләр»,— дип киттеләр. Җүләр: «Әллә-ли, коймагым!» — дип, аларның артыннан кычкырып калды.

## *Салам Торхан*

Борын заманда бер бик ярлы кеше бар иде. Кияргә киеме, торырга урыны юк иде. Һаман саламда тереклек кыйлыр иде. Шуның өчен исемен Салам Торхан падишаһ диерләр иде. Вә аның бер төлке дусты бар иде. Беркөн Салам Торхан янына килде вә әйтте:

— И дустым, минем сине өйләндерәсем килә, синең болай торуың миңа да яхшы түгел. Сине кеше күзенә күрсәтәсем килә,— диде.

Салам Торхан әйтте:

— Кулыңнан килсә, яхшы булыр иде. Ярар, шәфкатеңне күрсәт, күрәек,— диде.

Төлке аннан китте. Бер падишаһның ишегенә барды. Салам Торхан падишаһка алтын үлчәргә кирәк дип, падишаһдан подаука сорап алды. Кайдан булса да алтын вә көмеш кисәкләре табып, подаука читенә кыстыргалап, янә падишаһка илтеп бирде. Падишаһдан янә сорап алды, янә алтын кисәкләре кыстырып падишаһка илтеп бирде. Өч мәртәбә болай кыйлды. Ахыры бу төлке беркөн падишаһ янына керде, әйтте:

— И падишаһ җиһан, дустым Салам Торхан падишаһка шәригате Мөхәммәдия үзрә кызыңны биргәйсең! — диде. Вә һәм Салам Торхан тарафыннан мәһәр тәкабеленә[1] биш кара айгыр, ике йөз салам шәһәре бирмәкче булып, падишаһ кызын килеште. Аннан соң төлке Салам Торхан янына кайтты: «И дустым, падишаһ кызын килештем»,— диде. Салам Торхан моны ишеткәч, хәйран вә сәргәрдан булды[2]:

— Ялангач тәнем белән мин ничек итеп падишаһ кызы янына бараем? — диде.

Төлке әйтте:

— Әйдә, кайгырма бер дә, хәйлә кирәк,— диде. Салам Торханны алып китте. Бер тишек көймәгә утыртып, дәрьяга атып җибәрде. Үзе иске-поскы чикмән кисәкләре вә чыбыркылар табып, су буендагы талларга эләктерде вә яр якасыннан: «Дад, дад![3] Салам Торхан падишаһ суга акты, ярдәмгә килегез!» — дип кычкырып барды. Падишаһка барып хәбәр бирде:

— Киявең харап булды, һәммә җиһазлары белән суга акты. Тиз кешеләреңне җибәр! — диде.

Аннан соң падишаһның кешеләре килеп, Салам Торханны судан тартып чыгарып, падишаһ йортына алып килделәр. Кияү итеп, һәйбәт күлмәк-ыштан вә яхшы киемнәр кидереп, югары мендереп утырттылар. Әмма Салам Торхан, һичкая карамаенча, фәкать киеменә генә карап торыр иде. Чөнки гомерендә өстенә кием кигәне юк иде. Падишаһ әйтте: «Моның кием кигәне юк ла, ахры, өстенә генә карап торадыр ла»,— диде. Төлке әйтте: «Яхшырак кием кидереп карагыз, бәлки, киемне яратмый торгандыр»,— диде. Һәм бер аулакта Салам Торханга әйтте: «Син алай киемеңә карап торма, алай килешмәс»,— диде.

---

[1] Тәкабеленә — бәрабәренә.
[2] Сәргәрдан булды — аптырады, башы әйләнде.
[3] Дад — ярдәм сорап чакыру.

Шул рәвешчә, саламда тереклек кыйлып торган адәм бер падишаһка кияү булды. Әмма бик яхшы тереклек кыйлалар.

Бүген бардым, кичә кайттым. Бик сыйладылар, казык башына утырып, чәй эчтем. Ләкин һаман үзеннән салам исе килеп тора.

## Төлке

Янә бер кеше бар иде. Балык тотарга барды. Балык тотып кайткан чакта, юлда бер төлке очрады. Ул төлкене ничек булса да тотып, күшиленә балыклар катына салды. Төлке килә-килә күшилне тиште, балыкларны барын да күшилдән берәм-берәм юл буенча төшереп бетерде. Үзе дә күшил тишегеннән төшеп калды. Төлке юлдагы балыкларның һәммәсен җыеп алды. Бер печән кибәне башына менеп, балыкны ашый башлады. Бер аю килде дә төлке катына менә башлады. Төлке аюны яңагына чабып төшерде.

Аю әйтте:

— Төлке дус, ичмаса, бер генә кылчыгын бир,— диде.

Аюга төлке бирмәде.

Аю әйтте:

— Төлке дус, бу балыкны каян тоттың? — диде.

Төлке әйтте:

— Әнә шул бәкедән тоттым,— диде.

— Ничек тоттың?

Төлке әйтте:

— Койрыгыма козау бәйләп, бәкегә тыгып тордым да, балыклар үзләре козауга кереп тулдылар,— диде.

Алай дигәч, аю да, койрыгына козау бәйләп, шул бәкегә китте. Төлке кычкырды: «Аю дус, козавыңны бәкегә җибәр дә шытыр-шытыр иткәнче көтеп тор,— дип.— Шытыр-шытыр итсә, балык кергән булыр»,— диде. Аю шытыр-шытыр иткәнче торды. Бер хатын суга килде. Ул хатынны күргәч, аю тора башлады. Ул арада аюның койрыгы шытырдап катты. Ул хатын моны көянтә белән кыйный башлады. Аюның койрыгы шарт итеп өзелде дә качып китте.

Баягы кеше тагы өенә кайтып җитүе белән хатынына кычкырды, күшилен карамастан: «Хатын, төлке тоттым, иске төлкене ат утка!» — диде. Яна торган мич бар иде. Хатын иске төлкене алды да утка атты. Аннан соң күшил белән балыкны, төлкене өйгә алып керик дип карасалар, алардан җилләр искән. Ни төлке юк, ни балык юк. Ул арада иске төлке дә янып бетте.

Шуның өчен әйткәннәр: «Булыр-булмаска ышанып, кулыңдагыдан аерылма». Бу сүз халык арасында бер мәсәл булып калды. «Өр!» — дигәч, әйтәләр: «Хатын, иске төлкене утка ат!»

# Аю берлән төлке*

Янә аю берлән төлке дус булып шалкан сачтеләр. Шалкан өлгергәч, шалканны кисә башлаганда, төлке аюга әйтептер: «Үзле үземезгә куйыйк шалканны,— диептер.— Син кайсын аласың?» — диептер. Аю әйтептер: «Ул җирдә торган белән мин нишлим, миңа өстә торганы кирәк»,— диептер.

Әүвәл өстән яфрагын аю кисеп алыптыр, төлкегә шалканы калыптыр. Болар, шалкан кискәч, берен-бере кунакка чакырышыплар. Шунда аю төлкегә әйтептер: «И төлке дус, син мине алдадың бугай. Инде шалкан сачмимез, богдай сачәмез»,— диептер.

Богдай сачепләр. Тагын да богдай өлгергәч, ура башлаганда, төлке аюга әйтептер: «Юк, мин бергә салмыйм, син кайсын аласың?» — диептер. Аю әйтептер төлкегә: «Син мине элек тә алдадың. Юк инде, мин бу юлы җирдәгесен алам»,— диептер. Тагын ул төлке богдай урып алыптыр, тамыры аюга калыптыр.

Моннан болай дуслыктан аерылыптырлар.

# Мәче берлән аю

Бер аю зур имән башына бал куептыр. Аны мәче сизептер дә имән башына менептер. Мәче бал ашап торган чакта, аю килептер дә: «Монда ни эшлисең?» — диептер. Мәче әйтептер: «Менә аюларны, бүреләрне себер җибәрергә язу язамын, мин — Мәскәүский писер»,— диептер. Аю бу сүзләрне ишеткәч, артына әйләнеп, имән башыннан төшептер дә качыптыр. Мәче дә тагы үзе бер якка таба аюдан куркып качыптыр.

# Әләкче

Бервакыт арысланга сырхау тиде. Барча ерткыч хайваннар арысланның хәлен сорарга килделәр. Ләкин төлке килмәгән иде. Бүре барып, арысланга төлкене яманлады. Арыслан бүрегә әйтте: «Төлке килсә, син миңа хәбәр бир,— диде. Ул арада төлке килеп җитте. Бүре тиз үк арысланга барып әйтте. Икенче ерткыч хайваннар моны төлкегә белдерделәр: «Бүре сине арысланга барып яманлады»,— диделәр. Арыслан төлкене чакырып китерде, әйтте:

* Әлеге һәм киләсе әкияттә Каюм Насыйри үзенчәлекле фигыль формасы кулланып яза (*диептер, әйтептер* һ.б.).

— Син кайда идең? Күренмәдең,— диде.

Төлке әйтте:

— Синең авырганыңны ишетеп, сиңа дару эзләргә бардым,— диде.

Арыслан әйтте:

— Соң ничек, дару таптыңмы? — диде.

Төлке әйтте:

— Һичбер дару табып китермәдем. Ләкин шуны әйттеләр: бүренең арт аягындагы сеңерен алып, шул бүре сеңере белән дару итсәң, шаять, терелер идең,— диде.

Арыслан бүрене тотып, арт аягын ярды да сеңерен өзеп алды. Бүренең аягы канап китте. Төлке кычкырды: «Кая барасың, кызыл ыштан?» — диде.

## Төлке белән әтәч

Төлке бервакытны агач яныннан үткәндә күрде: агач башында бер әтәч утыра. Әтәчкә әйтте:

— Әй дус, агач башыннан төшмисеңме? Җәмәгать булып бергә намаз укыр идек,— диде.

Әтәч әйтте:

— Әле хәзердә имам агач артында йоклап ята, имамны уят,— диде.

Төлке карады, күрде: агач артында бер эт ята. Куркып, качып китә башлады.

Әтәч әйтте:

— Кая барасың, җәмәгать булып намаз укырбыз,— диде.

Төлке әйтте:

— Тукта, сабыр ит, тәһарәтем бозылды, тәһарәт яңартып килим,— дип, койрыгын күтәреп сызды.

## Шүрәле

Шүрәлегә бер кеше очраган икән. Шүрәле әйтә икән: «Кил, икәү кети уйныйк»,— дип. Янә шүрәле әйтә икән: «Син ни атлы?» — дип. Кеше әйтә икән: «Былтыр,— дип,— минем атым». Кеше әйтә икән: «Тушан ярыкка кагыл»,— дип. Капты. Кеше качты. Шүрәле кычкырды. Шүрәлеләр күп килделәр. Шүрәлеләр әйтте: «Кем кысты кулыңны?» — диде. Шүрәле әйтте: «Былтыр кысты»,— дип. Бәс, шүрәлеләр әйтте: «Былтырдан бирле нишләп тордың?» — дип. Кыйнап үтерделәр. Шүрәлеләр һәм китте.

# Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан — Гөлрох һәм Камәрҗан әкиятләре*

## Чин падишаһының кызы Гөлрох белән Хаварзәм шаһ углы Камәрҗанның маҗарасыдыр

Борын заманда Исфаһан шәһәрендә бер патша бар иде — Хаварзәм шаһ дип атыйлар иде. Аның матурлык, мөлаемлылык, сөйкемлелектә хәтта бөтен җир йөзендә тиңдәше күренмәгән сылу һәм акыллы бер углы бар иде, исемен Камәрҗан дип атыйлар иде.

Шушы шаһзадә унбиш-уналты яшьләргә җитеп балигъ булмастан ук, атасы Хаварзәм шаһ аны өйләндерү уена төшә. Ул үзенең бу уен хатынына да һәм вәзирләренә дә сөйли. Алар моның киңәшен хуплыйлар, теләген мәслихәт күрәләр. Шуннан соң Хаварзәм шаһ углын үз каршына чакырып ала да:

— Кешеләр, үзләренең нәселләрен дәвам иттерү өчен өйләнергә, гаилә төзергә тиешләр. Мин дә сине өйләндермәкче буламын. Ышанам ки, минем теләгемне читкә какмассың. Инде син миңа үзеңнең кайсы катлаудан өйләнергә теләвеңне әйтеп бирәсең: дәрәҗәле кешеләр гаиләсеннәнме, байлар нәселеннәнме, җария-колларданмы яки иреклеләрдәнме? Әлбәттә, син миңа үзеңнең теләгәнеңне туры әйтергә тиешлесең,— диде.

Камәрҗан — әле балалыктан да чыгып җитмәгән бер үсмер — атасының бу сүзләрен ишетеп, бераз вакыт аптырап калды. Ул, берничә минут уйланып, сүзсез торганнан соң:

— Әй кадерле атачыгым, мин гаилә төземәм дигән карарга килгән идем. Әгәр дә сез миңа өйләнүне шарт итеп куясыз икән, минем бу йорттан башала качып китүем дә бик ихтимал,— дип, шактый кыю җавап кайтарды.

Хаварзәм шаһ, углының шушындый кискен җавабын ишеткәч, дөрестән дә моның шундый эш эшләп куюы мөмкин, дип, сөйләшүне артык сузмады, мәзәк сүзләр белән углын үз бүлмәсенә җибәрде.

Шуннан соң шаһ, вәзирләрен тагын җыеп, углының каршылык күрсәтүе турында сөйләп бирде һәм бу вакыйгага карата киңәшләр сорады. Вәзирләре төрлесе төрле киңәшләр бирделәр. Белдеклерәк саналган бер вәзир: «Камәрҗанның шаһ бо-

* К.Насыйриның госманлы теленнән тәрҗемә иткән бу әсәре хәзерге татар әдәби теленә якынайтып һәм бераз җиңеләйтеп бирелә.

ерыгына шундый дорфалык күрсәтүе, баш тартуы аның бер дә җәза күрми үсүеннән килә,— дип юрады һәм: — шаһ углына үзенең хакимлек көчен сиздерергә тиеш»,— дигән тәкъдимне кертте. Патшага вәзирнең бу тәкъдиме ошап калды.

Камәрҗанны, ата сүзен тыңламаган өчен, берничә көнгә генә булса да хибесханәгә[1] салырга булдылар. Шул көннән үк аны махсус бер хибесханәгә кертеп тә утырттылар, һәм ул, хибесханәдә утыруны өйләнүдән җиңелрәк санап, көннәрен шат, күңелле итеп уздыра бирде.

Шушы хибесханәдән ерак та түгел бер иске, ташландык кое бар иде. Ул коега карт бер пәри кереп урнашкан иде. Көннәрдән бер көнне коедан чыгып, җир өстен тамаша кылганда, ул пәри хибесханәнең бер бүлмәсе тәрәзәсеннән урамга балкып торган якты ут шәүләсе күрде һәм, монда кем яши икән дип, шушы бүлмәгә юл тотты. Анда барып керүгә, Камәрҗанны күрде, шул минутта аңа гашыйк та булды. Бу вакыт шаһзадә йоклап ята иде, комсыз пәри түзә алмады, аның нур балкып торган ике бит алмасыннан үбеп тә алды. Камәрҗан моны сизмәде. Пәри шуннан ук чыгып та китте.

Камәрҗан яныннан чыккан пәри, дөньяда ниләр бар икән дип, күк йөзендә очып, тамашага китте. Озакламый ул үзенә күптәннән бирле дошманлык саклап йөргән икенче пәрине очратты да аңа һөҗүм итте. Ул пәри, моңа ялынып:

— Әфәндем, әгәр дә мине һәлак итми калдырсаң, мин сиңа лаек һәм дөньяда тиңе булмаган бер гүзәлне табып бирүне өстемә алыр идем,— диде.

— Яхшы,— диде бу пәри,— сөйлә, ул матур кайда?

— Берничә көннәр генә моннан элек Чин[2] шәһәренә барып чыккан идем. Шушы Чин дәүләтенең патшасы Шөҗаг ханның бик матур бер кызы бар икән. Ул кыз шундый гүзәл, шундый назлы, аңа тиңләштерерлек кыз әле дөньяга килгәне юк. Күрсәгез, сез дә акылыгыздан язачаксыз.

Бу пәри бераз көлемсерәп торды.

— Менә мин үзем бүген шундый бер матур адәм баласын күрдем, ичмасам, матур дисәң дә була! Ул син мактаган кыз мин күргән адәм янында чүп булып калачак,— дип, теге пәрине мыскыллап алды.

Шуннан бу ике пәри үзара сүз көрәштерергә керешеп киттеләр, һәр икесе дә үзләренекен мактады.

---

[1] Хибесханә — төрмә.
[2] Чин — Кытай.

Ниһаять, бер сүзгә килеп, теге Чин патшасының кызын хибестә ята торган шаһзадә янына хәзер үк алып килергә дә матурлыкларын бер-беренә тиңләштереп карарга булдылар.

Әгәр дә ул Чин кызы Камәрҗаннан матуррак булып чыкса, беренче пәри икенче пәрине гафу итәргә һәм арадагы дошманлыкны ташларга вәгъдә бирде.

Шуннан соң икенче пәри Чин иленә очып китте. Ярты сәгать вакыт үткәрмәстән, Шөҗаг шаһның кызын китереп тә җиткерде. Ике пәри кызны күтәреп керделәр дә йоклап яткан Камәрҗан янына түшәккә салдылар. Күрделәр ки, бу шаһ кызы белән шаһзадә Камәрҗан матурлык, сылулык, күркәмлелектә бер-беренә шулчаклы охшашлар, әгәр дә өсләренә кигән киемнәре төрле булмаса, боларның кайсысы Камәрҗан, кайсысы Гөлрох икәнлеген хәтта пәриләр үзләре дә аера алмаслар иде.

Пәриләр, бу хәлне күреп, иң элек, араларында дәвам иткән дошманлыкны ташлап, килешү вәгъдәсе бирештеләр. Аннан соң, тукта әле, бу ике гүзәлне уяу килеш бер-беренә күрсәтик, ахыры кая барып чыгар икән, дип, бер тәҗрибә ясарга булдылар. Өлкән пәри Камәрҗанны уятты. Шаһзадә, күзен ачып җибәрүгә, янында матурлыгы һәркемне хәйран калдырырлык сөйкемле бер кызның йоклап ятканын күрде һәм шул минутта ук, сабырлыгын югалтып, моңа гашыйк та булды. Шунда ул үз-үзенә: «Алай икән, атам-анам миңа кыз ярәшү, мине өйләнергә кызыктыру өчен бу эшне эшләгәннәр икән...» — дип уйлады. Кызның матурлыгы егетне шулчаклы аралашдырды ки, ул шунда ук: «Тукта, ни булса булыр, әмма мин бу кызны үземә хатынлыкка кабул итим»,— дип, кызны уяту теләге белән йөзеннән, муеныннан һәм авызыннан үпте. Ләкин кыз уянмады. «Ай-һай, бу гүзәл каты йоклаучан икән... Ходай кушса, иртән йокысы туйгач, үзе белән сөйләшермен һәм хатынлыкка кабул иткәнлегемне әйтермен. Шушы вәгъдәмнең билгесе булсын»,— дип, үз бармагындагы балдакны кызга кидерде һәм аның йөзеген салдырып үзенә киде.

Шул арада теге пәри, бер әфсүн өреп, шаһзадәне авыр йокыга салды.

Шуннан соң пәриләр Чин патшасының кызы Гөлрохны уяттылар. Ул, күзен ачып, үзен бер ят җирдә, ят кеше белән бер түшәктә күреп хәйранга калды, һушын җыеп, янында йоклап яткан шаһзадәгә карау белән, түземен югалтып, гашыйк булды һәм, аны уятмакчы булып, кулыннан тартты. Шул вакыт үзенең йөзеге шаһзадә кулына, аның балдагы исә үз кулына кидерелгән икәнен күрде. «Монда бер хикмәт булырга тиеш. Әм-

ма бу егетнең йокысы бик каты икән, сәбәбе нидер»,— дип уйланып торганда, кызны да пәриләр тирән йокыга талдырдылар һәм Чин иленә, атасының йортына илтеп тә куйдылар.

Иртәгесен Камәрҗан шаһзадә йокысыннан уянды, төнлә белән булып үткән вакыйгаларны күз алдыннан уздыра башлады. Әйләнә-тирәсен тикшереп карады, ләкин кызны тапмады, яны буш иде. Бармагында исә үзенең балдагы урынына ят бер йөзек күрде. Шуннан соң төнге вакыйганың ниндидер хыялый төш кенә түгел, бәлки чынлык булганлыгына ышанды. Кулындагы йөзекнең бик кыйммәтле икәнлеген белгәч, «ул кыз нинди дә булса бер патша баласы булса кирәк» дигән фикергә килде.

Шуннан Камәрҗан, хибесханә хезмәтчеләрен чакырып, шушы вакыйга турында сорашты. Алар үзләренең бу эшне белмәгән, сизмәгәнлекләрен әйттеләр. Шаһзадә бу турыда атасына да хәбәр иттерде. Атасы килде, ниләр һәм ничек булганлыгы турында сорашты. Углы барын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде һәм, таныклык итеп, кулындагы йөзекне күрсәтте. Хаварзәм шаһ углы әйткәннәрнең барысына да ышанды һәм, кичә килгән кызның кем, кайда икәнлеген белү өчен, дәүләтендәге олыларны киңәшкә чакырды. Озак һәм күп сөйләштеләр, киңәштеләр, ләкин ул кызның кем икәнен берәү дә әйтә алмады.

Шаһзадәнең гыйшык уты көннән-көн көчәя барды. Ул, дәртенә чыдый алмастан, авыруга сабышты, йөзен зәгъфран сарысы каплады. Углының бу хәлгә килүе, билгеле, патшага зур курку салды.

Ярый, патша углы шулай тора бирсен, без килик Чин патшасының кызы Гөлрох хәленә.

Ул да, әлеге төштә күргәндәй генә хәтердә калган кичәдәге очрашудан бирле, үзенә таныш булмаган бер егеткә төшкән гыйшык утында яна, көя, хәтта үз-үзен һәлак итү куркынычы алдына килеп җиткән иде.

Кызының шулай булуын күреп, Чин шаһы зур киңәшмә җыйды, вәзирләре, ил олылары белән мәслихәтләште. Уйлый торгач, ул:

— Кем дә кем минем баламны шушы авыруыннан коткарып, исәнлеген кайтарса, кызым Гөлрохны аның үзенә бирәчәкмен һәм илемнең дә яртысын аңар бүләк итәчәкмен,— дип яр салдырды.

Шаһның бу вәгъдәсе бик күп кешеләрнең күзләрен кыздырды. «Патша кияве була алмаммы» дигән теләк белән хәкимнәр, табиблар һәм төрле сихерчеләр килеп, Гөлрохны үзләренчә дарулап, им-том кылып карадылар, ләкин тырышулары бушка чыкты, кызның бертөрле дә авыруы табылмады. Ахыр

чиктә: «Бу кыз бик каты гыйшык дәртенә дучар булган икән»,— дигән карарга килделәр. Кыз исә үзенең гыйшык утында януын һаман да инкяр итте.

Гөлрохның Саба исемле бер карендәше бар иде. Ул, бик күп еллар буена гыйлем эстәп, ничәмә илләрне сәяхәт итеп, шушы көннәрдә генә кайтып керде. Саба сеңлесенең мондый авыр хәлгә төшүенә ни сәбәп булганын сорашты. Гөлрох аңа бу араларда башыннан үткәннәрне, хибесханәдәге егет белән булган вакыйганы сөйләп бирде.

Саба, серне төшенгәч:

— Сеңлем, кайгырма, бу дәртеңнең дәвасы минем кулда. Мин сине бу бәладән коткарачакмын. Син беләсең, сәяхәт итү — минем һөнәрем, җиде икълимне[1] гизеп әйләнү минем аңымны арттыра. Мин, тагын чыгып китеп, барлык шәһәрләрне янә бер кат йөреп чыгачакмын һәм әнә шул син сөйләп биргән төстәге егет турында хәбәр китерәчәкмен,— дип, сеңлесенә вәгъдә бирде.

Шуннан Саба юл кирәк-яракларын алды да сәфәргә чыкты. Ай китте, ел китте, ничәмә авыл һәм шәһәрләрне үтеп, ике ел тәүлеге тулганда, безнең Саба Фарси иле чигенә урнашкан Бәһманабад шәһәренә килеп җитте. Бу шәһәрнең нәкъ урта бер җаена салынган бик зур кәрвансарай бар иде. Саба да, үзе шикелле ерак илләрдән килгән мөсафирларны очратып, дөнья хәлләрен сораштырырга мөмкинлек булган дип, шушы кәрвансарайга җирләште.

Бер көн, бер атна үтте. Саба, сөйләшә-таныша торгач, бу шәһәрнең шаһы Хаварзәм исемле, имеш, һәм аның бердәнбер углына фәлән булган, имеш, төгән булган, имеш, төшендә бер кызны күргән, имеш тә, шуңа гашыйк булган, имеш, ул күргән кыз ниндидер бер патшаның бердәнбер кызы, имеш, ул кыз шаһзадә янына әфсүн белән китерелгән булган икән... кебек сүзләр ишетте, хәбәрләр җыйды. Шуннан моңарда: «Тукта әле, боларның шаһзадәләре миңа кирәкле кеше булу ихтималы бар ич»,— дигән уй туды. Ул уйлап торды да Хаварзәм шаһның олы вәзирләреннән берсе белән күрешеп сөйләшү юлларын табарга кереште. Үзе белән алып чыккан кыйммәтле әйберләреннән берсен бүләк итәргә һәм күргән-белгәннәрен матурлап сөйләп бирергә әзерләнеп, көннәрдән бер көнне Саба Хаварзәм шаһның баш вәзиренә юнәлде. Вәзир моны ачык кына

[1] Икълим — элекке заманда җир йөзен җиде өлешкә бүленгән дип уйлаганнар һәм һәрбер өлешен «икълим» дип атаганнар.

кабул итте. Болар сөйләштеләр, таныштылар һәм якын дусларга да әверелделәр.

Менә шушы көннәрдә, күңел ачу, кәеф-сафа кылу теләге белән Хаварзәм шаһ үз сараенда бер мәҗлес, тамаша, уенкөлке оештырырга боерды. Шаһның тәхет сараен бизәделәр, ашлар-сулар әзерләделәр, илдәге уенчы, көлкече, чичәннәрнең барысын да чакырдылар.

Менә табын ачылды. Хаварзәм шаһның кәефен табу башланды. Чичәннәр, мәзәкче, әкиятчеләр, тапкыр сүз, матур хикәяләр сөйләп, шаһның күңелен хушландырдылар, тамашачыларны көлдерделәр.

Шул вакыт өлкән вәзир, шаһка баш иеп:

— Әй минем иям, шаһлар шаһы Хаварзәм шаһ, гомерегез озын булсын, дәүләтегез мул, җаныгыз тыныч булсын. Рөхсәт итсәгез, минем сезгә бер сүзем бар иде,— дип мөрәҗәгать итте.

— Хуш, сөйләгез, тыңлыйм,— диде Хаварзәм шаһ вәзиренә.

— Безнең шәһәребезгә,— дип сөйләп китте өлкән вәзир,— ерак илләрдән бер мөсафир килеп төшмеш. Күп йөргән, күп күргән һәм күпне белгән кеше икән. Үзе сылу, акылы тирән, теле чичән, мәҗлесе хуш адәмгә охшый. Шушы мөсафирны чакырсак, шаһзадә Камәрҗанның дәртенә дәва, төшенке күңеленә дәрман булмасмы икән? Әгәр дә минем бу киңәшем шаһзадәгә тузан чаклы гына җиңеллек китерүгә сәбәпче була икән, мин үземне таудай бәхеткә ирешкән санаячакмын.

— Андый мөсафирларның файдалылары да була. Хәзер үк ул адәм минем сараема чакырылсын. Углым шаһзадә белән аны очраштыруны сиңа тапшырдым, минем ышанычлы вәзирем,— диде Хаварзәм шаһ.

Шул ук минутта, җигүле аргамаклар йөгертеп, Саба-мөсафирны патша сараена алып килделәр. Өлкән вәзир аны каршы алды һәм Камәрҗан шаһзадәнең тынгылык бүлмәсенә алып керде. Саба, бүлмәгә керү белән, үзенең сеңлесе Гөлрохка нәкъ бер тамчы судай охшаш егетне күреп гаҗәпкә калды, һәм шунда ук «эзләгән кешемне таптым булса кирәк» дигән уй аның аңын биләде.

— Бу егет безнең хөрмәтле шаһзадәбез җәнаблары Камәрҗан була,— дип таныштырды өлкән вәзир.

— Җиһан күрке, җаннар җаны, ничәмә мең мәгъшукаларның ардаклысы[1] Камәрҗан шаһзадәне үз күзем белән күрү

---

[1] Ардаклысы — сөеклесе мәгънәсендә.

бәхетенә ирешә алуым белән горурланырга хаклымын. Җаным сезгә бүләк булсын. Сезнең бер елмаюыгызга каршы мең җан корбан итәргә һәм әзермен,— дип, Саба Камәрҗан алдында баш иде. Ләкин шаһзададән бер генә сүз дә чыкмады. «Бу егет белән, икәүдән-икәү калып, яшерен серне ачып сөйләшү файдалырак булачак» дигән уй Сабаның башына килде, һәм ул, түбәнчелек күрсәтеп:

— Мөмкин булмасмы безне шаһзадә белән икебезне генә шушы бүлмәдә бераз вакытка калдырып торырга? Бәлки, миңа аңардагы сырхауның серен төшенү мөмкин булыр иде,— диде Саба өлкән вәзиргә.

— Баш өсте, сөйләшегез, мин чыгам, сүзләрегез берексен, серләрегез килешсен,— дип, вәзир сарайның мәҗлес бүлеменә юнәлде.

Болар икәү генә калдылар. Саба җайлап кына сүзгә керешТе һәм, уңаен китереп:

— Әфәндем,— диде, — сезнең дәртегезгә дәва булачак бер хәбәрем бар. Шуны ирештерергә рөхсәт итсәгез, минем теләгемә зур илтифатыгыздан булыр иде.

Камәрҗан, тирән уйлар, каты хәсрәт авырлыгы белән йомылып барган күзләрен ачып, Сабага карады да:

— Андый сүзегез бар икән, сөйләп карагыз, тыңлыйк,— диде һәм үз янәшәсеннән аңар урын күрсәтте.

Саба күрсәтелгән урынга җайлашты һәм сүзен башлады:

— Әфәндем, бармагыгызны зиннәтләгән кыйммәтле йөзек Хаварзәм шаһның үз хәзинәсеннән чыкканмы, әллә булмаса, аны сезгә икенче берәү бүләк иттеме? — дип сорады.

Сабаның соравы шаһзадәгә ниндидер хушлык, күңеленә җиңеллек бөркегәндәй тоелды. Ул, үзен авыр йокыдан айнып киткән бер хәлдә сизеп:

— Әйт, зинһар, күпне күргән мөсафир, син бу йөзекнең хуҗасын беләсеңме? Әйт тизрәк, коткар мине үлемнән, тынычландыр минем күбәләктәй газиз җанымны! — диде.

— Бу йөзекнең төп хуҗасы минем сеңлем, Чин шаһының кызы Гөлрох булыр,— дигәч тә, Камәрҗан урыныннан сикереп торды һәм килеп Сабаның маңгаеннан үпте.

— Сөйлә, барын да сөйлә. Миңа ни шатлыклы тормыш, дәртемә дәрман китергәнсең дип сизәм. Сөйлә, минем йөрәгемне парә-парә телгән серләрне белүче Саба дустым,— дип, мөсафирның алдына тезләнде.

— Мин,— дип сүз башлады Саба,— сезне эзләп табу нияте белән сәфәргә чыгып, инде менә өч ел буена тоташ йөрдем, ничә-

мә ил һәм шәһәрләрне үттем, меңнәрчә гашыйкларны очраттым, ахыр чиктә менә бүген максатыма ирештем. Шатланам ки, минем күргән мәшәкатьләрем җилгә китмәделәр, кичергән җәфаларым нәтиҗәсез калмадылар. Инде минем изге бурычым — сез ике гашыйкны кавыштыру. Монысын һәм булдыра алачакмын.

— Димәк, сез минем мәгъшукамның туганы буласыз. Аһ, нинди зур куаныч, нинди олы бәхет! Бу йөзекнең иясе — сезнең туганыгыз — бүген нихәлдә? Әйтегез, әфәндем, сөйләгез, минем табибым һәм бәхет йолдызымны табып бирүче юлдашым,— дип, сабырсызлык белән Сабага мөрәҗәгать итте.

— Сезнең мәхәббәт йолдызыгыз — минем туганым Гөлрох та бүгенге көнне гыйшык утына бәгъре көеп, җаны телгәләнеп, уф орып, ялкын сулап ятмактадыр. Аның нечкә бармагын бизәгән балдагыгыз исә һаман да шулай балкып тормактадыр...

Сабаның бу сүзләре Камәрҗанга тынычлык та һәм борчу да салдылар.

— Ай ул Гөлрох! — дип кычкырды Камәрҗан һәм,— бүгеннән соң минем телемдә тик бер генә сүз — «Гөлрох» кына булачак,— дип өстәде.

Бу ике дус тиз арада Гөлрох янына барып җитү теләге белән моннан ничек ычкынырга мөмкин булачагы турында озак киңәштеләр, хәйләләр эзләделәр.

Җае табылды, Камәрҗан, атасы каршына барып:

— Мәрхәмәтле атам, гомерең озын булсын. Минем хәлем көннән-көн яхшырып бара. Син миңа берничә көннәр буена дала һавасы иснәп, уен-көлке белән сунарга йөреп кайтырга рөхсәт ит,— дип үтенде.

Хаварзәм шаһ, углының сәламәтләнүенә куанып:

— Ярый, углым, дала һавасы иснәп кайтуның зарары булмас. Барыгыз, яланны тамаша кылып, ау аулап, кош чөйдереп кайтыгыз. Хезмәтегезгә нукирлар әзер булыр,— дип, углының үтенечен кабул итте.

Шунда ук Камәрҗан шаһзадә мөсафир Саба белән икәүләп, хезмәтләренә берничә кеше ияртеп, далага чыгып киттеләр. Өч көнлек юлны үткәч, үзләре белән алып чыккан кешеләрне адаштырып калдырып, Камәрҗан һәм Саба туры Чин мәмләкәтенә — Гөлрох янына юл тоттылар.

Берничә тәүлектән соң теге адашып калган хезмәтчеләр, Хаварзәм шаһка кайтып:

— Шаһзадә белән аның кунагы Сабаны югалттык,— дип хәбәр бирделәр, күз яшьләрен түктеләр.

Шаһның моңа ачуы кабарды һәм күңеленә әллә ни төрле куркынычлы уйлар да төште.

— Шул минутта меңләгән батырларым, гаскәрем далага чыксыннар һәм минем углым Камәрҗанны табып кайтарсыннар! — дип боерды.

Гаскәрләр һәм аучы-сунарчылар, йөгерек аргамакларга менеп, Камәрҗаннар киткән дала, яланнар, елга һәм күлләрнең аркылысын-буен эзәрләп чыктылар. Болар басмаган җир, тикшермәгән почмак калмады, тик таба алмадылар, кайгырышып, шаһ каршына буш кул белән кайтып керделәр.

Шул рәвешчә, Хаварзәм шаһ, кайгы-хәсрәт утында янып, сараенда утыра торсын, без шаһзадә һәм Саба мөсафирлар артыннан барып карыйк.

Камәрҗан белән Саба, хезмәткәрләрен адаштырып калдырган көннән алып, тауны тауга, ташны ташка ора-ора, нәкъ туксан көн тулды дигәндә, Чин шәһәренең капкасы төбенә килеп җиттеләр. Алар, шәһәргә кергәч, туп-туры патша сараена, Гөлрох янына бармадылар, бәлки иң бай кәрвансарайларның берсенә урнаштылар. Боларның теләкләре: Камәрҗан шаһзадәнең гыйшык дәрте, юл кыенлыклары белән сулган йөзен, алҗыган гәүдәсен ял иттерү иде.

Ул, тәүлек буена һичкая чыкмый, һичкемгә күренми ял иткәннән соң, Сабаның өйрәтүе буенча, Камәрҗан Чин патшасының сараена үзе генә барырга булды. Моның өчен кирәкле әйберләр дә әзерләнде.

Камәрҗан зур бер хәким-философ сурәтендә патша сарае капусына[1] барып туктады да үзенең бер белгеч, доктор һәм Гөлрохны дәвалау теләге белән килгән кеше икәнлеген сөйләп бирде. Капучылар докторның теләген патшага җиткерделәр.

Патша:

— Китерегез ул кешене минем каршыма! — дип боерды.

Камәрҗанны патша каршына керттеләр. Ул, патшалар, шаһзадәләргә хас әдәп һәм гадәтләрне җиренә җиткереп, үзенең бер доктор булуы һәм Гөлрохны дәвалау теләге белән килгәнлеге турында сөйләп бирде.

Патша, докторның мөлаем йөзе, мәгънәле сүзе, татлы теле һәм балкып торган матурлыгына исе китеп, бераз эндәшми торганнан соң:

— Минем кызым Гөлрохның авыруы тән авыруы түгел,

---

[1] Капусына — капкасына.

бәлки көчле хыял, тирәннән дәртләнү аркасында килеп чыккан, яшьләргә хас булган бертөрле сырхаудан гыйбарәттер. Аны дәвалау теләге дә бушка чыгачактыр,— диде.

Камәрҗан аңар:

— Падишаһым, гомерегез озын булсын. Сүзегез тугры, кайбер сырхаулар дәвага бирелмәүчән булалар. Шулай да миңа үземдәге көчне сынап карарга рөхсәт итүегезне үтенеп сорар идем,— диде.

— Хәер,— диде патша,— доктор, табибларның кулыннан килүе дә мөмкин. Авыру янына кереп карарга сезгә рөхсәт итәм... Даялар, кунакны Гөлрох бүлмәсенә алып барыгыз...

— Рөхсәт итегез, падишаһым-солтаным, авыруны, үзен күрмәстән, янына да бармастан, сәламәтләндеримче? — дип, яңадан үтенде Камәрҗан.

Патша, хәйран калып:

— Ярый, карап карыйк, андый сәләтегез булса, күрсәтегез,— диде.

Камәрҗан эченә Гөлрохның йөзеге төрелеп салынган бер порошок кебек төргәкне чыгарды да, авыз эченнән генә нидер укыган булып, шуңа өч тапкыр өреп, даяга бирде һәм:

— Рәхим итеп, шушы даруны авыру кызыгызга илтеп тапшырсагыз икән,— диде.

Дая, даруны алу белән, Гөлрох бүлмәсенә йөгерде. Гөлрох, кәгазьне сүтеп җибәрүгә, үзенең йөзеген күреп, яткан җиреннән кинәт аякка басты. Аңы ачылып, җанына яңа бер рух өрелгәндәй бер хәл сизеп, дару төрелгән кәгазьгә күзе текәлеп калды. Анда болай язылган иде: «И минем барлык матур сыйфатлар белән бүләкләнгән Гөлрохым, теге төш кебек кенә булып хәтердә калган кичәдәге очрашу вакытында, мәхәббәтебезнең билгесе итеп, йөзекләребезне алыштырган идем. Ул чагында сез, фәрештәм, бик каты йокыда булганлыктан гына, сөйләшә һәм бер-беребезгә кавыша алмый калган идек. Мин, сезнең каршыгызга доктор сурәтендә килгән кеше, Хаварзәм шаһның улы Камәрҗан колыгыз булам. Әгәр дә мине үзегезгә бәндәлеккә кабул итәр булсагыз, балдагымны кайтарып бирәсездер!

Гүзәлем Гөлрох, үтерсәгез дә, тере калдырсагыз да, минем язмышым сезнең кулда. Сезнең гыйшкыгыз белән бәгъре көйгән Камәрҗан...»

Гөлрох, хатын укып бетерер-бетермәс үк:

— Доктор, доктор! Кайда ул доктор? Китерегез, тизрәк кертегез аны минем яныма! — ди-ди, ишеккә ташланган иде, кинәт шаһзадәне күрде һәм, оялу, тартыну, намуссыну кебек хәл-

ләрнең барысын да онытып, аны кулыннан җитәкләде дә үз бүлмәсенә алып керде.

Ике гашыйк, бүлмәнең түрендә тезгә-тез тераn утырган килеш, эч серләрен, мәхәббәт төеннәрен бер-беренә чишәргә керештеләр.

Шул вакыт Гөлрох даясын чакырып алды:

— Атама бар да минем дәртемә дәва табылганлыгыннан сөенеч ал,— дип боерды.

Патша, шундый зур сөенеч хәбәрне ишеткәч, тәхетеннән торып, кызы янына юнәлде. Күрде ки, кызы Гөлрох белән әлеге «доктор» бер-беренә күптәннән таныш, хәтта туганнар шикелле, бик тыныч һәм татлы гына серләшеп утыралар иде.

Патшаның килеп керүен күргәч, болар икесе дә сикерешеп тордылар һәм, аның аягына ятып, йөзләрен сөрттеләр. Ул да, шатлыгына сыеша алмый, тиз генә моннан чыгып китте һәм, тәхеткә утырып: «Бүгеннән минем дәүләтемдә бер атналык олуг бәйрәм игълан ителә. Олуг-кече, ир-хатын — барысы да минем кызымның туй сыена килсен, ашымны ашасын, шатлыгымны уртаклашсын»,— дигән боерыгын игълан итте.

Шул минут чаптарлар, ярчылар, илнең барлык почмакларына таралып, яр салдылар[1]. Бер атна буена бөтен ил бәйрәм торды. Бөтен шартлары китерелеп, зур туй-тамаша ясалды. Ике гашыйк морадларына ирештеләр.

Гөлрох белән Камәрҗан, өч ел буена кунак булып, Чин шаһы янында кәеф-сафа кичерделәр.

Көннәрдән бер көнне, Гөлрох белән киңәшкәннән соң, Камәрҗан атасы иленә — Исфаһан шәһәренә кайтып китәргә Чин шаһыннан рөхсәт сорады. Шаһ кияvенең теләгенә каршы килмәде, кайтырга рөхсәт бирде һәм юл кирәк-яракларын әзерләргә кушты.

Берничә көннән соң зур кәрван һәм аны саклау өчен билгеләнгән күп кенә гаскәр белән Чин патшасының кызы Гөлрох, кияве Камәрҗан, Исфаһан шәһәренә табан йөз тотып, юлга чыктылар.

Болар көн киттеләр, ай киттеләр һәм бик матур җайга барып җиттеләр. Бу җайның суы йомшак, һавасы мөлаем, күренеше гүзәл икән. Монда туктагач, мөсафирлар озын юлда күргән газапларын оныттылар, тәннәре җиңеләеп, рухлары хуш-

---

[1] Яр салдылар — патша, дәүләт эшләре турында халыкка хәбәр тараттылар.

ланып, күңелләре күтәрелеп китте. Гөлрох белән Камәрҗан киңәштеләр дә, чатырлар корып, шушы җайда бер-ике көн ял итәргә, тынарга булдылар.

Гөлрох, юл мәшәкатьләреннән йончыган тәнен ял иттермәк булып, өстендәге киемнәрен чишенеп, зиннәтләрен салып, чатыр эчендә йокыга талды. Шул вакыт Камәрҗан килеп керде һәм, Гөлрохның йоклавын күреп: «Тукта, борчымыйм, йокласын»,— дип чыгып барганда, күзе хатынының биленнән чишеп куйган кәмәренә[1] төште. «Ай-һай, бу кыйммәтле күренә»,— дип, ул шушы кәмәрне кулына алды. Күрде, бу кәмәр якут ташыннан ясалган икән. Җентекләбрәк караган иде, кәмәрнең бизәкләре арасында вак хәрефләрдән язылган язу кебек нәрсә дә бар икән. Камәрҗан бу язуга кызыкты һәм, яктыда укыйм әле дип, кәмәрне тоткан килеш чатырдан тышка чыкты. Бу вакыт һавада зур бер кош очып җир өстен күзәтә иде. Камәрҗан кулындагы кәмәр аңа ит кисәге төсле булып күренде бугай, ул кинәттән кыелып төште дә аның кулыннан кәмәрне алып качты.

Моңа Камәрҗан бик кәефсезләнде. «Гөлрох белсә, ачулануы бар»,— дип, атына атланды да әлеге кошны куа чапты. Кош, үч иткәндәй, бер җирдән икенчесенә куна-куна, һаман алга табан оча бирде. Камәрҗан аны куды да куды, хәтта кич җитеп, караңгылык төшкәнен дә сизмәде.

Кош күренмәс һәм кире әйләнеп кайтырга юл да табылмас хәлгә килде. Камәрҗан атыннан төште дә шундагы бер әрәмәлеккә кереп кич кунды.

Менә берзаман сызылып таң атты, җир өсте ачылып китте. Төрле кошлар сайрап әрәмәлекне нәфис аваз белән җанландырдылар. Камәрҗан: «Хәерле булсын, кайтып китим»,— дип, атын иярләде һәм, атланыйм дигәндә, томшыгына Гөлрохның кәмәрен эләктергән килеш кичәге кошның очып килгәнен күрде. «Бу ләгънәт әле монда икән. Мин аны тотмый калдыра алмыйм»,— диде дә Камәрҗан гайрәтләнеп атын тартты һәм кош артыннан чапты. Шулай куып бара-бара, Камәрҗан, инде көн кичегеп, кояш баер алдыннан гына, ниндидер бер шәһәргә җитте. Монда җиткәч, ул теге кошны тагын югалтты. Аны эзләп йөри торгач, бер бакча ишеге төбенә килеп туктады.

Анда аны бакчачы карт:

— Әйдә, углым, хуш киләсең. Кай җирләрдән киләсең һәм

[1] Кәмәренә — билбавына.

кая таба барасың? Рәхим ит, минем бакчамда кунак булыйк,— дип, үзенә алып керде.

Шунда ашап-эчеп утырганда, карт моңардан сорады:

— Сез, углым, ят җир кешесенә охшыйсыз. Бу җайга нинди язмыш ташлады? Бу шәһәрнең халкы бик явыз вандал халык ич, ничек һәлак итмәделәр үзеңне?

Камәрҗан, башыннан үткәннәрне сөйләп, картка үзен таныштырды.

Бакчачы карт, тыңлап торганнан соң:

— Углым, күренә ки, хатының, кәрваның һәм гаскәрләрең сине эзләячәкләр, таба алмагач, китәчәкләр. Бу җирдән исә сезнең шәһәрегезгә кәрван йөрми. Елга бер тапкыр, төрле товарлар төяп, көймә генә китә. Аның киткәненә әле бары утыз көн генә. Димәк, сезгә тагын нәкъ унбер ай көтәргә туры килә. Бу унбер айны сез минем менә шушы бакчамда уздырырсыз. Шарты шул: бу бакчадан читкә бер адым да атламаска. Юкса тотып алып үтерәчәкләр. Менә минем бакчам, шунда яши бир, тик аның тышкарысына гына чыкма, харап булырсың,— дип сөйләп бирде.

Камәрҗанның башка чарасы юк иде, бакчачы картның киңәшенә буйсынды, унбер айны шушында уздырырга булды.

Ярый, Камәрҗан шушында тора бирсен, без инде Гөлрох хәленә күз салыйк.

Гөлрох йокысыннан уянды. Кәмәренең үзе куеп калдырган урында юклыгын күрде һәм хәзинәсе эчендәге котыйчыкларының да кузгалган икәнен белде. «Язуларын укып карарга дип, Камәрҗан алган булса кирәк» дигән уй белән ул үз-үзен тынычландырды. Көн үтеп, кич булды, ләкин Камәрҗан да янына килеп чыкмады, әйберләре дә табылмадылар. Гөлрох эшне тикшерде һәм Камәрҗанның кичәдән бирле юкка чыккан булуын белде. Шунда ук утырып егълады, ләкин уф орып, башны ташка бәреп эш чыкмаячагы бик ачык иде. «Шаһзадәнең югалуы турында кәрван халкына белдерү файдалы булмаячак»,— диде үз-үзенә Гөлрох. Дөрестән дә шулай иде, чөнки: «Камәрҗан югалган»,— дигәч, кәрванчыларның таралып, тузылып китүләре һәм Гөлрохның ялгыз калып, тагын да әллә нинди бәлаләргә төшү ихтималы бар иде.

Гөлрох мондый юлны тотты: үзенең төстә һәм кыяфәттә Камәрҗанга охшаган булуыннан файдаланып, тиз генә аның киемнәрен киенде дә, ул булып, чатырдан чыкты һәм кәрванга шул минутта кузгалырга боерды. Үзенең иң якын даясына исә бу серне һичкемгә сөйләмәскә кушты.

Кәрван берничә көннәрдән соң Бәсра дигән шәһәргә килеп җитте. Бу шәһәрнең патшасы Ходаколы дигән бер карт иде. Ул патша белән Хаварзәм шаһ бик күптәннән бирле берберенә якын дуслар икән. Ходаколы Гөлрохны Хаварзәм шаһ углы Камәрҗан дип белеп, бик олылады, аның килү уңае белән олуг бәйрәм, сый-хөрмәт, зур тамашалар оештыртты. Кәрван монда чын-чыннан кунак булды.

Шул килеш кунак булып торганда, Ходаколы «Камәрҗанны» үз янына чакыртып алды да, эч серен ачып:

— И углым, мәгълүмдер ки, минем байлыгым, синең атаңныкы белән чагыштырганда, ничәмә тапкыр зурдыр. Синең атаң әле яшь кеше, мин исә гомеремнең ахыр көннәрен кичерәм, картлыгым җиткән. Нәселем дә юк, тик бер кызым гына бар. Кыскасы, син миңа килеш-килбәтең, сүзең-башың, акылың-фигылең белән бик ошадың. Мин сине үзем исән чакта кызыма кияү, дәүләтемә хуҗа, илемә патша итәргә теләр идем. Шунысын да алдан ук әйтәм ки, без инде бу мәсьәлә турында вәзирләр һәм бикләрем белән киңәш-уңаш ясадык, алдан ук сүз беркетеп куйдык. Әгәр дә ки син минем бу тәкъдимемне кабул итмәс булсаң, эшне көчләү юлы белән хәл итәчәкбез. Минем сүземне кабул итеп, безне шатландырсаңчы...

Гөлрох, үзенең ифрат кыен, хәтта мөмкинлектән тыш вакыйгага очраганына төшенеп:

— Шаһлар шаһы, патшалар патшасы Ходаколы хәзрәтләре, гомерегез озын, дәүләтегез мул, илегез тыныч, күңелегез шат булсын, мин сезнең тәкъдимегездән баш тартырга кыймаячакмын, әлбәттә. Шулай да миңа моның турында өч-дүрт көн уйларга рөхсәт итегез. Мәгълүм ки, өйләнү ул сөйләнү генә түгел. Алдан һәрьяклап үлчәми торып эшләнә торган җиңел эш түгел бу, — дип, карт патшага мөрәҗәгать итте.

Дөньяны алдап һәм өркетеп яшәгән карт патша, сөйкемсез елмаеп:

— Бик хуп, углым, өч көн дә, дүрт көн дә уйла, сиңа ирек; тик уең яхшы якка, без теләгән якка юнәлсен, икенче якка таба борыла калса, башыңа авыр киләчәк,— диде.

Гөлрох, авыр мәсьәлә каршында калган килеш, өч көннән соң җавап бирәчәген белдереп, Ходаколы шаһ яныннан чыгып китте.

Өч тәүлек буена йокысыннан һәм ашау-эчүеннән калып, Гөлрох тик шушы мәсьәлә турында гына уйлау белән мавыкты. Ахыр чиктә бер хәйләсен тапты, патша кызын күреп, эш-

нең төп сере турында сөйләшергә карар бирде. Кош теле чаклы бер язу тоттырып, даясын патша кызына җибәрде.

Бу вакыт патша кызы кырык кыз-кыркыны белән үз бакчасына махсус ясалган күл янында аккошлар ашатып утыра иде.

Дая тапшырган язуны укыгач, патша кызы Фәррах Бану, мөлаем елмаеп:

— Барып әйтегез, мин аны хәзер үк шушы күл янында көтәчәкмен. Рәхим итсен, капулар аңар ачык,— диде һәм ике генә сүздән торган бер бөтик[1] язып бирде. Дая Гөлрох янына ашыкты. Патша кызы исә шул ук минутта кыз-кыркыннарына, сарай капуларын ачып, «Камәрҗанны» каршы алырга, шушы күл янындагы ханакаларның[2] барысына да табыннар тезеп, төрле ашамлыклар әзерләргә боерды, һәм үзе, кешлек киемнәрен киенергә дип, сараена кереп китте.

Гөлрох, патша кызының чакыру бөтиген алгач ук, шаһзадәләрчә махсус киемнәрен киенеп, үзе белән нукирларын ияртте дә кыз янына юнәлде.

Гөлрох барып җиткәндә, сарай тирәсе каршылаучы кызлар, җарияләр белән урап алынган иде. Аны төрле җыр-уеннар белән каршыладылар һәм сарай бакчасының түренә, аккош күле буендагы ханакаларның берсенә уздырдылар.

Анда Гөлрохны, тулган айдай елмаеп, патша кызы каршылады. Кыз уналты-унҗиде яшьлек бер гүзәл икән. Аның хәрәкәтләрендә әле балалык кыланышлары бик нык сакланганнар. Кызны күргәч, Гөлрох үз-үзенә: «Сабый бала икәнсең әле. Ышаныч бар, синең белән сер берләштереп булачак»,— дип уйлап куйды һәм, үзен югалтмастан:

— И җир йөзенең назлы чәчкәсе, минем ардаклым Фәррах Бану, сезне күрү бәхетенә ирешүем белән шатмын. Әткәгез мине үзенә кияү итеп сайлады. Мин аның теләгән аяк аска сала алмыйм. Менә инде күзгә-күз карашып, авызга-авыз куеп, сезнең белән сөйләшим һәм аңлашыйм дип, үз катыгызга килдем, былбылым. Максатым сезнең үз авызыгыздан чыккан сүзне ишетү...

Бу минутта Фәррах Бануны мәхәббәт балын әле беренче башлап кына авызына капкан яшьләргә хас балачыл тойгылар басып алдылар. Аның бит алмасына әллә нинди кайнар кызыллык йөгерде, колаклары ахактай кызарып киттеләр, уймак-

---

[1] Бөтик — язу, хат.
[2] Ханака— беседка кебек урын.

тай җыйнак авызын, артыграк җәелгән иреннәрен кыюсыз калтырау баскандай булып сизелде. Аның талчыбыктай нечкә куллары, ихтыярсыз рәвештә акрын гына күтәрелеп, Гөлрохка таба сузылдылар. Гөлрох аларны шундый ук йомшак, тик бераз сазаганрак куллары белән каршылады. Һәм, мөлаем елмаюлы иреннәрен тидереп, башын күтәрде дә Фәррах Бануга сораулы караш ташлады.

Яшь кыз, тамак төбенә килеп тыгылган ниндидер каты бернәрсәне читкә этәреп маташкандай бер хәрәкәт ясап алганнан соң:

— Шаһзадә, миңа сезнең исемегез һәм егетләр күрке булуыгыз күптән билгеле иде. Сезне уйлап йокламый уздырган төннәрем дә аз түгел. Бу минут минем күптәннән бирле үсеп яткан беренче мәхәббәт гөлемнең чәчкә аткан минуты. Мин синеке, син минеке булсаң иде: менә минем теләгем, — дип, артык кыюлануыннан үзе дә оялган бер кыяфәт белән Фәррах Бану башын аска иде.

Яшь кызның самимилеге Гөлрохка аерата йогынтылы тоелды. Ул түземлеген югалтып, ике күзен мөлдерәгән яшь каплады. Шул вакыт ул аякка басты да, Фәррах Бануның кара бөдрә чәченнән аналарча сыйпап, маңгаеннан үпте.

Фәррах Бануга аның бу үбүе әллә ничек бик таныш, гүяки әнкәсе үпкәндәге сизем белән сугарылган кебек тоелды. Ул «Камәрҗанның» йөзенә яңа бер дикъкать белән күтәрелеп карады һәм аның ике бит алмасы буйлап тәгәрәгән яшь тамчыларын күреп гаҗәпсенде, «бу нинди күренеш?!» дигән сорау алдында калды.

— Сеңлем,— диде Гөлрох, уң кулын Фәррах Бануның җилкәсенә куеп, — сиңа эч серемне ачмый булдыра алмыйм. Мин бит сез уйлаган Камәрҗан шаһзадә түгел. Мин аның хатыны, Чин патшасының кызы Гөлрох ханша булам...

— Ничек инде ул алай? Йа Раббем, мин яшь бер кызга нинди хикмәтләр күрсәтәсең? — дип, Фәррах Бану утырган урыныннан кинәт сикереп торды да бер-ике адым артка чигенеп куйды.

— Ардаклым Фәррах Бану,— дип, Гөлрох, аңа якынрак килеп, сүзендә дәвам итте,— бу вакыйганың сере тирән. Сөйләсәм, берничә көн һәм төннәр кирәк булачак. Мин аның сиңа кыскачасын гына әйтеп бирим. Камәрҗан белән без бер-беребезгә бер тамчы судай охшаганбыз. Әгәр дә без, икебез дә бер үк төрле киемнәр киеп, янәшә бассак, безне берәү дә аерып ала алмаячак. Без хәзерге көндә минем илемнән аның иленә

кайтып барабыз: юлда зур маҗарага тап булдык. Камәрҗан югалып калды. Мин исә, аның киемнәрен киенеп һәм кәрванга хуҗалык хокукын кулыма алып, үземнең Гөлрох икәнлегемне берәүгә дә белдермәстән, Хаварзәм шаһ хозурына кайтып барам. Ышанам ки, Камәрҗанны да эзләп табачакмын. Үзеңә мәгълүм, менә монда — сезнең шәһәргә килеп төшү аркасында, бик күңелсез вакыйгага очрадык: сезнең әткәгез мине үзенә кияү итеп сайлады. Мин аңар иртәгә үземнең ризалыгым турында соңгы сүземне әйтергә тиешлемен. Мин синең киңәшеңә мохтаҗмын, җиһанның былбылы, сеңлем Фәррах Бану. Үзеңә мәгълүм, әгәр дә мин әткәгезгә үземнең кем икәнлегемне ачсам, бердән, алдакчы хатын дип, ул мине астырачак, икенчедән, ул да, шулай ук син дә «бер хатынга гашыйк булучылар» дигән көлкеле исем тагып калачаксыз.

— Ай минем хәлем! Вай минем кара язмышым! — дип уф орды Фәррах Бану.

— Сеңлем,— диде Гөлрох, кызның аркасыннан сөеп,— хәзер безгә бер генә юл кала: кешеләр гадәтенчә эшләнә торган туй гадәтләрен уздырырга да, бөтен көчне салып, Камәрҗанны икәүләшеп табарга һәм туганнарча татулык белән өчәүләшеп яшәргә. Ышанам ки, син моңа риза булырсың. Шушындый юлга бассак, шиксез, бәхетле гомер табачакбыз...

Гөлрох сүзеннән туктады.

Берникадәр вакытка болар арасындагы әңгәмә тукталып, киселеп торды.

— Әйе, минем сөеклем Гөлрох ханша,— дип дәвам итте, тынлыкны бозып, Фәррах Бану һәм ханшага якын ук килде.— Гомерең озын һәм һиммәтле булсын. Фикерең тугры, сүзең дөрес. Барысы да син әйткәнчә булачак. Мин үземне синең кулга тапшырдым һәм синең намусыңа таянам...

Болар шушы килеш серне беркеттеләр.

Ходаколы патша, зур туй-тамашалар корып, кызы Фәррах Бануны «Камәрҗан»га никяхландырды һәм, патшалыгын да балаларына һибә кыйлып, тынычлык түшәгенә башын куйды...

Башыңа төшсә, ата казга да сәлам бирерсең дигәндәй, Гөлрох, кияү исеме күтәреп, карт патшаның таҗын киеп, зур бер илгә патша булып калды, уңлап-суллап хөкемен йөртә башлады. Мондагы маҗараның төп сере исә тик өч кешегә генә мәгълүм иде.

Әйдә, болар үз юллары белән бара торсыннар, без Камәрҗан янына килик.

Камәрҗан, читлеккә япкан кош кебек, әлеге картның бак-

часыннан һичкая чыкмый ята бирде. Унбер айны уздыру аңа унбер елдан да озаграк һәм авыррак тоелды. Аның күңелендә һәм телендә һәр минут мәгъшукасы Гөлрох булды.

Көннәрдән бер көнне бакчачы карт, җимешләрен сатарга дип, базарга китте. Камәрҗан, гадәтенчә, бакчага чыгып, бер агач төбенә утырды, күкне, анда йөзгән вак болытларны, иректә очкан төрле кошларны тамаша кыйлып утыра-утыра, ул татлы йокыга чумды. Бераздан соң күзен ачып җибәрсә, шушы агач башында теге Гөлрох кәмәрен урлап киткән кошның бер ботакта утырганын күрде. Шул секундта аның бик каты ачуы кабарды.

— Мине шундый авыр горбәткә салучы явыз кош, син әле тагын килдеңме? — дип сикереп торды да, кулына бер таш алып, агач башына үрмәләп менде. Башына орыйм дигәндә генә, теге кош очып китте.

— Ай бәдбәхет, тагын ычкындың бит,— дип, кулындагы ташны аның артыннан җибәргән иде, эләкмәде.

Камәрҗан тирә-юнен караштыргалаган иде, шул ук агачның икенче бер ботагында шактый зур бер оя күрде. «Бу, мөгаен, шушы мәлгуньнең оясы булса кирәк»,— диде дә анда үрмәләде. Күрде, оя төбендә үлем ачысы белән сызланып теге кошның баласы ята икән. Ул: «Әй ыруың үчкере, җир йөзендә нәселең калмасын»,— дип, ачу белән шушы кош баласын алып җиргә атты. Кошчык, башы ташка туры килеп, ахыр сулуын алырга да өлгермәде, катып калды.

Камәрҗан агач башыннан төште. Канга бөркелеп яткан кошчык үләксәсен күтәреп алды, аның тәнендәге соңгы җылылыкны сизеп:

— Үлдеңме? Анаңның явызлыгы, комсызлыгы сине шул хәлгә төшергәнен белми үлүең генә бераз үкенечлерәк. Шулай, ата-аналарының явызлыгы аркасында балалары михнәт чигү дигән нәрсә озак тарихлардан бирле сузылган бернәрсә ул. Мин үзем дә, төптәнрәк уйлап карасаң, шуның корбаны...— Камәрҗан, шулай сөйләнә-сөйләнә, кошчык үләксәсе тоткан килеш, үзе дә белешмәстән бакча сукмагы буйлап атлый бирде.— Тукта әле, нишләп соң мин бу үләксәне күтәреп йөртәм? Бер җиргә күмим үзен,— диде дә бер агач төбенә барып туктады. Караса, бу бер корыган агач икән.— Эткә эт үлеме һәм эт урыны да булырга тиеш... Моңа шушы корыган агач төбеннән дә лаеклы җай булмас...

Камәрҗан, шушы агач төбенә бер чокыр казымакчы булып, кулына көрәк алган иде, күзе янә дә җирдә тынсыз һәм хәрә-

кәтсез яткан кошчыкка төште. Ни өчендер аның бүксәсе кирәгеннән артык зур, шешенгән төсле күренде аңар. «Бу кабахәт бүксәсе шешеп үлгән булса кирәк. Анасы, комсыз, моңа ни дә булса кирәкмәс әйбер ашаткандыр. Ярып карыймчы» дигән уй Камәрҗанның башына килде, һәм ул билендәге хәнҗәрен суырып алды да кошның бүксәсен ярып җибәрде. Ни күзе белән күрсен, аннан, мин сиңа әйтим, Гөлрох кәмәренә беркетелгән теге кыйммәтле якут ташы килеп чыкты. Камәрҗан башта моңа бик гаҗәпләнде, соңыннан исә:

— Михнәт, җәфа чиксәм чиктем, әмма Гөлрох каршында йөз кызыллыгы кичерешеннән котылдым,— ди-ди бик куанды. Якут ташын элек бик нык юды, аннан, Гөлрох хатирәсе итеп саклый торган ефәк кулъяулыгына төреп, күкрәк кесәсенә салды.

Кошчык үләксәсен чокырга ташлап, арлы-бирле күмде дә үзенә билгеләнгән бүлмәгә кереп бикләнде һәм биләүсәгә салынган нәниләрдә генә була торган тынычлык белән рәхәткә талды.

Шушы вакыйгадан соң берничә көннәр үткәч, бакчачы карт тагын базарга киткән иде. Камәрҗан бакчага чыкты. Инде күптәннән бирле корып утырган бер агачны, бөтен бакчаның ямен китәреп тора ич бу, дип, пычкы белән кисәргә керәште. Агач, хәтта моның кисеп бетергәнен дә көтмәстән, төбе-тамыреннан ук ауды, һәм аның урыныннан җир эченә таба бер ишек кебек нәрсә ачылды. Камәрҗан кызыксынып шушы ишекне ачкан иде, ни күзе белән күрсен: анда мәрмәрдән ясалган йөз данә чүлмәк утыра, һәркайсының авызы бик таман итеп капланган. Берсен көч-хәл белән ачып караган иде, алтын комы килеп чыкты. Икенче һәм өченчеләрен дә ачты, шул ук алтын комы икән. Шуннан соң, бу бер яшерен хәзинә икән, бәлки, картның үзенекедер дип, чокырдан чыкты, ишекне ябып, җир белән каплады да икенче бер эш белән шөгыльләнде.

Менә карт та, базардан кайтып, бакчасына чыкты.

— Йә, кәефләр ничек, гүзәл егет, горбәт моңсулыгы бик борчымыймы? Зарар юк, яшьлегеңдә михнәтне күбрәк татысаң, картлыгыңны тыныч үткәрерсең. Йөргән таш шомара, яткан таш бәсәрә, дигәннәр картлар. Менә озакламый көймәчеләр кузгалачаклар, син дә шулар белән китәрсең һәм җан сөйгәнеңә җитеп кавышырсың,— дип, Камәрҗанны юатты карт.

— Рәхмәт, бабай, яхшы теләгегезгә. Дөрес әйтәсез, җәфаны чикмәгән адәм сафаның кадерен белмәс, дигәннәр. Зарар юк, бераз татып карыйк әле михнәт шәрабын да... Мин әле сезгә яңа хәбәр әйтмәкче булган идем,— диде Камәрҗан.

— Баш өсте, кадерлем, әйтегез. Сезнең шатлык һәм кайгыгызны уртаклашырга мин әзермен.

Гади бер бакчачының һәркайчанда да шундый мөлаем, кешелеклелек белән сугарылган сүзле булуына Камәрҗан кайчагында гаҗәпсенгәләп тә ала торган иде. Бу юлы ул үзендәге уйны яшереп кала алмады.

— Бабакаем, гомерең озын һәм тыныч булсын, син мондый саф күңеллелекне ничек һәм кайдан кәсеп иттең? — дип, картка сорау бирде.

— Мин, энем, матурлап сөйләп бирә алмыйм. Тик шунысын гына әйтәм сиңа. Менә мин шушы кыргый халык белән үз гомерем буена күрше булып яшәдем. Шулардан күргән җәбер-җәфалар, аларның кешелексезлекләрен үз җилкәмдә татулар минем намусны тәрбияләделәр. Кыскасы, мине кешелекле булырга өйрәттеләр. Әгәр дә мәгәр син монда миңа килеп очрамаган, минем бакчама кереп сыенмаган булсаң, Алла күрсәтмәсен, бу вандаллар сине эштән чыгарган, намусыңа тукынган, хәтта үзеңне эт баласы урынына үтереп ташлаган булырлар иде...

— Син үзең төп кайсы халыктан соң? — дип сорады Камәрҗан.

— Минем,— диде карт,— төп илем моннан шактый ерак. Итил, Чулман дәрьяларын, бәлки, беләсездер. Безнең борынгы бабайлар шушындагы халыклар нәселеннән. Безне русиялеләр дип атыйлар...

— Алай икән. Аңладым. Рәхмәт, бабай, мең яшә. Инде мин сезгә әлеге хәбәрне әйтим. Мин бүген әнә шундагы бер корыган агачны кисә башлаган идем, ул үзе ауды китте, һәм шунысы гаҗәп ки, астыннан бик бай казна килеп чыкты. Анда берничә чүлмәк алтын комы бар. Рәхим итегез, мин сезгә ул казнаны күрсәтим.

Камәрҗанның бу хәбәрен ишеткәч, карт елмаеп куйды һәм сабыр гына тавыш белән:

— Углым, минем балам-чагам, мирасыма ия булып калырдай беркемем дә юк һәм мин ул чаклы байлыкны үз гомеремдә файдаланып та өлгерә алмаячакмын. Син тапкансың икән, үзеңә булсын, мин аңа мохтаҗ түгел. Тик шунысы бар: син аны моннан ничек алып китәрсең икән? — диде.

— Ул байлык миңа да үземә генә күп булачак. Мин аның барысын да төяп китә алмаячакмын...

— Әмәлен табарбыз. Алып китәрсең, тик урынсызга әрәмшәрәм итәргә генә булмасын. Бигрәк тә синең шикелле ил

кешесе булган адәмнәр кулына кергән казна малы ул тулысы белән ил, ватан, халык кирәк-ярагына, аның файдасына тотылырга тиеш. Әгәр дә син аны, җилдән килгән — җилгә китсен, дип тотачак булсаң, аның әнә шул күмелгән урынында ятуы хәерлерәк.

— Сүзең тугры, хөрмәтле картым. Бүгенге көндә минем өчен мал кайгысы түгел, баш кайгысы зуррак әле,— диде Камәрҗан.

— Җайларбыз. Башың да исән-сау булыр, тапкан казнаны да үзең теләгән, нәфсең туйган чаклы алып китәрсең. Минем белүемә караганда, бу араларда сезнең илгә көймәчеләр мал төяп китәчәкләр. Шуңа әзерләнү мәслихәт булыр. Әнә шушы сарайда минем бик мәхкәм[1] итеп эшләнгән әрҗәләрем бар. Шуларның асларына әлеге алтын комны, өске өлешләренә исә менә шушы бакчада үсеп яткан зәйтүн җимешен салып тотырырга кирәк булыр. Күтәреп-төшереп йөртергә дә ипле булыр, кешеләргә шикләнергә урын да калмас...

Картның бу киңәшләрен колакка алып, Камәрҗан сәфәргә әзерләнә башлады һәм, берничә көн тоташтан эшләп, йөз әрҗәне тутырып та куйды.

Беркөнне көймәчеләр янына барды, аларның юлга чыгарга әзерләнүләрен белгәч, башлыклары белән сөйләшеп, үзенең йөз әрҗә зәйтүнен китереп тапшырды.

Көймә бүген яки иртәгә китәчәк, тик җайлы, юлаучы җил генә көтеп ята иде. Менә шулай көтеп ятканда, төнлә белән юлаучы җил өреп, көймә китеп тә барды. Көймәчеләр, ашыгып китү сәбәпле, Камәрҗанны чакыртырга оныттылар, шулай итеп, ул тагын утырып калды, төягән маллары китте. Шаһзадә, бу хәлне күреп, бик зур кайгыга төште, хәтта үзен-үзе һәлак итү дәрәҗәсенә җиткән иде дә, бакчачы картның үгет-нәсыйхәтләре аны тынычландырдылар.

Камәрҗан бакчачы картның өендә сабыр итеп тора бирсен, без көймәчеләр артыннан барып карыйк әле.

Җил җае туры килеп, көймәчеләр берничә көн эчендә Бәсра шәһәренә, ягъни Гөлрох патшалык итеп яткан калага килеп җиттеләр.

Гөлрох, читтән килгән һәрбер кешене үзенә чакыртып, Камәрҗан турында сорашып тора иде. Безгә таныш көймә ки-

[1] Мәхкәм — нык, таза эшләнгән.

леп туктау белән, аның башлыгын да Гөлрох катына алып киттеләр. Гөлрох сораша торгач, көймә башлыгы болай диде:

— Бик ашыгып китәргә туры килгәнлектән, бер мөсафирыбызны онытып калдырганбыз. Көймәбездә исә аның йөз әрҗә зәйтүн җимеше килде. Ул малны, безнең уебызча, хәзинәбездән алып үзе сатса һәм җыелган акчасын дәфтәргә теркәп, минем кулыма бирсә, бик яхшы булыр иде. Мин аны, кайткач, иясенә тапшырыр идем.

Гөлрох аңар:

— Ул зәйтүннәрне үзем карыймчы. Хәзер үк миңа бераз китертегез,— дип боерды.

Көймә башлыгы чыгып китте. Бер сәгать вакыт үтмәде, Гөлрох алдына бер табак зәйтүн җимешен китереп тә куйдылар. Ул аларны берәм-берәм алып карый башлаган иде, һәркайсысының өстен алтынга охшашлы ком сыман тузан каплаган икәнен сизеп алды. «Тукта, монда ниндидер бер хикмәт булырга тиеш»,— дип, үзалдына уйланып торганнан соң, ул:

— Зәйтүннәрнең барысы да бергә китерелсен,— диде.

Йөз әрҗә зәйтүнне китереп куйдылар. Гөлрох, хезмәткәрләрен кушып, әрҗәләрнең барысын да ачтырды, зәйтүннәрне аерым савытларга бушаттырды. Шул вакыт, ни күзе белән күрсен, әрҗәләрнең берсеннән, үзенең Камәрҗанга бүләк иткән кыйммәтле яулыгына төргән килеш, теге югалган кәмәрендәге якут ташы килеп чыкты.

Бу күренеш аңар зур шатлык һәм өмид бирде. Ул шул ук сәгатьтә теге көймә башлыгын янә чакыртып китертте дә аңар:

— Синең бу зәйтүннәреңнең иясе нинди кеше? Аның төсе, кыяфәте, гомумән, торышы ничек? — дип сораштыра башлады. Көймәче аңар ул кешенең нинди икәнлеген сөйләп бирде. Гөлрох белде ки, ул мөсафир Камәрҗан икән.

Шунда ук көймәчегә:

— Менә шушы адәмнәр белән бар да бу сәгатьтә көймәгездә булган барлык малыңны бушат һәм, һәрберсенә мөһер сугып, хәзинәгә тапшыр. Үзең буш көймәгә утыр да әлеге онытып калдырган мөсафирыңны тиз көндә монда китереп җиткер. Әгәр дә син шул эшне үтәсәң, азат буласың һәм бездән күп бүләк алачаксың. Инде булдырмыйсың икән, ул чагында сиңа бик зур җәза һәм үлем булачак, үзеңне дә, көймәңне дә, шулай ук бөтен малыңны да утка атачакмын,— диде.

Көймәче, баш өсте, дип, Гөлрохның боерыгын кабул итте. Бәхеткә каршы, шул ук көнне юлаучы җил чыгып, көймәче үз иленә кайтып китте. Ул бик тиз арада кайтып та җитте һәм,

теге «бакчачы улы», ягъни Камәрҗан катына барып, вакыйганы сөйләп тә бирде.

Камәрҗан, бакчачы карт белән туганнарча аерылышып, көймәгә утырды. Шунда ук юлаучы җил чыгып, болар кузгалып та киттеләр һәм унике тәүлек дигәндә Бәсра каласына барып та җиттеләр.

Гөлрох шаһ, бигрәк тә соңгы көннәрдә һәр минут диярлек дәрья өстендәге хәрәкәтне күзәтеп, чит илләрдән килгән көймәләрне тикшертеп, аларның каян килгәнлекләре, мөсафирлары кемнәр булуы турында мәгълүмат алып тора иде. Камәрҗаннар көймәсе, Бәсра каласына җитеп, ләнгәр[1] салырга да өлгерә алмады, Гөлрохның кешеләре килеп җиттеләр һәм «бакчачы улын» патша сараена алып та киттеләр.

Камәрҗан: «Монда тагын ниләр күрәсем бар икән?» — дип, юл буена куркулы уйлар белән килде. Менә аны зур һәм зиннәтле бер сарай эченә китереп керттеләр.

Гөлрох үзенең мәгъшукын тәхеткә утырган килеш каршылады, ләкин чыдамы җитмәде. Камәрҗанны күрү белән көчле тойгыга бирелеп, һушыннан язу дәрәҗәсенә якын хәлгә килде, хәтта иренә «утыр» дип тә әйтә алмады, тик кулы белән генә ишарә кылды.

Камәрҗан күрсәтелгән урынга барып утырды һәм, ят бер җирдә калган кешедәй, үзенең кайда икәнлегенә төшенә алмыйча хәйранга калды.

Гөлрох, үз-үзен кулга алып, «каенатасы» Ходаколы шаһны чакыртып китерде һәм аулак бер бүлмәгә алып керде. «Бакчачы углын» да шушы бүлмәгә кертеп утырттылар. Болар янына Фәррах Бануның да керүен үтенделәр.

Шуннан соң Гөлрох зур ихтирам белән карт патша Ходаколы алдына килеп тезләнде һәм:

— Сез мине гафу итегез! Мин моңарчы сезгә яшерен булган серләрне инде ачарга тиешлемен...— дип, вакыйганы сөйләргә керешкән иде, Камәрҗан, йокысыннан сискәнеп уянган кешедәй хәрәкәт ясап:

— Бакчы, бу минем мәхбүбәм[2] Гөлрох ич! — дип, муенына сарылды.

Болар икесе дә һушларын югалттылар. Сарай хезмәткәр-

---

[1] Ләнгәр — якорь.
[2] Мәхбүбәм — сөйгәнем.

ләре җитмеш җиде төрле гөл сулары китереп сипкәч кенә, аңнарына килделәр.

Ходаколы шаһ бу күренешкә хәйран булды:

— Афәрин, кызым Гөлрох! Мин синең тулы гакыллы, оста итеп эш йөртә ала торган, чын-чыннан булдыклы хатын булуыңны котлыйм. Без сине, Камәрҗан шаһзадәгә саеп, үзебезгә кияү иткән һәм патшалык таҗыбызны сиңа ук тапшырган идек. Карарыбыздан дүнмибез — киявебез һәм таҗ иябез һаман да Камәрҗан булып калачак. Тик үтенечем шул гына: минем кызым Фәррах Бануны үзегезнең туганыгыз итеп саклагыз,— дип, сүзен тәмамлады.

— Рөхсәт итегез минем атамнан да олуг итеп санаган шаһым Ходаколы җәнаблары һәм минем җанымнан кыйммәтле Камәрҗаным, Фәррах Бану белән бер тән һәм бер җан булып яшәячәгебез турында безнең антларыбыз, вәгъдәләребез беркетелгән инде. Ышанабыз ки, хөрмәтле шаһзадә безнең теләгебезгә каршы килмәс.

— Баш өсте! — диде Камәрҗан, аякка басып.

— Мин дә үземне бәхетле саныйм,— дип, Фәррах Бану торып иң элек Камәрҗанның, аннан соң Гөлрохның кулларын кысты.

Шуннан ук туй бәйрәме башланды. Фәррах Бануны Камәрҗанга никяхладылар.

Камәрҗан белән Гөлрох арасындагы төс охшашының көчле, һичкем аера алмаслык булуы сәбәпле, халык бу кыйссаны аңламады, сизмәде. Бу вакыйга хан сарае эчендәге берничә кеше арасындагы яшерен сер булып калды.

Гөлрох белән Фәррах Бану арасындагы дуслык вәгъдәсе көннән-көн ныгый барды. Болар икесе Камәрҗанның ике күзе булып әверелделәр.

Көннәр үтеп тора торгач, бер үк көнне, хәтта бер үк сәгатьтә бу ике ханшаның икесе дә берәр угыл дөньяга китерделәр. Бу ике солтанның туу шатлыгы итеп, бөтен ил кырык көн буена бәбәй туе уздырды.

Гөлрохтан туган угылга — Асыл, Фәррах Банудан туганына Насыл исеме куштылар.

Бу ике угланны тигез тәрбия һәм кадер-хөрмәт биреп үстерделәр. Боларның һәр икесе дә унсигез яшькә җитеп, аталарының ил белән идарә итү эшенә булыша башладылар; бере — Камәрҗанның уң ягыннан, икенчесе сул кул ягыннан урын алдылар. Гүяки аның байлыгының ике канаты булдылар. Камәрҗанның Илкәм исемле бер вәзире бар иде. Әбүҗаһил сыман

бер адәм иде. Бу шаһзадәләрнең дәүләт эшенә катнашуларына борчылып, ул һәр ике шаһзадәне берәр сәбәп белән читкә җибәрүне уйлап йөри иде. Максатына ирешеп, ул Гөлрохтан туган шаһзадәне Чин шаһы тарафына һәм Фәррахтан туган шаһзадә Насылны Шөҗаг шаһ тарафына сәяхәткә җибәртте.

## Шаһзадә Асыл кыйссасы

Әлеге вәзирнең фитнәсе белән шаһзадә Асыл сәяхәткә җыена башлады. Ул үзенең бабасы Чин падишаһы тарафына юнәлмәк булды. Юлда көннәрне шат һәм бәхетле үткәрү өчен, ул хәзинәдән кыйммәтле бүләкләр бирүләрен үтенде. Шул бүләкләрне алырга дип хәзинәгә кергәндә корычтан ясалган бер сандык күрде. Сандык өстенә алтын белән «Бу сандыкта бүләкләр һәм бик сирәк очрый торган борынгы әйберләр саклана. Дөнья хәзинәсе дә ул бүләкләргә тиң була алмас» дип язылган иде. Шаһзадә, сандыкта язылган сүзләрне укыгач, аны үз бүлмәсенә алып килде. Аулакта ялгыз хәлендә ул сандыкны ачып җибәрде: эчендә гаҗәеп бизәкле бер тартма күрде. Ул тартма эченнән тагын бер кечерәк тартма килеп чыкты. Тартма эчендә бакырдан ясалган бер мөһерле йөзек бар иде. Бәһасенә караганда бер тиенлек яки ике тиенлек нәрсә. «Бу ни хикмәт булыр?» — дип, шаһзадә бик гаҗәпләнде. Ләкин бу эшне берәүгә дә фаш кыйлмады. Берничә көннән соң сәфәр көймәсе әзер икәнен хәбәр иттеләр.

Аталары белән саубуллашып, шаһзадә Чин патшалыгы тарафына сәфәргә чыкты. Көймә белән ун көн киткәннән соң, каршы яктан җил купты. Диңгез өстендә тау-тау дулкыннар уйнады. Көймә җимерелеп, Сәгыйд исемле бер хезмәткәре белән шаһзадә Асыл гына бер тактага ябышып исән калдылар. Дулкын аларны бер утрауга китереп ташлады. Болар ярга чыктылар. Төрле-төрле җимеш агачлары белән капланган гүзәл бу утрау җәннәт кебек бер җир иде. Ләззәтле җимешләре белән тамак ялгап, татлы сулары белән сусауларын кайтарганнан соң, бер гүзәл урынга ятып йокладылар. Иртә белән шаһзадә йокысыннан уянганда хезмәткәре Сәгыйдне янында тапмады. «Бу кая китте икән?» — дип, ары йөгерде, бире йөгерде, чакырып та карады, һич җавап бирүче булмады. Бер биек агач башына менеп, тирә-якка күз салса да, Сәгыйдне күрмәде. Икенче бер тарафка әйләнеп караганда бер биек сарай күрде. «Тукта, барып күрим әле»,— дип, ашыгып сарай янына китте. Күрде ки, бөтен ягы җәүһәр һәм зөмред белән бизәлгән, гөмбәзләре мәрҗән һәм

төрле җәүһәр белән зиннәтләнгән, дүрт коймасы мәрмәрдән, капкасы алтын-көмеш белән капланган. Ишеге биш поттан да ким булмаган алтын йозак белән бикләп куелган. Шаһзадә бу сарайның дүрт ягын кат-кат әйләнеп карап чыкты. Сарайның эченә керә торган юл табалмыйча, яңадан капка алдына килеп туктады. «Бу нинди гаҗәп йозак икән?» — дип, кулы белән тотып карыйм дигәндә, кулы тигәч, йозак акбурдан ясаган нәрсә шикелле коелып төште. Капка ике якка ачылып китте. Эчкә кереп карау теләге зур булса да, берәр кеше күренмәсме икән, дип, шаһзадә курка-курка гына ике сәгать чамасы як-ягына каранып торды, һичкем күренмәгәч, баскычтан югары күтәрелеп, кырык-илле бүлмә үткәннән соң, зур бер залга килеп чыкты. Бу залның үзен һәм андагы җиһазларны тасвирлый башласаң, бер китап язарга туры килер иде. Кыскасы, шулдыр: бүлмәнең уртасында — олы табын, фарфор савытлар хәзер генә пешерелгән нәфис азыклар белән тутырылган, төрле җимешләр һәм шәраблар табынга тезелгән. Алтын таз эчендә алтын комганнар һәм алар янына кардан да ак нәфис тастымаллар куелган иде. Шаһзадә һич тартынмыйча һәм чирканмыйча табынга барып утырды да туйганчы ашады, туйганчы шәраб эчте. Соңыннан кулларын юып, тирә-яктагы бүлмәләрне тикшерергә кереште. Карап йөри торгач, тагын бер гаҗәп бүлмәгә барып юлыкты. Бүлмәнең нәкъ уртасында җәүһәрләнгән тәхет өстендә бер гүзәл кыз ята. Килеп озак кына кызның гүзәллегенә сокланып карап торды. Уятыр өчен шыпырт кына дәшеп караган иде, кыз уянмады, кычкырыбрак дәшеп карады — кыз уянмады. «Кул белән кагылып уятырга ярамас, тукта, үзе уянганчы сабыр итим»,— дип, кызның уянганын бераз көтеп торды. Шулай утырганда, диварда бер язу күрде. Алып укырга теләп, барып кул тидергән иде, теге йозак шикелле, бу язу да уалып, шалтырап идәнгә коелды. Шунда ук кыз уянып сикереп торды. Бүлмәдә шаһзадәне күргәч, исе китеп: «Син кем? Монда ничек кердең? Ул язуны ник ваттың?» — дип сорады.

Шаһзадә үзенең кем булуын, нинди бәлаләргә юлыгуын, капкадагы йозакның һәм дивардагы язуның ничек бозылуын — һәммәсен сөйләп бирде. Кыз берникадәр вакыт башын түбән иеп уйга калды. Хәйран булып шаһзадәгә:

— Бу сөйләгәннәрең һәммәсе акыл җитәрлек нәрсә түгел, чөнки бу утрауда адәм баласының бер минут яшәү ихтималын да күз алдына китерү мөмкин түгел,— диде.

Шаһзадә дә кызның кем икәнен сорады. Кыз болай дип җавап кайтарды:

— Мин Сәрандиб[1] патшасы Габдесаматның кызы Шивазадәмен. Ундүрт яшемдә идем. Бакчада җарияләрем белән сәер итә идем. Җеннәр патшасы, һавада очып барганда күреп, миңа гашыйк булган. Бакчадан җарияләр арасыннан мине алып китте. Бу утрауга китерде. Менә өч ел инде ул мине үзенә хатынлыкка үгетли. Үлемгә риза булып тәкъдимен кабул итмәгәнем өчен, сихер белән мине шул хәлдә йокыга салып китә. Ай саен бер мәртәбә килеп, син ваткан язуны кузгатып, мине йокыдан уята. Ялвару, ялыну сүзләре белән миннән ризалык сорый. Кабул итмәгәч, яный, куркыта да тагын калдырып китә. Өч ел инде мин бичара әнә шундый хәлдә. Күпме вакыт йоклаганмындыр — белмим, ләкин тиз арада ул килер дип уйлыйм. Синең монда булганыңны, язуны ватканыңны күргәч, һичшиксез, икебезне дә юк итәчәк.

Болар, куркышып, ничек качып китү турында уйланып торганда, кинәт, сәрсар җиле[2] кебек шаулап-гөрләп, бер кара болыт кояшны һәм күк йөзен каплады. Кыз ах-вах итеп: «Килде!» — дип кычкырды да һуштан язып егылды. Шаһзадә дә, җаныннан өмид өзеп, иманын укый башлады. Ул арада өстенә патшалар киеме, башына таҗ кигән гыйфритләр патшасы килеп керде. Кергәч тә шаһзадәгә күзе төште. Бизгәк тоткан кеше кебек дер-дер калтырап:

— Әфәндем, зинһар, һәлак итмә, җанымны кыйма, мордар канымнан кич,— дип, зар-зар егълый башлады. Чиксез куркудан аның селкенергә дә такате калмады. Шаһзадә һәм кыз бу хәлгә хәйран булдылар. Шаһзадә көчле рухлы, гайрәтле, бәһадир адәм иде.

Гыйфритләр патшасы каушаганын күргәч:

— Канымнан кич, дисең. Син миңа нинди начарлык эшләдең? — дип сорады.

Гыйфритләр патшасы:

— Әфәндемә начарлык эшләргә минем ни хакым бар? Алла сакласын, бер мәртәбә генә каршылык күрсәтсәм дә, утка янып китим. Бармагыңдагы изге йөзек белән ант итеп әйтә алам, бу кызга карата да явыз ниятем юк иде, гашыйк булуым сәбәпле генә аны бу сарайга китердем. Тиңсез мәрхәмәтегезне күрсәтеп, гөнаһымны гафу итегез. Әмерегезгә буйсыныр-

[1] Сәрандиб — хәзерге Цейлон утравының мөселманча исеме.
[2] Сәрсар җиле — салкын, давыллы җил.

мын. Берәр хезмәтегез яисә боерыгыгыз булса, мин хәзер. Ул, дисәгез, үләргә риза.

«Хәзинәдәге тартмадан табып алган бакыр йөзектә берәр хикмәт бардыр, йөзектә Сөләйман пәйгамбәр мөһере бардыр, бу хәл шул йөзек хасиятеннәндер» дип уйлады шаһзадә. Гыйфриттән ул Сәгыйд хәбәрен сорашты.

Гыйфрит:

— Хәбәрем юк, әмма әмерегез булса, барып эзләп карыйм,— диде. Шаһзадә әмере белән гыйфрит Сәгыйдне эзләргә китте. Шатлык һәм куанычыннан кыз килеп, шаһзадәнең аягыннан үпте. Шаһзадә дә кызны юатып, бер сәгать чамасы баштан үткәннәрен сөйләшеп, дәртләрен уртаклаштылар. Ул арада гыйфрит килеп, Сәгыйдне арыслан һәлак кыйлганын хәбәр итте. Шаһзадә Сәгыйднең вафатына кайгырып бик егълады. Гыйфрит, шаһзадәнең мәрхәмәтле һәм миһербанлы икәнен күреп, Шивазадә белән икесенең кулларын үпте һәм:

— Әфәндем, өч йөз елдан бирле гыйфритләрнең патшасымын, соңгы вакытларда гыйфрит хөкемдарларының кайберләре миңа буйсынмый башладылар. Бу колыгызны яңадан аларга хаким итеп билгеләсәгез икән, — дип ялварды.

Шаһзадә гыйфриттән:

— Син кайсы мәзһәбтән, исемең ничек? — дип сорады.

Гыйфрит:

— Мәзһәбем — әһле ислам мәзһәбедер, исемем — Шәмһаил,— дип җавап кайтарды.

Шаһзадә:

— Сине хаким итеп билгеләүнең тәртибе ничегрәк булырга тиеш? — дип сорагач, Шәмһаил:

— Әфәндем, Бабил солтаны Тайяр шаһның Җәвалә исемле бер углы бар. Аны мин үз балам кебек тәрбия кыйлдым. Кичә һәм көндез хезмәтегезгә әзер торсын өчен, шуны сезгә тапшырам,— дигәнендә, гүя ишек артында гына торгандай, бүлмәгә бер матур егет килеп керде.

— Менә, әфәндем, әгәр бу егеткә боерсагыз, ул барлык руханиларның[1] башлыкларын шундук җыеп китерер. Башка йомышларыгызны да үтәр,— диде.

Шаһзадә әмер бирде. Күз йомып-ачканчы, руханиларның башлыклары җыелдылар. Гыйфритләр, пәриләр, түбәнчелек һәм әдәп саклаганы хәлдә, саф-саф булып тәхет алдында басып

---

[1] Рухани — бу урында: җен-пәри, диюләр.

торалар. Унике икълимнең солтаны анда җыелган иде. Башларында — таҗлар. Шаһзадәнең килгәнен күрү белән, шундук сикерешеп тордылар.

Шаһзадә шундый боерык бирде:

— Байтактан бирле шаһиншаһыгыз булып торган Шәмһаил шаһны янә сезгә патша кыйлып билгеләдем. Сез аңа буйсынырга тиеш. Шул әмеремә буйсынып, аны яңадан патшалыкка кабул кыйлыгыз. Аның боерыкларына каршылык күрсәтмәскә вәгъдә бирегез,— дигәч, һәммәсе бердән:

— Баш өсте,— дип җавап кайтардылар.

Шаһзадә әмер итте: бер тәхет китерделәр. Шаһзадә Шәмһаилгә, утыр, дип ишарәт кыйлды. Шәмһаил, шаһзадә алдында җир үбеп, тәхеткә утырды. Пәриләр-женнәр һәм гыйфритләр төркем-төркем килеп, Шәмһаилгә итагать белдерделәр. Шаһзадә шундый боерык язды: «Мин, Сөләйман пәйгамбәр мөһеренең варисы шаһзадә Асыл, барлык женнәргә һәм гыйфритләргә хаким, әмир һәм баш шаһиншаһ итеп Шәмһаилне билгеләдем. Бу әмеремне телгә алынган төркемнәрнең һәммә башлыклары кабул итсеннәр. Әгәр шаһиншаһ вафат булса, солтанат олы углына калсын. Бу шартка каршылык күрсәткәннәр ошбу изге йөзек хөрмәтенә утта яндырылыр. Вәссәлам». Йөзектәге мөһерне басып, шаһзадә язуны Шәмһаилгә тоттырды. Аның әмере белән хатны бу мәҗлескә кычкырып укыдылар, һәммәсе ишетеп: «Баш өсте!» — дип җавап кайтарды. Аннан соң Җәвалә шаһзадәне шатландыргыч, хуш һавалы бер сарайга алып килде. Бераз ял иткәч, бер чибәр пәри килеп, шаһзадәдән Шәмһаилне кабул итүен үтенде. Рөхсәт бирелде. Шәмһаил, шаһларны тәбрикләү әдәбен җиренә җиткереп, шаһзадә каршына килеп утырды.

— Әфәндем, колыгызның ватаны Җәблика шәһәре иде. Шунда рәхим итсәгез икән.

— Юк, башта Шивазадәнең хәтерен табыйк; максатым — башта аны үз кулым белән әтисенә тапшырудыр. Аннан сезнең шәһәрегезгә юнәлербез.

— Әфәндем, Сәрандиб иле адәм йөреше белән моннан алты айлык юл. Ә Сәрандибтан Җәбликага өч еллык ара. Әмма безгә Сәрандиб чирек минутлык юл. Аннан Җәбликага ярты минутта барып җитә алабыз. Рөхсәтегез булса, сәфәр кирәкләре әзер.

Җәблика шәһәренә барып, өч көн торып, аннан Сәрандибка китәргә карар иттеләр. Җәбликада өч көн кәеф-сафа кыйлдылар. Аннан соң шаһзадә, Шәмһаилне чакырып, Шивазадә өчен бер ат һәм үзе өчен янә бер ат хәзерләргә боерды:

— Әле генә биредә булып, кинәттән Сәрандибка барып керүне теләмимен. Юлаучылар кебек, шәһәрдән шәһәргә күчеп, Сәрандибка көн яктылыгында барып керүне теләр идем,— дигәч, Шәмһаил һәммәсен шаһзадә әйткәнчә эшләде. Шәмһаил белән саубуллаштылар. Җәвалә атның тезгененнән тотып, Сәрандибка таба сәфәргә чыктылар. Барып җиткәч, шәһәр читенә туктап, Шаһзадә Җәваләне Сәрандиб солтаны Габдесаматка сөенче алырга җибәрде. Җәвалә, бер хезмәткәр кыяфәтенә кереп, патша сараена сөенечле хәбәр китерде. Капка сакчылары хәбәрне патшага җиткерделәр. Патша илчене кертергә рөхсәт бирде.

— Әфәндем, ике елдан бирле югалып торган кызыгыз Шивазадәне бер егет коткарып, кадер-хөрмәт белән шәһәрегезгә алып килде. Үзе шәһәр тышында калып, мине, рөхсәт сорар өчен, сезгә җибәрде.

Бичара патша, бу хәбәрне ишеткәч, бер утырды, бер торды, бер кычкырып егълады. Шундук хәкимнәр һәм вәзирләр җыелып, төркем-төркем гаскәр белән кызны каршыларга чыктылар. Шаһзадә Асыл атыннан төшеп, Габдесамат солтанга каршы барды. Шивазадә дә чатырыннан чыгып, әтисенең аягына егылды; аягын үбеп, ачы аваз белән шундый каты егълады ки, язып аңлату мөмкин түгел. Аннан соң кузгалып шәһәргә керделәр. Әнисе белән очрашып, икесе дә гаять егълаштылар. Әнисе баштан кичкәннәрне сорашкач, Шивазадә үзен җен алып киткәнен, бер сарайда бикләп тотканын һәм Бәсра шәһәре патшасы Камәрҗанның углы шаһзадә Асыл, бер сәбәп белән ул сарайга килеп, җеннәрдән коткарганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бичара Габдесамат патша, бердәнбер булган газиз кызы белән күрешкәч, бар хәсрәтләре шатлыкка әйләнеп, бөтен көче белән шаһзадәнең күңелен табарга тырышты. Шул рәвешчә берәр ай үткәч, беркөн патша, хатыны, Шивазадә — өчесе бер җирдә утырганда, патша, Шивазадәгә киңәшеп:

— Кызым, бу шаһзадәгә без мәңге бурычлы. Гакылым җитми, аны ничек кенә ризалатырбыз. Кыскасы, мин сине һәм таҗтәхетемне шаһзадәгә тапшырыр идем. Син ни әйтерсең? — диде.

Шивазадә елмаеп:

— И кадерле әтием, синең таҗ-тәхетең шаһзадә каршында тары бөртеге кадәр дә тормый, һәм мин колыгыз да аның кулына су салырга да яраралык түгелмен. Исәпсез-хисапсыз җарияләре бар. Берсенә дә илтифат итмәгәнен үзем күрдем.

Хәтта бу турыда аңа әйтү дә урынсыздыр. Үзеннән киңәш сорагыз,— диде.

Солтан Габдесамат шаһзадә янына килеп, аулакта шул хакта сүз кузгатты. Әмма шаһзадә: «Әфәндем, сезнең хәер-фатыйхагыздан башка миңа берни кирәкми»,— дигән сүзләр белән генә чикләнде. Шуннан соң патша шаһзадәгә сирәк очрый торган бер гаҗәп нәрсә күрсәтмәкче булды. Алар бер бакчага керделәр. Бакчаның артында җир астына төшә торган бер чуен ишек бар иде. Куеныннан бер ачкыч чыгарып, патша ишекне ачты. Җир астына уникe баскыч түбән төштеләр һәм гөмбәзләп ябылган бер бинага килеп керделәр. Бүлмә уртасында асылташлар белән бизәлгән буе-иңе унбиш терсәк зурлыгында бер күл бар иде. Ул күлнең эче җәүһәр, алмаз, зөмред, ләгыль һәм кызыл якут белән туп-тулы. Бу асылташларның иң начары да дөньяда бик сирәк очрый торган нәрсә иде. Күл тирәсенә ун данә өстәл куелган. Өстәлләрнең берсеннән кала һәр өстәлгә берсеннән-берсе гүзәлрәк сурәт утыртылган. Габдесамат шаһ шаһзадәдән түбәнчелек белән бу хәзинәне кабул итеп алуын үтенде. Шаһзадә: «Ярый, бу хакта чыккач сөйләшербез»,— дип җавап кайтарды.

Сарайга кайткач, шаһ үтенечен тагын кабатлады. Шаһзадә, сүзне икенчегә борып:

— Солтаным, ул бүлмәдә өстәлләр ун булып та, ни сәбәптән алардагы сурәтләр тугыз гына. Әллә бер сурәтне кемгә булса да бүләк иттегезме? — дип сорады.

Шаһ:

— Шаһзадә әфәндем, аның сәбәбе гаҗәп бер хикәяттер,— диде.

Шаһзадә ул хикәятне сөйләвен үтенде. Габдесамат шул хикәятне сөйләп бирде.

## Сәрандиб шаһы Габдесамат кыйссасы

Габдесамат, хикәятне башлап:

— Мин шушы Сәрандиб солтаны мәрхүм Мортаза шаһның углымын,— диде.— Әтием вафат булганда, егерме бер яшьтә булып, солтанлык тәхетенә утырдым. Ил белән идарә итүдә тапкырлык, иҗтиһад күрсәтергә тырыштым. Бер кичә яныма әнием килеп: «Улым, әтиеңнең сиңа васыяте бар, вакыты җитмичә сөйләмә, дип, миңа әйтеп калдырган иде. Васыятен үтәргә ант ит»,— диде. «Ата-ана баланы ярамас эшкә юлламас»,— дип, мин ул васыятьне үтәргә ант иттем.

Әнием мине, кулымнан тотып, шушы без күргән хәзинә бүлмәсенә алып барды. Малның күплегенә хәйран калдым. Әлеге буш өстәл өстендә атам кулы белән язылган бер хат күрдем, алып укыдым. Анда «Углым, бу васыятемне җиренә җиткермәсәң, кыяматтә ике кулым якаңда булсын. Моннан Мисырга барырсың. Рум иле мәйданында Әрдәбил чишмәсе якынында шәех Мөбарәк дигән бер мөхтәрәм зат бар. Голүме сәраир, ягъни яшерен гыйлемнәрне белүчедер. Бу хәзинәнең һәммәсен сиңа ул бүләк итте. Аягына йөзең сөртеп, түбәнчелек белән бу унынчы өстәлнең сурәтен сора, ул сурәтнең бәһасе, бәлки, калганнарының һәммәсенә бәрабәр булыр. Ул унынчы сурәтне кулга төшермичә, тәхетемә утырсаң, миңа гөнаһлы булырсың» дип язылган иде. Атамның шул сүзләренә буйсынып һәм унынчы өстәл генә сурәтсез тормасын диеп, сәфәр мәшәкатьләрен өстемә йөкләдем: вәзиремне урынбасарым итеп билгеләдем дә Мисырга юнәлдем. Мисыр шәһәренә җитеп, шәех Мөбарәкнең урамын эзләп таптым. Капкасын шакыдым. Бер хезмәтче кыз чыгып ишек ачты. «Шәех янына керергә рөхсәтме?» — дип сорадым. «Рәхим итегез»,— дип, мине шәех янына алып керде. Күрдем: кырык биш яшьләрендә бер кеше. Йөзендә илаһи бер нур бар. Әдәп белән барып, аягын үптем.

— Галәйкем әссәлам, углым Габдесамат. Әтиеңнең әйткән васыятен тотуыңа бик шатландым,— дип, утырырга ишарә кылды. Утырдым. Шундук табын әзерләделәр. Ашадык.

Шәех, миңа сүз әйтергә урын калдырмыйча:

— Углым, теләгән нәрсәң җәл түгел. Әтиең ул хәзинәне кулга кертер өчен бик күп хезмәт итте. Бераз хезмәт күрсәтмичә, син дә теләгеңә ирешә алмассың. Сиңа бер генә йомышым бар. Шул йомышымны үтәсәң, теләгән сурәтеңне сиңа бирермен. Ризамы? — диде.

— Боерыгыз. Кулымнан килә торган һәрнинди хезмәттән баш тартмам,— дидем.

— Кара, әгәр соңыннан баш тарта торган булсаң, һәлак булырсың,— диде. Баш тартмаска ант иттем. Шәех әмер итте: Мисырда өч көн торырсың. Аннан соң шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга китеп йөрерсең. Шуннан эзләп миңа гүзәл, пакь, гыйффәтле, һичнинди начарлыкны белми торган 14 — 15 яшендәге бер кызны табып китер. Аңа кулың тимәсен. Әгәр хыянәтең булса яки миңа китермичә китеп калсаң, һичшиксез, һәлак булырсың,— диде.

Мин:

— Әфәндем, ул гүзәлнең тышкы билгеләрен мин таба бе-

лермен, әмма күңелендә начарлыкмы, яхшылыкмы икәнен мин кайдан белим? — дидем.

Шәех миңа бер көзге һәм бер янчык бирде.

— Матурлыгын һәм кыяфәтен күргәннән соң, бу көзгене йөзенә каршы тотарсың. Әгәр күңеле саф булса, көзгедә дә саф күренер. Әгәр күңелендә берәр начар ният булса, көзге томанланыр. Бу көзгене хикмәт көзгесе диләр. Кирәк-ярагыңа шушы янчыктан алырсың, ул да хикмәтле янчык. Акчасы һич төкәнмәс,— диде.

Көзге һәм янчыкны алып, шәехнең кулын үбеп, саубуллашып чыгып киттем. Өч көн Мисырда торганнан соң, Димәшкъка таба сәфәргә чыктым. Бик күп шәһәрләр, бик күп авыллар аша үттем. Күп матур һәм гүзәлләрне очраттым. Ләкин һәрчак көзге томанлана иде.

Берәү:

— Син эзләгән кыз Бәгъдадта бар да бар инде. Ул тарафларга барсагыз, теләгегезгә лаек кызны, әлбәттә, табарсыз,— диде.

Мин Бәгъдадка юнәлдем. Бер бүлмә алып урнаштым да күңелемдәге кызны эзли башладым. Мин яшәгән мәхәлләнең имамы Хаҗи Бәкер дигән кеше иде. Кайбер кичләрдә сөйләшеп утырырга ул минем янга керә иде. Бер кич эчемдәге серне аңа сөйләдем. Шул мин эзләгән кызны табып бирсәң, бер янчык алтын бирер идем, дип вәгъдә иттем. Дөрес, андый кызны тапкан очракта, Мисырга кайтып, атам белән күрешмичә туй ясый алмыйм. Атам — Мисырда баш вәзир. Кызның әти-әниләре дә шул шартыма риза булырга тиешләр, дидем.

Имам бераз уйлап торды да:

— Хәлифәнең Насыйр исемле бер вәзире бар. Кайбер мәсьәләләрдә хәлифәнең хәтере калып, аны урыныннан төшерде, Насыйр фәкыйрьлеккә дучар булды. Аның 14 — 15 яшендә Шәһәрдил исемле бер кызы бар. Хатын-кызлар: «Дөньяда гүзәллектә аңа тиң килерлек кеше юк»,— дип сөйлиләр. Син теләгән кыз шул булса булыр, булмаса — таба алмассың,— диде.

Бу хәбәрне ишеткәч тә, имамның кулына ун алтынны салдым:

— Бу сиңа аяк ялы булсын. Барып атасыннан һәм кызыннан хәбәр алып кил, кабул итәрлек булсалар, миңа әйтерсең,— дидем.

Иртәгесе көнне имам килеп, кызның атасы белән очрашканын, аның риза икәнлеген сөйләде. Шундук мин аларның өенә киттем. Әтисе белән очрашып сөйләшкәннән соң, мине икенче бер бүлмәгә чакырдылар. Кыз шул бүлмәдә пәрдә астында утыра икән. Әтисе барып, кызның йөзеннән пәрдәсен

күтәрде, һичкемнең хыялына килмәс дәрәҗәдә матур, бу заманның Зөләйхасы дип әйтерлек бер гүзәл икән. Бер карауда ук эчемне-тышымны мәхәббәт уты чолгады. Бу тәмуг утыннан гакылым китеп, мәҗнүн булып калдым. Йөзе айга, кашлары җәягә охшаш. Шунда ук айнәи хикмәтне[1] чыгарып йөзенә тоттым, һичнинди томан күренмәде. Саф һәм гыйффәтле кыз икәненә ышандым. Аннан чыгып, этисенең кулларын үбеп:

— Бу фәкыйрегезне кияүлеккә кабул итсәгез лә,— дип үтендем.

— Без каршы түгел, Хак Тәгалә икегезгә дә озын гомер бирсен,— дигән өмидле җавапны ишеткәч, мин, туй расходларына дип, хикмәтле янчыкны аның кулына тапшырдым. Имам, мөәзин һәм мәхәллә җәмәгатен чакырып, шәригать кушканча, эшне рәсмиләштерү ягын тәмамладык. Менә монысына киемсалым алырсыз, дип, кирәк микъдарынча янчыктан тагын акча бирдем. Бер атнадан сәфәргә хәзер булсыннар дип үтендем.

Сәфәр кирәк-яракларын хәзерләп юлга чыктык. Юлда кызны тәхте рәванга[2] мендереп төшергәндә, ул, үзен минем кәләшем санап, йөзен яшерми иде. Аның гүзәллеге минем хыялымнан да бер минут та чыкмый иде. Мал һәм хәзинәләр дә, хәзинәдәге сурәтләр дә онытылды. Һәлак булырмын дип, шәех догасыннан гына курка идем. Шул рәвешчә, ах-вах итеп, Мисырга якынлаштык. Атларыбызны туктатып, бер җиргә төштек. Кызны, тәхте рәваныннан чыгарып, зонтик корып, шуның күләгәсенә утырттым. Серемне ачып, Мисырга аны бер шәехкә бирер өчен алып килгәнемне сөйләдем. Моны ишеткән бичара кызның такмаклап үксүләре һаваны селкетте. Яңадан тәхте рәванга утырттым да, Мисырга кердек. Шәехнең ишеген кактым. Бер җария чыгып ачты. Кызны шәех каршысына китердем.

Шәех:

— Вәгаләйкем әссәлам, углым, егетлек менә шул була ул, хезмәтеңне кабул кыйлдым. Фәлән урында нәфесеңә чыдамлык күрсәткән идең, нәфесеңне җиңгән идең. Шуңа мин бик шат булдым,— дип, көзгене һәм янчыкны сорады. Кайтарып бирдем.— Мисырда өч көн ял ит тә илеңә кайт, син теләгән сурәт хәзинәдәге өстәлең өстендә булыр,— диде.

Саубуллашып, кулын үбеп чыгып киттем. Мисырда өч көн торганнан соң, илемә кайтырга дип юлыма чыктым. Берника-

---

[1] А й н ә и  х и к м ә т н е — хикмәтле көзгене.
[2] Т ә х т е  р ә в а н г а — носилкага.

дәр сәфәр мәшәкатьләре күреп, ватаныма кайтып җиттем. Әни белән күрешеп, баштан кичкәннәрне аңа сөйләгәннән соң, хәзинәгә кердек. Сурәтсез өстәл өстендә сөеклем — Бәгъдад кызы Шәһәрдил утыра иде. Берникадәр вакытка һушым китеп, хәйран булдым. Мине күргәч тә, ул урыныннан сикереп торды, кулында бер кәгазь бар икән, шуны миңа бирде. Кәгазьдә шәех кулы белән: «Углым Габдесамат, мәрхүм этиең белән икебез сиңа бу язмышны күрсәтергә уйлавыбызның сәбәбе шулдыр: үзеңә яр эзләү юлында бераз авырлыклар һәм мәшәкатьләр күр. Үз күрмешең белән аңла: гыйффәтле кәләшкә ирешү хәзинәдәге өстәлгә дөнья бәһасенә торырлык сурәт табудан артыгррактыр. Ягъни шул өстәлгә бер сурәт табумы яки Шәһәрдил гүзәлне табуың артыгракмыдыр — үзең чамала. Инде ахыр гомереңә кадәр бу никяхлы хатының Шәһәрдилнең кадер-кыйммәтен белерсең».

Менә, шаһзадә әфәнде, хәзинәдәге бер өстәлдә сурәт булмауның сәбәбе шул. Ул өстәлдәге сурәт — сараебызның хуҗасы — Шивазадәнеңәниседер,— дип сүзен тәмам итте.

Бу хикәядән шаһзадә Асылның күңелендә яңа бер фикер туды: моның шикелле изге хатыннан туган кыз әнисе кебек үк гыйффәт иясeдер. Өч ел буе һәлакәткә разый булып, Шәмһаил дәгъваларын кире кагуы да шуны раслый. Мин аңа өйләнәчәкмен... Бу фикер торган саен аның күңелен ныграк биләде. Беркөн ул падишаһтан биш-ун көн сарайдан китеп торырга рөхсәт сорады: «Сәрандиб шәһәрендә бераз эшем бар иде, йомышымны үтәү белән, сарайга кайтырмын»,— дип вәгъдә бирде. Патша рөхсәт итте һәм шаһзадә өчен юл кирәк-яракларын хәзерләргә боерык бирде.

Шаһзадә әйтте:

— Борчылу һич кирәк түгел. Менә шул тора торган бүлмәмне биклим дә, симия[1] кувәте белән, үземә кирәк җирдә булачакмын.

Шаһзадә Асыл, Шәмһаилгә хәбәр бирер өчен, Җәваләне Җәблика шәһәренә җибәрде. Берничә минут үтмәстән, Җәвалә кайтып та килде, Җәблика шәһәрендә әфәндебезне көтеп калдылар, дип хәбәр бирде. Шаһзадә Җәвалә белән бүлмәсенең эченә кереп, ишекне эчтән бикләде. Җәвалә кулыннан тотып, күз ачып-йомганчы Җәблика шәһәренә ирештеләр. Барлык җеннәрнең рәисләре, гыйфритләрнең командирлары, диюләрнең, пә-

[1] Симия — алхимиклар идеясе нигезендә туган фантастик гыйлем.

риләрнең һәм башка рухани мәхлукатның башлыклары төркем-төркем гаскәр белән шаһзадәне каршы алырга чыктылар. Шәһәр капкасыннан патша сараена кадәр шаһзадәнең аяк астына кыйммәтле паласлар түшәлгән иде. Сарайда тиңе булмаган тәхет корылып, аның ике ягында муеннарына кызыл якуттан муенсалар таккан унар тиңсез гүзәл кызлар утыра. Шаһзадә килеп шул тәхеткә утырды. Гадәт буенча, сарайдагы халык шаһзадәне алкышлап, аңа мактау сүзләре әйттеләр. Шәмһаил шаһның күңеле куаныч һәм шатлык белән тулган иде. Аның бу куанычы Җәблика шәһәрен шул вакыйга уңае белән бизәтүләрендә дә күренә иде. Бу сәгатьтә шәһәр урамнарында ни рәвешле зәвык-сафа иткәннәрен, музыка уйнап, җырлаганнарын сөйләп бирергә телләр гаҗиз. Кыскасы, кырык көнгә кадәр зәвык-сафа кылганнан соң, шаһзадә Асыл Шәмһаилгә Сәрандиб солтаны Габдесаматның хикәясен һәм шул хикәядән соң үзенең Шивазадәгә өйләнергә ният итүен сөйләп бирде.

Шәмһаил:

— Әфәндем, Шивазадәнең гыйффәтен һәм акылын үз тәҗрибәсендә сынап күргән колыгыз сезгә ул көннәрдә үк бу киңәшне әйтмәкче иде. Әдәпсезлек булыр дип әйтмәгән идем. Инде, әфәндем, бу ниятне берүк кичектерә күрмә. Шивазадә әфәндемә лаектыр. Туй хәстәрләрен үзем күрермен, фәрман боерыгыз,— диде.

Шаһзадә, Шәмһаил белән саубуллашып, Сәрандибка кайтасы итте. Җәвалә шаһзадәнең кулыннан тотып: «Күзеңне йом!» — диде. Йомды. «Ач!» — диде, ачты, үзен Сәрандибтагы бүлмәсендә күрде. Шаһзадәнең кайтканын ишетеп, Сәрандиб солтаны аның янына килде. «Кайтуыгыз мөбарәк»,— дип, гаять зур кадер-хөрмәтләр күрсәтте.

Бер кичне ятар алдыннан шаһзадә Асыл Җәваләне Шивазадә янына җибәрде. Күңелемдәге яшерен серне аңа аңлат дип кисәтте.

Шивазадә, Җәваләнең кинәт кенә килеп керүенә бик шат булып:

— Әфәндебезнең сәламәтлекләре ничек? — дип сорады.

Җәвалә:

— Ханым, әфәндем мине сезгә махсус сәлам белән җибәрде. Күңелендәге яшерен серне әйтергә кушты,— диде.

Шивазадә, көтелмәгән бу хөрмәтләүгә хәйран булып, шатлыгыннан теле тотылып, бу Җәвалә үртәп сөйли микән яки чын микән, дип, аны кабат сөйләтеп күрсәтте.

Җәвалә:

— Шаһзадә теләмәгән нәрсәне сөйләргә колыгызның ни кодрәте бар. Ул шикне күңелегезгә дә кертмәгез. Шаһзадә әфәнде бу серне нинди юл белән падишаһ хәзрәтләренә җиткерү турында сездән киңәш көтеп калды,— дигәч, Шивазадә:

— Әфәндемнең аяк астында туфрак булыйм, ул, мине хатынлыкка кабул итеп, зур хөрмәт күрсәтә. Бу хәбәрне әти-әниемә җиткерүне мин үз өстемә алам,— дип, Җәваләне кайтарып җибәрде.

Иртән Шивазадә, әти-әнисе янына барып, шатлык белән әйтте:

— И олы дәүләтле атам, бу кичә илаһи бер төш булгандырмы, син шаһзадәгә тормышка чыгарсың, дип хәбәр иттеләр. Бу — чын төш икәненә шөбһәм юктыр. Бу хакта сезнең белән сөйләшүне шаһзадә миннән үзе үтенгән.

Шивазадәнең бу хәбәреннән күңеле гаять күтәрелгән падишаһ, шаһзадәгә аерылышу куркынычын сылтау итеп:

— Ах әфәндем, кяшки Хак Тәгалә хәзрәте әфәндем белән күрешү бәхетеннән мәхрүм итмәскә берәр сәбәп булдырса икән. Бу мине чиксез шатландырыр иде. Һәрни булса да, мин шундый сәбәп турында баш ватам. Хак Тәгаләнең әмере белән Шивазадәне җариялеккә кабул итүегездән башка берәр сәбәп таба алмыйм,— диде.

Шаһзадә елмаеп:

— Сөбханаллаһи, минем күңелемдә дә шул ук фикер иде. Берничә көн инде шул ук хакта уйлап йөрим. Алла моны һәр ике тарафка да хәерле кыйлсын,— диде. Бу хәбәрдән күңеле яктырып киткән шаһ, бу туй өчен махсус сарайлар бина кыйлырга кирәк булыр, дип уйлап торганда, шаһзадә:

— Солтаным, шул уңай белән сарай төзү турында уйлыйсыз кебек. Шәһәр тышында ике сәгатьлек җирдә бәндәгезнең күңел юатырлык сарайлары бар. Туйны шунда уздырсак ничек булыр? Сез туй хәстәрен күрмәгез. Билгеләгән вакытка һәммәсе хәзер булыр, һич борчылмыйча, зәвык-сафада булыгыз,— диде.

Шәһәр тышында шаһзадә әйткән сарайлар юк иде. Ләкин аның симия куәте белән андый сарайларны булдыра алуына ышанган патша бу хакта сүз озайтып торуны кирәк дип тапмады. Кич белән шаһзадә, Шәмһаилне чакырып: «Шәһәр тышында фәлән җирдә бер олуг һәм гүзәл шәһәр бина кыйлынсын. Җиде көндә барлык кирәк-яраклары белән хәзер булсын»,— дип әмер итте. Шәмһаил: «Әфәндем, һәммәсе хәзер!» — дип җавап биргәннән соң, шаһзадә, вәгъдәләшкән вакыттан бер көн элек патшаны чакырып:

— Бу кичә бәндәгез үз сараена китмәкче. Сезне һәм каенанамны, киленне, вәзир-вөзәраны, барча байлар һәм фәкыйрьләр, ирләр һәм хатын-кызларны — бөтен шәһәр халкын, һичберен калдырмыйча, туй мәҗлесенә чакырам. Шәһәр урамнарына игълан итүчеләр җибәреп, бу чакыруымны халыкка ишеттерегез, һичкем килми калмасын,— диде.

Шул кичәдә шаһзадә симия шәһәренә күчеп китте. Сәрандиб шәһәренең халкы, иртән торып, туйга хәзерләнделәр. Патша сараеның тәрәзәләре сахрага караган иде. Сарай әһеле барчасы: «Илчеләр килә микән?» — дип карашып торганда, күрделәр ки, бер урда микъдары гаскәр килә. Гаскәр алдында — байрак һәм әләмнәр. Алар артында — фил өстенә куелган тәхеттә йөзе айдай гүзәл бер патша. Аның артында — зиннәтләп иярләнгән илле мең аргамак, алтын-көмештән ун мең тәхте рәван — барчасы шәһәргә таба кодаларны алмага килеп торырлар. Алар, шәһәргә якынлашып, тиз арада патша сараена да килеп җиттеләр. Патша белән патша күрешкәндәге тәбрикләшүләрне җиренә җиткергәннән соң, шәһәр халкын берәм-берәм атларга утырта башладылар, һәр өйгә берәр тәхте рәван һәм өчәр ат билгеләп, өй хуҗасын, җәмәгате һәм балалары белән, берәүне дә калдырмыйча, туй шәһәренә алып киттеләр. Анда тагы моңарчы күрелмәгән хөрмәтләүләр белән кодаларны каршы алырга чыкканнар иде. Шәһәр капкасыннан чыккач та юлның ике ягына йөзәрләгән хөрмә агачлары үстергәннәр. Кыйммәтле ташлар һәм төрле бизәкләр белән бизәнгән, дөньяда тиңе булмаган гүзәлләр, алтын кушаклы, көмеш йөгәнле атларда кытай атласыннан тегелгән киемле җайдаклар, барабан сугып: «Хуш киләсез, мәрхәбә!» — дип торалар. Аларның аргы ягында — алтын иярле атларга атланган, кулларына сөңге тоткан егетләр. Меңләгән төрле байраклар сахраны каплап алган... Алар артыннан ике йөзләп зифа буйлы гүзәл җарияләр җәүһәрләр белән зиннәтләнгән киемнәрдә утыралар, һәрберсенең кулларында берәр тартма. Тартмалары кеше күзе күрмәгән кыйммәтле энҗе һәм төрле төсле якутлар белән туп-тулы. Сәрандибтан килгән кодагыйларга һәм кодачаларга төрле зиннәтләр: беләзекләр, йөзекләр, алкалар, бау-бау чәчәкләр, сөрмәләр һәм ислемайлар, каптырмалар, тараклар, сәгатьләр тәкъдим итеп торалар. Аларның артында шаһ Җәмшид дәрәҗәсендә җитдилек һәм мәһабәтлек күрсәтеп, алтын тәхетләрдә унике патша утыра. Алардан артта сыйфатлау һәм аңлатып бирү мөмкин булмаган дәрәҗәдә олы алтын тәхет өстендә руханилар патшасы Шәмһаил утыра. Аның тәхетен ике йөз гыйфрит күтәреп

торалар. Тагын шундый ук ике тәхет китерделәр. Берсе махсус Сәрандиб солтаны өчен хәзерләнгән иде. Җәүһәрләр белән бизәлгән икенче тәхет хатын-кызлар өчен ясалган иде. Бу тәхетләрне гаҗәп матур йөз пәри күтәреп торалар. Аларның артында дөньяда булган музыка кораллары хуш авазлар белән һаваны яңгыратып торалар. Алардан соң — сүз белән аңлатуы мөмкин булмаган төрле әкәмәтләргә бай күренешләр. Шәмһаил шаһ, Сәрандиб солтаны якынлаша башлагач, тәхетеннән төшеп, аңа каршы килде. Габдесамат шаһ та җәяүләп аңа каршы атлады. Сәламләшкәннән соң Шәмһаил, ике кулын күтәреп, Габдесаматны мактау йөзеннән:

— И шаһлар шаһы, солтаннар солтаны, дөньяда Сөләйман милкенең варисы, барлык патшаларга боерык биреп торучы әфәндебез хәзрәтләре, сезне тәбрикләп, тулы хөрмәтләү һәм олылау белән үз каршысына чакырырга боердылар,— диде.

Бичара Габдесамат шаһ килүченең кем икәнен аңлады. Бераз әңгәмәдән соң килгән кунакларның һәммәсе үзләренә билгеләнгән бүлмәләргә таралыштылар. Кода-кодагый һәм киленне каршылаулар аеруча тантаналы рәвештә оештырылган иде. Бу симия шәһәрендә халыкка күрсәтелгән сый-хөрмәтләрне сөйләп аңлатырга сүз җитми. Сәрандиб халкыннан шул мәҗлестә булган бер фәкыйрь адәм үзенә күрсәтелгән хөрмәтләр турында болай сөйләгән иде:

— Мине һәм ике балам белән җәмәгатемне, тәхте рәванга утыртып, ун бүлмәле бер йортка китерделәр. Атлас тун кигән егермеләп ага, каршы чыгып, култыклап, югары катка менгерделәр. Зиннәтле сарайда тәхеткә утырттылар. Каһвә һәм чәй китерделәр. Ул агалардан да яхшырак киенгән тагын бер ага килеп керде. Мин эчемнән: «Бу йортның хуҗасы шулдыр инде»,— дип уйлап куйдым, ә ул исә хезмәтче агаларның башлыгы гына икән. Ул, килеп итәгемне үбеп: «Әфәндем, мунча әзер, кереп чыгасызмы?» — дип сорады. Олылап, хөрмәтләп, чишендереп мунчага керттеләр. Юындырып, яңа нәфис атлас киемнәр кидерделәр. Аннан соң икенче бер сарайга китерделәр. Анда фарфор һәм көмеш савытлар белән төрле ашамлыклар әзерләнгән иде. «Җитешегез»,— дип ишарә иттеләр. Мин ашаганда, карап туйгысыз унлап музыкант тәэсирле көйләр уйнарга башладылар. Мондый нигъмәтләр һәм мондый тәэсирле көй оҗмахтан башка җирдә булуы мөмкин түгел. Аннан соң төрле фокусчылар, кош сугыштыручылар һәм жонглерлар үзләренең һөнәрләрен күрсәтә башладылар. Кич булгач, тагын шул рәвешчә табын әзерләделәр. Ашаганнан соң, бер ага килеп: «Әфәндем, җәмәгатегез яны-

на кайтасызмы?» — дип сорады. Хатыным һәм балаларым башка бер бүлмәдә булганга, аларның хәлен белешү уе күңелемдә бар иде. «Бик әйбәт булыр иде»,— дигәч, әлеге ага, алдыма төшеп, мине җәмәгатем янына китерде. Хатыным һәм балаларымның да төрле нигъмәткә чумганнарын күрдем, кәефләрен сораштым. Нәкъ миңа булган кадер-хөрмәтне аларга да күрсәткәннәр икән. Шул хакта сөйләштек, гаҗәпләнеп хәйран калдык. Иртәгесен тагын шулай. Нигъмәтләр тезелгәч, хезмәт күрсәтүче хатыннардан: «Шәһәрдәге дусларым белән монда күрешү мөмкин булыр микән?» — дип сорадым. «Әфәндем, тәхте рәван әзер. Кайсысын күрергә телисез, боерыгыз»,— диделәр. «Якын дусларымнан бер су ташучы бар. Аны беләсезме?» — дидем. «Беләбез, әфәндем, беләбез»,— диделәр. Сарайдан чыктык. Иярләнгән бер хайван тора икән, шуңа атланып, бер биек сарайга килдек. Баскычтан югары күтәрелдек. Дустым белән күрешеп, хәл-хәбәр сораштык та башка дус-иш белән очрашасы иттек. Сөйләшеп аңлашсак, һәммәбезгә бер үк төрле кадер-хөрмәт күрсәтелә икән. Утыз-кырык көн шул хәлдә яшәдек. Бу нигъмәтнең бер чиге булырмы, дип хәвефкә төштек. «Бу бәхетле көннәр тәмам булыр микән?» — дип, хезмәтчеләр башлыгыннан сорадым. Ул: «Әфәндем, бу туйның тәмамланачагы юк. Бу сарай да сезнекедер. Гомерегез буенча кәеф-сафа күрегез»,— диде.

Менә бу — шәһәрнең иң түбән катлау кешесенә күрсәтелгән хөрмәт. Шаһзаденең каенатасы Габдесаматка, каенанасына һәм вәзирләргә күрсәткән кадер-хөрмәтне исә сөйләп аңлату да мөмкин түгел. Кыскасы, солтан, сараеннан чыгып, әлеге гаскәрләр һәм Шәмһаил белән сөйләшкәннән соң, шәһәр тарафына юнәлде. Ярты сәгатьтән соң ул бер үр янында олуг һәм биек шәһәр күрде. Шәһәрнең коймасы уттан ясалган. Бу утның яктылык нурлары һавага ашкан иде. «Шәһәрдә янгын чыкканмы?» — дип, шаһ моның хикмәтен Шәмһаилдән сорады.

Шәмһаил:

— Юк, бу әфәндебезнең падишаһлык сарайлары шулай күренә,— диде.— Бу сарайның ишекләрендә һәм стеналарында булган кыйммәтле лампалар һәм җәүһәрләр ялтыравы шулай нур чәчә. Ут түгел ул,— диде.

Габдесамат һәм аның вәзирләре бу гаҗәпкә хәйран калдылар. Сарайга якынлаштылар. Күрделәр: башларына ике мөгезле алтын таҗ кигән меңләгән каравылчылар һәм берничә мең атлы сакчылар саф-саф булып торалар. Өсләрендә махсус киемнәр. Шәмһаил ике яктагы халыкларга сәлам бирде. Сарай капкасына килеп җиттеләр. Хисапсыз хезмәтчеләр патшаларның

килүен көтеп торалар иде. Шәмһаил шаһ һәм башка шаһлар тәхте рәваннарыннан төштеләр. Шәмһаил шаһ боерык бирде. Шунда ук кыйммәтле ташлар белән бизәлгән тәхет китерделәр. «Бөтен дөнья падишаһы солтан Габдесамат хәзрәтләре утырсыннар да, кадерләп һәм олылап күтәрегез»,— дип, Шәмһаил әмер итте. Солтан Габдесамат тәхеткә утырды. Шаһлар һәм вәзирләр камил әдәп белән беренче капкадан үтеп, бер мәйданга ирештеләр. Мәйдан сирәк очрый торган кораллар таккан гаскәр белән тулы иде. Аннан үтеп, икенче капкага килделәр. Аны үтеп, тагын бер олы мәйданга килеп чыктылар. Бу мәйданга исәпсез-хисапсыз дәүләт олылары һәм патшалык хезмәтчеләре җыелган иде. Сарай хезмәтчеләре башлыгы шулчак килен утырган тәхетне кияү сараена таба алып үтте.

Солтан Габдесамат, Шәмһаил шаһ һәм башка патшалар өченче капкадан үттеләр. Бер киң һәм иркен мәйданга килеп чыктылар. Мәйдан сансыз арыслан, каплан һәм башка бик күп күз күрмәгән киекләр белән тулы иде. Алар һәммәсе дә көмеш чылбырлар белән бәйләп куелган иде. Аннан үтеп, бер бикле капка алдына килеп туктадылар. Капка ачылып китте. Һәммәсе итәкләрен җыеп, акрын-акрын гына басып, әдәп белән эчкә уздылар. Бу бер зур зал иде. Залның дүрт стенасы яшма һәм лазурь белән, гөмбәз-түшәмнәре рубин белән, мебельләре алтын һәм көмеш белән зиннәтләнгән. Санап бетергесез гүзәл җарияләр, икенче тарафта нәфис киемнәр киенгән сарай агалары, әдәп белән аяк астына гына карап, боерык көтеп, җансыз сурәт кебек басып торалар. Залның түрендә җәүһәрләр белән бизәлгән гаять зиннәтле бер пәрдә бар иде. Патшалар һәм вәзирләр һәммәсе үзләренә тиеш урыннарында торалар. Шәмһаил шаһ пәрдәгә якын сул тарафтан урын алды. Габдесамат шаһ утырган тәхетне пәрдәнең уң тарафына куйдылар. Ярым сәгать микъдары сөйләшмичә һәм тын гына алларына карап, түбәнчелек белән шаһиншаһ шаһзадә Асылның күренүен көтеп тордылар. Бервакыт сарай эчендә барабаннар кагып җибәрделәр. Шунда ук пәрдә ачылып китте, һәм тәхет өстендә таҗ һәм патшалар киеме кигән шаһзадә Асыл, күренде. Залга җыелган барлык патшалар, вәзирләр һәм дәүләт олылары, җир үбеп, аны тәбрик иттеләр. Шаһзадә Асыл, каенатасына илтифат күрсәтеп, башта аңар эндәште. Соңра башка шаһларга кунак булып килүләре өчен рәхмәтләр белдерде. Шуннан соң табын хәзерләргә боерык булды. Хезмәтчеләр кунаклар алдына алтын-көмеш савытларда нигъмәтләр китерделәр. Аштан соң төрле ислемайлар сибеп, кунакларның күңелләрен күтәрделәр. Шуннан соң вә-

зир-вөзәра һәм дәүләт олылары һәркайсы үзләренең урыннарына утырдылар, никях уку башланды. Шивазадәне бер хәзинә мәһәр бәрабәренә шаһзадә Асылга хәлял җефетлеккә бирделәр. Догадан соң һәркемнең дәрәҗәсенә күрә бүләк итеп кыйммәтле киемнәр китерделәр. Шуннан соң зәвык-сафага рөхсәт бирелде. Мәҗлес таралып, Шивазадә белән шаһзадә Асыл кавыштылар. Болар монда адәмнең хыялы ирешмәгән зәвык һәм сафада булсыннар.

## Шаһзадә Насыл кыйссасы

Килик шаһзадә Насыл кыйссасына. Борадәре[1] Асыл диңгез белән Чин тарафына юнәлгән көнне шаһзадә Насыл да Исфаһан тарафына сәфәр чыкты. Бәсрадән ун көннәр киткәч, көтмәгәндә меңләп юлбасарлар каршыларына чыктылар. Шаһзадә Насыл белән булган кешеләрнең һәммәсен кырып, үтереп, малларын талап алдылар. Ялгыз үзе калган бичара шаһзадә өч көн, өч төн тауларда һәм сахраларда гизеп йөрде. Ниһаять, алда бер шәһәр күренде. Шаһзадә ул шәһәргә керде. Кая барырга белмичә, бер мунча янына туктап: «Бу шәһәр турында сорашып чыгыйм әле»,— дип, мунчага керде. Бераз ял иткәннән соң, мунчачыларның берсеннән сорап, бу җирнең Кәшмир шәһәре икәнен белде. «Бу шәһәрдә юлаучылар кунып чыгар өчен мөсафирханә бармы? Булса, ул кайсы тарафта, кайсы урамда?» — дип сорады. Кирәкле белешмәләр алганнан соң, мунчадан чыгып, мөсафирханә урамына барырга дип торганда, хатыннар мунчасыннан дөньяда тиңе юк бер гүзәл хатын чыкканы шаһзадәнең күзенә чагылды. Шаһзадәнең аяк атларга такате калмады. Насыл үзе дә чибәрлектә тиңсез егет санала иде. Әлеге гүзәл дә, шаһзадәне күреп, күңеленнән шунда ук аңа гашыйк булды.

Гүзәлнең гашыйк булганын сизгән шаһзадә:

— Әйдә, абыстай, мине үзеңә алып барсана,— диде.

Хатын да, һич тә оялмыйча:

— Юк, әфәндем. Хатыннар ирләрне үзләренә алмыйлар, бәлки ирләр хатыннарны үзләренә алалар. Хатыннар ирләрне алганнарын кайда күргәнең бар? Синең өеңә барыйк,— диде.

Бичара шаһзадә, «хәзер генә ят җирдән килдем, үземә дә кунып чыгарлык урын хәзерләгәнем юк» дип хәйран булып, бе-

[1] Борадәре — ир туганы.

раз фикердә торды да борылып мөсафирханә тарафына китте. Бер-ике урам киткәч, артына әйләнеп караса, баягы хатынның күләгә сыман артыннан ияреп килүен күрде. Шаһзадә: «Ләхәүләә!» — дип, хәтта бара торган тарафын ялгышты. Үз-үзенә ачуланып, һи, ахмак, үз башыңны илтеп тыгарга бер урының юк, танымаган, белмәгән хатыннарга сүз кушкан буласың тагын дип уйлап, борылып икенче тарафка йөз тотты. Ахшамга ярты сәгать калганчы шулай урамнар буенча йөрде. Йөри торгач, бер тупикка килеп керде. Алга узарга юл юк. Кире әйләнеп чыгыйм дип артына борылса, баягы хатын да янына килеп җитте. Урамның шаһзадә туктаган читендә гаять олы бер капка бар иде. Капканың ике ягына скамьялар куелган. Шаһзадә барып, бер скамьяга утырды. Хатын да икенче скамьяга урнашты.

— Җаным, капканы ач, эчкә керик,— диде ул.

Бичара шаһзадә:

— Капканың ачкычы хезмәтчедәдер. Ул бер йомыш белән киткән иде. Бер-бер вакыйга булгандыр. Инде бүген кайтмаса кирәк. Үземә дә бу кич берәр җиргә барып кунарга туры килер, ахры,— дип җавап кайтарды.

Хатын:

— Бу ни дигән сүз. Ә мин хәзер кая барыйм? — дип, ахвах итеп, җирдән бер таш алды да ачу белән ишекнең йозагына сугып ватты.

Шаһзадә Насыл, шул йозакны төзәтә калган булып, хатынга:

— Бар, син югарыга менә тор,— диде.

Югарыда берәр гауга күтәрелсә, качмакчы булып, бераз вакыт шаһзадә ишек төбендә тыңлап торды. Әмма эчтән тавыш-тын ишетелмәде. Гайрәт итеп шаһзадә дә югарыгы катка күтәрелде, җәннәт сараедай бер зур залга килеп керде. Залның тирә-ягында тагын унлап бүлмә бар икән. Хатын шул бүлмәләрнең берсенә кереп утырган иде. Зал уртасында гүя бер зур мәҗлес өчен табын әзерләнгән иде. Шаһзадә Насыл бер шәм кабызып алды да, ашханәне карап килү сылтавы белән, һәммә бүлмәләрне һәм түбән катны да әйләнеп чыкты. Өйдә һичбер адәми зат юк иде. «Гаҗәп, бу ни хәл булыр»,— дип уйлап, хатын янына килеп утырды. Хезмәтчесе кайтмаганга борчылган кыяфәт күрсәтте. «Тукта, ни булса булыр»,— дип, хатынны табынга чакырды. Табында шәраблар да бар иде. Ашап-эчеп, бераз кәефләнгәч, хатын белән зәвык-сафага мәшгуль булдылар.

Бу өй, асылда, Кәшмир патшасы Фәйруз шаһның өе иде. Фәйруз шаһ зәвык-сафа сөюче бер патша иде. Кичләрен, сурәтен

үзгәртеп шәһәр урамнарында йөргән вакытта, бу йортка кереп ял итә иде. Бу өйнең һәрвакыт хуҗасын кабул итәргә хәзер торуының сәбәбе шул иде. Фәйруз шаһ бу кичәдә дә, сурәтен үзгәртеп, шәһәр гизәргә чыкты. Урамнарда йөреп арыганнан соң, бу өйгә кереп ял итмәкче булды. Өйгә якынлашкач, бүлмәләрнең берсендә ут януын күрде. Капкадагы йозак та ватык иде. Гаҗәпкә калып, колак салып тыңлап торды. Җыр һәм хатын-кыз авазы ишеткәч, болар караклар түгелдер, дип уйлады. Үзе белән бергә йөргән кешеләргә: «Сез монда гына торыгыз»,— дип, Фәйруз шаһ ялгызы гына өйгә кереп китте. Шаһзадә Насыл белән хатын утырган бүлмәнең ишеген акрын гына ачып карады. Күрде: гүзәл бер хатын белән бер егет һич хәвеф-хәтәрсез зәвык-сафа кыйлып утыралар.

Ул арада шаһзадә:

— Тукта, бер тавыш бар. Анда кемдер килде бугай,— дип, урыныннан торып, бүлмәдән чыкты. Фәйруз шаһ баскыч артына яшеренде. Шаһзадә караңгыда бер кеше күреп, бик каушады, һуштан китеп егыла язды.

Фәйруз шаһ аңа шыпырт кына:

— Кил, кил, әфәндем. Курыкма,— диде.

Ни булса булыр дип, шаһзадә аның янына барды. Икәү икенче бер бүлмәгә керделәр.

Фәйруз шаһ:

— Борадәр, син монда нишләп йөрисең? Турысын сөйлә. Бу хатын кем? — дип сорады.

Шаһзадә:

— Ә син үзең кем буласың? — дип сорады.

— Мин бу өйнең хуҗасы. Синең монда килүеңә бик шатландым. Әмма сереңне миннән яшермә. Ни өчен бу өйгә килеп кердең? — диде.

Шул караңгы бүлмәдә шаһзадә башыннан үткән вакыйгаларны, ничек булганынча, түкми-чәчми сөйләп бирде. Фәйруз шаһ кәеф-сафага күңел куючы 23 яшьләрендәге бер егет иде. Шаһзадәнең курыкмыйча ят бер җирдә ят хатын белән кәеф-сафага керешүенә күңеле килеп:

— Сез хәзер эчкә керегез, кәеф-сафагызны дәвам иттерегез. Мин сезнең хезмәтчегез булып килеп керермен. Кычкырып, хурлап мине орышыгыз. Таң атканчы мин сезнең хезмәтчегез, колыгыз булыйм. Иртән без бу хатынны җибәрербез, сез минем кунагым булырсыз. Әмма мине хатын ышанырлык дәрәҗәдә каты итеп сүгегез. Колыгыз иканенә шиге калмасын,— диде.

Шаһзадә, рәхмәт әйтеп, өй хуҗасының кулын үпте дә хатын утырган бүлмәгә керде. Кабат баскычтан кеше менгән тавыш ишетелде.

Шаһзадә гайрәтләнеп:

— Кем бар анда! — дип аваз салгач:

— Әфәндем, мин — колыгыз,— дип, хезмәтче сурәтендә Фәйруз шаһ бүлмәгә килеп керде.

Шаһзадә ачу белән:

— Бу вакытка кадәр кайда иден, кайда йөрдең, хәсис? — дип кычкырды.

— Җибәргән кешегезне өйдә очратмадым. Көтеп торып соңга калдым. Көтә-көтә алҗып беттем,— дигән җавапны ишеткәч, хатынның да ачуы чыгып, колны кыйнамакчы булып һөҗүм итте. Колны хатын кулыннан коткарып калыр өчен шаһзадәгә байтак мәшәкать чигәргә туры килде. Кыскасы, ул-бу булмыйча гына төнне үткәрделәр. Иртән хатынны озатып җибәрделәр.

Фәйруз шаһ шаһзадәгә:

— Бер эшем бар иде. Тиздән килермен. Монда калып тор,— дип чыгып китте.

Ярты сәгатьләр узгач, биш-ун хезмәтче бер зиннәтләнгән ат җитәкләп килделәр. «Боерың, әфәндем!» — дип, шаһзадәне атка атландырып алып киттеләр. Шаһзадә, хәйран булып бара торгач, патша сараена килеп чыкканнарын күрде. Аны бер зур залга керттеләр. Залның түрендә — олы тәхет өстендә — төнлә танышкан кешегә охшаш берәүне күреп, Насыл һуштан китеп егыла язды. Кич белән булган хәлләр өчен күпме оялганын моны тыңлаган кеше үзе чамаласын.

Фәйруз шаһ шаһзадәгә бик зур кадер-хөрмәт күрсәтте. Аңа сараенда махсус бер бүлмә билгеләде. Шаһның шаһзадә Насылга мәхәббәте көннән-көн артты: бер сәгать ансыз тормас, һәрдаим күңел ача торган сүзләр, кәеф-сафа турында хикәятләр сөйләшеп юаныч табар иде. Кәшмирдән аның бабасының иле ерак түгел икәнен, теләгән вакытында анда бик җиңел бара алуын аңлатты. Әмма мөмкин кадәр Кәшмирдә үз янында калуын үтенде. Шаһзадә дә, Фәйруз шаһны бик сөеп, байтак вакытлар Кәшмирдә торуны кирәк тапты. Һәр көн махсус бер урында күңел ачып, зәвык-сафа белән вакытны үткәрделәр. Беркөн Фәйруз шаһ, шаһзадәне кайгылы күреп, сәбәбен сорашты. Шаһзадә әти-әнисен сагынуын, алардан аерым яшәүдән бик йончылуын белдергәч, Фәйруз шаһ:

— Әфәндем, әле сәфәр вакыты түгел, яз көннәре башлан-

сын, шунда юлга чыгарсың, дөньяда азмы-күпме михнәткә түзәргә кирәк. Шатлык һәм хәсрәт шундый инде ул: берсе килә, берсе китә, сабыр итү яхшы,— дигәч, Шаһзадә моңа:

— Әфәндем, Хак Тәгалә кайгы-сагыш бирмәсен, түзеп торулары бик мөшкел шул,— диде.

Фәйруз шаһ, бер аһ тартып:

— И дустым, бу сүзең минем кайгым юкка, ачы хәсрәт чикмәвемә шелтә кебек ишетелде. Аллаһы Тәгалә минем кайгымны сез дустыма түгел, иң яман дошманыма да бирмәсен,— диде.

Шаһзадә, урынсыз сүз әйтүен аңлап, оялып, Фәйруз шаһтан: «Ни хәсрәтең бар? Нинди кайгың бар?» — дип сорарга батырчылык итмәде.

Кич булгач, шаһзадәнең бүлмәсенә сарай хезмәтчесе килеп:

— Сезне әфәндемез чакыра, — дип, шаһзадәнең алдына төшеп, аны башка бер сарайга алып китте.

Анда Фәйруз шаһ шаһзадәнең кулыннан тотып, берничә заллар аша үтеп, бер бүлмә ишегенә килделәр. Фәйруз шаһ, ишекнең пәрдәсен бераз күтәреп: «Монда кил, тамаша кыйл!» — диде. Шаһзадә килеп карады: бүлмәнең түрендә бер тәхет өстендә дөньяда бер гүзәл хатын утыра. Аның үз гомерендә мондый гүзәл хатынны күргәне дә, андый кеше булуын ишеткәне дә юк иде.

Фәйруз шаһ шаһзадәгә:

— Син менә шунда торып күзәт әле,— дип, бүлмә эченә кереп китте. Бүлмәгә бер адым атлавы булды, гүзәлнең күзе Фәйруз шаһка төшеп, ул бер агарды, бер саргайды, төсе сула башлады. Фәйруз шаһ акрын-акрын аңа якыная барган саен, гүзәлнең чырае сытылып, хәлдән таюы арта барды. Фәйруз шаһ аңа өч адым җитмәстән, хатын куркынычлы бер кара тәнле кеше сурәтенә әверелде. Һушы китеп, тәхеттән егылып төшә дигәндә, җариялар тотып аны тәхетенә яткырдылар. Фәйруз шаһ аңа якын бара алмады. Утырып күп егълаганнан соң:

— И әфәндем, и солтаным, и минем Зөһрәм, кяшки Газраил җанымны алса да, синең бу хәлеңне күрмәсәм икән. Бер генә мәртәбә күзең ач та җәфа чигүче бу бичараңның йөзенә кара,— дип зар егълап, торып ишеккә таба юнәлде.

Ул ике адым атлауга гүзәл җанлану әсәрләре күрсәтә башлады, торып утырды. Фәйруз шаһ бер адым ерагайган саен, хатынның төсе һәм матурлыгы үз хәленә килер иде. Фәйруз шаһ ишек бусагасын атлавы белән, хатын тагын дөньяда тиңе булмаган гүзәлгә әйләнде. Фәйруз шаһ шаһзадәнең кулыннан тотып башка бүлмәгә чыкканнан соң:

— Менә, борадәр, моның кебек аеруча гүзәл хатын дөньяда тагын бар микән? Бу — минем хәлялем. Гыйшык һәм мәхәббәтенә грифтар булган хатыным. Бу хәлләрне сиңа теге сарайга кайткач, иртән аулакта сөйләп бирермен,— диде.

Ул кич, монда ни хикмәт бар икән, дип, шаһзадәнең күзенә йокы кермәде. Иртән Фәйруз шаһ шаһзадәне бер аулак бүлмәгә чакырды. Башындагы таҗны салып ташлады да кичәге вакыйганың серен сөйләргә кереште:

— Моннан биш ел элек, атам Хөсрәү шаһ фани дөньядан мәңгелек йортына киткәч, унсигез яшемдә мин атамның тәхетенә утырдым. Мәктәп-мәсҗетләр, гариппләр йорты һәм мөсафирханәләр салдыра башладым. Килгән-киткәнгә нигъмәт куйдым. Шул эшне башкарып торыр өчен махсус кешеләр билгеләдем.

Беркөн шулардан берсе, ишегемә килеп:

— И дөнья патшасы, дүрт-биш көн бардыр, шәһәребезгә нурлы йөзле бер карт килде. Аңа тиешле кадер-хөрмәтне күрсәттек. Пакь күренешенә һәм ак сакалына караганда, олылап ихтирам күрсәтүгә лаек бер кешедер. Шул карт: «Мине Фәйруз шаһ алдына илт, яшерен сүзем бар»,— дип үтенә. Рөхсәт бирсәгез, алып килер идем,— диде.

Рөхсәт биреп китерттем. Чыннан да, нурлы йөзле, күркәм бер карт икән. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, аңардан:

— Нинди үтенечегез бар? — дип сорадым.

Шәех миңа:

— Падишаһым, сез күрсәткән яхшылыклар һәм игелекләр башка патшалар тарафыннан эшләнмәгәнлеге дөньяга мәгълүмдер. Хак Тәгалә сезгә ул игелекләрне тагын да арттырырлык тәүфыйк бирсен. Ләкин үзегезнең һаман әле ялгыз, өйләнмәгән икәнлегегезне ишеттем. Бер аулак җирдә сезнең үзегезгә генә әйтәсе сүзем бар,— диде.

«Бик яхшы»,— дип, бер аулак бүлмәгә алып кердем.

Шәех сүз башлады:

— Әфәндем, Чин хаканы булучы Сәнҗар шаһның Зөһрә исемле бәхет йолдызыдай бер кызы бар. Гүзәллектә, үзен тотуында аңа охшаган берәү дә дөньяга туганы юк әле. Әфәндемә хатынлыкка шул кыз гына лаек булыр. Менә аның рәсеме,— дип, куенынннан бер сурәт чыгарып кулыма бирде.— Күпме көч куеп булса да шул кызны кулыңа төшерергә тырыш,— диде.

Картны озатканнан соң, сурәтне дикъкать белән карадым. Ул сурәт шулкадәр гүзәл сәнгать белән рәсем кыйлынган иде

ки, шунда ук гакылымны һәм сабырымны алды. Бик күп бүләкләр хәзерләп, вәзирләремнән берсен хаканга яучы итеп җибәрдем. Хакан чиксез куәт, хисапсыз байлык иясе иде. Көченә таянып: «Баламны ерак җиргә бирмим»,— дип, яучымны кире борып җибәргән. Көннән-көнгә гыйшкым һәм дәртем артып, сагыштан хаста булдым.

Беркөн вәзирем килеп:

— Падишаһым, бу кичә шәһәр тышында көтмәгәндә бер манара барлыкка килгән,— диде.

Мондый кыска вакыт эчендә, кеше көченнән башка барлыкка килгәнгә күрә, сихер һәм симиядән бер әсәр икәнен чамалап, ул тарафка кешеләр бармасын дип боерык бирдем. Өч көннән соң сараемның капкасына илле яшьләр тирәсендәге нурлы йөзле бер адәм килде. Гадәт кушканча, сәламләшкәч: «Син кемсең?» — дип сорадым.

— Әфәндем, мин шәһәр тышындагы манараның төзүчесемен,— дип җавап кайтарды. Утырттым. Каһвә һәм ширбәт китертеп сыйладым. Карт, үзенең күңелендә булган серләрен ачып: — Әфәндем, бәндәгез — мәгъриб икълименнән бер шәех. Исемем Фәррах. Егерме ел инде сәяхәттә йөрим. Ләһүр шәһәренә килеп-китеп йөрүче сәяхәтчеләрдән әфәндемнең тиңсез игелекле кеше икәнен ишетеп, күрешергә килдем. Симия гыйлемендә мәгърифәтемне белдерү өчен теге манараны бина кыйлдым. Ул хәбәр колагыгызга тиз ирешер дип уйладым. Әгәр дикъкать ияләреннән, гакыл ияләреннән икәнегезне үз күзләрем белән күрсәм, кулымнан килгән хезмәтемне аямам. Мине кире какмастан шулкадәр илтифат күрсәттегез. Манараны юк иттем. Инде мине дәүләтегез бәндәләреннән саный аласыз,— дип, тәхетемнең алдын үпте.

Мондый мәгърифәт иясенә хөрмәт күрсәтеп, хәтерен табудан башка чара юк, дип уйлап куйдым. Әгәр күңеленә хуш булмаган мөгамәлә кыйлынса, Алла сакласын, әлլә ниләргә таруыңны көт тә тор. Шул рәвешчә, намусымны саклап, аңа сараемнан урын билгеләдем. Гадәттән тыш татлы телле булганы өчен, ул һәрчак минем сөхбәттәшем иде. Үзенең искиткеч һөнәрләрен күрсәтеп, безне хәйран калдыра иде. Беркөн, ялгыз калып, яшерен серләремне һәм дәртемне аңа ачтым.

Җиңелчә генә елмаеп, ул:

— Әфәндем, минем өчен бу искитәрлек нәрсә түгел. Бер дә борчылмагыз. Сез беразга гына чыгып торыгыз,— диде.

Шундук икенче бер бүлмәгә кереп, бераз көтеп тордым. Ярты сәгать тә үтмәде: «Боерыгыз, әфәндем, рәхим итегез!» —

дип чакырып кертте. Бүлмәгә килеп керсәм, түрдә гыйшкым төшкән сурәтнең үзе — гүзәл кыз утыра. Карт кызны кулыннан тотып, минем алдыма китерде.

— Гыйшкың төшкән сурәт иясе шулмы? — диде.

Кызга исә:

— Кызым, бу кеше — Кәшмир падишасы Фәйруз шаһтыр. Әтиең сине аңа бирергә каршылык күрсәткән икән. Мин сине китертеп аңа тапшырдым. Син аңа хатын булмакны кабул итәсеңме? — диде. Кыз ихтыярсыз ризалык белдерергә мәҗбүр иде.

Карт:

— Инде мине никяхка вәкил ясагыз,— дип, тышка чыкты. Сарай хезмәтчеләрен чакырып килеп: «Шаһитләр булырсыз»,— диде. Мулла, голяма һәм мөәзиннәрне чакырып китереп, никях укытты, кырык көн туй мәҗлесе ясап, соңыннан зөфаф кичәсе хәзерләттем.

Зөһрә белән тора башладык. Зөһрә мине, мин Зөһрәне шулкадәр сөешә идек ки, бер-беребезне күрмичә бер сәгать тә түзә алмый идек. Шул рәвешчә ике ел үтте. Карт икебезнең дә әтиебез урынында йөри иде. Ул Зөһрәнең бүлмәсенә керә, иркенләп сөйләшеп утыра иде. Зөһрәнең матурлык һәм гүзәллекләренә карый-карый, карт шул дәрәҗәгә җитте ки, нәфесенә ияреп, беркөн күңелендәге серен Зөһрәгә ачып салды.

Саф күңелле, гыйффәтле, пакь Зөһрә, бичара:

— Әфәндем, мин һәм падишаһым сине әтиебез урынына санап йөрибез. Нәфес һәм дәрткә буйсынып, мондый килешмәгән адым ясау сиңа ярый торган эшме? — диде.

Карт бу сүздән бик гарьләнеп һәм оялып, Зөһрәнең йөзенә әфсен укып өрде дә шундук тәрәзәдән чыгып, төтен кебек һавада юк булды. Шулчак мин Зөһрәнең янына кердем. Зөһрәдә шул син күзәткән хәлне күрдем. Шул вакыттан бирле аның белән сөйләшү һәм киңәшү бәхетеннән мәхрүммен. Менә, газиз борадәрем, дәрт һәм кайгысы юк дип хисаплаган кешеңнең хәсрәтләренә кара да үзеңдәге дәрт һәм кайгыларны шатлыкка хисапла,— диде.

Шаһзадә Насыл, ун-унбиш көннәр Кәшмирдә торып, күргән хөрмәтләре өчен Фәйруз шаһка рәхмәтләр әйтеп, Исфаһан тарафына юлга чыкты. Моның кайту хәбәре Хаварзәм шаһка ишетелгәч, бабасы бөтен дәүләт олугларын оныгын каршы алырга чыгарды. Күп гаскәрләр белән каршылап, аны патша хозурына китерделәр. Патша, Насыл белән күрешеп сәламләшкәннән соң, углы Камәрҗанның сәламәтлеген һәм шаһзадәнең бу мәшә-

катьле сәфәрдә башыннан кичкәннәрен сорашты. Шаһзадә дә вәзирнең дошманлык белән шаһзадәләрне сәфәргә озаттырганын һәм башыннан кичкәннәрне сөйләп бирде. Хаварзәм шаһ аны Камәрҗаныннан да ныграк ярата башлады һәм үзенең тәхет варисы итеп билгеләде. Шул рәвешчә, берәр ай үткәннән соң, борынгы гадәтләр буенча, нәүрүз өчен Хаварзәм шаһ, шаһзадә, барлык вәзир-вөзәра һәм бөтен шәһәр халкы шәһәр тышына бәйрәмгә чыктылар. Чатырлар корылды, кыйммәт бәһале паласлар җәелде. Югары катлау һәм халык өчен төрле-төрле азыклардан сый хәзерләделәр. Ничә-ничә музыкантлар һәм җырчылар төрле җирләрдә күңелгә ягымлы көйләр уйнадылар, җырладылар һәм төрле уеннар күрсәттеләр. Шулчак кулына саф кызыл алтыннан ясалган ат тоткан бер һинди адәм патшаның чатырына якынлашты. Ул бу атның таң калырлык хикмәтләрен сөйләп бирде. Чыннан да, бу шулкадәр сәнгатьле итеп эшләнгән ат иде ки, аның ял һәм койрыклары, йоннары һәм тиресе нәкъ табигый атныкы кебек иде. Күпме дикъкать белән карасалар да, чын аттан һич аерма таба алмадылар.

Атның иясе һинди әйтте:

— Бу атның иң гаҗәп сәнгате шулдыр ки, атланып берәр тарафка бармакчы булсаң, өч айлык юлны бер көндә үтәдер,— диде. Шунда ук үзе атланып, һавага күтәрелеп, бер тарафка очып китте. Күп вакыт үтмәде, кабат патша сарае янына килеп төште. Бу гаҗәп хәлне күргән кешеләр хәйран калдылар. Патша бу һиндигә күп бүләкләр бирде.

— Һәрни теләсәң ал, син бу атны миңа сат,— диде патша.

Һинди әйтте:

— Әфәндем, бу ат бер сәбәп белән генә минем кулыма керде. Мин әле аның бәясен белмимен. Әмма миңа ул бик кыйммәткә төште. Ул бәяне миңа кем бирә алыр икән? — диде.

Җыелган кешеләр аңардан бу хәлнең тарихын сөйләп бирүне сорадылар.

— Мин фәкыйрьләр шәһәре халкыннан бер фәкыйрьмен. Мәхәллә мәсҗетендә мөәзинлек итеп тормыш күрә идем. Дөнья йортында тиңе юк бер гүзәл кызым бар иде. Гаиләмдә башка һичбер кем юк. Моннан утыз көн элек, икенде намазын укыгач, җәмәгать мәсҗеттән таралды. Тик бер карт кына халыктан аерылып соңга калды. Ул килеп, минем кулымнан тотты да: «Борәдәр, сиңа бер сүзем бар иде. Тик курыкма, тыныч фикер йөрт. Мин адәм баласы түгелмен, рухани бер затмын. Сиңа бер хәерле киңәш белән килгән идем»,— диде. Минем куркып, каушап кал-

мавымны күргәч, ул, кулымнан тотып, шәһәр тышындагы тау куышы — бер мәгарәгә китерде. Анда менә шул ясалма атны күрсәтте дә аның хасиятләрен, ничек итеп һавага күтәрелүен, ничек төшүен, ничек йөртү һәм ничек туктату кирәклеген миңа өйрәтте. «Бу атның дөньяда бәһасе юктыр. Минем кулыма бер сәбәп белән генә керде. Без рухани затбыз. Безгә ул һичнигә кирәкми. Мин аны синең белән алыштырыр идем»,— диде. Мин көлдем дә: «Мин фәкыйрь адәммен, минем һичнәрсәм юк. Аны нәрсәмә алыштырып алыр идем икән?» — дидем. Ул рухани әйтте: «Синең бернәрсәң булмаса да, кызың бар, аны миңа бирсәң, мин моны сиңа бирә алам,— диде.— Ләкин саклан, алтынга кызыгып, бәһасен төшермә. Әгәр кадерен белсәң, үзе кадәр йөз алтынга сатарсың»,— диде. Күп фикерләп, күп уйлаганнан соң, нәфесем мине риза булырга мәҗбүр итте. Килешкәннән соң, куеныннан кәгазь-каләм чыгарып: «Инде бу килешүебезне менә бу кәгазьгә яз», — диде. Мин язып кул куйдым. «Атны алып, өеңә китә аласың»,— диде дә күздән гаиб булды.

Өйгә кайттым. Кызым юкка чыккан. Үкенеп бик күп егъладым, үкенү файда итмәвен төшендем. Атны үз шәһәремә алып кайтсам, моны син кайдан алдың, дип аптыратасыларын беләм. Сезнең җумартлыгыгыз һәм гаделлегегез дөньяга мәшһүр. Бу ат кадерен белсәгез, сез, падишаһым, белерсез, дип, хозурыгызга килдем. Теләгегез булса, сезгә, атның үзеннән ун мәртәбә артык алтын бирсәгез, сатам,— диде.

Шаһзадә Насыл, атка бик кызыгып:

— Бабакаем, зинһар, алыйк. Бәһасеннән торма,— дип ялынгач, Хаварзәм шаһ атны алырга риза булды. Шаһзадә атны үз чатырына китерде. Һиндидән атны йөртү, туктату һөнәрен өйрәнде. Атның җилкәсендә бер ачкыч кебек нәрсәсе бар икән. Шул ачкычны тартсаң, ат һавага күтәреләә. Ачкычны бассаң, ат җиргә төшә. Уңга тартсаң, уңга, сулга тартсаң, сулга борыла иде. Ачкычны кулдан җибәрсәң, хәрәкәтсез кала. Шаһзадә Насыл, йөртү, туктату кагыйдәләрен өйрәнеп алганнан соң, тәҗрибәдә кулланып күрмәкче булып атка атланды. Әмма ачкычны тотып ул шулкадәр көч белән тартты ки, ат күз ачып йомганчы бер фәрсәх[1] һавага күтәрелде.

Һинди:

— Бик тартма, — дип кычкырды, әмма һава шаулаганга күрә, шаһзадә моны ишетмәде. Куркуыннан күзен йомып, ике

[1] Фәрсәх — ераклык үлчәве (6—7 километр чамасында).

кул белән ябышып, һаман ачкычын тарта иде. Шаһзадә һавада күздән югалгач, өч-дүрт сәгать көткәннән соң, Хаварзәм шаһ, онығыннан аерылганын аңлап, һиндине бик орышты.

Үзе:

— Ай-вай, нәүрүз көне шатлыкларыбыз матәмгә әйләнде ләбаса,— дип егълый иде.

Дүрт-биш көн шул җирдә торып, шаһзадәнең кайтуын көттеләр. Тирә-якка кешеләр җибәреп эзләттеләр. Әмма шаһзадәдән һич хәбәр юк иде. Барча халык шәһәргә кайтып, өсләренә кара киеп, матәм тоттылар. Алар матәм тота торсын, без килик шаһзадә хәленә.

Шаһзадә, коты очып, өч сәгатьләр чамасы күзен ачмады. Соңыннан гакылын җыеп: «Әгәр болай күземне йомып китсәм, мине бер хәтәр җиргә төшерер. Юкка күземне йомдым»,— дип, күзен ачты. Күккә ул шулкадәр югары күтәрелгән иде ки, һавадан башка тирә-якта һичнәрсә күренмәде, һиндинең өйрәткәнен хәтергә төшереп, ул ачкычны аска басты. Ат түбән төшә башлады. Уңга, сулга тартып карады. Теләгән якка бору мөмкин икәнлеген күрде. Тизлекне арттыру да, акрынайту да мөмкин икән. Җиргә төшәргә карар итте. Өч сәгать төшкәннән соң, үзенең бер шәһәр өстенә якынлашканын күрде. Кояш батып килә иде инде. Акрын-акрын гына түбәнәеп, бер сарай түбәсенә төште. Һушын җыеп, караңгылыкта тирә-ягына каранды. Керергә бер урын табылмас микән дип торганда, бер баскыч күрде. Акрын гына менеп, бер ишек төбенә килеп туктады. Монда кем бар икән, дип ишекне ачты. Патшалар гына тора торган гүзәл бер бүлмә күрде. Бүлмә кыйммәт бәһале түшәкләр һәм төрле әйберләр белән җиһазланган иде. Бүлмәнең түрендә әгъла[1] түшәктә гүзәл бер кыз ята. Матурлыкта, гүзәллектә Фәйруз шаһның җәмәгатеннән ун мәртәбә гүзәлрәк. Кызның тирә-ягына унлап җарияләр урнашкан. Озак уйлап торганнан соң, шаһзадә «җарияләрне уятмыйча, кызның үзенә хәлемне аңлатып бирү яхшырак булыр. Чөнки җарияләрнең берәрсен уятсам, ул мине карак дип белер дә шау-шу күтәрер» дигән карарга килде. Акрын-акрын гына кызның түшәгенә якынлашты. Уятырга куркып, озак кына кызга карап торды. Соңга таба, ястыгына йомшак-йомшак кына басып, кызны уята башлады. Кыз күзен ачты һәм үз янында башына таҗ һәм өстенә

[1] Әгъла — иң югары, иң биек.

патшалар киеме кигән бик чибәр бер егетне күрде. Нәфесе дәртенә буйсынып, шау-шу күтәрмәде. Тыныч кына:

— Син кем? Бу вакытта монда ни эшләп йөрисең? Бу кадәр каравылчылар һәм тирә-ягымдагы җарияләр аркылы ничек кердең? — дип сорады.

Шаһзадә:

— Әфәндем, әүвәл сез әйтегез, сез кемсез? Аннан соң мин дә кемлегемне әйтермен,— диде.

Кыз елмаеп:

— Әфәндем, син минем бүлмәгә кергәнсең, гаҗәп, үзең минем кем икәнемне белмисең. Әйтим алайса, бу шәһәр — Җиһанабад шәһәре. Мин исә Һинд падишаһы Һөрмес шаһның кызы Галәмара буламын,— диде.

Шаһзадә дә:

— Әфәндем, мин дә Исфаһан патшасы Хаварзәм шаһ углы Камәрҗанның углы Насылмын. Ишеткәнең юкмы? Бер хәлгә дучар булып, бер көндә Исфаһаннан бу җиргә килдем,— диде.

Галәмара ятагыннан торып, җарияләрен уятты. Җарияләр бүлмәдә шундый гүзәл бер патшаны күреп хәйран калдылар. Галәмара шунда ук каһвә һәм шәраб хәзерләп, егетне сыйлый башлады. Шаһзадәнең чынлыкта да карыны ач иде.

— Минем монда утыруым сезгә мәшәкать булыр. Мине башка бер бүлмәгә җибәрегез. Анда теләгән кадәр ашармын, эчәрмен,— дип рөхсәт сорады.

Кыз әмер итте. Шаһзадәне башка бер бүлмәгә илттеләр. Анда табын әзерләделәр. Шуннан соң Галәмара бер җарияне этисе Һөрмес шаһка җибәрде. Үз бүлмәсенә килүен үтенде. Шаһзадә Насылның башка бүлмә соравы кыз күңеленә бик хуш килеп, ул шаһзадәнең гыйффәтенә мең рәхмәтләр укыды. Шаһ Һөрмес тәшвишкә төшеп, кыз бүлмәсенә килеп җитте. Галәмара вакыйганы сөйләп биргәннән соң, ул да шаһзадәнең гыйффәтен аңлап, канәгать булды. Кызының шау-шу күтәрмәгәнен дә мактады һәм шаһзадә бүлмәсенә юнәлде. Шаһзадә Насыл шаһны күргәч тә, патша икәнен аңлап, урыныннан торып, аның итәген үпте. Шаһ, шаһзадәнең хәрәкәтләреннән һәм әдәплелегеннән разый булып, аны үз янына утыртты һәм башыннан үткәннәрен кабат сөйләтте. Ат кыйссасын ишеткәннән соң, ул атны түбәдән төшермәк өчен өй түбәсенә берничә хезмәтчене җибәрде. Атны түбәдән төшереп тамаша кылганнан соң, гаҗәпләнүләре тагы да артты. Галәмара тирәсендәге җарияләр дә шул хакта сөйләшәләр иде. Берәүләре: «Әфәндем, бик курыктыгызмы? Минем куркудан гакылым китә язды.

Курыккан булсагыз, салкын су эчегез!» Икенчесе: «Монда курка торган нәрсә бар? Аллаһы Тәгалә шаһзадәне әфәндебезгә үзе китереп бирде. Валлаһи, мин шаһзадәнең йөзен күреп исем китте. Сөбханалла, күз тия күрмәсен». Өченче берсе: «Әфәндебез нидән курыксын. Әфәндебезнең бәхете. Шаһзадәне күргәч тә, әфәндебезгә Алла кияү бирде, дип күңелемә килде»,— кебек сүзләр белән һәркайсы Галәмара күңелендәге хыялны кувәтләделәр.

Иртән шаһ, диванга чыгып, дәүләт олылары һәм ил терәкләре үз урыннарына урнашып патшаны тәбрик иткәч тә, шаһзадәне алып килергә ат күндерелде. Шаһзадә килгәч, шаһ аны үзенең янына утыртты. Шаһзадәнең мажараларын сөйләп, диван әһленә аның итәген үбәргә боерык бирде. Диван әһле шаһзадәнең бу вакыйгасына хәйран калдылар. Кояш кебек якты йөзенә карап сокландылар. Диван таралып, дәүләт олыларының һәркайсы үз эшләренә киткәннән соң, патша белән шаһзадә, бер бүлмәгә килеп, иртәнге ашны ашадылар. Унунбиш көнгә кадәр шул рәвешчә күңел ачканнан соң, бер кичә шаһ хатыны белән сөйләшеп утырганда, шаһзадәнең күркәмлеге хакында сүз чыгып, шаһның хатыны:

— Кызыбыз Галәмараны, әлбәттә, берәүгә тапшырырга тиешбез. Тирә-як патшаларының берәрсенең улына бирсәк, киявебез ата-анасын ташлап, безнең янда тормас, кызыбызны үз иленә алып китәр. Безнең исә башка варисыбыз юк. Милек һәм дәүләтебез ятлар кулына калыр. Шундый күркәм шаһзадә кулыбызга килеп кергән икән, аны үзебезгә кияү итәргә кирәк,— дигәч, патша да:

— Чыннан да, сүзең бик дөрес, шаһзадәне беренче мәртәбә күргәннән бирле, шул ук уй минем күңелдә дә йөри. Тик кызыбызны алырга риза булыр микән? Бабасын ташламас, Исфаһан минем дәүләтемнән күңеллерәк һәм төзегрәк ил. Бабасы да үзенең тәхет варисы шаһзадәнең Һиндта калуына рөхсәт бирмәс,— дип җавап кайтарды.

Хатыны:

— Шаһзадә гыйффәт иясе булса да, яшь егет ләбаса. Безнең Галәмараның да матурлыгы һәм гүзәллеге бөтен дөньяга билгеле. Галәмараның шаһзадәгә күңеле барлыгы сер түгел. Җил исми, яфрак селкенми дигәндәй, яшерен серләрен белүче җариясеннән ишеттем. Галәмара шаһзадәгә гашыйк булган икән. Шаять, кияүгә чыгарга разый булыр. Шаһзадәнең күңеленә дә тәэсир итәр. Рөхсәтегез булса, мин аның җаен табармын,— диде. Рөхсәт алып, хатыннар бүлмәсендәге баш хезмәтчесен — күп хәл-

ләрне күргән Мөнәвәрә исемле карчык-җарияне чакырды. Патша белән араларында булган киңәшне аңар сөйләде.

Мөнәвәрә:

— Баш өсте, әфәндем, шул гакылың белән мең яшә. Мин дә нәкъ шул хакта уйлап йөри идем. Бәлки, беләсездер, Галәмара шаһзадәгә гашыйк булып йокыдан калды. Йокысызлыктан күзләре авырта башлады. Сездән рөхсәт бар икән, иншалла, бу эшнең очына чыгармын,— диде.

Баш хезмәтче Мөнәвәрәнең бу вәгъдәсенә куанып, патша хатыны:

— Ярый, бар. Үзең белгәнчә эшлә,— дип, бу эшне аңа тапшырды.

Бер кичне Мөнәвәрә, Галәмараның бүлмәсенә кереп:

— Әфәндем, сиңа бер сөенчем бар,— дип, әти-әниләренең киңәшләрен һәм үзенең бу эшкә вәкил кыйлынганын сөйләп бирде.

Галәмара елап, Мөнәвәрәнең кулын үбеп:

— Әй дая, шаһзадәнең гыйшкы мине сабыр һәм әдәп чигеннән чыгарды. Бу дәрттә миңа ярдәм итмәсәң, валлаһи, үземне үзем һәлак итәчәкмен. Бер дәрман таба күр,— диде.

Мөнәвәрә, Галәмараны юатып:

— Хәсрәт чикмә, кызым. Бу эшне башкарып чыгуны минем җаваплылыгыма куй һәм миңа берничә көн вакыт бир,— дип, Галәмара белән саубуллашып чыгып китте.

Иртәгесен Насылның ялгыз утырган вакытын саклап, ул шаһзадәнең бүлмәсенә керде. Барып итәген үпкәннән соң:

— Әфәндем, бу фәкыйрегез патша кызы сараендагы баш хезмәтче, исемем — Мөнәвәрә. Патшаның әнисе урынындагы догачысы булганым өчен, сез әфәндемне дә углым кебек күреп, хәлегезне белер өчен кердем,— диде.

Шаһзадә дә олылау һәм хөрмәтләү йөзеннән:

— Рәхмәт инде сезгә, минем монда туганым-карендәшем юк, әнием урынына ана була күрегез, зинһар. Әйдәгез, түргә узып утырыгыз,— дип, бүлмәнең түреннән урын күрсәтте.

Мөнәвәрә татлы телле, сүзгә оста бер хатын иде. Шаһзадә белән ике сәгать чамасы сөйләшеп утырды. Ике көннән соң, бер хезмәтченең кулына төрле җимеш белән тулы бер табак күтәртеп, ул тагын шаһзадә янына килде. Татлы телле, хуш сүзле булганга, шаһзадә дә Мөнәвәрә карчыкның килүенә бик шатланды.

— Шаһзадәм, дөя дә бүләк, төймә дә бүләк дигәндәй, аз булса да бу бүләгемне кабул итегез — дип, җимештән татлы сүзләр

әйтеп, җимешләрен шаһзадә алдына куйды. Шулай биш-ун мәртәбә килеп, ул шаһзадәнең кылын тартып караштырды. Шаһзадә Мөнәвәрә карчыкка ияләшеп, патша сарае агалары аркылы: «Безнең әнкәйгә сәлам әйтегез»,— дип, аңа сәлам җибәрер иде.

Бер кич Мөнәвәрә карчык шаһзадә янына килде. Шаһзадә Мөнәвәрә карчыкны бераз кәефсез күрде.

Шаһзадә:

— Әнкәй җаным, бүген сездә бер кәефсезлек күрәмен, нидән күңелегез кырылды? — диде.

Мөнәвәрә:

— Юк, әфәндем, бернәрсә дә юк,— дип, күзеннән яшь чыгарды. Карчыкның егълаганын күргәч, шаһзадәнең дә күңеле йомшарды.

Күп үтенеп сораганнан соң, карчык:

— Ах, әфәндем,
Ах идәрсәм, яндырыр
Бу нәфесем галеми,
Сабыр идәрсәм, кемсә белмәс
Ошбу хаста хәлеми.

Бу сердер ки, аны белдерсәм дә — вай, яшерсәм дә — вай. Ләкин ни чара? Сездән башка миңа кем шәфкать кыйлыр? Сезгә әйтсәм дә куркам, әйтмәсәм дә куркам,— дип егълый башлады.

Шаһзадә:

— Сөбханалла, шулкадәр хөрмәтегезне күреп, сезне әнием дип йөргәндә, сезгә зарарлы эш кыйламынмы? Затым тәрбияле була торып, ахмаклар эшен эшлимме? Мин юлаучы углыгыздан нигә шулкадәр шикләнәсез? — диде.

Мөнәвәрә әйтте:

— Әфәндем, хезмәткәрләрнең хуҗаларыннан шикләнүләре әдәпсезлек түгел. Без бәндәләрегезгә никадәр игътибар кыйлып, бүләкләр бирсәгез дә, барыбер күңелебездән хәвеф китми. Кыскасы, «ни сөйләсәң дә, ни сер әйтсәң дә, ике арабызда гына калыр. Соңыннан да бер сүзем булмас» дип сүз бирмичә, серемне фаш итмим,— диде.

Шаһзадә:

— Һичкайчан да миннән сезгә һичбер җәһәттән зарар ирешмәс,— диде.

Мөнәвәрә әйтте:

— Әфәндем, хозурыгызга килгәндә һәрчак падишаһның гыйззәт һәм ихтирамы турында сүз ачасыз, шаһ та сезне олылап хөрмәт күрсәтә, ә менә Галәмара, сезнең шаһзадә икәнегезне

белми торып, сезне танымый торып та, теге кичәдә шау-шу күтәрмәде, һәрчак ул сезне искә алып, хәлегезне сорашып тора.

Шаһзадә әйтте:

— Әнкәй җаным, миң ел гомерем булса да, Галәмара хәзрәтләренең миңа шундый мөгамәлә күрсәтүенә рәхмәтләремне әйтеп бетерә алмам. Падишаһның миңа хөрмәте дә Галәмараның шул мөгамәләсе нәтиҗәседер. Галәмара ул кичне мине күргәч тә кычкырып тавыш күтәргән булса, мине тоттырып, халык алдында хурлыкка калдыруы мөмкин иде,— диде.

Мөнәвәрә әйтте:

— И әфәндем, хаклык исеменә сез, ичмасам, бер мәртәбә генә миннән Галәмараның сәламәтлеге, кәефе турында сорашсагыз икән.

Шаһзадә аңа:

— Әнкәй җаным, Галәмараны рәхмәт хисе белән телгә алу минем бурычымдыр. Әмма яшь егетлек дәрәҗәсенә яңа гына ирешкәнгә күрә, кызлар турында сорашырга ояламын. Чыннан да, бу мәсьәләдә минем кимчелегем зур. Әгәр бу тыйнаксыз сораулар белән нәзакәтләренә тап төшерерлек булмаса, мин бик теләп, җир үбеп, аның хәлен сорашырга батырчылык итәр идем,— диде.

Мөнәвәрә хатын:

— Ул сезнең хәлегезне һәрвакыт сорашып тора, әмма менә берничә көн инде кәефе бозылып, сәламәтлекләре бераз китеп торганга гына, бу сүзне кузгаттым,— диде.

Шаһзадә Насыл:

— Хак Тәгалә аңа сихәт бирсен, сырхавы ни-нәрсә икән? — дип сорады.

Мөнәвәрә хатын:

— Әфәндем, бәдәнендә һич авыруы юк шикелле. Ләкин йөрәк яндыргыч сүзләр сөйләп егъламактадыр. Сез килгән кичтән бирле тамактан калды,— диде.

Шаһзадә:

— Минем алар бүлмәсендә кинәт күренүем аны куркытып, бер-бер зәхмәт кагылдымы икән, мин генә сәбәпче булмасам ярар иде,— дигәч, Мөнәвәрә хатын:

— Алла сакласын, сезнең кинәт күренүегездән аз гына да курыкмаганын йөз мәртәбә сөйләде. Ләкин авыруына сәбәпче барыбер, әфәндем, сез булсагыз кирәк,— диде.

Шаһзадә Насыл:

— Сөбханалла, курыкмады дип торасыз лабаса, тагын мине сәбәпче итеп тә күрсәтәсез. Бу нинди сүз, аңламадым,— диде.

Мөнәвәрә хатын, бераз елмаеп:

— Әфәндем, Һинд икълимендә сезнең кебек күркәм егет күренгәне дә, ишетелгәне дә юк. Дөрестән дә, ул кичәдә кинәт сезнең кебек фәрештә сыйфатлы бер егетне күреп, гыйшкыгызга мөбтәля[1] булган ул. Галәмараның мәхәббәт дәрте белән ах-вах итүләрендә гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк,— дип, Мөнәвәрә хатын торып китте.

Ике көннән соң ул шаһзадә янына кулына йөз таҗ яфраклы бер гөл тотып килде. Гөлне шаһзадәгә биреп:

— Әфәндем, гыйшык һәм мәхәббәтегезнең әсире Галәмара җариягез, мөбарәк кулыгызны үпкән хәлдә, сезгә үзенең гыйшык һәм мәхәббәтен белдерде,— диде. Шаһзадә шатланып гөлне борынына якын китерде. Моны күргән Мөнәвәрә хатын, тагын да батырая төшеп: — Патша да сезне кияү итәргә бик әзер. Туй иткәч тә, җәнабыгызны ул, әлбәттә, Һиндстан тәхетенә утыртачак. Әгәр риза булмасагыз, Галәмараның һәлак булуы бик мөмкин,— дип, яшерен серен белдерде. Шаһзадәнең «әйе» дияргә дә, «юк» дияргә дә хәле калмады.

Шул рәвешчә торганда, Мөнәвәрә хатын, шаһзадәнең кулыннан тотып:

— Әфәндем, рөхсәт итсәгез, аулаграк бер җиргә барып, бераз сөйләшик,— дип, бер бүлмәгә алып килде.

Ул бүлмәдә гүзәл Галәмара шаһзадәнең килүен көтеп тора икән. Шаһзадәнең килүенә ул бөтен дөнья дәүләте үз кулына кергәндәй шатланды. Шаһзадә аягына егылып:

— Әфәндем, инсафлы һәм кешелекле икәнегезгә шөбһәм юк. Дөньяда һәркемнең тырышлыгы һәм иҗтиһады — балалары һәм хатыны өчендер. Күңелең теләгән гаиләң булмаса, Исфаһан тәхете түгел, бу заманның Сөләймана булсаң да, рәхәт тапмассың. Бу җариягез, әгәр сезнең белән кушылырга өмид булмаса, һәлак булачак. Үлүемә кайгыручы булмаса да, гыйшыктан үлде, дип әйтерләр,— кебек үпкә сүзләрен бик күп сөйләде.

Шаһзадә теге кичәдә Галәмараны күргән булса да, зиннәтсез кичке киемнәрдә генә очраткан иде. Бүлмәнең караңгы булуы, үзенең каушавы һәм дулкынлануы белән дә кызның йөзенә дикъкать белән карый алмаган иде. Бу юлы аның матурлыгын, гүзәллеген күреп, татлы һәм матур сүзләрен ишетеп, шаһзадәнең күңелендә дә мәхәббәт хисләре кайнады.

---

[1] Мөбтәля — дучар.

— Әфәндем, сабыр ит. Иншалла, гомер ахырына кадәр бергә булып кәеф-сафада булырбыз,— дип, Галәмарага кавышачакларын белдерде. Аның күңелен шатлыклы гыйшык хисләре белән тутырды. Мөнәвәрә хатын шаһзадәнең ризалыгын сөйләп, сөенче алыр өчен, патша һәм патша хатыны янына китте. Шул сәгатьтә үк патша дәүләт олыларын һәм ил терәкләрен чакырырга боерык бирде. Туй хәбәре игълан ителде. Никях укылганнан соң, зөфаф мәҗлесе булып, егет белән кыз кавышып шат булдылар. Иртәгесе көнне шаһзадә Насыл, патша янына барып, аның итәген үпте. Патша шаһлык тәхетеннән төшеп, аны Насылга тапшырды.

Шаһзадә Насыл берникадәр вакыт шатлык һәм хозур белән Һинд патшасы булып торганнан соң, бабасының хәсрәт утын басар өчен ике көнгә Исфаһанга барып кайту теләген белдерде. Моны ул вәзиренә генә сөйләп, Галәмарага белдермәстән, үзенең хикмәтле атына атланып, Исфаһанга таба очып китте. Җиһанабад шәһәреннән бер фәрсәх кадәр җир киткәч, күк йөзендә еракта кара болыт кебек бернәрсә күренде. Якынрак килгәч, аның гыйфрит икәнен белде. Гыйфрит атның тезгенен эләктереп алды да:

— Син бу атны кайдан алдың? — дип, атны да, Насыл шаһны да үзе белән бергә алып китте.

Бичара Насыл шаһ үзен-үзе шелтәләп, җаныннан өмид өзеп, яшь хатыны белән аерылуы исенә төшеп, ике күзе яшь белән тулды. Тиз заманда гыйфрит бер зур сарайга килеп төште. Ат белән Насыл шаһны бер бүлмәгә кертеп, ишекне бикләп куйды. Бу ат асылда Шәмһаил хәзинәсендә булып, аны бер җен урлап, мөәзин кызына алыштырган икән. Шәмһаил шаһ ул чак туй эшләре белән мәшгуль булып, моны белмәгән иде. Бу гыйфрит исә Шәмһаилнең сарай хезмәтчеләреннән булганга күрә, атны танып, аны Шәмһаил шаһ хәзинәсенә алып кайтты. Шәмһаил шаһ Асыл шаһның сараенда иде. Гыйфрит, Асыл шаһ сараена барып, Шәмһаилгә вакыйганы сөйли башлады.

Асыл шаһ:

— Нинди яшерен серегез бар? — дип сораганнан соң, Шәмһаил үз хәзинәсеннән хикмәтле атның урланганын, ул атны бер адәм белән алып кайтып, сараена бикләгәннәрен сөйләгәч, Асыл шаһ:

— Монда китерсеннәр. Нинди ат икән дә, нинди адәм икән, күрик. Ул адәм атны кайдан алганын сорашырбыз, — диде.

Шунда ук ат белән Насыл шаһны бу сарайга китерделәр. Зур залда берничә югары нәселле патшалар әдәп белән аяк-

ларына карап торалар. Әгъла бер тәхет өстендә бу заманның Сөләймане, шаһлар шаһы булып берәү утыра. Сарайның мәһабәтлелегеннән күзе камашкан Насыл шаһның күтәрелеп карарга такате юк иде. Әмма Асыл шаһ күрү белән туганы Насыл шаһны таныды. Тәхетеннән атылып төшеп:

— Ах, борадәрем Насыл,— дип барып, аны кочып алды. Насыл шаһ та күзен ачып караса, бу тиңе булмаган шаһлар шаһы үзенең борадәре Асыл, икән. Бер-берен кочаклап биһуш булдылар. Дәүләт олылары болар тирәсенә җыелып, бу вакыйгага хәйран булып торалар иде. Һушларын җыеп гакылларына килгәч, шаһ Асыл Насыл шаһны кулыннан тотып, үзе янына тәхеткә китереп утыртты. Бер-беренә сүз әйтә алмыйча, бер сәгатькә якын егълаштылар. Габдесамат солтан, сарай әһелләре Насыл шаһ Асыл шаһның югалган борадәре икәнен белделәр. Һәммәсе: «Мөбарәк булсын, солтаным! Күп яшә!» — дип тәбрик иттеләр. Шаһ Асыл Насыл шаһны китергән гыйфриткә асыл киемнәр кигезде. Аны югары дәрәҗәле итте. Мәҗлес тәмамланып, һәркем үз эшенә китәргә рөхсәт алгач, Асыл шаһ Насыл шаһны бер биек сарайга алып килде, күңелләре тынычланып, баштан кичкән вакыйгаларны бер-беренә сөйләшкәннән соң, шаһзадә Асыл Шәмһаил шаһны чакырып боерык бирде:

— Борадәрем Насыл шаһның хатыны Галәмара аз гына да куркытмыйча бирегә китерелсен,— диде.— Шулай ук иртәгә олы мәҗлес үткәрәчәкбез. Шул мәҗлескә бабаларыбыз Хаварзәм шаһ һәм Чин патшасы Шөҗаг, әтиебез Камәрҗан, әниләребез Гөлрох һәм Фәррах Бану, вәзир Шәрир, хатыны Зөһрә белән Кәшмир патшасы Фәйруз шаһ, Һинд патшасы Һөрмез шаһ кадер-хөрмәт белән шул мәҗлескә китерелсеннәр. Хатын-кызларга һәркайсына аерым бүлмәләр бирелеп, һәммәсе рәхәтләнеп кәеф-сафада яшәрлек булсын,— диде. Борадәре Насылга исә: — Сез, борадәр, барыгыз, хатыныгызны каршы алыгыз.

Шаһ Асыл сарае янында шаһзадә Насылга да бер сарай китереп утырттылар. Өч йөзгә якын гүзәл җарияләр җиң сызганып хезмәтенә хәзер торалар иде. Бер минут үтмәде, сарай ишегеннән Галәмара да килеп керде. Бер залга, бер Насыл шаһка, бер җарияләргә карап, хәйран булып, Насыл шаһ янына килеп утырды. Галәмара Насыл шаһның Җиһанабад шәһәреннән киткәнен белмәгән иде. Асыл шаһның сараена килгәч:

— Әфәндем, болар безнең җарияләребез түгел, бу бүлмә дә безнең бүлмәгә охшамаган. Сезнең янызыгыздан чыккач, мин бераз ятып торган идем. Уянып күземне ачсам, үземне менә

бу бүлмәдә күрдем. Аңлый алмыйм. Монда ниндидер бер хикмәт бар,— диде.

Насыл шаһ, җиңелчә көлемсерәп:

— Һич тәшвишләнмә, җаным, бу урын шаһиншаһ борадәрем, Асыл шаһның сараедыр,— дигәч, күңелләреннән хәвеф китеп, тагын зәвык-сафа белән мәшгуль булдылар.

Иртәгесе көнне барлык патшалар үзләренең җәмәгатьләре белән олы бер сарайга күчерелделәр. Моны алар үзләре сизмәделәр дә. Гыйззәт-хөрмәт соңында хезмәтчеләр килеп, аларны шаһиншаһ диванына чакырдылар. Шаһиншаһ диванына барып, тәхет янындагы кыйммәтле урындыкларга утырып, шаһиншаһ тәхетенең пәрдәсе күтәрелгәнен көтеп тордылар. Әле һичкем эшнең асылын белми иде. Һәрберсе төш күргән шикелле хәйран калып, гаҗәеп хыялга батып утыра иде. Ул арада Камәрҗанның әтисе Хаварзәм шаһны һәм башкаларны күрделәр. «Әлбәттә, бу дөнья түгелдер, бәлки мәхшәр җиредер. Бу диван да Хак Тәгаләнеке булырга кирәк. Без үлеп, теге дөньяда терелтелгәнбез, күрәсең»,— дигән фикергә килделәр. Кайберләре: «Юк, алайга да туры килми бит. Вәгазьче әфәнделәр сөйләвенчә, мәхшәргә җыелган халык яланбаш, яланаяк булырлар, имеш. Ә без исә әнә тәхетләр өстендә утырып торабыз. Бу ни гаҗәп?» — дип торганда, барабаннар кагылды, музыка уйнап җибәрде һәм пәрдә күтәрелде. Пәрдә артында алтын һәм җәүһәрдән ясалган тәхет өстендә патша күренде. Ике борадәр, урыннарыннан торып, әтиләре Камәрҗанның һәм бабаларының кулларын үптеләр. Кочаклашып, шатланышып, егълап туйгач, һәрберсе үз урыннарына утырдылар. Шаһиншаһ Асыл башыннан үткән вакыйгаларны бер кәгазьгә яздырган иде. Шаһиншаһ ул язуны баш сәркатиб кулына бирде. Барча халык ишетсен өчен, аваз белән кычкырып укырга боерды. Асыл һәм Насылның башыннан кичкән маҗаралар халыкка мәгълүм булганнан соң, шаһиншаһ диван халкына кыйммәт бәһале асыл киемнәр кидерде. Вәзир Шәрирне исә тәхете алдына китереп:

— И залим, хыянәтче, үзең генә баш булып, рәхәт яшәр өчен, сиңа яхшылык кына теләүче патшаның балаларын әтиләреннән аердың. Ни мәшәкатьләр күрсәттең, сине бер гыйфриткә биреп, җәза күрсәтеп, аңардан ашату кирәк иде дә, бу куанычлы сәгатьнең бәхетенә тап төшермәс өчен җәзаңны Аллага тапшырдым. Бар, күзеңне кыздырган Бәсра тәхетен сиңа бирдем, каршыбызда торма, чык, мәлгунь! — диде. Бер

гыйфриткә: — Бәсрага илтеп ташла шуны! — дип боерык бирде. Фәйруз шаһка ул олылап күп кадер-хөрмәт күрсәткәннән соң, бер кәгазь китереп, ул кәгазьгә хикмәтле йөзектәге мөһерне басты.— Бар, шул кәгазь белән хатының Зөһрәнең тәнен ышкы, ул әүвәлге хәленә кайтыр. Шуннан соң, теләсәгез, безнең янда кәеф-сафа кыйлырсыз, теләсәгез, үз илегезгә кайтарып җибәрермен,— диде.

Фәйруз шаһ:

— Берничә көн шаһиншаһның нурлы йөзен күреп, татлы сүзләрен ишетим димен. Шуннан соң үз ватаныма китәрмен,— диде.

Аннан соң һәркайсы үзләре өчен билгеләнгән урыннарга таралыштылар. Шаһзадә Асыл һәм шаһзадә Насыл этиләре Камәрҗан һәм әниләре Гөлрох һәм Фәррах Бану янына килделәр. Яңадан бергә кушылуларына шатланышып, җәннәттән башка җирдә мөмкин булмаган зәвык-сафа белән мәшгуль булдылар. Риваятьләргә караганда, Асыл һәм Насылның этиләре Камәрҗаннан аерылган көннән бер-берсе белән кабат очрашуларына кадәр туксан көн вакыт үткән.

Исемнәре телгә алынган патша һәм солтаннарның һәм Сәрандиб халкының хәлләрен төгәл сөйләп бирү мөмкин булмаса да, алар тиңсез зәвык-сафа белән тагын туксан ел гомер кичерделәр. Шуннан соң бу затларга да һичкемне аямый торган әҗәл иреште. Иң ахырга шаһзадә Асыл белән аның хатыны Шивазадә калган иде. Икесе бердән авырып, бер түшәктә үләргә ятканда, тәрәзәдән бер кош очып керде дә атаклы мөһерле йөзекне шаһзадә Асылның бармагыннан алып китте. Шул минутта ук ир-хатын бер сулуда теге дөнья сараена күчтеләр.

# ТӨБӘК ТАРИХЫ: ЛЕГЕНДАЛАР, РИВАЯТЬЛӘР, ИСТӘЛЕКЛӘР ЭЗЕННӘН

## АЛЫП АДӘМНӘР

Нидәндер бәгъзеләр Гад кавеме шикелле җәсаде олуг адәмнәр булган дигән сүзне рәд кыйлалар. Хәлбуки күп тәфсирләр моңар каилләрдер. Җөмләдән берсе, мәсәлән, «Тәфсире тыйбиян»[1]да, «Әгърәф» сүрәсендә вә «әз кәрда эзҗәгалләкем Халикъ мин бәгъзе кавеме Нух дә заде кем фил халикъ бәстыйт» аятендә мәзкүрдер. Янә «Һавадир Сөләйли»дә мәзкүрдер ки, «Төхфәтел вәл әл баб»[2] китабының иясе шәех Габдулладан риваять кыйлып язар ки, һиҗрәтнең 500 тарихында (1106 ел) Болгар вилаятендә Гад нәселеннән бер адәм бар иде. Күрдем. Буе 28 зирагдан[3] зиядә иде. Бер ләтыйф сурәттә, хөсне җәмал иясе адәм иде. Вә гаҗәп кувәтле адәм иде. Мәсәлән, бер ат чабып барганда, бер кул белән ул атны тотып, култык астына кыстырып китәр иде. Гаять олуг чинар агачларын, бер кулы белән тотып, төбе-тамыры белән куптарып чыгарыр иде. Вә кувәте белән филне сукса, уртага өзәр иде. Вә бу адәмнең җәмал иясе бер күркәм сеңлесе бар иде. Бер адәмгә никях итеп бирделәр. Араларында гаять мәхәббәт вә өлфәт вакыйг булып, бер кич бу хатын ире белән мөгашәрә кыйлганда, мәхәббәт белән кысып, иренең ике кулбашын сындырып чыгарды. Ахыр ире бу зәхмәттән вафат булды. Аннан соң ул хатынны алмага берәү дә җөрьәт итмәде. Мин икесен дә күрдем. Болгар вилаятендә алар — гүзәллек белән мәшһүр галәм иделәр. Болгар шәһәрендә алар керердәй бер хәммам[4] юк иде. Чөнки буйлары бик озын иде. Вә гаҗәеп ирделәр.

Безнең Болгар йортында, кайсы авылга барсаң да, Алып

[1] «Тәфсире тыйбиян» — «Медицина аңлатмалары».
[2] «Төхфәтел вәл әл баб» — «Буләкләр турында мәсьәлә».
[3] Зираг — терсәк (58 см).
[4] Хәммам — мунча.

хакында бер хикәят бар. Күп авылларда мәшһүрдер. Кырларында бер мәхәсрәк тау булса, Алып чабатасын каккан, дип хикәя кыйлалар. Бу дәлилдер ки, Болгар йортында бер зур кеше булгандыр. 800 елдан бирле бу сүз онытылмагандыр. Янә моңар дәлил: моннан мөкаддәм 4—5 ел мәрүрендә Мамадыш өязендә Теләче карьясендә тау җимерелеп, җирдән гаять олуг адәм сөякләре табылган, имеш. Йосыф ибн Вәлид әфәнде бу хикәятне нәкыль кыйлды. Шөбһә тотылса, аңа мөрәҗәгать мөмкин. Ул сөякләрне Казанның валисе Искаратин паша[1] Петербург шәһәренә юлламыш, дип сөйләделәр.

## ТӘВАРИХЕ КАЗАН[2]

Европа икълимендә Идел елгасының мәшрикъ[3] тарафы ягында Иделдән алты чакрым җирдә кадимнән гыймарәт кыйлынган[4] Болгар шәһәре дип мәшһүр бер шәһәр бар иде. Вә Болгар мәмләкәтенең олуг вә баш шәһәре иде. Ул Болгар шәһәрен һәлак кыйлган Аксак Тимер дигән адәмдер. Һиҗрәттән соң җиде йөзенче елларда, ягъни Европа тарихы белән 1390 елларда, Болгарны Аксак Тимер һәлак кыйлган вакытта Болгарның ханы Габдулла хан дигән адәм иде. Габдулла ханның ике углы бар иде: берсе Алтынбик вә икенчесе Галимбик исемле. Болгарның һәлаке вакытында Габдулла хан һәм һәлак булып, калган ике углы килеп, Казан суы янына (хәзердә Иске Казан диерләр шул урынга) кала салдылар. Анда 154 ел ханнар торганнан соң, аннан күчеп, Казанка суы тамагына Казан каласын салдылар. Ул вакыттагы хан, Наласа картының риваяте буенча, Гомәр хан дигән адәм икән. Бу яңа Казанның гыймарәте тәхминән[5] 1390 еллардадыр яки 1400 еллардадыр.

### Бу яңа Казанның гыймарәт кыйлынганы

Наласа картының риваяте буенча, иске Казанда ханнар берничә заман торганнан соң, берзаман бер карчык Казанка елгасыннан су алып менгәндә сукранып менә икән: «Һай, гакылсыз патшалар, мондаен җиргә кеше кала салырмы? Бакчы, моннан су алып бу кадәр биек тауга менүе ни газаптыр»,— дип.

---

[1] Валисе Искаратин паша — генерал-губернатор Скарятин.
[2] Тәварихе Казан — Казан тарихы.
[3] Мәшрикъ — көнчыгыш.
[4] Гыймарәт кыйлынган — төзелгән, салынган.
[5] Тәхминән — чама белән.

Карчыкның бу сүзен берәү ишетеп ханга барып әйткән: «Бер карчык сине вә һәм кала салган ханнарны яманлап, сукранып судан менәдер»,— дигән. Ул вакытта Иске Казанда Гомәр хан дигән патша булган, имеш. Аннан соң Гомәр хан әйткән: «Кайда, ул карчыкны тотып китерегез, ни сәбәптән ул карчык ханнарны яманлый икән, тәфтиш кыйлмак[1] кирәк»,— дип, үзенең вәзирләрен карчыкны эзләргә җибәргән, һәм алар дәррәү карчыкны табып патшага тотып китерделәр. Патша әйтте: «Әй, карчык, син безне ни өчен болай яманлап, бездән сукранасың?» — диде. Карчык әйтте: «Мин яманламадым, мәгәр тугырысын әйттем,— диде.— Мондаен урынга гакыллы кеше кала салмас, дип әйттем»,— диде. Патша әйтте: «Каланы ниндәен җиргә салырга кирәк?» — диде. Карчык әйтте: «Каланы салырлар алтын чабак эләккән җиргә»,— диде. Аннан соң патша боерды: «Бар, эзләгез, алтын чабак кайда эләксә, шунда кала салырмын»,— диде, һәм берничә адәм Казанка суы буенча кармак сала-сала киттеләр.

Шуннан Казанка буенча алтын чабак эзләп килә торгач, крепость астына килеп җиттеләр. Хәзердә ул җирдә Романов тегермәнедер. Шул җирдә Казанкадан бер алтын чабак тоттылар вә һәм, фәлән җирдә алтын чабак бар, дип, тиз үк барып патшага хәбәр бирделәр. Патша әмер кыйлды, әсбап хәзерләп яңа Казанны гыймарәт кыйлырга шөругъ кыйлдылар[2]. Ул вакытта Казан урынында вә һәм әтрафларында олуг караңгы урман булгандыр. Килеп Казанка якасына урман эченә кала салдылар. Шул заманның ханы бу урынга кала саласы булып әсбапларын хәзерләгәч, мигъмарларга[3] боерды: «Иртәге көн каланың хисарына[4] нигез салыгыз, мәгәр нигез корганда карагыз, иң әүвәл иртә белән урамда кем дә кем очраса да, ай-ваена карамыйча, каланың нигезе астына тотып салыгыз»,— диде.

Иртәгесен мигъмарлар иртә белән чыгып кала корырга тотынгач та күрделәр: ханның үз углы килә*. Аның артыннан янә бер эт ияреп киләдер. Мигъмарлар, ханның углын тотып нигез астына салырга кызганып, аның белән ияреп килә торган этне тотып, каланың нигезе астына салдылар. Ул көн каланың нигезен берничә микъдар эшләгәннән соң, кич белән эштән бушагач, хан сорады: «Каланың хисары астына берәүне-берәүне салдыгызмы?» — диде. Осталар әйтте: «Юк, каланы эшли башлаганда һичкем узучы булмады, мәгәр күрсәк, бер

---

* Бер риваятьтә ханның углы Коръән-китап күтәреп сабакка барадыр икән.— *К.Н.*

[1] Т ә ф т и ш   к ы й л м а к — тикшермәк.

[2] Ш ө р у г ъ   к ы й л д ы л а р — башладылар, керештеләр.

[3] М и г ъ м а р л а р г а — төзүчеләргә, архитекторларга.

[4] Х и с а р ы н а — ныгытылган урынына, үренә.

эт йөгереп барадыр, шул этне крепость астына салдык»,— диделәр. Хан әйтте: «Хәер, булган эш булды, алайса, яхшы иттегез, бу кала һәм ханлык этләр кулына кала икән».

Аннан соң каланы салып тәмам иткәч, калага җыелырга халык бик курыккан. Аның өчен: бу җирләрдә һәркайда еланнар чүмәлә кебек өелеп-өелеп ята икән. Күл буйлары, суконный урыннары — һәммәсе сазлык, камышлык булган. Кабан дуңгызлары бик күп икән, һәм шул сәбәпле Кабан күле дигән исем калгандыр. Вә һәм Казанка елгасы буенда еланнар, хәтта бүрәнә кебек аждаһа еланнар бар икән. Хосусән хәзердә Елан тавы диерләр, Бишбалтаның Ягоднига таба ягында, Елан тавында вә һәм тау тишекләрендә канатлы аждаһа еланнар яткан. Вә һәм шул сәбәпле Казанның вә һәм Казан губернасының гербы канатлы елан сурәтедер вә һәм хәзер дә Елан тавы дигән исем аннан калгандыр. Ахыр патша үзенең вәзирләрен җыеп мәслихәт кыйлышты[1], бу еланнарны ничек бетермәк кирәк, дип? Аңар мәслихәт күрделәр: «Елан яткан җирләргә салам ташып, ут төртеп яндырырга кирәк»,— диделәр.

Әлбәттә, ул чагында спичка юк, бер үткен егет кешене табып, атка атландырып җибәрделәр. Ул егет килеп, ат өстендә чакма чагып, ут кабызып, саламга ыргытты. Салам яна башлагач, бер зур елан койрыгын тешләп, алка кебек тәгәрәп, ут салып киткән егет артыннан җитеп, аты-ние белән сугып һәлак кыйлды. Салам янып, күп еланнар һәлак булып, калганнары җир астына тишеккә керделәр вә һәм тишектә калганнарны һәммәсен дары белән ут куеп һәлак кыйлып бетерделәр.

Еланнар бетеп, кала тирәсе имин булгач, халык җыелып калада тора башлады. Аннан соң бу Казан каласы ханнар кулында йөз илле ел кадәр торган. Әмма нинди ханнар булган —күбесенең исеме мәгълүм түгел. Ләкин монда урыс тәварихларында мәзкүр исемнәре язылыр. 1446 елларда (ягъни һиҗрәттән 864 елларда) Мөхәммәд дигән кеше хан булган. Янә шул вакытларда Мәмүтек хан булган вә һәм Хәлил хан булган. Янә 1467 елларда Ибраһим хан булган. 1480 елларда Гали хан булган. Янә 1485 елларда Мөхәммәд Әмин хан булган. Бу Мөхәммәд Әмин хан «Бабирнамә» китабында һәм мәзкүрдер. Бабир солтан хикәят кыйладыр, Шәйбани ханның бер бик оста нәкъкашы вә һәм музыка гыйлемендә маһир бер шагыйре бар икән. Казан ханы Мөхәммәд ханга бүләк итеп җибәрде, дидер. Бу вакыйга «Бабирнамә» мәзмунына караганда һиҗрәттән тугыз йөз еллардан соң булган вакыйгадыр. Янә Мәмүк, яки Мамык хан дигән кеше булган. 1496 елларда, янә 1497 елларда Габделлатыйф хан булган. Янә мәзкүр Мөхәммәд Әмин хан бер

---

[1] Мәслихәт кыйлышты — киңәште, килеште.

мәртәбә газел кыйлынып[1], 1502 елларда икенче мәртәбә янә хан булган. Тәварихларда мәзхүр Әҗем хан дигән бу булса кирәк. Мөхәммәдҗан Аитов хәзрәтләренең сүзе һәм шуңар барадыр. Янә 1519 еллар Шәгали дигән кеше хан булган. Асыл исеме — Шаһ Галидер. 1522 елларда Сафа Гәрәй хан булган. 1531 ел Җанали, чын исеме — Җан Галидер. Янә 1535 елларда Сафа Гәрәй хан икенче мәртәбә хан булгандыр. Янә 1540 елларда Ядкарь хан булгандыр. Янә 1545 елларда Шәгали хан икенче мәртәбә хан булган. Бу Казан алынмастан элгәре ун ел мөкаддәм Иван Василичның атасы вә һәм Иван Василич ничә мәртәбә гаскәр белән килеп Казанны алырга хәмлә кыйлып[2], күп ханзадәләрне вә Казан ханының вәзир-вөзәрасын әсир кыйлып киткәләде. Шул арада Шәгали хан һәм урыс кулына әсир төшкән иде. Ядкарь хан үлгәч, аны урыстан сатып алып хан кыйлдылар. Янә болардан башка Казанда Үтәмеш Гәрәй дигән кеше бервакытны хан булгандыр. Урыс тәварихларында кайсы елда икәне язылган булса да, татбикъ кыйлуы[3] читен, еллары хата булгандыр.

## Казан алынганы

Иске Казан ханлыгы вакытында вә һәм бу яңа Казанның гыймарәтеннән соң барысы ике йөз илле еллап мөселман ханнары кулында Казан шәһәре бик төзек торды. Голямалары, вә мөдәррисләре, вә һәм көтепханәләре күп иде, вә талибләре күп иде. Ханнарының дошманнары юк иде. Казан ханлыгы мөддәтендә[4] һичбер дошман килеп, Казанга кул сузмады. Күп ханнар үттеләр. Соңыннан Ядкарь хан дигән кеше хан булды. Ядкарь хан вафат булгач, ир баладан хан булырлык кеше бирәү дә калмады. Мәгәр бер тугыз яшәр кызы калган иде, шул кызны атасы урынына хан итмәкче булдылар. Бу кыз ханлыкны кабул итмәде. Ирләр барында миңа кыз кешегә ханлык ник кирәк, дип, үзен-үзе һәлак кыйлды. Ядкарь ханның вафатыннан соң Казан мәмләкәтен вәзир-вөзәра тәдбир кыйлып[5] торды. Бу форсатта урыс ханнары Казанга күп хәмлә кыйла башладылар. Ядкарь ханның балаларыннан хан булырга сәлахиятле[6] кеше булмагач, Ядкарь ханның нәселеннән Шәгали хан дигән адәм Ядкарь ханнан мөкаддәм дә берәр мәртәбә хан булып, урыс кулына плен төшкән иде. Урыс кулында тот-

---

[1] Газел кыйлынып — урыныннан төшерелеп.
[2] Хәмлә кыйлып — һөҗүм итеп.
[3] Татбикъ кыйлуы — тикшереп караву, килештерүе.
[4] Мөддәтендә — вакытында.
[5] Тәдбир кыйлып — идарә итеп.
[6] Сәлахиятле — сәләтле.

кын иде. Ул Шәгали ханны күп акча биреп йолып алдылар вә һәм яңадан ханлыкка утырттылар.

Шәгали хан булганнан соң, Казанда күп тынычсызлык вә фитнә күп була башлады. Шәгали хан мөселманнарга күп хыянәт кыйлды. Урыс ханнары белән дуслашып, алардан күп мал алып, мәмләкәтне карауга күп илтифат кыйлмады. Үз халкыннан вә һәм үзенең вәзир-вөзәрасы — бар да үзенә дошман булдылар. Хәзинәдәге дарыга су сиптерә, диделәр. Казан тирәсендә моттасил[1] җиде ел сугыш булды. Урыс ханының гаскәре Казанны җиде ел камап яттылар. Бәгъзе кабер ташлары гуаһлык[2] бирәдер: Казан алынмастан мөкаддәм елларда Чуел өязләрендә[3], Ядрин өязләрендә күп сугышлар булган. Иван Василич Казанны алмак нияте белән бу тарафка күп гаскәр җибәреп, халыкны кырдырган. Шул заманда шаһид булган голямадан яки башка олуг адәмнәр кабер ташы язып куйдырганнар. Җөмләдән берсе Чуел өязендә Шәгали дигән чуаш авылының зиярәтендә бер таш бар. «Тукыз йөз кырык тукызда... Кужай углы кяфер тукышындин шәһид...» дип язылган. Моның тарихы 1549 елларга тугыры киләдер.

Моннан башка һәм шул рәвешчә язылган берничә таш бардыр. Бу рисаләнең әүвәлге фасылында бәян кыйлынды. Гәрчә ни мөселман халкында, ни урыс халкында Казан вакыйгасы хосусында язылган язулар булмаса да, һичбер халык арасында Казан алынгандагы вакыйгалар бу көнгәчә онытылганы юк. Әлбәттә, зиядә зур сугыш булгандыр. Моңар шаһид бу хосуста бер бәет ишетелгәне бар: «Каладин калая туплар атылды, сучсуздан сучлуя[4] бәлаләр катылды»,— дигән кабилдән[5]. Һәр ике тарафның туплары атылып, җир йөзендә адәм каны елга кебек аккан. Казанка елгасы кан белән катышып аккандыр. Елан тавыннан башлап Бишбалта урыннары вә, гомумән, Казанның төшлеккә таба тарафы һәммәсе, Бакалтай аралары урыс гаскәре белән тулы булгандыр. Хәзердә азрак беленәдер: Бакалтайга таба җирдә Яңа бистәдән Усиягә таба сырланып барган җир күренәдер; урыс гаскәре үр казып яткан җир икән, дип, эткәй сөйли торган иде. Урыс гаскәре тарафыннан һәм Казанны алырга гыйлаҗ[6] таба алмыйча, хәйран булганнардыр. Ахры, урыс патшасыннан әмер булып, Елан тавы катында җир астыннан канау ясап, крепость астына дары куеп күтәрткәннәрдер. Наласа картының риваяте буенча, урыс гас-

---

[1] Моттасил — тоташ, өзлексез.
[2] Гуаһлык — шаһитлек, таныклык.
[3] Чуел өязе — Цивильск өязе.
[4] Сучсуздан сучлуя — гаепсездән гаеплегә санап.
[5] Кабилдән — төрдән, төркемнән.
[6] Гыйлаҗ — әмәл, чара.

кәре Елан тавыннан казый башлап, берничә вакытлар казыгач, җир астыннан канаудан өсткә таба казып чыгып караганнар, тагы ничә көндә крепостька җитәрбез, дип. Хәзердә шул урында памятник бардыр. Аннан янә казып килеп, үзләренең чамалары белән крепость астына җиткәч, югары таба казып менгәннәр. Кала эчендәге халык авазы һәм ханнарның сөйләшкәннәре вә кала эчендәге мөселман гаскәренең гөжләп сөйләшкәннәре канау казучыларга ишетелгән, имеш. Шулай итеп, Казан каласын дары белән ваттырып, урыс гаскәре крепостька кергәндер.

1552 ел октябрьнең 2 нче көнендә «Иннә-л мүлүк изә дәхалү карйатә әфсәдүһә вә җәгалү агыйззәтә әһлиһә әзилләтән»* мәзмунынча ханзадәләрне вә әкабирләрне[1] кайсын үтереп, кайсын әсир кыйлып һәлак итте. Голямаларын үтертте. Мәдрәсәләрен яндырды, Коръән-китапны җыеп яндырды, йортларын вәйран итте. Шәһәрлек сыйфаты бер дә калмады. Калган мөселманнар вә голяма, таләбә[2] — һәркайсы ак кием киеп, Казаннан качтылар. Төрлесе төрле әтрафка йөз тотты. Ләкин тау ягына таба китәргә күп җирләрдә урыс гаскәре ятканлык җәһәтеннән мөмкин булмады. Күбесе Җиләкле тау аркылы Галич юлы тарафына киттеләр (Җиләкле тау дигәне хәзердә Ягодни услабада диерләр) вә бәгъзеләре Арча юлы тарафына юнәлде. Шәгали һәм Арча юлы белән чыгып китте. Казаннан чыгып киткәндә, үзенең вәзир-вөзәрасына үпкәләп-егълап әйткән сүзләре ошбудыр:

Дус, дус, дигәнем
Дус түгел икәнсез,
Дус диебүк йөргәнем,
Бар да дошман икәнсез.
Әй, балалар, балалар,
Бездин егълап калалар;
Бездин калган малларны
Кяферләр килеп алалар,—

дип егълап, үзенең кавем-кабиләсе белән бер җиргә барып, авыл ясап утырды. Шәгале авылы диерләр, хәзердә Кышкардан ерак түгел бер авыл бардыр. Шәгали ханның кабере һәм андадыр вә бәгъзеләре аннан күчеп Мәңгәр янына утырганнардыр. Һәнүздә Мәңгәрнең бер кисәге «Шәгалиески пучинки» дип аталадыр. Вә дәхи бәгъзе талибләре качып чыгып

---

* «Әгәр патшалар бер шәһәргә һөҗүм белән керсәләр, ул шәһәрне җимерәләр һәм хөрмәтле олуг кешеләрен иң түбән вә хур итеп калдыралар...» — Коръән, «Нәмел» (Кырмыска) сүрәсе, 34 аять.

[1] Әкабирләрне — олы кешеләрне.

[2] Таләбә — укучылар, студентлар.

[3] Мәкам тоттылар — урынлаштылар.

төрле җирдә, болыннарда, урманнарда мәкам тоттылар[3]. Иван Василич Казанны алганнан соң, калган мөселманнарны Казаннан кудырды. Урыс халкыннан гайре кеше монда тормасын, дип әмер кыйлды. Казанда мөселманнар бик аз калды. Һәммә йортларга урыс халкы килеп урнашты.

Ул заманнан калган нәсел хәзердә Казанда бик аз. Бәлки, берничә нәсел генә булсалар кирәк. Казан алынган заманнан калган нәселләр кемнәр-кемнәр бардыр, иншалла, эзләп табып бу рисаләнең зәйлендә[1] бәян кыйлыныр. Рәхмәтулла Әмирхановның риваяте буенча, Казан алынган вакытта Казанда байлар, хуҗалар вә сәүдәгәрләр күп икән. Казанга урыс халкы икъдам кыйлгач[2], кайсы кая таркалып беткәннәр. Иван Василич Казанны алып, калган мөселман татарлар белән солых булгач, әмер кыйлды: «Хуҗалар вә сәүдәгәрләр миңа бәйгать биреп, үз йортларына кайтып утырсыннар»,— диде. Чыгып киткән мөселманнар әйттеләр: «Инде без күчеп чыктык, кире кайтмабыз»,— диделәр. Иван Василич әйтте: «Алайса, коллары хуҗалары йортына керсеннәр»,— диде. Бәгъзе хуҗаларның малайлары, коллары, хуҗаларыннан баш тартып, хәзер йорт безгә ярар, дип кире кайттылар вә һәм Казанда калган бәгъзе мөселманнар йортсыз-җирсезләре Кабан күленең җәнүб[3] тарафы ягына бер урам ясап утырдылар. Хәзердә Шиһаб хәзрәтләр вә Җиһаншалар урамыдыр вә һәм бу мәхәллә Казанның иң иске мәхәлләседер.

Вә янә берничә елдан соң бәгъзе фәкыйрь-фөкарә вә ятимйөтама җыелышып, Иван Василичтан үзләренә урын сорадылар. Иван Василич аларга шәфкать итеп, «вон вам место» дип, Яңа бистә урынын күрсәтте. Яңа бистә урыны болынлык эчендә бер таусу җирдер. Әмма Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләренең атасыннан риваять кыйлган сүздән аңлашыладыр: «вон вам место» дип күрсәткәне — күлнең төшлеккә таба ягы, Захария урамнары Пләтәнгә чаклы һәммәсе бистәдер. Ягъни шул «место» дигән сүздән бозылып бистә дип аталгандыр. Бу риваятьнең бик дөрес булмагына дәлил — түбәндә мәзкүр Касыйм Шәех хакындагы риваять бардыр. Әмма бу заманда бистә дигән сүз шәһәрнең фанәсе[4] мәгънәсендә истигъмаль кыйлынадыр[5]. Нитәкки урысча «слобода» яки «предместье» диерләр. Мәсәлән, Каргалыны Сәгыйд бистәсе дигән кебек. Вә янә бу урынга муафыйк «Казан бәете» дигән бер бәет бардыр. Кадимнән ишетелә килгән, язылып килгәндер.

---

[1] Зәйлендә — кушымтасында.
[2] Икъдам кыйлгач — килгәч.
[3] Җәнүб — көньяк.
[4] Фанәсе — бетерешкән, югала бара торган урыны.
[5] Истигъмаль кыйлынадыр — кулланыладыр.

## Казанның кадимге планы вә кадимге гыймарәтләре

Кадимге гыймарәтләр вә һәм Казан алынгач гыймарәт кыйлынган гыймарәтләр: асыл крепостьның тавы күп мөәррихләрнең гөманы[1] буенча, адәм ясаган тау, дип сөйләшәләр. Аның өчен: крепость тавының ташлары такта ташлардан өеп ясаган тауга охшыйдырлар. Ләкин һәрбер хосусан урыс тәварихларында язылган нәрсәләр белән татбыйк кыйлып азапланырга безгә лазем түгел, бәлки безнең максудымыз урыс историясендә булмаган эшләрне, халык авызындагы риваятьләрне мәйданга чыгармактыр. Юк исә кулыбызда алты җилд[2] Карамзин тәварихы бар иде. Бу рисаләне тасниф кыйлганда тәшвиш бирмәсен[3], дип кешегә бирдем, чөнки шундаен исторически китаплар кулда булса, бер-бер шөбһә вакыйг булганда, бу нәрсә урыс тәварихларында ничек икән дип карала башлыйлар. Монда тик халык авызындагы сүзләрдән фәһем итеп[4], максуд халык авызындагы сүзләрне вә риваятьләрне кәгазьгә мендерүдер.

Казанның хан заманасындагы кадимге крепость стенасы агач стена булгандыр. Бөтен имән агачыннан берничә кат итеп салган стена икән. Казанның крепость хисарында унике капкасы бар һәм крепость хисары бу замандагы крепостьтан зуррак булгандыр. Урыс патшалары, Казан алынгач, берничә елдан соң таш стена ясаганнардыр.

Гостинный урыннары һәм толчок тирәләре хисар эчендә булгандыр. Ул вакытта Казанның зиярәте һәм крепость эчендә булгандыр. Юнусов мәсҗетендә толчоктан чыккан кабер ташы хәзердә дә бардыр. Хәзердә Проломный урам дип әйткәне — урыс гаскәре дары белән ваттырып кергән җирдер. Шуның өчен «Проломный урам» исеме калгандыр. Казан тирәсендә һәммәсе калын урман булган. Мокрыйлар, Печән базары тирәләре сазлык, камышлык вә һәм Печән базары күл булгандыр. Проломный урамның Балык базарына таба башы һәм сазлык күл икән; тирес, туфрак тутырып урам ясаганнардыр. Водопровод өчен труба салганда замечать иткән кешеләр бардыр. Күтәреп ясаган җир икәнлеге заһирдыр[5] вә һәм Суконныйлар, вә һәм Арча кыры белән тоташ Әмә таулары һәммәсе урман булгандыр. Казаннан мөселманнар куылгач, Әхмәд исемле кеше Әмә тавында мәкам токтан. Шул сәбәпле Әмә тавы дип аталып калган. Әмә тавы асылда Әхмәд авылы дигән сүздән мөхәффәфдер[6]. Әмә

---

[1] Мөәррихләр гөманы — тарихчылар фикере, уе.
[2] Җилд — кисәк, бүлем, том.
[3] Тәшвиш бирмәсен — шикләндермәсен, буталдырмасын.
[4] Фәһем итеп — аңлап-төшенеп.
[5] Заһирдыр — ачыктыр.
[6] Мөхәффәфдер — кыскартылгандыр.

тавы кадим мөселман авылы булгандыр. Әмә тавында чүлмәк эшләүчедән сорашканым бар, ул риваять кыйлды: бездә элгәре татарча язган ташлар бар икән, дип. Вә һәм моңар куәт— Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре үзенең бабаларыннан риваять кыйлып сөйләшә: моннан мөкаддәм йөз еллар чамасында Әмә тавында мөселманнар һәм бар икән. Гаетләрдә, бәйрәмнәрдә муллаларга садака вә һәм үзенең ашлыгыннан гошер[1] китерәләр икән.

Дәхи Гобәйдулла мулла углы Мөхәммәдъяр үзенең атасыннан риваять кыйлгандыр: Әмә тавында кадимрәк, ягъни тәкърибән[2] 1750 елларда яки 1760 елларда мөселманнар бар икән. Гобәйдулла мулланы ашка Коръән укырга вә корбан чалырга алып китәрләр икән һәм озын-озын буйлы кешеләр иде, диер икән. Мөхәммәдъяр 1850 елда вафаттыр. Иван Василич Казанга хәмлә кыйлып сугышлар була башлагач, Казанның ханзадәләре, вә әкабирләре вә һәм байлары, вә хуҗалары күбесе качып беткәннәр. Бәгъзеләре күл башында әрхәрәй[3] бакчасы урынында бер авыл булып утырганнардыр. Әрхәрәй бакчасы янында хәзердә дә ташлар бардыр.

Әмма Казанда хәзердә хан заманасыннан калган бары хан мәсҗете дигән манара бар. Бу манара асыл Сөембикә ханым салдырган манарадыр. 1535 елларда Сөембикә ханым Җан Гали хан никяхында булгандыр. Җан Гали хан урыс ханнарына әсир булып, урыс ханнары аны үтерткәннән соң, Сөембикә ханым берничә еллар, углы Сафа Гәрәй үсеп җиткәнче, үзе ханлык кыйлгандыр, вә һәм бу манара Сөембикә ханлыгы заманында гыймарәт кыйлынгандыр. Ләкин бәгъзе урыс мөәррихләре бу манараның гыймарәтен Алексей Михаилич заманасына китерәдер. Ягъни гөман кыйлалар, бу манара Алексей Михаилич заманасында Казан алынгач, йөз еллар чамасында, ягъни 1645 елларда гыймарәт кыйлынгандыр, диләр. Ләкин моңар дәлилләре бик зәгыйфьтер, чөнки алар гөман кыйлалар, бу манараның архитектурасына караганда, урыс эшенә охшыйдыр, диләр. Сөембикә заманасында гыймарәт кыйлынып та, урыс архитектурасына охшаса, гаҗәп түгел аның өчен: Казанның соңгы ханнары, әлбәттә, урыс калаларына барып йөреп урыс гыймарәтләрен күргәннәре бардыр вә һәм урыс халкының мигъмарларын китертеп гыймарәт кыйлдырганнардыр. Әгәр бер тәкъдир бу манара Алексей Михаилич заманасында гыймарәт кыйлынган булса, ул заманада урыс халкы азрак ачыла башлаган иде, әлбәттә, бер-бер төрле бу хосуста язусызу булыр иде, халәнки бер дә әйтмиләр.

---

[1] Гошер — уңышның уннан бер күләмендә дини налог.
[2] Тәкърибән — чама белән, якынча.
[3] Әрхәрәй — архиерей.

# АКСАК КАРАТУН , ПУГАЧЕВ, ИШБУЛАТ МУЛЛА ХАКЫНДА

## Аксак Каратун әрхәрәй хакында риваятьләр

Алла разый булсын, Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләренә бу көнгә чаклы онытыла язган риваятьләрне үзенең ата-бабаларында ишетелмеш рәвешчә саклап һәм бәгъзесен үзенең мәҗмугасына язып куймыш икән. Бу хосуста аның берничә статьясы белән файдаланамыз. Бәли, халык арасында күп риваятьләр бар; ләкин халык авызыннан җыю бик читен. Кайсы вакыйганың ахырын, кайсы вакыйганың башын гына беләләр. Бәгъзе риваять кыйлучылар бер вакыйганы икенче вакыйгага кушып сөйлиләр. Шул сәбәпле мөбһәм[1] булып каладыр. Мөхәммәдҗан Сөләйман углы Аитов үзенең бабаларыннан риваять кыйлып сөйләшәдер. Хосусән Ишбулат мулла диерләр икән, бер бабасы булган. Казан халкы арасында үзенең заманасында мәшһүр вә могтәбәр адәм булгандыр. Хәтта күп заманга чаклы, Ишбулат мулла заманы, дип, аның вакытыннан тарих тотып сөйләшәләр икән.

Мәзкүр Ишбулат мулланың Аитов Мөхәммәдҗанга карабәте[2] ошбу рәвештәдер: Ишбулат мулланың углы Габдерәзак, аның кызы Хәбибә-Хәйбә диерләр икән, 1809 елда вафаттыр. Мәзкүр Габдерәзак кызы Хәбибә бистәнең йомышлы татар Аит Бакый углы никяхында икән. Аит Бакый углы 1797 елда вафаттыр, 70 яшьләрендә. Ул Аитның берничә углы булып, җөмләдән берсе Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләренең атасы Сөләйман дигән кеше булгандыр; вә һәм Сөләйман Аит углы сиксән яшьләрендә вафаттыр, 1844 елларда.

Гәрчә тәкрар вакыйг булса да[3], Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре үзенең атасыннан ишеткән риваятьләрне язып куймышынча — гайне гыйбарәте белән языйк[4]. Аитов хәзрәтләре әйтәдер: Ишбулат мулланың углы Габдерәзак, аның кызы Хәбибә (Хәйбә диерләр икән, 1809 елның мартында вафат) Иске бистәнең йомышлы татар Аит Бакый углына барган иде. Аларның угланнары: Сөләйман, Муса, Йосыф иделәр. Мәзкүр Сөләйманның алтынчы һәм иң кече углы — ошбуны язучы — мин Казанның өченче гилди сәүдәгәре Мөхәммәдҗан Сөләйман углы Аитов, 1823 елда октябрьнең 5 нче көнендә дөньяга килгән. Бабамыз Аитның чын

---

[1] Мөбһәм — аңлаешсыз, билгесез.
[2] Карабәте — кардәшлеге, якынлыгы.
[3] Тәкрар вакыйг булса да — кабатлап әйтү булса да.
[4] Гайне гыйбарәте белән языйк — үзе язганча языйк.

аты Гаед; 1797 елның ноябрендә алтмыш алты яшендә вафат булмыштыр. Әткәмез Сөләйман 1844 елда августның 11 ндә сиксән яшьтән узып вафат булды. Әткәбез Ишбулат мулла хакында күп сүзләр сөйләр иде; күп мәдех кыйлыр иде. Вилаятьтә[1] вакыйг булган бер-бер эшне әйтсә, ул вакыт Ишбулат мулла заманы дип, тарих күк итеп әйтер иде. Әмма үзеннән никадәр мөкаддәм икәнен сөйләшкәне хәтеремдә юк. Хәтта Габдерәзак бабайны һәм исәнлеген дә белгән күк түгел иде.

Аксак Каратун дигән әрхәрәй булган. Аның исеме тәварихларда Лука Канашевич языладыр. 1738 елда Казанга әрхәрәй булып килгәндер. Бу Аксак Каратун дигән әрхәрәй булгач, Казан мөселманнарын чукындырмак ният кыйлып, бу эшкә багыйс[2] әүвәл бу булыптыр: башта бер сәүдәгәр (фәләннәрнең бабасы дип әйтер иде[3]) Идел буе калмыкларыннан берничә яшь угланнар сатып алып килгән икән. Шуларны ул заманда бер мөәзин (аның һәм исеме хәтеремнән чыкты; әткәй, фәләннәрнең бабасы, дип, исеме белән сөйләр иде) иман тәлкыйн кыйлып[4], мөселман итеп, янәдән Гайса баба дигән бер баба бар икән. (Шумрушный Гали дигән вә һәм Шайтан Шәриф дигән адәмнәр шул Гайса бабаның нәбирәләреннән[5] икән; моннан мөкаддәм егерме еллар чамасында вафатлардыр вә һәм Гайса бабаның кече хатыныннан туган балалардан килгән нәселләр, хәзердә тентә Таһир, тентә Габдулла диерләр, сәламәтләрдер; хәзердә халык арасында, аналарына нисбәтән, тентәнекеләр диерләр; язуда һаман фамилияләре Гайсин дип язылaдыр.) Шул Гайса баба ул калмык балаларын сөннәткә утырткан икән. Ахыр бу эш урыс түрәләренең колагына төшеп, бу өч кемсәнәләрне алып, һәртөрле газап белән ахырында чукындыргач, Гайса бабаны чиркәү астына ябып асрап, ахыр шунда картаеп вафат булмыштыр. Әмма баягы сәүдәгәр урыс иненә ихлас куйган булып, хәтта бер мөселман юлыкканда аркан әйләнеп һәм мөселманнарның йөзенә карамаган булып әрхәрәйне ышандырыр икән.

Ләкин үзе иманында сабит булып[6] мөәзин (белән) Мәскәүгә китмәккә сүз куешып вәгъдәләшеп, Мәскәүдә юлыкышмакчы булганнар. Ахыр мөәзин ничек булса Казаннан китеп, сәүдәгәр ялгыз калгач вә һәм әрхәрәй бу сәүдәгәрнең урыс диненә ихласы бар кебек сизгәч, Казаннан ераграк, эчкәрерәк әтрафлардан кара халыкны — нугай юлы вә һәм закама хал-

---

[1] Вилаятьтә — өлкәдә, илнең бер өлешендә.
[2] Багыйс — сәбәп, сылтау.
[3] Ул фәләннәрнең бабасы дигәне Чукиннәрнең бабасы икән.— *К.Н.*
[4] Иман тәлкыйн кыйлып — инандырып, иман укытып.
[5] Нәбирәләреннән — оныкларыннан.
[6] Сабит булып — нык торып.

кын димләп, чукындыру хезмәтен кушыптыр. Никадәр аракы, перәннек, зөннар[1] вә һәм берничә мичкә кач[2] биреп чыгарып җибәрептер. Мәзкүр сәүдәгәр Казаннан чыгып киткәч, бер уңай урында ул нәрсәләрне сатып хәреҗгә[3] акча ясап, шул хәреҗ белән Мәскәүгә барыптыр. Мәскәүдә Ока суында коенганда мөәзин белән сәүдәгәр бер-берсенең колач* салып йөзүеннән танып юлыгышыплар. Шуннан соң патшага Казан татарларының әрхәрәйдән тарткан җәфаларын күрсәтеп кәгазь биреп, шуннан үзләре Истамбулга качыплар. Ул арада әрхәрәй үзенең һаман мөселманнарга җәбер кыйлуында мәсыйр булып[4], бистәне яндырып вә һәм мәсҗетләр, өйләр салырга рөхсәт бирмәенчә, мөселманнарны издихамда калдырып[5] вә һәм чукынсагыз торыгыз, чукынмасагыз, шәһәрдән чыгыгыз, дип кысып күп яманлыклар кыйлыр икән. Бистәдә ул заманда таш мәсҗетләр юк икән. Агач мәсҗетләр һәммәсе янган икән. Шул заманда намаз укыр өчен бистә халкы кабыктан салаш ясап, шунда намаз укыр икән. Ул салашлар өстенә Аксак Каратун качлар куйдырыптыр. Качны мөселманнар чалгы белән кисеп төшерепләр. Ул арада бистә янган — һәммә җире пусто булып, кеше буе алабута, кычыткан, тигәнәк үсеп, халык алабута эчендә ятыр икән.

Бистә халкының олуглары — Ишбулат мулла углы Габдерәзак дигән кеше икән. Аксак Каратун аңа бигрәк каныгыр икән, ягъни халыкны чукындырырга ирек бирмидер, нәсыйхәт кыйладыр дип, кешеләр җибәреп, мөселманнарны кыйнап, сугып тәгъзиб[6] кыйлырлар икән. Ул вакытта бистәдә чумарлар бабасы Йосыф дигән вә һәм нәкә Сәйфулла атасы Ибраһим дигән бик һиммәт[7] егетләр бар икән. Алар Аксак Каратуннан килгән кешеләргә каршы — алабута арасыннан күсәкләр күтәреп чыгып, монда ник килдегез, сезгә ни кирәк? дип каршы торырлар икән. Аксак Каратун кешеләре: «Кая Габдерәзак?» — диерләр икән. «Менә Габдерәзак!» — дип, Йосыф бабай белән (бу Йосыфлар нәселе шәҗәрәбездә бардыр. Аит Мөхәммәдҗан шәҗәрәсендә) Ибраһим күсәкләрен күрсәтерләр икән.

---

* Мөхәммәдҗан Аитов хәзрәтләре үзенең әткәсеннән риваять кыйладыр: әүвәл заманда бистә кешесе колач салып йөзәргә бик оста булырлар икән вә һәм бистә кешесе арасында колач салып йөзәргә, көрәшергә вә һәм йодрык белән сугышырга осталык бер һөнәр мәнзиләндә хисапланыр икән вә һәм моның белән фәхерләнеп сөйләшерләр икән.— *К.Н.*

[1] Зөннар — билбау.

[2] Кач — тәре.

[3] Хәреҗгә — чыгымга, расходка.

[4] Мәсыйр булып — дәвам итеп.

[5] Издихамда калдырып — кысуны дәвам иттереп.

[6] Тәгъзиб — газап.

[7] Һиммәт — сәләтле, тырыш, гайрәтле.

Шулай итеп, Габдерәзак бабайны Аксак Каратун кулына төшермәенчә саклАрлар икән. Аксак Каратун урамнар чатына качлар утыртып, урамнарда драгуннар йөртерләр икән, ягъни халык җыелып бер-бер эш кыйлмасыннар дип. Безнең егетләр моңа бигрәк үчегеп, төнлә ялгыз-ярым йөргән урыс-улакны тотып үтереп, күлгә ташларлар икән вә һәм качларны суырып ташларлар икән. (Риваять буенча, Яңа бистә шул вакытта салынгандыр. Аксак Каратунның җәфасына чыдый алмайча, Тихонский урамдагы вә һәм Сөерләр урамындагы кешеләр күчеп китеп, Яңа бистә урынына барып утырганнар, имеш.)

Вә һәм шул заманнарда югарыда мәзкүр булган мөәзин белән сәүдәгәр Истамбулга барып, хәлифәгә урысның мөселманнарны дин турысында кысып газаплаганын гарыз иткәч[1], урыска Истамбулдан илче килептер. Аннан соң патша һәм уянып, Казанга әмер җибәргән. Аксак Каратунны төшереп, Зөя монастырена япканнар. Шунда күп гомер сөреп, ахырында йөзе тискәре әйләнеп вафат булмыштыр. Безнең бистә халкы мәкәрҗәгә барганда монастырь ишегалдына койма ярыгыннан карарлар икән. Аксак Каратун һаман арлы-бирле шунда йөрер икән; йөзе тискәре килгән икән. Патшаның әмере белән Аксак Каратунны төшереп монастырьга куйганнан соң, мөселманнар бераз иркенләп, йортлар һәм мәсҗетләр сала башлаганнар.

Ул заманда, ягъни тәкърибән 1750 елларда, князь Мещерский дигән генерал-губернатор, яки бәгъзеләрнең риваяте буенча, Мусин-Пушкин дигән губернатор мөселманнарга үзе төшеп, йорт урыны үлчәп биргән. Хәзердә Захарский урам диерләр. Җиһанша байлар урамы һәм аннан ары Пеләтәнгә чаклы һәммәсе шул губернатор үлчәп биргән җирләрдер. Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре әйтәдер — бу сүзләрне әткәбез Сөләйман үзенең атасыннан риваять кыйлып сөйләр иде, диер.

Янә Сәгыйд мөәзин үзенең атасыннан риваять кыйладыр (вә һәм Рәхмәтулла Әмирхановның риваяте): бу Аксак Каратун заманасыннан соң, ягъни Әби патша заманасында — Екатерина Вторая заманасында — тәкърибән 1770 елларда Әби патша Казанга килгәч, мөселманнарның һәм олуг байлары Әби патша катына кереп гарызнамә биргәннәр, бистәгә таш мәсҗет салырга рөхсәт сорап. Вә һәм Әби патша Казан байларының гарызын кабул итеп, таш мәсҗет салырга рөхсәт биргән вә һәм мәсҗет урынын үзе килеп тәгаен кыйлган; вә һәм мөселманнарны бик яраткан; Казанда торган мөддәтендә, һәмишә мөселман арасына төшеп: «Урыстан җәфа күрмимсез?» — дип сорашып йөргән. Мөселманнар бер дә урыстан шикаfive кыйлмаганнар.

---

[1] Гарыз иткәч — белдергәч, аңлаткач.

Янә 1772 елларда булган вакыйгалардан Пугачев кыйссасы бар; халык арасында мәшһүрдер, моның хакында Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре атасыннан тәфсилән[1] ишетеп, язып куйгандыр. Моны һәм гыйбарәте белән нәкыль кыйлынып язылыр. Мөхәммәдҗан Аитов язган билә дию.

## Пугачев хакында эткәй мәрхүм сөйләде

Пугачев әүвәлдә Дон казагы икән. Җаек буена барып, бер Җаек казагында ялчылыкта бер хуторда туар карап торгандыр. Сүзгә оста, йөреше-торышы сәясәтле, йөзе күркәм адәм икән. Ул заманда патша Пит Федорич үлеп, әмма халык арасында «тере, имеш, үлмәгән, имеш, качып йөри, имеш» дигән сүз бар икән. Бервакытны Пугачев(ка) ниндидер бер карт казак урысы әйтептер: «Син Пит Федорич түгелме?» — дип. Пугачев дәррәү: «Берүк, агай, бу сүзне һичкемгә чыгара күрмә», — дип тәзвир кыйлыптыр[2]. Шуннан соң мәзкүр карт казак, һәркемгә акрын-акрын: «Бак, гафил булмагыз[3], әнә ул Пит Федорич патшадыр», — дип күрсәткәләптер. Ул заманда Әби патша булгач, Җаек казакларына сакал китәреп йөрергә әмер булыптыр. Җаек казакларының сакалларын көчләп, ирексезләп китәрткәнгә күрә һәм өсләренә форменный мундир киерткәнгә күрә, бик гаҗиз булып җиксенеп[4] торган заманнары икән. Шуннан соң Җаек буенда Пугачевның исеме Пит Федорич дип шаег булып[5], халык аңа җыелып, әүвәл үзе хезмәт итеп торган хуторыннан ат-тунны алып, күтәрелеп чыгып, якындагы хуторлардан ялчы-малчыны ияртеп, аннан соң бөтен Җаек халкын ияртептер вә һәм бер заманда Оренбурга килеп, Оренбурны камап ятыптыр. Ул вакытта Оренбурда бик кытлык булып, күп халык ачлыктан һәлак булыптыр. Ул заманнарда безнең Аит бабайның энесе Сәгыйд Оренбурда торгандыр. Ул әйтер икән, халык шулкадәр ачыкты, хәтта тимерчедә ат дагалагандагы кырып ташлаган тояк итен ашадылар, диер икән. Вә һәм үзе Сәгыйд бабай, бер пот арыш оным бар иде, шуны яшереп җиргә күмеп асрап, һәр көн кирәк саен азрак алып, җылы суга изеп эчә торган идем, диер икән. Вә һәм әйтер икән, Пугачев камап яткан заманда Оренбур бүген йә иртән бирелә м дип торганда бер төнне Җаек суы

---

[1] Тәфсилән — җентекләп.
[2] Тәзвир кыйлыптыр — кисәтеп куйгандыр.
[3] Бак, гафил булмагыз — кара, игътибарсыз булмагыз, белми калмагыз.
[4] Җиксенеп — туеп, йөдәп.
[5] Шаег булып — халыкка билгеле булып.

юка гына катып, шуннан губернатор егетләргә әмер итте, никадәр кеше таякларга таянып, шуып чыгып, төнлә Пугачев гаскәренә ата башладылар һәм Пугачев гаскәре эшнең асылын белмәен, кайдан булса да, Оренбурга ярдәмгә килгән гаскәрләрдер, дип гөман кыйлып, һәркайсы күтәрелеп, башбаштак качып беттеләр, диер икән. Вә янә әткәй сөйләр иде: шуннан соң Пугачев Казанга килгәндер. Әмма безнең Аит бабай ул заманда Җаектa икән*. Ул вакытта Җаекта сөйләшерләр икән, Пугачев Казанны алырга китте, дип. Аит бабай аларга әйтер икән, Пугачев Казанны тиз ала алмас, царь Иван Василич та җиде ел камап көчкә алган, диер икән. Бу сүзне Пугачев тарафыннан куелган Җаек утаманына җиткерделәр. Аннан соң утаман әмер итәр: Аит бабайны тотып, чи каеш белән беләкләреннән, ботларыннан будырып, кырга чыгарып ташларлар. Ул арада Аит бабайның дус-ишләре барып, утаманга гозер итеп, ул алай дип әйтмәгән, аның гөнаһысы юк, дип ыспайлап күрсәткәч, чишәргә әмер иткән. Ул арада күпме-азмы шул рәвештә яткандыр, кулы, боты шешеп чи каеш капланган, күренмәс булган икән; каешны кисеп, коткарганнар. Аит бабай шуннан соң тиз үк ике ефәк яулык алып, Пугачев гаскәренә әләмгә дип бүләк итеп, утаманга илтеп бирер. Янә Аит бабай әйтер икән, Җаекта аннан соң шундый низамсызлык[1] булды: минем ничә мең куй тиремне Җаек суының кичүенә күпер урынына түшәп, гаскәр чыгардылар, диер икән.

Әткәй мәрхүм әйтер иде, Пугачев Казанга килгәндә, мин шактый бала идем, диер иде. Ун яшьләремдә булса кирәк. Әүвәл Пугачев килер хәбәре чыккач, ул вакытта Казан губернаторы... дигән адәм икән, бистә кешеләрен Мәкәрҗәгә барудан мәныг кыйлды[2]. Аннан соң Пугачев Казанга килгәч, ул вакытта Казан татарларының кязгөзар адәме[3] югарыда Аксак Каратун вакыйгасында мәзкүр Кара Ибраһим дигән икән. Ул заманда безнең Аит бабайның өе Әфәнде мәсҗете каршында икән. Ул йорт урынында хәзердә Габдерахман Абизов йорты, соңрак мәдрәсәгә алдылар. Мәзкүр Кара Ибраһим бистә халкына әмер итептер, һәрни Мәкәрҗәгә барырга хәзерләнгән күмәч, бавырсак, сохари, икмәк, бал, май, йомырка, сыра вә һәм

---

* Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре риваять кыйладыр. Казан сәүдәгәрләреннән Җаекта иң әүвәл безнең Аит бабай сату итә башлаган. Аңарчы безнең Казан халкының Җаек белән эше булмас икән. Без кечерәк замандагы Җаек сәүдәгәрләренең күбрәге безнең бабайдан калган приказчиклардан вә малайлардан яки аларның балаларыннан калган сәүдәгәрләр иде.— *К.Н.*

[1] Низамсызлык — тәртипсезлек, законсызлык.

[2] Мәныг кыйлды — тыйды, тоткарлады.

[3] Кязгөзар адәме — башлап йөрүче кешесе, юл күрсәтүчесе.

моның кебек нәрсәләрне мәсҗет алдына китерергә вә һәм мәсҗет алдына скамьялар ясап, шул тәгамнарны[1] мәсҗет алдында скамьяларга өеп-өеп куйдылар, шуннан соң бер заманда Пугачев чирүеннән башкортлар килә башлады. Чуаш, чирмеш вә һәртөрле җыентык халык, бәгъзесе поп киемнәре, вә бәгъзесе штуф киемнәр, вә бәгъзесе хатыннар җиләне* игәннәр иде. Үзләре яланаяк вә бәгъзесе башына марҗа сарафаны, вә өстенә марҗаның ефәк киемнәрен, штуф киемнәрен киеп, корал, сөңге, мылтык, бәгъзеләрендә тимер сәнәк, чалгы, вә һәм бәгъзеләре агачның башын гына утка көйдереп, сөңге кебек иткән иде. Картлар вә мәзкүр Ибраһим башлык һәммәсе җыелып мәсҗет алдында торыр иделәр. Пугачев гаскәреннән килгән халыклардан башкортлар: «Илмесез, җаумысыз?» — дип әйтерләр иде. Картлар: «Ил, ил»,— дип торырлар иде. Башкортлар: «Ил булсагыз, атайга барыгыз, бәйгать бирегез»,— диерләр, шуннан соң Казан халкы аларны атларыннан төшереп, ашатып, эчертеп җибәрерләр вә һәм киткән заманнарында янәдән, атайга барыгыз, бәйгать бирегез, дип китәләр икән. (Аитов Мөхәммәдҗан хәзрәтләре риваять кыйладыр: Пугачев Казанга килмәстән бер ел мөкаддәм безнең Казаннан берничә кеше Бөгелмәгә чирүгә һәм җибәрелгән икән. Ул кешеләрнең эчендә бар икән буяучы Мөхәммәдъярларның атасы Гобәйдулла яки бабасы Йосыф мулла микән, бик сугышчы кеше булгандыр. Бөгелмәдә мәзкүр Йосыф муллага Пугачев полковнигы Аит мишәр дигән адәм юлыгып сорашкан, бистәдә минем Аит исемле бер дустым бар иде, беләсеңме? дип. Беләмен, дигәч, аңар бер камчат бүрек бирептер. Моны хәзер генә урысның бер полковнигын атып үтереп алган идем, дип. Әмма ике хилаф якның кешеләре ничек юлыгышкандыр, белмимен.)

Шулай итеп ике-өч көн азапланып бигрәк кыстый башлагач, Ибраһим карт халыкка әйтептер: инде чара юк дип, вә һәм унҗиде кешене коралландырып, атка атландырып, уң беләкләренә Пугачев тарафының галәмәте — күк чүпрәк бәйләтеп үзе һәм җәяү күсәк таянып, Акком астыннан китеп, Мокрыйдан әйләндереп, Арча кырына бармак булып, мәзкүр унҗиде кешене башлап барганында, Мәскәү юлында зур тузан күреп әйтептер: «Һәй, егетләр, атыгыздан төшеп, иярләрегезне беркетеп, күк чүпрәкне сул кулыгызга бәйләгез,— дигән.— Аннан соң инде атланыгыз, бу тузан патшадан калага ярдәмгә килә торган Михельсон генералның гаскәренең тузаны булса кирәк, аңа барыгыз»,— дигән. Шуннан бу егетләр, томрап чабып, Михельсон гаскәренә барып кергәннәрдер.

---

* Ул заманда хатыннар җилән киядер икән.— *К.Н.*

[1] Тәгамнарны — ашамлыкларны.

Шул көннәрдә безне өйдә тотудан куркып Яңа бистәгә җибәрделәр*. Мине, Мусаны һәм бер асрау кызыбыз белән. Ләкин ни сәбәптер без Яңа бистә астында бер лодка астына кереп яттык. Муса бик шук иде һәм яшь иде. Көймә астында шукланып авазлангач, асрау кызыбыз: «Һай, харап итәсең»,— дип курыкты, шуннан соң кичкә таба өйгә кайттык. Анда ат үлеп ята, монда ияр ватылып ятадыр. Анда сөңге, монда кылыч калган. Гусарлар, урам-урам йөреп, Пугачев тәвабигъларын[1] кырып йөргәннәр икән. Бу эшләр, Михельсон килгәч, Пугачев сынып, таралып китте. Әмма крепостьта халык бик ачыккан иде. Ничә көнгәчә каланы ачарга рөхсәт булмады. Ибраһим карт җыелган азык-төлекне крепостька илтеп, туп тишекләреннән солдатларга өләшер иде. Шуннан соң калада мәхкәмә[2] ачылып, бунтовщикларның эшләрен тикшереп, бәгъзесен астылар, бәгъзесен кистеләр. Бер Исмәгыйль исемле качкын солдат бар икән. Пугачев гаскәрендә тупчы башы булып йөргән икән, ике бистә арасында астылар. (Хәзердә ул урында ат көтүенең ихатасыдыр.) Янәдән берәүне күл башында астылар. Янә бер Дон казагы, Пугачев сынганын белмәенчә, калага килгән икән һәм: «Кайда атай?» — дип сораган. «Атаң кем?» — дигәч, «Пит Федорич»,— дигән. Үзе бер зур сакаллы кеше икән. Шунда ук аның телен тартып кискәннәрдер.

Шуннан соң бунтовщиклар хакындагы мәхкәмәдә сөйләшкәннәр. Казан татарлары Пугачев белән бер иде, һәммәсен кырмак кирәк, дигәннәр. Мәхкәмә халкы һәммәсе риза булганнар. Әмма Михельсон гаскәрендә татардан чукынган бер генерал бар икән, ул кул куймаган. Әйткән, алар яраклары белән безнең гаскәргә ярдәм иттеләр, дигән, һәм шуннан соң калада бикләнгән солдатлар: «Әгәр дә татарлар туйдырмаса, без үләр идек, Пугачев каладан чыгып киткәч, татарлар туйдырды»,— дигәннәр. Шуннан Казан халкы урыс гаскәренең ярдәмчесе дип мәдех кыйлынып калды, диер иде.

Бу Казанга Пугачев килгән елны, ягъни 1774 ел, Пугачев Казанны тәмам яндырып харап иткәндер. Пугачевка чаклы крепость әйләнәсендә әллә ничә манарасы бар икән, ватып бетергәндер. Пугачевның Казанга килгән заманын элгәре замандарак картлар эпоха итеп, ягъни тарих кебек итеп сөйләшерләр икән. Бер-беренең яшен сораганда: «Син Пугачевта

* Ибраһим Бикбау углы Нагаев үзенең атасыннан риваять кыйладыр вә һәм аның җәмәгате Хөсниҗамал үзенең атасыннан риваять кыйладыр икән: күп Казан халкы Пугачев заманында, Казаннан качып, тау ягына Ташкичү дигән авылга качып киткәннәрдер, диер икән, һәм Ташкичү халкы күбесе Казаннан барган адәмнәрдер.— *К.Н.*

[1] Тәвабигъларын — иярченнәрен.

[2] Мәхкәмә — суд.

ничә яшь идең?» — диерләр. Берсе «ун яшьтә», берсе «өч яшьтә» вә бәгъзеләре «мин Пугачев ел туган» вә бәгъзеләре «мин ана корсагында калган» диерләр. Вә янә Пугачев Казаннан гайре авылларга йөреп, күп һәлаклек салгандыр. Казанның Ибраһим Бикбау углы Нагаев үзенең атасыннан риваять кыйладыр (Бикбау Пугачев заманында 15 яшендә икән): Пугачев Лаеш округында берничә авылларда, мәсәлән, Күндә, Кара Баянда алпавытларны кырга чыгарып, дарга астырды вә һәм гайре авылларда бу заманда күп фитнәләр булды, диер икән.

## ЗӨЯ ӨЯЗЕ АВЫЛЛАРЫ

Халыкның риваяте буенча, Зөя өязендәге бәгъзе авыллар хакында берничә сүз сөйләмәстән элгәре, ләкин Зөянең үзенең кайсы вакытта салынганын бәян кыйлырга хаҗәт төште. Иң әүвәл башта Зөя каласын салган Иван Василич Грозный дигән патша, Казанны алмастан элгәре, 1551 елда.

Иван Василич Казанны килеп алмакчы булгач, үзенең ратникларына боерды: Казанга якын җирдә бер кала салырдай яхшы урын эзләргә. Ратниклар юлга чыктылар. Килеп бер җиргә туктадылар. Хәзердә ул җирдә Исакау һәм Кужамка дигән авыллар бар. Ул чагында Исакау белән Кужамка арасында ике тау бар иде: хәзердә һәм бар. Шул таулар өстенә кала кормакчы булдылар. Монда кала салсак, уңай булыр микән, дип, тагы яхшырак тикшереп карадылар. Әгәр дә анда кала салсалар, шул ике тау арасын дамба белән тутырып, ике тауны бергә кушарга кирәк буласы булды; хәзинәнең кувәте җитәсе түгел; шуның өчен анда кала салуны мәслихәт күрмәделәр, янә аннан киттеләр; хәзердәге Зөя каласы урынына җиттеләр. Яхшылап тәмам тирә-ягын тикшереп, карап йөрделәр һәм, кала салырга бу урынны мәслихәт күреп, Иван Василичка әйтергә киттеләр.

Барып Иван Василичка сөйләделәр. Әйттеләр, кала салырга бер мәслихәт урын таптык, бер тау өстендә бик һәйбәт урын бар, тауның бер ягында Зөя суы дигән елга ага, янә бер ягында бер елга бар, исемен белмәдек, ләкин щука балыклары бар, ул елга һәм байтак зур елга, икесе дә Иделгә коя, бик ерак бармый, диделәр. (Ул чагында Щука суы Зөядән ким түгел иде.)

Иван Василич:

— Инде алайса, ул елганың исеме Щука булсын,— диде һәм шул җиргә барып кала салырга боерды: — Ул каланың исеме һәм Зөя каласы булсын,— диде. Аннан соң Иван Василич боерды — Зөя тавының иң биек җиренә киндердән чиркәү ясадылар. Бу хәбәрне Казандагы татарлар ишетеп, бик куркыштылар. Урыс патшасы Казанны алырга килә икән, дип гауга купты.

Зөя каласы хосусында моннан башка янә бер риваять бар, әмма бусы дөресрәккә охшый. Бәгъзеләр ошбу рәвешчә риваять кыйлалар: элгәре Зөя каласы урынында җимеш, йөзем, алмагач бакчасы булган. Иван Василич килеп, шул урынга кала сала башлагач күрде: Казан ерак түгел, ихтимал Казан ханы бу эшне сизеп, эшебезне туктатыр дип, әмер кыйлды: кала салганда Казан ханы күрмәсен дип, Казан ягына зур киндердән чаршау кордылар. Алай булса да, бу хәйләнең файдасы озакка бармады. Казан ханы манара башыннан подзорный труба белән карап күрде: Зөя тавындагы бакчасында бер төрле галәмәт бар. Инде моны Казан ханы белсә дә, ни вакыйгалар булгандыр, һәрничек Зөя каласы — чаршау арты каласы — бар да бер, каланы салып тәмам иткәннәрдер.

**Әҗәл авылы** — хәзердә Әҗәл һәм икедер: берсе татар Әҗәлесе, янә берсе урыс Әҗәлесе. Ул Әҗәл мулласының углы атасыннан риваять кыйладыр, ул риваять кыйладыр икән шул Әҗәлнең Ишем мулладан: бу авыл Әҗәл яки Әҗәле дип аталуның сәбәбе шулдыр — бу авылга иң әүвәл килеп урнашкан кешенең исеме Хаҗ Гали дигән кеше икән, Хаҗ Гали дигән кешене кыскартыбрак Аҗәли йөрткәннәр, шуннан Әҗәле булып калгандыр. Ул Хаҗ Гали исемле адәм алты кеше белән Болгардан килеп, авыл булып утырганнар. Бу кешеләр элгәредән үк Болгардан килеп, монда сату итәләр икән. Болгардан тире-яры алып килеп, монда киндергә кызыл мал алышып китәләр; Казан ханлыгы заманында Үтәк каласында ярминкә буладыр икән. Бу Әҗәле авылы бик күптән бардыр. Моңа гуаһлык бирәдер: Әҗәл зиярәтендә бер таш бар, язылганына дүрт йөз елдан артык. Без Әҗәле мулласы һәм борадәрем Габделкави белән барып, әүвәл бик яхшы тикшереп укыдык. Ташның бер кырында калган язуы бары: «Талиб эд-дөнья в әлмәүти мотыйәтен»[1] дигән сүз генә калган. Икенче кырыендагысын укырлык түгел. Ташның йөзенә язылганы башында — ахырында язуы беткән; таш ярылып төшкән. Урта җирендә калганы ошбудыр: «Тарих сикез йөз сиксән алтыда Чура углы Дулгәнур фани сарайдин бака дарины мәкам идти[2]. Рәбигыләүвәл...» дигән сүзнең соңындагысы беленми, уалып жиргә баткан. Янә «Чура углы» дигән сүзенең алдында бер сүзнең бәгъзе хәрефләре генә калган, таныр хәл юк. Бу ташның язылганына 404 ел буладыр, 1469 елларда язылгандыр. Әмма хәзердәге Әҗәле элгәреге урыныннан күчеп, икенче җиргәрәк утырган, диләр. Иске Әҗәле урынында шул Хаҗ Гали коесы урыны бар хәзердә дә, диләр. Ләкин без барып карамадык.

---

[1] « Дөнья куу — әҗәлгә атлану» дигән мәгънәдә.
[2] «Фани дөньядан китеп, мәңгелек йортта урын алды» мәгънәсендә.

Ул Әҗәле авылы, бара торгач байтак зураеп, ике йөз йортлап булганнардыр. Ничә урамнары бар икән. Аннан соң Казан ханлыгын урыс алгач, Әҗәле халкын урыслар килеп-килеп җәфа кыйлалар икән. Анда-монда узсалар, олау сорап, ат сорап, бирмәсәләр, көчләп алып, талап китәләр икән. Урысның бу җәфасына чыдый алмыйча, төрле авылларга таркалып беткәннәр. Бәгъзеләре урыс диненә кергәннәр. Хәзердә урыс Әҗәлесе шуннан калгандыр.

Бикмәмәт мулла риваять кыйладыр икән: шул тирәдә бер якын зиярәт бар, мукшы зиярәте дип атыйлар икән. Ул зиярәткә хәзердә дә дога кыйлырга баралар, барып Коръән укыйлар икән. Ул зиярәттә изгеләрдән бәгъзе адәмнәр бар, имеш. Ул авыл мөселман авылы булган икән. Ул мукшы авылы Болгар таркалмастан элгәре һәм бар икән. Әҗәледә мулла булып торган адәмнәр тәхминән 1626 елларда Әҗәледә берәү имам булып торган — Җәмәд дигән кеше. Аннан соң Габдерәшид исемле кеше имам булган, 90 яшендә вафат булгандыр яки йөзгә кариб[1]. Аннан соң Габдерәзак мулла дигән кеше имам булган. Аннан соң Ишем дигән кеше имам булган, 95 ләрдә вафат, диләр. Янә аннан Бикмәмәт мулла дигән кеше имам булган. Яхшы галим вә күп тәҗрибә иясе вә һәм мөхафәзәле[2] кеше иде, диләр, сиксәннәрдә вафаттыр, бик күптән түгел. Аннан соң Әҗәленең үзендә имам булган кеше юктыр. Хәзердә Мамадышка табигъдыр[3]. Бикмәмәт мулланың углы хәзердә Мамадышта имамдыр.

**Панау авылы** — «Казанские ведомости»ның бәгъзе номерында күренәдер: әүвәл башта авыл салып утырган кешенең исеме Панай дигән икән; бу авыл аның исеме белән аталгандыр. Ул кеше бик батыр, куәтле, хәйләкәр кеше икән. Бервакытны үгез угырлап суеп, үгез тиресеннән үзенә торырга куыш яки салаш ясаган; шул сәбәпле хөкемгә бәйләнеп, җәзага тиешле булгач, диннән чыгып, җәзадан котылган. Ул вакытта урыс хөкеме икән; Казан алынганнан соң булырга кирәк. Ләкин моны алай димиләр.

Бәгъзеләрнең риваяте буенча, аның дөресрәге ошбу булырга кирәк: бер Николай дигән качкын поляк шунда килеп урнашкандыр: бик батыр, көчле, куәтле, хәйләкәр кеше булган, тирә-як кешеләре аңа күбесе баш биреп, багынып торганнар. Бер ише усал-унтакны үзенә җыеп, шайка ясап, аларга баш булып, пан булып торгандыр. Шулай җыелып бер авыл булып киткән. «Пан» — поляк сүзедер: господин яки әфәнде дигән сүз урынына әйтеләдер. Юкса пан, панай яки панау дигән сүз-

---

[1] Кариб — якын.
[2] Мөхафәзәле — тыйнак.
[3] Табигъдыр — буйсынгандыр, ияргәндер.

ләрдән төптә татар сүзе исе килмидер. Панаудан Норлатка бер юл бар икән, Николай юлы дип аталадыр. Шул пан Николай үзе салган юлдыр һәм ул пан Николай шул тирәдә бер чокыр казып калдырган; төнлә йөргән кешеләрне шул чокырдан пәриләр чыгып, чокырга тартып төшерәләр, дип, төнлә ул чокыр яныннан узарга куркалар икән. Шул сәбәпле һәркем ул чокыр яныннан узса, бер чыбык сындырып ташламыйча, ул чокырдан узмый. Бәлки, белмәгән кеше ташламаса ташламыйдыр икән. Инде ул эш гадәт булып калган: курыкса-курыкмаса, һәркем узганда, ул чокырга чыбык сындырып, йә булмаса үлән йолкып ташлыйдыр. Әмма ничә елдан бирле ул чокырга шулай чытыр ташлый килсәләр дә, һаман ул чокырда чыбык өелеп ятмыйдыр һәм күренмидер дә, диләр. Ташлаган чыбыклар кайда китә торгандыр? Мин семинариядә хезмәт иткән вакытымда шәкертләрдән фамилияләренең мәгънәсен сорый торган гадәтем бар иде. Панов фамилияле бер шәкерт бар иде. Сораганымда, пан дигән сүздән чыккан, поляк сүзедер, диде.

**Мамадыш авылы** — моннан башка янә шул тирәдә өч-дүрт авыл бар; бер кешенең балаларыннан таркалгандыр. Ягъни биш авыл бер исем белән аталадыр. Берсе — хәзердә Мамадыш дигәннәре — Мамадыш-Әкил дип йөртәләр. Янә Танай авылын Тәүгилде-Мамадыш диләр. Янә Салтыган авылы бардыр; аны Мамадыш-Салтыган дип атаганнар; хәзердә Ышналы башы дигәннәре шул авылдыр. Янә анда Багай дигән урыс авылы бардыр; Багаево-Мамадыш диләр икән. Янә Арсланово дигән урыс авылы бар; хәзердә аны Мамадыш-Арсланово дип әйтәләр. Янә Гордеево дигән урыс авылын Мамадыш-Гордеево дип йөртәләр. Бу биш авыл барысы да бер кешенең балаларыннан чыккандыр. Берәү — Җәмәд дигән кеше, үзенең биш углы, бер сеңелесе белән Болгардан килеп бер җиргә утырганнар.

Бәгъзеләр риваять кыйлалар: бу кеше үзе Биләр шәһәреннән килгән кеше икән. Янә бер риваять бар, түбәндәрәк язылыр. Хасыйле[1], ул Җәмәд Мамадышның җәмәгатьләре, бала-чагасы күбәеп, бәгъзе балаларын аерып чыгаргандыр. Бер углы Мәмәткол атлы икән; ул углы бер авыл булып утырган; хәзердә Мамадыш Әкил дигәннәре шул авылдыр. Янә икенче углы Тәүгилде атлы булган икән; ул үз алдына бер авыл булган; хәзердә ул Танай авылыдыр; Тәүгилде-Мамадыш дип йөртәләр. Өченче углы Габделхаликъ исемледер; ул һәм үз алдына бер авыл булгандыр; хәзердә ул Багай авылы дигән урыс авылыдыр. Янә дүртенче углы Арслан атлы булган. Хәзердә Арсланово дигән урыс авылы, бар; шул Арслан дигән кеше авыл булып утырган. Янә бишенче углы Гордеево дигән авылны ясаган кешедер.

[1] Хасыйле — кыскасы, нәтиҗәсе.

Ләкин бу углының исеме мәгълүм түгел. Бара торгач, бу өч авыл урыс авылы булып калганнардыр. Янә ул Җәмәднең сеңелесе Сагындык исемле икән; хәзердә Сатлыган дигән авыл аннан калгандыр; хәзердә Ышналы башы дип йөртәләр. Әмма «Казанские ведомости»ның номерында бишенче углы Горди атлы икән, дип язсалар да, ул хатадыр; аның исеме мәгълүм түгелдер. Горди дигән сүз гөрли дигән сүздән бозылгандыр. Тавышы бик зурга күрә Гөрли дип атаганнар. Ул кешенең Мамадышта сөйләшкәне Әҗәлегә ишетеләдер икән. Бик зур тавыш белән кычкырып сөйләшсә кирәк. Мамадыш белән Әҗәле арасы җиде чакрым; аның тавышы җиде чакрымнан аермачык ишетеләдер икән. Бикмәмәт мулла үзенең бабаларыннан шулай дип риваять кыйладыр икән. Иске заманда Мамадыш авылында кемнәр имам булып торгандыр, мәгълүм булганы юк. Ләкин элгәре бер заманда Кадер мулла дигән кеше имам булган. Аннан соң Мөхәммәт Шәриф мулла булган. Аннан соң Шәмсетдин мулла, хәзер дә сәламәт, туксаннарда бардыр, диләр. Янә яңа имам булгандыр Әҗәленең Бикмәмәт мулла углы Таҗетдин исемледер. Янә Мамадышта берәү бар — Гайнулла исемле, хәзердә мөәзин булып тора. Гайнулланың бабалары һәм Биләр шәһәреннән килгәндер. Атадан-бабадан мөәзин була килгәннәрдер. Аның бабалары кыргыз-казах нәселеннәндер. Гайнулланың атасы Хәбиб мөәзин булган. Аның атасы Корбангали диләр икән. Аның атасы Габид, аның атасы Кадер мулла; Мамадышта имам булып торган шул Кадер мулладыр. Аның атасы Сабыргуҗа, аның атасы Мәмсә, аның атасы Чупай, аның атасы Үти, аның атасы Барбулсын, аның атасы Байсар; бу Байсар баба үзе Биләр шәһәреннәндер. Янә Габиднең икенче углы бар икән — Хәлил дигән кеше; бик изге адәм булгандыр. Аның углы Мөхәммәдъяр исемле. Чүтидә имам булып торгандыр, хәзердә вафат.

Танай авылында шул Мамадыш бабалар нәселеннән берәү Әҗе дигән кеше булгандыр. Аның углы Бимәт, аның углы Мөхәммәдкол, аның углы Дәмин, аның углы Мулла-Әмин исемле кеше булган. Ничә заманнар ул авылда имам булып торгандыр. Аның углы мулла Мөхәммәдша һәм шул авылда имамдыр. Аның углы Хәсәнҗан һәм имамдыр. Танай авылы зиярәтендә һәм өч-дүрт таш бар; ләкин берәрсен укырга мөмкин булмады. Танай авылы мулласы Мөхәммәдша һәм борадәр Габделкави белән өчәү барып, укып, язып алдык. Ике ташны яхшы таныдык; ләкин ташның югары башында тәмам уалып төшкән вә һәм түбән башы җиргә баткан; ташының уртасы гына, ягъни тарихы һәм исеме генә калган. Берсендә язылган ошбу сүзләр: «Тарих тукуз йөз иллекдә[1] Уждага әфәнде углы Агдәү-

[1] Милади белән 1543 ел.

ләт даре фәнадин даребәкага рихләт кыйлды*. Әмма кайсы айда икәнен танып булмый. Ак Дәүләт дигән исем ишетелгәне бар; «каф» урынына «гаен» язылгандыр, шул заманның мөхрәҗенә[1] карап. Бу таш һәм Шигале зиярәтендәге таш кебек бары бер кеше кулы белән язылгандыр.

Риваять кыйлалар: анда Уждага әфәнде дигән бер кеше бар икән, ул Уждага әфәнде голямадан булгандыр һәм мөдәррис икән; кайсы авылда дәрес әйткәндер, мәгълүм булынмады; яки сораша торгач беленер. Бу ташның язылганына 340 ел буладыр; 1533 елларда язылгандыр — Казанда ханнар заманында. Янә бер таш бар. Моның һәм уртасы гына калган; югары башы һәм түбән башы укырга мөмкин булмады. Бер хәрефе дә беленми, бары тарихы белән исеме калган. Бу рәвешчә: «Тарих тукуз йөз кырык өченчедә[2] җөмәдиялахырның башында Ямгуҗи углы Ирдинжи» дигән сүз бик ачык беленә, әмма дөньядан үтте дигән сүзе укырлык түгел. Хәреф галәмәтләре бер дә калмаган. Баягы таш белән бервакыттарак язылгандыр. Язылганына 347 ел буладыр; 1526 елларда язылгандыр. Ямгуҗи чуваш исемедер; Ямгуҗи исемле чувашлар бу заманда да ишетеләдер. Исеме чувашча булган белән, чуваш кабере дип уйларга ярамый. Ул замандагы мөселманнар чуваш белән бик катышкан. Чуваштан бик күп халык мөселман булган. Чувашка кыз биргәннәр, чуваштан кыз алганнар. Риваять кыйлалар: моннан мөкаддәм 150 ел яки артыграк елларда урыс исеме белән аталган мөселманнар күп икән. Безнең гомеребездә бәгъзе кешеләр бар урыс исеме белән. Шул сәбәпле әүвәлге ревизия язылган елларда кайсы кешенең исеме урысча булганны керәшен дип әйтеп язганнар. Шундый халыкның 1727 елларда биргән кәгазьләренең решениесе хәзердә дә тәмам булганы юк. Ахры, бу авылларның Мамадыш дип аталуына сәбәп шулдыр. Ул Җәмәднең балалары берсе агасы янына барганда юлда берәү очрап: «Кайда барасың?» — дигән. Ул әйткән: «Мәмәдәшләргә барам», ягъни туганнарым-имчәктәшләрем катына барам, дигән икән. Шул сүздән чыккан Мәмәдәшләр авылы, ахры, Мамадыш авылы дип исем калган.

Бәгъзеләр риваять кыйлалар: бу Җәмәд дигән адәм Мамадыш каласында, кадим булган Бабадыш бабаның нәселеннәндер. Иске заманда Болгарда «Мәмәдәш» дигән берәүнең ләкабе булгандыр. Монда янә башка төрле риваятьләр бардыр.

**Югары Шырдан** — югарыда бәян ителде. Шырдан булмастан элгәре иске заманда Бишбатман мөселман авылы булгандыр. Ул заманда Болгардан берничә кешеләр Бишбатманга

---

* Бу бетәчәк дөньядан мәңгелек йортка күчте.

[1] Мөхрәҗенә — әйтелешенә.

[2] Миляди белән 1536 ел.

килеп-китеп йөриләр икән. Зөя янында бер күл бар; хәзердә Ырдан күле дип атала. Болгардан биш-алты кеше чыгып, җәй көнендә һаман ул күл янында хайваннар ашатып, симертеп, кыш булса, Болгарга кайтып китәләр икән. Аннан соң, Болгар тар- калгач, бу тарафны хуш күреп, монда күчеп килмәкче булганнар. Шул күл янына йорт-җир корсалар тугыры килмәгән; аның өчен: ул җирне яз көне су басадыр икән, дип, Бишбатманга белешләре вә карендәшләре янына киңәшкә барганнар.

Ул вакытта Бишбатманда Бикташ дигән бер кеше бар икән. Аның белән урын карарга чыгып, төрле җиргә ятып йоклап караганнар. Әүвәл Бурабия урынына ятып йоклаганнар. Төшләрендә чиркәү авазы ишеткәннәр. Анда утырырга күңелләре тартмаган. Ул чагында Бурабия авылы юк икән. Бурабия яңарак булган урыс авылыдыр. Шырдан кыры элгәре Белаволга кырына тоташкан икән, дип сөйләшәләр. Аннан соң хәзерге Иске Йорт дип әйтәләр. Югары Шырдан кырында бер уйсу җир бар, шул җиргә ятып йоклап караганнар; аннан соң шул җиргә утырмакны мәслихәт күреп, шул алты кеше анда килеп утырганнар. Ул алты кешенең берсе үзенең ике углы белән килгәндер. Әмма үзенең исеме мәгълүм булып калмаган. Бер углы Бираш (Бәйраш?), икенче углы Атна Хуҗа дигән кешеләр икән. Хәзердә Иске Йортта Атна Хуҗа күле дигән чишмә бар; шул Атна Хуҗа казыган чишмәдер. Әмма Бираш белән Атна Хуҗаның аталары монда күчеп килгәч, озак тормаган — хаҗга китеп, шунда вафат булып калган. Бик бай кешеләр икән. Ничәшәр мең баш җылкылары, сыерлары бар икән. Янә бер чишмә бардыр: Бираш кизләве дип йөртәләр; хәзердә ул кизләү Ачасыр кырында калгандыр. Шул Бираш баба казыган кизләү дип риваять кыйлалар.

Янә ул Бирашның атасы белән бертуган адәм бар икән, Әсгади исемле — бабалар башы дип йөртәләр икән. Ул Әсгади Бишбатманда торган. Аның нәселләре мәгълүм түгел. Бәлки, аның нәселе Кошманда булырга кирәк, хәзердә бабалар нәселе Кошмандыр. Кошман хосусында бәяны килер. Бирашның балалары булган. Ләкин берсенең генә исеме мәгълүмдер: Габдерәзак дигән бер углы бар икән; бик укыган, мулла кеше булган. Заманында Әбдерәзак мулла диерләр икән. Безнең ерак бабабыз шулдыр. Ләкин безнең вакыйган ерак бабабыз Бираш булса да, Габдерәзакның гыйлеме, дәмуллалыгы вә шөһрәте сәбәпле, Габдерәзакка туктатылды. Ахры, ул кешеләр Иске Йорт урынында озак тормаганнар, хәзердәге Шырдан урынына күчеп килгәннәр. Урман эченә алан ясап, урманны ачып утырганнар. Хәзердә дә авылның югары башында бер куаклык бар — Алан башы диләр, искедән калган исемдер. Шул Иске Йорт дигән җирдә бу вакытта бәгъзе йорт нәрсәләре табалар — балтадыр, пычактыр, шуның кебек нәрсәләр. Ул заманда

Бишбатман белән Шырдан арасында бик калын урман булган. Бишбатмандагы шул Бикташ исемле кеше килеп, Бирашлар катына килеп-китеп йөрергә үзенә урман эчендә юл ачкан. Бикташ юлы дигән юл хәзердә дә бар.

Шырдан мулла(сы) Габденнасыйр мәрхүм сөйләгәне бар иде. Бу Урси баба үзенең бабасыннан риваять кыйладыр икән: Габдерәзак мулланың дүрт углы булган — берсе Йосыф исемле икән, калган өч углының исеме мәгълүм түгел (түбәнрәк бәян кыйлыныр). Габдерәзак баба үзенең заманасында бик мәшһүр бай кеше булган икән. Чар[1] Иван Казанны алган заманда Габдерәзак баба сәламәт икән. Шул сәбәпле чар Иван дип халык телендә калган. Ул чар Иван дигәннәре Иван Василич Грозный булырга кирәк. Хәзердә дә бер-бер төрле бик кадимге иске нәрсә хосусында сөйләшкәндә әйтәләр: чар Иван заманыннан калган нәрсә яки чар Иван заманындагы нәрсә, диләр. Хәтта карчыклар арасында һәм бар, хатын кеше тәварихны төптә күрмәгән булса да. Янә Фәтхулла баба риваять кыйладыр Урси бабадан вә һәм Рәки баба риваять кыйладыр Мәмәт бабадан: Габдерәзак мулла бик гайяр, бай кеше һәм мулла кеше икән. Үзенең заманасындагы тирә-як халкы арасында начальник булып торган; кычкырыш вә дәгъвалары булса, Габдерәзак бабага килеп хөкемгә торалар икән. Габдерәзак аларны килештереп, хөкем итеп җибәрәдер икән, вә һәркайсы аның хөкеменә риза булып китәләр икән. Габдерәзакның ишегалды гыймарәте вә каралтылары бик зур булган; авылның югары башында чирек авылга чаклы күрсәтәләр. Ишегалдының егерме җирдән капкасы бар икән, диләр. Үзе тәкъва[2] вә диянәтле[3] адәм булгандыр. Бик картлыкның чигенә җитеп үлгәндер.

Сабит Җәмил углы Мөхәммәдъяр бабадан, Мөхәммәдъяр баба атасыннан риваять кыйлып сөйләшәдер икән: Габдерәзак мулла патшалар белән таныш булган. Пидыр Иванич[4] заманасында Габдерәзак баба мәшһүр кеше булып, Пидыр Иванич аны тау як халкына баш итеп куйган, имана шикелле халыктан җыя торган ясакларны акчадан, иген-тарудан җыеп, Пидыр Иваничка җибәрәдер икән. Һәрбер хәзинәгә тәгаллыклы[5] эшләр, гошерләр булсын, хәзинәгә Габдерәзак аркылы барыр икән вә янә моның кебек эшләр һәммәсе аңар тапшырылган икән.

Вә янә риваять кыйлалар. Хәсән баба үзенең атасыннан ишетеп сөйләр икән: Габдерәзак бабайга тирә-яктан гошер килгәндә, юлларны, күперләрне төзәтерләр икән; аңар китер-

---

[1] Чар — царь.
[2] Тәкъва — дини моральгә табынган.
[3] Диянәтле — динле.
[4] Пидыр Иванич — Федор Иванович, Иван Грозный улы.
[5] Тәгаллыклы — бәйләнешле.

гән игенне бушатырга нәүбәт тимичә, күбесе кырда кунарлар икән. Габдерәзак баба авылның тышына бер кеше куяр икән, таяк белән нәүбәт[1] тамгасы биреп торыр өчен. Гошерләрне, ягъни китергән игеннәрне бушатып тәмам булгач, артып калган тамга таяклары күп замангача шул урында ятыр икән. Хәзердә таяк ташлаган юл, диләр, шуннан калган исемдер. Бу Габдерәзакның ике углы бик гайяр кешеләр булып, Габдерәзак баба шул ике углын военный киемнәр киендереп, шул заманда яңа патша ханлыкка утыргач, котлап, урыс ханына ат мендереп бәхеш кыйлган[2], ягъни атлары, кораллары, киемнәре белән тәмам баштанаяк военный кеше итеп җибәргән.

Бервакытны урыстан Богдан дигән җанарал Казанга киләсе булгач, Габдерәзакка әмер булып, урман эченнән юл ачтырганнар. Хәзердә Богдан юлы дигән исем шуннан калгандыр, Шырдан кырында. Аннан соң Габдерәзакның ул ике углы кайтып килмәгәннәр; Митри сугышында* һәлак булганнар. Урси бабадан риваять кыйлалар: Пидыр Иванич белән Габдерәзак мулла дин тугрысында сөйләшкәндә, Габдерәзак мулла әйтәдер икән: «Әгәр урманны бер генә төрле агач итә алсаң, урыс йортын бер диндә итәрсең»,— дип.

Вә янә каршы тауда Габдерәзакның салдырып куйган ашлык сарайлары бар икән, хәзинәгә китәсе ашлыкларны асрар өчен. Урыс ханы тарафыннан аңар бирелгән берничә казаклар бар икән, каравыл өчен. Ул каравыл өчен бирелгән казакның нәселләре күптән түгел вафат булдылар. Без Габдерәзакка бирелгән казакның нәселләре, дип йөрерләр икән. Бер Чапи казак дигән адәм бар иде. Үзенең бабаларыннан риваять кыйладыр икән: без Габдерәзак мулланың хан тарафыннан бирелгән казаклар нәселеннән, дип. Янә Фәтхулла баба риваять кыйладыр Урси бабадан, Урси баба сөйләр икән: бервакытны Габдерәзак мулланың өенә кунаклар җыелгач, сүз чыккан. Берсе әйткән: «Габдерәзак кебек бай кеше бу тирәдә юктыр»,— дип. Аңар каршы икенче бер адәм: «Юк, мин Ишморзаны Габдерәзактан баерак булыр дип беләмен»,— дигән.

Ул заманнарда янә бер Ишморза дигән бай кеше бар икән. Габдерәзак мулла моны ишеткәч, үзенең кешеләренә боерган: «Бар, әйтегез, малайлар вә хезмәтчеләр һәркайсы военный киемнәрен киеп, атларын атланып, ишегалдына җыелып, саф ясап тезелеп торсыннар»,— дигән. Габдерәзакның боерыгы буенча, барысы да җыелып килгәннәр; атларының дагалары һәм иярләренең өзәңгеләре һәммәсе көмештән икән. Ничә батыр колла-

---

* Сүз Ялган Дмитрий турында бара.

[1] Нәүбәт — чират.

[2] Бәхеш кыйлган — бүләк җибәргән.

ры бар икән. Ул заманның истиляхынча[1], «чура коллар» дип әйтәләр икән. Авылдан бер яктарак Габдерәзак үзенең колларына торырга йортлар салдырган икән. Хәзердә Шурагыл дигән бер урын бардыр. Шырдан кырында. Шул «чура кол» дигән сүздән Шурагыл булгандыр. Янә Габдерәзак бабаның ишегалдында коесы бар икән. Габдерәзак коесы урыны дип хәзердә дә әйтәләр.

Ахыр ул заманда урыс ханнары арасында да тынычсызлыклар күп булып, Габдерәзак мулланың дошманлык вә көнчелек кыйлучылары күбәеп, ахыр көннәрендә фәкыйрьлеккә төшеп дәүләте киткән. Шул сәбәпле тәзкирәләре[2] бер дә калмагандыр. Бик фәкыйрьлектә вафат булгандыр. Габдерәзакның бер углы Йосыф исемле икән. Аның углы Галкәй, аның углы Габделгазиз, Әбләрзи дип мәшһүрдер. Аның углы Әлмөхәммәд, бу Әлмөхәммәд һәм Мүки дип мәшһүрдер. Бу Мүки баба һәм үзенең заманасында бик мәшһүр гайяр кеше булгандыр. Урыс халкы арасында мәкъбуль[3], сүзе үткен кеше булгандыр. Шул заманада кайда угрылар бар, кайда ни-нәрсә угырлана — һәммәсен шымчылап, сизеп торадыр икән. Берәүнең бер атымы яки башка төрле нәрсәсеме җуелса, Мүки бабага килеп, Мүки баба кем угырлаганын шымчылап белеп, ул угырланган нәрсәне табып чыгарадыр икән. Угрылар, Мүки белмәсә ярар иде, дип куркып торырлар икән. Хасыйле, бу заманның Маҗар Фазлый шикелле адәм булгандыр. Шул сәбәпле бәгъзе адәмнәр аның хакында Мүки карак дип ифтира кыйлалар[4]. Ул Мүки баба үзе голяма катарәсеннән[5] булмаса да, гыйлем әһеле белән дус вә әшнә булуы сәбәпле, углын яхшы укыткан. Углы бик мулла кеше вә диянәтле кеше булгандыр. Безнең Хөсәен бабабыз шул Әлмөхәммәд углыдыр. Хөсәен баба бик озак яшәмәгәндер. Нәхү гыйлеменә бик маһир кеше булгандыр; нәхү гыйлемендә аның язган китаплары: «Шәрхе мелла», «Мисбах», «Сарыф һәваи», «Гавамил» вә дәхи моның кебек китаплары хәзердә дә бардыр. Бәрәзәдә чагында Сәгыйд хәзрәттән тәгълим[6] алгандыр. Бәрәзәдә язылган аның кулы белән «Кәшфеләсрар» дигән китап 1190 елларда, ягъни 1773 елларда язылгандыр. Ул заманнар китап, Коръән басыла торган басмаханәләр юк, халык кулында һәммәсе язган китап, Коръән булгандыр. Хөсәен баба язуга оста кеше булгандыр.

---

[1] Истиляхынча — әйтелүенчә.
[2] Тәзкирәләре — истәлекләре.
[3] Мәкъбуль — танылган мәгънәсендә.
[4] Ифтира кыйлалар — яла ягалар, гаеп ташлыйлар.
[5] Катарәсеннән — төреннән.
[6] Тәгълим — белем.

Риваять кыйлалар: Хөсәен баба Коръән язучы иде; үзенең гомерендә берничә йөз Коръән язгандыр, диләр. Аның кулы белән язылган Коръәннәр бәгъзе кеше кулларында хәзердә дә күренәдер. Күп еллар Шырданда имам булып торган адәмдер. 1805 елларда вафаттыр вә һәм аның гыйлеменең әсәре хәзердә баласының балаларында да күренәдер. Аннан соң аның углы пәдәребез[1] мулла Габденнасыйр атлыдыр. Һәм үз заманасының атасыдыр. Ягъни һәрбер мөбтәля кешегә вә аннан ярдәм эстәп килгән адәмнәргә ата кебек шәфкатьчән булган адәмдер. Шул сәбәпле изгелекле вә изгелеге күп булган өчен Әбүлхәер ләкабе кушылсын. Бу Габденнасыйр мулла үзенең заманында гайяр, үткен вә һәм бик зирәк адәм булгандыр. Вә һәм урыс телен кәмаһүә яхшы белгәндер.

Бик галим кеше, хәтта замананың галлямәсе[2] дип атасак та, садыйк[3] булыр. 1812 елларда Шырданга имам булыр өчен эшне йөртә башлагач, Сәли бабаның кызын никяхлаган, соңында имам булуны тәрек кыйлып[4], дөнья мөгамәләсенә катышканлык сәбәпле, ясалган приговоры мөфти мәхкәмәсендә шулай ятып калгандыр. Гәрчә указной мулла булмаса да, тирә-якта Насыйр мулла дип мәшһүр иде. Замананың галлямәсе иде. Әүвәл башта Мәчкәрәдә тәгълим алгандыр. Аннан соң Бәрәскәдә Сәгыйд хәзрәттән тәгълим алгандыр вә һәм Сәгыйд хәзрәт бистәгә килгәч, Сәгыйд хәзрәт белән Бәрәскәдән Казан шәһәренә килгәндер. Язуга бик оста иде. Хәзердә егерме бишләп үз кулыннан чыккан китаплар бар. Фарси һәм гарәби язуга маһир иде. Хосусән ахыр көннәрендә күп китап язды вә һәм тасниф кылынмыш ничә рисаләсе бардыр гарәп телендә. Бәгъзеләрнең «иҗтиһад заманы мөнкариз[5]» дигән сүзләрен рәд кыйлып[6] язган рисаләсе бардыр. «Иҗтиһад заманы мөнкариз» дигән кешене бер дә яратмас иде. Һәр бәндәгә иҗтиһад лазем эш, дип, балаларына һәрдаим ишеттерер иде. Балалары һәм хәзердә шул мәзһәбтәдер[7]. Вә янә кыз-хатын сабантуй дигән җирләренә чыгып, уен-көлке ясауны рәд кыйлып, бер кечерәк рисаләсе бардыр, гарәп телендә. Вә һәм ошбу җиремездә җәй көннәрендә ястү намазы сакыйт[8] дигән кешеләрне рәд өчен гыйшаның[9] вөҗүбен[10] исбат кыйлып язган бер рисаләсе бардыр. Ахыр көннә-

---

[1] П ә д ә р е б е з — атабыз.
[2] Г а л л я м ә с е — күп фәннән белемле, зур укымышлы.
[3] С а д ы й к — дөрес, чын.
[4] Т ә р е к к ы й л ы п — ташлап, туктатып.
[5] М ө н к а р и з — беткән, үткән.
[6] Р ә д к ы й л ы п — кире кагып, кабул итмичә.
[7] М ә з һ ә б т ә д е р — юнәлештәдер, юлдадыр.
[8] С а к ы й т — юкка чыга, төшеп кала.
[9] Г ы й ш а — кояш баюы кызыллыгы беткән вакыт, ястү.
[10] В ө җ ү б е н — зарурлыгын.

рендә тәкъва вә диянәт бабында фәриди гасыр[1] иде. Үзенең вафаты соңында язылмыш тәзкирәләреннән хисап кыйлынды. Ахыргы кыйлган егерме биш ел гомерендә мең дә өч йөз мәртәбә Кәляме Шәриф хәтем кыйлмыштыр[2], һичбер риясыз вә һәм зиядә мөтәшәрригъ[3] адәм иде вә башка мәнакыйбе[4] күптер. Монда барысын зикер кыйлмак мөмкин түгел — ахыр вәгъдәсе җитеп мең дә сигез йөздә җитмеш икенче елда мартның унсигезенче көнендә мәрхүм сиксән биш яшендә икән рух порыфтухлары тайран итте[5]. Шырданда хәзердә ике нәсел бар: Болгар нәселеннән түгел, дип риваять кыйлалар. Берсе чуваш нәселе, берсе чирмеш нәселе икән, диләр. Бәйри дигән кешенең анасы Торламастан килгән чуваш хатыны икән. Янә берсе Ишем дигән кешенең балалары чирмеш икән, диләр. Рәки баба Сәгыйд хәзрәттән риваять кыйладыр: Сәгыйд хәзрәт әйтер икән, Шырданда зур ут[6] булмас, иген биек булып китмәс, дип. Дөрес, моңар чаклы зур ут булганын әйтмиләр һәм иген-тару да бик ишелеп булганы юк.

Шырданда имам булып торган адәмнәр: Габдерәзак мулладан соң бер заманнар, тәхминнән 1650 елларда, Михаил Федоричлар патша булып торган заман булса кирәк, Шырданда ике агай-эне кешеләр булган: берсе Сәлам мулла, берсе Җәгъфәр мулла, диләр икән. Шул заманнарда мөселманнарга дин тугырысында тыгызлык булган. Ул вакытта Җәгъфәр мулла имам булып торадыр икән. Шул заманның низамынча, солдат алырга набор булып, берәүне солдатка бирергә алып киткәннәр. Чукынып котылган да кайткан. Шулай итеп, унлап кеше чукынып, солдаттан котылганнар, Җәгъфәр мулла үзенең агасына, Сәлам муллага әйткән: «Инде, борадәр, әгәр дә болай карап торсак, бу бәдбәхет һәммәсе дә чукынып бетәрләр болар, мин үзем солдатка китим, син боларны дингә өйрәтеп имам булып тор»,— дип.

Җәгъфәр мулла үзенең ихтыяры белән солдатка китеп һәм хезмәтен тутырып кайткач, янәдән берничә заманнар имам булып торгандыр. Янә аннан соң имам Әхмәд мулла дигән кеше булгандыр, 1700 елларда. Аннан соң янә бер Җәгъфәр мулла дигән адәм имам булган. Аннан соң Хөсәен мулла имам булгандыр. Аннан соң Әбсәлам мулла имам булган, чын исеме Габдессәламдер. Аннан соң Хөсни мулладыр. Аннан соң Һи-

---

[1] Фәриди гасыр — үз вакытының бердәнбере.
[2] Кәляме Шәриф хәтем кыйлмыштыр — Коръәнне тәмам укып чыккандыр.
[3] Мөтәшәрригъ — динле, тәкъва.
[4] Мәнакыйбе — мактаулы эше.
[5] Рух порыфтухлары тайран итте — батыр рухы очып китте.
[6] Ут — үлән.

бәтулладыр. Аннан соң хәзердә Габделкави мулла имамдыр. Баягы мәзкүр риваятьләр — кара Хәмид үзенең бабаларыннан риваять кыйлгандыр. Бу кара Хәмид дигән карт адәм мәзкүр солдатка киткән Җәгъфәр мулла нәселеннәндер.

**Мулла Иле** — бу Мулла Иленең асылы бик күптәндер. Монда бер Муллагыл дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр. Алар әүвәл килгәндә берничә кеше булып килгәннәр. Бәгъзесенең исемнәре мәгълүм түгел. Аларның берсе Муллагыл дигән кеше. Янә алар белән берәү бар икән, Шәехби дигән адәм. Ул үзенең бер углы белән килгән. Углы Теләш исемле галим кеше булгандыр; Мулла Илендә дәрес әйткән, мәдрәсә ихъя кыйлган[1]. Бу Шәехбинең атасы Тәмте дигән кеше. Асыл Кытайдан килгән кешедер. Болгар йортында Кытайдан, Һиндстаннан килгән кешеләр күп булгандыр. Болгар төзек заманда Болгар җирендә ярминкә булып, Һиндстаннан, Кытайдан сәүдәгәрләр килеп, сату итәләр икән. Шул сәбәпле аннан килгән кешеләр бәгъзе сәбәпләр белән бу җирдә калганнардыр. Мулла Иле бик кадимге авылдыр. Янә аннан соң ике йөз ел чамасында, яки 1660 елларда, Хуҗаштан байтак халык күчеп, Мулла Иленә кушылгандыр вә һәм Өҗемнән күп мөселманнар анда күчкәннәрдер. Өҗем дигән авыл (хәзердә Мәҗен дип йөртәләр) Зөядән ерак түгел авылдыр. Хуҗаш хосусында бераз баяны кичте.

Мулла Илендә Тәмте балаларыннан бер мулла Ишмөхәммәд дигән адәм булган. Теләшнең углының углыдыр; яхшы галим кеше вә һәм хафизе кәламулла[2] икән вә һәм кыйраәт[3] гыйлеменә бик маһир кеше булгандыр. Ничә ел Мулла Илендә дәрес әйткән. Ул заманда Мулла Илендә иген белән сату итүчеләр, байлар күп булган. Вә һәм Мулла Илендә зур пристань булган, вә һәм Борындыкта пристань булган. Бәрле сулары, Гөбенә сулары бик зур су булган, вә һәм Зөя суында суднолар, баркалар йөридер икән. Бу авыллар Үтәк каласы тирәсендәге авыллар булганга күрә, Үтәк каласына игендер вә һәм башка төрле малдыр җыеп илтүчеләр, байлар күп булгандыр. Мулла Иле зиярәтендә бер таш бар, гәрчә бик күптәнге булмаса да, шул Тәмте балаларыннан килгән нәселдер. Бу таш казып язылгандыр, ошбу сүзләр: «1199 сәнә[4] мөхәррәм ае, тәүфыйк Алладан, дөнья һәм анда булган нәрсәләр бетәчәк. Бу урында Габделхалыйк бин Габделбакый бин мулла Сәед бин Касыйм бин Ишмөхәммәд Хафиз бин Имбулат бин Ирежмес бин мулла Теләш бин Шәехби бин Тәмти-Хытай әл-Болгари күмелгән». Вә янә моннан башка бер яңарак таш бар, шул югарыдагы

---

[1] Ихъя кыйлган — төзегән, салган.
[2] Хафизе кәламулла — Коръәнне күңелдән белүче.
[3] Кыйраәт — уку, күрми кычкырып уку.
[4] Милади белән 1784 ел.

кешеләрнең нәселеннәндер, 1850 елда вафат булган. Мулла Илендә мөкаддәмрәк бер Вәлид ишан дигән адәм бар икән. Аны монда тәфсыйлән язылмады, якындагы кеше булган өчен (ләкин черновойда бардыр). Вә янә Мулла Иле зиярәтендә бер таш бар, бик күптәнге, бер хатын кешенең кабере булмак кирәк, ошбу рәвешчә язылгандыр: «Тарих тукуз йөз унда[1] Тәвәккәл гаялы Рәҗәб Солтан... Әсәд дарелфәнадин даре бәкага рихләт кыйлды». Ләкин югарыда язылган аятьләре ашыгычлык белән язылмады. Бу таш Норлат зиярәтендәге таш иясенең, ягъни Тәвәккәлнең әүвәлге хатыны булырга кирәк. Ул Тәвәккәл исемле кеше Норлатта булып, әүвәлге хатыны Рәҗәб Солтан Мулла Иленә килеп вафат булгандыр. Бу ташның язылганына 380 еллар буладыр; 1493 елларда язылган булырга кирәк.

**Бакырчы авылы** — Чуел өязендә бик кадимге иске авылдыр. Валлаһе әгъләм[2], җиде-сигез йөз елдан бирле Бакырчы авылы бардыр. Кадимрәк Бакырчы авылында Динмөхәммәд мулла дигән кеше булган. 1838 елларда вафат; 95 яшенә җиткән кеше, бик карт кеше булган. Тәварих китапларын күп күргәндер. Аның бер китабы янында мин күрдем: унике бабага чаклы шәҗәрәсе бар. Иллешәр ел хисапласак та, алты йөз еллар булыр.

Кадимрәк халык күп яшәгәндер, бәлки, мең елга карип булырга кирәк. Менә ул шәҗәрә: Динмөхәммәд Габдерәшид углы, Габбас углы, Уразмәт углы, Тули углы, Тани углы, Чики углы, Дирбеш углы, Түки углы, Җиркеш углы, Бүки углы. Мәзкүр Динмөхәммәд мулла үзенең Габбас бабасыннан риваять кыйлып сөйләр икән: кадим заманда Бакырчы авылы бик караңгы урман эчендә Әрә суы буена утыргандыр, шуның өчен Әрә Бакырчысы дип аталадыр. Әмма Бакырчы авылы төп Болгардан килгән халык түгелдер. Бәлки соңыннан җыелган халыклар булса булыр. Иң әүвәл башта Бакырчы мукшы авылы булгандыр. Үзләре мукшы булсалар да, мөселман булганнардыр. Бакырчылык һөнәре белән тереклек кыйлалар икән; шул сәбәпле бу авылны Бакырчы авылы дип атаганнардыр; һәм хәзердә бакыр затлар, тимер затлар табыладыр икән, иске, кадимге нәрсәләр. Әрә суы белән җомычкалар, адәм кулыннан чыккан нәрсәләр агып килгәнен күрсәләр, әйтәләр икән, анда да торучылар бар икән, дип. Иске заманда урманның аргы ягында авыл бар икәнен һәм белмәгәннәр, шулкадәр калын урман эчендә булгандыр. Хәзердә Бакырчы байтак зур авылдыр. Соңыннан төрле җирдән җыелып зурайганнар. Тәтеш өязендәге Бакырчының асылы бу Бакырчыдан чыккандыр. Хәзердә Бакырчы зиярәтендә кадимге

---

[1] Милади белән 1504 ел.

[2] Валлаһе әгъләм — Алла белә, кем белә мәгънәсендә.

бер бик иске таш бардыр, бу заманда бөтенләй уалып беткән. Әмма Бакырчы зиярәтеннән аның тарихын язып алган Шырдан Габденнасыйр мулла, 1855 елда. Ул вакытта ташның язулары укылырлык икән. Габденнасыйр мулланың китабы янында язылгандыр ошбу сүзләр: «Бакырчы зиярәтендә зиярәт гаһ Мөхәммәд Чәләби, вафаты һиҗрәт тарихы берлән 939 да»[1]. Янә икенче җиргә мәзкүр Габденнасыйр мулланың язып куйганы бар: «Бакырчы зиярәтендә хаҗи Мөхәммәдгали Чәләби, вафаты һиҗрәт тарихы белән 939 сәнәдә» дип; мәсихия[2] тарихы белән буладыр 1522 елларда, Казан алынмастан элгәререк. Әмма без Кармышның Нигъмәтҗан мулла вә һәм борадәрем Габделкави мулла белән 73 елда барып ташны укырга һичбер вәҗһен[3] тапмадык, чөнки таш тәмам уалып таркалып беткән, җиргә кергән кадәресе генә калган. Габденнасыйр мулланың язып куйган тарихына бинаән, ул Мөхәммәд Чәләби үлгәненә 351 ел буладыр. Мәзкүр Габденнасыйр мулла сөйләшә торган иде, Бакырчы Динмөхәммәд мулла унынчы бабаларының сүзен бу көнге шикелле итеп сөйлидер, дип. Ләкин ул Динмөхәммәд мулла белән без мәҗлестәш була алмый калдык, без кечкенә чагында вафат булгандыр.

Мәзкүр Динмөхәммәд үзенең бабаларыннан риваять кыйлып сөйләр икән: Чуел өязендә хәзердә Әҗе баба дигән чуваш авылы бардыр. Шул авылда хаҗи Мөхәммәд Чәләби дигән адәм бар икән. Ул заманда Әҗе баба авылы мөселман булгандыр. Мәзкүр Мөхәммәд Чәләби шул авылда ничә еллар дәрес әйтеп, ахры хаҗга барган. Хаҗдан йөреп кайтканда Истамбулда калып шөһрәт тоткан, солтанга мәгълүм кеше булган. «Ул заманда Истамбулда солтан Сөләйман хан дигән адәмнең падишаһлыгы вакытыдыр. Солтан Сөләйман ул хаҗи Мөхәммәд Чәләбине Истамбулда бер мәдрәсәгә мөдәррис итеп куйган икән. Ничә еллар анда дәрес әйтеп, ахры «Хөббел ватан — мин әлиман»[4] дип, үзенең туган җиренә кайтмакны мәслихәт күреп, монда кайтып күрсә, авыл каралып, күбесе чуваш булып калганнар. Аннан соң ул Мөхәммәд Чәләби бу сәфәреннән йөреп кайткач, монда аны Хаҗи баба дип йөрткәннәр. Шул сәбәпле аның авылы Әҗе баба дип аталгандыр. Әҗе баба хаҗи бабаның мөхәффафедер. Аннан соң үзенә авыру тигәч, үзенең якыннарына васыять кыйлган: мин үлсәм, мине Бакырчы зиярәтенә илтеп күмегез — бу бәдбәхетләр каралып беткәннәр — тәнем чуваш авылында калмасын, дигән. Аннан соң вафат булгач, Бакырчы зиярәтенә китереп куй-

---

[1] Милади белән 1532 ел.
[2] Мәсихия — Гайсә (Иисус Христос), христиан дине.
[3] Вәҗһен — юлын, ысулын
[4] «Ватанга мәхәббәт — иманнандыр».

ганнар, мәзкүр Хаҗи баба дигән адәм Истамбулда байтак дәрес әйтеп могтәбәр голямадан булгандыр. Ничә тасниф кыйлынмыш китаплары бар, имеш, дип, Динмөхәммәд мулла сөйлидер икән; әмма мәгълүм түгел. Истамбулда мөдәррис булып торганлык сәбәпле, чәләбилек дәрәҗәсен алгандыр. Чәләби бертөрле олуг дәрәҗә вә чинның исемедер.

**Тау Иле** — бу Тау Иле һәм күптәнге авылдыр. Мөхәммәдрәхим мулла риваять кыйладыр Әсән мулладан: Тау иленә иң әүвәл бер бик бай кеше килеп утырган. Ул кеше бохарлык бер сарт икән. Байлыгы сәбәпле Тәвангәр[1] баба дип йөрткәннәр. Тау Иленең элгәреге исеме Тәвангәр авылы дип әйтелгәндер; хәзердә Тау Иле дип йөртәләр. Ләкин бер биек тау итәгендә утырганлыгы җәһәтеннән түгелдер; бәлки тәшәэм[2] җәһәтеннән Тау Иле дип йөртәләр. Аның өчен: әгәр берәү Тәвангәр авылы дип атаса, бертөрле зәхмәт күрә, имеш, дип шомланып, Тау Иле дип йөртәләр. Хәзердә бик фәкыйрь, кечкенә авылдыр. Ул авылга бер газиз бәддога кыйлган, диләр. Кайсыбер газиз килептер дә, аңар фатир бирмәйләр. Ул кеше дога кыйлып киткән, илаһи утыз төтеннән артмагыз, дип. Янә моңар кувәт — Бикмөхәммәд мулла һәм үзенең бабасыннан риваять кыйлып сөйләшәдер икән: Зөядән ерак түгел хәзердә бер авыл бар, Мәҗен дип йөртәләр. Әмма элгәре аның исеме Өҗем дип аталгандыр. Анда Өҗем дигән бер изге кеше булган икән: Иван Грозный Зөя бакчасына кала салганда сугыш булган. Яки бәгъзе риваятьтә Казанда сугыш булганда, бу Өҗем баба шунда барып сугышкан. Аннан Тау Иленә килгән, канлы киемнәре вә җәрәхәтләре белән фатир сораган. Тау Иле кешеләре фатир бирмәгәннәр, шул сәбәпле бәддога кыйлып киткән, имеш, диләр. Ул вакытта Норлат авылы бик кечкенә авыл булган, хәзердә мең иманага җиткән. Әмма Тау Иле һаман йөз иманадан һич артканы юк, диләр.

Тау Илендә иске замандарак берәү, Яркә дигән адәм, имам булып торган. Аннан соң Әхсән мулла имам булган, аннан соң Әсән мулла имам булган. Аннан соң Мөхәммәдрәхим мулладыр. Хәзердә Әсән мулланың углыдыр. Тау Иленең бер ягында ниһаятьсез биек таудыр. Шуның өчен Тау Иле хосусында берәр мисраг бәетләр һәм ишетелгәне бар:

Тау Иленең таулары,
Өзелә камыт баулары;
Камыт бавын ялгый-ялгый,
Сызыла йөрәк майлары.

---

[1] Т ә в а н г ә р — мал иясе, җәмгыятьтә икътисади һәм сәяси көчкә ия кеше.
[2] Т ә ш ә э м — шикләнү, начарга юрау.

**Бәчек авылы** — бу Бәчек авылы дәхи күптәнге авылдыр. Иң әүвәл бу Бәчек авылына Болгар яки Биләр шәһәре тарафыннан өч кеше килеп утырганнар. Алар Бәчек баба, Әнчек баба, Янчек баба — агай-эне булганнар. Олугсы Бәчек баба, диерләр икән. Авыл аның исеме белән аталгандыр. Бу Бәчек авылы кадим заманда зур авыл булган. Җирләре кечерәк булу сәбәпле, бәгъзесе Әлмән авылына, бәгъзесе Кармыш авылына күчкәннәр. Элгәре заманда кеше теләсә кайда авылдан авылга күчеп йөргәннәр. Аннан соң 1782 елларда үз ихтыяры белән авылдан авылга күчүне мәныг кыйлынган. Хәзердә Бәчек авылы зиярәтендә бер таш бар; күп сүзләре уалып төшкән, укырга мөмкин түгел. Без мулла Нигъмәтҗан вә һәм Габделкави белән барып укып, язып алдык. Калган сүзләре бары ошбудыр: «Тарих тукыз йөз йетидә»[1] дигән сүз күренә вә һәм «Шәгъбан бин Әсәд» дигән сүзе бар. Моның язылганына һәм дүрт йөз елга карип, ягъни язылганына 383 еллар буладыр. 1490 елларда язылгандыр, Казан алынмастан күп элгәредер.

Риваять кыйлалар: Шәгъбан бин Әсәд дигән адәм Бәчек авылында бик зур голямадан, кәрамәт иясе адәм булган, имеш, диләр. Хәтта бәгъзе картларның риваяте буенча, ул ташны ниндәен кеше язып куйганын белгән адәм юк. Гүяки таш шунда үзеннән-үзе булган, имеш, диләр. 57 ел(да) Бәчек авылының Сәйфулла мулла әткәмез мәрхүмгә сөйләгәне хәтеремдә калгандыр: кайда булса да бер җирдә мөдәррис булып дәрес әйткән адәмдер. Бик иске заманда Шырдан белән Бәчек авылы арасы тоташ бик зур урман булган. Адәм заты аяк баскан җир түгел, юл юк икән. Бәчек авылының берәү, Усман дигән кеше, Шырданнан кыз алган. Бәчек авылыннан туры юл ачкан. Имән башыннан имән башына карап, имәннәрне кисеп чыгып барган. Аннан соң ат белән йөрерлек юл ачкан. Шул сәбәпле Бәчек авылы белән Шырдан арасындагы юлны хәзердә дә Усман юлы дип йөртәләр; искедән калган исемдер.

**Рәсбуга авылы** — исеменә караганда, бу Рәсбуга авылы һәм бик кадимге авылдыр. Риваять кыйлалар: иң әүвәл башта бу авылга берәү Рәсбуга яки Рәсбай дигән кеше килеп утыргандыр. Кайдан килгәненә риваять тапканым юк. Бәгъзеләр риваять кыйлалар: анда иң әүвәл килеп урнашкан кеше бер хатын кеше икән. Бер баласы белән килгән. Җирне казып, шунда үзенә торырлык куыш ясап кына торган. Бер сихерче хатын икән. Бер чуваш хатыны, имеш, диләр. Монда янә тәфсыйлрәк риваять бар. Хәзер яхшылап белгәнем юк.

Рәсбуга картлары һәм Тау Иле Мөхәммәдрәхим мулла риваять кыйладыр: элгәре заманда Рәсбуга зиярәтендә егермеләп язулы ташлар бар икән. Кирмәле алпавыты Митунин ди-

[1] Миладй белән 1501 ел.

гән кеше 1600 ел яки 17 гасырларда пулат салганда, таш кирәк булгач, зияраттән һәммә ташларны җыеп алган, диләр. Ахыр пулатын салып бетергәч, пулатка керә алмаган, диләр. Югарыда бәян кыйлынды, Шырдан белән Бәчек авылы һәм Рәсбуга арасы калын иманлек урман булган. Хәзердә баягы мәзкүр Усман юлы өстендә Рәсбуга кырында бер кое бар, Бәкеш коесы дип әйтәләр. Ошбу җәй көнендә тәварих өчен халык авызындагы риваятьләрне табар өчен өязләрдә йөргән вакытымда, шул кое тугрысыннан Сәкел башына таба барсак, Сәкел башында Рәсбуга кыры белән Бәчек авылы арасында тугыз җирдә кечерәк өй урыны кадәр түбә сыман тау кебек булып торган урыннарны күреп, монда ни бар, икән, дип, атны туктатып, арбадан төшеп, ул түбә сыман җирләрне һәркайсын як-ягыннан яхшылап тикшереп карадык. Әмма һичбер шөбһәсез үзеннән-үзе булган түбәләр түгелдер. Мәгәр адәм кулыннан чыккан эшләрдер. Юлның уң ягында берсе бар, бигрәк билгеле. Биеклеге җирдән аршин ярым кадәр бар, түбә булып тау сыман тора. Түбәсендә урта җире азрак баткан, чокырланып тора. Түбәнең әйләнә җире чокыр булып гүя туфрагын алып өстенә ташлаганга охшый. Гүя астында бер баз кебек землянка булып, базның түшәме җимерелгәч, уртасы төшеп киткән шикелле. Ул җирне хәзердә Рәсбуга кешеләре «Тугыз түбә» дип йөртәләр икән. Картлардан сорашкач, мәгълүм булды, аларның риваяте буенча, угрылар, качкыннар землянкасы булгандыр. Бабаларыннан вә кадимге адәмнәрдән риваять кыйлып сөйләшәләр: моннан элгәре ике йөз ел чамасында, яки 1650 елларда, ул җирләр караңгы урман булып, шул җирдә ун-унбиш кеше бөтен җәмәгатьләре белән урманда землянкада ятканнар. Алар юл кисүче угрылар булып, шул якын-тирәдәге һичбер адәм ялгыз-ярым йөри алмагандыр. Әгәр авылдан авылга барсалар да, кырык-илле кеше булып, кораллар, чукмарлар белән, кәрван белән йөргәннәр. Әгәр дә әмер булып, шул җирләрне казып каралса, бәлки, бер-бер төрле иске нәрсәләр вә һәм шул заманның әсәрләре табылмас иде микән дип, күңел гуаһлык бирәдер. Шул авыл халкы гәрчә «Тугыз түбә» дип йөрсәләр дә, ул түбә тугыз гына түгел, без санадык, уникеләп бардыр һәм бер тирәдәдер.

**Ачасыр авылы** — бу Ачасыр авылына иң әүвәл килеп утырган кешенең исеме, кем икәне мәгълүм түгел. Әмма риваятьләр гуаһлык бирәдер, анда әүвәл бер чуваш килеп утырган бер ятим бала белән. Ул вакытта Ачасыр урыны урман булган. Ул кеше шул ятим бала белән килеп, баласын бишеге белән имән ботагына асып тирбәткән. «Йокла, атасыз, йокла!» — дип, үз теленчә. Шуннан Ачасыр дип исем калгандыр.

Ачасыр дигән чуваш сүзе булырга кирәк. Ача дип атаны әйтәләр икән, сыр дигәне хәрфе нәфидер[1]. Ачасыр — атасыз

[1] Хәрфе нәфидер — юклык билгеседер.

дигән сүз буладыр, ягъни бер атасыз ялгыз чуваш булгандыр. Шуннан соң җыелып, зур авыл булгандыр. Башка авыл халкына караганда, бу Ачасыр кешеләренең кыяфәтендә, терклегендә һәм телләрендә бер нәрсә аермасы бар. Ләкин Ачасырның тарихы кай заманнан икәне мәгълүм булганы юк, янә Ачасырга Түбән Шырданнан барып утырган кешеләр һәм бар икән. Ачасыр янында хәзердә бер Күҗәмкә дигән кечкенә авыл бар. Зөя янындагы Күҗәмкә шунда күчкәндер. Югарыда бәян кыйлынды. Хәзердә Янәкче Ачасыр дигәннәре Олуг Ачасырдан күчкәндер. Элгәрерәк Кече Ачасырда Исәнгол мулла дигән кеше бар икән, Өфе (дә) мөфти мәхкәмәсе ачылгач, иң әүвәл шул Исәнгол мулла указ алган, диләр. Хәзердә бу Ачасыр авылы — байтак зур авыл. Иген-тару аларда яхшы буладыр; хосусән богдайны бик игәләр. Әхмәд хәзрәт мәрхүм Ачасыр богдае дип мактый торган иде. Вакыйган Ачасырлар иген эшен бик пөхтә эшлиләр.

Кадим заманда Ачасырда Тукмаш мулла дигән имам булган. Аның артыннан Мәмәткол мулла имам булган. Аннан соң Исай мулла дигән кеше имам булган. Аннан соң Габбас мулла дигән кеше имам булып торган. Кадимнән бирле Ачасыр бик кара авыл булгандыр. Күбрәк шул Габбас мулла агарткан, динне ачкан. Аннан соң Сәгъди мулла дигән адәм имам булган. Аннан соң Таһир мулла имам булып торган. Таһир мулланың атасы Әмир мулла дигән кеше икән. Бозай авылында имам булып торган кешедер. Ул Таһир мулла әүвәлләрдә голава[1] булып торган кешедер. 1788 елларда Өфедә мөфти мәхкәмәсе ачылгач, мөфти Петербургка барганда кыш көне икән, Таһир мулла озатып куйган, кайда чаклыдыр. Чана Таһир мулланың үзенеке икән. Ачасырда Сәгъди мулла вафат булгач, Таһир мулланы муллалыкка сайлаганнар. Өфегә имтиханга баргач, мөфти сораган: «Җә, мулла Таһир, синең ул мине озаткан чанаң әле дә бармы?» — дигән. Мулла Таһир әйткәндер: «Бар, хәзрәт, бар ул чанам хәзердә дә»,— дип. Мөфти әйткән: «Алай булса ул чанаңны миңа җибәр»,— дигән. Таһир мулланың углы Гайни мулла мәрхүм шулай дип риваять кыйлгандыр. Таһир мулладан соң Гайни мулла имам булгандыр. Ачасыр хосусында янә башка риваятьләр табылганы юк.

**Сәлам авылы** — сәлам — ислам дигән сүздән бозылгандыр. Элгәре, Ислам авылы, дип әйтәләр икән. Хәзердә Сәлам дип әйтеләдер. Әүвәл башта Ислам дигән утыргандыр. Шул сәбәпле Ислам авылы дип аталгандыр. Хәзердә Сәлам авылында мөселманнар азаеп бара. Бер заманда Себердән кайткан берничә урыслар Сәлам авылына урнашканнар. Шуннан

---

[1] Голава — чиновник, руслар куйган түрә.

соң һаман урыс артып бара, мөселманнар аз-аз бетә, имеш, вә һәм, бара торгач, Сәлам бөтенләй урыс авылы булып калса кирәк. Элгәре Сәламдә мулла бар икән, Матак мулла, дип әйтәләр икән. Ул мулла үлгәннән соң, икенче мулла булганы юк. Хәзердә Сәлам кешеләре ... авылына мәхәллә булып тора.

**Борнаш авылы** — хәзердә Зөя янында Борнаш дигән урыс авылы бар. Иске заманда мөселман авылы булгандыр. Болгардан килгән агай-эне ике кеше бар икән. Берсе Борнаш баба, берсе Сәед ага дигән кешеләр. Шул Борнаш баба дигәне анда килеп утырган — бер авыл булган икән. Зөя каласы урыс кулына кергәч, алар Тәтеш өязенә күчеп киткәннәр. Хәзердә Тәтеш өязендә Борнаш дигән мөселман авылы шул Зөя яныннан күчкән Борнаштыр. Янә Сәед ага дигәне тагы үз алдына бер авыл булып утырган. Борындыктан килгәндә Сит дигән станца шул Сәед ага авылыдыр. Төхфәтулла мулла үзенең Әтнүк бабасыннан риваять кыйлган сүзләрдер.

**Борындык авылы** — Борындык Исмәгыйль мулла риваять кыйладыр Хәмид карттан: элгәрерәк Борындыкта Хәмид дигән карт бар икән, йөз яшьләргә җитеп вафат булгандыр. Ул Хәмид карт үзенең бабаларыннан ишетеп сөйлидер икән. Болгар харап булган вакытларда Арслан дигән бер адәм бар икән, үзе Болгарда вафат булгандыр. Аның ике углы Болгардан күчеп, Зөя янына күчеп килгәннәр. Бер углына Борындык баба диерләр икән. Икенче углы Чулпан баба дип мәшһүрдер. Борындык исемле углы килеп, Зөя суы янына, Бәрле суы тамагына урман эченә урын ачып утыргандыр. Борындык авылы дип исем шуннан калган икән. Чулпан дигән углы янә урман эченә, бер чишмә янына килеп урнашкандыр. Чулпанка дигән шул Чулпан баба ихъя кыйлган авылдыр.

Борындык бик күптәнге иске авылдыр һәм иске заманда бик бай авыл булгандыр. Фабрик һәм завод тотучы байлар күп булган. Зур мәдрәсәләр булып, дәрес әйтүче мөдәррисләр, галимнәр була килгән. Әмма ахыргы гасырларда голяма беткән; байлары бөлеп беткәннәр. Риваятьләрнең гуаһлыгы буенча, анда голямалар бетүнең, Борындык авылы фәкыйрьлектә калуның сәбәбе шулдыр: Борындыкта бер бик галим кеше булган икән, тәхминән 1720 елларда вафат булгандыр. Яки 1700 елларда. Мансур дигән бер гайярь кеше булган, Мансур ахун, диерләр икән. Үзе асыл төп Түбән Шырдан кешесе икән. Каргалыга барып Тәгълим алган икән*. Аннан кайтып, Борындыкта берничә заман дәрес әйткән. Нәхү гыйлеменә бик оста — маһир

---

* Каргалы яки Оренбург янындагы Сәет бистәсе 1744 елда төзелә башлаган. Шунлыктан 1700 — 1720 елларга кадәр яшәгән кешенең анда барып белем алуы мөмкин түгел.

кеше булган. «Мансурия» дигән тәркип шәрхен тасниф кыйлган[1] кеше шул Мансур ахундыр. Бәгъзеләрнең риваяте буенча, үзе мәдрәсәдә укыганда тасниф кыйлгандыр. Вә һәм шул заманда Тәтеш өязендә Тилчәле дигән авылда Мортаза мулла дигән кеше (мөдәррис) бар икән. Фикъһедән[2] дәрес әйткәндер. Тилчәледә мәдрәсәсе бар икән. Бервакытны Борындыкка килеп берәүгә кунак булган. Мансур мулла соңгарак калып, Мансур мулла килүенчә мәсҗеттә камәт төшерелеп[3], мәсҗеттә имам булмагач, кайсы намаздыр, бер җәһрия намазда[4] Мортаза мулла имам торган булса кирәк. Мансур мулла актыктан аңар икътида кыйлган[5]. Намаз тәмам булгач, Мансур мулла, үзенең белүенчә, Мортаза мулланың кыйраәтендә[6] хата табып, кыйраәтне ялгыш укыды, дип, намазын яңадан кайтарып укыган. Соңыннан Мортаза мулла моны белгән; кыйраәтемне яратмыйчы, намазым кайтарды, дип, Мансур муллага бик рәнҗегән. Аннан соң Мансур муллага бәддога кыйлып, хәтта бөтен Борындыктан бәрәкәт күтәрелсен, дип бәддога кыйлып киткән, имеш. Шуннан соң Борындыкта көннән-көн байлары беткән, яхшы дәрес әйтерлек муллалар һәм булмаган. Борындык халкы һәммәсе фәкыйрьлеккә калганнар. Бара торгач Мансур мулланың үзенә һәм бәддога төшеп, ахыр гомерендә зина вә хәмер белән мөбтәля булып бәгъзе эшләр өчен хибескә[7] кереп, шунда һәлак булгандыр. 1670 елларда булырга кирәк тәхминән, дип һәм Кайбычның Габделҗәббар хәзрәт үзенең атасыннан риваять кыйлып сөйләде. Габделҗәббар хәзрәт хәзер дә бар. Ике-өч нәүбәт Өфедә казый булып торган адәмдер. Шул сәбәпле падишаһ хәзрәтләре җанибеннән медаль белән тәшриф боерылгандыр[8].

Мансур мулладан соң Борындыкта имам булган кешенең исеме мәгълүм түгел. Әмма аннан соң Шәмгун мулла дигән кеше имам булган. Аннан соң имам булган Кәмъяр ахун, чын исеме Мөхәммәдъярдыр. Аннан соң имам булган Вахид мулла, аннан соң хәзер дә Исмәгыйль мулла имамдыр. Атасы Җуынчы карьялек мулла Төхфәтулла исемледер, халык арасында Токмәт мулла дип мәшһүр иде. Йөз яшенә җитеп вафат булган карт мулла бик күп эшләрдән хәбәрдар иде, дип риваять кыйлалар. Аның атасы Туктагыл исемле кеше булган. Йөз дә унбиш яшенә җитеп вафат булгандыр. Туктагылның атасы

---

[1] Тәркип шәрхен тасниф кыйлган — кушымталар аңлатмасын язган.
[2] Фикъһедән — ислам дине мәсьәләләре турындагы белемнән.
[3] Камәт төшерелеп — намаз алдыннан басып дога укып.
[4] Җәһрия намаз — тавыш белән кычкырып укыла торган намаз.
[5] Икътида кыйлган — ияреп укыган.
[6] Кыйраәтендә — күрми кычкырып укуында.
[7] Хибескә — төрмәгә.
[8] Тәшриф боерылгандыр — бүләкләнгәндер.

Әтнүк исемле кеше булгандыр. Риваять кыйлалар: яше хәтта йөз егермеләргә кариб[1] булгандыр. Бу Әтнүк дигән адәм мулла Исмәгыйльнең бабасының атасы Борындык Мансур мулла белән һәм Кәвалның Рәхмәт хәзрәт белән бер замандарак булгандыр. Бу кыйссаны мәзкүр Токмәт мулла бик яхшы беләдер икән, мулла Исмәгыйль риваять кыйладыр.

**Шәгале авылы** — бу Шәгале авылында хәзердә чувашлар тора. Бәгъзесе чукынган чувашлар, бәгъзесе чукынмаганы да бар, диләр. Бу Шәгале авылы Мамадышлар тирәсендә, Чуел өязендәдер. Кадим мөселман авылы булгандыр, ягъни мөселман чувашлар булгандыр. Шәгаленең зиярәтендә өч-дүрт таш бар. Хәзердә бик читенлек белән укып була. Берсе уалган, өч кисәк булып ята. Без Мамадышның мулла Таҗетдин вә һәм борадәрем Габделкави белән өчәү барып укып, язып алдык. Уалган ташның кисәкләрен бергә җыйгач, филҗөмлә укырлык булды. Язулары бик нәфис гарәби хат белән язылган. Ул чагында голяма юк дип әйтергә мөмкин түгел. Берсендә язылган ошбу сүзләр: «...йөз кырык тукызда... углы Кужайт рабигыләүвәл аенда кяфер тукышындин шаһид...». Әмма башта «йөз» дигән сүзнең алдындагысы җимерелеп төшкән, укырга хәл юк. Янә «углы» дигән сүзнең алдында үзенең исеме беленми; бер хәреф әсәре дә юк. Бу таш алдагы бәян кыйлыначак дүртенче ташның язуы белән икесе бер кешенең кулыдыр. Болай булуы гуаһлык бирәдер, «йөз» дигән сүзнең алдында «тукыз» дигән сүз ватылып төшкәндер. Болай булганда язылганына 949 ел[2] булырга кирәк. 1549 елларда Казан алынган чорларда язылгандыр.

Риваятьләр гуаһлык бирәдер: Иван Грозный Казанны алмак нияте белән Казан алынасы елларның элгәреге елларында һәмишә бу тарафка гаскәр җибәреп, халыкны кырдыргалаган. Шул заманда шаһид булган голямадан яки башка олуг бер адәм булырга кирәк. Ташның кырыйларына язылганы укырга мөмкин дә, ул кадәр тәфтиш кыйлынмады. Тарихы белән иседме булгач кифаяләндек[3]. Ләкин бер ягында ярты бәйте бик ачык таныла: вә лә тәбәкъка мәдамән бил карар[4], дигән бер сүз бар. Янә икенче ташында язылган: «Тарих мең дә егерме алты ел[5] узып ирде зөлхиҗҗә аеның ахырында ирде, кем мән Михал углы Данила дөньядин үтти». Әмма бу ташны калкытып язмаган, бәлки батырып язылгандыр. Җамаш авылы кы-

---

[1] К а р и б — якын.
[2] Милади белән 1542 ел.
[3] К и ф а я л ә н д е к — канәгатьләндек.
[4] «Һәрвакыт бер урында таптанып калма» мәгънәсендә.
[5] Милади белән 1617 ел.

рындагы таш белән икесен бер кеше язганга охшый. Язылганына 164 еллар чамасыдыр, 1709 елларда язылгандыр. Урыс исеме булганга бик гаҗәпләнергә кирәкмәс. Ул түгел, хәзердә дә мөселманнардан урыс исеме белән аталган кешеләр бар.

Шырдан Габденнасыйр мулла риваять кыйладыр үзенең атасы Хөсәен мулладан: Хөсәен мулла Шырданда имам булып торганда, берәү аны баласына ат куярга чакырган икән. Мулла сораган: «Ни атлы куйыйк?» — дигән. Алар әйткәннәр: «Иван атлы куясыбыз килә, хәзрәт», — дигәннәр. Хөсәен мулла әйткән: «Башка исем куймыйк микән соң?» — дигән икән, алар әйткән: «Инде, хәзрәт, Бурабиянең Иван агай бай кеше, шуның кебек углыбыз да бай булсын дип әйтәбез», — дигәннәр. Аннан соң мулла карышмаган, ярар, дип, балаларын Иван атлы куйгандыр. Янә өченче таш бар, баягы кебек казып язылгандыр; бу һәм бер кеше кулыдыр. Ошбу сүзләр язылгандыр: «Тарих мең дә йөз утыз[1] елда Бикбулат углы Хуҗа Мирза дөньядин үтти...» Моның язылганына 160 еллар бар, 1713 елларда язылгандыр. Янә дүртенче таш әүвәлгесе кебек язылган бик нәфис хат белән, бер кеше язган булмак кирәк, бер остаңың кулына охшый. Әүвәл башта язылган: «тарих тукуз йөздә илекдә[2] Хаҗ углы Шиш кяфер тукышында шәһид булды». Ташның бер кырыенда язылган. ...Икенче кырыендагысын укырга мөмкин булмады. Ләкин баягы бәйтләр булырга кирәк. Бу ташның язылганына 340 елдыр, 1533 елларда язылгандыр. Казан алынмастан мөкаддәмрәк. Әүвәлге таш һәм шул бервакыттарак. Казан алынмастан борын һәмишә бу якларда сугышлар булгалаган. Шул сугышларда вафат булган кешеләрдер. Ул ташларны зрә язмаслар иде. Ахры, зур кешеләр булганнардыр, голямадан яки бик байлардан.

**Күкеш авылы** — Чуел өязендәдер. Бу Күкеш авылы хосусында тәфсыйлән риваятьләр тапканым юк. Алай булса да Күкеш авылы бик иске, кадимнән булган авылдыр. Күкеш авылы зиярәтендә бер таш бар, Шәгале зиярәтендәге таш белән тәмам бертөрле, бик нәфис язу белән язылган; бер кешенең кулыннан чыккан язулардыр. Таш хәзердә дә кеше буе бар. Калкытып язгандыр. Ташның язуы: «...тарих тукуз йөз илледә Шумбак би углы Җаберхан». Ләкин исемендә шөбһәбез калды: «Шусак» яки «Шумбак»ка һәм охшый. Чөнки «син» астында («С» хәрефе астында) бер нокта бар шикелле күренә. Алай булганда «Шумбак би» булырга кирәк. «Җаберхан» дигән сүзе аермачык, аннан түбәндәге сүзләр җиргә баткан, казымыйча укыр хәл юк. Язылганына 340 ел. Шәгале зиярәтендәге таш белән бер елларда язылгандыр: 1533 елларда. Таш-

[1] Милади белән 1717 ел.
[2] Милади белән 1543 ел.

ның бер кырыенда «Әд-дөнья җифәтен вә талибаһа кәлбен»[1]. Икенче кырыендагысы танылмады. Кармыш Нигъмәтҗан мулла, борадәрем Габделкави — өчәү барып укып, язып алдык.

**Әлмән авылы** — Чабаксар өязендә. Чабаксар өязендә хәзердә бары ике мөселман авылы бардыр. Берсе Әлмән авылы, берсе — Кармыш авылыдыр. Арасы ике чакрым чамасындадыр. Бу Әлмән авылының асылы бик күптәнге авылдыр. Әмма Әлмән авылының асылы чуваш булгандыр. Аннан соң башка авыллардан күп халык күчеп килгәндер. Бәчек авылыннан барган халык һәм бардыр. Бәгъзеләр риваять кыйладыр: әүвәл башта Әлмән авылына төпләнгән кеше Гыйльман исемле булган. Әлмән дип җиңеләйтеп әйткәннәр. Авыл аның исеме белән аталгандыр, чуваштан мөселман булган кеше икән. Әлмән авылы иске заманда кара авыл булган. Бик кадим замандагы муллалары мәгълүм түгелдер. Әмма берәү — Әбдери мулла дигән кеше — Әлмән авылында имам торган. Үзе бик күп гомер иткән кешедер. 1670 елларда вафат булгандыр.

Аннан соң Мәмәткол мулла дигән адәм имам булган, тәхминән 1700 елларда. Шул заманнарда бик мәшһүр караклар бар икән; берсе Зайка керәшен диерләр икән, янә Әбдери карак, янә Әмүч карак дигән караклар бар икән. Шул өчесе Мәмәткол мулла кайдан булса да бер җирдән кайтканда үтерергә азаплаганнар. Мәмәткол мулла ничек булса да ычкынып качып бара икән, янә өстебезгә тел әйтер, дип, артыннан килеп үтергәннәр; тәхминән 1750 еллар чамасында булыр.

Аннан соң Тимергали мулла дигән адәм имам булган. Бик галим вә диянәтле, яхшы адәм һәм хаҗи булган. Хаҗ кыйлган адәм икән, Тимергали хаҗи дип йөрткәннәр. Язуга оста кеше булган. Гомерендә бик күп китап язган. Үз кулы белән язган күп китапларын күргәнем бар. Үзе язган һәм үзе тышлаган. Вә һәм Бәрәзәдә Сабит мулла мәдрәсәсендә тәгълим булгандыр. Җөмләдән берсе монда тәзкирәсе булсын өчен язылыр. Китапның ахырында улы кулы белән язылган: «Нәсабеләхбар» дигән китабы «Фәкыйрелхәкыйр кәтәбә һәзалкитаб Тимергали бин Габделкәрим — 1192 сәнә фи мәдрәсәти мелла Сабит бин Биккол фи карья Бәрәзә фи тарыйк Алат»[2]. Мәзкүр Тимергали мулла үз ягында мәшһүр мулла булган; бәлки, һәрбер хосуста мәрҗәгылкөл[3] булгандыр. 1810 елларда вафаттыр. Аннан соң Һибәтулла мулла — Тимергали хаҗиның

---

[1] « Дөнья — үләксәдер, аның артыннан куучы эттер» мәгънәсендә.

[2] Тәрҗемәсе: «Нәселләр тарихы» дигән китапны ярлы һәм түбән дәрәҗәле Габделкәрим углы Тимергали Алат юлының Бәрәзә авылы Биккол углы Сабит мулла мәдрәсәсендә 1778 елда иҗат итте».

[3] Мәрҗәгылкөл — мөрәҗәгать ителүче кеше. Күпләр аңа киңәш сорап килгәннәр мәгънәсендә.

углы — имам булгандыр. Күп яшәгән кешедер. Аннан соң имам булган Гыйбадулла мулла дигән кеше. Бу ел, ягъни 1873 елда, йөргән вакытыбызда Әлмән авылында иске гадәтләренә очрадык. Кадимнән, чуваш заманыннан кала килгән гадәтләр вә һәм чувашларның якында булучылыклары сәбәпле мөселманнарда һәм бәгъзе авылларда бардыр. Бу көнгәчә калган мәҗүсилек гадәтедер. Аның сәбәбе шулдыр: әгәр дә авылда хайван үләте беленә башласа, кияүгә китмәгән кызлар авыл тирәли сабан сөрәләр икән. Тәфсилен эстәгән[1] кеше мөгамәләләре вакытында барып күрсен. Тәфсиле бик озактыр. Моннан башка бер рисаләм бар, тәфсиле шунда язылгандыр.

**Кармыш авылы** — Чабаксар өязе. Бу Кармыш авылы хәзердә Чәнчас дигән чуваш авылы белән күршедер. Араларында бары чокыр гына бар. Кармыш авылының асылы бик күптән түгелдер. 250 ел яки 300 ел чамасындадыр. Аның өчен хәзердә алты-җиде бабага чаклы Кармышның шәҗәрәсе мәгълүмдер. Кадим заман Тәтештә бер Кармыш баба дигән адәм булган. Шул Кармыш бабаның Тәтештә чагында ике углы бар икән. Үзенең бер Янгилде исемле углы белән Тәтештән күчеп монда килгәндер. Бер углы Заид исемле икән. Ул углы берничә заман Җуынчыда торган, аның нәселләре хәзердә Кошман авылындадыр; бәяны анда язылыр. Бу Янгилде дигән углының чын исеме Җанкилде исемле булгандыр, Янгилде дип йөрткәннәр.

Мәзкүр Кармыш баба Тәтештән килеп, Чәнчас чувашларыннан бер өй салырлык урын сорап, монда йорт-җир торгызгандыр. Ничә елларга кадәр Тәтешкә барып-килеп йөргән. Тәтештә дә һәм монда да ашлык чәчәдер икән. Җәмәгатьләре күбрәк заман Тәтештә торганнардыр. Аннан соң Кармыш бабаның балалары күп булгач, монда өйләнгәннәр, хатын алганнар. Ул чагында чукынмаган чувашлар булган. Һәркайсы углына Чәнчастан чуваш кызларын алып биргән. Балалары җәмәгатьләре белән үрчеп күбәйгәч, һәркайсы үз алдына йорт-җир торгызганнар. Чувашлар җир һәм биргәннәр. Кармыш авылының асылы шуннандыр. Чәнчас белән Әлмән авылы Кармыш баба килеп урнашмастан элгәре байтактан бар икән, кадимге иске авыллардыр. Кармыш баба монда күчеп киләсе булгач, ничә җиргә ятып йоклап караган, кайда йокласа да, төшендә әнваг[2] хәшәрәтләр күргән. Янә Әлмән белән Кармыш арасында кырда йоклап караган. Һәрничек монда хәерле урын тапмаган. Болар бары да Ишмөхәммәд мулла дигән адәмнән риваять кыйлынгандыр.

Менә Кармыш бабаларының шәҗәрәсе (Кармыш бабадан Янгилде балаларыннан таркалгандыр): әүвәл Актәби, аның уг-

---

[1] Тәфсилен эстәгән — аңлатуны теләгән.
[2] Әнваг — төрле.

лы Арслан, аның углы Габдерәхим, аның углы Мөрсәлим мулла. Әмма бу Габдерәхимнең ләкабе Кызыл авыз дип мәшһүрдер. Мөрсәлим мулланың углы Нигъмәтулла мулла, аның углы Мөхәммәдвәли, аның углы Нигъмәтҗан. Кармыш авылында бер заман мулла Ишмөхәммәд дигән адәм мулла булгандыр, кай заманда икәне тәмам беленгәне юк. Янә Кармыш авылында имам булган мулла Арслан дигән кеше югарыда мәзкүрдер. Аннан соң аның углы имам булган, Кызыл авыз Габдерәхим диерләр икән. Аннан соң Мөрсәлим мулла дигән кеше имам булган. Бу Мөрсәлим мулла әүвәлдәрәк Бакырчыда имам булып торгандыр, аннан соң Кармыш авылына күчеп килгәндер. Мөрсәлим мулла үзенең заманасында бик галим мулла кеше вә һәм гайярь кеше булгандыр. Шул якта бер олуг мулла булып торган, диләр. Тирә-яктагы авылларга ул хаким булган. Дәгъвалары булса, аңар киләләр икән. Мөрсәлим мулла аларның дәгъваларын өзеп хөкем итеп мөддәгыйларны[1] килештереп җибәрәдер икән. Мәзкүр Мөрсәлим мулланың үзе язган «Җамигъ» китабы янында шуның решениеләренең формасы бардыр. Ул чагында законнар, судебный уставлар юк; һаман катгы низагларны вә дәгъваларны муллалар бетерәләр икән. Менә «Җамигъ»сының ахырында үзе язганы: «...Габдерәхим бин мулла Арслан мин әл-һиҗрәти миәтен вә әлфе вә тисгунә сәнәтен[2]. Вә һәм решениесеннән солыхнамә формасы ошбудыр, ягъни мулла алдында мөддәгый белән мөддәга галәйһи[3] солых кылышып, бер-берсенә солыхнамә бирешкәннәре: «Бу солыхнамәсидер бетелде түбәндә язылася Әмин мөгаттәмәд галәйһи гадел гуаһлар алдында һәр ике мөддәгыен вә һәм ике гадел гуаһлар алдында 1184 елда маһ рабигылахырның 23 яүмендә Чабаксар өязенең Курмыш юлының Бөрле башының Мәхмүд Ягъкуб углы сотнясенең фәлән авылның мән мөддәга галәйһи фәлән бин фәлән түбәндә язылася мөддәгый фәлән бин фәлән дәгъва кыйлмыш илле сум мөддәгый бәшиэдин солых кыйлдым егерме сум бәдәленә фидаи ямин вә катгы хөсумәт өчен кэнд ризалыгым илән била әкраһ вә била җәбер бу солых бәдәлени кабыз иттердем солых мәҗлесендә дәхи бу солых гакдени җаиз күреп соңгы көн әслан сүз-өн итмәс өчен бу солыхны икенче имамларә рәфгы кыйлмаз өчен хаҗәт вакытта хаҗәт улсын өчен һәм хакимләр хозурында телем киселеп сүзем йөрмәз өчен үз кулым белән тамгам салдым».

(Тәрҗемәсе: Бу солыхнамәсе төзелде түбәндә язылася катгый сүзле, олы һәм гадел шаһидлар алдында. Һәр ике дәгъвачы һәм ике гадел шаһидлар алдында 1184 елда (1770 ел) рабигыла-

---

[1] Мөддәгыйларны — дәгъвачыларны.
[2] Һиҗри белән 1190 елда.
[3] Мөддәга галәйһи — җавапчы, гаепләнүче.

хыр аеның 23 көнендә. Чабаксар өязенең Курмыш юлының Бөреле-Башының Мәхмүт Ягъкуп углы сотнясенең фәлән авылының мин олы җавапчы фәлән-фәлән углы түбәндә язылырасы дәгъвәт фәлән-фәлән углы җавапчы кешедән дәгъва кыйлмыш илле сум урнына солых кыйлдым егерме сум хакына. Фидакарь ант һәм катгый җавапчылык өчен үз ризалыгым белән бу солых хакына чирканыч һәм җәберле бәлаләр алырга булдым. Солых мәҗлесендә һәм шулай ук бу солых төзүне дөрес күреп, соңгы көнгәчә һичбер вакыт сүз-өн итмәс өчен, бу солыхны икенче имамнар арасында тавыш күтәрмәс өчен, тиеш вакытта кирәк булсын өчен һәм судьялар каршында телем киселеп сүзем йөрмәс өчен үз кулым белән тамгам салдым.)

«Вә дәхи мән мөддәгый фәлән бин фәлән бу солых гакдени кабул кыйлдым мәзкүр илле сум дәгъвамдин биздем кәнд ризалыгым белән бу солых била әкраһ вә била җәбер бәдәли егерме сум малны кабыз итдем солых мәҗлесендә вә дәхи гакыдне җаиз күреп соңгы көн әслан сүз-өн итмәс өчен бу солых гакдени икенче имамлар хозурына рәфгы кыйлмаз өчен хаҗәт җирендә хаҗәт улсын өчен хакимләр хозурында телем киселеп дәгъвам батыйль улсын өчен кәнд ризалыгым илә тамгам салдым хәзер әл-мәҗлес фәлән авылының имамы фәлән бин фәлән-фәлән авылның картлары фәлән бин фәлән тамгам салдым».

(Тәрҗемәсе: Һәм шулай ук мин дәгъвачы фәлән-фәлән углы солых актын кабул иттем. Күрсәтелгән илле сум дәгъвамнан биздем үз ризалыгым белән. Бу солых чирканыч һәм җәберле бәлаләр хакына булсын. Егерме сум малны алдым солых мәҗлесендә, һәм тагын да, солых төзүне дөрес күреп соңгы көнгәчә һич сүз-өн итмәс өчен бу солых актына икенче имамнар каршында сүз кузгатмас өчен, тиешле җирендә кирәк булсын өчен, судьялар алдында телем киселеп, дәгъвам бозык булсын өчен үз ризалыгым белән тамгам салдым. Мәҗлес хәзрәте фәлән авылның имамы фәлән-фәлән углы, фәлән авылның картлары фәлән-фәлән углы тамгам салдым.)

Вә дәхи — янә ике мөддәгый берәүне хаким ясап, үзләренең низагларын хаким алдында бетереп кул куешкан язулары:

«Бу намә ул тәхким намәсидер бетелде — түбәндә язылырасы Әмин мәгаттәмәд галәйһи гадел гуаһлар хозурында 1184 елда Казански намествоның* Чабаксар округының фәлән илнең фәлән углы сотнясенең фәлән авылның мән мөддәгый фәлән углы фәлән вә һәм мөддәгый галәйһи фәлән углы арамызда вакыйг улган дәгъвамызны шәригать Мөхәммәдичә катгы итәргә мәхкәм төзедек фәлән авылның имамы фәлән углы фәлән вә һәм фәлән авыл-

* Казан наместничествосы 1781 елда төзелә, һиҗри 1184 ел безнеңчә 1770 елга туры килгәнлектән, акт датасы дөрес күрсәтелмәгән булып чыга.

ның фәлән углы вә иткән хөкемләренә разый улдык соңгы көн һич сүз-өн итмәс өчен вә иткән хөкемләрне гайре имамларга рәфгы кыйлмаз өчен мән мөддәгый фәлән углы тамгам салдым вә һәм мән мөддәгый галәйһи фәлән углы фәлән тамгам салдым фәлән углы фәлән гуаһ булып тамгам салдым» диелгән. (Мөрсәлим мулланың «Җамигъ»се яныннан күчерелде.)

(Тәрҗемәсе: Бу акт беркетмә итеп төзелде — түбәндә язылачы Әмин катгый бөек турылыклы шаһидләр каршында 1184 елда Казан наместничествосының Чабаксар өязенең фәлән илнең фәлән углы сотнясенең фәлән авылның мин дәгъвачы фәлән углы фәлән вә һәм олы җавапчы фәлән углы арабызда килеп чыккан дәгъвабызны Мөхәммәдия шәригате буенча хәл итәргә суд төзедек; фәлән авылның имамы фәлән углы фәлән вә һәм фәлән авылның фәлән углы. Вә иткән хөкемнәренә риза булдык. Соңгы көнгәчә һичбер сүз итмәс өчен вә чыгарган хөкемнәрен башка имамлар алдында яңадан куймас өчен. Мин дәгъвачы фәлән углы тамгам салдым вә һәм мин олы җавапчы фәлән углы фәлән тамгам салдым. Фәлән углы фәлән шаһид булып тамгам салдым.)

Вә янә хатын алу хосусында шарт кыйлышып язышуларның формасы:

«Тарих Исламия илә мең дә йөз дә туксан өченче елда маһ рабигыләүвәлнең тукузынчы көнендә җомга көн ирди шоһуд годул хозурында бән хатыйб фәлән углы фәлән мәхтубә фәланә фәлән кызыни гакыд никях кыйлдым йөз сум мәһәр илә җитмеш сум мөгаҗҗәл вә утыз сум мөгаҗҗәл шул гакыд сахихдән шарт кыйлдым: бу мәхтубәи мәзкүрәнең өстенә кәндүсеннән изенсез хатын алмам, вә һәм гайре алмушны кабул кыйлмам вә һәм кәнизәк тотмам, вә би җәная шәргый сукмам әгъзасында зареб әсәре булыр кадәре вә би нәфкаи кифая алты ай ташлап китмәм, вә үземнең вә һәм мәзкүрә мәхтүбәнең турлагуыннан сәфәр кадәре булыр җиргә аның изененнән гайре алып китмәм, әмма ул аралыкта йөрермез әгәр бу шартларның берсенә каршулык кыйлсам, бу мәзкүрә мәхтубә фәланәгә ихтыяр бирдем үзе ни теләсә бер баин талак кыйлмага, теләсә кайсы урында теләсә кемләр алдында мәзкүр шартлар илә мәзкүр мәһәр илә гадел гуаһлар хозурында бән фәлән углы фәлән үз ихтыярым илә кулым куйдым». (Бәрәзәдә мулла Сабит Биккол углы мәдрәсәсендә язылган «Хөләса[1]» яныннан күчерелде; 1781 елда язылгандыр.)

(Тәрҗемәсе: Ислам тарихы белән 1193 елда (1779 ел) рабигыләүвәлнең 9 нчы көнендә җомга көн иде. Олы шаһидлар каршында мин никях укучы һәм язучы фәлән-фәлән углы

---

[1] Хөләса — нәтиҗә, йомгак.

ярәшелгән фәлән-фәлән кызына никях килешүе төзедем. 100 сум мәһәр белән: 70 сумы хәзер бирелеп, 30 сумы көтәргә калдырылып. Шул килешүчеләрнең турылыгын шарт кыйлдым. Бу ярәшелгән кызның өстенә үзенең рөхсәтеннән башка хатын алмам вә һәм башкача алмаш итмәм, шулай ук кәнизәк тотмам һәм шәригатькә җинаятьсез булырмын. Сукмам, тәненә зыян әсәре ясамам һәм тормышы өчен акчасыз калдырып 6 ай ташлап китмәм һәм үземнең шулай ук ярәшелгән кызның ризалыгыннан башка сәфәр кадәре булыр җиргә алып китмәм. Әмма ул аралыкта йөрербез. Әгәр бу шартларның берсенә каршылыкта кыйлсам, бу ярәшелгән кыз фәләнгә ихтыяр бирдем: үзене талакы бер баин[1] аермага, теләсә кайсы урында. Теләсә кемнәр алдында. Шушы печать белән күрсәтелгән шартларда гадел шаһидлар каршында мин фәлән-фәлән углы үз ихтыярым белән кулым куйдым.)

**Җамаш авылы** — Чабаксар өязе. Җамаш авылы хәзердә чуваш авылы булгандыр. Элгәре мөселман авылы булган икән. Ул вакытта Казаклар авылы дип йөрткәннәр. Казаклар булгандыр. Әүвәл башта казаклар килеп утыргандыр. Аннан соң 1700 елларда яки бераз соңрак ул казаклар күбесе моннан күчеп киткәннәр, кайда күчкәннәрдер? Риваятен кыскалык белән әйтәләр. Тәфсилен тапканым юк. Ул казаклар күчеп киткәч, алар урынына бер Җамаш исемле чуваш килеп утырган. Әүвәл башта һәм мөселман чуваш булгандыр. Шуның сәбәпле чуваш нәселе күбәеп чуваш авылы булгандыр. Күчеп киткән казакларның монда калган нәселләре берничә замангача Җамаш авылында торганнар. Аннан соң икенче мәртәбәдә калганнары да күчеп беткәннәр. Бу актык күчүләре бик күптән түгел, йөз ел чамасындарак булыр.

Кармышның Фәтхулла мулла актык күчүләренең вакыйгасын яхшы беләдер икән. Фәтхулла мулла бала чагында бик мәгълүм эш булгандыр. Җамаш авылында мәсҗетләре бик яхшы икән. Аннан соң аларның мәсҗетләрен Күкеш авылына күчереп алганнар. Күкеш авылының моннан элгәреге мәсҗетләре Җамаш авылыннан китерелгән мәсҗеттер. Җамаш авылы кырында бер-ике таш бар, язулы ташлар. Берсенең тарихыннан башка сүзе беленми, кырылып төшкән; калган язуы бары: «Тарих мең дә йөз унынчы елда»[2], аннан соң исеме беленми. Янә «үти» дигән сүз беленә. Язылганына 180 еллар чамасында; 1693 елларда язылгандыр. Янә икенче таш язылган ошбу рәвешчә: «Тарих мең дә йөз кырык алтыда[3] ирди

[1] Т а л а к ы  б е р  б а и н — яңадан кушылмаслык итеп хатын аеру.
[2] Милади белән 1698 ел.
[3] Милади белән 1733 ел.

кем Янбулат углы Савин дөньядин үтте». Болар һәр икесе дә казып язылган ташлардыр. Соңгысының язылганына 146 ел буладыр; 1727 елларда язылгандыр.

**Кошман авылы** — Кошман дигән бер елганың исемедер. Бәрле суының җәнүб тарафында. Кошман авылының мөселман авылы булганына бик күптән түгелдер. Кошман авылы элгәре урыс авылы булгандыр. Моннан мөкаддәм ике йөз еллар чамасында Кошман мөселманнары Бишбатман авылыннан күчеп барганнардыр. Кошман урыслары Бишбатманга алар урынына килеп урнашканнар. Сәбәбе ни рәвешледер, тәхкыйк[1] белгәнем юк. Вә һәм аннан соң Кошманның бәгъзе нәселләре Тәтештән килгән халыклардыр. Югарыда мәзкүр булган Кармыш бабаның балалары Болгардан чыккан адәмдер. Кармыш баба үзе Тәтештә булган. Ике углы бар икән: берсе Янкилде исемле, Кармыш авылы фасылында зикер ителде; янә бер углы Заид исемле булгандыр. Ул Заид исемле углы берничә заманнар Җуынчыда булган, аннан соң аның нәселе Кошманга килгәндер. Кармыш бабаның бабаларының бабасы Нәреш дигән адәм булгандыр. Аның углы Туктар баба, аның углы Кармыш бабадыр, аның углы Заид, аның углы Гомәр, аның углы Сәйфетдин, аның углы Фәхретдин, аның углы Шәрәфетдин хәзердә Кошманда имамдыр. Аның углы Хәйретдиндер.

**Тутаркасы** — Чабаксар өязендә Чабаксарга якынрак Гурной дигән елга янында хәзердә ике чуваш авылы бардыр. Берсе Тутаркасы янә икенчесе Юртакасы дип чувашча йөртәләр икән. Казан алынган заманнарга чаклы бу авыллар мөселман авылы булгандыр, ягъни татар авыллары булгандыр, ягъни чуваштан мөселман булган авыллар түгелдер. Шуның өчен Тутаркасы дип исем калгандыр.

Кармышның Фәтхулла мулла үзенең Габдерәхим бабасыннан риваять кыйлып сөйлидер икән: бу авыллар элгәре татар каласы булгандыр һәм бер хан кебек адәмнәре бар икән. Байтак зур авыллар булган. Мәдрәсәләре һәм голямасы күп булып, гыйлем яхшы укылгандыр. Мөдәррисләре бар икән. Хәзердә дә әйтәләр, бер чувашның бабадан бабага кала килгән өч сандык китабы бар, диләр. Күргән кешеләр бар икән, «Тамтави бәззазия» кебек зур китаплар. Әмма миллион бирүче булса да, сатмыйлар. Чувашларны әйтәләр, имеш, бер-бер авыру-сырхау булса, яки иген-тару начаррак булса, китапларны ачып, укыган кебек итеп, бабалар болай итеп укыганнар, дип, бармаклары белән китапны юл саен төртеп чыгалар, имеш, һәм шулай итсәң, «чабла» була дип әйтәләр, имеш. Ягъни, шулай итсәң, һәрбер эшебез бик яхшы була, дигән сүз.

---

[1] Тәхкыйк — ачык.

Вә янә ул вакытта авылларыннан берничә чакрым җирдә Идел яры өстендә бер кечкенә урманлык яки чыбыклык (кустарник дигән шикелле) җирләре бар икән. Үзләре чыбыксар дип әйтәләр икән, ягъни чыбыксар — күп чыбык үскән җир дигән мәгънәдә; мәсәлән, хәзердә дә әйтәләр, куаксар, каенсар дип, шуның шикелле чыбыксар дип. Бу һәм шул мәгънәдәдер. Анда Иван Грозный Чабаксар каласын салгач та, исеме һаман шул чыбыксар дигән сүздән ерак китмәгәндер. Аннан соң Иван Грозный Чабаксар каласын салып, бу якынга аяк тыга башлагач, Тутаркасының татарлары күбесе аннан качканнар. Калганнарын Иван Грозный урыс диненә керткән. Урыс һәм булып бетмәгәннәр; якында чуваш булу сәбәпле, һәммәсе чувашка әверелгәннәр. Дин беткән. 1600 елларда аларны дингә кертер өчен бик газаплап бетергән (нәр). Кыш көне салкын келәткә ябып асрап һәм ялангачлата салкын он эченә утыртып азаплаганнар. Күбесе чыдый алмыйча, үлеп һәлак булганнар. Калганнары бары, ни урыс түгел, ни татар түгел, кирәмәтле чуваш булып калганнар.

**Кавал авылы** — Чабаксар өязендә бер авыл бардыр, хәзердә базарлы авыл, чуваш авылыдыр. Татарча Кәвәл дип әйтелә, урысча «Ковали» диерләр. Иске заманда мөселман авылы булгандыр. Кайбыч. Габделҗәббар хәзрәт үзенең Солтан бабасыннан риваять кыйлып сөйләшәдер (Габделҗәббар хәзрәт хәзердә 85 яшендә): Кавал авылында голямадан чувашлар булган. Хәзердә мәшһүрдер: Кавалда Рәхмәт исемле бер чуваш бар икән, бик укыган һәм диянәтле тәкъва кеше булгандыр, Үлә казакларында дәрес әйткәндер. 1650 яки 1660 елларда.

Мулла Исмәгыйль риваять кыйладыр: Җуынчы Токмәт мулланың балалары Әтнүк белән Рәхмәт хәзрәт бер заманнардарак булганнардыр. Токмәт мулла риваять кыйладыр икән: Рәхмәт үзенең авылына кайтып агай-энесен вәгазь-нәсыйхәт кыйлса, агай-энеләре үзара сөйләшәләр икән: «Рәхмәт ача чабла каләт», ягъни, Рәхмәт агай яхшы әйтә, мәгъкуль әйтә, диләр икән.

Үлә казакларының Мөхәммәдҗан үзенең Чапи бабасыннан риваять кыйлып сөйләшәдер: Рәхмәт хәзрәтнең атасы Үлә казакларына кунак булып барганда, Рәхмәт хәзрәт белән мәдрәсәгә керә икән. Шәкертләре Рәхмәт хәзрәт кергәч, дөрр итеп һәммәсе аягүрә торалар икән. Рәхмәтнең атасы моңа исе китеп сөенеп әйтәләрдер икән, безнең Рәхмәт Фараун кебек, шәкертләре даравын кебек, дип мактанадыр икән, һәрбер мәҗлесләрдә сөйли икән, Шырдан Габденнасыйр мулла һәм Кармышның Мөрсәлим хәзрәттән риваять кыйлып шулай сөйләгәне бардыр. Үлә казакларында хәзердә Рәхмәт мулланың углының кызының углы сәламәттер. 70 яшьләрендә бар, диләр.

Мәзкүр Мөхәммәдҗан Чапи бабасыннан риваять кыйлып сөйләшәдер: Рәхмәт мулланың килене, бервакытны йөкле булгач,

җиләк ашарга нәфесе теләгән. Ул вакытта кыш көне икән. Ул килен үзенең нәфсесе нәрсә теләгәнен каенанасына сөйләгән. Аннан соң каенанасы бу сүзне Рәхмәт хәзрәткә әйткән: алаймы, булмас ла ул, кайда әле җиләк вакыты, дигән. Янә икенче бервакытны шулай сүз булган. Аннан соң Рәхмәт мулла хатынына әйткән, алай булса, киленгә әйт, идән астына төшсен, әмма анда ни күргәнен бер кешегә дә сөйләмәсен, дигән. Килене идән астына төшеп күрсә: нәфис җиләкләр пешеп утыра. Нәфесе теләгәнчә алган да берәүгә дә сөйләмәгән. Рәхмәтнең вафатыннан соң бу сүзләр фаш булгандыр. Рәхмәт мулла бик галим, тәкъва вә диянәтле адәм булып, кәрамәт иясе булгандыр.

## КАЗАН ШӘҺӘРЕ

Русия мәмләкәтенең пайтәхете икедер. Әүвәлге дәрәҗә пайтәхет — Петербург шәһәредер. Икенче дәрәҗә пайтәхет — Мәскәү шәһәредер. Казан Петербургтан мең дә дүрт йөз чакрымдыр. Бер һәйбәт төзек шәһәрдер. Кабан күле һәм Болак Казан шәһәрен икегә аерадыр. Кабан күленең вә Болакның җәнүбкә таба тарафында күбрәк мөселман йортларыдыр. Вә һәм Казанга тәбыг вә Казанның фәнасыннан Бишбалта бистәсе вә Яңа бистә вә дәхи Дары кярханәсе. Боларның мәҗмугысында ундүрт мәсҗеттер. Һәрбер мәсҗетнең тәхетендә олуг мәдрәсәләре бардыр. Мөселманнарның үзләренә хас Печән базары дигән бер мәйданнары бар. Ошбу мәйдан даирәсендә мәҗмугы ике йөзләп кибет бардыр. Һәммәсендә мөселман сәүдәгәрләре сәүдә кыйладыр. Мал, күбрәк кызыл мал, чәй-шикәр вә ашамак-эчмәк нәрсәседер. Вә һәм һөнәр ияләреннән бүрекчеләр, читекчеләр вә кәвешчеләр вә гайреләре ошбу Печән базарында сәүдә кыйлалар. Һәр елда Казанда ирләр вә хатыннарның аяк киеменнән ике йөз илле меңлек читек-кәвеш, башмак эшләнәдер. Болар һәммәсе мөселман осталарының кулыннан эшләнеп чыккан затлардыр. Вә дәхи Казанның хатын-кыз таифәсеннән һөнәр иясе күбрәк кәләпүш, такыя, калпак эшләп хәрәкәт итәләр. Бер Казан шәһәрендә биш йөз меңнән зиядә кәләпүш, такыя эшләнәдер. Вә дәхи йөз меңләп бүрек эшләнәдер. Бу затлар һәммәсе әһле ислам кулыннан чыгадыр вә Казан шәһәрендә ел саен биш йөз меңләп китап, Коръән басыладыр. Вә дәхи мөселманнарның кярханәләре, күбрәк сабын кярханәсе, кытат[1] кярханәсе вә һәм шәм кярханәседер. Кадимнән Казан сабыны дип һәркайда мәшһүр вә мәмдүхтер[2]. Казан шәһәре ел-

---

[1] Кытат — юка яшел тукыма.
[2] Мәмдүхтер — мактаулыдыр.

дан-ел зураеп, артып барадыр. 50 нче елгы календарьларда күренәдер, Казан шәһәрендә кырык биш мең халык икән, хәзердә (81— 82) меңләп халык җыелмыштыр. Казан шәһәрендә атнасында өч олуг базары буладыр: дүшәмбе, чәршәмбе вә җомга көннәрдә. Вә базар була торган олуграк мәйданнары дәхи өчтер. Печән базары, балык базары, ашлык базары дигән мәйданнардыр. Базар көннәрендә һәр тарафтан Казанга малның хәдде-ниһаяте[1] булмыйдыр. Берәү дә кире төяп киткәне юк. Бәгъзе көннәрдә китерелгән нәрсә җитми каладыр. Вә дәхи һәр ел май аенда Булакта Ташаяк ярминкәсе буладыр.

## КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘГЕ МӘСҖЕТЛӘР

Әби патша, ягъни Катерина патша хатын заманасына чаклы Казан шәһәрендә таш мәсҗетләр юк иде, кайда такта-токтадан гына салган салкын мәсҗетләр иде. Карт Мостафа агайның риваятенә бинаән Аксак Каратун заманасында Казан шәһәрендә мәсҗет атлы нәрсә калмаган иде. Мөселманнар анда-монда кабыктан корыштырып, салкын өйләрдә җыелып намаз укыйлар иде. Аксак Каратуннан соң берничә замана тынычлагач, Катерина патша хатын заманасында, тәхминән 1770 елларда, Катерина патша Казанга килгәч*, мөселманнарның олуг байлары Катерина патшага кереп гарызнамә бирделәр, бистәгә таш мәсҗет салырга рөхсәт сорадылар вә һәм Катерина патша, Казан байларының гарызын кабул итеп, таштан мәсҗет салырга рөхсәт бирде вә һәм үзе килеп мәсҗет урынын тәгаен кыйлды. Катерина патша мөселманнарны бик яратты, Казанда торган мөддәтендә һәмишә мөселманнар арасына килеп, рус халкыннан җәфа күрмимсез, дип сорашып йөрер иде, мөселманнар һәм урыс халкыннан әслан шикаять кыйлмадылар, Аллага шөкер, һичбер җәфа күрмимез, диделәр. Рәхмәтулла Әмирханов һәм бөйлә риваять кыйлыр иде. Казан шәһәрендә таш мәсҗет салырга падишаһ тарафыннан рөхсәт булгач, әсбаб хәзерләп мәсҗетнең гыймарәтенә шөругъ кыйлдылар[2]. Иң әүвәл Әфәнде мәсҗетен вә һәм байлар мәсҗетен салдылар, ул заманда олуг мәшһүр байлар җыелышып вә ярдәмләшеп вә рөхсәтне ганимәт белеп, бу ике мәсҗет бинасына ашыгып шөругъ кыйлдылар, хәтта кыйбласын да яхшы тәфтиш кыйла алмадылар, шул сәбәпле бу ике мәсҗетнең кыйбласы кыеграк вакыйг булгандыр. Мәсҗетне салып, манарасын күтәргәч, Казанның начальникла-

---

* Екатерина II Казанга 1767 елда килгән.
[1] Хәдде-ниһаяте — иге-чиге.
[2] Шөругъ кыйлдылар — керештеләр, башлап җибәрделәр.

ры төшеп карап, биеклегенә хәйран булып, Әби патшага яздылар: син мөселманнарга мәсҗет салырга рөхсәт бирдең дә, ләкин алар бик биек итеп салалар, диде. Патша җавабында язды, мин аларга җир өстендә урын микъдарын күрсәттем, әмма күккә никадәр чыгарсалар да ихтыярлары, күк минем милкемдә түгел, диде. Бу ике таш мәсҗет 1771 елларда салынып, Әфәнде мәсҗете — әүвәлге таш мәсҗет вә байлар мәсҗете — Икенче таш мәсҗет аталадыр.

Әфәнде мәсҗете мәхәлләсендә булган имамлар мәгълүмнәре әүвәл Бәкри мулла, икенче — Габдулла мулла, өченче — Йосыф мулла, дүртенче — Ибраһим әфәнде, бишенче — Мостафа хафиз, алтынчы — Сәгыйд хәзрәт имам вә мөдәррис булганнардыр.

Байлар мәхәлләсендә булган имамлар мәгълүмнәре әүвәл Мортаза мулла, икенче — Салих мулла, өченче — Фәхретдин мулла, дүртенче — Исхак хәзрәт, бишенче — Мөхәммәд Кәрим хәзрәт, алтынчы — Сәлахетдин хәзрәт, җиденче — Таҗетдин хәзрәт имам вә мөдәррис булганнар иде. Ибраһим Солтанаев дигән бай салдырган мәсҗетдер. Ибраһим Солтанаевның бары ун мең акчасы булып, ай-һай акчамыз җитсә ярар иде дип, җәмәгате белән кайгырырлар иде, эшчеләр киткәч, төнлә-төнлә хатыны белән икесе кирпечне үзләре ташып куяр иде диләр, бу риваятьнең тәфсиле икенче бер рисаләмдәдер.

...нче таш мәсҗет халык арасында Зәңгәр мәсҗет дип мәшһүрдер. Бу Зәңгәр мәсҗетне салмас борын анда агач мәсҗет иде, монда таш мәсҗет саласы булгач, ул агач мәсҗетне олуг Кавалга күчереп салдылар. Бу Зәңгәр мәсҗетне Исай Әхмәд дигән кеше бина кыйлдырды, 1812 елларда. Бу мәхәлләдә булган имамларның мәгълүмнәре — әүвәл Габдерәшид мулла, икенче — Мөхәммәд мулла, өченче — Мортаза мулла, дүртенче — Габденнасыйр ахунд, бишенче — Хәбибулла мулла, алтынчы — Бурнаев мәсҗете дип мәгъруфдер. Өченче таш мәсҗет — элгәре бу мәхәлләдә агач мәсҗет иде, Әпри дигән адәм салдырган иде 1769 елларда — ягъни Габдерәшид Мостафа углы Мучтуковны «Әпри» диерләр иде, 1871 ел бу агач мәсҗет җанып, аның урынына Бурнаев Садыйк бай таштан салдырды, шул мәсҗеттән Бурнаев мәсҗете дип мәгъруфдер. Бу мәхәлләдә булган имамларның мәгълүмнәре — әүвәл Салих мулладыр, кадим бу мәхәлләдә агач мәсҗетнең түбән ягында бер мәдрәсә бар иде, берничә еллар Салих мулла монда дәрес әйтеп, аннан соң байлар мәхәлләсенә күчте, икенче аннан соң кияве Баязит мулла, өченче — Мостафа Хафиз имам булып, соңыннан Әфәнде мәхәлләсенә күчте, дүртенче — Шәмсетдин хафиз, ятим Шәмсетдин, диерләр иде, бишенче — Шиһабетдин мулла, алтынчы — Сәлахетдин мулла — бу һәм ахырыннан байлар мәхәлләсенә күчте, җиденче — Мөхәммәдга-

ли әманәт ләваземын әда кыйлып торды[1], мәми мөэмин, диерләр иде, сигезенче Камалетдин мулла имам булып тордылар.

Әҗем мәхәлләсе яки завод мәхәлләсе һәм диерләр, монда хәзердә икенче агач мәсҗеттер, әүвәлге мәсҗетне Мәҗид хаҗи дигән адәм салдырган иде, әүвәлге мәсҗет тузгач, моны Әҗемлеләр салдырдылар — кадим монда мәхәллә юк иде, яңарак зурайган мәхәлләдер — монда әүвәлге имам Әсфәндияр мулла имам иде. Базар мәсҗете 1845 елда Юнусов Габидулла бай салдырган мәсҗеттер. Бу мәсҗеттә имам әүвәл Камалетдин мулла, икенче — Сәгъдетдин мулла, өченче — Габделгани мулла имам иделәр. Бу мәсҗетнең тәсаррыфында[2] мәдрәсәсе юктыр.

Бишенче таш мәсҗетне безнең заманымызда, Әхмәд хәзрәт мәхәлләсе, диерләр иде, әмма элгәрерәк, Печән базарына мәсҗет салынмас борын, Печән базары мәхәлләсе, диерләр иде. Бу мәхәлләдә кадим агач мәсҗет иде. Бу таш мәсҗетне Урнаш башы Муса бай Сәлим углы салдырды 1800 елларда. Агач мәсҗет вакытында кемнәр имам булгандыр, мәгълүм булмады, әмма бу мәсҗет салынгач, әүвәл Сәгыйд хәзрәт, икенче — Габди хәзрәт, өченче — Габделсаттар ахунд, дүртенче — Әхмәд хәзрәт, бишенче — Габдуллаҗан мулла имам булып дәрес әйттеләр.

Тугызынчы таш мәсҗет хәзердә Җиһанша мәсҗете дип мәгъруфдер, мәрхүм Җиһанша Госманов салдырды 1868 елда, вә бу мәсҗетне мөфти хәзрәтләре килеп фәтех кыйлды[3].

Таш мәсҗет Яңа бистәдә Мәчкә мәхәлләсе, диерләр иде, бу мәхәлләдә Мәчкәләр дип мәшһүр байлары булган сәбәпле, бөйлә тәсмия кыйлынмыш иде, Олуг таш мәсҗет мәхәлләсе дип һәм тәсмия кыйлынадыр. 1801 елда Мәчкәрәнең Габдулла бай салдырмышдыр. Бу мәхәлләдә булган имамнар мәгълүмләре әүвәл Фазлый хәзрәт, икенче — Әмирхан мулла, өченче — Вафа мулла, дүртенче — Байморад мулла, бишенче — Әхмәд Сафа мулла имам булып дәрес әйттеләр.

Таш мәсҗет Яңа бистәдә Урта мәсҗет мәхәлләсе, диерләр, кадим Мәхмүд мулла мәхәлләсе, диерләр иде, 1802 елда Рәкый бай салдырган мәсҗеттер, бу мәсҗеттә булган имамлар мәгълүмнәре әүвәл Мәхмүд мулла, икенче — Әбү Бәкер мулла, өченче — Габделгафур мулла илә бер мулла, диерләр иде.

Таш мәсҗет Яңа бистәдә элгәре дамелла мәсҗете, диерләр иде, Кечкенә таш мәсҗет мәхәлләсе дип һәм аталадыр, Муса Апанаев салдырган мәсҗеттер. Бу мәсҗеттә булган имамларның мәгълүмнәре әүвәл Хәмид мулла, икенче — дамелла Мөхәммәд, өченче — Шаһи хәзрәт имам вә мөдәррис иделәр.

---

[1] Әманәт ләваземын әда кыйлып торды — үтәлергә тиешле бурычларны үтәп торды.

[2] Тәсаррыфында — карамагында.

[3] Фәтех кыйлды — ачты.

Бишбалта мәсҗете кадимнән агач мәсҗеттер — хәзерге мәсҗет яңарак салынды, Юнусовлар гыймарәт кыйлды. Монда элгәреге имамларның исемнәре мәгълүм түгелдер, соңгы мөтәвәффа Габделислам мулла имам иде.

Дары бистәсендә әүвәлләрдә мәсҗет булганмы, юкмы, мәгълүмем булмады, әмма бу мәсҗетне Казан сәүдәгәре Муса, Мөнасиб углы салдырды 1809 елда. Мәнгер Муса диерләр иде. Бу мәсҗеттә имам булган адәмнәрдән әүвәл Габденнасыйр мулла, икенче — Шәмсетдин мулла, өченче — Габдерәкыйб мулла имам иделәр. Инде Казан шәһәрендә вә бистәләрендә барысы ундүрт мәсҗеттер — бу мәсҗетләргә караган әһле ислам унике меңләп җандыр. ...нче таш мәсҗет яңа мәхәллә дип мәгърүфдер, Яңа бистәгә чыкканда — Мөхәммәдҗан Нәзир углы салдырды 1874 сәнәдә.

## КАЗАН*

Бу дөньяда кем килеп, кемнәр китмәделәр. Һәм һәркайсыбыз, әлбәттә, китәчәкбез. Мәгәр, җан хатимә белән китсәк икән диеп, даимән хәер-фатыйхада булыйк.

Бу дөньяның Европа өлешендә, иң олуг елга — 3400 чакрым озынлыкта Волга, яки Кара Идел елгасының сул тарафында, Казан елгасы исемендә суның Волга елгасына кушыла торган җирендә, Волгадан җиде чакрым арада Казан шәһәре Идел буенда беренче дәрәҗәдә олуг вә матур бер шәһәрдер. Олуглыгы, календарьлар хисабына караганда, йөз меңнән арткандыр, ике йөз мең диелсә дә ышанырга мөмкин.

Урамнарында вә базарларында халкы казан кебек кайнап тормактадыр. Бу шәһәрдә һәм кемнәр килеп, кемнәр китмәделәр. Хәтта бу шәһәрдә падишаһ вә ханлык сөргән кемсәнәләрнең исемнәре онытылып, гүяки дөньяга һич килмәгәндәй булдылар. Бөтен дөнья ахырында һәм шулай булачак.

Ошбу шәһәрдә берничә мең мөселманнар да мәгыйшәт кыйлмакталардыр. Шәһәр кешеләре, әлбәттә, рәсми рәвештә мәгълүмдер. Без монда тәгаен кыйлмаенча яздык. Халык телендә Казанда утыз мең мөселман бар, дисәләр дә, ул кадәр үк булмаска кирәк, җөзафә[1] әйтелгән сүз булырга кирәк. Әгәр утыз мең мөселман булса, гакыл мәртәбә утыз мәсҗет булыр иде. Хәзерендә унике мәсҗет күренәдер. Ул мәхәлләләрдән дә мең кешелесе вә ...галимнәр бар микән.

---

* Мәкаләне Гүзәл Насыйрова әзерләде. К.Насыйриның бу кулъязмасы ТР БДМда 114215-1 номеры астында саклана.

[1] Җ ө з а ф ә — үлчәүсез.

Безнең татар халкының гадәтендә мең кешеле мәхәлләгә ике йә өч мәсҗет төзү, халкы азмы-күпме, аны сөйләү. Максатыбыз — анда нинди халык яши, вә ни кәсеп белән мәшгульләр, нинди холыкталар — шуны бәян кыйлып, шәригатькә каршы булган, начар булган холык вә гадәтләребезне ташлап, күркәм холык тәхсил итмәк. Бу шәһәрдә вә өлкәдә тереклек кыйлучы мөселманнар татар дигән таифәдер. Болар төрек таифәсеннән бер төркем булып, вә сыйныф мәшһүр, вә мәгъруфтыр. Аларны белмәгән кеше булмас. Әйтеп үтелгән таифәдә бер микъдар истикамәт[1] вә бер өлеш хәмәкать[2] вә куркаклык белән билгеле булсалар да, бер микъдар җәванмәрдлек[3] вә мөсафир дуслыклары да юк түгел. Гыйлем вә һөнәргә кабилиятләре дә юк түгел. Һөнәрләре ... шаять, зикер ителсә кирәк.

Казанның урамнарында электр көче белән йөри торган (трамвай) татарча вагоннар биш тиен, ун тиен. Олуг шәһәрнең бер читеннән икенче читенә тиз вакытта илтеп җиткергәнлектән, һәрвакыт вагоннарда туп-тулы халык гизмәктәдер. Кичәләрдә урамнарында ике тарафтан тезелгән газ фонарьларыннан башка, бу соңгы заманнарда электр фонарьлары көндез кебек яктыртмактадыр. Мөселман мәхәлләләре арасында олуг таш мәсҗетләр вә алтынланган айлар шәһәргә тагын да артык зиннәт бирмәктәдер. Кайбер җамигъларның алдында электр фонарьлары кичәләрне көндез кебек яктыртып тора. Һәммә байлардан өмид иteләдер, мәсҗетнең эченә электр лампалары куйдырмаклары ...булмаганлыктан, шаять, голямаи кәрам шәригать җәһәтеннән каршылык кыйлмасалар кирәк дип уйланыладыр.

Казан әүвәлдә мөселман ханнары тәсаррыфында[4] булганга, берничә җирләрдә зиярәт урыннары да бар. Кабан күле башында, ханнарның әүвәлдә җәйге дачалары булган җирдә, хәзерендә Архирей бакчасыдыр. Шул бакчада бер солтан кабере бар. Зиярәт кыйлучыларга архирей тарафыннан һичбер каршылык юк, һәркемгә изен[5]. Янә крепость эчендә Сөембикә манарасы кырыенда, кыйбла ягында, зиярәт бар дип риваять кыйлалар. Һәм шул манараның мәгъриб шималь тарафында, крепостьнең түбән тарафында бер чишмә булып, аның суы белән дәвалანучылар да юк түгел.

Бу Казан шәһәре өч кыйсемгә бүленәдер. Кояш чыгышыннан баешына таба сузылган Кабан күле һәм беренче җәмигъ мәсҗет кырыеннан башлап, Казанка елгасынача сузылган Бо-

---

[1] Истикамәт — туры юл, дөрес юнәлеш.
[2] Хәмәкать — ахмаклык.
[3] Җәванмәрдлек — юмартлык, шәфкатьлелек.
[4] Тәсаррыфында — кулында, идарәсендә.
[5] Изен — рөхсәт.

лак каналы икегә бүләдер. Болакның төн тарафы мәхкәмәләр вә хөкүмәт халкы һәм чиркәүләрнең күбрәге бу тарафтадыр.

Иң атаклы урамы — Воскресенский урамыдыр. Бу урам белән университет ягыннан көнбатыш тарафына барылса, татар ханнарыннан калган крепость капкасына кереп китәдер. Бу Кремль — әүвәлге мөселман ханнарыннан калган әсәрдер. Хан мәсҗете диелгән атаклы Сөембикә ханым салдырган манара һәм хәзерге көндә чиркәүгә әйләндерелгән мәчет бинасы һәм башка бинасы һәркайсы татарларның үз фикерләре белән төзелгәнлектән, заманаларында беренче дәрәҗәдә һөнәрле вә фикерле булуга ишарәдер. Хосусән Хан мәсҗете дип билгеле биек мизан белән ясалгандыр.

Югарыда әйтелгән Воскресенский урам — ике тарафы да магазиннардан башка «Казанский пассаж» вә «Гостиный двор» исемле сәүдәи ханәләре бардыр. Ислам сәүдәгәрләре әһелләре дә күптер. Моннан түбән Проломный урамда ике тарафында төрле магазиннарда тулып яткан мал вә сәүдә, сату-алу һәм ислам сәүдәгәрләре дә күптер. Шул урам белән көнбатыштан көнчыгышка таба барылса, «Балык базары» исемле базарга килеп чыгадыр, вә бу Балык базардан һәм башка берничә җирләрдән Болак аркылы күпер илән икенче тарафка чыгадыр.

Казанның икенче өлеше — югарыда әйтелгән Болак каналының көньяк вә төшлек тарафыдыр. Күбрәк ислам әһелләре яшидер. Унике мәсҗетнең тугыз мәхәлләсе бу өлештәдер. Бу тарафта «Печән базары» исемендә площадьта берничә йөзләр әһле ислам кибет вә магазиннарында бөтен Русия ислам әһелләренә җитәрлек әһле ислам товары тулып тора.

Өченче өлеше икенче өлешнең көнчыгыш-көньягында, Яңа бистә диеп билгеле өч мәхәллә, гомумән, әһле исламдыр. Бу ике өлешнең арасын яз башында Иделдән җәелгән бер микъдар су аерадыр. Су кайткач, яшел чирәм вә болын булып торадыр. Бу бистәне «Яңа бистә» диюләренең сәбәбендә бер төрле акыл булса да, асылсыз булса кирәк. Янәсе руслар Казан шәһәрен басып алгач, әһле ислам төрле тарафларга таралып, кайберләре янәдән килеп, руслардан урын сораганнар. Русларның башлыклары «вон вам место» диеп, бу урынны күрсәткәннәр. Аларның ишарәте буенча, шунда берләшкәннәр. Ул заманда урысча белмәгәнгә, башлыкның «вон вам место» дигән сүзеннән Яңа бистәне фәһем кыйлып, Яңа бистә дип атаганнардыр. Яисә югарыда әйтелгән икенче өлешне Иске бистә дигәнгә, шул бистәдән аерылып утырганнары өчен Яңа бистә дигәннәр. Бу Яңа бистәдә ике урам вә берничә переулок вә тыкрыклар бардыр. Бер урамны «Большой Симбирский» вә икенчене «Малый Симбирский» урам диеп атаганнар. Бу бистә Идел белән Сембер тарафыннан булса кирәк.

## Казан мөселманнарының кәсепләре

Казан халкы кул һөнәре белән бөтен Русиядәге Кама, Волга вә Агыйдел буйларында, Урал һәм Сибирия мөселманнарын баштан аяккача киендереп торалардыр. Бәгъзеләре читек-кәвеш, вә бәгъзеләре бүрек-калпак вә кәләпүш хезмәтләре белән бик күп эшләр кыйлалар. Һәм сабын вә тире, вә май кәсепләреннән башка мануфактур, чәй-шикәр вә галантир магазиннары белән эш кыйлучылары да бик күптер. Русиянең җәйге вә кышкы ярминкәләрендә даулашканда булган сәүдәгәрләре дә аз түгелдер. Әлхасыйль, халкы дәрәҗәләрендә кәсеп вә һөнәр ияләре дип әйтергә бик лаеклылардыр. Бу сүзебез кайбер «нәкыс әл-гакыл фид дин»[1] булган милләт исламия дошманнары булган татарларга хилаф булса да, булган хәлне язмыйча яшереп калдыруны мәслихәт күрмәдек.

## Казанның мәсҗет җамигъләры

Әүвәлге җамигъ мәсҗете «Юнусовлар мәхәлләсе» диеп билгеле. Юнусовларга мөнәсәбәттә бирелүе, алар төзегәннәре өчен булмыйча, фәкать дәүләтле вакытларында бу мәхәлләдә алардан шөһрәтле кеше булмаганга, аларга нисбәтән бирелгәндер, Юнусовлардан башка бирелердәй кеше ишетелмидер хәзерендә.

«Шиһаб хәзрәт мәхәлләсе» дип әйтүләре мәгъкульдер. Наданнарга нисбәт биргәнче, әһле фазыйльгә[2] нисбәт бирелү олыдыр. Бу мәчет 1181 һиҗри елында императрица Екатерина II Казанга килү боерыкларында ислам әһелләренең үтенечләре буенча императрицаның әмере вә фәрманы белән бина кыйлынган. Бу мәсҗетнең михрабы Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең тәхкыйкына нигезләнеп, кыйбладан тугыз дәрәҗә көнбатышка авышкандыр. Ул заманда кыйбланы белүнең озынлык вә киңлегеннән чыгып карамыйча, бәлки тәхәрри[3] белән ясаган булсалар кирәк. Казан мәсҗетләренең кыйблаларында ихтилафат[4] күптер. Бу мәсҗеттә әүвәлге имам — мелла Габдерәшит бин Йосыф бин Кадермөхәммәт әл-Каргалы. Асылы Оренбург Каргалысыннан булып, беренче җамигъ вакытында бу мәхәлләдә имам булып, мәсҗет бинасы хосусында яхшы тырышлыгы булгандыр.

Икенче имам мелла Әбү Бәкер бин Ибраһим бин Йосыф

---

[1] Акылда, диндә тулы булмаган.
[2] Әһле фазыйльгә — гыйлем әһелләренә.
[3] Тәхәрри — тикшерү.
[4] Ихтилафат — каршылыклар.

әл-Казани, чыгышы Казан әһелләреннән. «Җәмгыяте шәргыя» мәхәлләсе ачылуында Мөхәммәдҗан мөфти шәкерте белән казый булган.

Өченче имам дамелла Ибраһим бин Хуҗаш. Асылы — Бөгелмә төбәгендә Шарлама исемле авылда тугандыр. Әмма әүвәлдә үткәне Мәчкәрә авылы тирәсендә Янгул исемле авылдан күчеп киткән. Атасы Хуҗаш кабере Янгул карьясендә әле мәгълүмдер. Ләкин ул авыл әһеле хәзердә барысы чирмешләрдер. Ул тарафта авыллар әүвәлдә чирмеш вә ар белән кушылган булганга, мөселманнар аерылып, Бөгелмә төбәгенә күчкәннәр булырга кирәк. Әлеге Ибраһим хәзрәт халык телендә Әфәнде, хәзрәт диеп билгеледер. Кавказ вә Дагыстан тарафында мелла Гали әфәнде әш-Ширвани вә гайре галимнәр гозереннән гыйлем алгандыр. Әфәнде хәзрәт бик җөрьәтле вә гайрәтле динче вә тәкъва галим булган. Казандагы бик күп бидгатьләрне бетергәндер. Казанга ул килгән вакытларда Казан халкы кара чикмән вә итек киеп йөриләр икән. Туйларында ирләр вә хатыннар бер мәҗлестә хозур булып гел шулай йөргәннәр. Әфәнде хәзрәт бу гадәтләрне бетергән вә киемне төрле иткән. Мәсҗеткә вә мәҗлесләргә барганда чалма кию гадәтләренә һәм никях вакытында кыз тарафыннан кияүгә намазлык җибәрү һәм комган алып бару гадәтләренә бу кеше ирешкәндер. Кыскасы, Казан ханнарыннан соң шәригать юлын салучыларның иң әүвәлгеседер. Савабы кыямәт көненә барып торсын иде.

Кабан күлендә боз каткач, кечкенә бәкегә канәгатьләнмичә, ... зур иттереп тирәсенә хайваннар төшмәстән киртә тоту гадәтен бу зат чыгарган дип, дамелла Фәхретдин әл-Норлатый сөйли торган иде.

Дүртенче имам дамелла Сәгыйд бин Хәмид бин Солтан әл-Бәрәскәви. Чыгышы Казан төбәгендә Бәрәскә авылыннан. Гыйлем алуы Урнаш башы бер хәзрәт хозурында һәм дамелла Габденнасыйр әл-Ташты хәзрәт хозурында булып, ахырында Бохараи Шәрифтә галимнәрнең гозерен файдаланып, шул мәхәлләдә мөдәррис булган.

Алтынчы имам (бишенчесе күрсәтелмәгән.— *Г.Н.*) дамелла Шиһабетдин бин Баһаветдин бин Сөбхан әл-Мәрҗанидер. Атасы Ташкичү авылында имам вә мөдәррис булган. Атасы хозурында башлангыч гыйлемне алып, ахырында Бохараи Шәрифкә галимнәр гозерен файдаланган. Бу мәсҗеттә Әфәнде хәзрәттән соң моның кебек дус(?) сүзле булган кемсәнә имам булганы беленми. Бу хәзрәтнең камиллеген гасырдашларыбызга бәян кыйлырга хаҗәт булмаганга, артык җентекләп аңлатмадык. Әмма моның гозеренә ирешмәгән кешеләр бу хәзрәтнең әсәрләреннән «Вафият әл-әслаф», «Хәзамә», «На-

зурә» вә «Мөстәфад әл-әхбар» исемле вә гайре әсәрләрен укысалар, бу кешенең ни дәрәҗәдә камиллеген, вә ни холыклы, дөньяга нинди караштa булганлыгын аңларлар.

Җиденче имам мелла Борһанетдин Әбү әл-Габбас бин Шиһабетдин әл-Мәрҗанидер. Әүвәлдә атасы хозурында башлангыч белемне алып, соңыннан Истамбулда укып кайтып, имам булды.

Бу мәхәлләдә мәрхүм Әфәнде хәзрәт заманасыннан бер мәдрәсә бардыр. Ләкин әүвәлдә мәдрәсә Юныс угылларыныкы булмаган. Ибраһим бай белән Шиһаб хәзрәтләре арасында бертөрле бозылышу булганга, Юныс угыллары, аталары төзегән мәдрәсәне карамыйча, мәдрәсә тотарга мөмкин булмагач, мәхәллә халкы ярдәм итеп, мәсҗет каршысыннан бер йорт алып, мәдрәсә итеп үзгәртеп кордылар. Ибраһим бай соңыннан үзгәртеп корса да, ул мәдрәсә буш калды.

Шиһабетдин хәзрәт вафаты соңында мәдрәсәсендә үзеннән соң дәвам иттерүче булып хәзрәтнең кияве булмаклыгы җәһәтеннән мелла Сафиулла бин Габделҗәлнәви хәзрәт урынына мөдәррис булу фикере... төшеп, Борһанетдин мәхдүм мәншүрле[1] имам булганга, аның әмере белән мәдрәсәдән полиция белән мелла Сафиулланы аңа ияртүчеләре белән бергә чыгардылар. Мелла Сафи мәдрәсәдә күп торганга, иярүчеләре дә күп иде. 120 чамасында шәкертләр ияртеп чыгып, Казанның билгеле сәүдәгәрләреннән, Шиһабетдин хәзрәт шәкертеннән Мөхәммәтсадыйк Галкәевләрнең һиммәте белән Яңа бистәдә Степан исемле бер русның йортын әҗәткә алып, шәкертләрен шунда ирештерделәр дә фәкать остазының мәдрәсәсен туздырудан башка бер эш хасыйл итмәделәр. Шәкертләре берничә ай Степан өендә маташып, ахырында кайберләре авылларга, кайберләре әүвәлге мәдрәсә, вә кайберләре Күл буе вә башка мәдрәсәләргә таралып беттеләр. Халык телендә «Степан мәдрәсәсе» дип билгеле һәм мәшһүр булды. Сафиулла әфәндене хан урдасына мелла вә мөдәррис итеп алсалар да, казакъ җирендә татарларга дәрес әйтү тыелганга, казакътан өстенә икенче имам тәгаен кыйлып, дәрес әйтүдән тыелды. Янә анда ... имам булып тормагында файда булмагач, әйтелгән мәхәлләдәге мөхлисләрдән үтенеп, Борһан мәхдүм мәсҗеткә төзек гакыл белән йөрмәгәнлектән, ...бу мәхәлләнең сигезенче имамы булып саналды. Мелла Сафиулланың гыйлеме әүвәлдә Буада дамелла Габденнасыйр хәзрәт хозурында

[1] Мәншүрле — хокук кәгазенә ия.

булып, ахырында дамелла Шиһабетдин хәзрәттә гыйлем алып, шул дәрәҗәгә иреште. Мәхдүм һаман риза булмаганга, мәдрәсәгә керә алмаенча, фәкать билгеләнгән имам булып торадыр.

## Икенче мәсҗет имамнары

Бу мәсҗет хәзерендә «Байлар мәхәлләсе» диеп билгеле. Казанның мәшһүр байларыннан Ягъкуб бин Солтанай исемендә ...бина кыйлынмыштыр. Әлеге мәсҗетнең михрабы кыйбладан егерме дәрәҗә көнбатышка авышканлыктан, көнчыгыш тарафындагы почмакта имам торып, шул тарафка юнәлеп укыйлар. Халык телендә сөйлиләр: әлеге Ягъкуб байның ул вакытта дәүләте бетә башлаган вакыт икән. Калган бар кебек малны сарыф кыйлып, кичәләрдә хәлиләсе[1] белән чыгып, савап өмиде белән, таш вә агач, вә балчык кебек әйберләр хәзерләп куялар икән. Кыямәт көне савабы үзләренә насыйп булса иде. Амин.

Бу мәсҗеттә әүвәлге имам (Мортаза?) бин Габделгазиздер. Икенче имам мелла Салих бин Сәгыйд бин әл-Хәсән Әлкиледер. Бохараи Шәрифтә кямил гыйлем алып кайтып, Иске Кенәрдә имам вә мөдәррис булган. Ахырда, мелла булып сайлаганның соңында, Казанов имам вә мөдәррис булган.

Өченче имам мелла Фәхретдин бин сайлангандыр.

Дүртенче имам дамелла Исхак бин Сәгыйд асылда Кенәр авылыннан. Бохараи Шәрифтә укып кайтып, югарыда әйтелгән мәхәлләгә имам вә мөдәррис булган. Бик күп кешеләр файда алып чыккан.

Бишенче имам дамелла Мөхәммәткәрим бин Мөхәммәдрәхим әл-Тәкәнеш, чыгышы Мамадыш төбәге Тәкәнеш исемле авылдандыр. Әүвәлдә Мәчкәрәдә дамелла Габдулла хәзрәт мәдрәсәсендә укып, соңра Бохараи Шәрифтә укып кайтып, шул мәхәлләдә имам вә мөдәррис булып, гыйлем тараткан. Казан шәһәрендә гыйлемне кувәтләндерүчеләрдән бу гасыргача бу зат кебек кемсәнә килгәне беленмәде. Үзе бик тәкъва вә гайрәтле кеше булган. Хозурында белем алучы бик күп кешеләр кямил белем алып, файда алуча булганнар. Ахырында хаҗ сәфәренә китеп, Истамбулга күчә. Анда вафат була. Хәзердә бер углы Мирза Салих исемендә Истамбулда сатучы вә сәүдәгәр таифәсеннән. Икенче углы (мәдрәсәнең исеме язылмаган.— *Г.Н.*) исемендә хәрби мәдрәсәдә укып, пашалык дәрәҗәсенә ирешкән диеп ишетелде.

Алтынчы дамелла Сәлахетдин бин дамелла Исхак бин Сәгыйд әл-Кенәри югарыда әйтелгән дүртенче имам Исхак хәз-

[1] Хәлиләсе — хатыны.

рәтнең углыдыр. Бохараи Шәрифтә кямил белем алып кайтып, имам вә мөдәррис булган. Шиһабетдин хәзрәт белән бер гасырда бераз булдылар, мәгәр гомере кыска булды. Шиһабетдин хәзрәткә китап язу белән шөгыльләнмичә, дәрес белән мәшгуль булганга, Сәлах мәхдүм мәдрәсәсеннән чыгып, имам булучылар башка мәдрәсә шәкертләреннән күпкә өстен булып чыгалар иде. Гасырдашлары Сәлах хәзрәт белән Шиһаб хәзрәтне галимлек җәһәтеннән һәр икесе тигез диерләр иде. Бик зиһенле мөдәррис булган.

Җиденче имам дамелла Таҗетдин бин Бәшир әл-Суксуви. Чыгышы Буа төбәгенең Иске Суыксу исемле авылдан. Бохараи Шәрифтә белем алып кайтып, Олы Мәңгәргә мөдәррис булып, берничә еллар дәрес әйткәч, ахырында, Сәлах хәзрәт вафаты соңында, аның урынына мөдәррис булды. Бик яхшы истикамәтле мөдәррисләрдән иде. Шәһәрдә өч ел дәрес әйтеп, 1294 һиҗри елында рамазан шәрифнең 13 нче көнендә вафат булган...

## НЕКРОЛОГ ВӘ ҺӘМ КАБЕР ТАШЛАРЫ

*(Ягъни үткән голяма вә фозала хакында берничә сүзләр вә дәхи бәгъзе кабер ташлары хакында риваятьләр)*

### Мелла Габденнасыйр әл-Курсави

Мелла Габденнасыйр әл-Курсави — Казан губернасы вә өязе Курса илендә имам вә мөдәррис вә һәм зиядә мөхаккыйк вә мөдәккыйк голямаи заман, хәтта мөҗтәһид дәрәҗәсендә, Курса Габденнасыйр мелла дип мәшһүр адәм иде. Һәр хөкемне Кәламулладан иҗтиһад кыйлыр иде. Вә әйтер иде: «Замане иҗтиһад мөнкарыйз түгел, һәркем мөбтәля биһ үзе иҗтиһад кыйлсын. Мөҗаррәде тәкълид мәзмум»,— диер иде. Вә һәм: «Голямаи Тафтазанидан соң миндәин адәм дөньяга килгәне юк»,— диер иде диләр. Мөсәннафат вә тәхрирләре күптер. Җөмләдән берсе — «Гакаид-ән-нәсәфи»гә шәрех иткәндер. Башка гакаид китапларына караганда аермасы бардыр. Ягъни Габденнасыйр мелла «сыйфат уллаһ ваҗыб-эл вөҗүд биззат» дип язадыр. Бу хосуста Бохарада күп голяма белән моназара кыйлышып, күп адәмнәре иззах кыйлганнан соң, әмиргә мәгълүм булып, әмир Габденнасыйр мелланы сәясәт мәйданына китереп кател кыйлырга хөкем иткәч, дуслары вә шәрикләре: «Бу сүзеңнән кайт, вә илля башың китәдер»,— дип димләгәннәрдер. Як-ягында ничә җәлладлар ялангач кылыч белән

торганда, Габденнасыйр мелла: «Бу сүземнән кайттым», — дигәч, әмир кателдән хәляс кыйлгандыр. Әмиргә вә Бохараның башка голямасына хилаф төшкән гыйбарәт ошбудыр: вә иза тәхкыйкать мәнзә лед зат вә исфат гыйн әт тәгъдад вә-т-тәксир фаглам ән важыб әл вөҗүд биз зат һу Аллаһ Тәгалә вә сыйфәтә фәлән хасхас әл хак вә батыйл ма кян әйгамәлүн» дигән гыйбарәттер. Вә дәхи аның мөсәннафатыннан «Һәфтияк шәриф»кә ясаган тәфсире бар халык арасында мөстәгъмәл вә могтәбәр тәфсирдер. 1863 елда басылган иде.

Бу тәфсирдән башка янә берничә рисаләсе бар. Шәфәкъ хосусында бер рисаләсе бар. Ошбу рәвешчә ибтида кыйлынадыр: «Вә кад зекер Аллаһ Тәгалә әүкат-эс салат көллеһа фил-Коръән мәҗмаләт иля ахириһи». Янә әүкат эс-салат вә шәфәкъ хосусында күп тәхрирләре күренәдер. Тәхрирләреннән мазмуны фәһемләнә: мөбтәля биһ үзе иҗтиһад кыйлырга тиеш. Заман иҗтиһад мөнкарыйз түгелдер. Габденнасыйр мелла Курсавиның виладәте, тәкърибан 1765 еллардадыр. Хаҗ сәфәрендә Стамбулда тагун белән вафат булгандыр, 1813 елда. Казаннан бергә киткән кешеләр бер көнне ун кеше вафат булганнар. Күбесе Габденнасыйр мелланың шәкертләре иде, диләр. Хаҗ сәфәренә китмәс борын Курсада ничә еллар дәрес әйткәндер.

(Тәрҗемәсе. Ягъни үткәннең күренекле кешеләре һәм галимнәре турында берничә сүз һәм шулай ук кайбер кабер ташлары хакында риваятьләр.

Мулла Габденнасыйр әл-Курсави — Казан губернасы һәм өязе Курса авылында имам һәм укытучы, заманының чын мәгънәсендә дикъкатькә лаеклы зур галимнәреннән, хәтта яңача иҗат итүче Курса Габденнасыйр мулла дип атаклы адәм иде. Һәр хөкемне Коръәннән чыгарырга тырышыр иде. Һәм әйтер иде: «Яңалыклар ачу заманы бетмәгән, һәркем үз фикеренчә үзе тырышсын. Гомум агымга иярү хурлык»,— диер иде. Һәм тагын: «Галим Тафтаназыйдан соң миндәен адәм дөньяга килгәне юк»,— диер иде диләр. Язылган әсәрләре һәм мәкаләләре күптер. Җөмләдән берсе «Гакаид эн-нәсфи» китабына комментарийлар биргәндер. Башка хокук китапларына караганда аермасы бардыр. Ягъни Габденнасыйр мулла «Алланың сыйфаты зарури барлыкның асылында» дип язадыр. Бу турыда Бохарада күп галимнәр белән бәхәсләшеп, күп адәмнәр белән аңлашулар алып барганнан соң, әмиргә билгеле булып, әмир Габденнасыйр мулланы хөкем мәйданына китереп җәзаларга хөкем иткәч, дуслары һәм укучы иптәшләре: «Бу сүзеңнән кайт, яки башың китәдер»,— дип димләгәннәрдер. Як-ягында ничә палачлар ялангач кылыч белән торганда, Габденнасыйр мулла: «Бу сүземнән

кайттым»,— дигәч, әмир җәзадан коткаргандыр. Әмиргә һәм Бохараның башка галимнәренә каршы төшкән фикере будыр: «Хакыйкатьне эзләү һәм табу борын заман ышануларын (потларын) киң куллануда, аларга табынуларда түгел, ә бәлки аларның кирәксезләрен бетерү тиешле — бу Алла Тәгаләнең кешенең үзенә биргән сыйфаты һәм хокукы. Элеккечә гамәл кыйлу дөрес түгел»,— дигән сүзләрдер. Һәм тагын да аны язган әсәрләреннән «Һәфтияк шәриф»кә ясаган комментарийлары бар, халык арасында кулланыла һәм ихтирам ителә торган китаптыр. 1863 елда басылган иде.

Бу китаптан башка янә берничә әсәре бар. Шәфәкъ хакында бер мәкаләсе бар. Ошбу рәвешчә башланадыр: «Алла Тәгаләне Коръәндә күп телгә алу барысы бергә аңа мактаулы дога гына». Ахыры. Янә намаз һәм ясту турында күп язмалары күренәдер. Язмаларының эчтәлеге бу мәгънәдә: Кеше үз фикеренчә тырышлык күрсәтергә (эшләргә) тиеш. Заман — тырышлык. Эшчәнлек заманы бетмидер.

Габденнасыйр Курсавиның дөньяга килүе чама белән 1765 еллардадыр. Хаҗ сәфәрендә Истамбулда чума авыруыннан вафат булгандыр, 1813 елда. Казаннан бергә киткән кешеләр — бер көнне ун кеше вафат булганнар. Күбесе Габденнасыйр мулланың шәкертләре иде, диләр. Хаҗ сәфәренә китмәс борын Курсада ничә еллар дәрес әйткәндер.)

## МАКАРЬЯ ЯРМИНКӘСЕ

*(Асылда Казан ярминкәсенең каим мәкамыдыр[1])*

Мәгълүм ула ки, ошбу ярминкә кадим Казан ярминкәсе иде — Макарья календаренда мәзкүрдер ки, бу ярминкәнең ибтидасы[2] мәгълүм булган кадәресе 1257 гасырлар (еллар?) әснасендәдер[3] — әмма аннан мөкаддәм Болгардан Казанга күчерелмеш ярминкә булмак һәм ихтимал — кадим заманда бу ярминкә Казанда Арча кырында буладыр иде, Болакның шималь шәркый тарафлары вә Казан хисарының тышкы тарафлары Арча кыры аталган иде — һәр елны ошбу мәзкүр җирдә июнь аенда ярминкә буладыр иде. Азия тарафыннан, Кытайдан, Һиндстаннан, Мәскәүдән, Новгородтан вә гайре этрафлардан күп халык җыелыр

---

[1] Каим мәкамыдыр — эшен алмаштыручыдыр.
[2] Ибтидасы — башлангычы, әүвәлгесе.
[3] Әснасендәдер — вакытындадыр.

иде — олуг сәүдә кыйларлар иде. Һәр әдъяннан[1] вә һәр милләттән — Азия малы белән Европа малының сәүдәсе вә мөгавәзасы[2] анда иде — ярминкә җиренә Казан ханнары һәм чыкалар иде, ярминкәдә орыш-кырылыш булмый калган ел аз иде, һәр елны ярминкәдә талау вә үтерешү күп иде — Мәскәүнең ханы Василий Иванович IV* рус сәүдәгәрләрен Казан ярминкәсенә барып сәүдә кыйлуларыннан мәныг кыйлды вә һәм 1524 елда Сура елгасы тамагында Васил каласына ярминкә ясап карады, ул каланы үзенең исеме белән тәсмия кыйлды[3], сәүдә низамнары өчен анда мәхкәмәләр вәзыг кыйлды[4] — Азия сәүдәгәрләрен Мәскәү мәмләкәте тарафына тартырга иҗтиһад кыйлды — әмма ул ярминкә Васил каласында тупланып җитә алмады. Чөнки, бер тарафтан, Азия сәүдәгәрләре ул кадәр ят җиргә ярминкәгә барырга курыктылар — дәхи дә, икенче тарафтан, ул вакытта рус халкының Сары күл тигрәсендә Иделнең суң ягында шәриф җайлары булып, русның гыйбадәтчеләре анда бара-бара ярминкә халыклары һәм анда күчеп бетмешләрдер — ахыр татар таифәсенең усаллары һаман рус сәүдәгәрләренә тынычлык бирмәделәр, шул җәһәттән ярминкә эше анда да алга бармады, бәлки, билкөллия[5] бетте. Аннан соң Мурашкин дигән авылда Ибрами исемле бер кеше һиммәт кыйлып, Сары күл ярминкәсен яңартты.

Бәс, Макарья ярминкәсе 25 июльдә башланды. Ул вакытта Казанда олуг Мөхәммәд хан иде. Әүвәл мәртәбәдә бу ярминкәнең сәүдәсе: киндер, агач савыт, эшлия, киез итек, бияләй, бүрек вә һәм тун кебек авыл халкы эшләгән нәрсәләр иде; аннан соң бара-бара һәр этрафтан күп халыклар җыела башлады. Ул вакытта ярминкәдә сәүдә кыйлган өчен бер хак та түләмәсләр иде, бары амбар хакы, кибет хакы бирәләр иде Макарья монастыре файдасына.

Аннан соң падишаһ Михаил Федорич 1641 елда июльнең 25 нче көнендә бер көн өчен монастырь файдасына җыю салды, әмма Алексей Михайлич падишаһ заманында биш көн ярминкәдә һичнәрсә бирмәенчә сату итмәк рөхсәт иде, аннан соң, ягъни биш көннән гайресенә биш рәбех[6] алалар иде — 1666 елларда ярминкәнең мөддәте ике атна иде — ошбу елларда Ма-

---

* Дөресе: Василий III

[1] Әдъяннан — диннән.

[2] Мөгавәзасы — алмашуы.

[3] Тәсмия кыйлды — исем кушты.

[4] Вәзыг кыйлды — оештырды.

[5] Билкөллия — бөтенләй, тәмам.

[6] Рәбех — табыш, файда.

карья ярминкәсенең хосулы[1] 3500 сумнар иде вә һәм 1667 елда Алексей Михайлич падишаһ ярминкәнең хосулын хәзинәгә алыр булды, ләкин Федор Алексееч янәдән монастырь файдасына кайтарды. Федор Алексееч падишаһ заманында ярминкә байтак олуг булмыш иде — аның әмере белән Макарья монастыре файдасына ярминкәгә килгән малдан сумына өч акча[2] җыю салынмыш иде, әмма Казанның баҗханәсендә[3] сумына ике акча алыныр иде (чөнки бу тарихта, ягъни 1680 елларда Казанда баҗханәсе һаман бар күренәдер, мәшрикъ тарафыннан килгән малдан хәраҗны Казанда алыныр иде). Әмма Макарья ярминкәсенең кадимге урыны вә юлы бик яман, Иделнең уң ягында Сары күл дигән җирдә иде. 1816 елда бик олуг ут булып, бөтен ярминкә тәмам янып бетте. Аннан соң 1817 елда Ока Иделе белән Кара Идел арасына уңай җирдә ярминкә гыймарәтләре салып халән[4] ошбу урындадыр — 1890 елда ярминкәгә яңа баш йорт салынды, ике ел эшләделәр.

---

[1] Хосулы — кереме, доходы.
[2] Бер акча — ярты тиен.
[3] Баҗханәсендә — пошлина, налог конторасы.
[4] Халән — хәзердә, хәзерге көндә.

# ТАТАР ЭТНОГРАФИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

## ЙОРТ-ҖИР

Шәһәрдә вә калада торучы мөселманнарның йортлары-җирләре авыл халкының йортларына караганда күп пакизә[1] һәм аермасы бар. Моны һәркем дә беләдер. Әмма без әүвәлән бераз каләм тартаек шәһәр халкы хосусында. Бу шәһәрдә үз йорты булып, үз йорты белән торган кеше яхшы тора, үзе теләгәнчә. Әмма аларның йортлары тышкы яктан караганда урыс йортларыннан бер дә аермасы юк. Әмма өйнең эченә керсәң, өйнең эчтәге төзеклеге урыс өйләренә бер дә охшамый. Һичбер татар өендә юк урамнан керә торган ишек, булса да бик сирәк булыр. Күп вакытны татар өйләре була ике яклы, ягъни ирләр ягы, хатыннар ягы; ирләр өчен үзләренә бер ишек, хатыннар өчен үзенә бер ишек. Хатыннар ирләр ягыннан йөрмәсләр. Һәм күп өйләрдә тәһарәтханә хатыннар өчен башкача була. Бу эшләр мөселманның шәригатенә шулай килешә. Ирләр ягында хатынкыз нәрсәсе — киемдер-салымдыр булырга тиеш түгел. Күп мөселманның өйләрендә һәм шулай була. Шәһәрдә үзенең йорты белән торучы үзенә мәгъкуль[2] үзе теләгәнчә өйнең эчентышын төзек тота. Өендә берничә бүлмә: кунак бүлмәсе, аш бүлмәсе һәм үзенең шөгыльләнеп утыра торган бүлмәсе була; анда кәгазе, карасы, каләме, кенәгәләре һәм китаплары шунда була. Һәркайсы бүлмәдә идәненә палас җәюле. Идәндә палас өстендә кәвеш белән йөрмәк юк. Өйдә читекчән йөриләр. Өйнең эче бик яхшы була. Өйнең диварында һәйбәт бизәкле кәгазь; бик матур ачык төслене яраталар. Һәркайсы өйдә, күрәсең, өйнең төзеклеге урысча түгел. Өй эчендә җәйгән паластан башка өйнең эчен бизи торган нәрсә: көзге, өстәл, урындык, һәйбәт-һәйбәт сандыклар, кием-салым, мендәр-ястык; шуның кебек нәрсәләр белән өйнең эчен бизиләр. Өстәл өсләрендә, мич яннарында һәйбәт агартып куйган шәмдәлләр, җиз тазлар. Бәгъзе

[1] Пакизә — чиста, пөхтә.
[2] Мәгъкуль — яраклы.

кешенең биш-алты самовары була, агартып өстәл өстенә тезеп куялар: өйгә байтак зиннәт бирә. Тәрәзә төбендә — гөлләр, чәчәкләр. Диварга аскан сурәтләр һичбер өйдә юк; моның урынына истигъмаль кыйлалар[1], мәсәлән, бик бизәкләп шәмаил, һәйбәт рамкага куялар, башка догалар, «Аятөл-көрси» кебек һәм Мәккә, Мәдинә сурәте, яки гөл сурәтләрен кәгазьгә язып бик яхшы бизәкләп диварга асалар һәм диварны бизәкләр өчен һәйбәт сөлгеләр эләләр. Әмма тәрәзә пәрдәләре күбрәк ак бүздән яки яхшы кисиядән була. Өй эчендә ышкаф була. Ышкафта һәйбәт савытлар, һәйбәт чынаяклар тулы, көмеш кашыклар, бал кашыклары һәм аш кашыклары, ул һәйбәт баганалы көзгеләр; һәрничек өйнең эче матур, төзек була. Һәркайсы өйдә китаплар бар, хәле кадәренчә, гакылы җитәрлек кадәр, ягъни гыйлеме бар кадәр. Китапны укыйлар тәварихтан, хикәяләрдән; гашыйклар диваны кебек китап күп укыла. Күп кешеләрдә һәм урысча китаплар һәм картиналар була, ләкин диварга кадаклау юк, күз алдында тормый. Бәгъзеләрдә үзләренең портреты һәм була. Мөселман шәригатендә алай диварга картина асарга мәныг кыйлына. Шуның өчен китапларда күренә, сурәт бар өйгә фәрештә кермәс һәм сурәт булса, намаз укыган кеше алдында, уңында йә суңында, намазы дөрес булмас, дип риваятьләр бар. Шуның өчен: мөселман шәригатендә өйдә сурәт вә картина тотмак дөрес түгел; дәхи өйдә эт асрамак моның кебек дөрес түгел; бәгъзе риваятьләргә караганда, эт бар өйгә фәрештә кермәс, дигәннәр.

Бәгъзе кешеләрнең аш өе үз алдына була; бәгъзеләрнең шул өендә, ягъни үзе тора торган бүлмәнең бер бүлмәсе аш өе була; ашны шунда пешерәләр яки түбән өйдә пешерәләр. Ул өйдән башка ишек алдында була баз, ат амбары, амбар, тагы башка келәт кебек нәрсә, бакча, күбрәк капка төбендә кибет була. Әгәр таш өй булса, кладовой һәм була.

Күп кешеләр, урта гына хәлле булса да, тавык-чебеш, казүрдәк, күркә кебек нәрсәләрне асрыйлар, сыер һәм асрыйлар. Һич мөселман катыксыз аш ашамас, ашка катык салып ашар. Чәйне сөт белән эчкән кеше бик сирәк булыр, әмма катыклы ашны күбрәк яраталар. Шуның өчен күп кешедә сыер бар. Хәтта фәкыйрьрәк булса, кәҗә асрый сөте-катыгы өчен. Өй кошларын асраучы бик аз, мәсәлән, кенәри, сандугач кебек сайрый торган кошларны асраштыргалыйлар. Шәригать буенча кошны читлеккә ябып асрамак мәкруһтыр[2]. Шуның өчен кош асрамакны бик хуш күрмиләр. Әмма бәгъзе түбәнрәк дәрәҗәдәге халык Мисыр күгәрчене асрыйлар. Гүя аны асраган кеше

---

[1] Истигъмаль кыйлалар — кулланалар, файдаланалар.
[2] Мәкруһтыр — начар күренәдер.

саваплы була, имеш, дип, бер-бер карчыктан ишеткәннәре бардыр; ул күгәрченне тәбәррекән[1] асрый торганнардыр, ахрысы, шулай гөман итәмен. Мөхәммәд пәйгамбәр Әбү Бәкер белән Мәккәдән Мәдинәгә барганда бер тау тишегенә кергәннәр. Артларыннан куа килеп Әбүҗәһилләр бу гарга[2] җиткәннәр. Ул арада гарның тишегенә күгәрченнәр оя ясаганнар, үрмәкүчләр пәрәвез корганнар, аннан Әбүҗәһилләр кайтып киткәннәр, монда кеше юк, күгәрченнәр оялаган җирдә кеше тормас, дип. Шуның өчен бәгъзе татарлар бу күгәрченне асрыйлар. Әмма шәригать буенча аны һәм асрау дөрес түгел. Ул мөселман җәмәгатеннән бик аздыр үзенең өендә тәмәке, папирос, сигара тарткан кеше, әмма тартучы күп. Өйләрендә тартмыйлар, хосусән кыш көннәрендә иртә белән сәгать сигездә, тугызда өеннән чәй эчеп базарга чыга, өеннән чыккач та трахтирга чәй эчәргә китәләр папирос, сигара тартыр өчен.

## КИЕМ-САЛЫМ

Белгән кеше бар микән: бу татар мөселманнарның киеменең формасы кай заманадан бирле калган икән? Татарда бар кием: күлмәк, ыштан, камзул, казаки, җилән, чапан, чикмән, кыска тун, өч билле тун, толып, чалбар, бишмәт, читек, кәвеш, башмак, бүрек, такыя, кәләпүш. Бу киемнәрнең бәгъзесе бар, башка халыкта һичберәүдә күренми. Һичбер халыкның киеменә охшамый. Бу якын-тирәдәге халыкларда ирләр күлмәге күбрәк озынлыгы тезгә җитәр-җитмәс буладыр, җиңел ситсадан яки бүздән, һәркем үзенең теләгәненә күрә; әмма ирләр ефәктән күлмәк-ыштан кимиләр вә гайре киемнәр һәм кимиләр; ефәк кием кимәк шәригатьтә ирләргә дөрес түгел. Әмма кәләпүшне ефәктән тегеп кияләр, зарар юк. Ирләр ыштаны һәм ситсадан яки башка нәрсәдән, һәрничек фабрикада сугылган нәрсәдән була. Күбрәк ситсадан кияләр, балаклары киң һәм озынлыгы тубыкка чаклы була. Ыштанның төбе киң була һәм бөрмә дип әйтәләр, шул бөрмәгә тасмадан бау тагыла. Шул тасма бау белән ыштанны җыеп бәйлиләр. Ирләрдән бик аз булыр ак ыштан кигән кеше. Ләкин ишанлык дәгъвасын кыйлган бәгъзе ахмаклар — мин аларны әйтәмен салкын ишан дип — алар ак кәләпүш, ак ыштан кияләр. Моның хакында үз алдына бер фасыл язармын. Бәгъзе кешеләр ак күлмәк кияләр, Бохардан яңарак кайткан кешеләр; якасыз була, урыс күлмәгенә охшагандай — аны сарт күлмәге дип әйтәләр.

---

[1] Тәбәррекән — мөбарәк күренгән, мөбарәк эш дип.
[2] Гарга — тау тишегенә, мәгарәгә.

Дәхи камзул дигән бер кием бар. Ул камзулны һәртөрле материядән тегәләр, кемнең күңеленә ни-нәрсә ошый. Ул камзул бик кыска була, җиңсез була. Иң астан кия торган киемдер, күлмәк өстеннән, урысларның жилеты урынына. Якалы була, алдан төймәлиләр биш йә алты төймә белән, һәм кесәләре була. Ул камзулның тагы бер төрлесе була кыска җиңле, җиңе терсәгенә җитәр-җитмәс. Ул камзул күп кешедә әдрәстән йә бикасаптан[1] була.

Дәхи казаки дигән кием попларның полукафтаны кебегрәк була; озын була, тездән түбән, тубыкка чаклы, һәртөрле нәрсәдән. Элгәре күбрәк әдрәстән, бикасаптан буладыр иде; инде бу еллар башка яхшы нәрсәдән, пустау[1] кебек вә гайре заграничный заттан була. Ул казаки өч билле, озын җиңле була, төймәләре тапастан яки көмештән, һәркемнең теләгәненә күрә: ике якта ике кесәсе була һәм сәгать кесәсе була. Янә шул казакиның арасына мамык салып тексәләр, бишмәт дип әйтәләр. Ул бишмәтнең казакидан аермасы юк формада. Тирәсенә ефәк тасма йә йон тасма тоталар. Бу бишмәтне, казакины һәрбер төрледән тегәләр. Буй-буй нәрсәдән яки бер генә төследән. Вә дәхи җилән дигән киемнәре нанке һәм лачтек[1] вә гайре йон, мамык материяләрдән тегәләр. Пустаудан булса, чикмән дип әйтәләр. Җилән белән чикмәннең формасы билсез була, озын якалы. Бәгъзе кешеләр чикмәннең, җиләннең тирәсенә ефәк ышнау тоталар яки тасма тоталар йә йон тасма тоталар, хәленә күрә һәм охотасына күрә. Әмма бу чикмән һәм җилән буй-буй нәрсәдән булмый, элгәре җиләнне, чикмәнне әдепле итеп тегәләр иде; инде бу елда әдепле җилән, әдепле чикмән һичкемдә юк. Әмма чапан асыл Бохар киеме, сартлардан чыккан кием. Ул чапан әдрәстән, бикасаптан, саранчыдан, бәнаристан[1] була. Ул һәм җилән шикелле эчле-тышлы була, әйләнәсенә җияк тоталар ефәктән. Ул җияк ышнур кебек нәрсәдер. Ул чапан бу йортның голямасының киемедер. Күбрәк мулла җәмәгате кия һәм байлар кия мәҗлескә барганда, мәсҗеткә барганда; һәм голямага, мулла җәмәгатенә килешә торган киемдер. Махсус өйдә кияр өчен генә бер башка төрле кием юк. Ниндәен кием булса да өйдә кияләр, вакытына карап: өй җылы булса, камзулчан өйдә утыра, суык булса, кыска вә кечкенә тун киеп казакичан утыра. Бәгъзе кешеләр бар, өйдә башмак киеп йөриләр, идәннәренә палас җәйгән булса да.

Тун һәм шулай төрле формада була: кыска тун (бил астыннан) була яки түбәнрәк, тезгә чаклы. Аннан озын, тубыкка чак-

---

[1] Әдрәс, бикасап, пустау, нанке, лачтек, саранчы, бәнарис — тукыма төрләре.

лы булса, аны кыска тун дип әйтмиләр, өч билле тун дип әйтәләр; кесәсез була, толып урынына киеп йөри торган тун; әйләнәсенә камчат яки кама тоталар, тышы пустау яки башка төрле йон материя була һәм элгәрерәк әдрәс, бикасап була торган иде, хәзер әдрәс, бикасап истигъмальдән чыгып тора бара. Ул өч билле тунны һәм казаки кебек алдан биш төймә, алты төймә белән төймәлиләр. Ул тун һәм һәркемнең хәленә күрә төлкедән яки бәрәннән була. Инде бу заманда толыпны тегәләр шалевый якалы, пустау тышлы итеп. Мөселман татарларның гадәте: азрак хәле яхшырак булса. Кием-салымы күп була, байларны әйтмәймен дә. Гомумән, татарлар кием күп булганны яраталар, киемгә күп акча сарыф кыйлалар. Кыйммәтле киемнәр була. Бәгъзе кешеләр бар — унар тун була торгандыр, һәркайсы кием икешәр була, әлбәттә. Хәтта бер кешенең егерме биш баш киеме була торгандыр, күлмәк-ыштаннан башка. Күп кеше аякка кия торган киемне күп тота: башмак икешәр-өчәр кием, кәвеш һәм шулай, читек һәм икешәр-өчәр кием була.

Күп кешенең шулай һәрбер төрле киемнән икешәр-өчәр кат була бәйрәмлек киемнәре белән. Читек астыннан күп кеше кыш көне оек башы кия яки, булмаса, киндердән чолгавы була кат-кат. Итек киючеләр бик сирәк була байлардан; итекне күбрәк түбән дәрәҗәле кешеләр кияләр. Ул татар кәвеше урыс кәвешеннән башкарак була формасы. Ул кәвешне читек өстеннән кияләр. Бәһасе төрлечә була: бер тәңкәдән өч тәңкәгә чаклы. Була күҗулдан. Читек һәм күҗулдан була. Читекнең үкчәсенә сауры куеп тегәләр, тазага килә. Кәвеш үкчәсенә һәм сауры куялар. Бистә халкыннан башала юк оекчабата кигән кеше.

Дәхи башка кия торган киемнәр һәм төрлечә була. Инде бу заманда күбрәк такыя кияләр, ука белән эшләтеп, бәһасе өч тәңкәдән йөз тәңкәгә чаклы була, һәркемнең хәленә күрә. Яхшы эшлиләр, энҗеләр, кыйммәтле ташлар утыртып. Һәм бертөрле кешеләр кәләпүш кия. Ул кәләпүш асыл Бохардан, сартлардан чыккан нәрсә. Ул кәләпүш фарсыча сүз: кәлә — баш мәгънәсендә, пүш — япмак мәгънәсендә; баш капкачы дигән кебек була. Ул кәләпүшне башка бертөрле ефәк материядән, хәтфәдән ясыйлар, әйләнәсенә ука тотып. Ефәк чуклы була түбәсендә. Аны һәм яхшы итеп эшлиләр, ул кәләпүшне әдрәстән, бикасаптан, ситсадан вә һәртөрле материядән.

Бүрекнең һәм чиге юк бәһасендә. Камчат бүрекнең яхшылары бик кыйбат була. Яхшы камчаттан тегәләр, тышына кыйммәтле хәтфә белән, эченә ефәк яки төлке затыннан яхшы нәрсә куялар. Ул камчат биш тәңкәдән ике йөз тәңкәгә чаклы була. Кияләр тагы каракүл бүрек, данадар бүрек, һәркем хәленә күрә. Ул бүрекне яланбашка кимиләр, такыя яки кәләпүш өстеннән

киялəр. Элгəрерəк башка кия торган колакчын дигəн нəрсə бар иде, инде бу заманда һичкемдə колакчын күренми.

Дəхи бəгъзе кешелəр бар, эшлəпə киялəр; лəкин бəгъзе мөселманнар вə бəгъзе мутаука ак кəлəпүш муллалар эшлəпə кигəнне яратмыйлар. Ул эшлəпə һəм төрле була: бер төрле ак эшлəпə бар — мужиклар кия, вə дəхи француз эшлəпəсе, Мəскəү эшлəпəсе бар. Лəкин ул муллалар яратмый эшлəпə кигəнне. Алар танымайлар нинди эшлəпə икəнен. Дөрес, китапларда күренə, мəҗүс эшлəпəсен кисə кяфер булыр, дигəн; ул кию харам булган эшлəпə бу эшлəпə түгел. Шул ак кəлəпүш муллалар нинди эшлəпə икəнен белмилəр. Бу эшлəпə хосусында минем байтак зур рисалəм бар. Ул муллалар эшлəпə кигəн кешене кагалар белмəенчə.

Чалбар һəм киялəр. Ул чалбар ике төрле була. Махсус татар чалбары була, урыс чалбарына башкарак; төбе бик киң була, балак очлары таррак; бу чалбарны балагын чыгарып йөреп булмый. Инде бу заманда урыс брюкасы киялəр. Балакны чыгарып йөри күп кешелəр. Моннан мөкаддəм биш-ун еллар балак чыгарып йөрү юк иде, ул чак миннəн башка балак чыгарып йөргəн кеше юк иде.

Һəртөрле халыкта булса кирəк, хатын-кыз киеме белəн ирлəр киеме бер төрле түгел. Ирлəр киеме белəн хатыннар киеме арасында күп аерма бар. Инде хатын-кыз киемнəре менə: күлмəк, ыштан, читек, башмак, кəвеш, камзул, тун, кесəбикə, яулык, шəл, бүрек, чəч тəңкə, ука изү, тəңкə изү, хəситə, яка чылбыры, алка, белəзек, йөзек; вə гайре киемнəр һəм кыз-хатында күп, əмма болары бигрəк мəшһүрлəре. Инде бу заманда хатыннар күлмəге һəрбертөрле материядəн була, һəркемнең телəвенə күрə төрле төстəн.

Əмма, гомумəн, татар мөселманнар вə аларның хатыннары яраталар бигрəк ачыграк, матуррак булганны. Бəгъзе мөселманнар бар чем-кара киемне мəкруһ күрəлəр. Инде хатыннар күлмəге бик озын була, җиргə чаклы, аякны капларлык; шəригать буенча хатыннар киеме шулай кирəк. Хатыннар күлмəгенең итəге ике кат була. Элгəре күлмəкнең итəге башка төстəн була торган иде, инде күлмəге белəн бертөсле була. Ситса булса, унике аршын яки унөч аршын ситса кирəк. Һəркемнең буена күрə. Бəгъзе хатыннарның күлмəге өчəр кат итəкле була, бигрəк купшы булса (лəкин өч кат итəкле күлмəкне бəгъзелəр яратмыйлар, күтлəк сыман була дип, чөнки трактирдагы кызларның күлмəге шулай була). Һəм ефəк күлмəк, йон күлмəк булсын, формасы бəрабəр була. Ул күлмəкнең изүлəре була укадан, яки тəңкə тезəлəр. Ул ука изүне ясыйлар пырзумиттан[1] кат-кат

---

[1] Пырзумит — дөресе: позумент.

итеп, ягъни бер рәт була сары ука, бер рәт була ак ука, янә лента; һәйбәтләп түгәрәкләп изү тирәсенә ясыйлар; яки бер кат ука була, аның янына лента, ул лента өстенә көмеш тәңкә тезәләр, янә аның янына бер кат лента тоталар. Аннан башка янә муенга кия торган нәрсә бар, яка чылбыры, диләр. Әүвәле укадан яка ясыйлар. Ул каты була, аны тамак астына китереп каптырмалыйлар. Каптырмасы була көмештән, дәхи аңар асалар: көмештән ясаган чылбыры була. Ул чылбыр башларына көмеш тәңкә тагалар, һәркем хәленә күрә; яки тәңкә булмаса, көмештән бер төрле нәрсә ясыйлар, челтәр, дип әйтәләр. Асыл хатыннарның бу украшениеләре чуваштан калган түгел микән? Чуваш хатыннарының шуның кебегрәк нәрсәләре була. Дәхи хатыннар тирәсендә бар чәч тәңкәләре, чулпы дигән нәрсә. Артка чәч буена лента өстенә яки бер тасма өстенә тәңкә тезәләр, һәркем хәленә күрә, полтинниктан була, четвертактан була, җилкәдән, пожалый, билгә чаклы. Ул тәңкәне бәгъзе баераклар алтынга маналар; ул тәңкәләрнең башына ясыйлар көмештән ахак каш утыртып: аны чулпы диләр; бөтенешәр тәңкә тагалар...

Әмма хатыннар ыштанының ирләр ыштаныннан аермасы юк. Бәгъзе хатыннар бар, күлмәк астыннан кернәлин кияләр. Ләкин кисәләр дә, мөселманнарга килешә торган түгел, һәм күп мөселманнар яратмайлар. Ул килешер иде башларына зур шәл ябынып йөрсәләр, әмма алар чапан бөркәнеп йөриләр: килешми, сыерга камыт киерткән кебек була.

Янә хатыннарның камзул дигән киемнәре бар. Ул камзулны тегәләр бик яхшы штуфтан, хәленә күрә. Баераклары штуфның бик яхшысын алалар; эченә төлке тамагы яки гайре нәрсә куялар, һәркем үзенең күңеленә охшаганча. Камзулның әйләнәсенә тоталар бик яхшы камчат, киңлеге ике бармак, өч бармак иллесе. Тагы ул камчат янына тоталар кыйммәтле ука, шулай киң була. Бәгъзе кешеләр бар, салкын эчле итеп тегәләр. Ул камзул җиңсез була, озынлыгы тезгә чаклы.

Хатыннар туны һәм төрле материядән була. Тышы, эче һәм төрле мехтан була. Формасы һәм ирләр туны кебегрәк өч билле; мәгәр китекле яка була, яки шалевый була. Якасына камчат яки кондыз куялар. Бәгъзе кешеләр бар, марҗа туны кияләр, ягъни урыс хатыннары кебек салоп итеп тектерәләр. Ләкин күп кешедә юк, бөтен Казанда җиде, сигез, ун кешедә бардыр, хатыннары салоп кияләр бик олы җиргә кунакка барганда. Янә хатыннарның кесәбикә дигән киемнәре бар, белмәймен кайдан чыккандыр, яңарак чыккан кием. Тышы әдрәс, йә бикасап, яки башка бер төрле материядән була, мамык белән сырган. Җиңе кыска була. Әйләнәсенә тиен тоталар.

Дәхи хатыннарның башка кия торган киеме була — бүрек.

Ул бүрекнең кырпуы камчат була. Түбәсен ука белән, энҗеләп, кашлар утыртып чигәләр, бик кыйммәт төшә, бәһасенең чиге юк. Дәхи бәгъзе хатыннар күп вакытны калпак кияләр, ефәк калпак була. Гадәттә фабрик эше, бәрхетле калпак диелә. Биш тәңкә, алты тәңкә була простое. Шул калпакны янә төзәтәләр энҗеләр, тапаслар белән, кыйммәт төшә. Ул калпакка ука чачак һәм ука чук тагалар, бик арзан тормый. Дәхи ул калпакны ясыйлар кыйммәтле бәрхеттән. Кыз-хатын бар — бик осталар калпак ясарга. Бик кыйммәтле калпак эшлиләр Казан кызлары, энҗе белән кыйммәтле ташлар утыртып.

Дәхи хатыннарның читеге ирләр читегеннән башка була. Ул хатыннар читеген яхшы сәхтияннән каеп тегәләр ефәк белән яки ука белән, төрле төсле сәхтияннәр кыстырып тегәләр. Гадәти читек була байларда өч тәңкәдән ун тәңкәгә чаклы; әмма һәркемнең хәленә күрә була; илле тиен көмешлек читек һәм була, мин аны әйтмәймен, моннан соңрак әйтермен. Әүвәл байлар киемен сөйләрмен.

Хатыннар күп вакытны башмак кияләр җәй көне. Ул башмакны һәм бик яхшылап ука белән энҗеләр, ташлар утыртып ясаган була. Биек үкчәле башмакның очы очлы була. Дәхи кәвеш һәм кияләр, кыйммәтле була; төрлечә эшлиләр ука белән каеп, кыйммәтле ташлар утыртып. Вә дәхи бәгъзе хатыннар бар: урыс хатыннары кия торган кәвешне, ярты итекне кияләр, һәркем үзенең теләгәненә күрә, мәслихәтенә карап.

Менә инде күреп тор, бер хатынны яки кызны киендерермен. Аның киеме кыйммәткә төшәр микән?

Менә гадәти байларның хатыны киенә кунакка барса: әүвәл кия ыштан, ситсадан була, яхшы, бер тәңкә ярым; ефәк күлмәк кия, уртача бай булса — 25 сум; күлмәк изүе тора, ким булса — 10 сум; янә артында чәч буена чәч тәңкәсе ука чугы белән — 20 сум; янә муенына кия яка чылбыры; бик аз исәпләгәндә — 15 сум; әмма яка чылбыры бу заманда ташланып бара, яки муенга энҗе чук кияләр. Янә кия хәситә дигән нәрсә, иңбашыннан китереп култык астыннан бәйли, кыйммәт төшә; бик яхшы булса, йөз тәңкә тора. Янә камзул кия, гадәти байларның 2 йөз тәңкә тора. Янә энҗеле калпак яки простой гына калпак — 10 тәңкә; бүрек булса — кыйммәтрәк. Энҗе белән төрләп ясаган колак алкасы, ким булса, 25 тәңкә, янә башына ябына шәл, арзан булса — 5 тәңкә (яки ефәк шәл — 15 тәңкә, ким булмас). Янә тун кия — атлас тун, гадәти төлке карны эчле яки корсак карны, ким булса — 50 тәңкә; аның өстеннән чапан ябына — 15 тәңкә; аягына читек гадәти 3 тәңкә генә булсын; кәвеш кисә — 2 тәңкә. Барлыгы — 481 сум 50 тиен!

# АШАУ-ЭЧҮ

Аш дигән сүз күп мәгънәдә истигъмаль кыйлына: аш бар мотлакан[1] ашый торган нәрсә мәгънәсендә; һәрни булса да ашарга ярый торган нәрсә. Мәсәлән, балчыкны аш дип әйтеп булмый, ташны аш дип әйтеп булмый. Вә дәхи аш бар, казанда вә гайре нәрсә эчендә пешкән ашый торган нәрсә; шурпалы, кирәк шурпасыз. Дәхи аш бар бер билгеле вакытта хәзерләнгән ашый торган нәрсә, урысча — обед. Вә дәхи аш бар зыяфәт вә сый мәгънәсендә: фәлән кеше ашка чакырды, ул ашка китте, диләр.

Һичничек булса да булсын, бу аш бик күптөрле буладыр. Иң кирәкле аш — икмәк, ит, шурпа. Әмма гадәти ашларның берничәсен хәтерегез өчен язаек. Менә инде баеракларда аш ни-нәрсәдән хәзерләнә: ит, май, су, тоз, дөге, ярма, он, җимеш, каз ите, үрдәк ите, тавык ите (балыктан аз хәзерлиләр), алма, йомырка, кишер, кабак вә башка нәрсәләр. Йорт ашы була, күбрәк вакыт ит, токмач, яисә ит, салма, яисә пилмән. Әгәр кунак чакырылса, зыяфәт өчен күптөрле аш хәзерләнә. Бер чибәр генә бай кеше кунаклар чакырып сыйламак булса, гадәти аш — иң әүвәл пылау китерәләр. Пылауны казанда пешерәләр. Ул пылау ике төрле була. Әйтәләр, сарт пылавы вә дәхи берсе гадәти Казан халкының пылавы. Казан халкы күбрәк бу рәвешчә хәзерли: әүвәл пешкән итне бик һәйбәтләп турый, дөгене коры суда пешереп ала; аннан соң кайнар казанга сала май, казан астында азрак эссе күмер булсын. Әмма май, сары май яхшырак, куй һәм ярый. Аннан эрегән майга тураган итне сала. Ит өстенә вак кына турап кишер, суган сала, йөзем җимеше сала, аның өстенә пешкән дөгене сала. Шулай булсын: итләр, суганнар, кишерләр бары да дөге астына кереп калсын. Аннан соң казанны каплап дәмләп куялар. Кайнар казанда пылау бер сәгать йә сәгать ярым тора. Казаннан бушатып алалар, бик яхшы аш була. Аннан соң токмач, йә салма, йә пилмән китерәләр. Әмма бу ашлар һәркемгә билгеле, бу ашлар хакында бернәрсә язмасак та белерсез.

Аннан соң бәлеш китерәләр яки гөбәдия китерәләр. Бу бәлеш һәм гөбәдия карап торырга бертөрле формада. Әмма бәлешне хәзерлиләр бөккән кебек, ләкин түгәрәк була. Әүвәл камырны җәяләр, камыр өстенә дөге салалар, чи ит турап салалар, тоз, борыч азрак салалар да шул җәелгән камыр белән төреп бөккән кебек итеп ясыйлар. Табага куеп мичтә пешерәләр. Әмма гөбәдия дигәне һәм бәлеш кебек түгәрәк буладыр. Ләкин гөбәдиягә итне турап салмайлар, чабып салалар бик

---

[1] Мотлакан — шартсыз, шиксез.

вак итеп аска, аның өстенә корт салалар, аның өстенә йомырканы пешереп, төеп салалар, май салалар. Бәлеш кебек итеп камыр белән төрәләр; зиядә хуп нигъмәт була.

Дәхи күбрәк пилмән пешерәләр зыяфәт өчен вә һәм йорт өчен. Ул пилмәнне һәркем белә ни рәвеш ясалганын; моны язарлык эш юк. Һәм токмач пешерәләр кунак өчен һәм өй өчен: гадәти аш, моны һәркем белә. Вә дәхи салма аш була, бу һәм һәркемгә билгеле. Ләкин бу салма күбрәк шәкертләр ашыдыр. Бу салма ике төрле хәзерләнә. Мәдрәсәдә шәкертләр салма пешерәләр, менә болай: вак итеп итне турап казанга салалар. Ул ит пешеп килә, камырны басып, әнәчәсен ясап, салманы уч табанында ясап, казанга салалар. Казан кайный тора, салган бер салма пешә тора. Салманы салып бетергәч, суган турап салалар, булса, кишер турап салалар, вакытына күрә. Әмма йортта хатын-кыз пешергәндә салманы бу рәвешчә пешерәләр һәм ясыйлар: әүвәл итне вак кына чабып салалар һәм кисәкләп салалар, салманы кунада ясыйлар. Бу шәкерт салмасыннан күп вак була. Янә була өйрә. Бу өйрә төрлечә, һәрбертөрле ярмадан була. Һәм дөгедән була. Әгәр тавык ите пешерсәләр, шурпасына салма салалар яки дөге өйрәсе итәләр. Ул тавык шурпасында пешкән дөге өйрәсенә сөт салсалар, тәме һәм артык була, бик яхшы була.

Вә дәхи хәзерлиләр үрдәк бөккәне. Ул үрдәк бөккәнен ясыйлар бу рәвешчә: үрдәкне бөтен хәленчә дөге эченә күмәләр, ул чи үрдәк була. Аны табага куеп мичтә пешерәләр. Әмма ул бөккәннең сыйфаты, формасы урыслар пешерә торган бөккәнгә күп башка була. Бөккәнне ике төрле итеп ясыйлар: бөккәннең тышын өстәге яктан бөгәләр, моны әйтәләр безнең Зөя округында өстәл бөккәне дип. Янә бер төрлесе бар, кыек бөккән дип әйтәләр, ул ярты түгәрәк була да яныннан бөгәләр, ул бөккәнне күп нәрсәдән пешерәләр. Кабактан пешерәләр: ул кабакны вак итеп турап, дөге белән катыштырып бөккән итеп ясыйлар, табада пешерәләр, аңар май һәм салалар, пешкәч һәм май сибеп ашыйлар; бик яхшы аш була. Кишердән һәм бу рәвешчә итеп пешерәләр, йомыркадан һәм шулай пешерәләр. Әмма балыктан бөккән пешергән кеше бик сирәктер; булса да, юк, дисәң дә ярар.

Ул бөккәннең бер төрлесе бар: вак кына була, табада пешерәләр, чәй янына китерәләр. Бу һәм төрле нәрсәдән була. Ләкин моның исеме башка була, моны сумса дип әйтәләр. Вә дәхи салкын була бер төрле аш, каз итеннән яки күркә итеннән; кыяр турап, керән белән серкә сибеп ашыйлар. Вә дәхи алма бәлеше була, алмадан пешерәләр. Бу һәм урыс пешерә торган бөккән формасы түгел.

Күбрәк алма бәлеше түгәрәк була. Шикәр сибеп пешерә-

ләр. Яхшы була. Янә хәзерлиләр паштет алма кагыннан яки җиләк кагыннан.

Янә бер төрле аш бар — как-төш дип әйтәләр. Ул как-төш дигәннәре шул: әүвәл камырны басалар йомырка белән, сөт белән, май белән катыштырып. Ул камырны вак итеп әнәчә ясыйлар. Аны пычак белән вак итеп кисәләр, эрбет чикләвегеннән артык зур булмый, аны казанда кайнаган майга салып алалар. Май эчендә пешкәч, бик яхшы була; моны бавырсак дип әйтәләр. Шул бавырсакны бер подноска өеп катыралар бал белән, өстенә конфет сибәләр; бик яхшы нәрсә була. Аны чәй янына куялар. Вә дәхи кош теле дигән аш һәм шул рәвеш пешерәләр. Ләкин аны әүвәл токмач камыры кебек басалар, кыек кисәләр, май эчендә пешерәләр һәм чәй янына китерәләр.

Вә дәхи була бутка һәркемгә мәгълүм. Әмма бутка — сала халкының иң олуг ашы. Моның бәяны (үз) урынында — түбәндә килер.

## ЙОЛАЛАР

Мөселман җәмәгате арасында берничә төрле гадәтләр бар: мәсәлән, бала тугач ат кушмак, баланы бишеккә салмак, баланы сөннәткә утыртмак, үсеп буйга җиткәч, өйләнмәк, вафат булгач, дәфен кыйлмак. Болар барчасы һәр кешенең башына килә торган эшләр. Мин монда шул мәзкүр хосуслардагы гадәтнең берничәсен язармын.

### Бала тумак

Инде бала туар вакыт җиткәч, бер карчык китерәләр. Аны кендек әбисе диләр. Ул әбинең ярдәме белән ул бала туа. Ләкин җанлы булып сәламәт туса — яхшы, әмма кайчагында бала җансыз булып туа икән. Инде бу хосуста наданрак мөселманнар арасында бер төрле эш бар: мәсәлән, бала җансыз туса, баланың кендеген кисмәс борын, таба кагалар икән; таба каккач, баланың җаны кайтып керә, имеш, диләр. Мин бу ел бер карчыктан ишеткәнем бар, ул карчык сөйләде: «Фәлән кешенең җәмәгате җансыз бала китерде. Әлхәм укып, кендеген «саудык» таба кагып, балага җан керде, бала терелде»,— диде. Ничек булса да, бала сәламәт тугач, баланы бал-май белән авызландыралар. Биләүгә салалар. Туган көнне үк балага ат кушмыйлар, берничә көннән соң кушалар.

### Балага ат кушмак

Инде ат кушмак вә ат кушкандагы гадәтләр монда язылыр. Урта гына хәлле кешеләр, бала тугач, берничә көннән соң балага ат кушмак өчен аш хәзерлиләр: бер көнне билгеләп,

тиешле муллаларны вә карендәшләрне вә һәм тиешле кешеләрне, күршеләрне, мәхәлләнең чибәррәк кешеләрен чакыралар. Бу ашны бәби ашы яки бәби мае дип әйтәләр. Шул мәҗлескә тәмам халык җыелып җиткәч, баланы, бер мендәр өстенә салып, мулла алдына китереп куялар. Мулла сорый, ни атлы кушаек, дип. Балага исем биргәндә, атасы-анасы үзләре кайсы исемне ихтыяр кыйлса, шул исем белән мулла ат куша. Бәгъзе кешеләр мулланың үзенә тапшыралар, мулла үзе теләгән исемне куша. Инде бу заманда күбрәк кеше исемнәре гарәпчә була. Моннан соң мулла, баланың аякларын кыйблага таба куеп вә һәм баланың баш очында аягүрә торып, баланың уң ягында азан әйтә вә һәм сул ягында торып камәт[1] әйтә, аннан соң баланың йөзенә иелеп, кычкырыбрак әйтә «исме шәрифең[2] фәлән булсын» дип, өч мәртәбә. Моннан соң фатыйха укып, дога кыйлып, баланы аннан алып китәләр. Аннан соң бал-май китерәләр. Һәркем мәҗлестәге кеше үзе теләгәнчә бал-майдан кабып, һәркем хәле кадәренчә акча салалар. Анда байтак акча җыела, мәҗлесенә күрә. Моннан соң берәм-берәм аш китерәләр, зикер ителгән гадәти ашлар. Бу мәҗлес шулай тәмам була. Хатын-кыз җәмәгатенә һәм бу мәҗлесне ясыйлар; ләкин хатын-кыз бәби маена баралар, күбесе акча алып бармый. Башка зат-маттан, мәсәлән, ситсадан, яулыктан.

## Бишек туе

Моннан соң, балага ат кушкач, баланы бишеккә салалар. Әүвәл мәртәбә баланы бишеккә салганда бер мәҗлес буладыр — хатыннар мәҗлесе. Моны бишек туе дип әйтәләр. Бу мәҗлескә хатыннар җыела. Һәркайсы хатын хәле кадәренчә акчадан яки гайре заттан бүләк алып киләләр. Байларда бу бишек туе бик зур буладыр.

## Гакыйка[3] корбаны

Вә дәхи шәригатьтә сөннәт булган бер гадәт бар: бала тугач, җиде көннән соң бер корбан чалалар. Моны гакыйка корбаны дип әйтәләр. Ул корбанның тиресен садака бирәләр; итен һәм яртысын садака бирәләр тиешле кешеләргә һәм әбигә. Ул корбанның сөякләрен бер дә ватмыйлар, җекләреннән генә кисәләр. Корбанның бер ботын кендек әбисенә бирмәк кирәк,

---

[1] Камәт — намаз алдыннан аягүрә укыла торган дога.
[2] Исме шәрифең — кадерле, хөрмәтле исемең.
[3] Гакыйка — яңа туган балага чыга башлаган чәч, төк.

калганын садака бирмәк кирәк. Әмма ул гакыйка корбаны ир бала өчен ике куй, кыз бала өчен бер куй чалмак тиеш. Урта гына хәлле кешеләр бу корбанны чалалар, калдырмайлар. Вә дәхи, бала тугач, берничә көннән соң баланың чәчен китәреп, шул чәч авырлыгы алтын яки көмеш садака бирәләр.

## Сөннәткә утыртмак

Вә дәхи кайсы кеше, бала тугач, җиденче көндә сөннәткә утырталар. Әмма шәригатьтә җиденче көннән егерме яшенә чаклы мөмкин, мөстәхәб[1]. Әмма бу сөннәткә утыртмак гамәлен кыйлырга һәркем ярамый. Бу сөннәткә утыртучыны баба дип әйтәләр. Аңа бабалык атадан-бабадан кала килгән булмак кирәк, нәсел буенча. Бу Казан тирәсендәге авыллардан бабалар була. Кошман авылыннан, Зөя округы, яки Масра авылыннан, Казан округы бугай. Баба кисә, кечкенә баланы алдына утыртып. Баланың күзен каплый. Бала егъласа, аны көйләп әйтә: «Егълама, егълама, углым, менә сиңа кызыл ыштан бирәм, тукта, сиңа ыштан үлчим»,— дип, ул арада гамәлен кыйла.

## Кыз яучылатмак

Вә дәхи кеше үсеп буйга җиткәч, өйләнмәктә вә һәм кыз бирмәктә байтак гадәтләр бар. Әмма монда туй хосусында вә кыз бирмәк хосусында булган сүзләр бистә халкының гадәтедер. Авыл халкының гадәте дәхи түбәнрәк язылыр. Инде кызны яучылатмак бу рәвешчә булыр: бәгъзе өйләнмәгән яшь егетләр бар, өйләнәселәре килсә, күбрәк мәсҗеткә намазга йөри башлыйлар. Мин үзем мәдрәсәдә торган чакта ничә мәртәбә сизгәнем бар иде, үземнең иптәшләрем белән сөйләшә торган идек: «Фәлән егет намазга йөри башлаган, ахры, өйләнәсе килә торгандыр»,— дип; һәм дәрвакый[2], берничә көннән шул егетнең өйләнгәнен ишетә торган идек. Инде кыз-хатын арасында бертөрле карчыклар бар — яучы карчыклар; кемдә кыз бар, кемдә өйләнәсе егет бар, һәркайсының өйләренә кереп иснәнеп йөри: кемгә кыз кирәк, кемнең кыз бирәсе килә. Әгәр берәүнең өйләнергә нияте барын сизсә, кызлы кешегә барып, бик кечкенә генә сүз сала. Әгәр бирергә ниятләре барын сизсә, янә шул өйләнәсе егеткә барып җитештерә, егетнең атасына-анасына, яки гайре башка карендәшләренә, яки егетнең үзенә. Аннан соң егетнең атасы шул кызның атасына яучы җибәрә кызын

---

[1] Мөстәхәб — гүзәл, яхшы табылган эш.
[2] Дәрвакый — чынлап та, дөрестән дә.

сорап. Әмма күбрәк кызның атасы-анасы яучыны егетнең атасына җибәрә ишарәт белән аңлатып, әгәр кызымны сорасалар, бирер идем, дип. Әмма һәрбер кеше болай түгел.

Бистә халкы арасында, егетнең тәүфыйгы вә һәм һөнәре яхшы күренсә, мондый егеткә һәркем үзенең кызын бирәсе килеп тора. Инде баягы сүзгә килсәк, хасыйле кәлям[1], яучы дигәннәре ике өйнең арасында байтак көннәр йөреп ике коданы килештерәдер, мөмкин кадәр берсен-берсенә мактап. Аннан соң кызны вәгъдәләшеп, берничә микъдар мәһәр салып, кызны килешкәч, колак сөенчесе бирәләр, вә һәм туй шартларын шунда сөйләшәләр, ягъни мәһәр күпме, бирнә күпме, егет ягыннан кызга ниләр биреләсе, кыз ягыннан егеткә ниләр биреләсе, вә һәм егет ягындагы кардәшләргә, кем-кемгә бирнә буласы, һәммәсен шунда тәгаен кыйлалар.

Аннан соң бер кечкенә генә мәҗлес ясап вә һәм имамны чакырып иҗабы кабул[2] итәләр. Әмма бу никях мәҗлесе түгел, моны иҗаб кабул мәҗлесе дип әйтәләр, никях мәҗлесеннән элгәре була. Бу иҗаб кабул мәҗлесеннән соң туй мәҗлесенә чаклы туйга хәзерләнеп берничә көн уза. Туйның кирәгенярагын хәзерләп булгач, туй буласы көннең алдыннан бер көн мөкаддәм өндәү чыгаралар яки записка тараталар. Ул записканы баскан була яки язалар бәгъзе кешеләр үзләре. Ул записканың мәзмуны шул, мәсәлән: «Фәлән-фәлән углы үтенә фәләненче числода, фәләненче сәгатьтә никях мәҗлесенә рәхим итәсез...» Югарыда әйттек иҗаб кабул, дип; аның мәгънәсе шул: мәсәлән, имам сорый кызның атасыннан: «Син, фәлән, үзеңнең кызыңны фәлән-фәлән углына хатынлыкка бирдеңме?» Ул әйтә: «Бирдем». Дәхи егетнең атасына әйтә имам: «Син, фәлән, үзеңнең углыңа фәләннең кызын алдыңмы?» Ул әйтә: «Алдым». Аннан соң — фатыйха. Моның тәфсиле никях мәҗлесен бәян кыйлганда килер.

Аннан соң, бу иҗаб кабул мәҗлесе үткәч, берничә көннән туй мәҗлесе буладыр. Туй булмастан борын егет өендә бер мәҗлес буладыр, хатыннар мәҗлесе. Ул мәҗлескә хатыннар җыелалар, кызга биреләсе бүләкләрне карыйлар. Бик зур зыяфәт була. Һәрбер хатын үзенең хәленә күрә ул мәҗлескә бер зат яки акча алып киләдер; кызга биреләсе күлмәкне котлап салалар ситсадан, ефәк затыннан, акчадан. Бу мәҗлестә җыелган нәрсәләр һәммәсе кызга китә. Аннан соң, бу мәҗлесләр узгач, туй мәҗлесе буладыр.

---

[1] Хасыйле кәлям — сүзнең кыскасы, нәтиҗәсе, кыска итеп әйткәндә.
[2] Иҗабы кабул — өйләнүчеләрнең үзара ризалыклары.

## Туй мәҗлесе

Инде бу никях мәҗлесе буласы көн кыз өендә бик зур мәҗлес була, ягъни зур никях мәҗлесе кыз атасының өендә була. Никяхны һәм кыз өендә укыйлар. Бу туй буласы көн егет өендә һәм мәҗлес була. Никях буласы көн туй алдыннан бераз элгәре егет өеннән кыз өенә берничә төрле нәрсәләр җибәрелә. Егет өендә һәм кичерәк хатыннар мәҗлесе була. Кызга нәрсә җибәргән төштә хатыннар булырга тиеш. Бу көнне кызга җибәрәләр бүләк һәм мәһәргә хисап бер яхшы сандык, яхшы зур көзге, яхшы штуф яки хәтфә, берничә күлмәклек ефәк материя, берничә күлмәклек ситса, шәл, яхшы калпак, читек, башмак вә һәм разный фрукта вә һәм бүләкләр өчен йөзекләр, пәкеләр, вак көзгеләр вә һәм иннек-кершән, вә һәм мәһәргә тәгаен кыйлынган акчаны шул сандыкка салып бикләп җибәрәләр. Вә дәхи җибәрәләр берничә первый сорт күмәч, ярты пот бал, ярты пот май, һәм артыграк һәм кимерәк, һәркемнең хәленә күрә һәм мәҗлесенә күрә.

Инде егет өендә туйга барырга дип дәхи берничә кешеләр җыела. Мәҗлес була. Егет ягыннан кода булып баралар кыз өенә; һәм бу туйга барасы кодаларга егет өендә берәр төрле аш була. Ул менә бу рәвешчә була: кыз өенә туйга барасылар әүвәле егет өенә җыела, байтак була, мәҗлесенә күрә. Кыз өендә һәм егет өендә халык җыелып җиткәч, егет өеннән барасы кодаларны алмага кыз ягыннан атлар килә. Кодаларны алмага килгәч, берничә төрле ашны тәнавел кыйлып[1] дога кыйлып, китәләр шул атларга утырып кыз өенә. Кайсы кеше һәм үз аты белән бара. Кыз өенә никях мәҗлесенә баралар. Кыз өенә барган кодалар, кечерәк кенә туй булса да, ун-унбиш ат була.

Моннан барган кодаларны кыз өенә кабул итәләр: «Хуш киләсез, кодалар!» — дип каршы чыгып торалар. Хәзерләнгән урыннарның яхшырагына егет ягыннан килгән кодаларны утырталар. Халык җыелып тәмам урнашып беткәч, бер догаи фатыйха кыйлалар. Урта гына хәлле кешеләрнең туйларында ун табын, унбиш табын кеше була. Муллаларны вә голяма җәмәгатен үз алдына бер табын итеп утырталар. Әмма кияүнең атасы яки вәлие[2] шул муллалар табынында була. Кияүнең атасын һәм кызның атасын төп кода дип әйтәләр. Шул ике кода муллалар табынында була. Моннан соң мулла кызның атасын яки вәлиен чакырып сорый: аның кызы ничә яшьтә, ни исемле, мәһәр күпме, кызы ризамы, һәм шәригатьчә шулай кирәк. Мулла шә-

---

[1] Тәнавел кыйлып — авыз итеп, татып карау.
[2] Вәлие — вәкиле.

ригатьчә бу хосуста кызның атасын яки вәлиен җибәрә кыз катына, ике кеше гуаһ[1] кушып, кыздан ризалык сорарга. Шул ике гуаһ белән кызның атасы сорый кызыннан, әйтә кызына: «Кызым, сине фәлән кешегә бирәм, син ризадыр?» Кызы җавап бирә: «Риза». Ул ике гуаһ ишетеп тора (шәригатьчә шулай тиеш һәм шулай итәләр). Әмма мәһәрнең билгеле хисабы юк, һәркемнең хәле кадәренчә. Мәһәр салынадыр йөз тәңкә, ике йөз тәңкә, өч йөз тәңкә һәм моннан артык та була, хәтта биш меңгә чаклы, һәркемнең хәленә күрә. Мулла, бу эшләрне сорашып бетергәч, никях укый, кычкырып, гарәпчә гыйбадәт белән. Бу никях хөтбәсе төрлечә була. Бу никях мәҗлесендә кияү буласы кеше булмый. Әгәр карт кеше булса, никях мәҗлесенә үзе бара, гаеп итмиләр. Яшь кияүләргә ул мәҗлескә бармак килешми гадәттә, әмма шәригатьтә дөрес, теләсә үзе бара, теләсә берәүне вәкил итеп җибәрә. Хәтта бәгъзе яшь кияүләр була — туй мәҗлесенә килү түгел, мәҗлескә җыелган кодаларга вә халык күзенә күренми. Мулла никяхны тәмам кыйлгач әйтә ата булып утырган кешегә, ягъни кызның атасына, кызның вәлиенә: «Сез кем, фәлән, үзеңнең солбия[2] кызың тарафыннан вәли (вәкил) булып үзеңнең солбия кызыңны йөз тәңкә мәһәр тәкабеленә[3] фәлән углы фәләнгә хатынлыкка вә һәм хәлял җефетлеккә кабул итеп гадел гуаһлар алдында бирдеңме?» — «Бирдем». Янә мулла кияү тарафыннан ата булып утырган кешегә әйтә: «Сез кем, фәлән, үзеңнең углың тарафыннан вәли булып фәлән кызы фәләнне хатынлыкка вә һәм хәлял җефетлеккә кабул итеп, йөз тәңкә мәһәр тәкабеленә гадел гуаһлар алдында алдыңмы?» — «Алдым». Аннан соң барча халык «амин» дип кул күтәреп дога кыйла.

Кияү ягыннан ата булып утырган кешегә бу мәҗлестә бер мендәр бирәләр штуфтан, яки бер гайре төрле кыйбатлы материядән, яки яхшы ситсадан, мамыктан. Әмма бу никях мәҗлесендә ата булып утырырга кызның һәм кияүнең атасы булырга тиеш, әгәр исән булсалар. Инде әгәр аталары булмаса, ага-энесе ата булып утыра, хәтта кияү буласы егет үзенең атасы яки ага-энесе булмаса, вәкиллекне кемгә тапшырса да ярый; хәтта атасы сәламәт булса да, ят кешегә вәкиллек бирсә дә ярый. Әмма кыз бу никях мәҗлесенә килмәк юктыр һич — хәтта бу заман гадәтендә гаеп эштер. Бу туй мәҗлесендә туй ашы унунбиш төрле аш була. Әүвәле бал-май китерәләр, аннан соң гадәти ашларны берсе артыннан берсен китерә башлыйлар: пылау, гөбәдия, бәлеш, бөккән яки пилмән, үрдәк бөккәне (әмма

---

[1] Гуаһ — танык, шаһит.
[2] Солбия — үз кызы, үги түгел.
[3] Тәкабеленә — башма-баш бәрабәренә.

туй мәҗлесендә бөккән төбен кисмәк юк, хәтта гаеп итәләр), җәй көне булса, балык жаркое, күркә ите яки каз ите, паштет, алма бәлеше, кесәл вә һәртөрле җиләк-җимеш. Бу ашны тәмам халык алдына китереп бетергәч, бер подноска зур стакан белән куеп ширбәт китерәләр. Мәҗлестәге кешеләр ул ширбәттән бераз тәнавел кыйлып, һәркем хәле кадәренчә бераз котлап, подноска акча салып җибәрә. Әмма муллалар вә голяма җәмәгате акча салмак юк. Бу мәҗлестә муллаларга, голяма җәмәгатенә, фәкыйрь-фөкарәгә һәр ике яктан акча өләшәләр. Аннан соң бу туй мәҗлесе тәмам булып, килгән кешеләр, Алла риза булсын, дип китә, мондагылар, хуш, дип озатып калалар. Бу шулай тәмам була. Әмма байларда бу туй өч көнгә чаклы була. Икенче, өченче көндә сыйга дип чакыралар. Бу соңгы ике көндә зыяфәт артыграк була. Мөмкин кадәре тәкәллеф белән зыяфәт хәзерлиләр, аслан бәян итмәк мөмкин түгел, вә һәм була чәй. Бу соңгы ике көндә ул мәҗлестә төп кода һәм бик хас кешеләр, якын карендәшләр була. Инде бу заманда бар бәгъзе кешеләр туй өчен эчемлектән, сырадан алып куя. Охотасы бар кешегә бер кечкенә бүлмәдә буфет була. Әмма мәҗлескә эчемлек китермәк юктыр, хәтта гаептер.

## Бүләк багу

Бу туйдан соң һәм туй мәҗлесләре тәмам булгач, кияү кыз катына бармас борын, кыз өендә дәхи хатыннар мәҗлесе була. Моны бүләк багу мәҗлесе диләр. Һәм бу мәҗлескә өндәгәндә, хатыннарны шулай дип чакыралар, бүләк багарга дип; вә һәм анда бик зур зыяфәт була. Бу мәҗлескә җыелып хатыннар кызга кияү ягыннан килгән нәрсәләрне карыйлар. Һәрбер хатыннар, хәлләренә күрә, котлап бер нәрсә салалар, бүләк: күлмәклек ситса, материя, әдрәс вә һәм акча вә гайре заттан. Бу мәҗлесләр барчасы тәмам булгач, кияү кыз куенына керә. Бу бүләк багу мәҗлесендә җыелган акча, зат кызга була.

## Кыз куенына кермәк

Бу мәҗлесләр барчасы тәмам булганнан соң, кияү кыз куенына керәдер. Кыз куенына керә дигән сүзнең мәгънәсе шул: мөселман татарларының гадәтенчә, кияү булган кеше кыз катына бара, кызның өенә. Никях булгач, кызны егет үзенең өенә алып килә торган гадәт юк. Кияү әүвәлге мәртәбә күрүендә кызны, кыз белән күрешәләр кызның атасы өендә. Хәтта ничә заман егет кыз катына барып-килеп, кунак булып йөри. Моннан соң кыз катына барасы булгач, бер кичне тәгаен кый-

лып, кияү хәзерләнә башлый кыз куенына керергә. Егет үзенең яхшы киемнәрен киеп яки бөтенләй баштанаяк яңа кием тектереп кия. Такыя, казаки, чикмән, тун, читек, кәвеш — бары да яңа, бүрек яңа. Әмма гадәттә кияүләр кыз катына баралар әүвәле мәртәбә кече җомга кич яки дүшәмбе кич.

Кичләрдән бер кичне билгеләп, фәлән кич кияү рәхим итсен, дип, кыз тарафыннан егеткә өндәүче килә. Егет кыз катына киткән җиргә егетнең дус-ише, агай-энесе җыелалар, кияүне кыз куенына озатып җибәрергә. Кияүне яхшылап киендереп, озатып җибәрәләр. Ләкин кияү үзенең өеннән үзенең аты белән бармый. Кыз ягыннан килеп алалар кияүне бик зур тәкәллефләр белән, пар ат белән, һәйбәт экипажлар белән, ике ягында ике фонарь. Гадәтенчә, кыз куенына кич баралар, караңгы төшкәч, һәм кыз ягыннан яучы хатын килә кияүне алмага. Аннан соң кияү яучы хатын белән кыз катына бара. Күп кешеләрдә шулай була. Егет үз алдына арбага утырып бара, яучы хатын янә үз алдына утырып бара. Егет белән яучы хатын кыз өенә барып җиткәч, яучы хатын егетне кыз тора торган һәм кияү кертмәк өчен хәзерләнгән бүлмәгә алып керә.

## Кияү кертмәк

Инде бу кыз тарафында бик нәфис итеп кияүне кунак итәр өчен бер бүлмәне хәзерлиләр. Ул бүлмәгә кияү урыны ясыйлар: караватка ике кат түшәк җәяләр, мамык түшәк була, ефәк юрган вә һәм ефәк материядән яки нәфис ситсадан ул караватка чаршау. Ул кияү керәсе кичне ул бүлмәне бик нәфис итеп җыялар, һәрбер өстәлгә көмеш шәмдәлләр белән икешәр шәм яндырып куялар, өйне җыен һәйбәт нәфис хуш ис белән исләндерәләр. Шулкадәр өйне нәфис итеп җыялар, кисәктен барып керсәң, оҗмах микән, диерсең. Аннан соң, шулай хәзерләнеп беткәч, егеткә өндәү җибәрәләр: бу кичкә кияү рәхим итсен кыз катына, дип, вә һәм шул кияү керәсе кичне кызны һәм бик нәфис киемнәр киендереп, хуш исләндереп, шул караватка җәйгән түшәк янына утыртып куялар; һаман кияүне көтеп тора. Ул кызның өстенә кигән киемнәре баягы киемнәр фасылында язылган гадәти киемнәрдер, һәркемнең кыз-хатын киеме хәленә күрә була.

Аннан соң, кич булгач, кияүне алмага җибәрәләр, баягы әйткән кебек, яучы хатын белән. Шул кияү өчен хәзерләнгән кыз бүлмәсенең ишеге төбендә бер-ике бала тора. Бу балалар монда тормакны ишек бавы басмак дип әйтәләр. Әмма кияү булып килгән егет ул балаларга акча бирә, хәленә күрә. Ул кияү яучы хатын белән анда керә. Егет анда кергәч, өстен-

башын чишенә дә кыз белән күрешә яки кияүне кыз чишендерә, күрешкәннән соң. Кияү белән кыз күрешә дә, кызның кулына акча сала, хәле һәм дәүләте кадәренчә; моны күренеш диерләр. Ул бирелгән акчаны яки затны күренеш акчасы диерләр. Кияү белән кызны күрештергәч, яучы хатын аннан чыгып китә.

Аннан соң кияү белән кызга аш китерәләр. Кияү белән кыз әүвәле бергә утырып ашыйлар. Анда икесеннән башка кеше булмый. Иң әүвәле бал-май китерәләр, кияү белән кыз шул бал-майдан тәнавел кыйлалар. Аннан соң кияү бал-май табагына акча салып җибәрә; моны бал-май акчасы диерләр. Аннан соң ашны ашап, чәй эчеп булгач, кияү белән кыз, бераз утыралармы-юкмы, ятырга хәзерләнәләр. Кыз кияүне әүвәле чишендереп бетергәч, аннан үзе чишенә башлый. Тәмам чишенеп беткәч, караватка менеп яталар, йоклыйлар...

Аннан соң иртә белән кияү өчен мунча ягалар. Кияү, дәхи иртә белән урыныннан торып, кыз белән мунчага китә. Мунчага киткәндә түшәккә янә акча салып китә; моны түшәк акчасы дип әйтәләр. Ул акча түшәкне җәючеләргә була. Янә кияү белән кыз мунчага киткәч, кыз бүлмәсен җыештырып, түшәкне төзәтеп, яңадан җәеп куялар. Янә кияү мунчадан чыкканда мунчага акча калдырып чыга; моны мунча акчасы дип әйтәләр. Бу акча мунча ягучыга була. Кияү, шул рәвешчә, кыз катына әүвәле мәртәбә кергәндә дүрт кич куна тоташ. Аннан соң, дүрт кич кунып бишенче кичтә үзенең өенә атасы-анасы янына кайтып күрешеп, янә кыз катына китә.

Кайчан кияү кыз катында дүрт кич йоклап атасына-анасына күрешергә кайтканда, кыз катыннан алып кайта әүвәле үзенә бүләк: яхшы такыя, сәгать, яхшы чикмән, күлмәк-ыштан, аякчулар яхшы бүздән чигеп ясаган. Бу нәрсәләрне тәмам баштанаяк киенеп кайта. Вә дәхи кияүнең ата-анасына һәм агай-энесенә, кардәшләренә бирнә; бу бирнә дигәннәре кыз ягыннан бирелә торган бүләктер. Ул кыз ягыннан бирелә торган нәрсәләр барчасы күлмәк була: хатын-кызга булса, яхшы ситсадан яки ефәк материядән, ирләргә һәм күлмәк яхшы бүздән, ситсадан, полотнодан вә дәхи карчыграк хатыннарга өрпәк бирәләр. Вә һәм кияү кыз катыннан как-төш алып кайта, кыз ягыннан как-төш ясап җибәрәләр. Как-төш дигәннәре шулдыр: миндаль төшен шикәр белән, бал белән катырып, бер подноска ясыйлар, байтак зур була; аның өстенә төрле конфет сибәләр, аның өстенә как җәеп, бер подноска куеп җибәрәләр. Әмма кайсы уртарак хәлле кешеләр бу как-төшне ясыйлар, камырдан: бавырсак итеп ясыйлар әүвәле, аннан соң аны подноска өеп бал белән катыралар һәм баягы рәвешчә өстенә конфет сибеп, как белән ябып яки какны үзалдына бер подноска куеп җибәрәләр.

## Как-төш мәҗлесе

Кияү, кыз катына кереп чыккач, үзенең дус-ишен, күрше-коланын җыеп, вә мәхәллә халкын җыеп, һәм муллаларны җыеп, бер мәҗлес ясый. Ул мәҗлестә һәм күп гадәти ашлар була. Бу мәҗлесне как-төш мәҗлесе дип әйтәләр. Тәмам ашны биреп бетергәч, иң соңыннан как-төшне китерәләр бөтене белән. Ул мәҗлескә как-төшне китергәч, бер фатыйха кыйлалар. Аннан соң ул как-төшне мәхәлләнең мөәзине ватып, мәҗлестәге халыкка өләшә, тәлинкәгә салып һәркем алдына куя. Әмма гадәттә бу как-төш мәҗлесендә акча салмак юк. Ләкин бәгъзе мулла җәмәгате өйләнеп, как-төш мәҗлесе ясаса, ригая кыйлып акча салалар, һәркем хәленә күрә.

Бая һәм әйткән идек, кияү кыз катыннан бик яхшы такыя, күлмәк-ыштан, чикмән, сәгать алып кайта — кыз бүләге. Элгәре ул күлмәкнең якасын ука белән чигеп ясыйлар иде, инде бу заманда ташланган. Ул такыя һич булмаганда унбиш-егерме тәңкәлек була, сәгать егерме биш тәңкәлек, һәркемнең хәленә күрә...*

## Килен төшермәк

Кияү, кыз катында тоташ дүрт кич йоклап чыкканнан соң, кыз катына кич-кич кенә барып йөри. Аннан соң кече атна кич барып йөри. Аннан соң атнадан атнага кала. Хәтта шулай итеп бәгъзе кияүләр дүрт-биш ел кияүләп йөриләр. Кияү кызны кайчагында үзенең өенә алып килә, янә атасының өенә илтеп куя. Ни әйтсәк тә, бу шәһәрдә кияү кадерле була. Аннан соң, байтак кияүләп йөргәч, кияү кызны үзенең өенә бөтенләй алып килә, урын-җире белән. Моны килен төшерү диләр.

Бу вакытта һәм егет өендә килен төшергән җиргә дип мәҗлес ясыйлар — хатыннар мәҗлесе. Килен төшергәндә кыз артыннан байтак нәрсәләр килә; гадәттә әүвәле кияүнең үзенең кызга биргән көзге, сандык, янә ул сандыктан башка ничә сандык кызның нәрсәләре була: мамык түшәк, мамык ястык, дүрт муен мендәре, тышлары яхшы ситсадан яки ефәк материядән. Вә дәхи яхшы ситса юрган яки ефәк юрган, вә дәхи чыбылдык, чаршау яхшы ситсадан яки ефәктән, вә дәхи кызның үзенә тиешле затлар, вә дәхи самовар, ике комган, җиз ләгән, зур ике поднос, ике дюжина чынаяк, ике дюжина бал кашыгы көмештән, ике дюжина чәнечке-пычак, ничә дюжина аш әсбабы, ике җиз поднос самовар астына, ничә дюжина салфетка, берничә эскәтер, берничә сөлге. Кыз үзенә тиешле нәрсәләрне атасының өендә бер дә калдырмай, шуның өчен әйткәннәр «киткән кыздан пумала курка» дип.

* Монда кулъязманың берничә юлы төпләгәндә киселеп төшкән.

## Үлек күммәк

Кеше авырый. Мөмкин булган чаклы аңар дару-дәрман итәләр. Авыруның сәбәбе бик күп, һәм төрле авырулар бар. Бер кешегә авыру тисә, ул авырудан терелер өчен бер файдалы нәрсә эзли, мөмкин кадәре йорттагы дарулардан һәркайсысын кыйлып карый. Кешедән ишеткән имнәрне итә. Бу йорт дарулары файда бирмәсә, докторларга һәм бара — җан кадерле, үләсе килми.

Гөмбә авыруына юкә чәчәге эчәләр, шалфи эчәләр, балан кагы эчәләр, куак гөмбәсе кайнатып эчәләр, авылларда кура җиләк эчәләр. Ютәл зәхмәтенә күп кеше нашатырь ашый, ачуташ ялый. Бизгәк зәхмәтенә әрем эчәләр, аю-бүре тиресе белән бөркиләр, куенына елан кабыгы салалар; болардан бизгәк курка икән. Авыруның хәле бик авырайса, бик саташса — өшкертәләр; җиде азан әйтеп яки Коръән белән өшкертәләр. Бу дарулар, бу өшкертүләр файда бирмәсә, әҗәле белән вафат булып китә; үлемнән калмак юк.

Үләр хәленә җиткәч, мулланы чакырталар. Мулла авыруның өстенә «Ясин» укый, тәүбә иттерә, васыятең бармы, дип сорый. Җаны чыккан вакытка чаклы теле белән үлсә, васыятен әйтә. Үлгән чагында балалары, кардәш-ырулары җыела, «үлә-үлә» дип карап торалар егълашып. Ул үлгән вакытта мулла булса да, яки галимрәк башка бер кеше булса да, бу авыруның җаны чыкканчы өстендә карап, тәлкыйн әйтеп[1] авызына су салып торалар. Тәлкыйн шулдыр, авыру өстендә бу сүзләрне әйтеп тора: «Аллаһ, Аллаһ» вә дәхи «Лә илаһе иллаллаһ Мөхәммәдерәсүлуллаһ» вә дәхи «әшһәде ән лә илаһә иллаллаһе вә әшһәде әннә. Мөхәммәден габдеһевә Рәсүлеһе» вә дәхи «Аллаһе әхәде вә Рәсүлеһе Мөхәммәд»[2] вә һәм үлем хәлендә булып ятканда авыру кеше бу сүзләрне теле белән, теле булмаса, күңеле белән әйтә. Шулай үлем сырхавы тигән булса, үлеп китә; «үлде» дип егълашалар.

Аннан соң мәетне аякларын кыйблага таба сузып салалар, күмәргә хәстәрен күрә башлыйлар. Кабер казырга җибәрәләр. Ул каберне казыйлар кеше буе тирәнлеге, кабернең кыйблага таба ягын ләхет итеп алалар. Аннан соң, кабер казып булгач, мәетне юалар. Мәетне мөәзин юа күбрәк вакыт һәм баерак булса. Мәетне кабыкка салып юалар; аякларын кыйблага таба салалар, бер кеше су салып тора. Хатын кешене хатыннар юа. Аннан соң, юып бетергәч, кәфенгә салалар. Ирләргә өч кат кәфен, хатыннарга дүрт кат. Мәетне кәфенгә салып төрәләр.

---

[1] Тәлкыйн әйтеп — иман әйтеп.
[2] Ислам диненең иман сүзләре.

Башыннан, аягыннан кәфенне җыеп бәйлиләр. Ләхеткә куйгач, бәйләгәнен чишәләр. Аннан соң мәетне салып зиярәткә алып барырга ясала агачлардан бәйләп. Аның өстенә кабык куялар. Шул кабык өстенә мәетне салалар. Зиярәткә ун кеше күтәреп бара. Мәетне өйдән чыгарганда мулла килә, мөәзин килә. Мәетне өйдән алып чыкканда, мулла Коръән укый, азрак үзе теләгән җирдән. Әгәр мәетнең фидиясе[1] булса, шунда фидиягә дәвер итәләр[2]. Һәрбер үлгән кешегә фидия лазем, әгәр байлыгы булса, казага калган намазы, казага калган рузасы[3] юлынмак өчен.

Дәвер итмәк дигәнебез ошбу рәвешчәдер. Аннан соң мәетне алып чыгып, җеназага салалар. Ун кеше күтәреп китәләр җеназа укыласы җиргә. Мәетне мәсҗеткә кертмәсләр, мәсҗет ишеге алдында йә бер башка җирдә җеназа укыйлар. Җеназа укыласы җиргә мәетне куялар кыйблага уң ягы белән, мулла тора мәетнең күкрәге тугырысында. Ул җеназа намазы башка намаз кебек түгел, рөкуг[4], сәҗдә[5] юк, аягүрә дүрт тәкбир белән тәмам була. Ул намазда салават әйтәләр, янә бер догасы бар, аны укыйлар. Аннан соң зиярәткә барып җиткәч, мәетне ләхеткә куялар. Мәетне ләхеткә куярга мөәзин төшә, дәхи бер якын карендәше төшә, кирәк булса, янә берәү төшә. Аннан соң мәетне кабык өстеннән алып, ләхеткә төшереп куялар. Аннан соң ләхетнең авызын кирпеч белән яки такта белән каплап, туфрак белән күмәләр. Тәмам мәетне күмеп бетергәч, мулла мәетнең каршысына утырып, Коръән укый, «Тәбарәк» сүрәсен. Аннан соң, Коръән укып тәмам булгач, хәленә күрә акча өләшәләр шунда кабер тирәсендәге кешеләргә, фәкыйрь-фөкарәгә. Халык һәммәсе таркалып киткәч, мулла янә ялгыз кала кабер өстендә тәлкыйн[6] итәргә. Монда шулдыр: имам аягүрә торып, мәетнең каршысында әйтә, сөаль фәрештәләре килгәндә мәет катына мәетнең җавабы җиңел булсын, дип.

Аның өчен мәетне кабергә куеп киткәч, ике фәрештә киләр мәет янына. Сорарлар: «Тәңрең кем? Пәйгамбәрең кем? Динең ничек?» Мәет җавап бирер шул тәлкыйн кебек,ягъни әйтер: «Тәңрем — Алла, пәйгамбәрем — Мөхәммәд, динем — ислам дине».

---

[1] Фидия — йолым, үлгән кешенең гөнаһысын йолып алу өчен бирелгән мал.

[2] Дәвер итәләр — тирәли әйләнеп йөриләр.

[3] Руза — ураза.

[4] Рөкуг — намазда иелеп тору.

[5] Сәҗдә — намазда баш белән җиргә орыну.

[6] Тәлкыйн — үлекне күмеп, озатучылар киткәч, руханиның үлекне исенә төшерү өчен иман укуы.

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТОРМЫШЫНДА ИСЛАМ ДИНЕ ЙОГЫНТЫСЫННАН ТЫШ БАРЛЫККА КИЛГӘН ЫШАНУЛАР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР*

Рус җәмгыяте үзенең руслардан башка халыкларын (шул исәптән татарларны да) гомуми кешелек белеме яктылыгы астында агартып өлгергәнчегә кадәр аларны яхшылап өйрәнергә мәҗбүр булыр. Казан тирәсендә яши торган халыкларның (чуваш, мари, удмурт, мордва) тормышларын белүчеләр, шушы халыклар белән рус җәмгыятен таныштырырга дип, аерым китаплар, вакытлы матбугатта мәкаләләрен чыгардылар һәм хәзергә кадәр дә чыгарып киләләр. Алар татарларны да онытмыйлар, алай гына түгел, ә бәлки соңгы вакытларда, бу тирәнең башка халыкларына караганда, татарларның тормышларын тирәнрәк өйрәнергә, аларны агартырга тырышалар.

Татарның тормышын ачыклауда рус кешеләренә үземнең көчем һәм мәгълүматым җиткән кадәр ярдәм итәргә теләп, күп еллар бу тормышны тикшерү һәм күзәтү өстендә эшләвемнең нәтиҗәләрен матбугатта алар белән уртаклашуны үземнең изге бурычым дип саныйм. Үземнең тикшеренү һәм күзәтүләремдә мин мәсьәләнең, минем карашымча, башка язучылар тарафыннан азрак ачыкландырылган якларын күздә тоттым. Мин татарларны татар дип кенә сөйләрмен, мөселман татар турында, бигрәк тә аның мөселман булгач никадәр татар булып кала алуы турында соңыннан әйтеп китәрмен. Шул теләктән чыгып, мин рус укучысын барыннан да элек татарның әкиятләре, шул әкиятләр белән туган гореф-гадәт, йолалар һәм кайбер юк-барга ышану билгеләре белән таныштыруны кирәкле һәм файдалы дип саныйм. Аларда мин хәзергәчә сакланып килгән иске татар ышануларын һәм үз-үзләреннән татарлыкны күрсәтеп тора торган җанлы эзләр күрәм. Татар әкиятләре турындагы тикшеренү һәм күзәтүләремне, бер яктан, бала чакта ук ишеткән хикәяләремә һәм, икенче яктан, бу мәсьләгә фәнни күзлектән карый башлавымнан соң, татарлардан сорашып белүләремә нигезләп яздым.

## Ышанулар

Татар әкиятләрендә сөйләнеп килә торган әкәмәтләрне ике төркемгә бүләргә мөмкин:

1) су астында торучы әкәмәтләр;
2) җир өстендә яшәүче әкәмәтләр.

Беренче төркемгә мин түбәндәгеләрне кертәм: су бабасы, су иясе, су анасы, юха. Ә икенчесенә: убыр, албасты, өрәк, бичу-

* К.Насыйриның бу хезмәте рус матбугатында басылган. Шуннан тәрҗемә итеп бирелә.

ра, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен һәм дию пәрие.

Элек су астында торучыларын карап чыгыйк.

1. Татарлар, *су бабасы*, дигәндә, суда (мин җыйган әкиятләрдә күлдә генә) яши торган су патшасын, су бабасын күздә тоталар. Һичбер әкияттә аның судан чыгып йөрүе, кешеләр белән турыдан-туры аралашуы турында сөйләнми; моның өчен аның кушканнарын эшләп, боерыкларын үтәп торучы хезмәткәр сыман бернәрсәсе бар, ул да булса...

2. *Су иясе* (ягъни «водяной хозяин»). Мин язып алган татар әкиятләренең берсендә су иясе татар алдына үзенең хуҗасы — су бабасы белән татар арасында йомыш үтәп йөрүче үткен бер малай кыяфәтендә чыга. Ул аңгыра, куркак, тәҗрибәсез, татарны яхшы белми, татардан көчлерәк, ләкин аюдан көчсезрәк булып күренә.

3. *Су анасы*. Исеменнән үк моның хатын-кыз җенесеннән икәне күренеп тора, чөнки русчага «водяная мать» дип тәрҗемә ителә. Татарларда суда яшәүче әкәмәтләргә карата, үзенең чыгышы белән югарыда язылганнарга якын тормый торган юханы исәпләмәгәндә, башка исем юклыгы һәм, татарларның әйтүләренә караганда, болар үзара якын булулары сәбәпле, мин су анасы су иясенең анасы, су бабасының хатыны дип уйлыйм.

Кайбер вакытта су янына үзе үк көтмәгәндә килеп чыккан татарга су анасы чәчен тарап утыручы хатын булып күренүен дә искә алырга кирәк. Ул төнлә дә, көндез дә күренә. Аның турында башка сүз әйтә алмыйм. Бары тик шуны әйтеп китәргә кирәк: әкиятләрдә татарлар су анасын теләгән бер урында һәм бик еш кына су иясе белән бутап сөйлиләр. Борынгы заманда аларны аерганнар булса кирәк, югыйсә бер мәгънәне аңлату өчен ике төрле сүзнең нигә кирәге булыр иде?

Шуның белән бергә, татарларның аңлавы буенча, әкиятләрдәге әкәмәтләр ирлек-хатынлык вазифаларын башкаралар. Моны минем түбәндә китереләчәк тикшеренүләрем, шулай ук алар арасында ирләр-хатыннар, бала-чагалар һ.б. булулары мөмкин дип табучы чуваш әкиятләре белән дә, һичшиксез, исбат итеп була. Чыгышлары татарларныкы шикелле үк борынгы төркиләрдән булганлыктан, без монда чувашларны да күздә тотарга тиешле.

4. Барлык билгеле халыклар әкиятләрендәге вакыйгаларга *еланнар* катнашкан кебек, татар әкиятләрендә дә еланнар бар. Татар әкиятләрендә еланнар түбәндәге сыйфатларда биреләләр: барлык еланнар кара төстә булып, аларның патшалары гына ак була. Кара еланнар татарга дошман булалар, аны яратмыйлар. Ак елан аны яклый, ярата, алдан хәбәр биреп, аңар төрле файдалар китерә. Аның өстенә елан тиресе бизгәкне дә куа, имеш. Елан йөз ел яши алса, картаеп, *аждаһага*

әйләнә. Аждаһа дөньяда мең ел яши, шуннан ким дә, артык та яшәми һәм ул татарлар торган җирдә булмый. Йөз ел яшәп, әле генә аждаһага әйләнгән елан кая китә соң? Аны болыт күтәреп ала да диңгез атавына илтеп ташлый. Татарларның фикеренчә, аждаһаны болыт алган вакытта, ул һавада койрыкларын болгый, бик каты селкенә. Атауда мең ел яшәгәч, аждаһа *юха кызга* әйләнә. Юха кыз, төрле мавыктыргыч кыяфәтләргә кереп, татарга күренә, аңар зарар итә ала башлый. Мәсәлән, ул, чиксез матур кызга әйләнеп, күл буенда чәчләрен тарап утыра. Юха елан, кызга әйләнгәч, кияүгә бара ала, берәр кешенең хатыны да була ала. Шунысы кызык, юха кызның ире аны бик нык сөя, ләкин үзе һаман ябыга, кибә бара. Менә нинди була ул юха кыз! Монда бер сорау килеп чыга: татар үзенең адәм кызы урынына юха кызга өйләнгәнен белә аламы соң? Белә ала. Юханың менә нинди үзенчәлекләре була: 1) юханың авызы бик сасы; 2) юха сусыз берничек тә яши алмый; 3) юханың кендеге булмый.

Юхага өйләнгән татар, аңар үзен йоттырмыйча, аңардан котыла аламы соң? (Юханың кешегә кияүгә баруының төп максаты — ирен ничек итеп булса да йоту.) Мин аның котыла алу-алмавы турында бернәрсә дә белмим. Хәер, минем язып алган әкиятләрнең берендә шуңар охшашлы бер юл күрсәтелә шикелле. Ул болай була: бер патшаның улы юха кызга өйләнеп (билгеле инде, чын күңелдән яратып һәм аның юха икәнен белмичә), соңыннан, югарыда күрсәтелгән билгеләр буенча аның юха икәнен белгәч, эчен-тышын бизәкләп, ишек-тәрәзәсез итеп, тимердән бер сарай салдырган; шактый мараша торгач, шунда үзенең серле хатынын чакырып керткән, юханың керүе белән ишеген бикләп, сарайның тирә-ягына утын өеп, ут төртеп җибәргән дә юханы яндырган. Патша улы яңадан еланга әйләнгән юханың коточкыч зур койрыгы белән сарай стеналарына бәргәләнүен ишеткән. Юханың шул бәргәләнүеннән бөтен сарай дер калтырап торган, имеш.

Башка бер әкияттә төнлә, ире йоклаган вакытта, юха кызның еланга әйләнеп, ире өйдә су калдырмаганга күрә, өй янындагы күлгә су эчәргә баруы турында сөйләнә. Юха белән патша улы турындагы әкияттә, юха сарайда янып үлгәч, кешеләр аның көлен алып, тиръяк исеме белән йөртелә торган бер дару ясый башлаганлыклары турында да әйтелеп кителә*.

Хәзер җир өстендә яши торган әкәмәтләргә килик.

1. *Убыр.* Украинча упырь, чувашча вобур (чыны исә Көньяк Америкада яшәүче ерткыч хайван-вампир). Татарларның аңла-

* Чынлап та, тиръяк грекча Vhriv дигән сүздән алынмадымы икән? Чөнки ул сүз яңа грекча кечерәйтү сүзе Vmcaixi белән бертөсле ишетелә, кыр хайваны мәгънәсендә йөртелә.— *К.Н.*

вы буенча, берүзе дә яшәп, аерым хәрәкәт итә алса да, һәрвакытта берәр кешенең эчендә тора. Андый кешене «убырлы кеше» дип йөртәләр. Әкиятләрдә мин «убырлы карчык» дигәнне дә очратканым бар. Убырлы кешене татарлар бик җиңел белә алалар: аның култык астында тишеге була. Шул тишектән убыр кешенең эченә кереп йөри. Русларның домовойлары шикелле, убыр татарларны буа һәм көндез күзләренә дә күренә ала. Татарны убыр басканда, ул кыймылдый алмый. Әгәр дә ул, җаен китереп, убырны тешли алган икән, аның кай төшен тешләгән булса, «убырлы кеше»нең шул җире җәрәхәтләнгән була.

Әкиятләргә караганда, убырлы карчык аулак җирләрдә, татарлар тора торган урыннардан еракта яши. Андый урыннарга татарлар берәр җиргә барганда адашып кына килеп чыгалар. Убырлы карчыклар өйләрдә яшиләр, ләкин өйләре рус әкиятләрендәгечә тавык тәпиле түгел. Хәер, кайбер вакытта татарлар, берәр югалган нәрсәләренең кайда икәнен белү өчен, убырлы карчыкларны үзләре үк эзләп табалар. Ләкин бу эшкә бары тик бәхетле, оста, көчле, хәйләкәр кешеләр генә батырчылык итә алалар. Алар убырлы карчыкларның кайда яшәгәнлекләрен ничек беләләр соң? Менә ничек беләләр: алар, кай якка күзләре төшсә, шул якка таба карап чыгып китәләр дә, бик күп йөри торгач, бер күл янына җитеп, анда тарак белән чәчен тарап утыра торган бер матур кызны очраталар. Менә шул кыз аларга «убырлы карчык»ның кайда торганын әйтеп бирә инде. Бу кызны юха кыз дип уйламагыз. Юха кешегә бары зарар гына эшли ул, ә бу — дию пәриенең хатыны, бала вакытта ук коточкыч усал дию пәрие урлап алып киткән бер татар кызы.

Ярар, бу турыда соңыннан сөйләрбез. Кайвакытта болай да була: убырлы карчыкка бара торган юлны, татарга яхшылык тели торган дию пәриенең хатыны түгел, ә убырлы карчыкта булып кайткан кешеләр, ягъни бозык ниятле, акча яратучы һәм тәмлетамаклар күрсәтәләр. Кешеләрнең яхшылары да, начарлары да убырлы карчык өен төнлә ерактан ук ялтырап күренгән уттан табалар. Барып кергәндә, убырлы карчыкның ашап утырган чагы була; ул ат ашап утыра. Кергән кешенең: «Әссәламегаләйкем»,— дип сәлам бирүе мәҗбүри, югыйсә убырлы карчык аны шунда ук йота. Ләкин юлга чыкканда, ун потлы башмак киеп, кырык потлы күсәк күтәреп чыга торган һәм кучеры, алпавыты (ягъни «барин»ы, бигрәк тә становой яки капитан-исправник шикелле авыр гәүдәле кешеләре) белән бергә, җигелгән тройканы мәсҗет аркылы ыргытып ташларлык кешеләр шикелле батырлар убырлы карчыкка бер дә сәлам бирмиләр. Әгәр дә карчык, ачуланып, котырып, йотмакчы булса, бу батырлар (егетләр), кылычларын бер селтәү белән, убырлы карчыкның гомерен кыскарталар. Мондый кешеләр үзләреннән-үзләре дә, убырлы карчык киңәшеннән башка да

читен эшләрен эшли алалар, алар убырлы карчык янына, күрәсең, бары тик кызыксынып кына баралардыр.

Әгәр дә убырлы карчыкка килгән кеше хатын-кыз булса, ул аңа, мунча ягып, үзен чабындырырга куша. Убырлы карчык бик хәйләкәр булганга, үзенең теләген туп-туры гына әйтеп бирми. «Мине мунчага кулыңа күтәреп алып бар!» — диясе урынга: «Кызым, мин картайганмын, үзем бара алмыйм (ялганлый хәйләкәр карчык! Татарлар шома кешене тикмәгә генә «убырлы» димиләр шул!), мине култыклап алып бар, әгәр тиз бара алмасам, артымнан каты гына төрткәләп алып бар»,— ди. «Мине яхшылап чабындыр»,— диясе урынга: «Себерке сабы белән төйгәләсәң дә ярар»,— ди. Монда инде намуслы, байлыкка кызыкмаган яки үлсен дип урманга китереп адаштырылган татар кызлары убырлы карчыкка үзләрен яраттыра алалар. Мунчага барганда, аннан өйгә кайтканда, кулларына күтәреп йөртәләр, себеркенең сабы белән түгел, яфраклы ягы белән чабындыралар. Ләкин комсызлар, байлыкны яратучылар, аның хәйләсен аңламыйча, турыдан-туры ул әйткәнчә генә эшлиләр: артына төрткәләп алып баралар, ләүкәгә яткырып, бар көчләренә себерке сабы белән кыйныйлар. Мунчадан кайтканда, убырлы карчык кунак кызының намуслылыгын сынап карый. «Кызым,— ди кунак кызга карчык,— башымны тарак белән төрткәлә әле, әллә нишләп кычытып тора»,— ди. Кунак кызы карчыкның башын ачып караса, ни күзе белән күрсен, аның башы алтын, көмеш, энҗе, мәрҗән, асылташлар белән бизәлгән. Татар әкиятләрендәге фикер буенча, намуслы кызлар, билгеле, мондый калфакларга кызыкмыйлар. Ләкин комсыз хатын-кыз булса, бу кыйммәтле нәрсәләр белән бөтен кесәләрен, изүләрен тутырып бетерә. Убырлы карчык бу эшнең барысын да күреп, белеп тора. «Кызым,— ди кунак кызга убырлы карчык,— минем күңелем булыр, биеп кара!» Билгеле инде, биегәндә карактан бу нәрсәләр коелып төшәләр. Карчык кунак кызын караклыгы өчен бик каты ачулана да һәммә урлаган нәрсәләрен алып кала. Моның белән генә эш бетми әле, убырлы карчык кунак кызны яңадан сынарга тотына: «Кызым, бар әле, мунчага киптерергә салат оны куйган идем, кибеп бетмәдеме икән, карап кайт әле»,— ди.

Кунак кызы бара, ни күзе белән күрсен: анда салат оны урынына асылташлар тулган. Намуслы кыз аларга кызыкмый, ә комсыз кыз, беренче тотылуын онытып, тагын урлый. Өйдә яңадан бию башлана, карак тагын тотыла.

Язарга онытканмын, кайвакытта убырлы карчык кунакларын кеше ите белән дә сыйлап җибәргәли. Моннан соң яхшылыкка бүләк бирү, яманлыкка җәза бирү китә. Ул болай эшләнә: яхшылык иткән өчен убырлы карчык бүләк итеп яшел сандык бирә, комсыз һәм ач күзлеләргә кара сандык бирә. Һәркайсына өйгә кайтканчы сандыкларны ачмаска куша. Һәммәсе карчыкның

сүзен тыңлыйлар. Авылларына кайткач, этләр, төрлечә өреп, боларга каршы чыгалар. Беренчесенә: «Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң!» Икенчесенә: «Баерга киткән түтекәй үлеп кайта, ләң-ләң!» — дип өрәләр. Чынлап та, беренчесе яшел сандыкны ачып караса, анда кыйммәтле нәрсәләр тутырылган була, икенчесе кара сандыкны ачып караса, аннан елан сикереп чыга да кызның муенына чолганып буып үтерә.

Убырлы карчыкка килгән кеше, әгәр юлын адашып, карчыкның ярдәм итүен сораса, карчык аңа сихерле йомгак биреп, аны җирдән тәгәрәтеп җибәрергә һәм шуның артыннан барырга куша. Йомгак адашкан кешене тиешле җиргә илтеп куя.

Сбоевның язуына караганда, чувашлар үзләренең «вобур»ларына, айны урлап ашый, дип ышаналар икән. Ләкин татар убырының мондый кыю һәм сәләтле булуы турында әкиятләрдә бер сүз дә юк.

2. *Албасты* («әль» — кул, «басмак» — кешене кулы белән баса торган нәрсә яки «ал» — бернәрсәнең алды һәм «басмак» — басу, ягъни алга таба күкрәккә баса торган нәрсә). Бу нәрсә дә русларның «домовое», татарларның убыры шикелле, татар йоклаган вакытта, аның өстенә ятып, аны баса һәм, татарларның ышанулары буенча, ул баскан вакытта йөрәктән кан да эчә, имеш. Шунысы гаҗәп ки, ни өчен татарның хыялы кан эчүчелекне убырга гына кайтарып калдырмады икән? Чынлап та, убырның исеме, кеше һәм зур хайваннарга һөҗүм итеп, аларның канын эчә торган бер ерткыч җанвардан алынуы мөмкин.

Ләкин без югарыда, убыр кунакны ашыйм дип куркытса да, ул аның канга хирыслыгыннан булмыйча, бары тик кунакның сәлам бирмәгән ачуыннан гына дигән идек. Сүз уңае белән шуны да әйтеп китәргә кирәк, татарлар эшчән һәм булдыклы кешене — убыр, авыр һәм ялкау кешене албасты дип йөртәләр. Бу нәрсәдән чыккан икән?

3. *Өрәк* («өрмәк»тән алынган). Бу нәрсә урманда яки юлда барган татарларга көчләп үтерелгән кешенең кабере өстендә күренә. Татарларның ышанулары буенча, үтеп баручы татарның күзенә өрәк кеше кыяфәтендә дә, ава-түнә бара торган печән кибәне булып та күренә. Татарлар өрәкнең болытка әйләнеп китүе турында да сөйлиләр. Юлаучы татар, юлда үлекне күрмәсә дә, өрәкнең ачы тавышыннан үлек барлыгын сизә ала. Әгәр дә кешенең еракган күренә, кычкыра торган өрәкне якыннан карыйсы килсә, өрәк шунда ук күздән югала. Яшерен һәм билгесез нәрсәне күрмәс һәм аның ямьсез тавышын ишетмәс өчен, татарлар төнлә юлда үлеккә очраудан һәм үлек бар урынга кич белән барудан сакланалар. Татар бер нәрсәдән бик каты курыкса: «Өрәгем купты»,— ди. Моннан өрәкнең һәр татарда барлыгы күренеп тора. Татарларның «җан» дигән сүзләре фарсыдан алынуын, шул ук вакытта өрәк дигән сүзнең «өрмәк»тән

алынуы мөмкинлеген игътибарга алсак, өрәк турындагы әкиятләрдә татарларның кеше җаны турында исламны кабул итүләренә кадәр булган кайбер төшенчәләре (җанны «өрәк» дип йөртүләре) хәзергәчә сакланып калуын әйтә алабыз.

4. *Бичура.* Татарларның бичурасы рус халкының «кикимора»сы белән бер нәрсә. Ул татарга бер дә зарарын тидермәсә дә, төнлә белән аны төрле рәвештә борчып бетерә: кычкыра, уйный, көлә, шаяра, йоклый торган кешене бер урыннан икенче урынга күчереп куя; бер җиргә куелган нәрсәне икенче урынга яшереп куя. Татарларда аның хакында бер мәкаль бар: «Кая китте соң ул нәрсә, бичура урлады микән әллә?» Томаланган мичне төнлә белән ача, гомумән, ул бик шаян нәрсә. Бичура ничек килә соң ул өйгә? Татарлар ул хакта менә ничек итеп сөйлиләр: татар, өенә мич салдырмыйча озак торып, аннары ул өйгә күчеп керсә, шул вакытта өйгә бичура кереп кала. Бичураны йорттан куып чыгарып буламы? Кайсылары моның өчен йортны бөтенләй сүтеп, башка урынга күчереп салырга кирәк, кайсылары, өйгә аю кертеп чыгарсаң да, бичура кача, диләр.

5. *Өй иясе.* Аның бичурадан аермасы шул: ул йортта шаярмый, бәлки хуҗага файдалы эшләр эшли, аңа яхшылыгын тидерә, кайсы йортта ул тәңкә суга, кайсы йортта җеп эрли, кайсында, каләмен шыгырдатып, язу яза, китап актара. Ләкин татар өй иясенең хезмәте белән турыдан-туры файдаланмый, әмма аның шул хезмәте кешенең эше ничек булачагын алдан күрсәтә: өй иясе тәңкә сукканда, аның «чык-чык» дигән тавышын ишеткән хуҗа, сәүдә итә башласа, баеп китә; өй иясенең җеп эрләгәнен ишетүчеләр кул эшенә тотынсалар, эшләре яхшы бара, бәхетле тормыш белән тора башлыйлар; өйдә каләм шыгырдавын, китап актарган тавышны ишеткән кеше галим була. Бу соңгы хәлдә әкиятләрдә байлык турында бер сүз дә әйтелмәгән. Ахры, байлык дигән нәрсә гыйлем әһелләренә һәркайда да ул хәтле билгеле булмаса кирәк. Татарлар, бу яхшылык итүче һәм алдан хәбәр бирүче рухның барлыгы бары өйдә тынычлык булганда гына һәм ялгыз утырганда гына сизелә, диләр, һәм бу бик табигый дә!

6. *Абзар иясе.* Йорт хайваннары, атлар, бигрәк тә сыерларның хыялый хуҗалары шулай атала. Ул ат, сыер абзарларында тора. Ул яраткан хайваннар һәрвакытта көр, шома, матур булып, ул яратмаган хайваннар тирләүчән һәм бик тиз ябыгучан булалар. Татарлар арасында шундый кызык кешеләр бар: алар тирләүчән яки ябыгучан атларны «бу ат миңа төс түгел», ягъни абзар иясе яратмый дип, сатып җибәрәләр.

7. *Чәчәк анасы, чәчәк иясе.* Татарларның фикеренчә, балага чәчәк чыккач, аның зур чәчәкләрендә чәчәк анасы тора. Кайсы татарлар чәчәк анасы гына барлыгын сөйлиләр, кайсылары икесе дә бергә яшиләр дип ышаналар.

8. *Шүрәле*. Русларның «леший»лары шикелле бернәрсә. Шүрәлеләр урманда тора һәм алар ялгыз гына яшәмиләр. Алар татарларга кеше кыяфәтендә күренәләр. Шүрәленең имчәкләре бик зур була, аның берсен уң җилкәсе, икенчесен сул җилкәсе аркылы салган була, имеш. Әгәр урманда аларга татар очраса, алар аны кети-кети уйнарга чакыралар; әгәр дә ул күнсә, аны үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин татар шүрәлене алдалый ала; ул аны ничек алдалый соң? Балта белән ярган агачка кул тыгып уйната да, шүрәле, аңгыралыгы аркасында, шунда ук һәлак була.

Бу нинди уен соң? Татар калын бер бүрәнәнең буена таба балта белән чаба да, бүрәнә ярылып китә; ул ярыкны киңәйтер өчен, татар аңа чөй кага. Шүрәле шул ярыкка бармакларын тыккач та, татар, тиз генә суккалап, чөйне чыгарып ташлый да, шүрәленең бармаклары кысылып кала. Шүрәле, бармакларының авыртуына чыдый алмыйча, бик каты акыра башлый, үзен бу бәладән коткарып, татарны кытыклап үтерергә үзенең иптәшләрен чакыра. Әгәр дә татар шүрәленең: «Син кем?» — дип соравына: «Мин Былтыр атлы», — дип әйтергә башына килсә һәм, шүрәлене кыстырып, качып котылса, шүрәленең: «Былтыр кысты, Былтыр кысты!» — дип кычкыруына җыелган иптәшләре хәйләкәр татар артыннан чабу түгел, бәлки: «Былтыргы елны каян эзлисең, табып буламыни аны!» — дип, шүрәледән кычкырып көләләр генә, имеш. Күрәсең, шүрәлеләр бик аңгыра булалар икән.

9. Инде *җен* һәм *дию пәрие* дигәннәре хакында сөйләргә кала.

Башта шуны әйтергә кирәк: болар татар хыялыннан гына туган нәрсәләр түгел. Алар, иранлыларныкы булып, гарәпләрдән кабул ителгән мөселманлык аркылы татарларга да килеп җиткән нәрсәләр. Әгәр дә бу әкиятләрдә татарлык чагылышлары булмаса иде, мин алар турында сөйләп тә тормас идем. Монда ислам рухы шулкадәр аз, хәтта аның кайсы урыннарда гына сизелә алуын укучы үзе үк күрер.

Җеннең җенесе булмый, ләкин ул татарның хатыны яки татар хатынының ире булып яши ала. Моннан башка җеннәр татарга эт, мәче һәм елан кыяфәтендә күренәләр. Җенне күргән татар берәр нерв авыруы белән авырый башлый, төнлә саташа, бирән зәхмәтенә төшә. Татарга җен бик сирәк, анда да очраклы рәвештә генә күренә, чөнки җеннәр үзләре дә татарлардан качып йөриләр. Җеннәр күбрәк юлларда, күзгә күренмичә генә, яки сукырлар, аксаклар кыяфәтенә кереп йөриләр. Әгәр татар ялгышып җенгә кагылып китсә, ул җенләнә, аңар җен кереп урнаша. Татар авырый башлый, җеннең үзенә дә ул эш ансат түгел, ул үзе дә шуннан авыру була. Кайберәү-

ләрнең әйтүләренә караганда, җеннәр татарлардан качмау гына түгел, бәлки бик йөдәтүчән дә булалар икән. Алар төнлә хатыннар янына килергә гадәтләнәләр, алар янына түшәккә ятып, ире шикелле кылана башлыйлар икән. Ләкин татарларның ышануларына караганда, җен иялəнгән хатыннар бала тапмыйлар икән. Ирләргә хатын булып яшәгән җеннәрнең дә бала табулары турында татар әкиятләрендә бер сүз дә әйтелми. Җеннәрнең үзара торуларыннан бала табулары, үз балаларын татарларның бишектәге яки ана карынындагы бала белән алмаштырып китүләре турында шул ук әкиятләрдә сөйләнә. Җеннәр тимердән куркалар (җеннән курка торган татарлар йокларга ятканда мендәр яки түшәк астына балта яки бер-бер тимер корал салалар). Җеннәр артыш агачыннан да куркалар. Ни өчен икән? Минемчә, бу болай: татарлар бирән зәхмәтен җеннән күрәләр, ә татарлар һәм Казан тирәсендә яшәүче руслар да бирән зәхмәтен артыш агачы белән дәвалыйлар.

10. *Дию пәрие.* Диюләр гадәттә татарга төрле кыяфәттә урманнарда, кырларда очрыйлар; кайвакытларда печән кибәне булып күренәләр, кайвакытта кызга әйләнеп, татарга кияүгә чыгалар. Дию пәриләре үзләренең шәһәрләрендә яшиләр, диңгез һәм җир астында аларның патшалыклары була. Җир өстендәге патшалыклары исә кеше күзенә күренмиләр. Җир өстендә җеннәр хәзинә күмелгән җирләрдә яшиләр һәм җиргә күмелеп озак яткан хәзинәләрнең үзләреннән дә диюләр яратылалар. Диюләр хакында шуны әйтергә кирәк, алар һәрвакыт татарга дошман булалар: 1) алар кечкенә кызларны урлап алып китәләр дә, үсеп җиткәч, хатынлыкка алалар; 2) диюләр татарны мыскыл итәләр, аның дусты яки берәр яхшы кеше кыяфәтенә кереп, дию татарны үз шәһәренә алып китә дә, сыйламакчы булып, аның алдына начар ашлар китереп куя; 3) дию үзенең кунакка чакырып китергән татарны ничек тә булса һәлак итәргә тырыша; ул, гадәттә, болай итә: хатынына мунча ягарга куша, кунакны мунчага алып бара, кунак чишенгәч, аңа якты йөз күрсәткән булып, үзе юындырырга тели. Татар риза булып, аркасы белән әйләнгәч, дию аны себерке сабы белән кыйнап үтерә дә үз мунчасының ләүкәсе астына күмеп куя.

Дию «бисмилла»дан курка. Шулай да, сирәк кенә булса да, убыр турында язылган әкиятләрдә сөйләнгән батыр егетләр аларны җиңәләр. Андый егетләр мунчада диюгә алдатмыйлар. Алар, үзләренең кырык потлы күсәкләрен күтәреп, диюнең артыннан киләләр дә аның җилкәсенә кундыралар, шуның белән диюнең эше бетә. Өйдә вакытта дию, мондый авыр күсәкне күтәрмәкче булып көчәнсә, тәрбиясезлек тә эшләп куя. Кырык потлы күсәкне кулында кечкенә таяк белән уйнаган шикелле генә итеп әйләндерүче көчле (әкияттә әйткәнчә,

ун яшьлек) батыр бер дә арткы яктан яшеренеп килмичә дә диюне куркыта. Ул вакытта инде дию ничә татарны үтереп, ләүкә астына күмгәнен сөйләп бирә. Батыр кушкач, аларның һәммәсен казып ала да, «җан даруы» биреп, аларны тергезә. Димәк, татарларның уенча, дию үлекләрне тергезә ала.

Монда «ничек һәм ни өчен батырлар диюләр янына баралар, дөньяда иң явыз һәм иң көчле булган диюләргә каршы торырлык кыюлык һәм батырлыкны алар кайдан алалар соң?» дигән сорау туа.

Бу сорауга әкиятләр түбәндәгечә җавап бирәләр: батыр диюләр янына үзенең сеңлесен коткарырга бара, чөнки кызны диюләр бала вакытында ук урлап киткән булалар. Батыр күзе караган якка төн китә, көн китә, бик озаклап, бик күп җирләр үтеп бара. Ул юлда убырлы карчыкка да кереп чыга. Батыр анда диюгә бара торган юлны табу турында убырлы карчык белән киңәшләшү яки аңардан сихерле йомгакны алу өчен түгел, бәлки кызыксынып кына керә һәм (алдан үзенең көчен сынап карау өчен булса кирәк) убырлы карчыкның башын кисеп ташлый. Аннары ул юлын дәвам итә. Бара торгач, батыр күл янында чәчен тарап утыручы сеңлесен очрата. Һәм, аның күрсәтүе буенча, диюнең торган җирен эзләп табып, диюне үтерә, урланган кызны коткара. Янында сеңлесе чәчен тарап утыра торган күлнең суы көч бирә торган су булганлыктан, батыр, шул күлнең суын эчеп, үзенең көчен арттыра.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, кайсы вакытта куркак һәм ялкау татарның хәйләкәрлеге дә диюне җиңеп куя. Татарның хәйләкәрлеге нәрсәдән гыйбарәт икәнлеге, минемчә, укучы өчен бик кызыклы булганлыктан, мин бу турыда ачык итеп сөйләмәкче булам, ягъни читләтеп китерелгән фикерләр урынына авыл татарларының нинди икәнлеген татарларга карата махсус язылган әсәрләрдән ким тасвир ителми торган бер татар әкиятен тулысынча сөйләмәкче булам*.

## Юк-барга ышану, юраулар

Һәрбер кешедә була торган теләк — киләчәктә ни булырын беләсе килү теләге белән татар табигатьнең тышкы күренешенә карап уйлана башлый, аннан нәрсәдер көтә, аннан үзенең язмышының ничек буласын ачып бирүне сорый. Табигатьнең тышкы күренешеннән түбәндәгеләр татарга аның киләчәген алдан белдереп тору хезмәтен үтиләр:

* Моннан соң К.Насыйри «Гөлнәзек» турындагы әкиятне язып китә. Бу әкият шушы томның 89–91 битләрендә урнаштырылган.

1) йорт хайваннары (татарларда: мәче, эт, тычкан, ат);

2) йорт һәм аның тирәсендә яши торган кошлар (тавык, карга, саескан, чәүкә);

3) үз тәнендәге әгъзалары (борын, ирен, кул, колак) һәм киләчәкне белергә теләгән кеше үзе булмаса, аның баласы;

4) кием-салымның нинди булса да бер хәлдә торышы.

Татарлар түбәндәгеләрне юрап белергә тырышалар:

1) һава ничек булачак: яңгыр булырмы, буранмы; ашлыклар, яшелчәләр ничек булачак;

2) кайчан аңар кунак килер, кайчан кем аны сыйлар, кайчан кемнән ул күчтәнәч алыр, бер-бер сөенеч булмасмы;

3) кайчан ул зарар күрәчәк (бәла-каза, бәхетсезлек);

4) сугыш булмасмы;

5) якыннарыннан берәү яки ул үзе үлмәсме?

Авыл татары юрау белән бик аз нәрсә белергә тели, ләкин бу аның аңлау чамасы тарлыктан, теләкләре бик гади, бик чикле булудан килгән бер нәрсә.

1. Татарның уң колагы кычытса, җылы булыр дип, сул колагы кычытса, салкын булыр дип юрый; әгәр кояш «колаклы» булып чыкса, салкын булачакны белдерә дип уйлый; янган чыра бырылдаса, татар буран көтә; мәче кашынса, ул тагын буран булыр дип уйлый. Җәй көне эт аунаса, яңгыр булыр, кыш көне аунаса, буран булыр, имеш. Карга ачы тавыш белән каркылдаса, көн бозыла; яз көне кар явып, өйдә калган терлек кычкырса, кар тиз эреп, терлек кырга тиз чыгар дип ышана. Әгәр дә яңа өйнең беренче нигезен кыз кеше салса, кыш бу өйдә җылы булыр, ди. Шомырт агачы башыннан башлап чәчәк атса, иртә чәчкән богдайны уңа дип уйлый; шомырт агачы түбәннән башлап чәчәк атса, бары соң чәчкән богдай гына уңа дип ышана. Әгәр кыш көне Волгада боз өем-өем булып торса, җәен ашлык уңа дип уйлый татарлар.

2. Саескан кычкырса, мәче битен юса, самовар җырласа, ике кешенең маңгайлары бәрелсә яки түшәмнән ак таракан егылып төшсә, татар кунак килә дип уйлый. Саескан кычкырганда, татарлар аның кайсы якка карап кычкырганын карыйлар һәм шул яктан үзләренә кунак килүен көтәләр. Татарның ирене кычытса, үзенә күчтәнәч (бер җирдән икенче җиргә күчеп килгән — күчкән аш) килә дип ышана. Кием кигәндә итәге әйләнсә яки ишеккә кысылса, татар сыйлануны көтә, ялгышып күлмәкнең кире ягын кисә, сөенеч була. Учы кычытса, акча керә, тырнакка ак төшсә, яңа кием кияргә була. Бер-бер кешенең яки атның төчкерүе икенче бер кешенең әйткән сүзенең дөреслеккә чыгуын күрсәтә.

3. Татар җирдә аунап ята торган нинди дә булса берәр очлы казыкны алып, яна торган мичкә ташласа, аңар: «Очын кисеп ташла, сызлавык чыгар»,— диләр. Балаларга: «Утка

төкермә*, авызың кутырлар»,— диләр. Татарлар, берәүнең бәдрәфтә файдаланып ташлаган чүпрәк яки кәгазь шикелле нәрсәне алып, аны үзеңә файдалансаң, бармакка эт тырнагы чыга, диләр. Татарларның фикере буенча, астында келәү ителә торган агачны, мәсәлән, чуваш кирәмәтен, кисәргә ярамый, зарар булыр, диләр. Йорт тирәсенә чәүкә иялӛнсә, зарар китерә, шулай ук тавык әтәч булып кычкырса, зарар була, диләр.

4. Татарлар койрыклы йолдыз күрсәләр яки күктә кан төсе күрсәләр: «Патшалар арасында тынычсызлык булыр, сугыш булыр»,— диләр. Йолдыз атылганны күрсәләр дә шулай диләр.

Өй түбәсендә карга кычкырса, татарларның ышануы буенча, ул өйдә кем дә булса үләр. Әгәр бер-бер бала, күңелсезләнеп, иягенә таянып утырса: «Алай итмә, әтиең-әниең үләр»,— диләр. Әгәр эт уласа, хуҗасына бер-бер кайгы булыр: яки ата-анасы үләр, яки берәр хайваны үләр дип уйлый. Самовар уласа, ата-ана үлә. Татарның ышануы буенча, алар шул самовар улаган елны үләләр. Шәгъбан аеның[1] унбишенче кичәсендә төн аяз булса, татарлар үзләренең күләгәләренә карыйлар, күләгәләрендә башларын күрмәгән кешеләргә шул елда үләргә туры килә дип ышаналар.

## Ырымнар, им-томнар

Казан татарлары ислам дине кушкан гореф-гадәтләр һәм догалардан башка мәҗүсилектән калган ырым һәм им-томнарны да ясыйлар. Мин түбәндә язачак им-том һәм ырымнар аркылы алар ваба, хайван үләте, чәчәк, күз тию, эч авырту, бирән зәхмәте, бизгәк, котырган эт тешләп котыру һәм эт имчәге шикелле авырулардан котылмакчы булалар. Шуның өстенә бу ырымнар белән алар үзләренә дошман булган мифик көчләрне, үлекләрне юаталар яки берсүзсез җиңәләр, куалар һәм, гомумән, бәлаләрдән котылырга тырышалар. Үзләренең тормышларына файдалы булырлык берәр эшне эшләү өчен дә мондый ырымнарга мөрәҗәгать итәләр. Безнең татарларның тормышына ислам диненең тәэсир итүе һәм шуннан алына торган гореф-гадәтләр нәтиҗәсендә им-том итү һәм ырымлауларның көннән-көнгә кысылып чыгарылулары сәбәпле, мин аларның аз гынасын язып алырга өлгердем. Язганым кадәрлесе дә, минемчә, фәнни яктан әһәмиятсез булмас дип уйлыйм.

1. Ваба яки хайван үләте була башлагач та, авыл әйләнәсен сабан белән сызып чыгалар. Ирләр дә, хатыннар да бу

* Бу сүз борынгы заманда татарларның утны мөкатдәс санауларын һәм әле хәзер дә утка хөрмәт белән карауларын күрсәтә.— *К.Н*

[1] Шәгъбан ае — сигезенче ай (борынгы календарьда).

эшкә катнашмыйлар, бары кияүгә чыкмаган кызлар гына, башлары ялангач көенчә, бу ырымны эшлиләр. Алар, иң яхшы бәйрәм күлмәкләрен киеп, чәчләрен тузгытып, яңа яулык белән билләрен буып, ат урынына сабанга җигеләләр. Моңа күпме кыз кирәк булганын белә алмадым. Барының да кулларында чыбыркы була. Бу эшкә тагы карчыклар да катнашалар. Бер карчык алдан пумалага атланып бара, аның да чәчләре тузгыган була. Икенче бер карчык, сабанның сабыннан тотып, кызларны ат тоткан шикелле дилбегә белән тотып, камчы белән кыйный-кыйный әйдәп бара. Өченче карчык шулай ук пумалага атланып арттан бара. Бу вакытта авылга берәүне дә кертмиләр, керергә батырчылык иткән кешене үтергәнче кыйныйлар; шулай ук авылдан да берәүне дә чыгармыйлар. Мондый күңелсез һәм куркыныч күренешне күреп, ваба качар, хайван үләте тукталыр дип ышаналар.

Җәй башында хайваннарны беренче мәртәбә көтүгә чыгарырга вакыт җиткәч, аларны үләттән саклау өчен, татарлар көтүне кырга чыгару көнендә җиргә капка ясап куялар да, бөтен көтүне шул капка аркылы куып чыгаралар; шуның аркылы кешеләр дә үтеп чыгарга тиеш. Моны «җир үтә кичерү» диләр. «Җир үтә кичкән хайванга үләт тими» диләр. Бу көнне иске утны, иске суны һичкайда калдырмыйлар. Бу ырымны үтәр өчен аерым бер кеше бөтен авылның иске суын түктереп, иске утларын сүндертеп чыга. Шуннан соң бөтен авыл, бер урынга җыелып, имәнне имәнгә ышкып, ут чыгаралар, һәркем шуннан ут ала. Моны «яңа ут чыгару» диләр. Аннан соң аерым су савытларыннан кирәк кадәре су алып тоталар.

Хайван үләте башлангач та, беренче үлгән хайванның иреннәрен яңа йозак белән бикләп, басу капкасы төбенә күмеп куялар. Шуның белән үләт бетә дип уйлыйлар.

2. Баланың чәчәге җиңел үтсен өчен, фәкыйрьләргә ак үрдәк яки ак каз садака итеп бирәләр. Бала чәчәк авыруыннан тазара башлагач, «чәчәк боткасы» дигән ботка пешереп ашыйлар. Болай эшләмәгәндә, чәчәк авыр үтә дип уйлыйлар. Бу ырым зур чәчәкләрдә яши торган чәчәк анасы һәм чәчәк иясен рәхим-шәфкатьле итү өчен эшләнә булса кирәк.

3. Татарлар, балаларны күз тиюдән саклар өчен, аларның битләренә кара яки күк буяу белән сызыклар сызалар, янәсе, күз, баланың йөзенә төшүдән элгәре, буяуларга төшә дә баланың исәнлегенә зарар китерә алмый, имеш. Моннан башка тагын балага, күз тимәсен дип, карази орлыгын бөтигә тыгып тагалар. Ишек тоткасын яки бакасын су белән юып, күз тимәскә баланың битенә сөртәләр. Шулай ук күз тимәсен дип, балага артыш агачының бер кисәген тагалар. Татарлар, бернәрсәдән бик каты курыксалар, куркулык коялар, ягъни эретелгән кургашынны суга коялар да, ул анда төрле форма белән оешып ката. Татарлар-

ның ышануларына караганда, ул кеше кыяфәтендә дә ката, имеш. Шуннан соң әлеге кургашынны курыккан кешегә тагалар да шуның белән авыру бетә дип ышаналар. Соңгы ике фактка караганда, авыруның күз тиюдән булмыйча, бәлки артыш агачыннан, балтадан һәм кургашыннан курка торган җеннән булуы күренә. Димәк, татарлар бу ырымнарның барын да җеннәрнең зарарларыннан саклау өчен эшлиләр.

4. Чишмә, күл яки елга суы эчеп, бер татарның эче авырта башласа (җәйнең эссе көннәрендә эшче халыкның салкын суга сусаган вакытында яки берәр зарарлы су очраганда мондый хәлнең булуы мөмкин), «мине су тоткан булырга кирәк» дип уйлый һәм, авыру бетсен өчен, шул су эчкән җиренә алма яки йомырка сарысы ташлый яки кулына бер тотам үлән йолкып ала да, мине су тотмасын иде, дип, аны суга ташлый. Мин монда, бер яктан, борынгы татарларның су ияләрен олылауларын, икенче яктан, аларның күңелләрен йомшартырга тырышуларын күрәм.

5. Әгәр татар шешенсә, аңар артыш җиләге кайнатып эчертәләр, бу чынлап та бирән зәхмәтеннән файдалы дару үзе. Шуның белән шештерүче җен кача, имеш. Татарларның фикере буенча, җен артыш агачын яратмый торган булса кирәк.

6. Бизгәк тотып ятучы кеше аркылы татарлар аю үткәрәләр. Аюдан куркып, бизгәк кача, имеш. Бизгәкле кешегә тагын аю яки бүре тиресе ябындыралар, калтыраткан вакытта куенына елан тиресе салалар. Болар барысы да бизгәкне куар өчен эшләнә.

7. Әгәр дә татарны котырган эт тешләсә, ул кырык йорттан икмәк борыны җыеп ала да, шуны ашый. Ләкин икмәк борынын җыйганда, ул аны бары ян тәрәзә аркылы гына алырга тиеш. Шундый дарудан соң ул кеше тазара, имеш.

8. Татарның култык астына эт имчәге чыкса, аны икмәк борыны белән имлиләр. Имләгәндә, икмәкне шешкән урынга тидереп алып, аны «дүрт күзле эткә» ашаталар. Ике күзе өстендә башка төсле йоннан кашлары булса, шундый этне татарлар «дүрт күзле эт» диләр. Эт имчәге, кыярак, бака булганда, бертөрле үк им-том кулланалар. Аермалары бары шунда гына: эт имчәген икмәк борыны белән, баканы ташбака кабыгы белән авыру урынга тидереп имлиләр. Имләгәндә шушы сүзләрне әйтәләр:

— Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз — тугыздан кайтсын, тузанга, туфракка китсен;

— бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде — җидедән кайтсын, җилгә, күзгә китсен;

— бер, ике, өч, дүрт, биш — биштән кайтсын, биш юл чатлыгына китсен;

— бер, ике, өч — өчтән кайтсын, өч юл чатлыгына китсен;

— бер — бердән кайтсын, име-томы шул, имеш, шуны көтеп торган, имеш, минем кулым түгел, Гайшә Батман кулы.

Бу саннарны әйтеп, икмәк борынын, кыяр орлыгын яки бака кабыгын бер мәртәбә авыру урынга тидереп, саннарның икенче юлын укыгач, як-якка берәр тапкыр төкерәләр. Минемчә, Гайшә Батман им-том итәргә оста бер хатынның исеме булса кирәк.

9. Христианнарның пасхасы алдыннан олы пәнҗешәмбе көнне авыл татарлары үлгәннәр хөрмәтенә бәйрәм итеп, коймак пешерәләр. Татарларның фикере буенча, бу көндә җаннар чыгып, кеше күзенә күренмичә йөриләр, имеш. Алар бу көнне, үлекләр булмасын дип, ат җикмиләр, хәтта атка камыт та кидертмиләр. Татарларда тагын бик кызык бер ышану бар: русларның юл чатларында баганаларга куелган тәреләре алдына салынган акчаны алырга ярамый, алса, тәре көчләп аның кулына керә яки авызына ябыша, имеш. Христианнар үзләренең тәреләрендә Алла тарафыннан кешеләргә бирелгән тойгы һәм сыйфатларны гәүдәләндерәләр дип белгәнгә күрә, алар (татарлар) иконаларны монголларның «Тәңре» (Алла) дигән сүзләреннән бозылып әйтелгән «тәре» сүзе белән атыйлар.

10. Йөкле татар хатыннары һавада очып бара торган убырны очып бара торган ут кыяфәтендә күрәләр икән дип ышаналар; убыр зарар итмәсен өчен, аңа миләш сәнәк белән сугарга кирәк, диләр, шуннан ул көл булып чәчелә, имеш. Татарны албасты баса башласа, басылуның уңайсызлыгыннан котылыр өчен, чәнчә бармакны селкетү җитә дип уйлый ул. Шуның белән албасты кача, имеш. Җен кагылган татардан яки татар хатыныннан җенне куып чыгару өчен, аларны күкерт яндырып, шуның төтене белән төтәслиләр. Моннан башка тагын авыруның өстенә дары сибеп, дарыга ут төртәләр; тагын аның ятагы астына балта яки башка бер тимер нәрсә салып куялар икән; болардан куркып җен, артына да карамыйча, татардан яки татар хатыныннан кача, имеш.

11. Татар кызлары, рус авылларында май чабу бәйрәме җиткәч, җеп эрли торган кабага утырып, таудан шуалар. Шулай итсәң, җитен нечкә, озын, ак һәм таралып тора торган булып үсә икән, имеш. Яшелчәләр, икмәкләр уңсын өчен, татарлар бакча яки кыр читәне казык башларына ат башы сөяге элеп куялар.

Монда хәзинәләр турында да әйтеп китик. Җиргә күмелеп озак яткан акчага дию пәрие ияләнә икән. Мондагы татарлар фикеренчә, алар үзләре дә җирдә күмелеп озак яткан акчалардан яратылалар, имеш. Хәзинә яткан җирдә дию пәриләре төрле кыяфәттә күренәләр һәм: «Ал мине, ал мине!» — дип кычкырып яталар икән. Им-том итмичә, ул хәзинәне алырга ярамый. Ырым болай була: дию пәрие татарга күренгән җиргә, төнлә чыгып, көл сибеп куялар, иртә белән көл өстендә

нинди хайван эзе барлыгын карарга баралар. Көл өстендә нинди хайван (эт, мәче яки кеше) эзе күренсә, шул урында шул ук хайванны корбан итәргә тиешләр. Шуннан соң инде хәзинәне алып була. Монда борынгы татарларның үзләренең ут-су аллаларына, үлекләргә, су ияләренә, өй ияләренә һәм шайтаннарга, эт, мәче һәм кешеләрне корбан итүләренә ишарә юкмы икән?* Татарлар, җиргә күмелгән хәзинә мәче кыяфәтенә кереп йөри икән, аны кулга кертү өчен «бисмилла» әйтеп, бер тибеп җибәрү җитә, диләр.

Җәй көне корылык булса, татарлар, яңгыр юклыкка кайгырып, яңгыр теләргә чыгалар; халыктан кайсыннан ярма, кайсыннан сөт, май, кайсыннан тоз җыеп алалар да, бер елга яки күл янына барып, яңгыр боткасы пешереп ашыйлар. Шуннан соң инде күлмәк-ыштаннары белән суда коеналар. Шулай иткәч, яңгыр була дип беләләр инде, бичаралар.

12. Әгәр дә татарның баласы җиргә егылса, шул урынга берәү яки ул бала үзе кайтып килә дә, балага берәр зарар килмәсен дип, шул җиргә кадак кага да бер савыт су сибә. Кайсылары балага: «Егылган җиреңә төкер», — дип киңәш кенә биреп куялар.

---

* Югарыда 1, 2 һәм 11 пунктларда әйтелгәннәргә караганда, боларга тагын үрдәк, ак каз (йорт кошларын), алма, йомырка, ботка (көндәлек ашларын) һәм атны (йорт хайванын) арттырырга мөмкин бугай, ахры.— *К.Н.*

# ТӨРЛЕ ХЕЗМӘТЛӘРЕННӘН*

## «ТАТАРЧА-РУСЧА ЛӨГАТЬ»ТӘН

### Ыслуглар

Урысча ыслуг дигәннәре безнең телебездә *иҗек* тәгаен кыйлыныр. Сүз яки кәлимә ыслуглардан тәркиб кыйлына[1]. Дәхи ыслуглар хәрефләрдән тәркиб кыйлынадыр. Урыс телендә гласный хәрефләр фәкать үзләре генә бер ыслуг була алалар, һәм алар белән икенче бер согласный хәреф кушылса, бер ыслуг буладыр. Урыс телендә бер ыслуглы, ике, өч, дүрт, хәтта җиде, сигез ыслуглы кәлимәләр бар.

### Ударение бәянында

Ике ыслуглы кәлимәләрдә һәм күп ыслуглы кәлимәләрдә бер ыслугны, гадәттә, кувәтләндеребрәк, сузыбрак, күтәребрәк яки басыбрак әйтәләр. Бу кәйфияттә[2] әйтелүне урыслар *слогоударение* дип атыйлар. Бездә вә безнең телебездә күбрәк, бәлки, һәркайчан ударение кәлимәнең ахыргы иҗегендә буладыр. Урыс телендә ударение буладыр бәгъзе сүзләрендә ахыргы ыслугда, вә бәгъзеләрендә ахыргы ыслугның алдындагы ыслугында, вә бәгъзеләрендә өченче, дүртенче ыслугларында буладыр. Һәм урыслар ударение булган ыслуг өстенә бер галәмәт куялар: бу лөгать китабына кергән сүзләрдә без һәм урыслар үзләре куя торган галәмәтне куябыз. Аларның бәгъзе кәлимәләре бар, бер рәвешле языла, әмма ударениесенә карап мәгънәгә дәлаләт[3] кыйладыр. Мондаен хосусларда алар ударение галәмәтен куймакны зарур күрәләр.

---

* 269—323 битләрдәге текстларны Гүзәл Насыйрова әзерләде.

[1] Тәркиб кыйлына — тора.

[2] Кәйфияттә — рәвештә.

[3] Дәлаләт — ишарә итү, күрсәтү.

# «ИСТЫЙЛЯХАТЕ ГЫЙЛЬМЕҺӘНДӘСӘ»ДӘН

## Кәгыб

Берничә шәкелдә тасвир кыйлынмыш җисем кәгыб аталыр ки, бу шәкелнең алты тарафы бардыр, һәр тарафы бер-беренә тигездер, вә һәр тарафы бер-беренә бәрабәр булучы дүрт зыйлгы[1] белән ниһаятләнмештер. Вә һәр ягының кырые оч вә түбә дип аталадыр, рәэс[2] дисәк  тә дөрес, шулай ук нокта дип аталыр. Янә җисемнең интиһасы[3] вә чиге сатых[4] аталадыр. Бәс, кәгыбның һәр алты тарафы аның өстедер. (Балаларга кәгыбны вә һәм һәрбер шәкелне күрсәтеп бәян кыйлыныр.)

Инде сатых дигәнебез яки сатых мөстәкыйм[5] булыр, нитәкки кәгыбның сатыхлары кебек. Яки сатых мөнхәни[6] булыр, шарның өслеге шикелле. Тигез өслекләр һәммәсе яссылык вә тигезлек дип аталадыр.

Яссылыкның кырые вә чиге хат[7] дип тәсмия кыйлыныр. Хат дигәнебез шулай ук хат мөстәкыйм булыр яки хат мөнхәни булыр. Сызыкның очы ноктадыр. Мәсәлән, очлы вә үткен карандаш белән ак кәгазьгә төртсәң, ул урында нокта заһир булыр, вә шуннан карандашыбызны бер тарафка тартсак, сызык заһир булыр. Бәс, мәгълүм булды ки, нокталарның тәркибеннән[8] сызык хасыйл буладыр. Бәс, моннан мөнтаҗ буладыр[9], хатның тәхәррегеннән сатых вә сатыхның тәхәррегеннән җисем хасыйл булыр, ягъни бу мәзкүр моталәгабызда[10] тавил[11] булды, гарыз[12] булды һәм гомык[13] булды. Болар җисем өлешләреннән иде. Инде бу җисем һәндәсә[14] дигәнебезне яхшырак аңлату өчен бер мисал китерәм. Мәсәлән, бер агач кисәген йомшак балыкка батырып, аннан янә чыгарып алсаң, мәзкүр агачыбыз күләмендә тишек калыр, бәс, җисем һәндәсә шулдыр, ягъни шул буш җирдер.

Һәрбер җисемнең өч мәсахәсе[15], ягъни өч тарафы бардыр ки: озынлыгы, яссылыгы вә һәм тирәнлеге. Әмма тирәнлек

---

[1] Зыйлгы — як.
[2] Рәэс — баш.
[3] Интиһасы — ахыры, чиге.
[4] Чиге сатых — өсте, яссылык.
[5] Сатых мөстәкыйм — туры яссылык.
[6] Мөнхәни — бөгелгән, кәкре.
[7] Хат — сызык.
[8] Тәркибеннән — кушылуыннан.
[9] Мөнтаҗ буладыр — барлыкка киләдер.
[10] Мәзкүр моталәгабызда — югарыдагы өйрәнүебездә.
[11] Тавил — озынлык.
[12] Гарыз — киңлек, иң.
[13] Гомык — тирәнлек.
[14] Һәндәсә — геометрия.
[15] Мәсахәсе — киңлеге.

дигән сүз урынына кайчакта калынлык дип әйтсәк тә дөрес. Яссылык дигәнебезнең ике киңлеге бардыр ки, озынлык вә яссылыктыр. Мәсәлән, ишегалдын яки бакчаны үлчәгәндә, фәкать озынлык вә яссылык кына игътибар кыйлынадыр.

Ноктаның һичбер киңлеге юктыр. Озынлык, яссылык, тирәнлек анда сурәтләүче түгелдер. Инде нокта дигәнебез югарыда бер мәртәбә әйтелгән булса да, янә тәкрар: нокта, диерләр, кәгазь өстендә яки такта өстендә бер очлы нәрсә белән, яки карандаш белән, яки каләм белән төрткәч калган эздер. Вә хат дигәнебез бер сызыктыр ки, нинди корал башы белән булса да бер тарафка тарткач калган эздер. Яссылык һәрбер җисемдә бардыр. Әмма һәрбер җисем һәндәсә җисеме табигый булыр вә ля билгакес[1].

## «ЛӘҺҖӘИ ТАТАРИ»ДАН

### Мөкаддәмә

Россия мөселманнарыннан мәгъруф вә мәшһүр хадиме лисане татар Габделкаюм әл-Насыйри әйтәдер ки: «Ләһҗәи татари», ягъни татар телебездә булучы әлфаз вә кәлиматның[2] тәрҗемәседер ки, ул әлфаз вә кәлимат ике төрле булып, берсе — асыл татар ләфызларыдыр вә икенчесе — гарәп вә фарсы теленнән алынмыш кәлимәләрдер. Мәсәлән, диянәт вә әхлакка мөтәгалликъ фәннәрнең истыйляхлары[3] вә гомуми риязиягә мөтәгалликъ фәннәрнең истыйлях кәлимәләредер ки. Аларны телебездә йөртмәк зарурдыр. Бәс, инде татар теленең мөбәдә’е вә мөнәшә’е хакында берничә бәян кыйлаек.

Иң элек бу тел Нух галәйһиссәламнең Йәфес исемле углыннан садир[4] булмыштыр ки. Йәфеснең Төрек исемле углы бар иде. Төрек балаларыннан дәхи Татар исемле бер угыл вөҗүдкә килеп, татар нәселе аннан садир итмештер. Шөйлә ки, төрек нәселеннән Угыз хан дигән бер кемсәнә бар иде. Әүвәле бу тел аңа нисбәт кыйлынып, «Угыз хан теле» дип сөйләшерләр иде. Җәмигъ төрек таифәләренең тарихлары Угыз ханнан башланадыр. Янә Уйгур дигән бер мәшһүр кемсәнә булып, Угыз таифәсенә табигъ[5] иде ки, төрек олысларыннан бер мәшһүр олыс иде. Ошбу Уйгур Һинд тарафыннан хөруф һиҗа һәм китабәт әхез кыйлып[6], төрек олысларына укырга, язарга өйрәтеп,

---

[1] Ля билгакес — киресенчә түгел.
[2] Әлфаз вә кәлиматның — сүзләрнең.
[3] Истыйляхлары — терминнары.
[4] Садир — барлыкка килү.
[5] Табигъ — буйсынган.
[6] Хөруф һиҗа һәм китабәт әхез кыйлып — алфавит һәм язу алып.

телләре мәшрикъ төркиләре арасында могтәбәр булмыш иде... Хәзердә бер китап бар, ләкин басылганы юк бугай. «Нәһҗел фәрадис» диерләр. Кадим уйгур теле белән үзрә язылып, соңыннан чыгтай теленә тәрҗемә кыйлынмыштыр.

Бәс, угыз теле белән китабәт вә язулар языла башлагач, төрек кавеме гарәпләргә итбага хәрәкәт максураны измара язарлар иде. Ягъни хәрәкәт хәрефләрен хәзеф кыйлып[1]. Мәсәлән, олуг (اولوغ) дигән кәлимәне الغ, карамак (قاراماق) дигән кәлимәне قرامق дип язарлар иде. Заманымызда кәзалик[2] кәлимәнең асылын белмәгән әфәнделәр *кәлде, кәтде, кәрәк, нәчә* язарлар — угыз кагыйдәседер. 700 нче тарихларында сәлҗүкыйлар монкариз булып, Госман Газый мөстәкыйль калганнан соң, госманлы халкының тәрбиясе белән тәрәккый тапкан телне госманлы теле аталмыштыр. Ул заманда телгә хезмәт итүчеләрдән мәгъруф вә мәшһүрләре: Мохлис Пашазадә, Гашый Паша, Гыйльван Чәләби, Шәйхи вә Әхмәд Бәйҗан вә һәм Сөләйман Чәләбиләрдер.

Уйгурлар хат вә китабәттә рәваҗ[3] табып, татар вә магулның Төркестанга галибәсеннән[4] соң Чыгтай ханның мәмләкәтләрендә җәмигъ мөхәррәрат[5] гелән уйгурча иде. Җиде йөз тарихларда чыгтай теле шаигъ[6] була башлыйдыр. Чыгтай — Чыңгыз ханның өченче углыдыр.

Ягъни Чыңгыз ханның дүрт углы булып, берсе — Үгәдәй хан, икенчесе — Бату хан*, өченесе — Чыгтай хан, дүртенчесе Һүләгү хан иде. Үз заманында мәмләкәтен дүрт углына тәкъсим кыйлып, Татарстанны вә Кытайны — Үгәдәй ханга, Кыпчакны вә Русияне — Бату ханга, Иранны вә Гыйракны, вә Әрменияне — Һүләгү ханга, Төркестанны, вә Хорәсәнне, вә Харәзмне Чыгтай ханга биреп, ул тарафларда сөйләнеп язылган телне «чыгтай теле» аталмыштыр ки, кадим уйгур теленнән мәншагыйб булмыштыр[7]. Алты йөздән тугыз йөз тарихына кадәр мәшһүр иде. Бәс, чыгтай теленә хезмәт итүчеләрдән: Латыйфи, Габидулла, Нәвои, Хөсәен Бикара, Хәйдәр мирза, Солтан Бабыр кебек мәшһүр мәснифләрдер ки, чыгтай теле аларның мәснәфәте белән мәгъмур булмыштыр. Бәс, мәгълүмдер ки, һәр адәм үзенең телен ислях кыйлмага[8] мәэмүрдер. Чөнки хәзрәти

---

* Бату хан — Чыңгызның оныгы (Җучы хан улы).

[1] Хәзеф кыйлып — төшереп калдырып.

[2] Кәзалик — шулай ук.

[3] Рәваҗ — таралу, уңыш.

[4] Галибәсеннән — җиңүеннән.

[5] Мөхәррәрат — язылган нәрсәләр.

[6] Шаигъ — тарала.

[7] Мәншагыйб булмыштыр — аерылып чыккандыр.

[8] Ислях кыйлмага — үзгәртергә, төзәтергә.

Гомәр димештер ки: «Сәмигъту Рәсүлуллаһу йәкулу Рәхимуллаһу, имраән ислях мин лисаниһи».

Татар вә магул кадим заманда икесе ике кавем вә телләре дәхи ике төрле тел иде. Озак заманнардан бирле бер-беренә катыша-катыша, хәзердә мәшһүррәге татар теле дип калмыштыр. Ләкин мәзкүр тарихтан да бу заманыбызга кадәр татар телемезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телемез артта, гаять бәгыйд[1] йоклап калмыштыр. Әмма татар телебезгә хезмәтче мин булаем дип, утыз биш ел уздырдым, ләкин күп мәгънә чыкмады. Төн-көн никадәр иҗтиһад кыйлсам, шулкадәр җәфа чиктем. Милләтебез халкын «татар» тәсмия кыйлсам — яратмадылар. Татар теле дисәм — яратмадылар. Вә янә ошбу «Ләһҗә» китабына телебездә булгучы нәбатат тыйббия исемнәре вә һәм әмрад[2] исемнәре әдхәл кыйлынадыр[3].

## «НӘМУНӘ ЯКИ ӘНМҮЗӘҖ»ДӘН

### Мөкәбир вә мөсагыйрь исемнәрнең кулланылышы

Рус телендә мондаен тасгыйр сыйгасы[4] вакыйган кечкенә булмаса да, бер нәрсәне сөеп вә яратып, вә һәм мәдехләп сөйләгән вакытта истигъмаль кыйлынадыр. Вә һәм бер нәрсәне мәсхәрә вә тәхкыйрь кыйлып сөйләгәндә мөкәбир формасы белән китерәләр. Шуның өчен рус истыйляхында мәдех өчен кителгән мөсагыйрьне (уменьшительное ласкательное слово.— *Авт.*) диерләр. Бер нәрсәне җумалап вә мәдехләп әйтә торган кәлимәдер вә һәм исем мөсагыйрьнең дә тәхкыйрь өчен истигъмаль кыйлынган маддәсе бардыр. Менә мәдех мәкамендә исем мөсагыйрьнең истигъмале Крыловның ошбу бәетләрендә: «Голубушка, как хороша! Ну что за шейка, что за глазки! Рассказывать так, право, сказки». Тәрҗемәсе: «Һай күгәрченгенәм, ниндәен һәйбәт! Кара аның муенгынасын, кара аның күзгенәсен! Сөйләсәң раст бер хикәядер». Әлеге җөмләләрдә *голубушка, шейка, глазки* дигән сүзләр ласкательное словолардыр. Мәдех мәкамендә зикер ителгәндер. Моның кебек гыйбарәләр бездә һәм бар. Мәсәлән, *күгәрченгенәм, абзыкай, дускай, җанкай, кашкынасы, күзгенәсе* вә гайреләре мәдех мәкамендә әйтелә торган кәлимәләрдер, нитәкки гавамның шигырьләрендә:

«Әгузү» белән «бисмилла»
Һәр китапның башкынасы;
Кара тузгак кебек ярылып ята
Мин аласы ярның кашкынасы.

---

[1] Бәгыйд — ерак.
[2] Әмрад — авыру.
[3] Әдхәл кыйлынадыр — кертеләдер.
[4] Тасгыйр сыйгасы — кечерәйтү формасы.

Дәхи рус бәетләреннән[1] бер бәетнең эчендә (какие перышки, какой носок, и верно, ангельский быть должен голосок) тәрҗемәсе: «Ниндәен нәфис аның җонгынасы, ниндәен аның борынгынасы, дәхи фәрештә тавышы кебек микән аның тавышкынасы!» Монда *перышки, носок, голосок* дигән исем мәсгыйрьләрдер. Мәдех мәкамендә зикер ителгәндер.

Моның кебек гыйбарәләр рус телендә бик күп, ягъни тасгыйрь ләфызы белән күп җирдә мәдехне ирад кыйлынадыр. Әмма мөкәбир формасы белән мәдехне ифадә кыйлган гыйбарәләр аз булса кирәк. Бу урынга лаек күренгән гыйбарәләрне китерәек: «Послушайка, дружище! Ты, сказывают, петь великий мастерище». Тәрҗемәсе: «Ишетәм, син дускай гына, сине әйтәләр җырга бик оста гына». Монда *дружище, мастерище* дигән сүзләр исем мөкәбирләрдер. Монда бу мөкәбир исемнәр бер нәрсә мактауны аңлатса да, мәкбир ләфызы күбрәк гадәттән тыш зур вә гаять тупас вә нәрсәләр хосусында әйтеләдер. Мәсәлән, *мужчина* дип тупас вә мужикны әйтерләр.

## «ХИСАПЛЫК» ДӘРЕСЛЕГЕННӘН

### Истыйляхат гыйльме хисап

Бу вакыткача гыйльме хисап фәнендә безнең үз телебез белән бер дә язылган китап юклык сәбәпле, терминнары да юк. Инде бу хисаплык дигән китабыбызда истыйлях сүзләре өчен мөмкин кадәр үз телебездәге сүзләрне сайладык. Мәсәлән, *хисаплык*, дидек. Бу гәрчә гарәпчә сүз булса да, аны белмәгән кеше юк. Бу хисаплык дигәнебез «гыйльме хисап» дигән сүз булсын. Вә янә *сан*, дидек, гарәп телендәге «исме гадәд» дигән сүз урынына булсын. Вә янә гыйльме хисапның бер кагыйдәсен *җыю* дип атадык, гарәпчә «җәмгы» дип әйтәләр. Вә янә гыйльме хисапның икенче кагыйдәсен *аеру* дип атадык, гарәпчә «тәфрикъ» диерләр. Вә янә гыйльме хисапның өченче кагыйдәсенә *сугу*[2] дип исем бирдек, гарәпчә «зарб» диерләр. Янә тагы дүртенче кагыйдәсе *бүлү* аталыр, гарәпчә исеме «тәксыймдер». Гыйльме хисапның мәшһүр дүрт кагыйдәсе ошбулардыр. Вә дәхи җыю кагыйдәсендә хисапка керәсе саннар *җыясы саннар* дип аталыр. Вә шул саннардан җыелган саннар гарәпчә «хасыйле җәмгы» дип әйтелер. *Сумма* дип әйтелсә дә дөрестер. Вә дәхи аеру кагыйдәсендә бер олуграк саннан кечерәк санны аерып чыгарыладыр ки, ул санны *киметәсе сан*, дип әйтәләр. Аерып алынган санны *кимetelгән сан*, дип әйтербез. Кечерәк санны аерып алгач калганын *калдык*, дип тәгъбир кый-

[1] Б ә е т — биредә: шигырь юллары.
[2] С у г у — хәзерге аталышы: тапкырлау.

лырбыз. Вә дәхи сугу кагыйдәсендә югары дәрәҗәдә *сугылмыш сан* дигәнебез гарәпчә «мәзрубен фиһи» дип аталыр, аның астындагы санны *суккыч сан*, диербез, гарәпчәсе «хасыйле зарб» аталыр. Инде бүлү кагыйдәсендә *бүленәсе сан* дигәнебез ничәгә бүленәсен күрсәтүче сан гарәпчә «мәкъсум» аталыр, лөгатебезчә *бүлүче*, диербез. Вә һәм бүлгәч хасыйл булган санны *пай* яки *хисса*, диербез, гарәпчә «хасыйле кыйсмәт» аталыр. Вә дәхи гыйльме хисап кагыйдәләрендә бер кагыйдәсендә телгә алына ки, *исемле гадәдләр* яки *үлчәү саннары* дип исемләнер. Мәсәлән, *пот, кадак, мыскал* исемнәре санга кушылып кулланылган кебек, яки *чакрым, сажин, аршын*, яки *көн, сәгать, дәкыйка* кебек исемнәр санга кушылып кулланылсалар, *үлчәү* саннары дию әүлядыр. Инде үлчәү саннарын вакландыру дигәнебез гыйльме хисапта бер кагыйдәдер ки, бөтен саннарны вакланмаларга әйләндерү диюдер. Вә шулай ук үлчәү саннарын кайтару дигәнебез вакланмаларны бөтен саннарны вакланмага кайтару димәктер.

## Гыйльме хисап ниндәен гыйлемлектер

Бу гыйльме хисап голүм риязияттән бер фәндер ки, гыйльме хисапка тулысынча ия булган кеше әгъдад мәгълүмәдән[1] мәҗһүләт гадәдияне[2] истихраҗ кыйлмага[3] кадәр булыр вә дәхи гыйльме хисапның мәүзугы маддәдә хасыйл булучы саннардыр, ягъни үлчәү саннары димәгебез кебек саннардыр.

## Әгъдад вә саннар бәянында

Бу ни-нәрсә дип сораган вакытта, җавап бирәсең ул нәрсәнең исеме белән атап: мин каләмне тотып, бу ни-нәрсә, дип сорасам, сез җавап бирәсез, ул —каләм, дисез, ягъни мин сораган нәрсәнең исемен әйтәсез. Инде мин, берничә каләмне кулыма алып, монда ничә каләм, дип сорасам, сез миңа ничек дип җавап бирәсез. Әлбәттә, әйтәсез: ике каләм йә өч, яки дүрт, дип. Әгәр бер йә ике дип җавап бирсәгез, «ни»нең исемен атап җавап бирдегез. Инде монда бернәрсәнең исемен дә әйтмәдегез, бары сан исемен генә әйттегез.

*Сан* дигәнебез һәммәсе бертөрле вә бер җенестән булган нәрсәне саный торган сүздер, ягъни ул һәммәсе бер җенестән булган саналмыш нәрсәнең чамасын белдерә торган сүздер. Инде әгәр мин, ике, дип әйтсәм, башка сүзне бер дә катыштырмасам, мин санның исемен әйтәм бары. Бер һәм сан, ике һәм

---

[1] Әгъдад мәгълүмәдән — билгеле саннардан.
[2] Мәҗһүләт гадәдияне — билгесез саннарны.
[3] Истихраҗ кыйлмага — чыгаруга.

сан, өч һәм сан. Һәркайсы саннар һичбер нәрсәгә, һичбер сүзгә кушылмаганда, үзалдына гына алар бар нәрсә түгел, бары берсен нәрсәне санаган чагында гына кулланылалар. Мәсәлән, бер каләм, ике китап, өч тәрәзә. Әмма һичбер сүзгә кушылмаганда да без аларны әйтә алабыз, аерым, үзалдына. Ләкин ул саннарны әйткәндә, бер-бер нәрсәне күңелдә тотабыз. Мәсәлән, мин сорасам: «Шәкерт ничә?» — дип, син әйтерсең: «Унбиш», — дип, әмма «шәкерт» дигән сүз синең күңелеңдә торып торадыр.

## «ҖӘГЪРАФИЯ'И ГОМУМИЯ» ДӘН

Җәгърафия фәне һәр мөселманга белү важиб булганлыгы өчен «бисмилләһ» белән башладык. Җәгърафия фәне бөтен дөнья йөзендәге җир хәлләрен бәхәс кыйладыр. Җәгърафия дигән сүз юнан теленчә «җирне язмак» мәгънәсендә.

Җир — алма шикелле һава йөзендә йөзеп йөри торган бер түгәрәк нәрсәдер. Җирнең дүрт өлешеннән өчесен су каплаган, калган дүрттән бер өлеше коры җирдер. Җирнең һәр урынын яхшырак аңлар өчен, җирнең дүрт тарафына дүрт исем бирелмештер: бере — мәшрикъ, ягъни кояш чыгышы тарафы; икенче — мәгъриб, ягъни кояш баешы тарафы; өченче — җәнүб, ягъни төшлек тарафы; дүртенче — шималь, ягъни төн ягы. Кояш күренеп торганда, бу тарафларны белү җиңел. Әмма кояш булмаганда, болытлы вакытта яки төнлә бу дүрт тарафны тану күп вакытта җиңел булмайдыр. Бәс, шул сәбәптән, мәзкүр дүрт тарафны белү җиңел булсын өчен, компас исемле корал ихтираг кыйлмышлардыр[1]. Компас дигәнебез бер ящиктыр ки, эчендә стрелкадыр ки, аның бер башына магнит ташы сөртелгән буладыр. Аның бер башы төшлеккә, бер башы төнгә карыйдыр.

Җир иң әүвәле биш өлешкә бүленгән: Европа, Азия, Африка, Австралия, Америкага. Дөньяның бу кыйсемнәрен күрсәткән харита карта дип атала, әгәр дә җәеп күрсәткән булса. Әмма түгәрәкләп күрсәткәне глобус һәм көррә'и мөҗәссәм дип атала. Картаның һәм глобусның уртасыннан мәгърибтән мәшрикъка таба әйләндереп алган сызык хатты истива дип һәм экватор дип атала, ягъни кояш бар чагында күләгәсе юк һәм җирнең һәр ике тарафы бертигез җир мәгънәсендә.

Җәгърафия гыйлемен яхшырак аңлар өчен җәгърафия галимнәре җирне күрсәткән картаны һәм глобусны 360 градуска бүләләр, вә һәр градус унбишәр өлешкә бүленәдер, һәр өлеше бер милдер...

Җирнең шималендә бер полюсы һәм җәнүбендә бер полюсы бардыр. Глобусның өстеннән төньяктан көньякка таба сы-

---

[1] Ихтираг кыйлмышлардыр — уйлап чыгарганнардыр.

зылган сызыклар меридиан дип, ягъни төшлек сызыклары дип атала. Фиррә(?) җәзирәсе[1] аркылы үткән меридиан әүвәлге сызык дип хисаплана. Фиррә җәзирәсе Африкада экватордан төньякка таба карап килгәндә 27 нче гарыз (киңлек) төньякта Канар утраулары дигән утрауларның берседер ки, җәгърафия фәнендәге галимнәр, карта ясаганда, һәркем ясаган карта бердәй булсын өчен, шул җәзирәне килешү белән сайлаганнардыр. Югыйсә һәр олуг мәмләкәтләрнең йолдыз гыйлемендә эшләү өчен корылган берәр биналары бар. Ул бина астрономическая обсерватория дип атала. Шундагы эшчеләр шул обсерватория тугрысын әүвәлге меридиан хисаплап йөртәләр. Мәсәлән, Русиядә Петербург янындагы Полков авылында астрономик обсерваторияне үткән сызыкны беренче меридиан хисаплыйлар. Әмма Фиррә җәзирәсеннән хисаплагач, Петербург 47 ярымтавил шәрыктадыр...

Меридиан белән меридиан ераклыгы тавил дип атала, ягъни озынлык яки буй.

Экватор сызыгы уңаена һәм һәркайсы бертигез ераклыктагы сызыклар параллель сызыклар дип атала, ягъни янәшә сызык дигән сүз.

Экватор белән бер мәгълүм параллель сызыгы арасындагы ераклык гарыз дип атала, ягъни аркылы яки киңлеге дигән сүз...

Җир һава җәһәтеннән биш өлешкә бүленәдер: икесе салкын өлешләр ике полюстан поляр сызыкларгача, икесе һава өлешләре.

Җирне түгәрәк йомгак шикелле дисәк тә, ике полюсы тарафыннан бераз сыгындылыдыр, алманың сабы белән чәчәк тарафы шикелле. Җир астына никадәр казып төшкән саен, кызулык градусы арта барадыр. Җирнең бәгъзе сыйфатларына караганда, җир бер эрегән заттан салкынаеп каткан нәрсә булмак кебек, диләр. Болай өсте катса да, эче, үзәге бөтенләй катып бетмәгән. Бу сүзнең дөреслеген янартаулар һәм аннан эреп аккан затлар күрсәтәдер. Бу китап бер мөкаддәмә, биш баб, бер хатимә үзәренәдер.

## Көнчыгыш тарафы губерналары

Мәшрикъ тарафы губерналары Волга иделенең түбәнге агымында биш губерна: Казан, Сембер, Самара, Саратов, Әстерхан губерналары. Әүвәлге икесендә имән, юкә агачы күбрәк. Калган ике губерна бөтенләй урмансыз дисәң дә булыр. Соңгы ике губернада яңгыр аз була, кыш карсыз һәм бик салкын, туфрагы һәркайда кара һәм иген өчен яхшыдыр, ләкин Әстер-

[1] Җәзирәсе — утравы.

хан губернасының гына җире комлы һәм тозлы. Әүвәл заманда диңгез төбе булган сәбәбеннән күп җирендә тозлы сазлар, күлләрдә камыш һәм кырку ачы үләннәр үсә. Тоз күлләре зурракларында тәүлегенә ун миллион потлап тоз хасыйл була. Халкының кәсебе — иген игү.

*Казан губернасы.* Җире 55 987 квадрат чакрым. Халкы 2 миллион 66 мең. Өязе — 12. Губерна шәһәре Казанка елгасы Волга иделенә койган җирендә, Казан исемле. Халкы 141 мең. Университет һәм православныйларның Духовный академиясе, мөселманнарның 24 мәктәп вә мәдрәсә, 15 мәсҗет, бәзкомач фабригы, күп күн заводлары, дары заводы, сабын заводлары белән мәшһүр. Иген һәм тире сәүдәсе белән мәшһүр. Казан тирмәннәрендә тартылган оннар аерым мактаулы. Әүвәлдә атлы, хәзердә электриклы вагон, электрик нуры, Кабан күлендә пароход йөри. Телефон, тимер юлы бу заман ихтирагатедер. Бишбалта слободасы белән төп Казан арасында буе өч чакрымлы, биеклеге җиде сажинлы дамба 1849 елда ясап ачылган. Чистай һәм Тәтеш шәһәрләрендә, әүвәлгесе — Кама елгасында, икенче — Волгада иген пристане. Казанда Кабан күле башында Архирей дачасының капкасы төбендә сәедзадәләрдән Мәхмүд бин Хәсән исемле зат-шәрифнең зиярәте әһле бәсыйрәт[1] килеп, истимдад[2] кыйлып, Кәлям-Шәриф укып багышлыйлар. Әһел әхалис күп файдалар күрәләр.

## «ЫСУЛЫ ҖӘГЪРАФИЯ'И КӘБИР»ДӘН

Мәмләкәтебездә берничә җәгърафия китабыннан моталәга кыйлып[3], башта дүрт-биш төпләп яздым, үз телебезгә килешә торган кәлимәләрне табып, җәгърафия истыйляхларын белдердем. Чөнки һәрбер фәннең үзенә махсус истиляхы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр. Безнең телебездә электән бу фәннәр язылa килмәгәнлек сәбәпле, урынына яраклы вә килешә торган сүзләрне табуы читенгә килде. Кемдә табгы сәлим[4] бар, ул беләдер ки, лөгать белән истыйлях арасында, әлбәттә, бер галяка[5] кирәктер, һичбер мөнәсәбәтсез бер сүзне истыйлях ясап булмый. Әлхасыйль, сабак саен бу таснифемнән аз-аз укып, дәхи үзебезгә язылган харитадан бәян кыйлып күрсәткәч, балаларның һәм күңелләрендә бу фәнгә рәгъбәт[6] барлыгы сизелде. Шушы

---

[1] Әһле бәсыйрәт — аңлы кешеләр.
[2] Истимдад — булышлык, ярдәм.
[3] Моталәга кыйлып — укып.
[4] Табгы сәлим — нормаль (кеше) табигате.
[5] Галяка — бәйләнеш.
[6] Рәгъбәт — кызыксыну.

рәвешчә, җәгърафия китабын тасниф итеп тәмам кыйлырга күңелем карар тотты. Галимнәрдән бәгъзе адәмнәргә моны укып һәм үз телебездә язылмыш хариталарны бәян кыйлып күрсәткәннән соң, «бу китапны халык укып туя алмас икән» дип, яхшы аваз бирделәр. Хәтта мондаен гыйлемгә рәгъбәте булган адәмнәрдән кайберләре, акка күчермәс борын, карасын алып-алып укыдылар һәм телләрендә «бәрәкаллаһ» сүзен әйттеләр. Әлбәттә, кеше башка телне никадәр яхшы белсә дә, мондаен фәннәрнең үз телендә булуы күңеленә артыграк кызыксыну саладыр. Вә бу китапны тасниф кыйлганда, кулымда һәр телдә унлап җәгърафия китабы бар иде, ошбуларны моталәга кыйлып, телебезгә туры килгәнен яздым. Мең дә сигез йөз дә җитмеш өченче елдан башлап, җитмеш җиденче елларда тәмам кыйлдым. Габделкаюм ибн мелла Габденнасыр әш-Шырдани.

Инде җәгърафия сүзе килде юнан сүзе булып, һәр телдә кулланыладыр. Җир йөзенең әхвәлен бәян кыйлучы бер фәндер ... Инде ошбу җәгърафия дигәнебез бер төрле гыйлемдер ки, җир йөзенең әхвәл вә кыяфәтеннән бәхәс кыйлыр, эчтәлеге, шиксез, җир йөзедер вә җәгърафия белүдән максуд...

## Зилзилә бәяны

Зилзилә вә җир хәрәкәтенең сәбәбе шулдыр ки, җир астында яшеренеп вә кысылып яткан диңгез икәненә җәмигъ әһле расыйд[1] бер сүздәдер. Шөйлә ки, бәхерләр, җир астында кысылып яткан вакытта, бер тишек табып, югары чыгар. Куәт белән атылып чыгуы сәбәпле, җирне селкетер.

...Әмма бу зилзилә күбрәк Азия кыйтгасында вә Америка кыйтгасында вакыйг буладыр вә күп шәһәрләрне вә авылларны харап итәдер.

## Мәгъдәннәр бәяны

Мәгъдәннәрне ике дәрәҗәгә бүләргә мөмкин. Берсе — металлар, икенчесе — хәҗәр[2]. Бу ике сүз арасында тәфрика бары гомуми, хосусый җәһәтеннәндер. Әүвәлге дәрәҗәдә мәгъдән диермез ки, аларның ут күренүчеллек хасыяте бардыр. Ялтыравыклы булып, утта эридер һәм тышкы җылылыкны үткәрәдер, вә электр утын үткәрәдер, вә һәрбер мәгъдән холкый вә һәм җәгъли[3] булуы мөмкиндер. Ягъни мәгъдән көенчә табылса, холкый, диерләр, әгәр адәм сәнгате белән ясалса, җәгъли, диерләр.

---

[1] Җәмигъ әһле расыйд — барлык астроном әһеле.
[2] Хәҗәр — таш.
[3] Холкый вә һәм җәгъли — табигый һәм ясалма.

Алтын — металлар арасында иң кыйммәтле металлдыр. Сары төсле булыр, әмма китапларда гүзәл вә матур мәгъдән дип китерелсә дә, кыйммәтенә күрә матур күренәдер. Бу алтын мәгъдәне бездә иң әүвәл мәртәбә 1745 елда табылгандыр. Алтын металларның авыррагыдыр. Чүкечне бик каплыйдыр, ягъни чүкечләп никадәр җәйсәң дә җәеләдер, ягъни йомшак мәгъдәндер, һәр ел Русиядә 645 пот чамасында алтын чыгадыр.

Көмеш — бик күптәннән булган металлдыр. Бу көмеш мәгъдән җир йөзендә көмеш көенчә, ягъни табигый көмеш вә һәм башка металл белән катыш булып, гамәл белән аерып алалар. Мәсәлән, кара кургашын, күкерт белән. Көмеш акча ясарга кулланудан башка, дәхи даруларга да китәдер.

Бакыр дөньяда бакыр көенчә вә табигый булып та табыладыр. Дәхи мәгъдәненнән гамәл остасы белән хасыйл итәдер. Электән мәгълүм нәрсәдер, хәтта тимердән элек тә мәгълүм иде.

Җиз — бакыр белән катыш бер металлдыр. Дәхи бакыр төрле мәгъдән белән катышып, төрле исем белән аталадыр. Мәсәлән, тунпак, бронза. Вә гайреләре кебек бакыр һәркайда бардыр.

Тимер — адәм өчен гаять файдалы нәрсәдер. Хәтта Кәлям-Шәрифтә «фиһә бәэс шәдид вә мәнафигъ лин-нәс» (якынча: кешеләр өчен каты, нык вә файдалы нәрсә) дип китереләдер. Вә һәркайда бер нәрсәдер — гамәл остасы белән балчыктан чыгадыр. Табигый тимерне җир йөзендә табылганын әйтмиләр, ләкин һавадан төшкән тимерләр буладыр. Санкт-Петербургта университетта бардыр, ике мең потка кариб.

Кара кургашын җир йөзендә күкерт белән кушылган хәлдә табыладыр. Яки үзенең хас мәгъдәне буладыр. Әмма кургашынны үзенең мәгъдәненнән эретеп аерып алалар. Кургашын күп урында кулланыладыр. Кершән вә ... (?) дигән буяу кургашыннан ясаладыр. Дәхи туп вә мылтык җәдрәләре, вә һәм җир астындагы су йөртер өчен морҗалар кургашыннан буладыр.

Ак кургашын ак хурашын ташы дигән мәгъдәннән эретеп алынадыр. Әмма кара кургашыннан җиңелрәк эридер. Бакыр савытларны вә тимер затларны агарталар, ак кургашын пыялага һәм катыштыр. Ак мич кирпечләре ак кургашын һәм пыяла белән эретеләдер. Вә таш савытларның ялтыравыгы пыяла белән ак кургашыннандыр. Ак кургашын Англиядә, Испаниядә һәм Һиндстандадыр.

Бәллүр дип үтә күренә торган тау пыяласы тәсмия кыйлыныр. Төре бик күптер. ... Швейцариядә, Франциядә, Венгриядә, дәхи Урал тауларында буладыр. Төсенә карап берничә исеме бардыр.

Фирүзә — асыл вә кыйммәтле ташлар җөмләсеннәндер. Йөзек кашларына, колак алкаларына, беләзекләргә вә кәмәргә

зиннәт өчен кулланыладыр. Табыла торган урыны күбрәк Һират тирәсендәдер. Кызылбаш халкы пычак сабына кулланадыр. Әмма ясалма фирүзәләр күп буладыр. Чын фирүзәдән аерып белергә бәгъзе тәҗрибәләр бардыр...

## «ИСТЫЙЛЯХАТЕ ҖӘГЪРАФИЯ»ДӘН

### Мөкаддәмә

Җәгърафиянең әһәмияте, ягъни заһид булып, тау тишегенә кереп ятмаган адәмгә җәгърафия фәненең кирәклеге бәянында бер мөкаддәмәдер. Аллаһы Тәгаләнең سيروا فى الارض дигән аятендәге әмер-кушуынча, бөтен җиһанны гизеп, һәр җирдә Аллаһы Тәгаләнең кодрәтләрен күреп гыйбрәт алмак һәрбер кешегә мөяссәр[1] булмаганлыктан, җәгърафия галимнәре ошбу фәндә күп китаплар яздылар. Бәс, җәгърафия китапларына күз салып укучы дәкыйка шинас[2] адәмнәр, җиһан гизүчеләр кебек, бер сулуда бөтен җиһанны сәйар вә тамаша кыйлалар. Бу хыялый бер сәяхәт була: сәйар үзенең ханәсендә диваны өстендә бу фән китапларын карап яткан хәлдә, гакылы вә зиһене белән әтраф галәмгә сәйар вә сәяхәт кыйлып, никадәр бик матур гыйлем хасыйл итәр ки, бөтен гомер сәяхәттә йөргән адәмнәр дә ул кадәр гыйлемне ала алмаслар. Чөнки һаман җәгърафия китапларына кире кайтып вә мөмарәсә[3] белән караганда, җир йөзенең өлешләре вә кыйтгалары[4], вә ул кыйтгаларның берберенә нисбәте вә мөнәсәбәте, вә форма-рәвешләре зиһен тактасына шулкадәр нык кереп урнаша ки, бер тарафны вә бер дәрьяны белергә хаҗәт булганда зиһен тактасына каралса, шунда ук ул тарафның матур , күркәм хәлләре гүяки күзең алдында күренеп торган шикелле булыр. Инде бер адәм, мәсәлән, үзе тора торган өенең әтрафларын, чикләрен вә күршеләрен белмәсә, өй эчендәге ишекләре, бүлмәләре һәм башка кирәк урыннары белән таныш булмаса, ул кемсәнәне кем гаеп итмәс? Әмма ошбу әшраф голүм булучы җәгърафия фәненә әшнә булмаган кешене әүвәле гаеп итмәк тиеш. Бакчы, гафил адәм икән, дип кайгырырга тиеш. Бәс, бер адәм әлеге фәнне булдырып, серләренә төшенсә, ул кемсәнәгә дөнья хәлләре тәмам заһир вә рәүшан булып, Хак Тәгаләнең искитәрлек ясалган вә таныш булмаган әйберләрен белер, вә сәфәр мәшәка-

[1] Мөяссәр — җайлы.
[2] Дәкыйка шинас — бик нечкә мәгънәләрне тиз аңлаучы.
[3] Мөмарәсә — тәҗрибәлелек.
[4] Кыйтгалары — кисәкләре.

тен чикмәенчә өендә ятып, галәмнең төрле якларын белеп, кулына аршин вә аркан тотмаенча ераклык вә якынлыкларны белеп, вә кайбер очракта төгәл серләргә төшенүче булыр.

## Мәмләкәт вә падишаһлык

Бер вилаятьтә[1], бер дәрьяда җыелып торучы халыклар бер низам вә әхкямгә[2] буйсынып вә урнашкан законнар буенча тереклек кыйлсалар, аны мәмләкәт дип атарлар. Бәс, бер кавем бер канун вә низам тәхетенә җыелмаенча, мәмләкәт һәйәтенә керә алмайдыр. Әмма тәдбир[3] Амур мәмләкәтенең кыяфәте вә рәвешенә караганда, мәмләкәтнең идарәсе ике төрле буладыр ки, бер мөстәкыйль падишаһның тәхет хөкүмәтендә булыр яки җөмһүр иттифакый хөкүмәтендә булыр. Бәс, мәмләкәтнең мөдәббире[4] вә мәмләкәтне биләп торучы төрле ләкаб белән аталадыр. Мәсәлән, әмир, солтан, хан, патша, хөкемдар вә һәм император дип исемләнер. Әгәр мәмләкәт җөмһүр иттифакый тәдбирендә булса, падишаһ урынына каим мәкам[5] булучы адәмне берничә елга мәмләкәт халкы тарафыннан сайланып куеладыр, диванханәдә садыр нишин[6] ул буладыр. Мәркәз — хөкүмәт, пайтәхет яки тәхет шәһәре, диерләр, падишаһ тора торган шәһәрдер; вилаять шәһәре яки мәркәз идарә, диерләр, бер вилаятьнең валие торган олуг шәһәрдер.

Ярты атау җәгърафия истыйляхында коры җиргә тоташкан тар гына җирдер, гарәпчә бәрзәх дип әйтерләр, әгәр дә бу муен дип аталса һәм җаиздыр.

## «ГЫЙЛЬМЕ ЗИРАГАТЬ»ТӘН

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Зирагать[7] — кәсепләрнең артыграгыдыр.

Иген икмәк, ашлык чәчмәк, зирагать итмәк — бары бер мәгънәдәдер. Иген чәчә торган җиребез мәнбәт[8] булмайдыр вә ашлык үстермәйдер, мәгәр үсемлекле урын буладыр, ул җиребездә аш күп булса. Чөнки ашлык чәчкән җирдә чәчкән ашлыкны

---

[1] Вилаятьтә — өлкәдә.
[2] Низам вә әхкямгә — тәртип (кагыйдә) һәм законга.
[3] Тәдбир — тиешле чара.
[4] Мөдәббире — башкаручы.
[5] Каим мәкам — урынбасар.
[6] Диванханәдә садыр нишин — дәүләт югары органының башында торучы.
[7] Зирагать — игенчелек.
[8] Мәнбәт — үсемлекле урын.

тишелдереп үстерергә вә, үстереп, орлык хасыйл итәргә җитәрлек ул җирдә аш булуы кирәк. Шиксез, һәрбер туфрак ашлык булдырмайдыр, фәкать су булучылык вә яңгырлар гына да җитмидер. Комга никадәр су сипсәң дә, ашлыкны үстермәс. Инде ашлык җиренә шулкадәр куәтне бирү өчен җирне тиресләмәк дигән гамәл бардыр вә җирне әслах кыйла торган матдәләр бардыр. Ашлык чәчә торган җиргә уңдырышлылык куәте бирүче матдәләр: азот, фосфор, калий дигән нәрсәләр. Ошбу матдәләр күп булган җирдә һәркайчан иген яхшы уңадыр. Әмма бу матдәләр аз булса, ул җирдә һәркайчан ашлык та уңмайдыр. Бәс, элек ашлык уңганлыкта ул җирнең уңдырышлылык куәте кимегәч, янә ул куәтне яңадан хасыйл иттерер өчен югарыда әйтелгән нәрсәләрне арттырырга хаҗәт буладыр. Аннан ары ул җир яңа куәт хасыйл итеп, һаман уңдырышлы вә ашлыкны уңдыручы буладыр. Әмма ул мәзкүр матдәләрне кайдан алыйк: нәрсәләр иген җирен яхшырткан, соңында һәммәсе табыладыр.

## Ихьяи әрыз[1]

Җир ясау, ягъни җирне ашлык чәчәргә салахиятле итеп яңарту вә ашлыкны булдырырлык дәрәҗәдә итмәк, ягъни җирне сукалау, йомшарту. Ай ярымда яки ике айда эшләп, җир тәмам чәчәргә салахиятле булып өлгерәдер. Җирнең шул дәрәҗәгә җитеп өлгерүе шуннан беленәдер ки, өлгергән җир карасыман төсле булыр һәм махсус башка бер төрле исе булыр, сука артыннан кабарып, күпереп калыр. Җир хосусында вә чәчү җирен сукалау хосусында ошбу кагыйдәне игътибарга алырга кирәк:

— беренчедән, юеш вакытта җир эшен эшләргә вә сукаларга кирәкмәс;

— икенчедән, буразна араларын чи калдырмаенча, еш сукаларга тиеш, шөйлә ки, буразнадан кубып чыккан кантарның киңлеге калынлыгыннан бер ярым өлеш артык булсын. Дәхи дә тырышырга кирәк: буразнадан кубып чыккан кантарлар чат аркасы белән әйләнеп төшмәсен, бәлки азрак кабыргасы беләнрәк ятсын. Әгәр дә сука белән сукаламайча, сабан белән сукаласаң, кубып чыккан кантарларны ватарга кирәк, әйләнеп төшкән көе калмасын;

— өченчедән, җир ясаганда, җирнең өстен сабан белән куптарып чыгарган кәзләрне әйләндерергә кирәк. Әгәр дә сука белән сукаланса, буразналарын бик янәшә сукаларга кирәк. Кәзне, кипкәч, себереп ваткларга кирәк;

— дүртенчедән, җирне әүвәл кат сукалагач та себермәк

---

[1] Ихьяи әрыз — җир яңарту.

хаҗәт түгел, таки сукалаган җирнең артык юешлекләре чыксын вә үлән тамырлары кипшенсен. Икенче кат сукалаганда карап, әгәр дә үлән тамырлары кипкән булса, дәррәү себерергә кирәк;

— бишенчедән, үләннәрне вә үлән тамырларын сукалагач та бетерергә кирәк. Коры вакыт булса, себерке йөртеп бетерерләр, әмма яңгырлы вакытта, сукалаган җирдә үләннәр вә үлән тамырлары бетсен өчен, җиңел генә өстән-өстән бер кат сукаларга кирәк;

— алтынчыдан, әгәр дә җәй коры килсә, каты сука белән чәчү арасында сукалаган җирне себергәндә бик вак итеп себерергә тиеш түгел. Шулай ук пар белән сабан ашлык чәчү арасында парлаган җирне себергәндә бик вак итеп себерергә ярамай, чөнки бик вак себергән туфрак өстенә, ихтимал, куәтле яңгыр яуса, җир тәмам тыгызланып вә тачкаланып утырыр, җир һаман эшкә килмәс, бары хезмәт әрәм китәр;

— җиденчедән, мөмкин кадәр җирне иртә сукаларга кирәк, таки җир чәчкән вакытка кадәр тәмам пешеп өлгереп торыр. Сабан ашлык чәчәсе җирне шулай ук иртә сукаларга тиеш;

— сигезенчедән, иген, ашлык чәчәр өчен җирне тирәнрәк сукалау тиеш, буразнаның тирәнлеге, һич булмаганда, 30 вершок булу кирәк.

## Орлык

Ягъни чәчәргә дип хәзерләнгән орлык ашлыгының яхшы сыйфатлы булуы киләчәк елда игеннең уңмагына бик олы сәбәптер. Бәс, шул җәһәттән, ашлыкны чәчәргә дип хәзерләгәндә яки сатып алганда, бик карап вә дикъкать кыйлып алмак тиеш, чөнки орлыкны, кирәк сатып алган булсын, кирәк үз гамәлеңнән хасыйл ителгән булсын, һичкайчан саф вә катышсыз булмайдыр. Бәс, чәчәргә мөмкин кадәр саф орлык куллану тиеш. Караганда саф кебек күренсә дә, чәчкәндә иләк аркылы үткәрергә тиеш. Әгәр дә сатып алган орлык тишелерме, тишелмәсме дип шөбһәле булса, төбе тишек чүлмәккә ком салып, юеш комда ул орлыкны үрдереп карарга кирәк. Яхшы булса, биш-алты көндә борнап чыгар, тишеләсе шуннан мәгълүм булыр. 100 данә орлыктан 85 яки 90 данәсе тишелсә, бик яхшы орлык дип әйтергә ярый.

## Хәсад

Ягъни урак вакыты. Ашлык өлгергәч, орлык данәләре туйгач, урырга вакыты җитте димәктер. Ләкин тәмам агарып орлык данәләре каткач, орлык тупсасыннан кубып коела башлый, моны көтәргә кирәкмәс. Ягъни ашлык өлгергәнлеккә галәмәт: саламында яшел җире калмас, башагы вә саламы ак булыр,

орлык данәләре хәзер генә каткан булыр — уру вакытыдыр. Аннан ары, орлыгы коела башласа, бәрәкәте китәдер. Орлык каткач, башакта никадәр торса, шулкадәр күлмәге калыная-дыр. Орлыкның күлмәге калынайса, көрпәсе күп чыгадыр. Камылда яшеллек булган вакытта, тамырдан камылга (сабакка) аш киләдер. Камылның һәрбер яшел әҗзасы орлыкка хезмәт итәдер, ягъни орлыкны туйдырадыр вә моның белән орлык зураядыр, үсәдер — ашлыкның орлыгы туйды, диерләр. Ашлыкның серкәсе вә чәчәге коелып тупсага утыргач та, орлык туя башлыйдыр. Шул заманга кадәр туядыр ки, камыл төптән яртысына кадәр саргаядыр. Ул вакытта тамырдан орлыкка бара торган аш киселәдер. Булса да — бары орлыкның кабыгын гына калынайтадыр, онга файдасы булмайдыр.

## Нәүбәт

Ягъни чәчү нәүбәте. Җирне тиресләп яхшыртканнан соң, әүвәл арыш уҗымы вә богдай уҗымы чәчәләр. Аннан соң сабан ашлыгы чәчәләр. Солыны вә карабодайны җир искергәчрәк тә чәчәргә ярый. Бу кыяфәттә бөтен кыр өчкә бүленәдер: арыш басуы, сабан ашлык басуы, кара басу яки такыр басу, диерләр. Хасыйле кәлям, җир ике җәй хезмәт итә, бер җәй ял итәдер.

## Арыш

Арыш йомшак вә мөлаем җирдә, тиресле җирдә яхшы уңа. Бәс, җирне тиресләгәч вә әслах кыйлгач, әүвәл арыш чәчәргә кирәк. Арышның берничә төре бар. Гадәти арыш, мәмләкәтебездә күбрәк ошбу арыш кулланыладыр. Башка төрләреннән аермасы шулдыр ки, бу арыш озынчарак вә һәм очлырак данәләрдәдер.

## Богдай

Богдай балчыклырак җирне яратадыр. Вә һәм җылылыкны яратадыр. Әмма богдайның дәхи төрләре күптер, хәтта 150ләп төре бар, диләр.Бу җирдә кулланылганы ошбулардыр: сандомирка, саксонка, гирка, арнаутка, кубанка, билаторка. Сандомирка дигәне — кылчыклы богдай, бик әрсез богдайдыр, һаваны да, җирне дә сайламайдыр.

## Солы

Ошбу солы ашлыгы һәрбер җирдә яхшы уңадыр, хәтта эшендә бик дикъкать кылуны да теләмидер. Күп вакытны начар җирне төзәтер өчен әүвәл мәртәбә солы чәчәләр. Юеш һавада гына түгел, хәтта чат яңгыр эчендә дә солыны чәчәргә мөмкин. Әм-

ма башка ашлыкларда бу эш юктыр. Нитәкки солы теленнән рус мәкале бар («сей меня в грязь, буду князь»). Солының иртәрәк өлгерә торган төрен чәчмәк тиеш, төрләре күптер.

## Хәшхаш

Мәк дигән нәрсәдер. Бу да бик йомшак җирне яратадыр, алай да ныграк җир кирәк. Йомшакта булып саерак чәчелсә яки комлык булса, мәк егыладыр. Шуның өчен алты-җиде вершок кадәр җиргә чәчелсә дә чыгадыр. Мәк чәчәсе җирне ошбу рәвешчә яхшыртырга кирәк: көз көне сентябрь ахырларында җирне сабан белән сукаларга кирәк. Тирәнлеге алты-җиде вершоктан ким булмасын. Аннан соң яз көне янә сукалап себерергә кирәк.Аннан соң мәк орлыгын иләнгән вак туфрак белән катыштырып чәчәләр. Бер дисәтинә җиргә биш кадак, алты кадак мәк орлыгы кирәк булыр, ләкин бик тирәндә чәчелмәсен. Мәк орлыгы тишелеп чыккач, куерак чыккан җирләрен йолкып ташларга кирәк. Чөнки бик куе булса, бер-беренә бәйләнеп егыладыр.

## Бакча вә сәбзәват[1]

Җимеш бакчасының туфрагын яхшыртмак вә түтәлләр төземәк. Бакчаның җимешен җыйгач та, киләчәк ел өчен көздән бакчаны хәзерләп калдырырга кирәк. Җимешен җыеп алгач, җирен яхшыртырга кирәк тирес белән яки башка нәрсә белән вә һәм бер кат сукалап калдырырга кирәк. Язга чыккач, янә җирне нәфис йомшартмак кирәк. Бакча җимешенең һәркайсы җире йомшак вә тирән булуны яратадыр. Дәхи түтәлләрен бастыртып, яраклы итеп төзергә кирәк. Әмма түтәлләрне биек ясарга тиеш түгел, мәгәр юешрәк җирдә булса, биеклеге зарар итмәс. Түтәлнең киңлеге аршын ярым булса җитәдер, түтәл таррак булса, чүп утарга уңай булыр.

Бәрәңге игәр өчен комлык вә җиңелрәк җир яхшы. Әмма бәрәңге һәрбер җирдә уңмайдыр, дәхи яңа тиресләгән җиргә дә бәрәңгене игәргә ярамай. Әгәр дә бәрәңге утыртыласы җир начаррак булса, ул җирне көл белән вә сөяк оны белән катыштырып әслах кыйлмак хаҗәт. Утыртыр өчен бәрәңгенең уртачасы кирәк. Әгәр эре булса, ярып утыртырга ярый. Шөйлә ки, һәрбер өлешендә күзе булырга тиеш. Әгәр ярып утыртасы бәрәңге булса, бер көн алдан ярып куярга кирәк. Таки кискән җире юеш булмасын. Бәрәңге тишелеп бераз үскәч, сука белән әйләндерергә кирәк, астагы яфраклары туфракка күмелсен. Иртә-

[1] Сәбзәват — яшелчә.

рәк күмелсә, бәрәңгесе күбрәк булыр. Бәрәңге суыктан курка, шуның өчен, суыклар була башлаганчы, бәрәңгене җирдән алырга тиеш. Аны салкынчарак идән астында яки яхшы базда сакларга кирәк. Дәхи бәрәңге чәчәккә йомарлангач, кайчы белән яки чалгы белән кыркырга кирәк, таки кувәте чәчәккә китмәсен.

## Кавын, карбыз

Бу үсемлекләргә күп җылы кирәк вә һәм болар бик акрынлык белән өлгерә. Шул җәһәттән безнең бу тарафларда кавын вә карбыз икмәк могтәбәр түгелдер. Кавын вә карбыз игүнең гамәлләре икесе дә бердер. Бәс, бу хосуста бары сүзне кавын белән йөртербез. Чөнки бу җирдә кавынны җылы җирдә игәләр, русча «парник» диерләр, пыяла астында үстерәләр. Кавынның астыннан алты вершоктан ким туфрак булмаска кирәк. Кавын борнап чыккач, яфракларын өзәләр, бары ике ботак калдыралар. Янә кабат яфракны азайталар, бары сигез данә ботак калмак тиеш буладыр. Кайчан ки кавынның җимеше күренсә, астына такта кисәге куярга кирәк. Бер төп кавында дүрт-биш данә җимештән артык булырга тиеш түгел. Кавынның җимешсез ботакларын кисәләр. Әмма парникта кавын өлгертмәк — зур мәшәкатьле эштер. Кавын татлы булсын өчен, җылы көннәрдә һаман саен өстен ачык тотарга кирәк.

## Бакча вә мивәһа[1]

Ягъни алмагач вә башка җимеш агачлары бакчасы. Алма вә төрле җиләк-җимешләр бакчасы яхшырту өчен могтәдил[2] биегрәк җир кирәк. Вә һәм төньяк вә көнчыгыш тарафларында химая кыйлучы[3] нәрсәләр булмак кирәктер. Мәсәлән, төньяк тарафында вә көнчыгыш тарафында тау яки урман булса, алмагач бакчасын суыктан саклыйдыр. Әгәр дә алар булмаса, бакчаның төньяк һәм көнчыгышына олуг үсә торган агачлар утыртмак кирәк. Алмагач вә гайре җимеш агачлары утыртасы урынның кара туфрагы, һич булмаганда, калынлыгы дүрт-биш вершок булмак кирәк. Әгәр дә ул микъдарда булмаса, тирес туфрагы белән калынайтырга кирәк. Гөл утыртырга хәзерләгән туфрак шикелле катыштырып йомшартырга кирәк, таки таш кебек яки кирпеч кебек нәрсә алмагач урынында булмасын. Әгәр дә начар җир булса, иген җирен әслах кыйлган шикелле әслах кыйлырга тиеш.

---

[1] Мивәһа — җиләк-җимеш.
[2] Могтәдил — уртача.
[3] Химая кыйлучы — саклаучы.

Агач утыртасы чокырны көз көне казып калдырырга кирәк. Чокырдан чыккан туфракны катыштырырга кирәкмәс, ягъни өстәге кара туфрагын үз алдына, астан чыкканын үз алдына куярга кирәк. Тирәнлеге аршын ярым, киңлеге ярты аршын кадәр итеп казырга кирәк. Әгәр дә чокырдан чыккан туфрагы аз булса, яхшы кара туфрак кирәк. Әгәр дә кара туфрагы артык күп булса, вак ташларны арттырырга кирәк яки акбур кушарга кирәк.

## Кыска агачны ни кыяфәттә саклау

Яшь агачларны кышкы суыклардан саклау өчен салам белән төреп бәйләргә кирәк яки камыш белән. Әмма агачның тамырларын ни рәвешле сакламак кирәк? Агачның тамыры өшемәсен өчен, алмагач тирәсендәге туфракны йомшартырга кирәк. Вә һәм алмагач төбенә салам ябарга кирәк. Дәхи кыш көне агачны тычканнан саклау өчен җепшек көнне алмагач тирәсен таптау кирәк, чөнки тычкан җир белән кар арасыннан йөридер. Вә һәм алмагачның көпшәсен дегет белән буярга мөмкин.

## Агач ялгамак

Алмагач ялгау төрле рәвештә буладыр, ләкин хәзердә мәшһүррәге ике төрледер: берсе — ялгау яки шүре кую, янә бер төрлесе — пар бөре кую дип аталыр. Ялгамак дигәнебезнең дә рәвешләре күптер. Әүвәл ике яшәр, өч яшәр алмагачны төптән бер карыш кадәр җирдән кисеп алалар, кыек итеп. Шүрене һәм кыек кисәләр, кара-каршы куеп,туз белән чорнап бәйлиләр. Яки туры кырт кисәләр, шүрене киртләп, шул төпкә ярып тыгалар. Ялгамакның гамәле моннан башка һәм күптөрле буладыр. Ләкин хәзерге көндә бу рәвешле ялгаулар бик сирәк кулланыладыр. Әмма бөре куймак шул рәвештәдер ки: әүвәл шул җәй үскән чыбыкны алма бирә торган алмагачтан бөресен кайрысы белән бергә куптарып алалар, эчке ягына кул тидермичә генә хәзерләп куялар. Аннан соң бөре куясы алмагачның бер ягыннан кайрысын аркылыга кисәләр, дәхи буйга таба да ярып төшерәләр. Бераз кайрысын күтәреп, кайры белән агач арасына тыгып, тышыннан туз белән чорнап бәйлиләр. Бөре дип әйткәнебез пар белән алмагачка ябышып каладыр. Әмма бөренең очын кайры астыннан чыгарып калдырырга тиеш. Алмагачны яз көне ялгыйлар, бөрене җәй көне куялар.

## Әмруд, өрек, чия

Әмруд җимеше шулай ук алма төреннән, бакчаларда тәрбия кыйлынадыр. Бу җимеш җирнең коры вә тирән һәм җылы булуын яратадыр. Әмма бу җимешне игү өчен комсыман кара

туфраклы җир кирәк. Моның һәм төрләре күп булса да, мәгънәсе бердер.

Өрек — слива дәхи әмруд кебек бакчаларда үсәдер. Вә ошбу җимеш өчен юешрәк авыр җир кирәк ки, ул балчыклы кара туфрак димәктер. Моның дәхи төрләре күптер.

Чия тәрбия кыйлырга нинди җир булса да ярый, ләкин кара туфрак азмы-күпме катыш булсын. Кара чия, кызыл чия.

## «ИРШАД ӘЛ-ӘТБИХА»ДАН

### Җиренә вә вакытына карап тәгам

Билгеле ки, тәне вә табигыяте таза кеше, үсемлек, хайваннар — һәркайсы ашыйдыр. Аның каршында һәркайсы бәрабәрдер. Ләкин эссе якларда тәгам өчен асыл, үзенчәлекле үсемлекләр яхшырактыр. Ягъни үсемлек җенесеннән булган ризыклар. Әмма өзлексез үсемлек тәгамы гына ашап тору яраклы түгел. Чөнки тоташ үсемлек ашлары ашау шәһвәтне өзәдер.

Салкын якларда хайван ризыклары яхшырак, өстенрәк күреләә. Безнең ошбу җиребез уртача тараф, үсемлек ризыклары белән хайван ризыклары катыш истигъмаль кыйлу яраклы.

### Тәгам микъдары

Билгеле ки, адәм угланнары ашарга артык хирыслардыр, хәтта ихтыяҗ кадәреннән һәм артык ашыйлар. Шул уңайдан ашаган тәгамнары тәмам сеңдерелеп бетмидер. Өзлексез күп ашап тереклек кыйлган кеше сәламәт тәнле була алмас, галибән[1] зәгыйфь вә кыска гомерлерәк булыр. Бер адәмгә бер ашарга бер кадак тәгам җитәрлектер, әгәр берәү үзенең гадәтенчә ашап күбрәк су эчсә, аш сеңдерүе зәгыйфьләнер. Бәс, аның зәгыйфьләнгәнен сизсә, бер көн, ике көн ашамый тору важибтыр.

### Ике тәгам арасы

Мәгълүм ки, ашаганннан соң мигъдәдә[2] тәгам, әлбәттә, сеңдерелергә тиеш. Вә аның өчен никадәр тормак кирәк, бәс, һәркемнең табигатенә ара бардыр. Гадәти һазымлы[3] кешегә тәгам һазымына 4 сәгатьтән 5 сәгатькәчә вакыт бардыр, ягъни ике тәгам арасы 4 сәгатьтән ким булмайдыр. Ләкин ашказаны бер әгъзадыр ки, бераз ял итәргә дә мохтаждыр. Ул тәкъдирдә ике

---

[1] Галибән — күбесенчә.
[2] Мигъдәдә — ашказанында.
[3] Һазымлы — үзләштерелүле.

тәгам арасы 6–7 сәгать булу кирәк, чөнки ашказаны бушагач та, дәррәү ашказанын тутыру аңа авырга киләдер. Әмма төнлә ашаудан сакланырга кирәк, чөнки бу вакытта ашказанына ике эш тиеш була ки, йокларга да кирәк, ашны сеңдерергә дә кирәк. Әмма тук корсак белән йокласаң, һичбер яхшы төш күрмәссең, һаман тәшвишле төшләр күрерсең. Гакыл эшләре белән мәшгуль кешегә тәгамны аз ашау тиеш, чөнки кайбер ризыкның үзләштерелүе авыррак булып, фикергә буталчыклык бирәдер.

## Ашауның мөддәте[1] вә кәйфияте

Ризык ашаучы кешегә авызына алган ризыкны озак чәйнәргә кирәк, таки җиңел үзләштерелсен. Чөнки озак чәйнәү белән тәгамга төкерек күп катышадыр ки, моны һазым әүвәл диерләр, ягъни ашаганда ризыкка никадәр төкерек катышса, шулкадәр сеңдерелүе җиңел буладыр. Әмма ашыгып, капыл-копыл ашаганда һазым әүвәл булмай, вә шулай ук ашыгып ашау мәмдух булмаган шикелле, бигрәк акрын ашау һәм макталмайдыр. Әгәр тәгам берничә төрле табактан бирелә торган булса, 35 минут ашарга кирәк, күп булса, бер сәгать кирәк.

...Ашаган вакытта гакыл рәхәт булсын вә зиһен һичнәрсә белән мәшгуль булмасын. Хәтта ашаган вакытта кайгы вә көенеч вә хафалык китерә торган сүзләрне бөтенләй сөйләшмәскә тиеш, чөнки күңеле һуш вакытта тәгам җиңелрәк үзләштерелә. Кайгы вә хәсрәт һазымга киртәдер.

Мәгълүм ула ки, ошбу китабыбызда 70ләп төрле ризык искә алына. Вә һәм үзебездә электән кулланылган ризыклар бәян кыйлыныр, аш осталарының күрсәтмәләренә таянып.

## Шеш кәбаб

Гадәти шеш кәбабы ошбу рәвешчә хәзерләнә. Әүвәл берике кадак яхшы сарык ите ал, калҗалап тура, әмма бик вак итмә. Аның катына вак итеп тураган суган куй, тоз, борыч сал, бераз дарчин сал. Аннан соң боларның барысын камыр баскан кыяфәттә кул белән бас, кат-кат угала. Берничә сәгать өстен ябып, бер җирдә тот. Ул арада суганны төеп, бер тастымал аркылы сыгып, суын хәзерләп куй. Аннан соң ул тураган ит кисәкләрен берәм-берәм яхшылап тимерчыбыкка тез. Мичтә утын ягып, утлы күмерләре генә калгач, бераз таркатып җибәр. Аннан соң чыбыкка тезгән итне утлы күмер өстендә әйләндерә-әйләндерә тот. Ит азрак кызара башласа, суган суын кашык

[1] Мөддәте — вакыты.

белән ит өстенә аз-аз сип. Һаман әйләндер, таки үзеннән чыккан шулпа үзенә сеңеп тәмам кәбаб булып җиткәч, ит табагына сыерып төшер. Бик йомшак вә куәтле бер нигъмәт булыр.

### Яшел эште

Әмма яшел эште дигән ашны кычыткannнан, яки кузгалактан, яки чөгендер яфрагыннан хәзерләргә мөмкин. Кайсы булса да, әүвәл бик арчып ю, аннан соң пешер, пешкәч, иләккә сал, суы саркысын. Бик вак итеп чап, бакыр савытка яки чүлмәккә сал, бер баш суган тура, бер кашык пешкән каймак сал. Дәхи бер кашык онны шулпага из, аны да сал, ике кашык май сал, ут өстенә куй, йомшап пешсен. Аннан соң алдан бер сәгать элек боларны һәммәсен шулпага сал, ашаганда каты пешкән йомырка һәм турап җибәрергә мөмкин.

### Пылау

Бу пылау дигәнебез рус пылавыдыр. Сарык итенең яхшы җирен ал, вак итеп тура, аны суда пешер, суган тура. Аннан соң майлы камыр яса, уклау белән җәй, бер табага сал. Дүрт йомырканы тугла, камыр өстенә сал, кайнар мичкә куеп тор. Йомырка пешкәч, мичтән ал, тураган итеңне, аның өстенә юка гына итеп җәй дөгене, май белән, йомырка белән катыш пешереп, ит өстенә җәеп сал. Шөйлә ки, бер кат ит, бер кат йомыркалы дөге булсын. Иң өстәге катлавы дөге булырга тиеш. Аның өстенә йомырка сөртеп, мичкә куй да, өсте кызарганчы торсын.

Пылауның төрләре күп. Мәсәлән, мич пылавы, казан пылавы, сусыз пылау, майсыз пылау, баданҗанлы пылау һәм башка төрләре бар.

### Хәлвә

Сигез йомырка агы, алты йомырка сарысы, ярты кадак шикәр, ярты чынаяк бәрәңге оны — боларны бергә тәмам яхшылап болгат, катыштыр, шөйлә ки, төере калмасын. Барысын бер катыргыдан ясаган тартмага уртача эссегә куй. Пешкәч, алып суыт, бер савытка сал, өстенә мөрәбба[1] сал, дәстәрханга[2] куй.

### Алма тәгамы

Бер дистә яхшы алма ал. Кабыгын, орлыгын арчы, ваклап кис, коры суда пешер. Суына азрак дарчин, канәфер сал, татлы булырлык кадәр шикәр сал. Алмалары тәмам пешкәч, алып

[1] Мөрәбба — кайнатма.
[2] Дәстәрханга — ашъяулыкка.

иләккә сал, суы саркысын. Алма пешкән шулпаны тастымал аркылы сөзеп ал. Янә кара өрек пешереп, алма белән бергә сай табакка сал. Кайнаган җиләк суы сибеп аша. Моны аннан соң хушаб[1] урынында китерергә мөмкин.

### Каймак мөрәббасы

Бу гаять ләззәтле мөрәббадыр. Хәтта моны белмәгән кешеләр дә бик күптер. Бик куе каймак ал һәм бер стакан каймак бәрабәренә ике стакан шикәр сал. Кәбаб чүлмәгендә кайнат. Бераз шоколад сал. Тәгам кайнап чыккач, таш савытка салып суыт.

### Мөрәбба карбыз кабыгы

Карбыз кабыгын ваклап тура. Зәрниҗ суына салып чылат, ике көн анда торсын. Аннан соң бик яхшы кат-кат итеп ю. Һәр мәртәбә юганда, махсус су белән ю, тәмам зәрниҗе чыгып бетсен. Аннан соң гадәти сироп яса, карбыз кабыкларын сал, ут өстендә пешер. Әмма карбызыңның тышкы кабыгын бик юка арчып ташла.

## «САНАИГЪ ГОЛФАНИЯ»ДӘН

### Хикмәт голфания

Хикмәт голфания дигәнебез бер фәндер ки, бу фәнне белгәннән соң җиз вә бакыр кебек нәрсәләрне, хәтта барча төр металлны җиңел юл белән вә утсыз алтынлау вә көмешләү мөмкин буладыр. Беренче бу гыйлемне Голфан дигән адәм уйлап чыгаргандыр. Шул җәһәттән голфан хикмәте дип аталды. Монда хикмәт шулдыр ки, голфан гамәленең әсәреннән зоһур итмеш бер төрле күвә'и кәһрабә'иядер вә тәэсир итүче бер куәттер, вә бу куәт кайбер тозларның измәсеннән хасыйл булыр. Әмма монда тоз дигәнебездән морад химия тозларыдыр.

Мәсәлән, күк куфаразны суга изеп, аңар яссы ике җиз кисәген батырып, ул җиз кисәкләрен тимерчыбык белән бә'ер голфания тәсмия кыйлынмыш. Электр көче чишмәсенә кушсак, шунда ук күрербез: электр билгеләнгән тимерчыбыкка кушылган җиз кисәге кими башлар. Әмма электр мәнфи[2] чыбыкка кушылган металлар үсәр вә калынаер, ягъни аңлатмасы будыр: куфараз суына эреп чыккан металл килеп электр юк ителгән

---

[1] Хушаб — компот, татлы су.
[2] Мәнфи — юк ителгән.

тарафына мөлясыйк[1] металл өстенә катлау булып утырыр. Бәс, ошбу хикмәт шөйлә бәян кыйлыныр ки: һәрбер химия тозы ике нәрсәдән тора: берсе — хәмузәт бер металлдыр, вә шулай ук яшел куфараз яки бакыр куфараз, фән теле белән әйтсәк, хамиз[2] милех[3] нәхас кибрите[4]. Дәхи алда әйтелгән хәмузәт белән нәхас металлдан торган. Электр голфаны кувәте белән мәзкүр хәмузәт нәхас металлдан аерыладыр. Электр вазгый өчен юка бакыр кисәге кулланыладыр. Бәс, күкерт кислотасы бакырны эретәдер, аннан тагы бакыр куфараз пәйда буладыр, шул сәбәпле бу куллануда бакыр кисәге дигәнебез кими вә юкара. Әмма икенче башындагы, ягъни мәнфи тарафындагысы үсәдер.

Хикмәт табигыя фәнендә зарбә'и голфаниянең әсәрен электр көче яки кыскалык өчен, шиксез, электр дип атала. Хикмәт голфания дигәнебез ни-нәрсәдер, югарыда искә алынган тәҗрибәне янә кабатлыйк: әмма мәнфи электр өчен бу хосуста бакыр кисәге урынына бакыр акча кулланырбыз. Вә күрербез ки: бакыр акча өстенә юка гына катлау бакыр үсәр, вә һәм бакыр акчаның чокыр җирләренә вә калкып торган җирләренә бәрабәрчә бер катлау бакыр үсәр. Вә аны бик акрын гына куптарып карасак, аңа акчадагы язулар һәммәсе төшкән булыр. Ләкин бары шул гакесе төшәр, ягъни кирегә таба төшәр. Бәс, ошбу соңгы заманнарда һәрбер металлдан мәгълүм булган нәрсәләрне алтынга, көмешкә вә һәм никельгә ошбу голфан юлы белән маналар.

## Голфан гамәле белән алтынга вә көмешкә ману

Голфан гамәле белән шөгыльләнүче әфәнделәр бакырлау һәм җизләү гамәлен белгәннән соң, алтынлау вә көмешләү гамәлен белсәләр дә, бик ят эш булмаса кирәк, чөнки берберенә якын эшләрдер.

Алтынлауның, металлга күрә, төрле юллары бардыр. Мәсәлән, көмеш нәрсәне алтынламакчы булсаң, әүвәл ул нәрсәне чистартырга кирәк, аннан соң хавызга[5] җибәрелер. Әгәр дә җиз яки бакыр нәрсәне алтынламакчы булсаң, милхемләмәк лаземдер. Әгәр тимер нәрсәне дәхи тутиядан, ак кургашыннан вә кара кургашыннан эшләнгән нәрсәләрне алтынламакчы булсак, әүвәл бакырламак, соңыннан милхемләмәк тиештер.

Инде алтынлау өчен хавыз хәзерләмәк хосусында кайнар юл белән мәслихәт күрәләр. Алтын өчен мәүсаль[6] да алтын-

---

[1] Мөлясыйк — янәшә урнашкан, тоташкан.
[2] Хамиз — кислота.
[3] Милех — тоз.
[4] Кибрите — күкерте.
[5] Хавызга — ваннага.
[6] Мәүсаль — тоташкан урын.

нан кирәк. Зарбә дигәнебез Даниилның ике элементыннан, кайвакыт дүрт элементыннан алынадыр. Инде алтын өчен хуз бу юл белән хәзерләнәдер: әгәр дә салкын хуздан хәзерләмәкче булсаң, мәслихәт будыр: егерме өлеш сары синельный калий, унбиш өлеш саф поташ, өч өлеш нашатырь мең өлеш суда изелә. Бу мәхлутны кайнатып, аңа тагын бер ярым өлеш хлористый алтын бераз суда изелеп кушылыр.

Әгәр дә кайнар хуздан алтынласак, мең өлеш суга унбиш өлеш сары синельный калий, биш өлеш поташ, ике өлеш нашатырь. Ошбу катнашманы кайнатып тондыралар, суыталар, аңа янә бер ярым өлеш хлористый алтын арттырып, тагын кайнаталар.

Туп-туры тимер нәрсәне алтынлау, ягъни башта бакырламайча: мең өлеш суда илле өлеш фосфорно-кислый натрий, унөч өлеш натрий күкерте, ике өлеш хлористый алтын, ярты өлеш сиян калий. Бу хузның җылылыгы илле-сиксән градус булырга кирәк.

Голфан гамәле белән алтынлаган нәрсәләрнең төсе саф алтын төсле булсын дисәң, мөмкин кадәр элементларның зарбәсен пропорциональ һәм тигез итәргә кирәк. Дәхи дә хуз да алтын тигез микъдарда булу кирәк. Әгәр зарбәнең кувәте чамадан артык кувәтле булса да яки хуз эчендә алтын кирәк микъдардан артык булса да, кызыл төсле булып чыгар. Әгәр микъдарыннан ким зарбә зәгыйфь булса да яки хузда булган алтын микъдарыннан ким булса да, нәрсәнең төсе күгелҗем булып чыгар. Зарбәне тигезләү мәүсальне түбәнрәк төшерү белән хасыйл булыр. Алтынның микъдарын тигезләү өзлексез хлористый алтынны арттыра тору белән хасыйл булыр. Алай булса да кайсыбер вакытта билкасд[1] кызылрак итәләр яки яшелсыман итәләр. Әгәр кызгылт итәем дисәң, хузга мусыл белән бергә бакырны да җибәр. Әгәр яшькелтрәк кирәк булса, мәүсаль янына бергә һәм көмештән җибәр. Әгәр алтынлаган нәрсәнең алтыны бозылса, төзәтергә мөмкин. Ул нәрсәне сиян калийны изеп, җылытып, нәрсәңне аңар салып асра.

Көмешләү ысулы. Моның өчен көмеш хуз хәзерләмәк кирәк: ... биш йөз өлеш йодистый калий, мең өлеш су. Ун минутта, күп булса утыз минутта көмешләнеп бетәдер һәм бик һәйбәт буладыр. Бу хосуста мәүсаль дигәнебез көмеш такта кирәк. Әгәр дә ул такта өстенә йод чыга башласа, һәм кушылмабыз ... төс алса, хузга жидкий калий изеп, тамчы-тамчы тамызырга кирәк. Әгәр көмешләнгән нәрсәнең көмеше килешмәсә, төзәтергә мөмкин яки көмешне яңадан алырга мөмкин.

Никельләмәк. Һәрбер металлны никель белән ябу мөмкин, ягъни бакырдан, җиздән, тутиядән, ак кургашыннан, тимердән, чуеннан эшләнгән нәрсәләрне һәммәсен никельләү мөмкин.

---

[1] Билкасд — алдан уйлап.

Кайсы металлны булса да никельләмәкче булсаң, бик яхшы тасфия кыйлырга[1] кирәк. Аннан соң хузга җибәреләдер мәүсаль дигәнебез, никель такта кирәк. Бакырны, җизне, ак кургашынны никельләгән вакытта бунзин элементларыннан ике-өч элемент васитасы белән зарбә җибәрелер. Әмма тимерне вә тутияне никельләгән вакытта янә артыграк гонсыр хаҗәт, чөнки боларга кувәтлерәк зарбә кирәктер.

Хуз никель. Җизне, бакырны вә гайреләрне никельләү өчен ...күкертле никель аммиак тозы ун өлеш, күкерт кислотасы аммиак тозы ике өлеш, күкерт никель амоний өч йөз өлеш суда изелә. Бу тозлар кайнар суда изелер. Әмма хуз салкын кирәк.

Янә тимергә, чуенга, корычка янә башка төрлерәк кушылмалар кирәк. Мәсәлән, ун өлеш күкерт әчесе тозы, бер ярым өлеш күкерт әчесе аммоний, ике йөз кырык өлеш су.

Никель хузы шулай ук башкалар шикелле гаять дикъкать белән хәзерләнәдер. Һәммәсеннән элек хуз мөтәвәссыйт булу кирәк, ягъни уртача булсын. Хузда булган катнашмабыз бик ачы да, бик йомшак та булмасын. Мәсәлән, әгәр дәлак мәүсале кәгазьне хузга тыксак, зәңгәр икән — кызармасын, кызыл икән — зәңгәрләнмәсен. Зарбәнең кувәтен хузда никельнең барлыгын тигезләргә кирәк. Әгәр дә хуз пакь булмаса, дәхи гайре заттан вә гайре металлдан кушылган нәрсәләр булса, күкертле натрий белән утырту кирәк. Инде әгәр дә никель җитәрлек кадәр калын утырсын дисәң, ул нәрсәңне никель хосусында һич булмаганда ярты сәгать тотарга кирәк. Хәтта бер сәгать һәм күп түгел.

## «МӘНАФИГЪ ӘЛ-ӘГЪЗА ВӘ КАНУНЕ СЫЙХХӘТ»ТӘН

Мәгълүмдер ки, тыйб[2] дигәнебез адәмнең җисеменә гариз булган[3] авыруларны белмәктән гыйбарәттер. Вә һәм ул авыруларны дәва кыйлып, адәмнең тәненнән чыгара белүдән гыйбарәттер. Әмма ул авыруларны бәян кыйлудан элек, гәүдә төзелешен белү тиештер. Ягъни һәрбер әгъзаның әҗзаларын[4] вә сыйххәт хәлендәге вазифаларын белү кирәктер.

Билгеле ки, адәмнең җисеме бик күптөрле өлештән торган бер аләттер. Һәрбер әгъза үзенең вазифасы белән мәшгуль хәлендә барлык әгъзаның интизамы[5] хасыйл булыр. Дәхи дә бер-бер сәнгать иясе үзенең ясаган нәрсәсенең төзелешен вә өлешләрен беләдер. Мәсәлән, сәгать төзәтүче сәгатьнең кыйт-

---

[1] Тасфия кыйлырга — пакьләргә.
[2] Тыйб — медицина.
[3] Гариз булган — очраклы килеп чыккан.
[4] Әҗзаларын — өлешләрен.
[5] Интизамы — тәртип буенча эш итүе.

галарын вә өлешләренең ничә икәнлеген белмәк, вә кайсы кыйтгасы кайсы урынга тиеш, вә ул кыйтга ни өчен мәүдугъ икәнен[1] белү сәгатьчегә важиб эштер. Шул кабилдән табиб та адәмнең гәүдә вә әгъзасы кыйтгаларын вә һәрбер кыйтгасының гамәлен белү тиештер. Бәс, табиб булды исә, галим тәшрикне яхшы белмәк лаземдер. Дәхи галим тәшрикне белсә, фән мәнафигъ әл-әгъзаны белмәк лазем, ягъни Аллаһы Тәгалә һәр адәмнең һәрбер әгъзасын ни мәнфәгать өчен яраткандыр, аны белмәк лаземдер. Бу ике фәнне белмәсә, табиб түгелдер, чөнки мәзкүр ике фәнне адәмнең тәнендә вә кайсы өлешендә авыру бар, вә һәрбер әгъзага ни рәвешле авыру барлыкка килә, вә һәрбер әгъзаның сәламәт чагында ни рәвештә буладыр да, авыру хәлендә ни рәвешле була, аны белмәсә, чыннан да авыру кешене сыйххәт дип хөкем итәр яки, киресенчә, вә мәга залик табиблыкны дәгъва кыйлса, үкенечле эшләр бетте, тәҗрибәле, оста табиблар калды. Надан алдакчылар ки, алар галимгә мозыйрлардыр[2] вә адәм балаларына дошманнардыр.

## «КАНУНЕ СЫЙХХӘТ»ТӘН

### Һава

Билгеле ки, һәрбер җан иясе өчен һава иң зарур нәрсәдер. Вә барлык хайванатның барлыгына нигездер. Вә һава барлык җисемнәрне әйләндереп алгандыр, вә һәр яктан җисемгә иминдер, вә кямиллек бирүчедер, вә һәрбер хайванның әгъзаи тәнәффесеннән[3] эченә керәдер, вә һава мөтәгайяр[4] нәрсәдер. Кайчак эссе, кайчак салкын, кайчак юеш, кайчак коры, кайчак бозык, кайчак саф вә нәфис һава буладыр. Адәмнең вә җәмигъ хайванатның тәнәффес юлыннан гына түгел, бәлки бөтен бәдәненнән эченә һава керәдер. Әгәр дә һава салкын булса, тирегә бик тиз мөәссирдер[5], чөнки һәрбер төк төбендә тишек бардыр. Һава тирегә гаять тәэсир итәдер. Тәнгә салкын һава тисә, тирне туктатадыр, бигрәк тә тирләгән вакытта. Дәхи вә җил, вә һава тирене кисәдер вә чыгасы тирне мәнигъ кыйладыр. Әгәр чыгасы тир чыкмай калса, күп авырулар пәйда буладыр. Мәсәлән: томау, күз авыруы, тамак авыруы, күкрәк авыруы кебек.

Дәхи җегәр[6] авыруы, эч авыруы вә илтиһаб[7] кебек авыру-

---

[1] М ә ү д у г ъ и к ә н е н — эманәт ителгәнен.
[2] М о з ы й р л а р д ы р — зарар итүчеләрдер.
[3] Ә г ъ з а и т ә н ә ф ф е с е н н ә н — сулыш органыннан.
[4] М ө т ә г а й я р — үзгәрүчән.
[5] М ө ә с с и р д е р — тәэсир итәдер.
[6] Җ е г ә р — бавыр.
[7] И л т и һ а б — шешү.

лар күп вакытны суык тиюдән буладыр. Шул сәбәпле тышкы һаваның тәэсире вакытында бик ихтираз[1] кирәктер. Суык тигән сәгате белән җылы кием киенеп тирләргә кирәк. Тирләгәч тә өстеңне салып ташлама, башыңны ачма. Өйдә ишеккә вә тәрәзәгә каршы тирләп чыкма. Үтеп чыккан җилдә торма, вә кичләрдә тәрәзә вә ишек ачык икән, ачык калдырма. Әгәр дә һава шулай ук бик эссе булса да, тәнгә бик тәэсир итәдер. Эссе һаваның бәдәнгә тәэсире шулкадәрдер ки, тирнең куәтен арттырыр, вакытсыз тир чыгарыр, кан савытларында мөттасил[2] кан тулып йөрер. Бигрәк тә эссе заманда борыч, зәнҗәбил кебек нәрсәләр, вә тозлы балык бик зарардыр, вә ит күп ярамайдыр, күбрәк үсемлекләр ашарга кирәк. Ләкин күкрәк авырулы кемсәнәләргә эссе һава яхшыдыр.

Әгәр дә һава коры булса, сулау авыр буладыр. Әгәр һава салкыннан кинәт эссе булып китсә, сәламәтлеккә гаять зарардыр. Әгәр дә һава юеш вә ратыб булса, бигрәк тә эсседә юеш тә булса, бәвел артык күп булыр, сулыш алу да мөшкел булыр, зәгыйфь күкрәкле кешегә вә барлык бәдәнгә зарары бардыр. Аеруча зәгыйфь табигыятьле кешегә мондаен һавада аякка кадәр кием кимәк тиеш. Эссе кояш астында озак тору да зарарлыдыр. Әгәр дә бозык һава булса, ягъни томанлы вә начар газлар гаять зарарлыдыр. Мәсәлән, базларда, коеларда бер төрле газ пәйда буладыр ки, җан иясе керсә үләдер, бер мәртәбә тәнәффескә форсат булмайдыр, хәтта бер аягы анда калса да үләдер. Яки сулап була алмаслык төтен эчендә адәм чыдамайдыр. Халык бик күп җыелып торган җирдә дә һава бозык буладыр. Сыйххәткә зарардыр вә дәхи мәгъдән тузаны, вә күмер тузаны да сыйххәткә зарардыр.

## Су

Билгеле ки, адәмгә иң файдалы эчемлек — саф судыр, чөнки эчемлектән башка тормыш мөмкин түгелдер. Су сусауны бетерер, тәнгә ротубәт бирер, һазымны җиңеләйтер. Әгәр су саф булмаса, зарарлыдыр. Суның яхшырагы агымсудыр, чишмә суыдыр. Яхшы суның исе вә тәгамы булмас, борчакны вә ясмыкны пешерер, вә сабынны эретер, күбекләндерер.

Әмма бел, суны тәсфия кыйлмак вә сафламак ошбу тарикча мөмкиндер ки, ком аркылы, мамык аркылы үткәрергә кирәк. Моның өчен махсус аләтләр[3] бардыр, суның гыйбарәләре анда каладыр яки кайнатып суытырга кирәк, эчәргә бик яхшы буладыр.

[1] Ихтираз — саклану.
[2] Мөтассил — өзлексез.
[3] Аләтләр — кораллар.

## «КАВАГЫЙДЕ КИТАБӘТ»ТӘН

*Ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кыйлучы бу бер яңа фәндер ки, бер сахиб әлфөнүн мөтәлага кыйлып, мәфһүменә төшенсә, ифадә'и шифаһиядә вә ифадә'и тәхририядә хатадан саклана белер*

Мәгълүм ула ки, һәрбер телдә китабәт вә язу дигән нәрсә хәрефләрнең бер-бере белән кушылуыннан хасыйл булган кәлимәләр вә гыйбарәләрдер. Вә әгәр башлангыч мәгънәсен игътибар кыйлынса, хәрефләрне бер-беренә кушып, каләм белән ул кәлимәләрне кәгазь өстенә китермәктән гыйбарәттер. Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөдәттә үгрәнгән теледер, икенчесе дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган телдер. Әмма сөт телендә безнең эшебез юк, чөнки бу кадәресе анасының эшедер вә атасы тарафыннан бер гафләттер. Инде шуңа бинаән замана балалары әлфаз вә әлкабның хикмәтеннән мәхрүм калмышлардыр, чөнки телләре гыйлем вә фән теле белән ачылмактан мәгъзүрләрдер. Олуглары гыйлемнән ләззәт алмаган булса, балалары ни белсен. Үкенеч өстенә үкенеч.

Инде мөхатәбәт шифаһиядә вә мөхатәбәт кыйльмиядә ниндәен маддәдә вә ни рәвештә әйтелмәк вә язылмак тиеш булган фикърәләр[1] белән үзеңнең морадыңны тыңлаучыга белдермәк вә фәһемләтмәк хосусында ригаясе лазем булган кагыйдә вә ысул үзә ифадә кыйлышмак вә дәхи китабәттә ни хәлдә вә ни рәвешле язылса, мәкъбуль вә мөлаем булачак, аны ригая кыйлмак гаять зарур эштер. Бәс, гыйбарәнең дә кимчелекләре булып, тыңлаучының колагына нәмөлаем ишетелердәй нәрсәләрдән ихтият кыйлып, мәкъбуль вә мөлаем кәлимәләрне истигъмаль кыйлмак гыйлем бәдигъ[2] хисабынча зарур нәрсәләрдер. Бәс, бу бер яңа фәндер ки, ифадә'и шифаһиядә вә ифадә'и тәхририядә телеңне вә гыйлемеңне хатадан саклар ки, бу фән ысул китабәт[3] тәсмия кыйлыныр. Ошбу рисалә берничә маддәдән гыйбарәттер.

### Гыйбарә

Гыйбарә диерләр телгә китермәстән әүвәл бер нәрсәне күңелдән фикер итеп, соңыннан телгә китермәктер. Димәк, зиһеннән бер нәрсәне уйлап, тыңлаучыга бәян кыйлуны ифадә'и шифаһия аталадыр. Вә бер нәрсәне зиһеннән фикерләп, соңын-

[1] Ф и к ъ р ә л ә р — параграф, абзац, аерым бүлекләр.
[2] Б ә д и г ъ — матурлык.
[3] Ы с у л  к и т а б ә т — язу ысуллары.

нан каләмгә китерүне ифадә'и тәхририя[1] тәсмия кыйлынадыр. Хосусән зиһендә уйлаган фикерне каләмгә китергәндә гарәп сүзен кулланмакчы булсаң, ул сүзнең мәгънә хакыйкыйсын эзләп, яраклы вә кирәкле мәгънәләрен куллан, таки тыңлаучың яки язмаңны укыган кеше шөбһәдә калмасын. Әмма зиһендә вә каләмдә гыйбарә тәртип кыйлмак сәһел[2] эш түгелдер. Бәгъзе вакытта бер сәтыр[3] язуны язганда, берәр сәгать уйлап торыладыр ки, мәкъбуль хәвас вә фәһем гавамга муафикъ булсын.

## Мәктүб[4]

Икесе ике мәмләкәттә булучы ике адәм арасында булган мохабәрат[5] вә тәблигатка[6] мөтәгаллик[7] бер язмадыр ки, телебездә мотлака хат тәсмия кыйлыныр. Әмма мәктүб җибәрүче вә җибәрелмеш кемсәнәләрнең дәрәҗәсенә күрә төрле исемнәре һәм булмак мөмкин. Мәсәлән, әмернамә, шикаятьнамә, вәрәка[8] вә гайреләре.

## Тәзкирә

Икесе бер мәмләкәттә торучылар арасындагы ифадә'и тәхририянең исемедер. Бу дәхи мәктүб сүзе шикелле җибәрүче вә җибәрелмеш кемсәнәләрнең дәрәҗәсенә карап, төрле сыйфат белән мәүсуф булырлар[9].

## Хата вә саваб

Мәсәлән, безнең телебезгә кергән гарәп вә фарсы ләфызлары җәмигъ икән, телемездә мөфрад мәнзилендә[10] истигъмаль кыйлынадыр. *Әүлиялар* вә *голямалар* дип *-лар* күплек сан кушымчасын үзебездән әлхак кыйлабыз[11]. Мәсәлән, *голямалар мәҗлесе* дип әйтәсе җирдә *голяма мәҗлесенә* дип әйтергә табигать рәва күрмидер, чөнки мондаен кәлимәләр тәмам үз сүзебезгә әйләнеп беткәндер. Инде бу кәлимә җәмигъ сыйгасы[12]

---

[1] Т ә х р и р и я — язу.
[2] С ә һ е л — җиңел.
[3] С ә т ы р — юл.
[4] М ә к т ү б — хат.
[5] М о х а б ә р а т — хәбәрләшү.
[6] Т ә б л и г а т к а — ирештерүгә, хәбәр итүгә.
[7] М ө т ә г а л л и к — бәйле.
[8] В ә р ә к а — записка.
[9] М ә ү с у ф б у л ы р л а р — ия булырлар, билгеләнерләр.
[10] М ө ф р а д м ә н з и л е н д ә — берлек сан урынында.
[11] Ә л х а к к ы й л а б ы з — кушабыз.
[12] Җ ә м и г ъ с ы й г а с ы — күплек формасы.

үзәдер дип, үземезнең әдәт җәмгыбезне[1] тарик кыйлып *голяма мәҗлесенә* дип язмак хатадыр. «Әнбияләр иясе җилдин тугмыш ирдия» дип бер китапта гыйлем заманыннан бирле языла килгәндер. Вә кәзалик *халаеклар* кәлимәсе һаман истигъмальдәдер. Дәхи әүвәл үз телендәге сүзләрне тикшерми торып, гайре телдән сүз истигарә кыйлмакны[2] хатага хәмел кыйлынадыр[3].

Хаһ ифадә'и шифаһиядә булсын, хаһ ифадә'и тәхририядә булсын, моннан сакланмак тиеш. Чөнки нигә дисәң, *табынмак* ләфызын кулланудан *гыйбадәт кылмак* дигән сүзне кулланылса, мең мәртәбә артык булыр иде, чөнки ләһҗәи Госманиядә: тапынмак вәсниюн[4] кеби бетә, тапмак килмештер.

## Изафә'и фарсия[5]

Шулай ук телебездә фарсы изафә мөстәгъмәл булмак җәһәтендән, изафә'и фарсия ахырында телемезгә махсус булгучы әдат җәмгымезне, әздад[6] кыйлып, *бәндә'и ходалар* дип әйтелмәс, дәхи сыйфатына кушылган гарәп сүзләре кулланылганда да җәмигъ галәмәте булгучы *-лар* хәрефен ялгап *хайванат вә хәшиялләр* дип әйтелмәс вә язылмас. Бәс, мондаен тәклифләргә[7] чумганча: *Хода бәндәләре-кызыл миләләр-вәхши хайванлар* димәгемез артыктыр вә фәсахәткә карибдер.

## Әдат җәмгы[8]

Вә җәмигъ галәмәте телебездә ике төрле булып, әлфаз татариянең мәхрәҗенә[9] карап, исемнәрдә вә фигыльләрдә гали әсвия язуда ригая кыйлынычак шәйләрдер. Мәсәлән, исемнәрдә тәфхим вә калын әйтелә торган кәлимәләрдә *-лар*, тәркыйк вә нечкә әйтелә торган кәлимәләрдә *-ләр* дип тәләффыз кыйлмак вә язмак тиеш. Киресенчә, мәсәлән, *куллар, аяклар, күзләр, йөзләр* кебек. Чөнки калыннан нечкәгә яки нечкәдән калынга әйтү, беренчедән, авыр, икенчедән, ишетергә нәмөлаем киләдер. Вә дәхи фигыльләрдә шулай ук калын әйтелә торган сүзләрдә, мәсәлән, үткән, хәзерге, билгесез киләчәк заман фор-

---

[1] Әдәт җәмгыбезне — күплек кушымчасын.
[2] Истигарә кыйлмакны — читтән алып куллануны.
[3] Хәмел кыйлынадыр — юраладыр.
[4] Тапынмак вәсниюн — тәрегә, потка табынучы.
[5] Изафә'и фарсия — фарсы изафәсе.
[6] Әздад — каршылыклар.
[7] Тәклифләргә — көчләп кушуларга.
[8] Әдат җәмгы — күплек кушымчасы.
[9] Әлфаз татариянең мәхрәҗенә — татар сүзләренең артикуляциясенә.

маларында: *бардылар, баралар, барырлар* кебек. Янә нечкә әйтелүче сүзләрдә: фигыльнең үткән, хәзерге һәм билгесез киләчәк заман формаларында: *киләләр, килделәр, килерләр* кебек. Ля билгакыс, вә шулай ук үткән заманның барлык I затларында җуан вә калын тәләффыз кылына торган фигыльләрдә күплек галәмәте к (ق) йомшак вә нечкә әйтелә торган кәлимәләрдә күплек галәмәте к (ك) хәрефе киләдер. Мәсәлән, *бардык* — *яздык* охшашлы вә дәхи *килдек* — *бирдек* охшашлы. Хәтта бу тәфрика масдарларыннан ук мәгълүмдер: *бармак, килмәк* шикелле, вә янә *килде, китде* дигән кәлимәләрдә *китде, килде, китерде* дип язмак хатадыр. Чөнки безләр, татарлар *килде, китде* дип сарыф[1] кәсрә белән сөйләшәбез. Вә шулай ук *ничә* вә *кирәк* дигән кәлимәләрдә халис кәсрә белән әйтәбез: *кәрәк, нәчә, ничук* язмак хатадыр. Янә бу заман язучыларының хата'и фәхешләрендәндер ки, *булды* урынына *улды* язалар. Телебездә *улды, улур* кебек кәлимәләр юктыр. Вә кәзалик *бар* урынына *вар, бирде* урынына *вирде* язмаклары сарфи хатадыр.

Бәс, мәгълүмдер ки, безләр, татарларыбыз, артикуляциягә мохтаҗ түгелләрбез, мәгәр әлфаз вә әлкаб бабында мохтаҗларбыз. Үзебезгә кирәк сүзләрне тапсак гарәптән алабыз, тапсак фарсыдан алабыз. Тапсак төректән алабыз, ләкин үз телебезнең нәхү кагыйдәләренә салабыз. Үзебезгә җитәрлек нәхүебез бар. Мәсәлән, бик мәшһүр *голяма* вә *әулия* вә *халаек* дигән кәлимәләр гарәптән алынып, үзләре күплек формасында булсалар да, аңар канәгать калмыйбыз. Күплек кушымчасын үз телебездән кушабыз. Мәсәлән, дәгъватнамәләрдә «үтенәдер насыйп булса фәлән-фәлән галимләр мәҗлесенә керем кылмагыңызны» дип язалар ки, бу бер дә хата түгелдер, мәгәр бу кәлимә тәмам үз телемездән булган бер кәлимә урынына төшкәндер. Зан[2] кыйлынмасын ки, белә язмак хатадыр. Әмма аның табигате тәказа кыйладыр[3] (бу сүзләремә канәгать калмаган кеше үз катыма рәхим итсен). Әмма ошбу актык сүзем хакында язсам, янә берәр бит сүз булыр иде. Зирәк адәм үзе дә фәһем итәр.

## Васыф тәркибе

Васыф тәркибе дигәнебез ике кәлимәдән мәркиб бер сыйфат димәктер. Әмма ошбу васыф тәркибе дигәнебезне бәян кыйлмастан мөкаддәм бер мәга риза китерәек ки. «Ысул китабәт» дигән китапта мәзкүрдер ки: «...кәлимә'и әүвәлнең хәреф ахыры вә кәлимә'и сәниянең хәреф әүвәле мөтассил язылган

[1] С а р ы ф — морфологик.
[2] З а н — ачык, анык.
[3] Т ә к а з а  к ы й л а д ы р — таләп итәдер.

хәрефләрдән булса, кәлиматин ләфыз вахид лисалли идекрә мөтассил язылыр вә кәлиматин хөруф мөтассилдән исә аеру-аеру китабәт улынур». Мәсәлән, мәзкүр бер китапның ошбу сүзеннән күренәдер ки, ул мисал итеп китергән васыф тәркибесе кәлимат төркиядән түгелдер, мәгәр фарсы теленнән алынмыш васыф тәркибеседер. Төрек теленә кергәннән соң да халәт Кадимәсе үзә калмыштыр, чөнки фарсы теле үзенә башка бер телдер. Кагыйдәсе һәм үзенә башкадыр. Төрек вә татар телебезне аңар кыяс кыйлып[1] булмастыр. Инде васыф тәркибе төркидән яки васыф тәркибе татардан — моны тәфтиш кыйлмак әүвәле татарча, мәсәлән, кызыл тышлы китап язылса, бер җаһил адәм моны ничек дип укырга да белмәс. *Кызыл* дигән сүзне *дөхтәр*[2] мәгънәсен ирад кыйлып, *ылтышлы* дигән сүзне табалмас.Әлфаз төркиядән билә бер васыф тәркибене дә тоташ язылса, мәгълүм түгелдер. Чөнки фарыз кыйлдык *җәүһәр герә нәкыйммәт* дигән сүзне бер фән күрмәгән кеше күрсә, *җәүһәр* дигән сүзне белер. *Герә* дигән сүзенә урын тапмас, *нәкыйммәт* сүзенең дәхи мәгънәсен белмәк. Бу кадәр мәшәкатьләргә дучар булганга, *җәүһәр герән кыйммәт* язылса, яхшырак түгелме? Һәр ни гыйндәбездә[3] аерым язмак уладыр: *кызыл тышлы китап, озын саплы пычак, көмеш саплы пәке, эре бизәкле әдрәк* язмак тиеш. Дәхи дә фарсы васыф тәркибе шулай ук *җәүһәр герән кыйммәт* язмак тиеш. Инде монда артык тәфсил хаҗәт түгел. Әмма ул әфәнде уйламыйчарак әйтәдер, һәркемне үзең кебек кямил дип исәпләргә ярамай. Дәхи сыйфат мәүсуф ошбу кабилдәндер. Хаһ хөруф мөтассил, хаһ хөруф мөнфәсыйлдән[4] булсын, аерым язылыр. Мәсәлән, *бәлягатьле каләм — баһадир адәм* дигән кебек. Әмма, әй угыл, васыф тәркибе дигән сүзнең мәгънәсен фәһем иттең микән. Инде билгеле ки, васыф тәркибе диерләр ки, мәзкүр булды.

## Тәзкир вә тә'нис[5]

Телебездә тәзкир вә тә'нис вакыйган юк булса да, му'әннәс хакыйкыйга сыйфат итеп китерелгән кәлимә му'әннәс сыйгасы үзә язылыр. Мәсәлән, *галимә хатын, гафифә хатын* дигән кебек. Әмма ахырында әлиф хәрефе булган татарча сүзгә сыйфат итеп гарәп сүзе китерелсә, му'әннәс кәлимә китер-

[1] Кыяс кыйлып — чагыштырып, тиңләштереп.
[2] Дөхтәр — кыз.
[3] Гыйндәбездә — каршыбызда.
[4] Хөруф мөтассил, хаһ хөруф мөнфәсыйлдән — кушылган хәреф, аерым хәрефтән.
[5] Тәзкир вә тә'нис — грамматик категория, ир һәм хатын җенесе (род).

мәк җаиз. Мәсәлән, *такта' и тавилә, тәртә'и касирә* дип әйтүебез дөрестер. Нитәкки *Азия'и вәсатый* (Урта Азия), *Африка'и җәнуби* (Көньяк Африка) әйтелер.

## Изафә'и фарси вә татари[1]

Мозаф илә телебездә фарсыча һәм мөстәгъмәлдер. Китапларда, мәсәлән, *кәлям Хода, бәндә'и Хода* вә гайреләр. Бәс, ят телдән алынган кәлимәләр һәммәсе аерым язылыр. Әмма татар телебездә изафә ике төрледер ки: телебездә бәгъзе изафәләр бар, ләфызында мозаф илә игърабы[2] заһир булмайдыр. Вә гяһа мозаф илә игърабы зикер кыйлынадыр. Сәбәбе телнең нәзакәтенә мөтталигъ зирәкләргә мәгълүмдер. Әмма кайсы кыйсеменнән булса да мөзаф илә аерым язылыр. Мәсәлән, *арыш оны, имән яфрагы, сарык тиресе.* Әлфаз татаридән изафә'и фарсия мөмтанигъдыр[3]. Мәсәлән, *аяк өстәл, ишек сарай* дип язылмас. Вә кәзалик бер ләфыз фарсыдан, бер ләфыз гарәптән изафә һәм мөмтәнигъдыр. Мәсәлән, *колак инсан, тырнак арыслан* дип язылмас. Инде мондаен артык тәфсил кирәк булса, «Нәхү» рисаләмнән карарсыз.

## Әдат сәлби[4]

Ягъни нәфи хәрефе[5] телебездә бар, вә бәгъзе маддәдә гарәптән, вә бәгъзе маддәдә фарсыдан алып истигъмаль кыйлынадыр. Үз телебездә мәүҗүд[6] хәреф нәфиләр ошбулардыр: *юк, түгел, -сыз.* Дәхи гарәптән: *ля, гайре*; вә фарсыдан: *нә, би* хәрефләре мөстәгъмәлдер. Әмма ошбу әдат нәфиләрне урынына күрә куллана белү тиештер: *юк* сүзе гарәпчә *ля* мәгънәсендә, *түгел* мәгънәсе гарәпчә *ләйсә* мәгънәсендә мөстәгъмәлдер. Дәхи *-сыз* дигән юклык кушымчасы гарәпчә *биля* урынында кулланыладыр. Мәсәлән, *гозерсез* дигән сүзебезне гарәпчә әйтсәк, *биләгозер* чыгар. *Кулсыз, аяксыз, күзсез* һәм ошбу кабилдән. Ошбу *-сыз* хәрефе кушылып язылыр. Вә кәзалик *түгел* хәрефе кушылып язылу хатадыр. Мәсәлән, *бай түгел* диясе урында *байтүгел* дип язылмас. Дәхи дә үз гыйбарәтебездә *дәгел* язмак хатадыр.

Әмма икенче җәһәттән кулланылулары «Нәхү»дә бәян кыйлыныр. *Ля* хәрефе *би* белән кушылып та вә ялгызы гына да

---

[1] Изафә'и фарси вә татари — фарсы һәм татар изафәсе.
[2] Игърабы — төрләнүе.
[3] Мөмтанигъдыр — тыелгандыр.
[4] Әдат сәлби — инкяр кушымчасы.
[5] Нәфи хәрефе — юклык кушымчасы.
[6] Мәүҗүд — булган.

кулланыладыр: *билә гозер, билә түбә; ляйагакыл, ляйәбәли* дигән кәлимәләр кебек. *Гайре* сүзе шулай ук юклык урынында *би–* хәрефе белән кушылып кулланыладыр: *бигайре хак, бигайре риза* кәлимәләре кебек. Дәхи фарсыдан алынган *нә–* хәрефе юклык кисәкчәсе урынында: *нәмәгкуль, нәмәшруг, нәмәхрүм, надан* кәлимәләре охшашлы. Янә фарсыдан алынган телебездә *би–* хәрефе бардыр: *бичара, билгакыл, бикәр* дигән кебек сүзләр.

## Кинаят[1]

Ошбу кинаяләр күбрәк төрек китапларында кулланыладыр. Мәсәлән, *мөшар иләйһи, мума иләйһи* (югарыда күрсәтелгән) — *мәзкүр, мәркум* дигән кебек кәлимәләрдер. Әмма *мәзкүр* сүзе телебездә күп кулланыладыр. *Мөшар иләйһи* дигән сүз зикер кыйлынса, олуг дәрәҗәдә булучы адәм морад булыр. *Мума иләйһи* дип ишарә кыйлынадыр, аннан алдынрак дәрәҗә иясе ирадә кыйлыныр. *Мәркум* ләфызы, гомумән, ул кадәр могтәбәр булмаган адәмнәр хакында әйтелер. *Мәзбур* (әйтелеп үткән) шулай ук түбән дәрәҗәдә булучы таифә хакында мөстәгъмәлдер. Әмма *мәзкүр* сүзе, һичшиксез, югарыда зикер кыйлынмыш нәрсә хакында әйтелер.

Искәрмә: әгәр дә язылмыш гыйбарәләрнең ибтидасында[2] бер кешенең исеме зикер кыйлынып, берәр җөмләдән соң башка бер исем тәхрир кыйлынса, сүз сөрешеннән *мөшар иләйһи* яки *мәркум* дип киная кыйлмак кирәк икән, ләкин кайсы икәне мөбһәм[3] булып тәгаен өчен *мөшар иләйһи фәлән* яки *мәзкүр фәлән,* яки *мәркум фәлән* дип исеме һәм зикер кыйлыныр.

## Зат

Зат дип әйтеләдер олуг вә кечек мәртәбә иясе вә могтәбәр адәмнәр морад булыр. Кемсә вә кемсәнә дип зикер кыйлынса, ля гали[4] адәмнәрдән бер адәм морад булыр. Мөзәккәргә, мөәннәскә мөсавидыр[5]. Әгәр шәхес дип зикер кыйлынса, сахиб кабәих[6] яки әдна[7] таифәдән булган адәм ирад кыйлыныр. Фәлән исемле адәм, фәлән исемле кемсәнә дип игътибарсыз адәмнәр хакында киная кыйлыныр.

---

[1] Кинаят — читләтеп әйтү.
[2] Ибтидасында — башында.
[3] Мөбһәм — аңлаешсыз.
[4] Ля гали — бөек булмаган.
[5] Мөсавидыр — бәрабәрдер.
[6] Сахиб кабәих — начар, әшәке дус.
[7] Әдна — түбән.

## Нәфир

Китапларда нәфир дигән кәлимә зикер кыйлынадыр. Әмма асылда нәфирдән «гаскәр» морад булыр, ләкин каринә[1] белән нәфир ләфызы адәмнәрнең махсус сыйныфлары хакында зикер кыйлыныр. Мәсәлән: *биш нәфир сәүдәгәр, өч нәфир шәкерт, ике нәфир табиб* дип сөйләшерләр вә язарлар.

## Баш-данә

Баш яки гарәпчә рәәс дип сөйләшерләр, хайванат әһле хакында күбрәк мөстәгъмәлдер. Мәсәлән: *бер баш ат, ике баш сыер, биш баш сарык*. Вә бал корты хакында, йортларын зикер кыйлып, *алты баш умарта*, диерләр. Әмма кошлар җөмләсеннән *бер данә тавык, биш данә үрдәк*, диерләр. Шулай ук ашамлыктан *ике данә алма*, вә гадәд (сан) сүзенең истигъмале кәзалик данә сүзе кебектер. Әмма телебездә *данә* ләфызы газиз булган нәрсә хакында мөстәгъмәл күренәдер. *Ике данә алмас, биш данә мәрҗән*, вә кәзалик *ун данә китап*. Вә дәхи әйтерләр ки: *аның бары бер данә.*

## Таифә

Таифә җәмәгать мәгънәсендә вә җәмәгатьтән бер җенесе морад булган вакытта изафә белән: *ирләр таифәсе, хатыннар таифәсе* дип тәгаен кыйлыныр. Вә дәхи «гөруһ» кәзалик бер төркем халыктан гыйбарәттер. Гяһа булыр ки тәкрар кыйлып: *гөруһ-гөруһ гаскәр*, диерләр, гаять күплектән гыйбарәттер. Вә бер сыйныфтан булган халыкның тәҗәммегыннан[2] гыйбарәттер.

## Кыйтга

Кыйтга сүзе галибән әнваг мәгадиннән[3], вә агачтан, вә сөяктән, вә таштан мәгъмул нәрсәләр хакында әйтелер: *бер кыйтга мылтык, биш кыйтга арба, ике кыйтга чана,* дәхи дә җирдән бер микъдарны һәм кыйтга белән тәгъбир кыйлыныр. *Аның бер кыйтга бакчасы бар; Азия кыйтгасы, җир йөзенең биш кыйтгасы; бер кыйтга җиребез бар, сигез подаука арыш керәдер.* Әмма җирнең микъдарын бәян кыйлучы кәлимәләр җиренә вә вилаятенә карап, төрле исеме бардыр: *ике имана*

[1] Каринә — сүз сөреше.
[2] Тәҗәммегыннан — җыелуыннан.
[3] Әнваг мәгадиннән — төрле җир асты байлыкларыннан.

*җире, ярым биш, бер кишәрлек.* Янә җир хакында татар сүзе *кисәк* дигән сүз кыйтга мәкамендә мөстәгъмәлдер. Дәхи кыйтга мәкамендә *парә* ләфызы һәм мөстәгъмәлдер.

## Кабза

Кабза — тотам мәгънәсендә. Телебездә сап мәгънәсендә дә мөстәгъмәлдер. Пычак кабзасы пычак сабы мәгънәсендә. Пычак, кылыч, балта кебек аләт җархидә[1] истигъмаль кыйлмак тиеш. Мәсәлән, *бер кабза хәнҗәр, биш кабза пычак, өч кабза кылыч* димәктер. Дәхи кабза тотам вә оч мәгънәсендә булып, *бер кабза чәчәк, биш оч богдай,* диерләр. Бер адәм, өч кылыч, сигез тавык дип язарга мөмкин булса да, әүвәле вафси булганы билә кирәк димәктер.

## Инша

Инша яратмак вә халык итмәк, тәгъмир кыйлмак, шигырь итмәк мәгънәләрендә булып, ошбу урында төзәтмәк вә тәгъмир кыйлмак[2] мәгънәсендәдер. Ләкин бер-беренә гатыф белән инша вә тәгъмир кыйлмак дип кулланылса әүләядер. Инша вә тәгъмир кыйлынмыш мәдрәсә, диерләр. Янә күперләр вә тимер юллар инша вә тәгъмир кыйлынды, диерләр. Әмма үзлегеннән яңадан эшләнсә, бина вә тәгъмир кыйлынмыш мәдрәсә, йорт, мәсҗет вә гайреләр.

## Фәсех

Фәсех итмәк вә бозмак кәлимәләре мөрәккәб[3] вә күп әҗзадан җәмигъ кыйлынмыш шәйләрне[4] мөтәфәрригъ[5] әл-әҗза кыйлмакта мөстәгъмәлдер: иске йортыбызны фәсех кыйлып вә бозып, яңа йорт торгыздык. Дәхи бу *фәсех* ләфызы онытмак мәгънәсендә.

## Шифа вә тиям

Китап телендә ошбу ләфызларның истигъмале: шифа эчтәге авырулар хакында, эттиям тыштагы авырулар хакында мөстәгъмәлдер. Мәсәлән, фәлән вакыттан бирле фәлән адәм күкрәк авыруы мөбтәля иде, бу көннәрдә шифа тапкан, имеш.

---

[1] Аләт җархидә — җәрәхәтли торган корал.
[2] Тәгъмир кыйлмак — төзәтмәк.
[3] Мөрәккәб — бергә җыелган, катлаулы.
[4] Шәйләрне — әйберләрне.
[5] Мөтәфәрригъ — аерылган, төрле.

Янә: үткән сугышта мәҗрух булган[1] адәмнәр гыйлаҗханәдә[2] дәва кыйлынып, эттиям тапмышлардыр, дип әйтерсең. Ля билгакес, нитәкки үз телебездә эчтәге авыру хакында *терелде* вә һәм җәрәхәт хакында *төзәлде* дип сөйләшәбез.

## Җеназа-мәет

Җеназа вә мәет сүзләре, һичшиксез, вафат булган адәмнең җеназасыз тәне морад булып мөстәгъмәлдер. Мәсәлән, кичә вафат булган фәлән адәмнең җеназасын бүген чыгардылар, диерләр. *Уләксә*, диерләр, кырларда вә чокырларда үлеп ята торган хайванның җансыз тәне морадтыр. Киресенчә куллану дөрес түгелдер.

## Җөрьәт-җәсарәт[3]

Бу гариза яки бер истидга[4] тәхрир иткәндә гыйбарәт. Арасында яки тәхрирнең ахырындан «зат шәрифләреңезне бимаза кыйлмага җөрьәт кыйлынды» дигән гыйбарә тәвазыйглыкка[5] мөнасиб булмаганлык җәһәтеннән бу урында *җәсарәт* сүзе кулланылса әүлядер.

## Тәшриф-газимәт[6]

Бер кемсәнәнең бер җиргә киткәнен яки китәчәген бәян кыйлганда, *тәшриф* ләфызы мөстәгъмәл булса да, барасы җире мәкам мөбарәк булган тәкъдирдә *газимәт* куллану яхшырактыр: фәлән кемсәнә Мәккә’и Мөкәррәмәгә газимәт кыйлды. Вә баручы адәмнең мәнзиләтенә күрә тәшриф кыйлды яки тәшриф барды, диерләр. Әмма җиребездә ошбу *тәшриф* ләфызын һичбер урынсыз кулланалар. Вә голяма таифәсе моңар һичбер игътибар кыйлмайлар.

## Дәфга-мәртәбә

Бу ике кәлимә әфгальдә мөстәгъмәлдер: *өч дәфга бардым, ике мәртәбә күрдем,* диерләр. Тәкрар кәзалик әфгальдә мөстәгъмәлдер: *тәкрар иттем, сабкыңны тәкрар кыйл*[7], диерләр. Дәхи мөтәгаддид сүзе әгъянда[8] кулланыладыр: *аның мөтәгаддид*[9] *китаплары бар,* диерләр.

---

[1] Мәҗрух булган — яраланган.
[2] Гыйлаҗханәдә — даруханәдә.
[3] Җөрьәт-җәсарәт — батырлык, кыюлык.
[4] Истидга — ялынып, үтенеп.
[5] Тәвазыйглыкка — әдәплелеккә.
[6] Тәшриф-газимәт — бару, юлга чыгу.
[7] Сабкыңны тәкрар кыйл — үткәндәгене кабатла.
[8] Әгъянда — югары дәрәҗәле кешеләрдә.
[9] Мөтәгаддид — күпсанлы.

## ت (тә) хәрефе

Телебездә гарәптән алынган кәлимәләрдә «тә» хәрефе урынына ة «тә мәрбута» язылыр: *җарият, дәфигать, кәсират* кебектер. Вә гайре урыннарда озын ت язылыр: *сыйфат, нигъмәт, рәхмәт, гыйззәт, хөрмәт* кебек кәлимәләрдер. Кәлимәнең ахырында нәфис кәлимәдән булган «тә» хәрефе нәсыб хәлендә гарәптән алынган көенчә «әлиф» язылыр. Әмма нәсыб хәлендә нәфис кәлимәдән булган «тә» хәрефе озайтып язылып, өстенә ике фәтхә куелыр.

## Әркян әрбәга

Әркян әрбәга'и китабәт[1] — ифадә'и тәхририядә мөбтәдигә[2] читенлек бирүче сәбәпләр вә сәһел кыйлучы сәбәпләр ошбу маддәдә бәян кыйлыныр. Инде әркян китабәт дигәнебез дүрт нәрсәдер: берсе — хәсән ибтида, икенче — тәхәллыс[3], өченче — хәсән таләб, дүртенче — хәсән интиһадыр[4]. Бәс, ифадә'и тәхририя белән бәян кыйлынган маддәнең кайбер гыйбарәләрен үти торган сүзләрнең вә мәгънәләрнең әүвәл җөмләнең әүвәл мәртәбә күз төшкәндә мөлаем, татлы сүзләр булып, бәлягатькә зарар бирүче әхвальдән мөбәрра булмак үзрә[5] тәртип вә тә'лиф[6] әйтелмәгенә хәсән ибтида, диерләр. Тә'лиф кәлямдә хәсән ибтида бәгъдендә киләчәк сүздән максудыңа дәляләт кыйлучы[7] бер мөлаем рабита белән мәтлаб асылыйга интикал[8] өчен ике сүз арасында иртибат булмакны тәхәллыс аталыр. Бу тәхәллыс тә дәхи максудка дикъкать назар лаземдер. Мәктүбтә языласы һәр шәй ни хосуста булса да, язучы кеше үзенең морад вә максудын әлхак вә дәгъва истихкактан[9] гари[10] булган хәлдә вә мәкаменә муафикъ бер сурәттә мөлаем сыйганә сүзләр белән үтәүгә хәсән таләб, диерләр. Кәляменең ахыры ... ниһаятенә кадәр бер минвәл[11] үзрә мөлаем вә фәсих булмакны хәсән интиһа, диерләр. Димәк, хәсән интиһаның нәтиҗәсе улдыр ки, мәктүбенең башыннан ахырына кадәр вакыйг булган

---

[1] Әркян әрбәга'и китабәт — язуның дүрт терәге.
[2] Мөбтәдигә — бер эшне башлап җибәрүчегә.
[3] Тәхәллыс — арыну.
[4] Хәсән интиһадыр — яхшы, күркәм ахыры.
[5] Мөбәрра булмак үзрә — пакь булу өчен.
[6] Тә'лиф — җыйнак.
[7] Дәляләт кыйлучы — күрсәтеп торучы.
[8] Рабита белән мәтлаб асылыйга интикал — бәйләнеш белән асыл максатка күчү.
[9] Истихкактан — лаеклы булудан.
[10] Гари — саф.
[11] Минвәл — үрнәк, тәртип.

ноксанатен сәтыр кыйлыр. Ләкин бу кадәр нечкәлекләр милләтебез халкында юк булса да, озак заман ихтималдыр ки, гыйлем вә фөнүннең тәрәккыйсына кайбер әрбаб гакыл[1] икъдам кыйлсалар[2] гаҗәп түгел.

## Мөшкел сәбәпләр

Ягъни тә’лиф кәлямдә мөбтәдигә мөшкеллек бирүче сәбәпләр биштер. Әүвәл — язучы булган адәм анасыннан сөт имгәндә белгән теленең кәлимәләре белән генә таснифка тотынмаклыгы. Дәхи ифадә’и тәхририядә кулланылучы гарәп вә фарсы сүзләрен белер-белмәс имля вә таснифында куллануы.

Икенчедән, каләмгә алынасы нәрсәләре ни хакында вә ничә маддәдән гыйбарәт илә әүвәл әмердә, якынча зиһенендә тасвир итмәенчә вә маддәләрен тиешле тәртип кыйлмаенча язарга тотынмаклыгы, ягъни анасыннан сөт имгәндә үгрәнмеш теле белән китап тасниф кыйлмага җөрьәт итмәклеге.

Өченчедән, бер хосуста бирелгән имляны тыңлап торган хиндә[3] зиһененнән башка нәрсәләр фикерләп, мәзмунын аңламаенча калмаклыгы.

Дүртенчедән, сәвадны[4] тасниф кыйлмага шөругъ итмәс борын тәртип гыйбарәттә вә тә’лиф кәлямдә ничек әйтим икән, ничек дип языйм, дип, күп фикерләп, белгәнен дә онытмаклыгы.

Бишенчедән, мөбтәди зиһенендә фикерләп яза торган нәрсәсен бер-ике юл язгач, кайтып, язганын тасхих кыйлмаклыгы[5]. Вә тә’лифе тәмам булганча кабатлавы. Инде язучы әфәнде ошбу биш халәттән котылса, эше җиңелгә әйләнер.

## Мәдар сөһүләт[6]

Язуда җиңеллекләр биш чара белән хасыйл булыр. Әүвәл югарыда бәян кыйлынган шул язучы булган кемсәнә фән күргән адәм булып, гарәп вә фарсы гыйбарәләренә төшенгән кеше булса, тиз яза, тиз фикерли икән, каләменең теле, зиһененең кувәи натыйкасы[7] хөкемендә булуы кирәк.

Икенчедән, имля сурәтендә ишеткән маддәләрен онытмас өчен, камил, сәламәт зиһен белән колак салып тыңлаганда, мөмкин мәртәбә зиһендә калдырырга тырышып тыңлау кирәк.

---

[1] Әрбаб гакыл — гакыл ияләре.
[2] Икъдам кыйлсалар — тырышсалар.
[3] Хиндә — вакытта.
[4] Сәвадны — укый-яза белүне.
[5] Тасхих кыйлмаклыгы — төзәтүе.
[6] Мәдар сөһүләт — җиңеллекләр юлы.
[7] Кувәи натыйкасы — сөйләү куәте.

Өченчедән, бирелгән имля күп маддәләрдән гыйбарәт булып, хәтердә тотар өчен бер кәгазьгә ишарәт белән язмактыр. Таки ишеткән маддә онытылмасын.

Дүртенчедән, яза торган яки имля кыйла торган кәгазьнең юллары кирәгенчә сирәк булу кирәктер.

Бишенчедән, бер маддәнең бәянын яза башлаганда, ахырына кадәр итеп максудыңны аңлаткан кебек ифадә'и тәхририядә дәхи бернәрсәне яза башлагач, ахырына кадәр язылып, хатасын төзәтү өчен, кире кайтып укырга тиеш.

## Тәнбиһ[1]

Әүвәл мәртәбәдә карага язып, соңыннан акка күчермәйчә, укымайча үзенең мәһарәтенә[2] һаман мәгърур торып, мөһерләп күндерелмәктән хата чыннан да булмаклыгына ихтимал сакланмак тиештер.

## Фикърә

Фикърә, диерләр, асылда адәмнең арка сөягендә булучы 12 санлы сөяктер ки, мөрәттәб вә монтазам[3] сурәттә барысына арка сөяге, диләр, һәрбер саны бер фикърәдән гыйбарәттер. Аннан алынып, тәртипкә салынган сүзләр вә җөмләгә әйтәләр. Фикърә тәртибендә кагыйдәсе ошбудыр ки, әүвәле белмәк кирәк. Фикърә, диерләр, мәгънәләре бер-беренә могайярь[4] кәлимәләрне бер җиргә җыеп, бер маддә хасыйл итмәктер. Соңыннан ничә фикърәләрдән торган җөмләләрнең тәртибендә дәхи соңгыны ригая лаземдер. Фикърә тәртибендә игътибарга алыначак кагыйдәләр җидедер.

Беренчедән, беренче фикърә белән икенче фикърә тигез булырга тиеш.

Икенчедән, ике тигез фикърә булмаганда, икенче фикърә элеккесеннән артыграк булачак.

Өченчедән, иң кыска фикърә дигәнебез ике кәлимәдән ким булмаска кирәк.

Дүртенчедән, фикърәләрдән аңлашылган мәгънә бер-беренә охшаган булмаска кирәк.

Бишенчедән, бер фикърә эчендә бер кәлимә кабатланмаска кирәк.

Алтынчыдан, фикърә ахырында сәҗгыгә[5] игътибар итәргә кирәк.

---

[1] Тәнбиһ — искәрмә.
[2] Мәһарәтенә — сәләтлелегенә.
[3] Мөрәттәб вә монтазам — тәртипкә салынган, төзелгән.
[4] Могайярь — үзгәртелгән.
[5] Сәҗгыгә — рифмага.

Жиденчедән, фикъра ахырында мөтәрадиф[1] булучы сүзләр рифмадан һәрбере бер формада булуына игътибар итәргә кирәк. Мисаллар ошбу хосуста телебездә булучы хәсән гыйбарәт белән: *мәхбүбеңнән килгән суган исе гайреләрдән килгән җофар исеннән хуштрактыр; аягының аклыгы, башмагының кызыллыгы; сурты төзек — күңеле бозык; һәркем мактаучы дустан вә яманлаучы дошманнан хали булмас; әйткән сүз — аткан ук, кире кайтмас; һәркем шәһвәтен үтерде, мөрәүвәтен тергезде; зарар китерүче хаклык шатлык китерүче батыйльдән хәердер.*

Рисаләбезнең ахырында янә яхшы фикърәләр язылса кирәк, аннан карарсыз.

## Җөмлә'и тәмма[2]

Фикарат мөсәҗҗәгъне[3] тәмам кыйлмак. Ике фикърә'и мөсәҗҗәгъне тәмам кыйлмакның җиңеләйтелгән шартлары бардыр. Фикърә'и мөсәҗҗәгъне тәмам кыйлып, ул бәйләнешебез ике фикърәгә дә мөлаем килә торган булса, җөмлә тәммә'и мәрбут тәсмия кыйлыныр. Әгәр ике фикърәнең икесенә дә мөлаем туры килмәсә, гайре мәрбут аталыр. Мәрбутка мисал: *һәркем мактаучы дустан, яманлаучы дошманнан хали булмас*. Ошбу тәркибтә булган фикърәләрдән әүвәлгесендә *дустан*, икенчесендә *дошманнан* кәлимәләре соңында *хали булмас* кәлимәсе һәр икесенә дә мөлаем кәлимәдер.

Янә бер мисал: *дәүләт вә гыйззәт эчендә вафат булмак хур-хәкыйрь булып тереклек иткәннән артыграктыр*. Ошбу тәркибтә дәхи әүвәлгесендә *булмак*, икенчесендә *итмәк* сүзе соңында *артыктыр* кәлимәсе һәр икесенә дә мөлаем килеп, бер җөмлә'и тәммә хөкемендә булды.

## Ихтар[4]

Әгәр ике фикърә'и мөсәҗҗәгътән гыйбарәт бер җөмлә'и тәмманың икенче өзекнең әүвәлендә булган сүзнең әүвәлге хәрефе «уау» булып, янә бер «уау» кушылса, дәхи зикер ителсә, укырга авыр вә каршылыклы булганга, башта соңгы фикърәне әүвәлге фикърә урынына күчермәк лаземдер. Бәгъзе ахыргы җөмләнең икенче фикърәсен беренчесе урынына китерү мөмкин булмаса, икенче фикърәдә иң элек «уау» белән башланган сүз урынына беренче сүзнең синонимын китерү белән янә мөш-

---

[1] Мөтәрадиф — синоним.
[2] Җөмлә'и тәмма — тәмамланган җөмлә.
[3] Фикарат мөсәҗҗәгъне — рифмалы өзекләрне.
[4] Ихтар — искәрмә.

кел мөндәфигъ[1] булыр. Фикърәдә мондаен эшләр сәнаигы бәдигадән[2] булуына нигезләнгәч, игътибар итү кирәк.

## Сәҗгы кыйсемләре

Әүвәлән сәҗгы, дип әйтерләр, нәсердә фикърәләрнең ахыргы хәрефе бертөрле булмактыр ки, чыгтай халыклырының һәр каюсында моның йогынтысы бардыр. Бәс, сәҗгы өч төрледер: сәҗгы мөтавази[3], сәҗгы мөтараф, сәҗгы мөтәвазян.

Сәҗгы мөтәвази. Фикърәләрнең ахыргы кәлимәләре вәзендә[4] вә гадәд хоруфда[5], хәреф руида муафикъ булмак белән булыр. Мәсәлән, *мәүзуга — Мәрфуга, вәхәдәт — кәсәрәт, шәраб — газаб, гитаб — хиҗаб, дәрд — бәрд* кебек кәлимәләр. Фәкать татар сүзләренә дә бу кагыйдәне йөртергә җаиз.

Сәҗгы мөтараф, диерләр, фикърәләрнең ахырында килгән кәлимәләрнең үзендә вә гадәд хоруфда муафәкате булмаенча, фәкать хәреф руида муафикъ булсалар кяфидер. Инсар — начар — мөстәгар кебек. Мәсәлән, *мөрут шигарь — хакыйкать асар.*

Сәҗгы мөтәвазиян[6] дигәнебез шулдыр ки, фикърәләрнең ахырында килгән кәлимәләрнең вәзендә вә гадәд хоруфда муафикъ булып, хәреф руида могайярь булмак белән булыр. Мәсәлән, *мөстәбин — мөстәкыйм* кебек кәлимәләр.

## Бәрагать истиһлял[6]

Кәлямның ибтидасында алдагы фикърәләрдә бәян кыйлынасы максуд мәгънәгә гайре сарих вәҗһегә[7] ишарә булмак бер кагыйдәдер. Әмма бәрагать истиһлял сәнгате һәрбер рисалә вә мәктүбатта тиеш нәрсәләрдән саналмас. Язучының үз ихтыярындадыр. Дәхи дә бу мәзкүр сәнгать ибтида'и кәлямгә махсус түгелдер. Мөхәррәратның[8] ахырына чаклы җаиздыр.

## Ләф вә нәшер[9]

Ләф вә нәшер дигән нәрсә шулай ук матур телләләр каршында бер сәнгатьтер ки, ике кәлимә яки өч кәлимә тәхрир кыйлынып, аннан соң янә шулкадәр сүзләр китермәктер ки, башта

---

[1] Мөндәфигъ — беткән.
[2] Сәнаигы бәдигадән — сөйләмнең тышкы төзелеше һәм мәгънә ягыннан матурлыгы.
[3] Сәҗгы мөтәвази — янәшә рифма.
[4] Вәзендә — иҗек санында, үлчәвендә.
[5] Гадәд хоруфда — хәреф санында.
[6] Бәрагать истиһлял — сүз башлау осталыгы.
[7] Сарих вәҗһегә — ачык стильгә, ысулга.
[8] Мөхәррәратның — язылган нәрсәнең.
[9] Ләф вә нәшер — төрү (урау) һәм таратү (белдерү).

әйтелгән вә язылганча соңгы өлкәсенең икенче әйтелгән вә язылганына соңгы икенчесенең мәгънәдә мөлаем булмагы белән мәрҗигълары[1] ачык булмаенча, аңлашылуы кирәктер. Бәс, бер җөмләдә әүвәл китерелгән сүзләргә *ләф* вә соңыннан китерелгән сүзләргә *нәшер* тәгъбир кыйлыныр. Ләф вә нәшер ике кыйсем булып, берсе — ләф нәшер мөрәттәб, икенчесе ләф нәшер мәгъшуш[2] тәсмия кыйлыныр. Ләф нәшер мөрәттәбтә нәшернең тәртибе ләфкә муафикъ булмактыр. Ягъни әүвәл — әүвәлгә, икенче икенчегә яраклы булудыр. Инде ләф нәшер мәгъшуш улдыр ки, мәзкүр монтазам булуы игътибарга алынмас.

## Тәнсыйк әс-сыйфат[3]

Матур сөйләүчеләр кашында тәнсыйк әс-сыйфат улдыр ки, бер нәрсәне ничә билге белән сыйфатлау кагыйдәсенә әйтелер.

## Мөбаләга[4]

Мөбаләга дигәнебез өч төргә бүленә: берсе — тәблигъ[5], икенчесе — игърак[6], өченчесе — голү[7] тәсмия кыйлыныр. Тәблигъ бер нәрсәнең зиядә куәт вә киресенчә зәгыйфьне васыф вә тәгърифтер[8] ки, аннан хасыйл булган мәгънә гакыл вә гадәт буенча мөмкин булыр. Игърак шулай ук тәблигъ кебектер, ләкин хасыйл булган мәгънәнең мөмкин әлгакыл вә мәхаль әлгадәт булмагыннан гыйбарәттер. Голү шулай ук, ләкин хасыйл булган мәгънәнең гакыйлән вә гадәтән мәхаль булмагыннан гыйбарәттер. Әүвәлгеләре үткән заман әдипләре каршында мәкъбуль. Әмма өченчесе ки голүдер сарфи ялган булганга күрә мәкъбуль түгелдер.

Тәблигъка мисал. Ул пәһлеван шәҗәгать нишанның мәйданда тарткан кылычыннан дошман күзләре камашып, вә аның сауләт вә салабәтенә мәгәр ки никадәр киң булса да, тар булыр иде.

Игърака мисал. Ул галим вә дананың дәрәҗә'и фазыйль вә кәмаләтенә нисбәт башкаларга караганда артыграк булган вә күп белүче бала төрле фәннәргә бәйле китапларына караганда сәяхәтче җыентыклары эчтәлеге хөкемендә калганлыгы ачык күренәдер (?)

---

[1] Мәрҗигълары — мөрәҗәгать итеlә торган нәрсәләре.
[2] Мәгъшуш — тәртипсезләндерелгән.
[3] Тәнсыйк әс-сыйфат — сыйфатларны тәртипкә салу.
[4] Мөбаләга — арттыру, гипербола.
[5] Тәблигъ — ирештерү.
[6] Игърак — арттырып мактау яки яманлау.
[7] Голү — арттырып җибәрү, зур итеп күрсәтү.
[8] Васыф вә тәгърифтер — сыйфатлау вә билгеләүдер.

Голугә мисал. Ул бичара дил[1] хастаның әләм вә иftикар[2] белән зәгыйфьлеген вә нәхифлеген[3] бер дәрәҗәдә күрдем ки, хәлен гарыз вә бәян кыйлмак мөшкел булучылыгыннан шулкадәр генә...

## Тәрсыйг

Тәрсыйг, диерләр, ике фикърә'и мәсҗыгнең берсендә булган сүзләрнең ритм һәм рифмада икенчесендә булган сүзләрнең ахыры белән туры килүеннән гыйбарәттер. Мәсәлән, *хәрәкәт вә сәкәнәте мәкъбуль кәбир әй бәнам хәсәнәт вә садакате мәбзүл фикер әй анам иде.*

## Мовазәнә[4]

Мовазәнә, диерләр, ике фикърәдән булган әлфазның фәкать үзендә генә бер-беренә туры килүеннән гыйбарәттер. Телебездә: *йөргән таш шомарыр, тик яткан таш мүкләнер.*

## Тәшарек[5]

Тәшарек, диерләр, нәсердә вә нәзымдә рифма белән әйтелгән кәлимәнең хәреф руидан әүвәл бер сәкенле хәреф вә аның алдында бер хәреф мөтәхәррик[6] булып, ике фикърәдә яки ике биттә китереләсе рифмалы сүзләрнең хәреф руисыннан (?) игътибар кыйлып, өч хәрефе бер җенестән булмактыр. Мәсәлән, *фәттах — мифтах, надан — мәйдан, тәгъдия — тәбдия* кебек гыйбарәдән. Мисал: *тәхсыйл, мәгарифтә ник нам, вә әхраз мөрәүвәттә мәмдух әл-анам булды.*

## Итнаб[7]

Асылда күп сөйләшмәк вә сүзне озайтмак мәгънәсендәдер. Әмма галим бәдигътә максуд булган мәгънәне аңлатканда, артыграк бәян вә рәвешен кыйлаем дип сүзләрне озайта торгач, морад булган мәгънәне дә җуеп җибәрүдән гыйбарәттер. Тасниф вә имля бабында мәмдух нәрсә булмаганлык җәһәтеннән язучы булган кеше моннан сакланмак тарафыннан булсын.

---

[1] Дил — күңел, йөрәк, акыл.
[2] Әләм вә ифтикар — авырту (газап чигү) һәм аерылышу.
[3] Нәхифлеген — ябыклыгын.
[4] Мовазәнә — тигез үлчәүлелек.
[5] Тәшарек — уртак булу.
[6] Мөтәхәррик — хәрәкәле.
[7] Итнаб — сүз озайту.

## Мөсавәт[1]

Гыйлем бәдигътә[2] мөсавәт, диерләр, ифадә'и шифаһиядә вә кәзалик ифадә'и тәхририядә алмашлык булган нәрсәне асылына яраклы итеп арттырмай, киметми үтәүдән гыйбарәттер. Хосусан мәгамәләдә, ягъни сөаль вә җавапта мөсавәт кирәк нәрсәдер ки, кәма һүә сөальнең эчтәлегенә озынайтусыз вә кыскартусыз гыйбарәт китермәктер. Мәсәлән: — *Әфәндем, дәрестән туктаганыгызга ничә көн булды? — Әфәндем, дәрестән туктаганыбызга бер җомга булды.*

## Иҗаз[3]

Асылда кыскартмак вә мохтасыйр итмәк мәгънәсендә иде. Ошбу фәндә дәхи мәзкүр мөсавәттән түбәнрәк саилгә[4] морадыңны аңлатканда, кыскалык белән җавап бирәем, дип әйтеп, бигрәк кыска җавап бирмәктән гыйбарәттер. Әмма моның кабул ителгәне бар, кабул ителмәгәне бар. Кабул ителгәне: — *Әфәндем, сез бу ел кәсеп нияте белән авылга чыгасызмы? — Бәли, әфәндем, чыкмага ниятем бар.* Кабул ителмәгәне: — *Чыгамын.*

## Тәҗнис[5]

Әмма тәҗнис гарәп телендә әлфаз мөштәрәкәнең[6] күплеге вә гарәп теленең киңлеге хисабынча гарәп теленә махсус булып, моңар бәрабәр телебездә бераз уртак сүзләр барлыгыннан җинас там вә җинас накыйс[7] исемнәре белән истигъмальләре мөмкиндер.

Җинас там. Бер тәркибтә ике кәлимә сарыфта[8] вә вәзендә бер җиренә мотабикъ вә муафикъ булган хәлдә мәгънәләре башка булмактыр — җинас там аталыр. Мәсәлән, *фәлән-фәлән җитмеш җитмеш яшьлек заманында, гыйлем исламиядә китапны тәмамлау соңында, ханәсенә дүнмеш бакыя'и*[9]*, гомерендә гаять тәкъвалыгы белән Аллаһның нурлары*

---

[1] Мөсавәт — тигезлек, бердәйлек.
[2] Гыйлем бәдигътә — матур сөйләмдә.
[3] Иҗаз — кыскарту.
[4] Саилгә — сораучыга.
[5] Тәҗнис — аваздаш сүзләр, омонимнар.
[6] Әлфаз мөштәрәкәнең — уртак сүзләрнең.
[7] Җинас там вә җинас накыйс — аваздаш сүзләрнең һәр ике мәгънәсен аңларлык итеп төгәл куллану һәм кыска куллану.
[8] Сарыфта — төрләндерүдә.
[9] Ханәсенә дүнмеш бакыя'и — бакый йортына китте.

*тулып ташуыннан икътибасән калебе баштанаяк гәүдәсенә дүнмеш иде.*

Җинас накыйс. Җинас накыйс дигәнебез шулдыр ки: бер тәркибтә ике кәлимә хәрефтә мосави, вәзендә вә хәрәкәттә гайре муафикъ булып, башка мәгънәгә килер.

## Тәүрия-иһам[1]

Тәүрия, диерләр, тәркибтә бере кариб[2], бере бәгыйд[3] ике мәгънәне мөтазаммин[4] булучы бер сүзне китереп, каринә'и хәфия яшерен мәгънә белән ерак мәгънәне аңлатадыр. Мәсәлән, *берәү, улын сәфәргә озатканда «улым, яхшы ат алып кайт» дип васыять кыйлды.*

## Икътибас[5]

Гыйлем бәдигъттә икътибас тәсмия кыйлыныр: нәзымда вә нәсердә, гыйбарәттә Коръән аятеннән яки пәйгамбәр хәдисләреннән бер уңай белән бер сүз китермәктер.

## Тәнафер вә мөнафәрәт[6]

Гыйлем бәдигъттә тәнафер вә мөнафәрәт, дип әйтерләр, хәрефтә вә хәрәкәттә бер-беренә каршы кәлимәләр булып, сөйләгәндә вә ишеткәндә телгә вә табигъка[7] авырлык бирүче кәлимәләрне бер җөмләдә китермәктер яки телгә авыр бер кәлимә сөйләмәктер. Мәсәлән, берәүнең кари кабер хәребдә кабере бар кабиленнән телебездә каты сүзләр бик күптер: *бака бакылдай, казлар какылдай*, зирәки калын вә тәфһим[8] әйтелә торган хәрефләр бере артыннан бере күп килүе телгә авырлык бирәдер. Дәхи: *җидегәнем җиде җолдыз, җидегә чикле санасам, саваб булыр.* Янә: *чана карамаларга биргән идем, карамалады микән, карамаламады микән, карамаламаса да алып кайт.* Бу — балалар арасында тиз әйтеп өйрәнергә бер мисалдыр. Телгә авырлыгы барлыгы өчен, тиз тәләффыз кыйлу[9] мөшкелдер.

---

[1] Тәүрия-иһам — киная-шөбһәләндерү.
[2] Кариб — якын.
[3] Бәгыйд — ерак.
[4] Мөтазаммин — эченә алган.
[5] Икътибас — үрнәк алу, цитата китерү.
[6] Тәнафер вә мөнафәрәт — каршылык.
[7] Табигъка — басучыга.
[8] Тәфһим — авазны тутырып әйтү.
[9] Тәләффыз кыйлу — әйтү.

## Тәтабегъ изафәт[1]

Вә кәзалик тәтабегъ изафә гыйлем бәлягатьтә кабул күрелгән вә урынлы фәсахәттер. Тәтабегъ изафәт дигәнебез бер җөмлә эчендә берничә мозаф илә китермәктер. Мәсәлән, *галәмнең тәхсыйленең сәбәпләренең олысы — иҗтиһад кыйлмактыр.*

## Тәгъкыйд[2]

Дәхи фән бәдигътә тәгъкыйд, диерләр, бер гыйбарәттер яки бер җөмләдә сүзләрне мөәххәр[3] кирәгене мөкаддәм китермәк белән теленең кыяфәтенә гайре муафикъ вә мәгънәсе аңлашылмастай бер сурәттә җөмлә вә кәлям тәртип итмәкне тәгъкыйд диерләр ки, гайре мәкъбульдер.

## Гыйбарә әлфаз[4]

Җөмлә эчендә вә гыйбарәләрдә гариб[5] вә ят сүзләр куллану укучыларны мәгънә фәһемләүдән гаҗиз калдырырлык дәрәҗәдә сөйләмдә һәм язуда дөрес, яраклы вә кабул күрелгән түгелдер. Мәсәлән, төрекчәдән бер мисал: *ул шәҗүб рафигъдан әгъбабның сәфех чәмән сыйфә'и дилкәшәгә инһиракы...* Бәс, ошбу гыйбарәдә *шәҗүб, әгъбаб, сәфех, инһирак* сүзләре ят сүзләрдер, мәгънәсен аңлау мөшкелдер.

Янә берәү пәйгамбәр (с.г.в.)гә килде вә әйтте: «*Тамыш тах вә гадир сәбәләр вә шәбә*»,— диде. Пәйгамбәр (с.г.в.): «*Эннәшиб лишшәбли...*»,— диде. Әгәр бу ят кәлимәләрне гарәпчә калдырып тәрҗемә кыйлынса: *бер тамыш тах әйтте* югарыда зикер ителмеш вәҗһе үзрә *рәсме хат* вә *ысулы китабәт* синоним сүзләр булып, әдипләр каршында кабул күрелгән рәвешчә язуны рәсме хат яки ысулы китабәт аталыр.

## -мак, -мәк

Татар телебездә әдат масдар[6] ошбу ике төрледер ки, кәлимәнең хоруф тәркибиясенә[7] карап, калын яки нечкә әйтеләдер. Масдар формасының сурәте *–мак* хәрефе (кисәкчәсе) яки *–мәк* хәрефе кушылып, *язмак, килмәк* кебекләрдер. Әгәр масдарның

---

[1] Тәтабегъ изафәт — бер-бер артлы килгән изафә.
[2] Тәгъкыйд — буталчыклык.
[3] Мөәххәр — соңыннан.
[4] Гыйбарә әлфаз — сүзләрнең, җөмләләрнең тышкы ягы.
[5] Гариб — чит, таныш түгел.
[6] Әдат масдар — исем фигыль кушымчасы.
[7] Хоруф тәркибиясенә — хәрефләр төзелешенә.

ахырында –*мак* булса, мөтәкәллим фигыль мадыйның[1] күплегендә шулай ук «к» (ق) хәрефе килер, *яздык* кебек. Вә *кермәк* булса, үткән заман I зат фигыльнең күплегендә һәм «к» (ك) килер, *килдек* кебек. Әмма үткән заман I затында берлектә һәм күплектә «д» хәрефеннән соң «у» яки «и» хәрефе язылмас. Мәсәлән, *яздум* яки *яздым.*

## Мәбдәэ иштикак[2]

Телебездә мәбдәэ иштикак — әмер формасыдыр ки, өч заман вә хәзерге заман сыйфат фигыль, вә төшем юнәлешендәге сыйфат фигыль, вә исем фигыль вә гайреләр һәммәсе боеру формасыннан алынадыр. Әүвәлән боеру формасы *-мак, -мәк* кисәкчәләрен ташлап, *яз, кил* каладыр ки, әмер сыйгасы дигәнебез ошбудыр. Инде мондый галәмәте өчен шул *яз* яки *кил* дигән сүзләр янына *язд* яки *килд*, дәхи моның янына I зат өчен *-м*, мохатәб[3] өчен *-нең*, гаиб өчен *-ы* кушымча кыйлынадыр. Бәс, *яздым, яздың, язды*. Һәр үткән заман фигыльдә бу кагыйдә игътибарга алынырга тиеш. Ләкин бу нәрсәләр телнең сарыф вә нәхү кагыйдәләренә раҗигътыр[4]. Сарыф вә нәхү татар телебез өчен хәзерге вакытта тасниф кыйлынмактадыр.

## -дан, -дән

Ошбу *-дан* вә *-дән* кәлимәләре телебездә хоруфы җәрләрдер[5]. Сүзнең әйтелешенә күрә *-дан* яки *-дән* язылады: *Казанда, мәсҗеддән* дигән кебек. Гарәпчә «мин» вә «гъән» мәгънәләрендәдер.

## -да, -дә

Шулай ук бу *-да, -дә* хәрефләре һәм хоруфы җәрләрдер, тәфхим сүз соңында да язылмак тиеш иде. Ләкин кирәксә калын, кирәксә нечкә булсын — хәзерге телебездә гелән *-дә* кулланыладыр: *Казандә, мәсҗеддә* кебек. Чыгтай теле үзә язылган китапларда һәр ике хәлдә *-да* язылады.

## Өчен-ичүн

Ошбу ике хоруфы шулай ук хәрфе җәрләрдер. Икесен һәм куллану дөрестер. Инде монда артык озак тәфсыйл хаҗәт тү-

---

[1] Мөтәкәллим фигыль мадыйның — I зат үткән заман фигыльнең.
[2] Мәбдәэ иштикак — башлангыч тамыр яки нигездән фигыль ясау.
[3] Мохатәб — II зат.
[4] Раҗигътыр — кайтып каладыр.
[5] Җәрләрдер — бәйләгечләрдер.

гел, сүзнең бинасы вә тәркибаты[1] морфологиягә кайтып каладыр, вә ахыргы хәрефләре, вә игърабблары[2] синтаксис фәненә карыйдыр. Икесе дәхи басылачаклардыр. Хәзердә шуны әйтербез бары: *кәлде* дип язма, *килде* дип яз; *дәгел* дип язма, *түгел* диң; *кәрәк* дип язма, *кирәк* диң; *ничә* дип яз, *нәчә* димә; дәхи نجوك яки نجك дип язма, نيجوك дип яз; *тиш* дип язарга кирәкмәс, *тиеш, тиешле* язылыр. Янә хәрфе тәшбиһдән *кебек* ләфызыдыр ки, аны телендә *кеби* дип язма. Бу кәлимә асыл төрек телендә дә кебек дип кулланыладыр, ләкин «кебек»нең ахыргы «к»сен шулкадәр йомшартмышлардыр ки, билкөлли ишетелмәс булып калмыштыр.

## «Кавагыйде китабәт» ахырында бирелгән хикәятләр

Күңелләр сөеклесе вә ул хикәя-өзекләр Габделкаюм ән-Насыйриның тезмә сүз һәм рифмаларыннан.

Юмартлык хакында. Сәха[3] — адәмилек бакчасының агачы, бәлки, ул бакчаның җимешедер. Вә адәмилек өлкәсенең дәрьясы, бәлки, ул дәрьяның күһедер[4].

— Сәхавәтсез кеше — яңгырсыз болыттыр...

— Саран оҗмахка кермәс, гәрчә сәд[5] каршы булсын, юмарт тәмугка бармас, гәрчә бәндәи хәбәши[6] булсын.

— Юмарт кеше — болыттыр, эше хәзинә бирмәк. Саран кеше — кырмыскадыр, эше — башак җыймак.

— Һиммәт әһеленә юмартлык хас.

— Адәм — тәндер, һиммәт аңа — җандыр. Һиммәтсез кеше ир хисабында имәс, җансыз тәнне кеше терек, димәс. Һиммәт иясе, фәкыйрь булса да, хур булмас, һиммәтсез кеше, хәзинә тапса да, зур булмас.

— Исраф юмартлык имәс, юк урынга тәләф кыйлынганны[7] мәгънә әһеле юмарт, димәс.

— Мәгънәсез мал тәләф кыйлганны дивана, диерләр, якты көндә шәм яндырганны гакылдан бигянә[8], диерләр.

— Ул адәм, кем кеше күрмәгәндә бирмәс — саран; юмарт имәс.

— Сорагач биргәнене һәм юмарт, димә, ялынып сорагач, биргәннән бирмәгән яхшырак, димә.

---

[1] Бинасы вә тәркибаты — нигезе һәм төзелеше.
[2] Игърабблары — төрләнеше.
[3] Сәха — юмартлык.
[4] Күһедер — тавыдыр (биек урыныдыр).
[5] Сәд — киртә.
[6] Бәндәи хәбәши — Эфиопия кешесе.
[7] Тәләф кыйлынганны — әрәм-шәрәм ителгәнне.
[8] Бигянә — чит, ят.

— Бер икмәкне икегә бүлеп яртысын ачка биргәнне юмарт, диген, үзе ашамаен, ярымын мохтаҗга биргәнне мәрд[1] диген.

— Ашым заигъ[2] булмасын, дисәң, ашат, кием искермәсен, дисәң, кидер.

Кәрәм вә фөтүвәт[3]. Юмартлык тарихын югарыда әйтелгәннәрдән аңла. Әмма кәрәм вә фөтүвәт башка нәрсәдер, тыңла. Кәрәм вә фөтүвәт ни-нәрсә — бер җәфа чигүченең мәшәкатен күтәрмәк вә аны ул мәшәкатьтән үткәрмәк. Берәүнең михнәт тигәнәгеен кабул кыйлмак вә ул кыйлганыңны телгә китермәү вә авызга алмау, вә ул кешегә миннәт[4] куймак, вә аның йөзенә күз һәм салмак. Кәрәм — сыйфаты, әкрам әл-кәримин — эшедер. Кәрәм сыйфаты адәм табигатендә табылмас, бу сәбәпле кәрәм әһеле дөньяда аз.

Мөрәүвәт[5]. Мөрәүвәт — кәрәмнең бер тугма карендәшедер. Икесе дә холыкның вафасызлыгыннан агяһ[6] булырлар. Кәрәм иясе ул нәфсе мөтәгаддән аерылмакны хуп күрмәйдер. Вә мөрәүвәт иясе ул изге холыктан аерылмайдыр. Бу ике сыйфат кемдә булса да Ходай Тәгаләнең саклавында булсын.

Вафа[7]. Вафа шундаен сыйфаттыр ки, кәрәм вә мөрәүвәтнең качканыннан хәбәрдар булып, Гаден мәмләкәтенә аларны эзләмәгә юнәлептер. Җиһанның бакчасы вафа гөле юклыгыннан зиннәтсез, адәмилек гөле вафа исе юклыгыннан иямсез. Вафа бер чырадыр, кара заманның балчык өйләрен яктырта алмай. Вә заман вафасызларның күңеле белән дуслык тоталмай. Вафа бер мәхбүбдер пакь хилкать[8] пакизә[9] түгел, күңелгә өлфәте юк, вә бер мәтлубтыр пакизә фитърәттән[10] гайрегә рәгъбәте юк. Вафа — бер кыйммәтле энҗедер, адәмилек таҗына зиннәт. Кәрәм вә мөрәүвәт — ата вә анадыр, вафа вә хәя — туган балалардыр. Кемнең күңелендә вафа булса, хәя һәм анда. Вафасызда хәя юк, хәясызда вафа юк. Кемдә бу икесе дә юк — иман да юк. Вә кемдә иман юк, анда адәмилек тә юк. Ирләр — вафа әһеле, хатыннарда вафа юк. Кямилләр — хәя әһеле, нәкыйсләрдә хәя юк. Вафа белән хәя золмәт галәменнән үтеп, билгесез галәмдә урын тотырлар. Вафасызлар вә хәясызлар аны онытырлар, һәркемгә бер вафа күрсәттем, йөз вафасызлык күрмәенчә котылмадым, һәркем белән гаделлек вә мәхәббәт төзедем, йөз

---

[1] Мәрд — кешелекле.
[2] Заигъ — әрәм.
[3] Кәрәм вә фөтүвәт — юмартлык һәм киң күңеллелек.
[4] Миннәт — ярдәм.
[5] Мөрәүвәт — егетлек, кешелеклелек.
[6] Агяһ — хәбәрдар.
[7] Вафа — сүздә тору, бурычны үтәү, эштә тугрылык күрсәтү.
[8] Хилкать — табигать.
[9] Пакизә — чиста.
[10] Фитърәттән — кул тимәгән табигатьтән.

җәбер вә золымлык тартмаенча котылмадым. Дөнья вафасызларының җүрендән дад вә замана хәясызларының золымыннан форьяд[1].

Хилем[2] вә миһербанчылык дигәнебез адәмдә бер сыйфаттыр, адәм җүденең[3] җимешле бакчасыдыр.Изге холык — адәмдә кыйммәт бәһале киемдер. Вә ул кием адәмне нәфеснең хилаф җилләреннән саклап, холык тарафыннан тәгъзыйм вә гыйззәткә сәбәп. Олыдан кечегә илтифатка сәбәп. Изге холык адәмдә бер сыйфаттыр ки, йоклаган күңелләрне уятыр вә каткан күзләрне егълатыр. Изгеләргә ирешмәк этне пакьләр җөмләсенә катты. Вә явызларга катышмак пәйгамбәр балаларын җәһәннәмгә озатты. Шиксез, күзе сукыр Ходай дусларын күрә алмас. Тәүфыйкъ — аягы аксак кеше — Аллаһ юлына йөгерә алмас. Мәзлумгә ярдәм ит, залимнән тынычлык күрерсең. Гакыллы мохаләфәттән качар, муафәкать ишеген ачар. Дәрт әһеленең нәфесе бер уттыр, каты күңелне йомшартыр, коры күзне егълатыр. Сүз әһеленең сулышы бер җилдер, мин-минлек чүбен очырыр, ачу тузанын туздырыр. Ни-нәрсә кем бәкасыздыр, аңа күңел бирмәк хатадыр.

Күңел — бәдән мәмләкәтенең падишаһыдыр, күңелең сыйххәт булса, тәнең сыйххәт. Күңелең бозык булса, тәнең бозык. Тәнең сыйххәт вә сәкыйм[4] булса, күңел аның сәлах вә фәсаденә[5] иярә. Фәсыйк галим — үз нәфесенә залим. Саран бай гыйлеме юк, үзенә залим. Бу икесе, гомерне бушка уткәр, диләр. Кабергә хәсрәт алып бар, диләр. Бере гыйлем өйрәнергә зәхмәт чикте, гамәл кыйлмады. Вә бере мал җыярга имгәк тартты, сарыф кыйла белмәде.

Гыйлем өйрәнү дин кувәте өчендер, түгел мал җыю. Саран бай — яңгырсыз болыттыр, шиксез. Вә гыйлеме белән гамәл кыйлмаган галим — китап төягән йөкне тартып баручы ишәк. Саран кеше үз малын сакламактан михнәте каты. Көнче кеше кыйлган эшләренең оятыннан тереклеге ачы. Ул үз байлыгы белән, бу үз фигыленнән мәгърур кеше. Үз малыннан ни-кем файда алды, аныңдыр вә һәрни кем асраганы ятныңдыр. Зәхмәт белән тапканыңны үзеңнән аяма вә михнәт белән җыйганыңны дусларың белән аша, дошманың өчен асрама.

Нәфесеңнән сиңа золым ирешсә, үкенеч ишеген ач, тәүбә итәгенә кулың сузылыр, вә ул тәүбәнең өстендә көчле тор.

Һәр күңел тел җәрәхәте белән җәрәхәтледер. Йомшак сүз, татлы тел аңа дәва. Телгә ихтыярсыз — холыкка игътибарсыз.

[1] Форьяд — ярдәм сорап кычкыру, кычкырып елау.
[2] Хилем — йомшаклылык.
[3] Җүденең — юмартлыгының.
[4] Сәкыйм — авыру, бозык, начар.
[5] Фәсаденә — бозыклыгына.

Кем мәгънәсез күп сөйләр — эттер, кичтән таң атканча өрер. Яман телле күңелгә җәрәхәт китерер. Үз башына һәм афәт китерер.

Наданның мәгънәсез сүзгә бугаз кырмагы — ишәкнең юк җиргә бакырганы. Адәм тел белән башка хайваннардан өстен, һәм аның белән башка адәмнәрдән өстен. Сөйдергән дә тел, биздергән дә телдер.

Ялган. Кемнең сүзе ялган — ялганы заһир булгач, оялган. Ялганын чын итеп әйтүче — сүз остасы. Сүзнең төре күптер. Ялганнан яманрагы һич юктыр.

Нәмимә[1]. Кем сүзне бер җирдән бер җиргә җиткерер, холкының үткән гөнаһысын үз муенына төшерер. Нәмамчылык чын сүздә дә гөнаһ. Әгәр заһир булса, ялган булып йөз мең аһ.

Ахирәт юл азыгы — изге гамәл, алай да хак лә тыйфенә терәл. Ходайга лаек гамәлең булса да, гамәлгә таянудан кинә. Аның фазыйл вә кәрәме булмаса, гыйлем вә гамәл көлке. Надан ишәк, бәлки, ишәктән һәм тинтәк. Ишәккә һәрни йөкләсәң, тартыр, кая кусаң, анда барыр. Гакыл вә тәмиз дәгъвасы юк, бирмәсәң, ачтыр, әгәр бирсәң, тук. Әмма надан бу сыйфатлардан мөбәрра, заты гыйлем бизәгеннән азат. Эше бозыклык —хыялында йөз горурлык.

Шәригать юлы тигез вә мәхкәм, вә гаять тугры юлдыр һәм түз. Анда кирәк кич йөр, кирәк көндез, һәркем бу юлга керсә, аңа ике дөнья рәхәте. Аннан чыккан җәһәннәмгә китте. Туры барган — максудка җитте. Кемгә бу юл истикамәте кул бирәште, берәр эшне үтәүче кеше ирәште. Бу кылдан нечкә, кылычтан үткен юлдыр, кем бу юлдан туры барса, егет — улдыр. Кем бу сыйрат мөстәкыймнән барыр имәс, аның борынына оҗмах исе кермәс. Әмма явыз холыклы бер бәлагә грифтар булмай булмас, кая барса да, аннан котылмас. Хуш холыклы адәме — җәннәт аның мәкаме. Сабырлык белән эшләр ачылыр, эштә ашыккан — күп таелыр, күп таелган — күп егылыр. Эштә ашыкмак — балалар эше. Сабыр белән эш кыйлучы — тәҗрибәле кеше. Күп ашаучы, күп диюче[2] — ашыгып тәмугка китүче. Аз димәк — хикмәткә сәбәп, аз йимәк[3] — сыйххәткә сәбәп. Телгә килгәнне әйтмәк — надан эш. Туры килгәнне ашамак — хайван эше. Гыйлем укып гамәл кыйлмаган — җир сукалап ашлык чәчмәгән. Белмәгәнен сорап өйрәнгән — галим, сорамаган — үзенә залим. Әз-әз өйрәнеп укымышлы булыр, тамчы-тамчы җыелып дәрья булыр.

Гыйззәт әһеле вә дәрәҗә иясе хурлыкка төште. Кулында һөнәре юк, сорарга теле юк. Аңа мәрхәмәт кыйлмакны бел вә

---

[1] Нәмимә — әләк, яла, сүз йөртүчелек.
[2] Күп диюче — сөйләүче мәгънәсендә.
[3] Аз йимәк — аз ашамак.

кулыңнан килгәнчә яхшылык кыйл. Тыныч күңел белән ашаган умач яхшырактыр ки, ашасаң бал белән калач. Иске кием белән туфракта аунамак яхшырактыр ки, җефәк чапан киеп, кул астында кол булмактан.

Нәфес тәрбия кыйлудан һөнәр чыкмас, симертүдән башка, нәфес симертүдән файда чыкмас, гөнаһ кыйлудан башка.

Егетлек вакыты — гомер бакчасының языдыр вә тереклек киченең көндезе. Тереклек вә шатлык гөлләре аннан ачык, зәвык вә сафа йортлары моннан ярык. Хәваска юк итү аннан, әгъзага сыйххәт аннан.

Һәр адәми зат — вөҗүд мәлигендәге йортын туздырып сәфәр төзүче. Бу сәфәр сиңа, миңага түгел, бөтен галәмгә килүче. Һәркем юклык йортыннан барлык сараена кадәм[1] орыптыр, фани йортта берничә нәфес торыбдыр. Янә кайтып асыл йортка сәфәр итмәк, вә кайдан килдең, анда китмәк. Дүрт-биш көн бу фәна йортында мәсрүр[2]. Бак, кара, булма дәүләтеңә мәгъруր.

Үлемнән качмак юк, һәркем аннан котылмак юк. Бәс, юл ярагында булмак, сәфәр әсбабын хәзерләмәк зарур. Юл ярагы вә сәфәр әсбабы түгелдер яхшы-яхшы арбалар, озын-озын трантаслар, төенчек-төенчек әсбаблар, бәлки сәфәр әсбабы — әхлак, хәмидә вә изге гамәл.

## «КАЗАН ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЬ»ТӘН*

### Әлхитабес-салис

Үзегез хәер, балаларыгыз утын; сез бала тәрбия кыйла белмисез. Бары дөньяга балалар китермәк сезнең эшегездер. Әмма бу сыйфат хайваннарда да бар, мактанырга лаек эш түгелдер. Бала дөньяга килгәч... тәрбия кыйлмак атаның зиммәсендәдер. Балаларыгызның бары анасыннан имчәк имгәндә үгрәнгән телләре бар. Хайваннан тәфрикасы бары шулдыр. Бичаралар, ни үкенечтер, мәгърифәттән мәхрүмнәрдер. Ләкин мәгърифәт ни-нәрсә икәнен үзегез белмисез, нинди кабилиятле балаларыгыз тугыры килгәне бар, ләкин мәгърифәт иясе бер адәмгә тапшырып тәрбия кыйлдыра алмыйсыз, ни кәйфиятчә вә ни тарикъча тәрбия кыйлмак тиеш — аны белмисез. Мәдрәсәдә бер хәлфә кебек нәрсәгә бирәсез ки, үзе дә сезнең балаларыгыздан әдвән, балаларыгызга ни укытырга кирәкне белмидер, хәтта ни-нәрсә укытканын үзе дә белмидер. Бәна-

---

* «Хитабәт ли әһли Казан» исемле бу әсәр 15 бүлектән тора. Биредә 3,4,8–12 мөрәҗәгатьләрдән өзекләр бирелде.

[1] Кадәм — адым.

[2] Мәсрүр — шат.

гяһ, балаларыгыздан: «Энем, ни-нәрсә укыйсың?» — дип сорасаң, «Фәзаилешшөһүр» яки «Бакырган» вә «Йосыф китабы» дип җавап бирерләр һәм шуның белән мәдрәсәдән чыгарлар. Ул баладан ни мәгърифәт өмид итмәк кирәк. Иң зиһенне ача торган фәннәр гакылыяттан вә һәм риязыяттан[1] вә һәм әхлактан мәхрүм, адәм белән мөхаварә вә мәгашәрә[2] вә мөгаләмә тарикын асла белми калалар.

Азрак укыткалагач, язу галәмәтен куя белгәннән соң, эшкә кушасыз, яки кибеткә куясыз. Кибеттә дә һаман утын. Берәү нәрсә алырга керсә: «Ни кирәк?» — дип акаеп кычкыралар. Мөштәри булган кеше белән ни тарикъча мәкаләмә кыйлырга кирәк, әхлактан хәбәрдар булмаганлык сәбәпле сүзнең җаен белмиләр, кеше белән каты вә тупас сөйләшәләр, мөштәрине биздерәләр, бер кергән кеше кибетегезгә икенче мәртәбә кермәскә сәбәп буладыр. Балаларыгызны укыткан буласыз: «Угылым, бүген ни укыдың?» — дип, нигә сорашмыйсыз. Язу үгрәнергә җибәрәсез, «әүвәл алдым» үгрәнеп кайтадыр.

## Әлхитабер-рабигъ

Бөтен галәм халкы гыйлем арттырырга һиммәт багламышлар икән, шундаен заманда сез гыйлемнең хилафына сәгый кыйласыз. Ул нигә кирәк, бу нигә кирәк, дисез. Гыйлем кирәк булмый икән, ишәк бул, гыйлем кирәк булмаса, китабын да тасниф кыйлмаслар иде. «Бакырган»нан ни чыга, «Фәзаилешшөһүр»дән ни чыга? Башка зарур булган гыйлемне тәхсыйл кыйлганнан соң, андый китапларны алып укымак мөмкин. Фән укыганда, андый китапларны укымак вә укытмак хаҗәт түгел. «Арык шайтан белән симез шайтан хикәяте» фәкать балаларның газиз гомерләрен заигъ итүдән артык ни хасыять. Дәхи дә «Фәзаилешшөһүр»дә һич кәйфияте мәгълүм булмаган нәрсә — тәмуг матчасына асарлар, дигән сүзнең балаларга ни файдасы бар? Мондый нәрсәләрне ник башыгызга алмыйсыз? Сез шуны гыйлемгә сәясыз: «Һай-һай, углым мәдрәсәдәнниләр белеп кайткан», — дисез. Тәмугның матчасы бар, имеш! Тимердәнме? Тимер булса — эрер. Агачтанмы? Агач булса — янар. Аңар ник гакылыгыз җитми?

## Әлхитабес-самин

Мәдрәсә талипләрегез ун ел, унбиш ел фәкать мантыйк белән гомерләрен уздыралар. Мантыйк исә голуме хикмиягә бер аләттер. Гыйлем аләте булган нәрсәгә ун ел тәләф кыйлып та,

[1] Риязият — математика.
[2] Мөхаварә вә мәгашәрә — сөйләшү, аралашу.

имамәтчелеккә шөругъ кыйлгач, мантыйктан һич эш чыкмый. Әхлак та кирәк була, фикыһ та, җәгърафия дә кирәк була, һәндәсә дә кирәк була, һәйәттән дә беләсе килә башлый. Гыйльме сәнәгатьтән дә кирәк була, вә гыйльме мәгаш вә гыйльме тәдбире өмүр дә кирәк була. Мондаен гыйлемнәрнең мәбнаси[1] риазыяттыр вә голуме табигыядыр, аннан хәбәрегез юк. Мантыйкны мәдрәсәдә укытуны бер олуг гыйлемгә саясыз, әмма гыйльме хикмәттән мәхрүмнәрсез. Сез, мантыйк укып, максудыгыз фәкать бер-берегезнең тавышын ишетмичә дәфгатән «мәмнуг, ла нәсәллим!»[2] кычкырмактадыр. Юк, әфәнделәр, файдалырак гыйлем укымак кирәк иде. Бәли, мантыйк һәм тәсхихы фикер өчен булганда, «Шәмсия» мәтенен бер кышта тәмам хифыз кыйлып белергә мөмкин, әмма гыйльме фикыһ, дин вә диянәт зарур нәрсә булса да, мәдрәсәдә вакытта мәтен китапларын бик забыт кыйлганнан соң, мәдрәсәдән чыккач та мотаувәл китапларын тик моталәга кыйл. Аның вакыты үтмидер. Ләкин мәдрәсәдән чыккач, голүме хикмия вә риазыятны тәхсил итүе мөшкил. Голүме риазыядан нәфис гыйлемнәр бар исә дә борыныгызга кергәне юк. Гимназиянең әүвәлге дүрт классы дәрәҗәсендә укыла торган фәннәр дигәч, котыгыз чыкты, әгәр мөкаддәмдә ул фәннәрне белгән булсагыз иде, бер дә исегез китмәс иде. Мәмләкәт балалары гадәттә җиде-сигез яшендә укырга бирелэдер, унбер-унике яшьләрендә бу фәннәрне тәмам кыйладыр. Бик курыктыгыз, унбер яшәр балалар укый торган фәннәр, имеш. Ләкин мәмләкәт теле белән укыгыз димәк түгелдер ки, бу фән төрек телендә вә гарәп телендә көн бәкөн артмактадыр. Чөнки ул фәннәрне кайсы тел белән белсәң дә бел, мәмләкәт теленә махсус фәннәр түгелдер, кайсы тел белән булса да, ул фәннәрне белгәннән соң бары каладыр тел белмәк.

## Әлхитабет-тасигъ

Ул гимназиянең әүвәлге дүрт дәрәҗә фәннәре гыйльме хисап, җәгърафия, һәндәсә, рус тәварихы. Ул фәннәрне ун яшәр балалар укыйдыр. Җитмешенче елда мөдәббирләрнең әүвәлге тәдбирендә «әүвәл мәртәбә дә фәннәр әһле исламның үз теле белән укытылыр» дигәннән соң, 73 елда «Хисаплык» дигән бер китап зоһур итте. Бер календарьда җәгърафияне кыскалык белән белдермешләр иде. Янә бер календарьда мәмләкәт тәварихы күренде. Аларны гыйлемгә хисапламадыгыз. Кайсы гыйлем булса да, укымыйча белеп булмый. Әгәр дә бу мәзкүр фәннәр мәдрәсәләрдә кадимнән укыла килгән булса, мөдәббирләр һәм уку белән тәклиф кыйлмаслар иде.

---

[1] Мәбнаси — нигезе.

[2] Мәмнуг, ла нәсәллим — ярамый, килешми.

## Әлхитабел-гашир

Югарыда балаларыгызның анадан сөт имгәндә үгрәнгән телләре дигән идек, аның тәфсыйле будыр ки, берәү гайре телне үгрәнмәкче булса, әүвәл үз теленең кагыйдәләрен яхшы белсен, һәр телнең кагыйдәсе бардыр. Әмма сез мондый нәрсәне инкяр кыйласыз. Балаларыгызны русча укытмакчы булсагыз, бер-ике айда рус телен тәмам кочакламакчы. Әүвәл хәрефләрен яхшы танып каләменә төшенгәннән соң, бик күп әлфазы мөфрәдә белмәк кирәк. Әлфазы мөфрәдә белгәч тә, кавагыйдатын белмәсәң, һаман русча сөйләшергә, дөрес язарга белеп булмый. Хат тышыны гына язсаң да, ничә төрле кагыйдә белмәк кирәк. Тел бар да бер гарәп теле шикелле: сарыфы бар, нәхүе бар, мөбтадә, хәбәре бар, фигыль, фагыйле бар, сыйфат, маусуфы бар, хәрфеҗәрләр бар. Һәркайсы үз урынында истигъмаль кыйлынмак тиеш. Әмма сезнең моннан хәбәрегез юк. Шул сәбәпле тел үгрәнүнең тарикын белмисез. Дәхи дә фән күрмичә үскәнсез, һәрбер милләттә балалар өчен һәр фәнне мөштәмил вә һәр фәннән берәр мәсьәлә тасниф кыйлалар. Башка телдә күргәнегез булмаса да, Истамбулдан килгән кыйраәт китабы тәсмия кыйлынмыш бәгъзе китап сатучыларда күренәдер, сез аны ни икәнен фәһемләмисез. Шуның кебек китапларны укып-укып укырга үгрәнгән бала, һәр фәннән укый башлагач, тиз фәһем итәдер. Мәдрәсә хәлфәләре карчыклар укытуы белән укыта биргән. Сез аны: «Балаларым сабак укый»,— дип хисаплыйсыз. Юк, сабак укымак — алай түгелдер.

## Әлхитабе-әлхади-гашәр

Инде сезгә мәслихәт вә нәсыйхәт кыйлып карыйм, кабул итәрсезме. Балаларга ошбу мәзкүр фәннәрне укытсагыз булмыймы? Бакчы, бичаралар ачылып китәрләр иде. Ләкин сезнең бу уку эшләрен тәртипкә салучыгыз юк, мәгърифәт иясе булган кешегез юк. Бәлки, бардыр, әмма сездә кешенең мәгърифәтен үлчи торган бизмән юктыр. Чәчен кыркытып, мәмләкәт әһленчәрәк киемдә биек үкчәле итек кисә, аны мәгърифәт иясе дип беләсез, гөман кыйласыз, гүяки аның мәгърифәте киемендә ябышып тора. Шул тәмәрредегез белән торыгыз, нигә чаклы торырсыз. Гыйльме җәгърафия, гыйльме тәварихны кадимге халыкларыбыз укыганнардыр. Чөнки бу фәннәрдә җиребездә язылган кадимге китаплар күренәдер. Бездән мөкаддәмдәгеләр хам түгелләр иде. Әмма сез балаларыгызның букчага күп китап тутырып сабакка йөрүләрен гыйлем укый дип саясыз. Хәзердә гыйлем уку — алай түгелдер. Сез аны фәһемләмисез. Гыйльме хисап, гыйльме җәгърафия, гыйльме һәндәсә вә табигыять гыйльме риязыятның шөгъбәләредер. Боларны күрмәгән адәм — адәм

булмыйдыр. Адәмне егетләндерә торган фәннәрдер. Мәдрәсәдә укыган балаларыгызның зиһеннәре бер дәрәҗә катып калмыштыр ки, эшкә китермәк мөшкил. Гыйльме хисаптан, җәгърафиядән, һәндәсәдән, табигыятьтән, тәварихтан, кимиядән, сәнагыятьтән — һәркайсыннан балаларыгызга бераз-бераз белдермәк лазем иде.

### Әлхитәбес-салисе-гашәр

Гыйлемнең хилафына сәгый кыйласыз, әфәнделәрем! Гыйлем арттырмага касдыгыз юк. Әгәр күзе ачыграк балаларыгыз үзе эстәгән бер китап алмакчы булса, китап сатучыларга алдан әйтеп куядыр: «Әти юк чагында миңа фәлән китап китер», яки кибеттә утыручы хезмәткәрегез булса: «Бай юк чагында миңа фәлән китап китер». Әлбәттә, сезнең мәнгыгезгә күрә балагыз яки хезмәткәрегез яшертен аладыр, бу мутлык эше түгелдер. Аны фәһемләмисез. Хәтта фәрхән вә сөрүрән[1] рөхсәт бирмәк кирәк иде. Гяһан балаларыгыз урамда акча уйный яки кузна уйный, яки күгәрчен очырта. Андый эштән ник балаларыгызны мәнгы кыйлмыйсыз. Болар яхшы эш түгел ләбаса. Сез хөсен вә кобыхны белмисез, яхшыны, яманны танмыйсыз. Кечкенә балаларыгыз, кечкенә пәке, пычак алып, тәти ясаса, өегез эчендә уйнаса, чүпләмә, дип, башына сугасыз. Белмисез ки, балаларыгызның бу эше һөнәрмәнд булмакына дәлаләт кыйладыр. Бишалты бала үстерәсез, алдагы көндә балаларыгызның һөнәр вә гыйлем иясе булачаклармы — тәҗрибә кыйлмыйсыз. Дәхи «алдагы көндә һөнәрмәнд вә гакыл иясе адәм булса икән» дип эстәмисез дә. Баланы ата-ана изге юлга дәлаләт кыйлмаса, ул балада өмид булмыйдыр, сез аны уйламыйсыз.

## КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘ МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ РУСЧА УКЫЙ ТОРГАН МӘДРӘСӘНЕҢ ИБТИДАСЫ

Моның ибтидасы кемнән булгандыр? — Монда бу сөаль варит булса[2], без бәян кыйлаек, моның ибтидасы, әлбәттә, ошбу мөгаллимнәндер*. Асыл бу мәдрәсәнең ибтидасы 1871 елда булды. Бәлки, бәгъзе адәмнәрнең хәтерендә бардыр, 1871 елгы календарьда министрның бу хосустагы[3] проектын бераз бәян кыйлып, бу мөгаллим язган иде. Һәм бу рәвешле календарьга

---

* Мөгаллим яки бу адәм, дип К.Насыйри үзен әйтә.

[1] Фәрхән вә сөрүрән — шатланып.

[2] Сөаль варит булса — сорау килсә.

[3] Бу хосустагы — бу турыдагы.

язып, мөселманнарга төптә мәгълүм булмаган эшне белдереп, филҗөмлә аларга аңлатты вә һәм бу календарь рус галимнәренең кулларына төшеп, мөселманнарның русча укырга мәеле булачакларына календарьда язылмыш сүзләрне дәлил тоттылар. Вә һәм бу хосуста бәгъзе статьялар бастырдылар. Вә бу статьялар дәхи правительствоның проектына тәкъвия[1] булып, 71 нче елның ахырында, Казан шәһәренә берәүне* начальник тәгаен кыйлып җибәрделәр. Вә һәм ноябрь көннәрендә мәзкүр начальник, бер мөгаллимне эзләп табып, үзен рекомендовать итте. Вә һәм бу мәдрәсәне вөҗүдкә чыгарырга илтимас кыйлды[2] ки, зинһар, бу эш гайренең кулыннан киләчәк түгел, әлбәттә, син башласаң кирәк дип, бу эшне аңар, ягъни бер мөгаллим адәмгә хәвалә[3] кыйлды. Бу адәм һәм, әлбәттә, мөмкин булмаган эш юк, шаять, мин моны җаена китерермен, дип, үзенә илтизам[4] кыйлды. Вә һәм шул инспектор хәзрәтләренә үзенең элгәрге хезмәтеннән нәүмиз булып чыкканнан шикаять кыйлып сөйләшкәч, инспектор хәзрәтләре һәм һавадагы торналар белән күп бәшарәтләр[5] биреп, бу адәмнең һәм күңелен берничә тәшвиштән[6] чыгарып, үз файдасына күндерде. Әлбәттә, аның һәм өстенә лазем булган эш; берәү ярдәм кыйлышмаса, ул кеше нишләр иде. Бәхетенә каршы, бу адәмне Аллаһы Тәгалә аңар юлыктырды. Инспектор хәзрәтләренең һәм ул вакытта татар теленең исе борынына бик аз керәдер иде. Шул сәбәпле, бу адәмнең шикаятен ишеткәч: «Кайгырмаң, мин министрның колагына салаем, кыйлган хезмәтләрең һәм бикяр китмәс, алай-болай»,— дип, кыргызчарак гыйбарәләр сөйләп, алдагы көндә бу адәмгә өмидләр булачагын фәһемләтте[7]. Бу мөгаллим һәм хыял кыйлды, бу начальник хәзрәтләре министрның колагы...** кодрәте бар икән. Вә һәм бу инспектор хәзрәтләре танышмастан борын, 71 нче елның башыннан бирле, дүрт яки бишләп, русча укып торган балалар бар иде. Бу, инспектор танышкан көннәрдә, Сәгъди Яхин фатирында торадыр иде. Аннан Сая Ибрай номерына күчкәч тә өч шәкерте бар иде. Аның өчен, бу адәм үзенең 71 нче елгы календаренда «русча укытамын» дип мәгълүм иткәннән соң, бәгъзе адәмнәр балаларын русча укы-

---

* В.В.Радловның татар мәктәпләре эше буенча инспектор булып билгеләнүе хакында сүз бара.

** Берничә сүз танылмый.

[1] Тәкъвия — көчәйтү.

[2] Вөҗүдкә чыгарырга илтимас кыйлу — оештырып, корып жибәр, дип үтенү.

[3] Хәвалә — йөкләтү.

[4] Илтизам — өскә алу.

[5] Бәшарәт — сөенеч.

[6] Тәшвиш — борчу.

[7] Фәһемләтте — аңлатты.

макка бу адәмгә җибәргәннәр иде. Һәм шул балалар Сая Ибрай номерында да шөгыльләнеп ятты. Инде инспектор хезмәтенә тотынырга вакыт җитте. Фатир табып булмый. Аена илле тәңкә бирсәң дә, балалар укытамын, дигәч, фатир бирмәделәр. Ахыр 72 нче елның февраль башына чаклы фатир табып булмады. Ахры, нагыйлаҗ[1], Мокрый урамында, бер кабак өстендә фатир алып һәм капка өстенә игъланнамә куеп, алты-җиде, бәлки, унлап бала җыелды. Бичара бу адәм дә чикте җәфаны: астында кабак — төн буе җырлыйлар, сугышалар, күрше бүлмәләрдә — кайсы кәвешче, кайсы тегүче, кайсы скорняк. Ишек алдындагы уртадагы өйдә — сыра заводы. Ишек алды артындагы өйдә... яки кызлар ханәсе. Чыкса — урамы кабахәт; керсә — күршесе кабахәт. Халык сүзен ишетсә, яман сүз ишетә. Мең бәла белән ике айлар бу фатирда торды. Балалар укыта башлап, капка өстенә вывеска куйгач, частька барып әйткәннәр. Частьтан сотниклар килеп, сорашып йөрделәр. Хәтта бәгъзе адәмнәр Казан шәһәреннән кудырырга йөрделәр: укый торган балаларның мәдрәсәдәге хәлфәләре, «русча укыма» дип, һәркайсын яткырып сукты. Бервакытны тагын балалар бетеп китте. Болай булгач, инспекторга барып шикаять кыйлырга кирәк булды. Әгәр барып шикаять кыйлыйм дисә, мөселманнардан шикаять кыйлырга үзенең мөселманчылыгы җибәрми, инде нишләргә кирәк? Алай да инспектор тирәсендә йөри торган бер адәм барып илка[2] кыйлганнан соң, инспектор, хәлфәне чакырып, филҗөмлә тәхвиф кыйлгандыр[3]. Вә һәм адәм күп иҗтиһад[4] белән янә берничә бала җыйды. Әмма вакыйган, әүвәл баштан җыелган балалар да, билкөллия[5] ят кеше балалары түгел иде. Бәгъзесе үзенең шәкерте, угылы, бәгъзесе шәкертләрнең агай-энесе яки агай-энесенең балалары иде. Асыл тугры акыл белән уйлаганда, аслан[6] ят кешене китереп булырлык түгел иде. Бу әүвәлге фатирда чагында янә ун-унбишләп балалар җыелды. Аннан соң Захарьев* урамында икенче фатирга күчеп, вывеска кадаклагач, чиркәү вывескасы дип исем чыгардылар. Вә һәм бәгъзеләре: «Бу эшне туктатырга мөмкин булмасмы икән»,— дип, фартальныйга[7] барып шикаять кыйлганнар, фартальный һәм үзе, фатир хуҗасын чакырып, орышкан, андый кешегә ник фатир бирәсең, дип, фатир бар дип ишеткән җирдән барып сораса, ун тәңкәлек фатирга илле тәңкә сорадылар. Ләкин сораган кешене гаеп-

---

* Хәзерге К.Насыйри урамы.

[1] Нагыйлаҗ — чарасыз.

[2] Илка — хәбәр салу.

[3] Филҗөмлә тәхвиф кыйлу — куркыта төшү.

[4] Иҗтиһад — тырышлык.

[5] Билкөллия — бөтенләй.

[6] Аслан — һич.

[7] Фартальный — квартальный.

ләргә ярамый, теләсә ни сорар, ихтыяры бар. Бу, мескен, фатир таба алмый, кыйбат сорыйлар дип, инспекторга әйтсә һәм инспектор: «Ахмакмы икән ул кеше»,— дип, аның белән орышырга заставить итәдер. Бу адәм, мескен, шулкадәр җәнҗал белән мәдрәсә ачып, ни файда хасыйл итте? Шулкадәр җәнҗалдан соң бу икенче фатирда янә егермеләп-егерме бишләп сабак баласы булды, һәрничек бу адәм кайсы баланы атасына яки агасына әйтеп, димләп, вә бәгъзесенә кеше аркылы әйттереп, чакырып җыйды. Янә яңа биш-алты малай йөрде. Алардан да берсе зуррак та фәкыйрь бала иде. Аягыма юк, дип йөрмәс булды. Ул йөрмәгәч, икенчеләре дә туктадылар. Янә бу адәм, шуңа хафа булып, ул малайны чакырып, аларны син ияртеп йөр, дип, аягына кәвеш бирде. Яз көне җир кипкәч, бу малай лимон сата башлап, янә аңар ияреп килә торган малайлар сабактан туктадылар. Лимон сатып табыш иткән акчасыннан башка, көн дә ун тиенлек көмеш тәңкә биреп җибәрә-җибәрә, ул малайны яллап йөртте. Югыйсә аңар ияреп килә торган балалар да туктыйлар. Шулай итеп, берәр ай узды, утызлап малай җыелды. Яхшы сүз белән, йомшаклык белән сыйлап-сыйпап, утызлап малайны ияләндергән иде. Бер көн инспектор килеп, балалардан бәгъзе сүзләр сорап, «это что? это что?» дип, төкерекләрен чәчеп, кычкырып сорагач, бәгъзе вак балалар гомердә русчаны күргәне юк, рус ләфзын[1] ишеткәне юк, азбука укый башлаган балалар куркып, тагы килмәс булды. Кечкенәдән бирле анасы: «Җылама, руска бирермен»,— дип үстергәнгә күрә, гәрчә инспектор булса да, балалар бары рус гонваны[2] белән генә беләләр. Аларга инспектор кем? Барыбер, бары да рус. Шул вакытта инспектор хәзрәтләре бу адәмгә әйтте: «Купец баласы күпме, крестьян баласы күпме, мещан баласы күпме, исемнәрен яз»,— диде. Аннан соң крестьян дигән сүздән аңладылар, боларны христиан итәргә, дип әйтә дип. Чөнки яңа азбука укый башлаган балалар рус сүзен ишеткәннәре юк. Әмма крест, крестить дип әйткән сүзне часто ишеткәннәре бар икән. Аннан соң икенче көн сабакка бер генә малай да килмәде, һәммәсе качты. Бары хуҗа балалары гына икәү-өчәү бар иде. Аларны чакырып алып, дәресне уздыра алды. Өченче көндә дә, дүртенче көндә дә, аннан соң тагы байтак көннәр сабакка килгән малайлар башала[3] бетте.

Инде нишләргә кирәк? Бу адәм дә бик хафа, бик күңелсез булды. Инспектор хәзрәтләренә донесение җибәрсә дә, файдасы юк; чөнки инспектор хәзрәтләре яңа кеше, мөселман арасында торганы юк, мөселманнарның холкын, гадәтен яхшылап белгәне

---

[1] Ләфзын — сүзен.
[2] Гонваны — исеме.
[3] Башала — бөтенләй.

юк. Полиция белән куркыта башлый. Әгәр бу адәм шул рәвеш барып шикаять кыйлса, мөселманнардан шикаять кыйлу була, һәм бу сәбәпле халык арасында сүз күбәя, төрле сүз ишетеп, бу бичараның да башы әйләнеп беткән. Янә яңадан балаларны өндәп йөрергә калды. Аннан соң ул җәй узгач, шул мәзкүр[1] урамда яңа өченче фатирга күченде. Көз көне мәкәрҗә кайткач, бу адәм тагы үзенең агай-энесеннән биш-алты малай тапты вә һәм акрынлык белән балалар азаюның сәбәбен инспектор хәзрәтләренә аңлатты. Ул кыш инспектор хәзрәтләре ул кадәр строго килеп йөрмәде. Бөтен кыш буенча утыз биш малайдан ким булмады, һәм укырга-язарга вә һәм гыйльме хисапка яхшы төшенүчеләр булды. Ул җәй инспектор хәзрәтләре Германиягә сәфәр кыйлып, аннан берничә картина алып килгән икән. Янә сентябрь числосы җитеп, балалар байтак җыелгач, бер көн инспектор бу картиналарын төяп килә. Дәресханәгә кереп, картинага каратып, балаларны русча сүзләргә өйрәтмәкче булды, һәм картиналарны класс тактасына асып, балаларга күрсәтеп: «Бу ни-нәрсә (это что)?» — дип сораштыргалый башлады. Авызыннан төкерекләрен чәчрәтеп, кычкырып, класста очып-очып йөри, кызарып китте, тирләп китте: күзләре аларды, балалар дер-дер калтырап утыра. Яңа азбука укый башлаган балалар ул картинадан ни белсен? Рус ләфызларын яхшылап, төптә таләффыз[2] кыйлганнары юк. Әүвәл җитәрлек русның берәм-берәм сүзләрен белгәннән соң аз-аз сөйләшү тарикын[3] белерләр иде. Ул кечкенә балалар ни беләләр, хәер, Уфада укый торган егетләр өчен берничә файдасы булса да булсын, әмма балалар өчен аслан моның файдасы юк. Аннан башка да аз-аз төшендерергә мөмкин. Ул бернәрсә белми торган балаларга ачуланып, пожалый, кычкыр! Гамбургта шул тарика укыталар, дип очынып йөри. Россиянең үзендә генә дә безгә җитәрлек гыйлемлек бар. Россиядә барында ни өчен заграницага барырга кирәк. Без — Россия кешесе. Бу Россиядә булган нәрсә безгә җитә. Ул картиналар берничә йөз тәңкәгә төшкәндер, төшсә дә төшсен, хәзинә акчасы күп. Аз мөддәттә[4] дәфгатән[5] Германияне монда китереп булмый. Россия халкы Петр Великий заманыннан образоваться итә. Кешене берьюлы төшендереп булмый. Биш ел, ун ел, алай-болай йомшаклык белән, укучыларның ихтыярына салып, кагыйдә вә низамга төшендерсәң дә ярар. Безнең халык эчендә булмаган эш, ул башта халыкка бик хилаф[6]

---

[1] Мәзкүр — сөйләнеп узган.
[2] Таләффыз — әйтү.
[3] Тарикъ — тәртип, юл мәгънәсендә.
[4] Мөддәтә — вакыта.
[5] Дәфгатән — кинәттән.
[6] Хилаф — ят.

тоела. Акрынлык белән төшендермәсәң булмый. Мондаен эшкә күп тәҗрибә иясе кирәк. Олуглар тирәсендә берничә ел тәрҗеман[1] булып кына йөрү җитмидер. Класс хезмәтендә озак көннәр әүвәл үзең практиковаться итәргә кирәк. Бу адәм: «Бу ел инде иллеләп бала булыр»,— дип, өмид итеп торган иде. Шулай итеп, балаларның атасы-анасы ишетеп, сурәткә табынырга өйрәтә икән дип, балалары башала килмәс булды. Һәм январь башына чаклы алты-җиде малайдан артмады. Әмма март, апрель айларында утыз икеләп малай җыелды. Инспектор хәзрәтләре һәм малай азаюның сәбәбен аңлады. Кыш буенча бер дә килмәде.

Янә 73 нче ел январь башында мәдрәсәләрдә русча укытырга мөгаллимнәр куелды. Бу адәмгә бер мәдрәсә бирелде. Мәдрәсәләргә тәгаен кыйлынган мөгаллимнәрне инспектор хәзрәтләре үзенә чакырып-чакырып нәсыйхәт бирде, укытуларның тарикъларын әйткәләде: «Балалар утырган өстәлдән аршин ярым кадәр җирдә торып, акрынлык белән генә, бик аваз күтәрмичә, балаларга дәрес бирергә һәм сорарга тиеш»,— дип өйрәтсә дә, үзе класска килгәч, аны оныта икән. Класска кычкырганына урамдагылар туктап-туктап, монда әллә сугышалармы икән дип карап тордылар. Аршин ярым кадәр җирдә тору түгел, яннарына барып, колакларына ун мәртәбә тәкрар тәләффыз кыйлдырсаң, алай булса да телләрен күндереп булмый. Хосусән, зуррак кеше булса, бигрәк читен буладыр. Кайда калды аз мөддәттә рус телен белдерергә, хәтта моттасил[2] шуның өстендә торган Уфа шәкертләре дә тиз төшенә алмыйлар. Шуның өчен кечкенә балаларны укытудан мәдрәсә шәкертләрен укыту читенрәк. Әүвәл мәдрәсәләргә рус телен керткәндә, бәгъзе мәдрәсәләр учительне кабул итмәделәр. Ник кабул итмәделәр? Тәдбирсез[3] кертергә мөмкин түгел. Бер хезмәттән бушаган солдат, военный киемнәре белән башлык киеп, тыпырдап барып кергәч, курыкканнар. Ичмасам, гадәтчә киенеп, кеше сыйфатында барса, кабул итәрләр иде. Шундаен кыяфәттә күргәч, бер солдатны хәлфәлеккә кайчан кабул итсеннәр? Бу сәбәпле мәдрәсә ябыла язды. Хәтта бу эш губерния башлыгына ирешә. Бернәрсә булмады. Тәдбирсез эш кыйлганга күрә, начальник оятлы булды бары. Һәркем, табгы сәлим иясе[4] аңлар: мәдрәсәдә рус телен укытырга бер дә рәвеш[5] юк. Йөзләп малай шаулап тора. Анда ничек шөгыльләнергә кирәк. Бары мәдрәсәдә аерым бер дәресханә кирәк иде. Болай булганда, шәкертләрдән русча укырга

[1] Тәрҗеман — тәрҗемәче.
[2] Моттасил — тоташ.
[3] Тәдбирсез — алдан уйламыйча.
[4] Табгы сәлим иясе — акыллы кеше.
[5] Рәвеш — хәл мәгънәсендә.

мәел кыйлучы[1] адәмнәр күбрәк булыр иде. Инде кемнең моңар акылы җитә? Начальник булган адәм дә тәҗрибәле булмак кирәк. Югары начальниклар мәдрәсәләрдә русча укылсын дип хөкем ясаганнар. Алар мәдрәсә ни кыяфәттә икәнлеген килеп күргәннәре юк. Алар, бәлки, гөман кыйлганнардыр, гимназияләр шикелле дип. Әгәр белсәләр, икенче тарикъча бер тәдбир ясарлар иде. Түбәнге начальник моннан ары мәслихәтен үзе белмәк кирәк иде. Әмма асыл бу инспекторлык хезмәтен рус халкыннан бирәүгә, Россия кешесенә тапшырмак кирәк иде. Чөнки Россия кешесе мөселманнар белән бер җирдә (торган) һәм бер җирдә үскән, бер икмәкне ашап үскәнлекләре сәбәпле, бу ике халык бер-берсенең гадәтен вә мөгамәләсен яхшы беләләр. Мөселманнар өчен ни тарикъча мәслихәт икәнен Россия кешесе яхшы беләдер һәм бәгъзе хосуста, урынына күрә, правительствоның решениесен үзгәртергә тарикын карыйдыр. Һәрничек Россия кешесе һәркайсы бер-берсенең мәслихәтен яхшы беләдер. Татарның холкын, фигылен, гадәтен вә һәм башка мөгамәләсен белмичә торып, еракта́н «татар дигән халык бар, имеш» дип ишетү белән генә татарларга начальник булуы читен. Начальник булгач та, үз күңеленә муафыйкны гына кыйлып булмыйдыр. Низамнар, законнар күбрәк халыкның гадәтеннән, мөгамәләсеннән истихраҗ кыйлынадыр[2]. Тәҗрибәле кеше булса, аның кул астында хезмәт итүчеләргә уңайрак буладыр. Мәмләкәтнең фәрманы һомаюн[3] иясе булган адәм куйган низам вә законнан һич кеше: русы, татары, чувашы, чирмеше вә гайреләре һәркайчан баш тартмыйдыр. Әлбәттә, иҗраи закон[4] вә низам өчен куелган адәмгә фикре саип[5] кирәк. Фәкать коры тавыш кына җитмидер. Шулай итеп, бу мәдрәсәне вөҗүдкә чыгару хосусында гаять халәте изтыйрарда[6] булып, бу адәм өч ел михнәт чикте. Чөнки бу эш билкөллия яңа эштер, моңар чаклы булганы юк. Бу адәм үзе ихлас белән халыкка бернәрсә файда китерим дип тырыша. Кадерен белгән юк. Аның өстенә күп төһмәт вә бөһтан вә тәгънә[7] ишетәдер. Мөселманнарга ярыйм, дип әйтсә, начальник форма требовать итә. Начальникка ярыйм, дип әйтсә, мөселманнарга уңайсыз, башала бизәләр. «Ахирәт дәрәҗәсен арттыра торган эш түгел, сабакка бармасаң да ярар»,— дип, балаларын сабакка йөртүдән туктаталар. Бу бичараның кадимге дуслары бизеп бетте, очраса, сәлам дә

---

[1] Мәел кыйлучы — алынучы.
[2] Истихраҗ кыйлына — чыгарыла, алына.
[3] Фәрманы һомаюн — зур власть.
[4] Иҗраи закон — законны эшкә ашыру.
[5] Фикре саип — туры фикер, туры караш.
[6] Халәте изтыйрарда — чарасыз хәлдә, аптыраштa.
[7] Төһмәт вә бөһтан вә тәгънә — яла ягу һәм хурлау.

бирмиләр. Бу — начар, намәшруг[1] эш артыннан йөри, мөселманлыктан чыгып, ислам диненең хилафенә[2] йөри дип хыял кыйлалар. Бу хосуста бигрәк кабахәт «сияһлар[3]». Диннең каралуына бу кеше сәбәп буладыр,— дип,— бу эш, фәкать бу адәмнән садир улды[4]», — диләр. Шундаен сүзләр бу адәмне изтыйрарга[5] салганлык сәбәпле, вазыйфасының[6] бәрәкәте юк. Акчасының тәме юк. Һәм вазыйфасын тизрәк барып алыйм дип, ул кадәр ыргылып тормый. Биш-алты ай акча барып алырга охотасы юк. Әгәр бу адәмнең бу хосуста иҗтиһатын правительство үлчәүгә салып караса, фәкать бер мәдрәсәне вөҗүдкә китергән өчен биш мең тәңкә җүгыль[7] тиеш иде. Әүвәл баштагы кыргыз лафызларына игътимат кыйлып[8], бу адәм байтак гомерен вә сәламәтлеген сарыф кыйлды. Бар да һәбаән мәнсүра[9]. Моннан соңгылар, әлбәттә, файдаланырлар. Халык та күнегер, тыныч булыр, неприятно сүзләр ишетмәс. Әмма һәрбер нәрсәне әүвәл башта ихтираг кыйлган, вөҗүдкә чыгарган[10] адәмнәр, халыкның тәгънәсеннән[11] башка нәрсә хасыйл итмиләр. Нитәкки, Колумб вә һәм Гутенберг вә гайреләрнең кыйссасы мисалы мәшһүрдер. Аларның хасиятен соңгы гасырдагы адәмнәр генә беләләр. Тугры акыл иясе үзенең акылына салып фәһем итсә мөмкин; әүвәл кабак өстендә мәдрәсә ясап, аннан тагы яхшырак фатирга, аннан тагы яхшырак фатирга, янә аннан тагы яхшырак фатирга югары этажга мәдрәсә ясавы, хәзердә мәдрәсәнең сыйфаты гимназия классларыннан бер дә ким түгел, һәммәсе Европа мәдрәсәләренчә төзелде. Класс скамьялары һәйбәт, балалар шөгыль вакытында әдәп-инсаф белән утыралар, күргән кеше хәйран булырлык. Мөрәббиең[12] идарә кыйлуда мәгърифәтсез булса, хатыныңны казый орса, кемгә шикаять кыйлырсың? Вай бу адәмнең хәле! Ни мәгънә? Иҗтиһат сарыф кыйлды, максудына улашмады. Мәзкүр тәҗрибәсез мерәббие бу адәмнең иҗтиһадына рәваҗ[13] бирмәсә, ни кыйлсын? Обществога ни файда кыйлмады бу адәм! Кирәк рус егетләренә булсын, кирәк мөселман балаларына булсын, егерме елдан бирле дәрес биреп, вә

---

[1] Намәшруг — дин законнарына каршы булган.
[2] Хилаф — зарар.
[3] Сияһлар — карагруһлар.
[4] Садир улды — башланды.
[5] Изтыйрар — кайгы.
[6] Вазыйфасының — хезмәт хакының.
[7] Җүгыль — түләү.
[8] Игътимат кыйлып — таянып.
[9] Һәбаән мәнсүра — җилгә китте, бушка чыкты.
[10] Башта ихтираг кыйлган, вөҗүдкә чыгарган — уйлап тапкан, эшкә ашырган.
[11] Тәгънәсеннән — сүз озатуыннан, тиргәвеннән.
[12] Мөрәббие — тәрбияче.
[13] Рәваҗ — игътибар (алга җибәрү).

никадәр файдалы нәрсәләр тасниф кыйлып, күп гомерен сарыф кыйлды. Хәзердә дә бөтен Казан губернасындагы духовный җәмәгать, гаибанә[1] вә мөшафәһәтән[2] зикер кыйлып, благодарность укыйлар. Ул бер грамматика яздырып бастыруы — файдалы түгелме, ниндәен зур кәттә профессорлар бу грамматикага ссылаться итәләр. Алтмышынчы елдан бирле күп адәмнәр кулында метод улдыр. Янә «Сборник статей» дигән бер мосаннәфе[3] кайсыдыр кем, семинария шәкертләре өчен татар теленә тәсныйф кыйлынгандыр, үз вакытында семинария шәкертләре файдаландылар. Бәгъзе берләре, яхшы книга чыкты, дип сөеп заниматься иттеләр. Боларны укып файдаланган адәмнәр — җөмләдән берсе Масловский, Катаринский, Пенковский вә гайреләр хәзердә дә игътираф кыйлалар[4].

*1876 сәнә*

## ИГЪЛАННАМӘ

Казан шәһәрендә икамәт итүче[5] гыйззәтле мөэмин вә мөселман кардәшләргә игълан кыйламын, шул хосуста кем, бу Россия мәмләкәтендә торып русча белмәк дөнья мөгамәләсе өчен гаять зарур вә мөһим эштер. Әкалле мәртәбә[6] укырга вә язарга өйрәнмәк бик лазем булмак кирәк. Мөселман балаларына русның бәгъзе мәдрәсәләренә кереп укырга мөмкин булса да, бәгъзе уңайсызлыклар бар. Мәсәлән, рус мәдрәсәләрендә дәрес күбрәк иртә берлә, өйләгәчә буладыр. Безнең мәдрәсәләребездә һәм өйләгәчә дәрес бирелә вә сабак укыладыр. Бер бала, русча өйрәнермен, дип, рус мәдрәсәсенә керсә, әлбәттә, үзенең мәдрәсәсен ташласа кирәк. Бәс, мөселман балалары өчен русча өйрәнергә бер уңай җир юктыр, әгәр дә учитель яллап, өенә чакырып укытмаса. Бу эшләрне исәп итеп караганнан соң, күңелемә бу килде ки, мин дә азрак русча белән укырга да, язарга да беләмен. Үзем белгән кадәр икенче кешегә һәм өйрәтергә булыр. Җәнабе галиләрегезгә мәгълүм итәмен, бала-чагагызны азрак русча өйрәтергә минем кулымнан килер һәм күп хак сорамыйм. Бер ай укытыргамы — сөйләшербез. Бик ким бәһа берлән укытырмын. Үземнең фатирым фәлән йортында. Эстәрсәгез[7], үземне күреп сөйләшерсез.

*Габделкаюм мулла Габденнасыйр углы*

---

[1] Гаибанә — күрмәстән.
[2] Мөшафәһәтән — күрешеп, сөйләшеп.
[3] Мосаннәфе — төзелгән китабы.
[4] Игътираф кыйлалар — таныйлар, әйтәләр.
[5] Икамәт итүче — торучы.
[6] Әкалле мәртәбә — иң аз дигәндә.
[7] Эстәрсәгез — теләсәгез.

# БАЛАЛАРГА ТӘГЪЛИМ БИРМӘК

Заманабызда балаларга тәгълим бирмәктә бераз тәртипсезлекләр сизеләдер. Бер тәртипкә салмак бик зарур иде. Хасыйле кәлям, балаларга азрак гакыл керә башлагач, файдасыз вә мәгънәсез нәрсәләргә вә уенга мәел кыйлмасын өчен кулына кәгазь, карандаш биреп сабак укый башлаган булмаса да, хәреф куярга, таки, хәрефнең ни икәнен белмәсә дә, хәреф куя белсен. Бәгъзе балалар буладыр, үгрәтүче булмаса да, үзеннән-үзе карандаш, кәгазь табып, сызгалап бер нәрсә сурәте, пароход сурәте яки әтәч сурәте куеп маташа, яки пычак вә агач кисәге алып, юнып тәти ясыйдыр. Мондаен эшләр баланың һөнәрле булмакына дәлилдер. Мондаен эшләрдән аны тыярга кирәкмәс, теләгәнен кыйла бирсен. Әлбәттә, бу яманлыкка таба түгелдер. Әмма бәгъзе балалар, ишек алдына вә урамга чыгып, үз тиңдәше балаларны табып йөзек уйнамага, акча вә кузна уйнамага, вә күгәрчен очыртмага мәел кыйла башлыйдыр. Мондаен эшләрдән балаларны тыя килергә тиеш. Мутлыкның вә һөнәрсезлекнең ибтидасы йөзек уйнамак, акча уйнамак, күгәрчен очыртмак кебек нәрсәләрдер. Вә төрле балалар белән урамда шаярып вә төрле әлфазе кабихәләрне[1] ишетеп, табигате билкөллиһи һөнәрсезлек тарафына юнәлсә, ата-ана сүзен вә хәлфәләре сүзен тыңламый башлыйдыр, табигате һөнәрсезлек тарафына юнәлсә, ул баланы тәртипкә салмак читендер. Мондаен хосусларда балаларны иркәләмәк тиеш түгелдер. Яман фигыльләрдән вә явыз холыклардан тыя килергә тиештер. Аннан соң мәдрәсәгә бер яхшы хәлфәгә биреп, иҗекне тәмам танып җиткәч, батәртип[2] төрки китапларын күп укытмак лаземдер. Аз-маз төрки китаплары укып, ашыгып гарәпкә төшермәктә мәгънә юктыр. Хәтта укымаган, күрмәгән, ят төрки китапларын укып карап тәҗрибә кыйлмак кирәк, таки төркигә тәмам төшенсен. Дәхи язуга үгрәткәндә дә гаять тәхкыйк[3] вә дикъкать белән мәнфәгатьле тарикъча[4] язуга төшендермәк лазем. «Әүвәл алдым биш баш куян тиресе» — язу үгрәтмәкнең тарикы шулай түгелдер. Әхлак мәсьәләләреннән көн саен берәр мәсьәлә күчергеч язу бирмәк кирәк. Яки укыган сабагын тәкрар китаптан күчерсен. Гәрчә тәмам кагыйдә белән булмаса да, хәрефләрне дикъкать белән дөрес куйдырмак тиеш. Кечкенә вакытта яхшы тәгълим алмаганлыктан бәгъзе адәмнәрнең билкөллиһи язулары язуга, хәрефләре хәрефкә охшамыйдыр. Игътибарсыз, аннан-моннан сыз-

[1] Әлфазе кабихә — сүгену сүзләре.
[2] Батәртип — тәртип белән.
[3] Тәхкыйк — дөрес итеп.
[4] Мәнфәгатьле тарикъча — файдалы ысул белән.

галамак язуны вә хәрефләрне тәхфиф кыйлу[1] булмас микән, чөнки безнең язу хәрефләребез Корьән сүзендәге хәрефләрдер, ригая кыйлмак[2] тиеш. Хәреф хөрмәте бар... Аннан соң җиңелрәк гыйбарәтле гарәп китапларына төшермәк кирәк, һәрбер сабак биргәндә кирәк төрки, кирәк гарәп китабы булсын, укыган сабагында ни әйтте, дип, сабак баласының үзенә тәкърир кыйлдырырга[3] кирәк. Таки укыган сабагыннан фәһемләгән нәрсәсе хәлфәгә дә мәгълүм булсын. Билә тәкърир кыйлдырып укытмакта күп файда бардыр. Язу вә тәгълим биргәндә дә сабак баласының үзенә тәкърир кыйлдырып тасниф кагыйдәсен үгрәтмәк лаземдер. Мәдрәсәдә пешмәгәнлектән, дөньяга чыккач та биш-алты юл хат тасниф кыйла белмәгәннәр бик күптер. Аннан соң, күбрәк төшенә башлагач, сарыф вә нәхү истыйляхатеннән[4] фигыль, фагыйль (мөбтәда), әхбар, мосаф, мозафен иләйһи[5] кебек нәрсәләрне әнмүзәҗләрдән[6] интихаб кыйлып[7] бераз гына белдермәк бик файдалы булыр иде һәм олуг голяма вә мөдәррисләр моңар игътибар кыйлып, сарыф вә нәхү кагыйдәләрен белдерер өчен бер кечкенә китап ясасалар, мәдрәсәдә озак укымый торган балаларга бик яхшы булыр иде. Сарыф вә нәхүнең иң кирәкле кагыйдәләрен аз заманда бер тарикъча белдерергә мөмкиндер.

Вә дәхи урысча укыла торган җирләрдә вә мәктәпханәләрдә урысчага төшендереп, грамматика кагыйдәләренә һәм аз-аз төшендермәк лазем вә янә мәдрәсәдә хәлфәдән укый торган бала, әгәр гыйлем вә һөнәргә кабилиятьле[9] күренсә, инде укыганы йитәр, мулла буласы кеше түгел дип, мәдрәсәдән алмак бик хата эштер.

Олуг голяма вә мөдәррисләрдән үтеп, мондаен сүзләрне сөйләмәк безнең вазифабыз түгел иде. Әйттек исә, тагнә кыйлмаясыз[8]. Ләкин олуг голяма вә мөдәррисләргә мондаен нәрсәне игътибарга алмак бик лазем иде, чөнки ихьяи шәргъ[9] дигәнемез мондаен ибтида кыйлынадыр[10].

---

[1] Тәхфиф кыйлу — кимсетү.

[2] Ригая кыйлмак — олылау, хөрмәтләү.

[3] Тәкърир кыйлдырырга — сөйләтергә.

[4] Сарыф вә нәхү истыйляхате — морфология һәм синтаксис терминнары.

[5] Фагыйль (мөбтәда), әхбар, мозаф, мозафен иләйһи — ия, хәбәр, иярүче сүз, ияртүче сүз.

[6] Әнмүзәҗ — өлге, калып, үрнәк; К.Насыйри язган татар теле грамматикасы исеме.

[7] Интихаб кыйлып — аерып алып.

[8] Тагнә кыйлмаясыз — сүкмәгез.

[9] Ихьяи шәргъ — ислам шәригатен торгызу.

[10] Ибтида кыйлынадыр — башланадыр.

## ӘЛҖАҺИЛ

Әй угыл, наданлык дигән нәрсә бик мәзмүм[1] сыйфаттыр. Белмәклеге важиб[2] булган нәрсәне белмәссезлек харамдыр. Наданлык дәвасыз бер авырудыр. Наданлык ике төрледер: берсе фәкать наданлык вә белмәссезлектер, гыйлаҗны кабилдер[3]. Бу кеше укыса, тәгълим алса вә гыйлемгә мөдавәмәт кыйлса[4], галим булмакны кабилдер. Әмма җәһле мөрәккәб[5] дирләр: бер төрле наданлыктыр ки, һичбер гыйлаҗны кабил түгелдер, чөнки ул кешедә ике наданлык җыеладыр: берсе — надан, бернәрсә белмәй, дәхи үзенең белмәгәнен дә белмәйдер, белмәгәнлеген гыйлемгә саядыр. Әүвәлге нәүгысыннан[6] әшәд мәзмүмдер[7]. Бу кеше хайван белән бәрабәрдер. Наданлыкның зыйдды[8] гыйлемлектер, мәмдүх[9] сыйфаттыр. Гыйлем яхшы сыйфат вә наданлык мәзмүм сыйфат икәненә дәлил шул йитәр ки, бер чеп-чи наданга, син белмәйсең, дисәң, дошман буласың, бер наданга, бәрәкаллаһ, яхшы гыйлемең бар, дисәң, шат буладыр, сине дус- тотадыр.

## «ӘХЛАК РИСАЛӘСЕ»ННӘН

...Мәгълүм ула ки, адәмне башка хайваннан аера торган сыйфат нотыктыр, ягъни сүз сөйләшүдер. Аның соңында, камил адәм булмак өчен, белмәгәнене үгрәнмәк, изге холык белән явыз холыкны белмәк, вә изге холык белән холыкланып явыз холыктан сакланмак лаземдер. Чөнки башка хайваннар һәм адәм кебек ашар, эчәр, йоклар вә дәхи моның кебек сыйфатларда адәм белән хайван икесе дә бердер. Инде адәмнең башка хайваннардан аермасы шулдыр ки, адәмнең гакылы бар — фикерли белә, теле бар — сөйләшә белә. Ошбу тел вә сөйләшү дигәнемез дәхи гыйлем белән, ягъни мотлакан[10] белмәгән нәрсәләрне белгән кешеләрдән үгрәнеп белмәк вә китаптан укып фәһемләмәк белән булыр. Әмма адәм бу мәзкүр сыйфат белән башка хайваннардан аерылгач та, һәнүз камил адәм түгелдер.

---

[1] Мәзмүм — начар, хурлыклы.
[2] Важиб — тиеш.
[3] Гыйлаҗны кабилдер — төзәлә алырлыктыр.
[4] Мөдавәмәт кыйлса — омтылса.
[5] Җәһле мөрәккәб — чеп-чи надан, томана.
[6] Нәүгысыннан — төреннән.
[7] Әшәд мәзмүмдер — тагын да әшәкерәктер.
[8] Зыйдды — киресе, капма-каршысы.
[9] Мәмдүх — мактауга лаек (мактаулы).
[10] Мотлакан — тулысынча.

Кәмаль адәмилек дәхи изге холыклы булмак вә явыз холыктан сакланмак белән хасыйл булыр. Ошбу җәһәттән балалар акны-караны аерып белә башлаган вакытларында яхшы вә яман нәрсәләрне дәхи аңлатмага иҗтиһад вә гайрәт итмәк бик лазем нәрсәдер, чөнки балалар яшь агач кебектер. Яшь агач һәр никадәр кәкре булса да, төз итмәк асаттыр. Шуның кебек, адәм дәхи кечкенә вә яшь вакытта тәрбияне кабул итмәке асан[1] булыр. Ләкин үсеп йиткәч, хосусән явыз вә яман холыкларга гадәтләнгәннән соң, аны шөйлә яман холыклардан аерып, изге юлга күндермәк гаять мөшкел эштер...

* * *

И газиз бала! Агяһ бул, адәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лазем нәрсә — гыйлемдер. Вә гыйлем дигәнебез белмәгән нәрсәне үгрәнеп вә сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнебез белмәклеге лазем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер вә хайван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр. Кайда барса да, надан кешенең кадере юктыр. Инде гыйлем үгрәнмәгә, ниятеңне яхшы дөресләп укымага, язмага вә һөнәр, вә мәгърифәт хасыйл итмәгә иҗтиһад кыйл, чөнки гыйлем вә мәгърифәт иясе һәр җирдә хөрмәтле булып, халык арасында кадере зур булыр. Наданлык һәркайчан сине үкендерер, һай, гомерем үтте, сабак укымадым, надан калдым, дирерсән... Наданлык шундаен бер сыйфаттыр. Илаһи ният кыйлдым гыйлем үгрәнмәккә, белмәгәнемне белмәк өчен вә белмәгәннәргә үгрәтмәк өчен, вә шәригатьне тергезмәк өчен, вә дин исламны бакый кыйлмак өчен, дип ният итеп гыйлем үгрәнмәгә иҗтиһад кыйла күр... Наданлык сыйфаты бик яхшы сыйфат түгел. Надан кала күрмә, сабак укыганда белмәгән вә аңламаган сүзеңне хәлфәңнән сора. Укып кына белми кеше, сорашып күбрәк гыйлем хасыйл була. Ни укысаң да, сабак алган вакытта белми китәргә бер дә ярамас. Белмәгән сүзеңне хәлфәңнән йә башка кешедән сорарга бер дә оялма...

Хәлфәңне борчып бетер, бу тугрыда хәлфә сиңа бер дә рәнҗемәс. Инде һәркайчан мәсьәлә сорасаң, ашыгып сорама, үзеңә гыйбадәткә вә мөгамәләгә тиешле мәсьәләне сора. Урынсыз ашыгып сорасаң вә тиешсез мәсьәләне сорасаң, оятка калырсән, наданлыгың зоһур булыр[2]...

---

[1] Асан — асат.
[2] Зоһур булыр — күренер.

## АРАКЫ ЭЧӘРГӘ ГАДӘТЛӘНГӘН КЕШЕЛӘРГӘ БЕР-ИКЕ КӘЛИМӘ СҮЗ

Һәркем аш ашарга утырганда тоз ала, борыч ала, аш арасында ит капканда, тозга бармак тиереп яисә итне тозга тидереп каба. Ашның, итнең ләззәте артык була. Ашка азрак борыч сибәләр, ашның табигате хуш була. Тозның, борычның адәмгә һич зарары юк, бәлки файдасы бар. Әмма әгәр берәү тозны, борычны учлап яки бөтенләй савыты белән кабып җотса, шул сәгать авыру булачагы билгеле. Хәтта үләр. Моның кебек дәхи аракы аш алдыннан бер уймак яки ярты рюмка аракы гадәтләнгән кешегә файдалы, ләкин бәгъзе ахмаклар бар, берьюлы бер касүшкә яки полштофны эчеп җибәрә. Бу кешегә исерү генә аз, исерсә бернәрсә булмас иде, хәтта үзенә бер авыру пәйда буладыр. Мигъдәсендә[1] рак дигән авыру — һичбер дару белән төзәлми торган авыру. Эчкән кеше кабакка кергәндә шуның кебек нәрсәләрне исенә төшерсә ярар иде.

## АРАКЫ ДИГӘН ЭЧЕМЛЕК АДӘМИ ЗАТ ӨЧЕН САРЫФ БЕР АГУДЫР

Аракы белән торган кеше судан үләр — бу дәхи бер мәкальдер — ягъни гомере буенча күп аракы эчкән кеше ахырында истиска[2] зәхмәте белән вафат булыр димәктер. Европа халкының гашәре, ягъни ун өлештән бер өлеше, төн-көн тиргә батып эшлидер — ни эшләйдер, үзенә агу хәзерләйдер, вә үзенең эшләүче көчен вә куәтен тәләф кыйладыр[3], вә үзенә вә балаларына мосләххanәләрдә вә диванахaнәләрдә, вә гыйлаҗханәләрдә, вә зинданнарда урын хәзерлидер. Дәхи белмәк кирәктер ки, эчемлек истигъмаль кыйлгучыларның яртысы гакылдан шашып үләдер. Европаның башка мәмләкәтләренә караганда, рус мәмләкәтендә ул кадәр түгел, дисәләр дә, бер ел эчендә биш мең дә бер йөз кеше эчемлектән үлгән күренәдер. Бу кадәр булыр микән, дип шөбһә тотсагыз да, бәлки, мөзагаф[4] булмак ихтималы бардыр, чөнки күп вакыйгалар вә күп кешенең үлеме мәгълүм булмай каладыр. Хәтта яшь вакытта эчемлекне күп истигъмаль кыйлып пәйда булган сырхаулар,

---

[1] Мигъдәсендә — ашказанында.
[2] Истиска — сары су авыруы (русча «водянка» дип атала).
[3] Тәләф кыйладыр — әрәм-шәрәм итәдер, һәлак итәдер.
[4] Мөзагаф — икеләтә артык.

бара торгач көчәеп, вакытыннан мөкаддәм әҗәлгә сәбәп буладыр. Хәланки[1] кеше аны үзе белмәйдер, фәлән авыру белән үлде, дип, икенче бер авыруны күрсәтәдер. Вакыйган яшь вакытта эчемлектән хасыйл булган авыру иде. Тәҗрибәдән беленәдер ки, эчкән кешенең башы авырудан күп чыкмайдыр, вә эчкән кеше гомеренең ахырына күп барып җитмәйдер, яшь заманында ук үлеп китәдер.

Эчемлек шикелле адәмне мөһлик[2] нәрсә вә эчемлек шикелле сиздермәенчә куәтле нәрсә итә торган һичбер агу юктыр. Адәмдә холкан вә табган[3] ни яхшы нәрсә булса, эчемлек һәммәсен юкка чыгарадыр. Эчемлекнең кайсы гына нәүгысын[4] алсаң да, һәммәсе адәмгә зарарлыдыр вә агудыр: кирәк йөземнән мәгъмүл[5], кирәк икмәктән мәгъмүл булсын — кирәк тазарткан, кирәк тазартмаган эчемлек булсын, һәммәсендә рух (спирт) бардыр. Аның зарарлы матдәсе шулдыр — аның зарары шул кәйфиятьтәдер ки, ашаган-эчкән тәгамнән хасыйл булачак канны тәнгә йибәрмәйдер вә сеңдермәйдер. Хасыйле кәлям, эчемлек адәмгә шөйлә зарардыр ки, әгәр дә адәм черегән нәрсә ашаса, нитәкки зарар итәдер, тазартмаган эчемлек эчеп адәм тизрәк мәсмүм буладыр[6]. Зарарлы нәрсә катышмаган һич йөзем аракысы юктыр, һәрбер йөзем суын чагыр тәсмия кыйлынган мөддәтендә карурәгә[7] тутырмас борын, төсе матур булсын өчен бер төрле буяу җибәрәләр. Гаять зәһәр эчемлек буладыр. Чит йорт сатучылары игъланнамәләрендә үзләре язалар ки, йөземнән мәгъмүл эчемлеккә төс бирәбез ки, һичбер җәһәттән белергә мөмкин түгел, диләр. Әмма аны зарарлы нәрсә катышкан икәнен асат белергә мөмкин, чөнки андаен җәгъли[8] эчемлек карурәләрендә серкәләнеп ачыйдыр, иң зарарлы рух хасыйл буладыр...

Эчемлектән хасыйл булган авыруны туксан табиб дәва кыйлсалар да мөмкин булмайдыр. Мәгәр эчемлекне билкөллиһи ташларга кирәк. Эчемлектән ашказаны бозылып, ашаганы батмас буладыр, һич гыйлаҗны кабул итмәгән бер авырудыр. Табибларның азрак аракы вә гайре эчемлек адәмгә файдалы

---

[1] Хәланки — чынлыкта.
[2] Мөһлик — һәлакәткә илтүче.
[3] Холкан вә табган — холкы һәм табигате ягыннан.
[4] Нәүгысын — төрен.
[5] Мәгъмүл — эшләнгән.
[6] Мәсмүм буладыр — агуланадыр.
[7] Чагыр тәсмия кыйлынган мөддәтендә карурәгә — чагыр дип аталырлык хәлгә килеп җиткән вакытта шешәгә.
[8] Җәгъли — ясалма.

дигән ялган игътикадлары[1] адәмнең бозылуына вә исереклекнең күбәюенә бер бик олуг сәбәптер ки, күп адәмнәр үзләренең наданлыкларына бинаи[2] аракыны дәва мәнзилендә истигъмаль кыйлалар, хәтта бәгъзе табиблар икенче тарафтан аракының адәм бәдәненә зарарын фәһем итмәенчә, аш алдыннан берәрне җибәрергә мәслихәт кыйлалар. Һай-һай, мондаен шәриф[3] дәваны уймак шикелле бер кечкенә генә финҗаннан[4] башлап адәм стаканга ирешә, аннан бөтен карурәсен эчеп бетерәдер. Чәй вә кәһвә шикелле гадәт булып, ни барын эчеп бетерәдер...

Әмма бу аракы вә эчемлек эчүнең сәбәпләре бик күптер ки, кайгы булса — эчә, шатлык булса — эчә, кыш көне туңса, җылыныр өчен эчә, яки берәр авыру өчен төрле үлән яки бер төрле тамыр белән төнәтеп эчә. Ах Алла, бу ниндәен гаҗәп дәва, имеш, әхваләт мөхтәлифәдә[5] файдасы бар, имеш. Әмма әрем белән вә гайре үләннәр белән төнәтеп эчүнең күзгә зарары күптер. Күзебез алдында булган вакыйгадан берсе: бер мәгълүм хатын әүвәл туйганчы кан алдырып, аннан соң чирек аракыда тамыр төнәтеп эчмеш икән, ике күзеннән җәда булып[6] гыйлаҗханәдә ничә айлар дәва иттереп, алай да күзлексез чара тапмамыш. Мондаен зарарны ник фәһем итмәй бу бичаралар?..

Аракы вә гайре эчемлек мигъдәгә төшсә, агу кебек әсәр итәдер. Мигъдәдән бөтен тәнгә сәер кыйладыр[7]. Тәндә канның гадәти йөрешен бозадыр һәм тәнгә һичбер мәнфәгать[8] бирмәенчә, мигъдәгә кайтадыр. Канның вә тамырларның гамәле бозылып, ничә көннәр яңадан төзәлергә кирәк буладыр. Халыкның наданлыгы шул дәрәҗәгә җиткермеш ки, гүяки аракының ашаганны сеңдерергә файдасы бар, имеш. Һәйһат![9] Әмма вакыйган аракы вә гайре эчемлек хәтта аш сеңүне зәгыйфьләндерәдер, хәтта кешене билкөллиһи ашамас итәдер, тәгамга иштиһаны[10] бетерәдер, бары эчне вә мигъдәне көйдереп сусатадыр. Хасыйле кәлям, ашны сеңдереп тәнне тәрбия кыйла торган сыйфат аракыда вә гайре эчемлекләрдә асла юктыр. Бәгъзеләр тәмам ялгыш гөман кыйлалар[11] ки, эш кешесенә эчәргә кирәк,

---

[1] Игътикад — ышану.
[2] Бинаи — нигезләп, таянып.
[3] Шәриф — кадерле.
[4] Финҗан — чәшкә, чынаяк.
[5] Әхваләт мөхтәлифәдә — төрле-төрле хәлләрдә.
[6] Җәда булып — аерылып.
[7] Сәер кыйла — тарала.
[8] Мәнфәгать — файда.
[9] Һәйһат! — нинди зур хата!
[10] Иштиһаны — аппетитны.
[11] Гөман кыйлалар — уйлыйлар.

кувәтне торгызадыр дип уйлыйлар. Юк, эчемлек кувәтне торгызу түгел, бар кувәтеңне бетерәдер. Әмма бу гөман бик олуг хатадыр. Эчемлек эчкән кеше моны дәлил итеп тотадыр. Мондаен эшләр җиребездә исереклек күбәюенә зур сәбәптер. Мәгълүмдер ки, төкерекнең мигъдәдә аш пешүенә вә аш сеңүенә күп сәбәбе бардыр. Әмма аракы эчкәннән соң авызда төкерек кибәдер, төкерек урынына бер төрле куе вә ачы нәрсә пәйда буладыр. Бу матдә мигъдәгә төшкәннән соң, авыру пәйда кыйла вә косасы килдерәдер. Вә кәзаликә[1] уйлаганнар иде вә һаман уйлап торалар ки, эчемлек арыган кешенең кувәтен кайтарадыр вә кувәтен арттырадыр, имеш. Юк. Бу һәм ул гөманча түгелдер. Бары тик арыган атны чыбыркы белән сугу кабиленнәндер ки, арыган ат чыбыркы белән суккач, бар кувәтен җыеп, бар көче белән тартып, егылганчы барадыр. Кәзалик адәм дәхи аракының чыбыркысын күзе белән күрмәй үзен тәләф кыйладыр[2].

Эчемлек якыйнән[3] хәвасе хәмсәне[4] зәгыйфьләндерәдер. Бер мөддәткә[5] генә кайгыны оныттырадыр. Халәнки бер кайгыны ике итеп кайтарадыр вә иштиһаны бетерәдер, вәхаләнки эчкән кеше иштиһаны ача дип хата гөман кыйладыр. Вә суыкны сизмәс итәдер, авыртканны сизмәс итәдер, әмма бу бер ялган гөмандыр ки, эчемлек кувәтне арттыра, имеш, әгъзаны тергезә, имеш, иштиһаны ача, имеш. Әлбәттә, бу ялган гөманны шайтан илка кыйлмыштыр[6]. Вә эчемлекнең иштиһаны бетермәклеге вә аракы эчеп кеше үзенең арыганын белмәгәнлеге адәмгә гаять зарардыр, чөнки адәмнең ашарга иштиһасы вә адәмнең холкы, кувәте адәмне хифыз вә химая[7] кыйлгучы нәрсәләрдер.

Һәркем вә һәрбер ахад[8] хисаб кыйладыр ки, эчемлекнең адәмне җылыта торган хасияте бар, имеш, ки, һәрбер эчемлек эчкән кеше инсафына кайтып әйтсә, моны рәд[9] кыйла белер вә инкяр кыйлыр. Чөнки эчемлек эчкән кеше кирарән[10] тәҗрибә кыйлгандыр ки, ул бер мөгайян[11] микъдар аракы эчеп, әүвәл мәртәбәдә җылынган шикелле булыр. Әмма бераздан тәненең җылысы

---

[1] Кәзаликә — шулай ук.
[2] Тәләф кыйладыр — һәлак итәдер.
[3] Якыйнән — шиксез.
[4] Хәвасе хәмсә — кешедәге биш тойгы.
[5] Мөддәткә — вакытка.
[6] Илка кыйлмыштыр — ташлагандыр.
[7] Хифыз вә химая — тынычландыру һәм саклау.
[8] Ахад — гади халык, аерым кеше.
[9] Рәд — кире.
[10] Кирарән — күп мәртәбә.
[11] Мөгайян — билгеле.

сүрелеп айныгач, бизгәк тоткан кебек әгъзасы калтырайдыр. Моннан беленәдер ки, эчемлек йөрәктәге канны тәннең тышына ыргытадыр. Адәмдә җылылыкны, суыклыкны сизә торган ләмес[1] кувәте заил буладыр[2]. Җылылык тәннең бары тышына киләдер, кан тамырлары киңәядер, шул сәбәпле эчкән кеше кызыл төсле буладыр. Тәненең җылылыгы эчемлек эчкәннән соң кимидер. Ни өчен? Эчемлек тәннең тышкы тарафындагы кан йөри торган вигаларны[3] вә кан юлларын киңәйтәдер, эчтәге җылыны киметәдер. Шул җәһәттән исерекләр аек кешеләрдән күбрәк катып үләләр.

Эчемлек истигъмаленнн канның сәере кувәтләнәдер, игътидалдан[4] чыгадыр, ягъни гадәти йөрешеннән артык тиз сәер кыйладыр. Эчтәге хәмернең гайрәте беткәч, янә зәгыйфьләнәдер. Эчемлекне эчкәндә сулыш әүвәл кувәтләнәдер, аннан соң ул һәм игътидалдан чыгадыр, ягъни эчтә хәмер кувәте барында нык тәнәффес кыйладыр[5]. Айныгач гаһән[6] җыш тәнәффес кыйла, гаһән бик сирәк тәнәффес кыйладыр вә һәм көч белән тәнәффес кыйладыр, вә нәфәсе[7] гырылдап киләдер. Шулай итеп адәм тәненең гамәлләренә һәр каюсына хәләл[8] киләдер вә игътидалдан чыгадыр. Вә адәмнең тәненнән аерылып чыгасы матдәләр тәндә каладыр. Мәсәлән, тәнәффес кыйлганда адәмнең үпкәсеннән хамиз фәхиме (угольная кислота) дигән нәрсә аерылып чыгадыр. Бу матдә үпкәдә калса, гайне[9] зарардыр. Эчкән кешенең үпкәсендә мәзкүр хамиз фәхиме бүленеп калса, үпкәнең вигалары вә савытлары бер төрле спирт лайласы белән туладыр. Йөрәк сикерүе кувәтләнәдер, кан тамырлары киереләдер. Үпкә бар кувәте белән тәннән пычрак эчемлекне чыгарырга үзендә бар гамәлен сарыф кыйлып та, ул бозык матдәне аерып чыгара алмаганына гаҗиз булганнан соң, үпкәнең үзендә бер илтиһаб[10] хасыйл булып, ахырында силгә (чахоткага) әйләнәдер. Әлгаязе билләһи[11], ахыры үлемдер. Яман эчемлек булса, актыгыннан көзән җыеру пәйда буладыр һәм гакылы саташадыр.

Исерек кешенең вә эчкән кешенең тәненнән вә әгъзасын-

---

[1] Ләмес — сизү.
[2] Заил буладыр — бетәдер.
[3] Вига — сосуд.
[4] Игътидалдан — нормаль хәлдән.
[5] Тәнәффес кыйла — сулый.
[6] Гаһән — кайвакыт.
[7] Нәфәс — сулыш.
[8] Хәләл — бу урында: кимчелек.
[9] Гайне — бөтенләй.
[10] Илтиһаб — ялкынсыну.
[11] Әлгаязе билләһи — Алла сакласын.

нан су вә ак дигән матдә күбрәк аерыладыр, халәнки бу нәрсәләр тәннең файдасына иде. Әмма бәвеле азрак киләдер. Вә бәвел буласы матдә тәнендә каладыр, вәхаләнки ул матдә тәннән чыкмак зарур иде. Дәхи тәнгә зарур булган матдә хамиз фосфор дигән нәрсә күп аерыладыр. Адәм ошбу агуны истигъмаль кыйлу тәкабәленә билкөллиһи әгъзасы мөтәгайяр буладыр[1] вә һичбер гыйлаҗны кабул итмәгән авырулар пәйда буладыр. Мәсәлән, бавыр авырулары, бөер авырулары вә фалиҗ[2] зәхмәте, вә гакылдан шашу шикелле нәрсә пәйда буладыр, вә дәфгатән[3] егылып китү кебек авырулар күбрәк эчемлектән хасыйл буладыр. Бер дә аракы эчмәгән кешенең үпкәсендә илтиһаб пәйда булса, өмид бардыр ки, дәвасыз төзәләдер. Әмма мөттасил[4] эчкән кешенең үпкәсендә илтиһаб пәйда булса, туптуры үзенә, син үләрсең, дип әйтергә мөмкин.

Ошбу зекер кыйлынган сүзләрдән мәгълүмдер ки, эчемлек истигъмаль кыйлганның зарары гаять олуг вә хәтәрдер. Адәмнең һичбер әгъзасы эчемлекнең зарарын йөкләргә мөкътәдир[5] түгелдер. Әгәр йөз авыру булса, иллесенең эчемлектән пәйда булган авырудыр. Хәтта француз авыруы дигән мәшһүр авыру исереклектән күбрәк пәйда буладыр, ягъни исерек кешегә бу авыру күбрәк ябышадыр. Хәтта бу авыруны эчемлекнең углы дип тәсмия кыйлырга мөмкин.

Дәхи сыра дигән эчемлекнең зарары зыя да күптер, чөнки сыра эчү гаеп түгел дигән кебек, сыраның истигъмален җиңелгә саялар, хәтта бәгъзеләр, сыра файдалы нәрсә, сырада шикәр бар, крахмал бар, дип батыйль гөман кыйлалар[6]. Әмма адәмнең тәне бу нәрсәләргә мохтаҗ түгелдер. Әгәр кирәк булса, ул нәрсәләр сырадан башка һәм арзан вә зарарсыз тарикъ белән табыла торган нәрсәләрдер.

Эчемлек белән мәсмүм[7] булган кеше куркучан вә хафаланучан, вә юкны уйлаучан буладыр, вә юк-барга ачуланучан буладыр, һәм, бара торгач, чынлап авыруга сабышып китәдер. Әмма эчемлек белән мәсмүм булмак ике төрле буладыр: бер мөгайян мөддәттә[8] мәсмүм булып йөри, гаһан буладыр ки, мәсмүм булмаклыгы гомергә китәдер. Бер вакытта мәсмүм булмак ошбу

---

[1] Истигъмаль кыйлу тәкабәленә билкөллиһи әгъзасы мөтәгайяр буладыр — куллану аркасында барлык әгъзалары үзгәрәдер.

[2] Фалиҗ — паралич.

[3] Дәфгатән — кинәт.

[4] Мөттасил — өзлексез, бертуктаусыз.

[5] Мөкътәдир — сәләтле.

[6] Батыйль гөман кыйлалар — ялгыш уйлыйлар.

[7] Мәсмүм — агулану.

[8] Бер мөгайян мөддәттә — билгеле бер вакытта.

рәвешчә буладыр ки, адәм эчәдер, исерәдер. Әүвәл башта бик хозур була, куәтле була, баһадир була, йөрәкле була, күзләре ялтырый, йөзе ачыла. Бу вакытта адәмгә гайре мөтәгариф[1] бер шатлык килә. Аннан соң башы әйләнә башлый һәм мие саташа башлый. Мие саташканлыгы шуннан билгеле ки, сүзенең тәртибе булмай, әйтә торган сүзен онытып җибәрәдер, рабытсыз[2] сүзләр сөйлидер. Бер сүзне кат-кат әйтәдер, үзенең хәлен белмәйдер. Мие саташканлыктан шундаен сүзләр сөйләшәдер ки, аек заманда ул сүзләрне әйтергә үзе дә оялыр иде. Исерек адәмдә оят вә хәя[3] дигән нәрсә... билкөллиһи бетәдер. Шундаен вә шундаен кабахәт гамәлләр кыйладыр ки, аек чагында кыйнасаң да, аларны эшләмәс иде. Вә дәхи исерек кеше үзенең эшен онытадыр, күзе җүнләп күрмәс була, колаклары шаулый. Үзенә үзе хилаф[4] сөйли, вә хәтта үзенең зарарына сөйли, кемне күрсә, үбәргә тотына, үзен гакыллыга хисаблай, халыкны ахмакка хисаблай. Исерек кеше һәркайчан әүвәл башта йокыда төш күргән шикелле була. Аек вакытта кешегә изһар кыйлмай[5] торган хәлләрен изһар кыйладыр. Күз күрүләр вә колак ишетүләре зәгыйфьләнгән өчен кеше күрмәгән нәрсәләрне күрәдер вә кеше ишетмәгән нәрсәләрне ул ишетәдер. Кисәктән бер тавыш ишетсә, йөрәге сикереп китә, куллары, әгъзалары калтырый, җенле кеше шикелле саташа, урынында утырып тора алмай, тешләрен шыкырдата, өстендәге киемнәрен ерта, тырнаклары белән аны тырный, моны тырный. Әмма мондаен вакыйга табибларның дәваи[6] дигән әрем аракысын эчеп мәсмүм булган кешедән күбрәк садир буладыр[7]. Дәхи бу хәлләрдән соң ул исерек кеше котын җуя, йөзенең нуры китә. Хәвасе хәмсәсе зәгыйфьләнә, гакыл вә фәһеме җуела, тәне суына, йокысы оча, аннан соң гүяки җәмадат[8] җөмләсеннән булып каладыр.

Әмма бәгъзе вакытта эчемлек эчеп мәсмүм булган кешегә бер фәлуҗият халәте вакыйг буладыр, ягъни фалиҗ сугадыр. Бу бигрәк тә яман халәттер. Кешегә билә исереклек вакыйг булганда адәмнең әгъзасында хис бетәдер, үзен-үзе белмәйдер, тәне салкынлана, гырылдап тәнәффес кыйла, күзләре тона вә күзләре утыра, нәбыз бәтаәт үзә хәрәкәт итә[9], ягъни нәбыз та-

---

[1] Гайре мөтәгариф — билгесез.
[2] Рабытсыз — бәйләнешсез.
[3] Хәя — тыйнаклык.
[4] Хилаф — каршы.
[5] Изһар кыйлмай — ачылмый.
[6] Дәваи — шифалы.
[7] Садир буладыр — барлыкка киләдер.
[8] Җәмадат — җансызлар.
[9] Нәбыз бәтаәт үзә хәрәкәт итә — пульс тибүе акрыная.

мыры бик сирәк тибәдер, бәдәнендә хис вә хәрәкәт бетә, миенә кан коела вә миендә бер илтиһаб пәйда була. Моның гакыйбәте[1] үлемдер. Эчеп мәсмүл булып үлгән кешенең үлеменнән яман үлем юктыр. Авызыннан кан катыш күбекләр килә, йөрәк тибүе туктай, нәбызы хәрәкәттән кала, исерекнең бу халәте әҗәленең галәмәтедер. Әмма исереккә айныгач та төрле вакыйгалар буладыр, һушы китеп егыладыр, сулуы тараядыр, йөрәгенең хәрәкәте туктыйдыр вә бу вакыйгалар адәмне кабергә сөйри торган вакыйгалардыр. Әмма гомергә мәсмүм булу эчкән кешенең үзенә генә түгел, бәлки бөтен җәмәгатенә вә нәселенә дәхи зәхмәте тиядер. Аның галәмәте шулдыр ки, йокысызлык вә мөттасил хафа булучылык, вә аяк вә кул бармакларын көзән җыеру, вә бәдәненнән хис җуелу, кул вә аяк калтырау кебек нәрсәләр бары да эчемлек белән мәсмүм булган галәмәтедер. Вә моның зәхмәте торган саен артадыр, вә башка авырулар, вә тамыр авырулары кушыладыр. Йокыдан торганда башы әйләнүчән була, күзләре күрмәс була, вә ул адәм сабырсызлана, вә тынычсызлана, вә хафалана, вә һаман йокысызлыгы куәтләнә. Йокласа да, тыныч йокламай, төрле кабахәт төшләр күрә, гакылы саташа вә фикере яңлышадыр. Мине үтерәләр, дип батыйль фикергә китә башлый, ялгыз бер караңгы өйдә торырга курка вә гакылы көннән-көн зәгыйфьләнәдер. Ахырыннан кулындагы вә аягындагы көзән зәхмәте бөтен тәненә җәелеп, фалиҗга әйләнәдер.

Ниндәен эчемлек булса да, мөттасил туктаусыз эчүнең ахыры үлемдер. Вә эчкән кешенең мигъдәләре вә эчәгеләре авыру буладыр, шуның өчен ашны сеңдерә алмайдыр. Иштиһасы җуяладыр. Укшып бертөрле кабахәт лайла нәрсә косадыр. Аннан соң бер каты ютәл пәйда буладыр, азрак ашаган булса да, кан зәгыйфьлек сәбәпле, тәнен тәрбия кыйла алмайдыр. Йөрәк тибүләре билкөллиһи үзгәрәдер. Ул вакытта кан бөтенләй үпкәгә коеладыр, сулыш юлында һәмишә[2] илтиһаб пәйда буладыр. Аннан, чахоткага әйләнеп, ахыры үлемдер. Вә эчкән кеше күбрәк чахотка белән үләдер. Эчемлек белән мәсмүм булган кешене ниндәен дару белән дә иске хәленә кайтармак мөшкелдер, гакыйбәте әҗәлдер. Эчә торган адәмнең җиңел генә авыруы да зурга китәдер. Хосусән, үпкәсендә җәрәхәт пәйда булган булса, бик хәтәрдер. Әмма ул эчкән кешенең зарары үзенең бәдәненә генә вә гомеренә генә түгел, бәлки исереклек сәбәпле вә эчемлек сәбәпле ниндәен олуг, баш китә торган эшләр зоһур итә-

---

[1] Гакыйбәте — нәтиҗәсе.
[2] Һәмишә — һаман.

дер[1]. Бу эчемлек дигән нәрсә адәмне шул дәрәҗәгә ирештерәдер ки, актыгыннан адәм үз җанына, үзе касд[2] кыйладыр.

Әмма эчкән кешене бик асат белергә мөмкин: кеше никадәр күп эчсә, шулкадәр кабахәт исе артадыр. Эчкән кеше каршы очрап ун колач җитмәс, авызыннан барда ашаган ат тизәге исе киләдер. Дәхи эчкән кеше үзе авызыннан исе килмәсен дип яшерергә тырышса да, һичбер гыйлаҗ тапмас. Эчкән кешенең борыны кызарадыр, ул кызыллыкны бетерә торган буяу дәхи юктыр. Куллары калтырый, әгъзасы калтырый, ул калтыравыкны бетерә торган дару дәхи юктыр. Эчкән кешеләр, халык сизмәсен дип, никадәр суган ашап карыйлар, лимон, канәфер, дарчин чәйнәп карыйлар вә төрле хуш исле майлар истигъмаль кыйлып карыйлар, һич беленмәенчә мөмкин түгел. Хосусән аракы йотмаган кешегә бик тиз сизеләдер. Мөмкин кадәр яшерергә тырышадыр, юк гыйлаҗ. Адәм үзенең җанына үзе касд кыйлса, аны дәфгы кыйла[3] торган гыйлаҗ юк. Моннан морад үзенә-үзе әҗәлне эстәп китерә димәктер.

Эчемлек эчә торган кеше һәрбер чарканы эчкән саен үзен генә үтермәйдер, бәлки бөтен нәселен үтерәдер, чөнки адәм бер чарка аракы эчсә, тәнендә һичбер тамчы кан калмас, һәммәсенә аракы сираять кыйлыр. Әлбәттә, солбендән киләсе нотфәдә дә җөзьән аракы бардыр[4]. Бәс, аннан туганнар аракы нотфәсеннән тугадыр вә аннан туган балалар яки тиз заман үләләр, яки газапланып берничә заман тереклек кыйлалар. Әлбәттә, исеректән исерек тугса кирәк. Моңар дәлил шул җитәр ки, елданел дөньяда исереклек артадыр. Исеректән туган балалар гәрчә үлмәсәләр дә, зәхмәтле вә кабилиятьсез[5] вә ахмак булып тугалар. Аракы катышкан нотфәдән вөҗүдкә килгән бер гакыллы вә зирәк баланы табып бирчегез. Исеректән туган балалар күбрәк зыяндаш зәхмәтле булалар. Шул кабахәтнең кәсафәтедер[6] ки, торган саен адәм череккә таба барадыр. Егермегә җитмәгән егетләрне күрерсең, бәгъзесе яңагын бәйләгән, бәгъзесе колагын бәйләгән, ничек тә булса бер зәхмәт белән мөбтәлядер[7]. Кайда китте элгәреге таза адәмнәр? Бер ахмак балага бер хәким карап торды да, әйтте: «Сине атаң исерек чагында тугдырган икән»,— диде...

---

[1] Зоһур итәдер — килеп чыгадыр.
[2] Касд — явызлык.
[3] Дәфгы кыйла — кире кайтара.
[4] Солбендән киләсе нотфәдә дә җөзьән аракы бардыр — женси бездән килә торган орлыкта өлешчә аракы бар.
[5] Кабилиятьсез — сәләтсез.
[6] Кәсафәте — зарары, тәэсире.
[7] Мөбтәлядер — дучардыр.

Вә бәгъзе халык арасында, вә түбәнрәк дәрәҗәдә сәүдәгәр халкы арасында, вә һәм кечкенә калаларда түбәнрәк дәрәҗәдәге хезмәт әһеле арасында кунакны эчемлек белән сыйламак гадәте ештыр. Берәү үзенең кунагын агу белән сыйламаса, килешмәгән эшкә саялыр. Кунак үзе дә дәхи берәүгә кунак булып, эчемлек белән сыйламаса, тәҗир кыйладыр[1], икенче мәртәбә ул кешегә кунак булырга күп ригаять[2] итмәйдер. Уйласаң, бик гаҗәп тоеладыр ки, өй иясе үзенең кунагын кыстап-кыстап эчертәдер ки, кунагына гайне зарар касд[3] кыйладыр, яки тизрәк үтерергә, яки бер-бер төрле авыруга мөбтәля булмакына сәбәп ачадыр. Аннан гаҗәбрәк берәүгә берәү чаркага салып аракы сонса, ул кеше аны алып, сезнең сәламәтлегегез өчен, дип эчеп җибәрәдер. Бу аракы вә эчемлек белән сыйлашулар эчемлекнең зарарын фәһем итмәенчә гайне бер ахмаклыктыр. Ул эчемлектән пәйда булган зарарны фәһем иткәннән соң кыстап эчермәк түгел, кунакның алдына китереп куймак ояттыр вә гаеп эштер. Белә торып кунакка зарар касд кыйлудыр.

Югарыда мәзкүр булган әхвәләттән мәгълүм булды, кайчан ки нәвахидә[4] эчемлекнең истигъмале азайса, гаепле вә низамга гөнаһлы кешеләр дә азаер иде. Хәреҗ вә хәраҗатны манигъ булгучы[5] фәкыйрьлек вә мохтаҗлык азаер иде, вә дәхи ул вакытта гыйлаҗханәләр вә диванаханәләрнең һәм хәраҗате азаер иде. Сихәтлек вә сәламәтлек, вә эшләүче куәтләр куәт табар иде, нәвахидә байлык артыр иде. Шуның өчен ки, адәмгә изгелек эстәгүче һәрбер ахадкә лазем вә ваҗибтер ки, мөмкин кадәр бар куәте белән үзенең якыннары арасында исереклекне вә эчемлек истигъмаль кыйлуны бетерергә иҗтиһад кыйлгай. Дөньяның бозыклыгы бары эчемлектәндер. Һәм эчемлек вә исереклек булмаса, нәвахидә рәхәт булачактыр вә исереклек күбәйсә, мәмләкәтнең варидате[6] азаядыр вә сарыфы күбәядер. Мәйханәләр вә кабаклар кимесә, үлем аз булыр иде вә авырусырхау аз булыр иде.

---

[1] Тәҗир кыйладыр — кәефе китә, үпкәлидер.
[2] Ригаять — игътибар.
[3] Гайне зарар касд — күрәләтә зарар.
[4] Нәвахидә — тирә-якта.
[5] Хәреҗ вә хәраҗатны манигъ булгучы — чыгымны тоткарлаучы.
[6] Варидат — керем.

# ХАТЛАР*

## КАЮМ НАСЫЙРИ ЯЗГАН ХАТЛАР

Әти-әнисенә:

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Гыйззәтлү әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга күп-күп ихласлы дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт вә сәламәтләрмез. Ләкин Гани** авырып торадыр, ягъни ятып авырыйдыр дүшәмбе көндән бирле. Үзеңез берлә алып китсәңез нә буладыр иде. Авыру да булуы, мәдрәсәдә булуы үзеңезгә мәгълүмдер. Иншалла үзеңез тиз килсәңез кирәк.

Вә гәнә[1] билитне йибәрдем, числасын язмаган, мөмкин булмасмы иркән апрель унбишендә әйтеп яздырырга? Янә бер айлык билит булыр иркән?

Вә канә кибетче Абдулла кайтмаган, биргәнемез юк һәм сездән записка юк, язып бирергә онытылган иркән.

Дагый вә мөстәдгый әл-фәкыйрь әл-хәкыйрь[2] мәгълүмеңез Габделкаюм.

*1847 сәнә, апрель, 15 ендә*

*819 т., I кисәк, № 1*

---

[1] Гәнә — йәнә.

[2] Дагый вә ...— дога кылучы һәм дога үтенүче, түбәнчелек белән баш июче.

* Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Шәрык бүлекчәсендә К.Насыйриның шәхси архивы саклана. Ул материаллар арасында К.Насыйриның әти-әнисе, туганнары һ.б. кешеләр белән үзара язышкан байтак кына хатлар да бар. Әле моңарчы ул хатлар матбугатта тулысы белән басылып чыкканнары юк. Бары тик М.Галинең «К.Насыйриның кулъязма мирасы» дигән мәкаләсендә һәм М.Ногманның «К.Насыйриның кулъязмалары тасвирламасы»нда хатлардан аерым кыска-кыска өзекләр бирелгән иде.

Бу томга кергән хатларны шушы китапханә хезмәткәре Диләрә Абдуллина гарәп графикасыннан гамәлдәге алфавитка күчереп язды, сүзлек һәм искәрмәләр әзерләде.

Күчереп язылмаган хатлар әле шактый күп калды.

**Хатларда очраган исемнәргә ачыклык кертү өчен, Д.Абдуллина М.Ногман «Тасвирлама»сыннан алынган мондый мәгълүматлар китерә:

Газиз-әл-кадир әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга күп ихласлы дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сәламәтләрмез. Вә канә мәгълүм улынадыр: «Шәрхы Габдулла» китабы* бик зарур буладыр вә һәм «Фөзули»** китабыңызны йибәрәсез, бәгъзе вакытта укыштырырга зарур буладыр. Әхмәтҗан кайтканы юк. Хода теләсә, бу җомга үткәч, Кышкарга барып килергә торамыз. Кавины китерсәңез, мин кайткач китерерсез, ахры, берәр җомгасыз кайтмастыр.

Дагый вәләде фәкыйреңез.

*1852 ел, гыйнвар 1 ендә*

Бал йибәрмәкче идеңез, гаҗәп, килмәйдер.

*Хат кәгазенең икенче ягындагы язу:* Виреләдер Шырданда әткәмез мулла Габденнасыйр мулла Хөсәен әл-мәрхүм углына Казаннан.

*819 т., I кисәк, № 2*

Гыйззәтле әткәмезгә вә әнкәмезгә күп сәламнәремез бәгъдендә абзыйдан бу көннәрдә хат юк. Үзем һәм язмай торамын. Әхмәтҗан кода һәм нәрсәләрен йибәрмәгән икән. Инде йибәрсәк йитешер, йә юк. Пушты берлән йибәрер идек, кем белә, әллә кайтып чыгарлар.

Вәләдеңез Габделкаюм

*1860 ел, март 9 нда*

---

Габделхәй Казанский — К.Насыйриның бертуган абыйсы. Зур сәүдәгәр, Мәскәүдә шәм һәм сабын кайната торган завод тоткан. Россиянең төрле шәһәрләренә, ярминкәләргә барып сату иткән. Үзенә Казанский фамилиясен алган.

Габделмән Казанский — К.Насыйриның абыйсы Габделхәй улы. Соңыннан атасының дәүләте аның кулына күчә. Казанда сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Китап җыю белән дә кызыксынган. 1909 елда үлгән.

Габделгани — К.Насыйриның энесе. Екатеринбург якларында сату-алу эшләре белән шөгыльләнгән. Соңыннан Себергә барып, алтын приискаларында һәм башка төрле җирләрдә эшләгән.

Габделвәли — К.Насыйриның уртанчы энесе. Мәскәүдә яшәгән. Агасы Габделхәйнең сату-алу эшләренә катнашкан, аның белән төрле ярминкәләргә йөргән.

Габделкави — К.Насыйриның кече энесе. Шырданда мулла булып торган.

Биби — К.Насыйриның кыз туганы.

Галим — К.Насыйриның әтисе белән бертуган абыйсы. Печән базарында Акмәчеттә мөәззин булып торган.

Бәдигъ мөәззин — К.Насыйрига кардәш тиешле кеше. К.Насыйри аның йортында квартирда торган.

* Габдулла ибн Акмөхәммәт шәрехләгән гарәп теле грамматикасы.

** Фөзули (1504—1567) — төрки халыклар арасында исеме киң таралган мәшһүр шагыйрь.

Рамазаннан соң [...]* баручылар бар икән. Муса артыннан әманәтеңезне алдым. Мөхәммәтша көткән, һәнүз көтә бугай, үзен күреп булмады. Галим абзый баласы үлгәне юк.

Рамазан башы, ай күренсә, шимбә дип торалар.

*819 т., I кисәк, № 3*

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Газиз әл-кадир әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга шомулән[1] күп-күп ихласлы дога вә сәламнәремез бәгъдендә үзләремез лилләһи-л-хәмди вә-л-миннәт сыйххәт вә сәламәтләрмез. Вә канә кардәш вә белеш-таныш сыйххәт сәламәтләр. Ләкин Шәмси абзый вафат булды. Июль 23ндә дәфен улынды, Алла рәхмәт итсен. Бәлки, ахунд Хөсәенләре кергәннәрдер, анлардан ишеткәнсез, кермәкчеләр иде. Макарьягә баргач, абзыйлар анда килмәгәннәр булса, безгә бер хат язарсыз һәм үзеңездән тиз-тиз хат язарсыз. Хәвефле еллар, бер көн эчендә әллә ни эшләр хадис булып китәдер, һәрничек бер хәбәр бирерсез.

Вәссәлам.

Дагый вә мөстәдгый мәгълүмеңез әл-фәкыйрь Габделкаюм ибн мулла Габденнасыйр.

Вә һәм карт Абдулла мулла вафат булды, Алла рәхмәт итсен, июль 26нда дәфен улынды.

Канә абзыйлардан хәбәр булмаганга бик кайгырырга кирәк түгел, сабыр кирәк. Ләкин әхәд-эт-тарафәйн[2] мәгълүм булмас борын хәлүфе рижада[3]. Ләкин Алла алар берлән аерылырга язмаса иде. Амин.

Ләкин Габдетдиндән чәй мөяссәр булмады[4]. Шәр икәнләрен[5] Галим абзыйлардан ишетеп, берәр көн кичегеп барган идем, бетердек, диделәр. Әллә бирмәүләренә галә булды сүзләре.

*819 т., I кисәк, № 7*

Гыйззәтлү әткәмезгә вә әнкәмезгә вә Кавига күп ихласлы дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт-сәламәтләрмез. Йибәргән әманәт митеркәләреңез йитде.

---

* Бер сүз танылмады.
[1] Шомулән — тулысынча.
[2] Әхәд-эт-тарафәйн — ике якның берсе.
[3] Хәүфе рижада — курку белән өмет арасында.
[4] Мөяссәр булмады — җиңел үтәлмәде.
[5] Шәр икәнләрен — начарлыкларын.

Хатыңыз берлән зиядә мәсрүр булдым. Үзеңезне көтәдер идем, килмәдеңез. Бу дәфга тынычлабрак торасыз икән, Аллаһ хәерле. Иншалла, Ходай үзе хифзы химаятендә[1] кыйлса иде. Амин. Гаибә боерылмая. Вакыт тәгъҗил[2] булды, сүз күп, шул йитәр. Әл-бакый гыйнд-эт-тәлякый[3].

Әтдагый вә-л-мөстәдгый вәләдеңез Габделкаюм.

*819 т., I кисәк, № 8*

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Гыйззәтлү эткәмезгә вә әнкәмезгә күп сәламләрем бәгъдендә йибәрдем сезгә абзый хатындан копияләр. Дәхи абзый язган сезгә Япиевтән кырык тәңкә акча алып йибәрергә. Ләкин Япиев өйдә юк, авылга киткән. Зөягә эткәйгә хат яздым дигән, бәлки, алгансыз. Әмма Япиев, мондан ары мин акча бирмәмен, дигән иде. Әгәр ул бирмәсә, абзыйга язармыз, бирмәй, дип. Вә иллә[4] ашыгып килүеңез бушка китмәсен. Япиев авылдан кайткач сорармын, бирсә, хәбәр йибәрермен. Ике-өч көндән кайтыр, диләр.

Вәссәлам. Әл-мөстәдгый вәләдеңез[5] Габделкаюм.

*Март 6 нда*

*819 т., I кисәк, № 9*

Йа һүә.

Гыйззәтлү эткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга күп догалар күндерелде. Канә мулла Вәли җизнигә вә һәм абыстайга күп ихласлы догаларымыздыр. Үземез әлхәмделилла сыйххәтсәламәтләрмез, сезләрнең догаларыңызда. Канә моннан элек мондагы әхвәлдән хат язган идем, Галим абзыйлар хосусында. Җавап булмады. Үзеңез тиз килмәкче идеңез, килә алмадыңыз.

Гайре нә язаем, хатны озын яза белмәймен, язасы сүзләр күп.

Вәссәлам.

*Июль 14 ндә*

*819 т., I кисәк, № 13*

---

[1] Хифзы химаятендә — саклавында.
[2] Тәгъҗил — ашыгыч.
[3] Әл-бакый гыйнд-эт-тәлякый — калганы күрешкәндә.
[4] Вә иллә — ничек булса да.
[5] Вәләдеңез — улыгыз.

Газиз әл-кадир әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаларыңызга күп дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сәламәтләрмез. Канә абзыйдан хат бар ирде ... бирелмичә монда килгән. Кармыш авылының Абдул писергә йибәргән идем, иншалла биргәндер.

Гайре нә язаем.

Дагый вә мөстәдгый Габделкаюм вәләдеңез.

*Август 23 ндә*

*819 т., I кисәк, № 11*

Виреләдер Югары Шырданда әткәмез мелла Габденнасыйр мелла Хөсәен әл-мәрхүм углына.

Гыйззәтлү әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга күп ихласлы дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт-сәламәтләрмез, хәер догаларыңызда. Вә канә бу хатны Кармыш авылына йибәрсезләр. Йомышлары булмады, пешереп йибәрмәгәннәр һәм үзләренең хатын йибәрдем, сез ни фәһемләрсез. Ул хат бинаән[1] һичбер эш кыйлып буласы түгел. Вә һәм Гани бер күлмәклек бирмәкче иде, бирмәдеме икән, бик яхшы булыр ирде дәю яздым.

Вәләдеңез Габделкаюм дәю беләсез.

*Сентябрь 28ндә*

*819 т., I кисәк, № 14*

Йа һуә.

Сез ки гыйззәтлү әнкәмезгә вә барча һәмширәләремезгә[2] шомулән күп-күп ихласлы догаларымыз бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт вә сәламәтләрмез, изге догаңызда. Вә канә мәгълүм улынадыр: әткәй сишәмбе көн кайтты. Өйгә кайчан кайтасын белмәймез. Гайре язасыларым сүз тапмадым.

Вәссәлам.

Дагый вә мөстәдгый вәләде фәкыйреңез Габденнасыйри.

*819 т., I кисәк, № 12*

Гыйззәтлү әткәмезгә вә әнкәмезгә вә барчаңызга күп дога вә сәламнәремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт-сәламәтләрмез. Канә хатыңызны карига укыдым, рәнҗемәкче бу-

---

[1] Б и н а ә н — нигезләп, таянып.
[2] Һ ә м ш и р ә л ә р е м е з г ә — кыз туганнарыбызга.

ладыр. Ганидан хат юк, вә һәм абзыйны Мәскәүдә күреп кайткан кеше бар. Гайре ни язаем, хәлем сезгә мәгълүмдер.

Китапларыңны тышлап куйган идем, үзеңез килгәнчә торадыр, йибәрмәдем. Йибәрдем: капчык, кулек.

*Хатның тышында язу:* Виреләдер Шырданда эткәмезгә.

*819 т., IV кисәк, № 7*

Абыйсы Габделхәйгә:

Әс-сәламу галәйкум вә рахматуллаһи вә бәрәкәтүһү илә җәнабикум-ул-галия. «Вөсуле сәнәтин синәтүн вә һөҗүрү синәтин сәнәтүн»[1] фәхвасенчә, кичәге кич күңелле иде, бүген син һая да мин һая[2]. Алла безгә язмаган икән агай-эне бергә чукырдашып, бәгъзе вакытта тукырдашып торырга. Кайтасыз да китәсез, күңелгә ямансу итәсез. Үткән кич ярыйсы иде, бүгенге кич ямансу. Эткәй һәм син киткән көн китте, янә ялгыз калдым. Биби бик авыру, эткәй кайтып йиткәнче, җан тәслим кыйлмаса ярар иде. Шул чамага йиткән икән, Алла сакласын. Әмма ялгызлыктан башка читен эш бар микән? Әмма мин ялгызлыкның зәхмәтен чиктем. Унбиш елга якын мәдрәсәдә яттым, миңа һич тиң чыкмады, ялгыз булдым. Семинариядә ике ел торамын, анда һәм ялгыз. Ни итмәк кирәк. Әмма сез ничек чыдыйсыз? Хәер, сезнең шөгылеңез күп, тоелмай торгандыр. Белмим, миңа, кая барсам да, дөнья тар, эчем вәсвәсә берлән тулган, һәммәсе хыяле батыйль[3]. Ник вәсвәсә булмасын, һәр җанибтән җәмигъ ноксанат[4] миндә җыелган.

Әле шул фатирда торып торамын. Утенәмен ки, барып йиткәч бер хат языңызла. Вәлигә сәлам әйт. Миңлебай абзыйга сәлам әйт. Синең арттан хат язмакчы идем, онытылган. Сезләр кайтып, янә агай-эне бер җиргә җыелсак икән.

Хатны язсаңыз, үз исемемә язсаңыз да булыр. Бу рәвешчә язсаңыз, иншалла, миңа тапшырылыр:

В Казанской Духовной семинарии лектору татарского языка Каюму Насырову в Казани.

Әд-дагый вә-л-мөстәдгый энегез Габделкаюм ибне мелла Габденнасыйр.

*1858 дә 23 апрельдә*

---

[1] «Кавышуларның елы төш кебек, аерылышу төше ел кебек» мәгънәсендә.
[2] Син һая да мин һая — син кая да мин кая.
[3] Хыяле батыйль — буш хыял.
[4] Ягъни: һәр яктан бөтен кимчелек.

* * *

Ай хәбәре: ахыр чәршәмбе көн рамазан башы булуы мөсбәт[1] булыр шикелле, алай булганда гаед җомга көн булса кирәк.

Әгәр Истанбулдан «Океанус»[2] алдырсаңыз, минем өчен һәм берне алдырсаңызла. Акчасы, иншалла, сезгә миннән йитешер. Аның өчен, миңа һәм бик зарурдыр. Ләкин хәзинәлектән басылганны алырга кирәк, арзанрак булыр.

*819 т., IV кисәк, № 3*

Акча күп булгач, Алланы онытырга кирәкмәс, фәкыйрь кешеләр дә «йа Алла» ди.

Аллага шөкер, мин сәламәт кайтып йитеп, өйдә бер кич кунып килдем. Хезмәткә шөругъ кыйлдым[3]. Мин сорамадым — бишмәт кыска җиңле булсынмы яки озын җиңле? Чөнки бервакытта ишеткән идем бугай, кыска җиңле бишмәт кирәк, дип. Әдрәс бишмәт Әчтерхан манеры берлә сыргач килешмәй бугай, буй-буй булса ярар иде, әмма ничек сырдырырга кирәк, тиз бер хат язарга тиешле булыр. Гыйззәткә һәм Фазлыйга әрҗә ясарга әйттем, аларга акча кирәк булыр, ахры. Әхмәтҗан кода Бөгелмәгә киткән. Чалма бүрке эчле булсынмы, ничек кирәк? Тиз хат язарлар. Мин үлчәү һәм алып кайтмадым, үлчәүсез ничек тектерермен, үзләре һәм белмәделәр.

Мәскәүгә бардым, кайттым, анда вакыт юк икән. Аллага шөкер, ач булмадым. Мәскәүдә кыйбатчылык, диләр. Бер төлке үгез артыннан өч ел йөргән, имеш. Үктәбер башларында мөфти Мәскәүгә бара бугай. Тун, камзул өлгерсә, аның артыннан барыр. Әмма бишмәт ничек кирәк, анда тәвәкъкыф[4] бар, һәм чалма бүрке?

Укыган кеше хатны фәһемләп укый. Мәскәү бик зур икән. Мәскәүчеләр хосусында Галим абзый күп сүзләр әйтте, һичнәрсә димәдем. Язсам, кәгазь күп кирәк. Күбесе онытылды, калганы да биш-алты ушат булырмы. Гаҗәп, бәгъзе кешенең картайган саен тәртәсе кыскара икән, әллә яшь чагында ук чыршы яки җирек[5] тәртә җигә кем белсен.

---

[1] Мөсбәт — исбат ителгән.
[2] «Океанус» — төрекчә сүзлек.
[3] Шөругъ кыйлдым — керештем.
[4] Тәвәккъкыф — тоткарлык.
[5] Җирек — зирек.

Әхмәтҗан абзый сәламәт. Галим абзый яңа өйгә кергән. Әткәйләр сәламәт. Башка ят хәбәр юк. Вакыт килсә янә бер хат язылыр, иншалла, тиз килсә кирәк. Бу көннәрдә көтеп торалар.

Каюм.

*Сентябрь 21, 1859 да*

Әмма тәфсыйлән[1] бер хат язарга тиеш булыр, хосусән бишмәт берлә чалма бүрке хосусында. Бәгъзесе мөфти артындан йибәрелер, бәгъзесе — Әхмәтҗан абзый берлән. Нижнайда Әхмәтҗан абзыйга өлгермәдем, миңа чаклы кайтып киткән икән. Бу сәлам хат Гомәр абзыйгадыр һәм Миңлебай абзыйга.

Гыйззәтлү Гомәр абзыйга күп дога вә сәлам, үзенә бер хат язармын. Миңлебай абзыйга дога вә сәлам, үзенә һәм бер хат язылыр бервакыт. Хәзердә Казанда һич вакыт юк. Бик былчырак.

Адрес: В Москву, Казанскому мыльному мастеру татарину Абдулхаю Насырову, близ Данилова монастыря в собстенном доме.

*819 т., III кисәк, № 5*

Сентябрь 24ндә бер хат язган идем. Сентябрь 19нда язган хатыңны сентябрь 25ндә алдым. Гыйззәткә һәм Фазлыйга әрҗә ясарга бирдем. Язасың: ун мең әрҗә алып йибәр, дип. Бөтен Казаннан эзләсәң, ун мең әрҗә вакны таба алмассың. Монда вак әрҗәле сабын аз китәдер икән, табылса да, акчасыз ничек алмак кирәк. Дөрес, язасың: минем исемемә берәүдән-берәүдән акча ал, дип. Мин синең прикащигең түгел, миңа доверенность биргәнең юк. Минем сүзем берлә генә миңа бирмәсләр.

Үзеңдә булмаса, дисең. Дәхи дә синең бәгъзе суманң миндә йөрми, мин кайдан алып бирим? Дүрт елдан бирле җыелган утыз тәңкә, бәлки, утыз биш акчаны сарыф кыйлып, Мәскәү барып кайттым. Дәхи дә соңга калганым өчен ярты айга жалуния бирмәскә әйтәләр. Мәскәү кыйбат төште, акча күплектән бармадым, алай да күңелем булмады, өч атнага якын тордым, скушно тордым, үзең һәм замечайть иткәнсең.

Эшләгән саен Гыйззәтләргә акча бирергә кирәк булыр. Йибәрерсеңме яки Әхмәтҗан кодага язарсыңмы? Әмма бу хатны алгач, бер хат язарга тиеш булыр.

Дәхи дә вә ма галә-р-рәсули иллә-л-билах. Мәгәр, ясарга гына куштым, бәясен сөйләшмәдем, син кушмаган эшне мин кыймадым. Әмма мин гөман кыйламын: бәясен сөйләшергә ки-

---

[4] Тәфсыйлән — җентекләп.

рәк. Гыйззәт әйтә, мин Габделхәй берлә сөйләштем. Габделхәй монда кайткан вакытта өч тәңкәгә эшлидер идек. Мин аңар әйттем, хәзер өч тәңкәгә эшлимез, көз көне, кышка таба тугыз сум илле тиенгә эшләргә мөмкин булыр, дидем. Әмма инде аннан соң пожар булды, кабык кыйбат булып китте, өч тәңкәдән ким эшләргә мөмкин түгел, диядер. Ягъни бер кадаклы әрҗәне өч тәңкәгә, ярты кадаклысы ярты бәя булыр, диядер. Син ни әйтерсең? Шуның өчен әйтәмен, бер хат язарга тиешсең. Ничә төрле эш куштың, барчасы мөбһәм ула. Бишмәт кыска җиңлеме яки озын, һәм арасына чүпрәк салмаенча килешмәс. Әчтерхан манеры берлә тегәргә белмәйләр вә һәм ул буйбуй яки бер генә төсле булса килешер иде. Саниян[1], үлчәү бирмәдең, әллә киң, әллә тар кирәк. Салисән[2], чалма бүрке эчлеме, эчсезме. Рабигән[3], каракүл бүрекнең эче аяк булмасын, бәрән булмасын, дисең, хәер, анда бер нәрсә тәгаен бар. Хамисән[4], әрҗәнең бәясен әйтмәдең, имде баягы сүзгә килдек. Кулдан килгән хезмәткә баш өсте, бер кашык каным калганчы йөгерермен, әмма акчага терәлгән эшне, Алла разый булсын, зинһар, боермасана. Әмма Гыйззәтләр эшләгән берсенә акча ала торырлар, бирә торырга минем кулымда акча булса иде. Кулымда акчаң торса да, бер тиенгә хыянәт булмас, хатир җәмгъ бул[5]. Гыйззәтләр өлгертмәсәләр дә тапсам, ун мең ярты кадаклы йибәрермен. Аны да әйтмәк кирәк: ул әрҗәләрне бер әрҗәгә салыпмы яки чыптага төрепме йибәрергә тиеш булыр? Чыптадыр, баудыр сатып алмак тиеш булыр. Миңа боерылган нәрсәләрне, ягъни бишмәт, камзул, бүрек, тун, итек әрҗәләр берлә бергә йибәрелерме яки, Әхмәтҗан абзый барса, аның артынданмы йибәрелер? Әхмәтҗан абзый әйтәдер, камзул әйләнәлектән бүреклек калмас, диядер. Яки миңа боерылган вә һәм Әхмәтҗан абзыйга боерылган, вә һәм Әхмәтҗан кодага боерылган нәрсәләрне декабрь башына табарак әрҗәләр берлә бергә йибәрелер. Мәҗмугсын бер әрҗәгә салып, әрҗәләр берлән бергә йибәрсәк, шаять, хәвеф-хәтәр булмаса кирәк. Аның өчен, хәзер мөфти бара бугай, аңа өлгермәс. Әхмәтҗан абзый бара йә юк. Кәма һүә бәян кыйлып, бер хат язарга тиеш булса кирәк. Эшне пешереп эшләгән яхшы, соңыннан татлырак булыр. Үзеңнән хат алсам, янә бер хат язармын.

Вәссәлам, әд-дагый[6] энем дигәнегез Габделкаюм.

*Сентябрь, 26, 1859 да*

---

[1] Саниян — икенчедән.
[2] Салисән — өченчедән.
[3] Рабигән — дуртенчедән.
[4] Хамисән — бишенчедән.
[5] Хатир җәмгъ бул — исеңдә тот, тыныч бул.
[6] Әд-дагый — догада булучы.

Миңа тиешле икән Мәскәүдән фирүзә вә һәм разный ташлар, кашлар алып кайтырга, яхшы табыш итеп булыр иде. Мәскәүдән кайтканымны ишеткәч, алтынчылар сораштылар. Ничек булыр икән ун мең фирүзә алып йибәрсәң? Сатып йибәрер идем. Ул өч сорт булыр һәр төрлесеннән вә һәм ташлар, кашлар.

Синең үзең вә һәр фигылең кешегә хилаф. Кеше хатның башыннан укый, син ахырыннан укырсың, сиңа бары да бер. Шуның өчен башсыз хат яздым. Һәр эшнең әүвәлендән ахыры могтәбәр. Дөрес әйтәләр: арбаның алды кайдан тәгәрәсә, арты шундан тәгәри, дип. Әмма бу раст түгел икән: мин Мәскәүгә барганда, арбаның арты алды тәгәрәгән җирдән тәгәрәгән иде, кайтканда икенче җирдән тәгәрәде. Менә кая китте эш.

Вот замечание: С начала 7я строка!

*819 т., III кисәк, № 4*

*Хатта бу юл* «Синең үзең вә һәр фигылең...» *дип башлана.*

*К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган җыентыкта (1948) бу хаттан өзекләр китерелгән.*

Йа һүә.

Гыйззәтлү абзыйга бик күп ихласлы дога вә сәламнәрем бәгъдендә үзем әлхәмделилла. 13 майда язган хатыңны алган идем, имде Мәскәүгә өлгермәс дип, хат язуны кичектем. Майның 16 нда пашпорт берлән бер хат язган идем, алгансың.

Канә Баришовлардагы Хәмидулла малае хосусында. Ул малай хәзердә Баришовлардан чыккан һәм өйләнгән. Ахры, Баришовлар үзләре өйләндереп чыгарган бугай. Үзләрендә асраулыкта торган кызны биргәннәр. Әмма болай бик ризалашып чыккан. Баришовлар ул малайдан даволен кебек күренә, чибәр малай. Сиңа кирәк булачак булса, мин аның берлә сөйләшеп карармын, хат язарсың.

Агай-эне барчасы сәламәт. Ят хәбәр юк.

Догалар өмид итеп вә һәм дога кыйлып язгучы энегез Габделкаюм.

Кореннойдан* берәр хат язарсың хәл-әхвәлдән.

*30 май, 1860 да*

*819 т., III кисәк, № 6*

Адрес: В Коренную ярмарку Курской губернии, в мыльной лавке, Казанскому мыльному мастеру Абдулхаю Насырову.

---

* Курск шәһәрендә җәй көне була торган ярминкә «Коренная ярмарка» дип аталган.

*Шушы ук биттә* «Бу хатны күчереп йибәрдем июнь 5 ндә» *дип язылган сүзләр бар.*

Илле тугызынчы елдан бирле язган хатларыңны бер кич, бер төн актардым. Алтмыш беренче ел 29 май язган хатың да дәхи чыкмады. Дәхи дә чыкмады шул ел сентябрьдә язган хатың.

Ул записка буенча һичкемгә акча бирелгәне юк булса — инде булса ни, булмаса ни. Мин йибәргән бер язусыз, дәхи бер язулы записканы алдым дип — күренмәй. Табылганын йибәргән идем.

Мин дә бу чагында тәкә ите сайлап алам, югыйсә ашап булмай, харап тешем сызлый.

Ул запискалар буенча акча бирелмәгәнен әле белдеңмени, нигә моңарчы язмадың?

Хәзер көн саен имтихан. Никадәр тырышам, алай булса да 17 нче числосыз булмас чыгарга. 19 нда–20 ндә мине көтегез, вә иллә ла. Сәбәбен дәхи язармын.

Аслан рабитасыз[1] язган дип гаеп итмә, искә төшкән берсен яздым. Бу шулай торып торсын, бәнагяһ[2] мин барсам да, бу хосуста гәп булмасын.

Сарык исән, бүре тук, хат башында сәлам юк, дип гаеп итмә, сәламемне үзем алып барырмын. Син дәхи гаеп итмә, кылтырпылтыр дурачески сүзләр яза, дип. Бәгъзе хатларыңда күренә: «Синең эшләреңдән, синең кыйланмышларыңдан мин риза»,— дип. Шуңар ссылаться итеп батырчылык кыйлам. Разный история, чөнки сөйләшергә кеше юк — югыйсә хат, хат, хат. Дәхи бер хатыңда: «Һәрни язасың — тәмле». Икенче бер дәхи хатыңда чыкты: «Синең хатларың, синең кыйланышларың миңа мәгъкуль». Алай дигән белән дә мин аңар мәгърур булмыйм. Каким-то манером син мине ловить итәргә можешь. Көчле берлән көрәшмә, дигән. Не дай бог, чтобы ты меня ловил.

Хәзердә яңгыр ява, утырырга урын юк, аягүрә язам. Чарлакка ягъмур үтә, казенный заведение бик таза була икән.

Мин сиңа әйткән идем, иртәрәк килергә мөмкин, дип. Мин аны исәпләп карадым, хлопоты бик күп икән, вакытын көтмәк лазем булды. Һәрбер башыма килгән сүзне язамын, ләкин серьезный сүзләр түгел, так — фантазия. Барысы да һәзел тарикынча[3]. Синең берлән лично мосахәбәт кыйлырга вакыт аз.

---

[1] Аслан рабитасыз — һич бәйләнешсез.
[2] Бәнагяһ — көтмәгәндә.
[3] Һәзел тарикынча — шаяру рәвешендә.

Покрайний меру син сүзнең мәгънәсен беләсең, монда бер хикмәт бар. Гәрчә әйткән булсалар да ки, һәзел сүз булса да мәгънә кирәк, аны белергә дана кирәк, җигәргә чана кирәк, саварга тана кирәк. Сөйләргә сүз булсын, җерләргә сүс булсын, кыйферләргә кыз хаҗәт, яки кыска аяк, бар утынны пичкә як, аш пешсен, самавыр кайнасын, чынаякка чәй сал, стаканга мәй сал. Курыкканны постыр, сүз арасына келәй кыстыр. Тәме юк чәйнең, кичә эчкән мәйнең чыкмай баштан бохары[1], бетми бүген комары[2]. Баштан үткән фәзыйхәт[3], бирмиләр миңа нәсыйхәт. Әйтсәләр ни була миңа: инде ни кирәк сиңа, кечкенә генә башың, фикер-сагыш ашың, кара-каләм эшең. Яңгыр үтсә ни эшләрсең, бер почмакка сыярсың. Малаем юк, дип үкенмә, үзең кеше малае түгелсең. Акчаң булмаса, кесә ертыклыгында ни гамең бар. Бүген ашамай калдым, дип кайгырма, эч авыруың юклыгына шөкер кыл. Су меңгерүче булмаса, Ходай үзе түбәдән агызып төшерә. Ашарга итең булмаса, тешең авыртканнан ни зарар. Аш пешерүчең булмаса, расходың ким, дисәләр, бу — ялган. Бәлки, аш булмаса, ике мәртәбә, өч мәртәбә зиядә расход.

Вәссәлам дип тәмам кыйлганчы берничә һәзел сүз сөйләдем, агач берлән тимер чөйләдем, үзем кебек тынычсыз күңелләрне көйләдем. Кояш баеды, ай беткән, йолдыз калыкмаган. Яңгыр ява, су күренмәй. Сүз берлән күңелем тук, инде әйтер сүзем юк, алпараский бадьян чук. Авыл башында капка, анда бар биш такта, пожалуй, кеше яратмасын, ичмаса, син макта. Гәзиттә язалар: быел һәркайда начар иген, моны язган Каюм диген. Июльнең унөче бик караңгы булды киче. Алтмыш дүртенче ел, бик скушно быел. Әнә мең дә сигезе, юк дөньяда тигезе. Менә сиңа тарих, Мәскәүгә барих, күңел ачылсын, гамьнәр сачылсын. Мин анда калыйм, бал тисә, бармак җалыйм. Сез монда кайтыңыз, мөстәҗаб-әд-дәгъвәт[4] кемсәләрдән фатыйха алыңыз. Һәркем сездән риза булсын, Хода күптән риза. Син бу гыйбарәтне бак, риза-эл-халик, риза-эл хак. Һичкем әйтмәсен нәләт. Дога-әл-вәлидәйн лилвәләд[5], әйтә торган иде әби, кә дога-ән-нәби[6].

Адрес: В Москву, против Данилова монастыря в собственном доме, купцу Абдулхаю Казанскому.

*13 июль, 1864*

*819 т., III кисәк, № 7*

---

[1] Бохары — пары.
[2] Комары — махмыры.
[3] Фәзыйхәт — хурлык.
[4] Мөстәҗаб-әд-дәгъвәт — догалары кабул була торган.
[5] Дога-әл-вәлидәйн лилвәләд — ата-ананың балага догасы.
[6] Кә дога-ән-нәби — пәйгамбәрләр догасы кебек.

* * *

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Гыйззәтлү абзыйга барча тәвабигъларың[1] илән күп дога вә сәлам. Үзем әлхәмделилла сәламәт. Мамашев артындан 25 тәңкә акча берлән хатыңны алдым. Йөрүче тапсам, ул башмакларны җүнәтеп йибәрермен, булмаса, үзем алып барырмын. Ләкин Сәйфетдин агай ул башмакны Мәскәүдә биреп калдырган. Миңа илле тиен көмеш бирде, шулай дип мин кычкырышмадым. Ул илле тиенне алдым, үз араларында сүз булгандыр дип, һәм ул илле тиенне Әхмәтҗан абзыйга илтеп биргән идем. Башка ят хәбәр юк. Әхмәт хәзрәттән башкасы агай-эне сәламәт. Әхмәт хәзрәт вафат. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун[2]. Май 24 ндә дәфен кыйлынды.

Вәлигә сәлам. Иншалла Кореннойга бер хат язармын, Кореннойдан син һәм язарсың.

Хәерле гомерләреңезне теләп, яздым Габделкаюм Габденнасыйр углы.

*Май 29нда, 1868 ел. Казан*

Адрес: В Москву, против Данилова монастыря, в собственном доме, купцу Абдул Насыровичу господину Казанскому.

*Сургуч белән Каюм Насыйриның шәхси мөһере басылган.*

*819 т., III кисәк, № 8*

Гыйззәтлү абзыйга барча тәвабигъларың илән күп дога вә сәлам. Үзем әлхәмделиллаһ сәламәт. 12 ндә аугуст язылмыш хатыңны алдым. Галим абзый бер кеше йибәрде, шаять, барып йиткәндер, ләкин ул кешене мин күрә алмадым. Абдуллин әйткән кеше мәгъкульрәк булыр микән дип белгән идем. Галим абзый кыйлган эшне бозасым килмәде — күрерсез, ярамаса кайтарып йибәрерсез. Абдуллин әйткән кешене кыйммәт сорай дип әйткәндер, һәр нә булса, хәерле булсын. Бу ел барып булмады, өйгә күп кайтып торып һәм булмады, училище өчен фатир хлопоты күп булды. Бу эштә бер дә ихласым юк, нә кыйласың, хат берлән сөйләшеп бетереп булмай.

Аллага шөкер, шәһәр тыныч, көннәр салкын. Шаять, 20 лә-

---

[1] Тәвабигъларың — кул астындагы кешеләрең.

[2] Иннә лилләһи... — Алла биргән, Аллага кире әйләнеп кайтачак.

рендә өйгә бер кайтып килермен һәм килгәч, бер хат язармын. Бәлки, 25 ләренә чаклы өйдә булырмын.

Габделкаюм Габденнасыйр углы.

*Август 15ндә, 1872. Казан*

*819 т., III кисәк, № 9*

*Сургуч белән Каюм Насыйриның мөһере басылган.*

Гыйззәтлү абзыйга вә Габделмәнгә күп дога вә сәламнәр бәгъдендә үземез әлхәмделилла сәламәт. Хода теләсә, Галим абзый белән шимбә көн Мәскәүгә чыкмак ният итеп торамыз. Билетем юк иде, билет алырга киттем. Байтак кичегелде, вакыт аз калып бара, хәерле булсын. Галим абзый да барырга һәвәс иткәч, агай-эненең мәрзасы булсын[1] дип, барырга решит ителде, күренмәгән бер-бер төрле манигъ булмаса.

Әл-бакый гыйнд-эт-тәлякый догагуй[2] Габделкаюм бине Габденнасыйр бине Хөсәен бине Әлмөхәммәт бине Габделгазиз бине Бикәй бине Йосыф бине Габдерразак бине Бәйраш эл-Болгари.

*Август 2ндә, 1873 ел*
*Казан*

*819 т., II кисәк, № 10*

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Гыйззәтлү абзый вә һәм җиңгәйгә күп дога вә сәламнәрем бәгъдендә үзем әлхәмделилла сыйххәт-сәламәт. Майның 29нда язган бер хатыңны алган идем, гаҗәп, хат язмайсың. Бер өч хат яздым: май 27ндә вә һәм 29нда вә һәм июньнең 12ндә. Алдыңмы, алмадыңмы? Соңгы хатым берлә ящикләр капитансәсен салган идем үз исемеңә. Быел Мәскәүгә бармакчы идем, имди нишләргә белмәймен, үзеңдән хат булмагач. Әмма июльнең 17 ләренә чаклы, бәлки, егермеләренә чаклы монда торылыр, андан соң буш вакыт була. Әллә бер-бер төрле тынычсызлык, хафалык бармы? Югыйсә хат язмай ничек түзәр идең? Алай да язарга кирәк иде. Сиңа язып ни файда, диярсең, ләкин минем хатыма каршы хат язмадың, хосусән капитансә берлән соңгы хатыма.

---

[1] Мәрзасы булсын — күңеле булсын.
[2] Догагуй — дога кылучы.

Анда тагы әткәйләр Габделхәй кайта дип көтәләр, имеш. Черт та не разберет эшегезне. Мин монда ишетәмен: өйгә кайтам, дип, Габделхәй хат язган, имеш, дип. Әмма бүген Мөхәммәтҗан абзыйны күрдем, ул авылдан йөреп кайтты. Кайтмас әле, дияр. Дәхи әйтә: Киевтән соң Габделхәй эчмәй башлаган иде, яхшы булган иде, Казандан йөреп кайткач янә эчә башлаган, ди. Ул какой тукран тәүбәсе? Син ачулансаң да, бу сүзләрне яздым, гаеп итмә, бик хафаланып киттем. Эчем пошкан саен бер хат язам, хәтта көн саен, берсе дә йибәрелмәй кала. Ни була, хәл-әхвәлдән бер хат язып мине шатландырсаң? Син безгә ага, мин сиңа эне, синнән кечкенә булсак та филҗөмлә[1], акылымыз да бар, син аны уйлама, вә һәм сөйләшә дә беләмез, тел ачыла башлаган. Ләкин синең чаклы ук тыкыл-пыкыл белмәсәк тә, ыкыл-мыкыл беләмез. Һәрбер тыкылның бер быкылы бар, дип әйтсәң дә, һәрбер ыкылның бер мыкылы да бар икән, аны да бел син. «Тутый» китабында да әйтә: «Ликөлли мәкамин мәкаль, вә ликөлли урманин чакал[2]»,— дип. Әмма Мәскәүдәге чакаллар монда кайтып та чагалар. Чакал дигән дә яман нәрсә икән. Бер хатын да әйткән, имеш: [...]. Урманда утын кискәндә җомычкасы әллә кая чәчрәп төшә. Яманат күтәргән, кулына тубал берлә бук күтәргәннән дә яманрак. Урыс та әйтә: «Добро дома лежит, зло далеко бежит».

Мөхәммәдҗан абзый хафаландырды: әллә нидәй хлопоты бардыр, әллә ничек, кеше керткән фатирына, ул да бетмәгән, вә һәм марҗасы берлә дә бер-бер төрле эшләр булмады микән, ди.

Адрес: В Москву, Казанскому татарину Абдулхаю Насырову близ Данилова монастыря в собстенном доме или: у Ильинских ворот, на семянной лавке, Якову Ивановичу г.Иванову с передачею татарину Абдулхаю Насырову

*819 т., III кисәк, № 2*

Энесе Габделвәлигә:

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Гыйззәтлү энемез Габделвәлигә күп дога вә сәламләремез бәгъдендә үземез әлхәмделилла сыйххәт-сәламәтләрмез. Бәгъдә апрельнең 19нда вә һәм 23ндә язган хатларыңны алдым,

---

[1] Филҗөмлә — җыеп әйткәндә.
[2] Ликөлли мәкамин ...— һәр урынның мәкале бар, һәр урманның шакалы бар.

ләкин бик кыска язасың такыя[1] вә һәм кәмәр[2] дип. Үз кәмәремне йибәримме яки ясатып йибәримме? Ләкин үз кәмәремне Ханга йибәргән идем, сатылмай кайтса, йибәрермен. Анда берәүгә-берәүгә сатарсың. Бу хатны алгач хат язарсың. Әгәр Кореннойга бармасаң, пушты берлән булса да такыя йибәрермен, кәмәрне һәм вакыты берлән бер-бер йибәрермен. Язасың, ышанмаймысың, дип. Ышанмагандан түгел. Үзең беләсең, мин достаткалы кеше түгел, айдан-айга кой-как җүнәтәмен, кеше шикелле кысып тора белмәймен. Әмма постау монда да бар, әллә бәясе схутныйрак булыр дип сиңа кушамын.

Абзый апрельнең 22ндә Мәскәүгә чыгып киткән иде, бу көннәр, иншалла, Мәскәүдә булса кирәк. Үзем абзыйдан соң Чыршы Габдидә торып торамын рамазан беткәнче. Әткәйләр сәламәт, ләкин Биби бик авыру, имеш. Ганидән хат алдым, кайтамын, дип язадыр. Бу хат берлән бергә абзыйга һәм яздым, ләкин бер пакет эченә тыкмадым. Әгәр кәмәрем сатылса, үзеңнең кәмәреңне ясатып йибәрермен, әмма тиз дип әйтә алмаймын, сәбәбен югарыда яздым.

Вәссәлам. Дагый агаңыз Габделкаюм бин мулла Габденнасыйр.

*Май 1ндә, 1858*

Адрес: В Москве, у Ильинских ворот на семянной лавке, Якову Ивановичу г-ну Иванову, с передачею Валею Насырову, ему самому.

*819 т., II кисәк, № 1*

Энем Габделвәлигә сәлам бәгъдендә үзем әлхәмделилла сәламәт. Үзендән бер хат юк. Миңа күп җәбер иттең. Әллә эшләпәңне миңа унике тәңкәгә исәпләп калдырдыңмы? Мин эшләпәңне кигәнем юк һәм кимәмен. Ничек булса да ул акчаны җүнәтеп йибәр. Син болай яхшылыкка каршы яманлык кыйлма. Инде бу еллар эш үзеңә мәгълүм. Үзем дә кой-как торамын. Кави да рәнҗидер. Нуябр башында йибәрмәкче булып киттең, икенче нуябр йитәдер. Мөфти артыннан көткән идем, б... та юк. Хәер, Вәли, шулай кирәкме? Бер хосуста бик акча кирәк булгач, унйиде тәңкәгә алган сәгатьне ун тәңкәгә бирдем. Бу миңа файда түгел ләбаса. Бар да синең кәсафәтең[3].

---

[1] Такыя — түбәтәй.
[2] Кәмәр — билбау.
[3] Кәсафәтең — начарлыгың.

Мин сине монда ун көн тәсәлла кыйлдырдым[1], мөмкин кадәр көмеш акчаларны сатып.

Габделкаюм Габденнасыйр углы.

*Май 28ндә, 1862*

Адрес: В Москву, на Стреженьке, с передачею татарину Абдулвалию Насырову.

*819 т., IV кисәк, № 2*

Энесе Габделкавига:

Гыйззәтлү әнкәмезгә вә мелла Кавига дога вә сәламнәрем бәгъдендә абзыйдан хат алып һәм сезгә йибәрәмен, укып күрерсез. Мәскәүгә чакырадыр. Галим абзый һәм барырга исәбе бар. Күп уйлап карадым, миңа бару бер дә тугры килми. Минем монда да эшем йиткән. Бары шул гына: бармасаң үпкәләр. Берәүгә ачу итеп, икенчегә файда итми торган гадәте бар икәне мөҗәррәб[2]. Үзем монда килгәнемә дә үкендем. Сираҗи белән яңадан кайтып китәргә кирәк иде. Үзем дә бик сау түгел. Ни мәслихәт кыйласыз. Әгәр мәслихәт булса, бер айлык билет алып йибәр яки үзең кил, Козловкага чаклы бергә барырмыз, Галим абзый белән. Расхотыңны мин түләрмен. Расхотка Мортазадан алырга кирәк булыр. Анда кайтып, Козловкага аннан барып утырсак, парохотта бик тыгыз булыр. Яхшырак монда: элгәрерәк барып урын алырга мөмкин. Дүшәнбеләрдән калмасак иде. Билетсыз тыныч буламын дип беләм. Галим абзый белән анда кереп китсәк тә булыр иде. Үзенең ирадәсе шулай. Ләкин мин расхот тотып барыйм, ул күршегә кереп ... бу не приятно, кайтканда керермез.

Габделкаюм Рәззакый.

*26 июль [1873 ел]*

*819 т., I кисәк, № 5*

## Төрле кешеләргә язган хатлары

Галиәскар Гаффаровка:

Гыйззәтлү Галиәскар Гаффаров хәзрәтләренә дога вә сәлам бәгъдендә мәгълүм ула: мәктүбеңез илә ике сум акчаңызны юлыгып, бәрабәренә китаплар йибәрдем, ләкин пуштыга 46 тиен акча чыкты. Әгәр дә яңадан китаплар соратсаңыз, пушты өчен үзенә тәгаен кыйлып йибәрерсез.

---

[1] Тәсәлла кыйлдырдым — күңел юаттым, тынычландырдым.
[2] Мөҗәррәб — сыналган.

Янә сезләргә йибәрергә мәгъкуль китаплар күренмәде. Бәгъзе китаплар булса да, телләренә разый түгел. Анадан сөт имгәндә үгрәнгән тел белән китап тасниф кыйлмайлар, гыйлем теле вә фән теле үзенә башкадыр.

Ән-Насыйри.

*Июль 9нда, 1892*

*Ачык хат кәгазенә язылган.*

Адресы: г.Тургай, Галиаскару Гаффарову.

*819 т., IV кисәк, № 6*

Салих әфәндегә:

Гыйззәтлү борадәрем мелла Салих әфәнде җәнабларына дога вә сәламнәр бәгъдендә безләр әлхәмделилла сәламәт. Бәгъдә 22 июнь язылмыш мәктүбеңезне алдым һәм галә-л-фур[1] сораган китабыңызны пучтага салдым. Ләкин бераз кичекмәгенә сәбәп: үзем өйдә юк идем, Оренбурхта идем. Июль 17ндә кайтып, яңарак китаплардан: бер данә «Лөгате рус», бер данә «Зирагат», бер данә «Кавагыйде китабы», бер данә «Иршад-эт...»*, бер данә «Җәгърафия» йибәрдем һәм Галиевтәге акчаңны алдым. Шул акчаңыз бәрабәренә мәзкүр китаплар йибәрдем. Моннан башка янә бер «Җәгърафия» (Азия кыйтгасы хакында) басылып тәмам булгач, мәгълүм итәрмен. [...] миндә бар: «Фәвакиһелҗөләсә», [...], «Тарихе рус» [...] вә гайреләр. Әмма бастырырга китаплар күп, ләкин бастырып чыгармак гаять мөшкелгә калды. Үземдә булмаган китапларны һәм йибәрмәк мөмкин. Хаҗәт булса соратырсыз.

Әд-дагый Габделкаюм ибн Габденнасыйр ән-Насыйри.

*18 июль, 1893 ел*

*819 т., IV кисәк, № 5*

Бәдигъ әфәндегә:

Сезки борадәремез мелла Бәдигъ әфәндегә сәлам. Июль 9нда язылмыш хатыңны алдым. Безләр сәламәт. Каргалыга барып килдек. Оренбурхның әтрафы һәм коры икән, һичбер яшел нәрсә юк, ләкин эчендә бакчалары күп икән. Каргалы шәһәре кәзалик коры йирдә утырган икән. Һава бик эссе, сирәк-сирәк ягъ-

---

* Хатның аскы читләре таушалган, ертылган, укылмас хәлгә килгән. Шул урында күп нокталар куелды.

[1] Г а л ә - л - ф у р — тиз, шунда ук.

мурлар бар. 15 июльгә чаклы монда булсак кирәк. Эшләр урта кырлы. Кымыз монда да күп икән, казак хатыннары урам буенча сатып йөриләр.

*[Июль, 1893]*

*819 т., IV кисәк, № 4*

Студент Писаревка:

Милостивейший государь!

Прошу Вас возвратить мне мою «Татарскую грамматику» Насырова, которую Вы взяли у меня давно, я Вашу квартиру не найду.

К.Насыров.

Адрес: В университет, Его благородие студенту господину Писареву.

*819 т., III кисәк, № 1*

Әттилмиз-әл-әгаззә![1]

Мелла Исмәгыйль әфәнденең җәнабларына бәгъдан дога вә сәлам. Минем сездә калган китапларны җыештырып йибәреңезлә. Вә һәм бер такта да булса кирәк. Хосусән «Мәвалиде сөләсә»[2] китаплары вактан ма зарур[3] буладыр.

Әт-дагый эл-фәкыйрь ибн эн-Насыйр.

*819 т., II кисәк, № 9*

Мелла Әхмәдҗанга:

Гыйззәтлү карендәшемез мелла Әхмәдҗан абзыйның җәнабе рәфгате мәабләренә[4] холусанә[5] дога вә сәламләреме бәгъдендә фәкыйрьләр лилләһи-л-хәмди вә-л-ама сыйххәт вә гафияттәмез[6].

Мелла Әхмәдҗан абзый, мән дәхи илтимас итәмен: зинһар, шул әткәйләрнең пружбасын агай-энечелек вә карендәшлек тарикы үзә, аларның файдасы җанибенә сәгый вә иҗтиһад[7] кыйлсаңызла. Вә иллә әткәйнең үпкәсе мокаррәрдер[8].

Дагый фәкыйреңез Габделкаюм вәләде Габденнасыйр.

*819 т., II кисәк, № 7*

---

[1] Әттилмиз-әл-әгаззә — гыйззәтле шәкерт.
[2] Үсемлекләр, хайваннар, минераллар турындагы фән.
[3] Вактан ма зарур — вакыты белән бик кирәк.
[4] Рәфгате мәабләренә — галилек, югарылык чыганагына.
[5] Холусанә — чын күңелдән.
[6] Гафияттәмез — сәламәтбез.
[7] Сәгый вә иҗтиһад — бер эш артыннан тырышып йөрү.
[8] Мокаррәрдер — билгеле, ачыктыр.

Мөхәммәтгалимгә:

Әгазз-эл-холк вә әкрам-эл-мәхәллә рәфгате маәб вә варисы хәзрәти Билал.

Гыйззәтлү Галим абзый җәнабләреңезгә илтимас: «Ләйлә китабы»н Бәдигъ артыннан йибәрсәңез лә. Иясе бик сорый, кайтарып бирергә кирәк. Үзем барганда онытканмын.

Адрес: За Сенной базар, по Краснорядскому переулку около Белой мечети, азанчию Мухаммедгалиму Хусаинову.

*819 т., II кисәк, № 3*

Галигә:

Гали агайга сәламдән соң мәгълүм ула: минем абзый Мәскәүдән кайткан, Нәҗмине үзе берлә алып китмәкче була. Әгәр йибәрәм дисәң, бер еллык пашпорт алып йибәр. Ике тәңкә акча йибәрдем, тизлек берлән майның унйиденче-унсигезенче числосында килеп йитсә өлгерер. Йибәрергә кеше тапмасагыз, яллап йибәреңез.

Язгучы Габделкаюм Габденнасыйр углы.

*Майның унберендә*

*819 т., II кисәк, № 4*

Мелла Хөснетдингә:

Мелла Хөснетдин абзый!

Зинһар, китапларны китермәй озатты дип, күңелеңезгә китермәңез. Хәзердә кулына акча төшерә алмай аугустка чаклы. Әмма «Тарих Пәчәви»не* алмас бугай. Әгәр алмаса, кайтарып илтермен, башкаларына акчасын тапшырырмын.

Мәгълүмеңез Габделкаюм.

*Июль 20 ндә*

*819 т., II кисәк, № 8*

## КАЮМ НАСЫЙРИГА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

Әнисе исеменнән энесе Габделкави язган хат:

Һүә Аллаһ.

Углым Габделкаюм, сиңа безки анандин һәм Габделкавидин сагынып күп дога вә сәламләремез бәгъдендә безләрне сорасаңыз, әлхәмделилла сәламәтләрмез. Канә йибәргән хатыңызга

* Пәчәви (Ибраһим әфәнде) — «Тарих госмани» китабы авторы.

юлыктык, сәламәт икәнсең һәм бу көннәр Кышкарга китмәгән икәнсең, әлхәмделилла. Безнең морадымыз синең Казанда торуың иде. Бәбкәм, ник ул кадәр офтанасың. Кышкарга барырга без дә бик җыраксынадыр идек. Ходай теләвеннән тыш булмас. Ходай Тәгалә Казанда гына торып тәгаллекъләнергә[1] насыйп итсен дип, догалар кыйлып торамыз. Амин. Йа мөгайин вә би мөтәкки бәни эл-йәмин.

Вә канә атаңның кәсебе юк, тауга-ташка караган кеби, абзаңа карап торамыз, абзаңдан килсә дип торамыз. Ындырларны алдырмаган. Бу көнгәчә чәчүдән (калган)* арышны ашап торамыз. Иншалла, ындырларны алдырсак, игенләремез бар. Вә канә сиңа монда файдалыдыр. Кышкарга барып, нә ашыйм, нә эчим, дип торганчы. Нигъмәтҗанның хатынын күрә торгансың. Нә зарлык берлән язадыр ике [иске?] вакыттагы имананы бирергә. Бу көннәрдә абзыйдан зар көтеп торамыз. Зинһар, догада була күр. Вә канә бераз ит йибәрдек, авыз итеңез Гани берлән. Вә канә бик сагындык, бер кайтып, күрсәм яхшы булыр иде. Бер тынычлагач, барып алыр идек, атымыз юк, бичарамыз, дәю газиз гомерләреңезне теләп язгучы Габделкави энеңез. Вә канә хат язарга кәгазь юк, абзый хаты кырыен кисеп алдык.

*1851 сәнә, дикәбрнең 19 нда*

Канә сиңа бал өлеше куйган, бер вакыт берлән йибәрермез.

*820 т., III кисәк, № 11*

Әтисеннән:

Каюм сиңа дога вә сәламләр бәгъдендә фәкыйрьләр әлхәмделилла сыйххәтс-әламәтләрмез. Ләкин Мәскәүдән хат-хәбәр юк, валлаһе әгълам, Одеска киткәнләрдер, вә иллә ике хатыма бер җавап булыр иде. Без һәм Ходa хаһласа[2] алтынчыларында өйгә мөтәвәҗҗиһ булсак[3] кирәк. Насыйп булса, сәламәт [булсам] гаедкә чаклы шәһәргә барырмын. Мин баргынча, миңа бер кәвеш тектереп куй, полный алты вершок[4], башы киң булсын, очлы булмасын, җомшак үкчә, манерлы шыгырдавыклы булсын. Канә бер читек бик калын, яхшы булсын, җефәк берлән каеган.

---

* Җәя эчендәге сүзләр безнең тарафтан куелды.
[1] Тәгаллекъләнергә — бәйләнештә, элемтәдә торырга.
[2] Хаһласа — теләсә.
[3] Мөтәвәҗҗиһ булсак — юнәлтсәк.
[4] Алты вершок — якынча 27,5 см

Ике аягыңа тиң булса һәм дөрест, әгәр ким булса, нур галә нур[1].

Вәссәлам. Әл-мәгълүм әл-фәкыйрь Габденнасыйр.

*Сентябрьнең 4ндә, 1852 сәнәдә.*

*820 т., I кисәк, № 1*

Углым Габделкаюм, сиңа дога вә сәламләр бәгъдендә фәкыйрьләр әлхәмделилла сыйххәт вә сәламәт. Бик зарур буладыр икән бер пичәт миңа. Мин баргынча ташка пичәт язып хәзерләп куй. Онытылган, бик хаҗәт иде «Шәрхе мулла»* китабы.

Вәссәлам.

*820 т., I кисәк, № 27*

Улым Габделкаюм вә Габделкави, сезгә дога вә сәламләр бәгъдендә йибәрдек самавыр, күлмәк-ыштаннар, өч күмәч. Хода хаһласа, имтихан үткәч, өйгә кайтырсыз. Сәгатемез йөрмәйдер, вакыт белү өчен бик зарур буладыр, хосусән төннәрдә. Андагы сәгатьне төзәлгән булса, яхшы йөрүче булса, йибәрсәңез, зиядә хуп булыр иде.

Вәссәлам.

*Декабрьнең 17ндә, 1855 сәнәдә*

*Хатның тышында* «Әхмәт хәзрәт мәдрәсәсендә Габделкаюм вә Габделкави Габденнасыйр угланнарына» *дип язылган.*

*820 т., I кисәк, № 3*

Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим.

Габделкаюм, сиңа дога вә сәлам бәгъдендә мәгълүм улына: өйгә һәнүз шөругъ кыйлганымыз юк. Егерме тәңкәгә якын өч остада йөридер. Тәфсыйлен Кави әйтер. Берәр кадак чәй, шуңар лаек шикәр алып йибәр. Кәрванындан кайткач йибәрермен, дип язадыр. Инде кайтырлар. Бу пуштыларга, иншалла, булыр. Осталарны кушкач, үзем һәм төшәрмен, Ходай теләсә, бергә һәм өйгә кайтырмыз.

Ибн мелла Хөсәен әл-мәрхүм.

*Июльнең 5 ндә, 1857 сәнәдә.*

*820 т., I кисәк, № 5*

---

* «Шәрхе мулла Җами» — гарәп теле синтаксисы буенча дәреслек.

[1] Нур галә нур — нур өстенә нур, бик яхшы.

Әнисеннән:

Бисми...

Каюм, күп сәлам. Күрәсем дә бик киләдер. Бер тәмле чәй эчкәнем юк, тәмле чәй йибәрә күр. Бездән кызганма, ярты кадак чәй йибәр. Саклап кына тотармын. Камзулым бик беткән, ничек кенә алырсыз. Янә җиңгә тотарга бар дигән иден, йибәрә күр, зинһар.

*820 т., IV кисәк, № 12*

Әтисеннән:

Угланнар, сезгә дога вә сәлам бәгъдендә без әлхәмделилла сыйххәт-сәламәтләрмез. Ләкин анаң авырыйдыр, ашамайдыр, җокламайдыр, валлаһе әгълам, кичтә бер сәгать тултырамы-юкмы. Каюм, син мин баргынча белеш дуктор Волктан* җокларга ни дару сорап белеп тор.

Лимун сорый, яхшысы бер ярты кадак-бер кадак чәй, дидер. Ходай теләсә, җомгага якын үзем һәм төшәрмен. Кайтмаган булса, аңа бигайбә, иншалла, Нигъмәтҗан һәм кайтыр.

Вәссәлам.

*Гыйнварның 13ндә*

*820 т., I кисәк, № 13*

Угылларым Габделкаюм һи вә Габделкави, сезгә дога вә сәлам бәгъдендә безләр әлхәмделилла рабби-л-галәмин сыйххәт-сәламәтләрмез, ләкин анаңның күзләре авырыйдыр. Габделхәйдән шәһәргә хатлар бар дип ишетәмен, тиз кайтамын, дип. Әмма безгә язмайдыр. Хода хаһласа, Идел катса, тәвәкъкыфсыз[1] барыр идем. Шәһәрне вә һәм сезләрне бик сагындым. Ләкин кайтырга вакыт узды, нуябер башында анда эш күп буладыр, аннан ары — якыйн.

Әл-фәкыйрь ибн мелла Хөсәен әл-мәрхүм.

*Ноябрьнең 2ндә*

*820 т., I кисәк, № 14*

---

* Докторның фамилиясе Волков булуы мөмкин.

[1] Тәвәкъкыфсыз — тоткарлыксыз.

Абыйсы Габделхәйдән:

Бисми Тәгалә.

Энем Габделкаюм, сиңа дога вә сәлам бәгъдендә үзем әлхәмделилла сәламәт. Сентябрь 6нда, 18ндә язган хатыңны алдым. Моңарчы күптән кайткан булыр идем. Ничә шарт манигъ булып, тукталдым. Иншалла, тиз кайтылыр. Үзем һәм уйлыймын, инде өйләнми дә мөмкин түгел. Әгәр өйләнергә мәйлең булса, мәслихәтен карарсың. Сиңа йөз тәңкә минем тарафтан йитешер, артык булмас. Үзең беләсең, җортта һәм берсен өйләндереп әткәй-әнкәйләр янына куярга кирәк, азмы-күпме — бар да минем зиммәдә[1]. Синдән йә башкаларыңыздан ни мәхсул[2] бар. Әткәй ни булса миңа язадыр.

Себер Гыйбай кызы хосусында шул көннәр основательный бер хәбәр көтеп торамын. Ләкин мин Себер Гыйбайның байлыгына һәвәс итмәймен. Вә иллә арада бер сүз чыккан икән, инде Ходайга тапшырдым, булса булсын. Янә башка йирләрдән сүз башлап, эш башлап йөргәнче бу яхшы. Әткәй өчен бу билгеле эш.

Әхмәт абзыйга, Галим абзыйга күп дога вә сәлам.

Үзең һәр заман миңа хат яз. Башкаларыңыз берлән хат язышып, мәслихәт кыйлышып, мөгамәлә кыйлырлык күренмәйдер. Гаҗәп хикмәте Хода, бар да пустой чыктылар. Берсендә бер җүнле эш юк.

Дагый Габделхәй вәләде Габденнасыйр.

*1858 ел, 24 сентябрь*

Сентябрь 15ндән хат бар Вәли пашпорты берлән. Вәли сентябрь 12ндә миннән хисап алып, минем хезмәтемдә түгел.

*820 т., II кисәк, № 1*

Энем Габделкаюмга күп сәлам бәгъдендә үзләремез әлхәмделилла сыйххәт вә сәламәт. 18ндән башлап 25ндә тәмам кыйлган хатыңны алдым. Шул пуштыда Исхак Баришовтан һәм колач ярым да бер аршин хат алдым. Мәгълүм улсын: хәзрәтләреңезгә бик зур эшне башкарып тәмам итеп йибәргәнсең. Бу хосуста мин бик довольный булдым. Сәламәт булсак, эшләр абад булса[3], сиңа бик матур кыз алып бирешермен. Үзеңә мәгъ-

---

[1] Минем зиммәдә — минем өстә.
[2] Мәхсул — керем, файда.
[3] Абад булса — житеш булса, алга китсә.

лүм Ачасырның Гайни мулла кызын Вәлигә ярәшеңез, дип, Вәли берлән бергә мәслихәт кыйлышып эткәйгә 25 декабрь язган идек, ул уңмаган нәрсә болай аварә булып[1] җөрмәсен. Болай эшләрне әгәр мин карамасам, шулай торып торыр, әгәр мин хәмлә кыйлсам, иншалла, бары да яхшы булыр. Ләкин Вәлигә чаклы минем кашымда син өйләнгәнең яхшы иде. Син һәм бер уйлап, миңа Киевкә һәм Мәскәүгә хат яз. Бу эш синең кашыңда мәслихәтме?

Әхмәтҗан каенагадан хат-хәбәр юк. Үзем, Хода теләсә, 9нда Вәли берлән Киев чыксам кирәк. Ләкин эткәйгә язган идем, Каюмдан акча алырсыз, дип, ул эш булмады. Бичаралар аптырап тора торганнардыр. Бүген янә йибәреп булмады. Дүшәнбе көн, иншалла, йибәрермен пушты берлән. Дөрест әйтәсең: анда чагында көн дә бәйрәм, көн дә туй, монда чагында мөфти дә бирмәкче була, улы да бирмәкче була, бусы да бирмәкче була. Барып сораганда берсендә дә юк. Ходай һәркайсымызга җүн бирсен, болар һәммәсе гыйбрәт.

Вәссәлам. Габделхәй.

*1860, гыйнвар 2ндә*

Пуштыга йибәрдем шимбә көн 9нда. Үзем чыгамын якшәмбе көн 10нда кич берлән.

18 үктәбр йибәргән әрҗәләрне алдым.

Исхак Баришов язадыр, сиңа дип хәзерләгән әрҗәләрне сатарга хәридар[2] эзләп җөриләр, дип. Аңар сәлам әйт. Аларга дип хәзерләгән әрҗәне миңа сатарга килтерсәләр, миңа файда булыр иде. Аларның фамилиясе Баришов. Монда аларга убытка юк, булса файда булыр. Ясаган әрҗәне ашарга ярамай, суга гына ташларга. Түгел сабын коярга, хәлләре юк. Әлбәттә, Баришовларга файда, очсызрак сатарлар. Пиравaт акча биреп, аварә булып җөргәнче, бу — хәзер нәрсә, ала бирсеннәр. Янә ясарга кушармыз. Хәзер булгач, хәридар эзләп, Баришовларга барырлар. Әйдә, аларга файда булсын, очсызрак алырлар. Ләкин минем бу сүземә карап, әрҗә ясарга кушма.

Эткәмезгә миндән акча йитешмәде, бүген 25 тәңкә йибәрәм пушты берлән.

Киевкә, контрактовый залда, сабын кибетендә.

Дагый Габделхәй.

*6 нчы гыйнвар, 1860 ел*

---

[1] Аварә булып — каңгырып, сугылып.
[2] Хәридар — сатып алучы.

* * *

Яңа йибәргән нәрсәләр килеп йиткәне юк. Иртәгә шимбә көн Зөягә 25 тәңкә йибәрәм.

*820 т., II кисәк, № 2*

*Хат кәгазенең икенче ягында К.Насыйри* «16 гыйнварда алдым» *дип язып куйган.*

Бисми Тәгалә.

Энем Габделкаюмга күп дога вә сәлам. Үземез әлхәмделилла сыйххәт вә сәламәт. Хатыңны алдым.

Ярминкә бетеп бара, нәрсә бетә. 15ндә кайтып чыгамыз, Хода теләсә.

Кече Урыс Шырданы марҗасын күреп сөйләшеп хат язмакчы булган идең, күренмәйдер. Кайда торганын әйтеп калдырган идем.

Галим абзый безнең авылның мәсҗете хосусында Апанаевны күреп сөйләшмәкче иде. Күрде микән, сөйләште микән, белешеп миңа яз. Ачасырда мәдрәсә эшләнеп беткәнме, юкмы? Бер дә язган кеше булмады. Белешеп яз. Тәмам булмаган булса, чана җулы беткәнче, Салабаш базарында агач алырга кирәк булыр, белешеп яз.

Әткәйләрдән хәбәрдар булып тор, миңа һәм яза тор. Сәламәт җөреп кайткач, Мәскәүдән бераз акча йибәрермен.

Калган әрҗәләр чана җулы берлән Мәскәүгә килеп йитсә икән. Су берлән йибәрергә янә ясарга кушармыз. Никадәр кирәк икәнен Мәскәүдән язармын.

Мәскәүдән хат алып торамын, сәламәтләр.

Вәссәлам.

Дагый Габделхәй вәләде Габденнасыйр.

*1865 ел, 8 нче февраль, Киев*

*820 т., II кисәк, № 18*

Энемез мелла Габделкаюмга күп дога вә сәлам бәгъдендә җәмәгатемез 16 июльдә дөньядан үтте. Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигунә[1].

Габделмән сәламәт, яхшы гына торып торадыр. Үземез аварә[2] булып калдык, Хода ахырын хәерле кыйлсын.

---

[1] Иннә лилләһи ...— без Алладан һәм Аллага кайтачак.
[2] Аварә — эшсез, бушка йөрүче.

Хода теләсә, бу хатны алгач, Мәскәү килә күр. Ялгыз калдым. Бергә-бергә мөшавәрәт кыйлышып[1], монда эшләремезне бетереп, бергә кайтырмыз. Югыйсә бик каушадым, бер эшкә кулым бармай, күңелем төшмәй, тазалыгым юк. Эшем яхшы, болганчык түгел, тиз генә бетерермез. Ләкин үз башымнан хәзер тотынып бетереп булмайдыр, читтән бер имин кеше кирәк, хосусән — син.

Янә дә ничек булыр икән, әгәр үзе һәвәс итсә, Галим абзый берлән бергә килсәңез. Җул расхотына акча кирәк булса, Мортаза байдан алырсың.

Габделхәй.

*1873 ел, 19 июль.*

*819 т., I кисәк, № 5*

Энесе Габделганидән:

Һүә әл-бари.

Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү агамыз Габделкаюм абзыйга бик күптин-күп сәлам бәгъдендә үземезне сорасаңыз — саусәламәт, сезләрнең хәер-догаларыңызда. Сезгә ничә еллар хат язганым юк һәм сездин тоже хат алганым юк. Бу ел күп файдалы эш булмады, егерме кадак алтын җудым, тольке җәй җавымлы булды, сентябрьдә җир тунды.

Сезнең ни хәлеңез бар? Бик картайдыңмы? Хәер, син бик күп ватылган кеше түгел, җул йөрмәгән. Мине тайгы ватты, хәзердә башым шаулый, колагым ишетми. Үзем ялгыз. Рабочийлар бары да урыс. Язучы тотамын тоже урыс, стряпкиләр[2] тоже урыс хатыннары. Габделвәли углын алдырыйм дип уемда бар иде, ул да вафат булыптыр. Азлап-азлап бетеп барабыз. Хат яз. Анда ни яхшы эшләр бар? Белгән кешеләргә сәлам диясезләр. Кемнәр бар дөньяда мин белә торганнар?

Вәссәлам. Язгучы энеңез Габделгани мелла Габденнасыйр мәрхүм углы.

*820 т., VIII кисәк, № 3*

Һүә Аллаһ әл-бари.

Сезки гыйззәтлү Габделкаюм абзыйга күп сәлам вә һәм мине сораган агай-энегә бик күп сәлам диясезләр. Дога вә сәлам бәгъдендә үземезне сорасаңыз, әлхәмделилла саг-сәламәт, сез-

---

[1] Мөшавәрәт кыйлышып — киңәшләшеп.

[2] Стряпкиләр — аш пешерүчеләр.

ләрнең догаларыңызда, көн борын әмре Алланыңдыр. Инде мондин Амурга ерак калмады. Ошбу Нерчин округында бары каторожный халык. Мин Бутиндә Нарәкә дигән приискада староста булып торамын. Минем кулымда өч йөз баш ат һәм йитмеш кеше. Конюхлар, камытлары, арбалары, солылары, печәннәре барчасы минем кулымда. Мин барчасын эшкә кушып җөримен ат менеп. Помошникларым под староста дишниклар, барчасы покорон булып җөриләр. Бик юаш булып, мин рөхсәт бирмәй беркайда чыкмай уйнап [кына] җөриләр. Вә канә мәгълүм уладыр Кавал Фәтхинең угланнарына сәлам диясез. Агалары Мостафа вафат булды. Башка ят хәбәр юк.

Озак гомереңезне теләп язгучы энеңез Габделгани Габденнасыйр углы.

*1867, сентябрьнең 20*

*820 т., VIII кисәк, № 2*

Энесе Габделкавидан:

Гыйззәтлү Каюм абзыйга бәгъдә-әс-сәлам. Безләр сәламәт, әнкәй бертөрле генә.

Мәгълүмеңез ула, Земский управага бер гласный член апрельнең 25ндә сайлана. Һәр авылдан душ хисабы берлән сайлар өчен берничә адәм хәзерләнде, таинки үз араларындан ярарлык кешене табып торсыннар өчен. Шул шарт берлән дигән: ягъни игүче мужик булсын, податный пахотный мужик вә һәм грамотный булсын, вә өч ел хезмәт вә һәр елга сигез йөз тәңкә вазыйфа. Ахутаң юкмы?

Кави.

*22 апрель, 1875 ел*

*820 т., III кисәк, № 7*

Төрле кешеләрдән:

Каюм әфәндедән бәгъдә илә мөстәдга. Мәгълүм итәмез, безләргә биреп йибәрсәңезлә: 10 данә «Кырык вәзир», 10 данә «Әбүгалисина», 5 данә «Кабуснамә».

Шәмсетдин Хөсәенов хезмәткәре Исмәгыйль Нәҗметдин углы.

*30 январь, 1892 ел*

*820 т., VI кисәк, № 44*

Мөхәммәтгалидән:

Әлхәмделиллаһи рабби-л-галәмин иһдина-с-сирата-л-мөстәкыйм, сезки афзал-әл-фодаләи вә әкрәм-әл-голамаи мәркәз-әлхилми вә-л-хайаи мәнбәг-эл-гыйлми вә-с-сафаи сахибу-т-тәмизи вә әһл-эл-газиз әгна биһазиһи-л-аусаф дамелла Каюм абзый хәзрәтләренә догаи хәерләремези сәнаи җәзилләремезне тәблих мәздүр кабули гыйндаллаһ мәрҗүдер. Әмма бәгъдә бу тарафдин филҗөмлә истифсар ма-фил-бал бикадри [кыскартылды...]

Мән бәгъдә мондагы укудан сөаль шәрифеңез улынса, гыйльме хисаптан «Дораб» укый башладык, дәхи естественный история укыймыз. Һәрничек Аллаһы Тәгалә абруй биреп, курс бетерергә насыйп иткәй иде. Амин. Канә мәхфи улынмыйә[1], вакытыңыз булса, андагы мәдрәсәләрнең хәл-әхвәлен язсаңыз, бик яхшы булыр иде. Чөнки Сәлах хәзрәт мәдрәсәсен ябылган дип ишетәмез, һәм безнең мәдрәсәдә укыйлармы? Аны да мәгълүм итәсез.

Дәхи дә мәхфи улынмыйә, Радлов хәзрәтләре имтихан кыйлып китте. Иншалла, күңеленә охшаса кирәк. Дәхи дә Радлов хәзрәтләре мондагы «Положение»не бастырып йибәрмәкче булган иде. Каюм абзый, шуны әйтсәңез тизрәк йибәрсә бик яхшы булыр иде. Чөнки һәркайсы талибләр, өенә йибәрмәкче булып торалар. Халык безнең монда укуымызны төрлечә сөйлиләр. Шул «Положение»не йибәрсәң өйгә, бераз карар[2] табарлар иде, дию үтенеп, гомер газизләреңезе теләп тәхрир идүче Гали бин Габденнасыйр мәгълүмеңездер.

Язылды 8 нче февральдә.

*820 т., VI кисәк, № 7*

Гыйззәтлү мелла Габделкаюм абзый җәнабеңезә сәлам сөннәт-эл-исламләремезне юлладым.

Бәгъдә — әс-сәлам бу сәнә шәһре Истамбулга чыгып булмады. Ходай Тәгалә сәламәтлек бирсә, киләчәк җәйгә чыгу касдында[3] торамын. Хәер догада буласыз.

Бу ел тәхсил[4] өчен Урда ханга* мөтәвәҗҗиһ булдым[5].

---

* Урда хан — Бүкәй хан урдасы. Башкаласы Әстерхан губернасында.
[1] Мәхфи улынмыйә — сер булмасын.
[2] Карар — тынычлык.
[3] Касдында — ниятендә, теләгендә.
[4] Тәхсил — гыйлем алу.
[5] Мөтәвәҗҗиһ булдым — юнәлдем.

Мелла Габделкаюм абзый, лөгате русиядән лөгате татарга перават улан Словар нам китап шәриф ләтыйфыңыз тәбгыда тәмам булып, почта илә безә бер-ике нөсхә йибәрәсез вә бәһасене әйтеп бер хат язасыз. Иншалла, хаккыны әда кыйлырмыз[1].

Ханга русча адрес бу тарихка: В Ханскую Ставку, Астрахань г.

*820 т., VI кисәк, № 9*

Сөләйман Аитовтан*:

Гыйззәтлү Габделкаюм абзыйга сәлам бәгъдендә мөмкин булса бүген Исмәгыйль өйләгә өйгә кайтсын, Троискидан каенагамыз киләдер. Кичке сабакка барыр.

Салкын вакытлар үткәнче кич өйгә кайтып кунганы мәслихәт булмасмы? Янә салкын тиеп авырмасын, идән бик суык, галим булырга идәндә яту шарт булса, үземездә дә идәнгә ятыр. Ибраһимга Каюм абзый килеп йөресен дип әйткән дию, сезгә һәр көн йибәрәләр. Бик җүләр вакыты, сезгә күп бимаза кыйлмый микән.

Төзәттерә торган яки ясата торган нәрсәләреңез булса, бу көннәр бездә балта осталары эшлиләр, ясаттырырсыз һәм такта-бүрәнәдәй нәрсәләр бу көнләр мәүҗүд[2].

*820 т., VI кисәк, № 19*

*Хатның читендә һәм юл араларында К.Насыйри кулы белән язылган сүзләр бар:* «Гакыл кергәнче бер-ике ел укымай торса, яхшы булмасмы?! Углыңыз бу дәрәҗәгә йитте, үзеңездәнме?!»

Габдрахманнан:

Мелла Габделкаюм абзыйга сәлам бәгъдендә шушы Дәмин исемле кешегә ун данә «Әбүгалисина», ун данә «Кырык вәзир», биш данә «Хәвас нәбатат», биш данә «Җәваһирел хикәят» биреп йибәрәсез, бәһаләрен язып йибәрәсез Шәмсетдин абзый алдырган 20 данәгә.

---

[1] Әда кыйлырмыз — түләрбез.
[2] Мәүҗүд — бар.

Үтенеп язгучы Гали Кадыйров хезмәткәре Габдрахман бин Фәйзебакир.

*820 т., VI кисәк, № 40*

Сәгадәтлү Габделкаюм абзыйдан бәгъдә иләмөстәдга. Безләргә дәхи 50 данә «Җәваһир» биреп йибәрсәңезлә. Хакын абзый бирер, моннан мөкаддәм 10 данә алган, янә 50 данә берлән.

Язгучы мәгълүм Исмәгыйль Нәҗметдин углы.

*18 июльдә*

*820 т., VI кисәк, № 41*

Сәгадәтлү Габделкаюм абзыйдан бәгъдә илә мөстәдга. Безгә 10 данә «Җәваһир» биреп йибәрсәңезлә. Икенче алганда акчасын бәрабәр бирермез, иншалла.

Язгучы мәгълүм Исмәгыйль Нәҗметдин углы Шәмсетдин Хөсәенов* кешесе.

*28 июньдә*

*820 т., VI кисәк, № 42*

Каюм абзыйга сәлам бәгъдә шушы китаплар кирәк иде: 10 «Җәваһир», 20 «Әбүгалисина», 20 «Кырык вәзир», 5 «Кабуснамә».

Язгучы Хөсәенов хезмәткәре Фәйзрахман Рахматулла углы.

*820 т., VI кисәк, № 43*

Габделкавига абыйсы Габделганидән:

Һүә Аллаһ әл-бари.

Сезки гыйззәтлү энемез Габделкавига барча җәмәгатьләреңез берлә бик күп сәлам һәм Габделхәй абзыйга улы берлән һәр икесенә сәлам диясез. Һәм Габделкаюм абзыйга, Габделвә-

---

*Шәмсетдин Хөсәенов — нашир, татар китапларын бастыруда күп хезмәт күрсәткән кеше.

ли углына сәлам диясез. Биби абыстай балаларына, һәм Сабит абзыйның балаларына, һәм Галим абзый балаларына һәркайсына сәлам диясез. Дога вә сәлам бәгъдендә үземезне сорасаңыз, әлхәмделилла, сау-сәламәт, сезләрнең дога вә хәереңездә. Көн борын әмре Алланыңдыр. Язар сүз күп иде, вакыт тар булды. Хәзер килдем калага. Пушты вакыты кыска булды. Аның өчен каласы пуштыга калсам, күп вакыт үтте. Ошбу хат берлән җибәрәмен егерме биш сум акча. Пашпорт алып җибәрәсез. Киләчәк вакытта подробный язармын хат язганда. Бу ел бик начар: арыш оны 4 сум, крупчатный 5 сум, солы 2 сум, ит 3 сум, печән бер сум поты булды. Хәзердә ул да юк. Май 16 сум, киндер мае 12 сум, шикәр 18 сум поты. Киләсе хатта һәр эштән мәгълүм кыйлып язармын. Үзең һәм яз. Һәр эшне мәгълүм итеп хат яз.

Ошбу хатны язгучы агаңыз Габделгани мелла Габденнасыйр углы.

*1879 нчы [сәнә], 23 майда*

Габделгани адресы: Забайкальск. область, Нерчинск, на прииске.

*820 т., VIII кисәк, № 1*

## ЭЧТӘЛЕК


Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы. *Х.Мәхмүтов* . . . . . . . . . 3

**Халык иҗаты әсәрләре**

Табышмаклар . . . . . . . . . . 15
Мәкальләр һәм әйтемнәр . . . . . . . . . . 22
Сынамышлар һәм ышанулар . . . . . . . . . . 43
Җырлар . . . . . . . . . . 53
Мәхбүбләрне мәдех бәянында . . . . . . . . . . 53
Һиҗран вә фирак шигырьләре . . . . . . . . . . 55
Иштиякъ, васләт . . . . . . . . . . 57
Интизар хәбәр вә сагынмалык . . . . . . . . . . 60
Һиҗран вә җәүр, мәгъшуктан шикаять вә үпкә . . . . . . . . . . 62
Фирак вә өмид васләт . . . . . . . . . . 64
Бәетләр . . . . . . . . . . 70
Казан бәете . . . . . . . . . . 70
Рус-француз сугышы бәете . . . . . . . . . . 73
Җыен бәете . . . . . . . . . . 75
Чәй бәете . . . . . . . . . . 75
Уңмаган килен . . . . . . . . . . 78
Сәламнамә . . . . . . . . . . 80
Гыйшык сүзләре . . . . . . . . . . 81
Әкиятләр . . . . . . . . . . 85
Үги кыз . . . . . . . . . . 85
Гөлнәзек . . . . . . . . . . 89
Байдек . . . . . . . . . . 91
Өч угыл . . . . . . . . . . 93
Гакыллы бала . . . . . . . . . . 96
Җүләр угыл . . . . . . . . . . 98
Салам Торхан . . . . . . . . . . 99
Төлке . . . . . . . . . . 101
Аю берлән төлке . . . . . . . . . . 102
Мәче берлән аю . . . . . . . . . . 102
Әләкче . . . . . . . . . . 102
Төлке берлән әтәч . . . . . . . . . . 103
Шүрәле . . . . . . . . . . 103
Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан — Гөлрох вә Камәрҗан әкиятләре . . . 104

## Төбәк тарихы: легендалар, риваятьләр, истәлекләр эзеннән

Алып адәмнәр . . . 166
Тәварихе Казан . . . 167
Аксак Каратун, Пугачев, Ишбулат мулла хакында . . . 176
Зөя өязе авыллары . . . 184
Казан шәһәре . . . 215
Казан шәһәрендәге мәсҗетләр . . . 216
Казан . . . 219
Некролог вә һәм кабер ташлары . . . 226
Макарья ярминкәсе . . . 228

## Татар этнографиясе материаллары

Йорт-җир . . . 231
Кием-салым . . . 233
Ашау-эчү . . . 239
Йолалар . . . 241
Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр . . . 253

## Төрле хезмәтләреннән

«Татарча-русча лөгать»тән . . . 269
«Истыйляхате гыйльме һәндәсә»дән . . . 270
«Ләһҗәи татари»дан . . . 271
«Нәмунә яки әнмүзәҗ»дән . . . 273
«Хисаплык» дәреслегеннән . . . 274
«Җәгърафия'и гомумия»дән . . . 276
«Ысулы җәгърафия'и кәбир»дән . . . 278
«Истыйляхате җәгърафия»дән . . . 281
«Гыйльме зирагать»тән . . . 282
«Иршад әл-әтбига»дан . . . 288
«Санаигъ голфания»дән . . . 292
«Мәнафигъ әл-әгъза вә кануне сыйххәт»тән . . . 295
«Кануне сыйххәт»тән . . . 296
«Кавагыйде китабәт»тән . . . 298
«Казан халкына мөрәҗәгать»тән . . . 323
Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы . . . 327
Игъланнамә . . . 335
Балаларга тәгълим бирмәк . . . 336
Әлҗаһил . . . 338
«Әхлак рисаләсе»ннән . . . 338
Аракы эчәргә гадәтләнгән кешеләргә бер-ике кәлимә сүз . . . 340
Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр . . . 340

## Хатлар

Каюм Насыйри язган хатлар . . . 350
Каюм Насыйрига язылган хатлар . . . 369

Литературно-художественное издание

*Каюм Насыри*

ИЗБРАННОЕ
в четырех томах

Том 3

(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.З.Шиһапова, С.Н.Мифтахова, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 31.05.2005.
Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 21,21. Нәшер-хисап табагы 21,06 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 экз. Заказ А-407.
Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.